# Әдәби туган як

ТУГАН ЯК

**«Шушы яктан, шушы туфрактан без»**

**проекты буенча үткәрелеп килүче**

**Республикакүләм укуларның**

**«Түгәрәк өстәл» юнәлеше материаллары**



2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ
КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР
ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ



Җәлил бистәсе – 2023 ел

**ББК 84 (2Рос=Тат)6**

**УДК 821.512.145**

**М62**

**Составители:**

Шайдуллина Л.К., руководитель проекта «Шушы яктан, шушы туфрактан без»

Галиахметова Г.И., учитель математики.

Габдрахманова А.М., учитель английского языка

**Ответственные за работу направления секции:** Шайдуллина Ч.К., Нуртдинова Г.С., Шагвалиева Г.М., Харисова И.М., Салимгараева А.М., Салихова А.Р., Мусина Г.Ф., Нуретдинова А.Г., Фархутдинова Т.Ф., Шангараева Н.Н., Бурганова А.С., Шайхелисламова Л.Ф.

**Технические редакторы:**

Гарипова А.И., ВрИО директора МБОУ «Джалильская СОШ №2»

Зиннатуллина А.И., педагог-библиотекарь МБОУ «Джалильская СОШ №2»

**Әдәби туган як**. Материалы Республиканских чтений, посвященных юбилеям писателей Сармановского района: 95-летию со дня рождения поэтессы, драматурга, заслуженного работника культуры ТАССР, лауреата премии имени Г.Тукая Гульшат Зайнашевой, 110-летию со дня рождения писателя, журналиста Соббуха Рафикова, проводимых по проекту «**Шушы яктан, шушы туфрактан без»** – пгт. Джалиль, 2023 год

**В сборнике собраны материалы конкурса конспектов (сценарий, технологических карт) уроков и внеурочных занятий, нацеленных на пропаганду творчества писателей и поэтов-юбиляров, составленных учителями и воспитателями, библиотекарями.**

**Тыңларсыңмы җырларымны**

(Г.Зәйнәшеваның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби – музыкаль кичә)

Шәфигуллина Лилия Әгъзәм кызы,

Арча 7 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы,

Арча муниципаль районы

Максат: Г.Зәйнәшеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; күренекле шәхесләр белән горурлану хисе, татар җырларына, сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү .

Җиһазлау : Г.Зәйнәшеваның портреты, китаплары күргәзмәсе, презентация, язучы иҗатына багышлап чыгарылган стенгазеталар.

1 алып баручы: Хәерле көн, хөрмәтле укучылар , укытучылар, килгән кунаклар! Бүген без "Тыңларсыңмы җырларымны" дип аталган Г.Зәйнәшеваның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби – музыкаль кичәгә җыелдык.

2 алып баручы: Татар халкы – талантларга бай халык. Бүген без халкыбызның моңлы кызы, шагыйрә, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы Г.Зәйнәшева турында сөйләрбез. Зәйнәшеваның һәр шигыре диярлек көйгә салынган. Җыр барлыкка китерү өчен аерым талант кирәк һәм шагыйрә шул талантка ия була.

1 алып баручы: Г.Зәйнәшева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр. 2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тегермән авылында уза. Ләкин апасының ире бу баланы яратмый, аны хәтта кайчакларда кыйный да.

2 алып баручы: Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була. Минзәләдән артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр. 4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар. Спектакль караганнан соң, артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, ул артист булып уйнарга ярата. Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

1 алып баручы: Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә педагогия училищесында укый. Педагогия институтында укый башлагач та, җиңел булмый аңа. Иң башта фронтта бер кешең дә юк дип, тулай торактан урын бирмиләр.Гөлшат бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри, бер елдан соң гына урын бирәләр аңа. Бик яхшы укыганы, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә.

2 алып баручы: Г.Зәйнәшева үзе Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза: ”14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесендә укыдым. 1942-1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астыдагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшь үсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек ....”

1 алып баручы: 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

2 алып баручы: Г. Зәйнәшеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 нче елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Ә хәзер  шул җыентыкка кергән берничә шигырен тыңлап китәрбез .

1 укучы “Күпме йөрдем “ шигырен, 2 укучы “Кайтырмын мин туган ягыма“ шигырен сөйли.

1 алып баручы: Г. Зәйнәшева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре, җырлары матбугат битләрендә күренә башлый.

“Туган җирем – Татарстан “ җыры башкарыла ( А.Ключарев көе )

1 а.б. Г.Зәйнашеваның туган  җир, туган як турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйланадыр, минемчә. Чөнки туган як белән бәйле  тойгы һәркеменң  күңеленә газиз. Туган як кеше өчен  кадерле, изге  булырга тиеш. Туган як  темасы  язучы иҗатында зур урын алып тора.

4 укучы ”Тәкермән“ шигырен сөйли

2 алып баручы: Г.Зәйнәшеваның  шигырьләре  күңелгә үтеп керердәй, халыкчан гадилеге, ачык аңлаешлы, музыкаль аһәңе белән аерылып тора  һәм бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер   композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп, популяр җырлар язганнар. Иң популяр җырлар туплаган “Илле җыр“ (1998) исемле китабы өчен Г.Тукай  исемендәге Дәүләт  бүләгенә  лаек була. Ә хәзер  шул җыентыкка кергән берничә җырын  тыңлап китәрбез .

“Сәяхәтче җыры“ җыры башкарыла.

1 алып баручы: Г.Зәйнашева  иҗатында  яшь буынга багышлап язылган  шигырьләр дә шактый урын алып тора. Мәсәлән: ” Тукран белән сөйләшү”, “ Кояш гомере“, “ Әбиемне яратам“ һәм башка бик күп  шигырьләрен  яратып укыйбыз, яттан сөйлибез, җыр итеп җырлыйбыз .

5 укучы ”Тукран белән сөйләшү” шигырен, 6 укучы “Әбиемне яратам“ шигырен сөйли.

“Кояш гомере“ җыры башкарыла. (Ф.Әхмәдиев көе )

2 алып баручы: Г. Зәйнәшеваның  үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Клуб сәхнәсе»  кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. Аның  “Бәхет кошым”, “Рамай”, “Гайфи бабай, өйлән давай”, “Язмышлар һәм ялгышлар” һәм башка пьесалары  тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

1 алып баручы: Гөлшат Зәйнәшева сүзләренә җырлар язган композиторларыбыз бик күп. Г.Зәйнашеваның композитор С.Садыйкова белән дуслыгы турында әйтеп үтәсе  килә. Алар иҗатташ дуслар гына түгел, җан дуслар булалар. Сара апа каты авырып киткәч, аның янында Гөлшат була. Соңыннан С.Садыйкова вафат булгач, ул кадерле дусты, иҗатташының якты образын мәңгеләштереп китап яза.

2 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел, татарлар яши торган барлык төбәкләрдә яңгырый. Аның җырлары – мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк.

“Туган авылым урамы“ җыры башкарыла.

**Җырга багышланган гомер**

(Чара эшкәртмәсе)

Габдрахманова Гөлназ Расит кызы,

А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш

төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат: укучыларны Г.Зәйнәшеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; якташ язучыларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләү.

Алып баручы:

Тугай ярып аккан чишмәләр кебек,

Саф хисләрем җырыма талпына.

Җырым кайнар чишмә булса,

Татлы суын үзем эчми,

Бирер идем хезмәт сөйгән халкыма!

Һәрбер шатлык кояш нурлары булып,

Үрли минем күңелем түренә.

Йөрәк җырларым да шулай

Кояш кебек якты нурлар

Сипсен иде туып-үскән җиремә!

«Туган җиремә» (Г.Зәйнәшева сүз.)

1 а.б. Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, укытучылар, килгән кунаклар! Бүген без гомерен җырга багышлаган шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби-музыкаль кичәгә җыелдык.

2 а.б. Сарман – талантларга бик бай як. Кайсы гына язучыны алма, сөйләп, язып бетерә алмаслык зур шәхес.

(«Очрашу җыры» И.Шакиров көе башкарыла)

1 а.б. Әле генә тыңлаган җырның авторы Гөлшат Зәйнәшева – якташыбыз, шагыйрә, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы.

2 а.б. Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 нче елның 13 гыйнваренда Татарстанның элекке Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган.

«Туган авылым урамы» (Ганс Сәйфуллин көе)

1 а.б. Авыл халкын күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында аның әтисен кулак сыйфатында сөргенгә җибәрәләр.Шагыйрәнең бала чагы моңлы-җырлы Сарманда түгел, ә Минзәлә ягы Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч мәктәпне тәмамлый. Ул Югары Тәкермән авылын үз итә, аның матур табигате, чишмәләре күңеленә юаныч, илһам бирә.

2 а.б.Тагын кайттым әле авылыма,

Төшләремә кереп йөдәтте.

Бәлки, ял иттерер авылым өе

Сагынулардан арган йөрәкне.

Чәчәк аткан яран гөле белән

Ямьле безнең авыл өйләре.

Күп күрдем мин тәрәз төпләрендә

Гөл үсмәгән чит-ят илләрне.

Алсу,кызыл,ак чәчәкләр ата

Тәрәз төпләрендә яраным.

Яран чәчәкләре арасыннан

Авылым урамына карадым.

Кечкенә Гөлшат яхшы укый, һәрвакыт белемгә омтылышы көчле булган кыз, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

Җыр «Гөлләр иле » (Сәлимә Шәмсина көе)

1а.б. Г.Зәйнәшева Минзәләдә укыган еллары турында болай дип яза: «14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесенда укыдым. 1942-1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астындагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшүсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек ...»

2 а.б. 1945-1949 елларда Гөлшат апа Зәйнәшева Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

1 а.б. Г.Зәйнәшева бик яшьли әдәбият белән кызыксына, мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтыла, авыл сәхнәләрендә, соңрак институт кичәләрендә катнаша.

2 а.б. Ә Казанда Гөлшат апа шагыйрьләр дөньясына эләгеп кенә калмый, музыкантлар, җырчылар, композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Композитор Александр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар куя. Һәм ул «Туган җирем – Татарстан» җыры белән бәйгедә җиңеп чыга. Бу җырның музыкасы дәртле, халык күңелендә туган җиренә булган изге тойгыларны әйтеп бирерлек моңлы.

«Туган җирем – Татарстан» җыры башкарыла (Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе)

Үз шигырьләрендә Г.Зәйнәшева ватанга бирелгәнлек,тормыш, аналар язмышы турында уйлануларын һәм мәхәббәт темаларын яктырта.

«Ана турында баллада» (Г.Зәйнашева сүз.) шигыре башкарыла

1 а.б. Гөлшат Зәйнәшеваның җырларын халык бик яратып кабул итә, чөнки җырларның сүзе гади, тормышчан, ә музыкаль аһәңнәре халык рухына туры килә, бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп популяр җырлар язганнар. Иң популяр җырлар туплаган «Илле җыр» ( 1998) исемле китабы өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә җырын тыңлап китәрбез .

«Сәяхәтче җыры» (З.Гыйбадуллин көе), «Үз илемдә» (Сара Садыйкова көе)

башкарыла.

2 а.б. Г.Зәйнәшева иҗатында яшь буынга багышлап язылган шигырьләр дә шактый урын алып тора . Мәсәлән: «Тукран белән сөйләшү», «Әбиемне яратам» һәм башка бик күп шигырьләрен яратып укыйбыз, яттан сөйлибез, җыр итеп җырлыйбыз .

1) «Тукран белән сөйләшү», «Әбиемне яратам», «Перәнник» шигыре укыла.

2) «Кояш гомере» җыры (Ф.Әхмәдиев көе ), «Бөрлегән» (А.Хөсәенов көе) башкарыла.

2 а.б. Г. Зәйнәшеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә шигырен тыңлап китәрбез .

«Күпме йөрдем», «Кайтырмын мин туган ягыма» шигырен сөйлиләр

1 а.б. Г.Зәйнәшеваның драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре зур игътибарга лаек. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» һ.б. драма һәм комедияләре үз заманында Минзәлә театры һәм башка татар театры сәхнәләрендә уйналып йөри, «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным жәл түгел сиңа» дигән комедияләре К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә куелды.

2 а.б. «Әкият» татар курчак театрында Г. Тукайның «Шүрәле» әсәре нигезендә язылган «И, кызык Шүрәле» спектакле куелды.

Спектакльдән өзек карау.

1 а.б. Г.Зәйнәшева сценарийлары буенча «Татарстан – Яңа гасыр» телевидениесе тарафыннан «Моңсара», «Салих Сәйдәшев», «Тузган торактан күчкәндә» телефильмнары төшерелә.

2 а.б. Тормыш Г. Зәйнәшеваны төрлечә аяусыз сынаса да, ул бөгелми, бөтен авырлыкларны җиңеп, гомере буе иҗат итә.

1 а.б.Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге олуг хезмәтләре өчен Г.Зәйнәшева «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

2 а.б. Гөлшат Зәйнәшеваның иҗаты безгә көч, дәрт, илһам бирә. Яшь буынны яшәргә, туган якны, тормышны яратырга өйрәтә.

Кичәбезне Г.Зәйнәшеваның «Мин тормышка гашыйк» шигыре белән тәмамлыйсы килә.

Кая барсам, якын дуслар табам,

Дуслар белән озын юл кыска.

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Чишмәләрнең җырын отар идем,

Җыр өйрәнер идем һәр коштан.

Әллә кошлар матур сайраганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Озак яшәрмен дип тибә йөрәк,

Ашкына күңелем һәр эшкә.

Әллә эшем бәхет китергәнгә,

Мин тормышка гашыйк, тормышка!

**Туган ягым – гөлләр иле**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗатына багышланган әдәби музыкаль кичә)

Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы,

Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы,

Адлер Тимергалин исемендәге Иске

Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат: Якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнәшева иҗаты һәм аның балалар өчен язган шигырьләре белән танышу.

Көтелгән нәтиҗә: якташ язучыларны таный һәм хөрмәтли белү; аларның хезмәтләре белән кызыксынып танышу теләге уяну; иптәшләреңне тыңлый, ишетә, үз фикереңне ачык итеп әйтү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйли белү.

Кичә барышы

1 а.б: Сарман ягы халкы чыннан да бәхетле... Ул тырыш як, моң чишмәләре уянган як. Сарман үзе дә,авыллары да табигатьнең матур җиренә урнашкан. Халкы ачык, киң күңелле, талантлы, җырга- моңга бай, ярдәмчел һәм хезмәт сөючән.

Төбәгебездәге авылларыбызның, алар янындагы су-чишмәләрнең матурлыгы шагыйрьләребезне шигырь язарга һәм композиторларыбызны көй язарга этәрә.

2 а.б: Җырларда җырланган Сарман ягы, Сарман төбәге. Бу якның никадәр гүзәл икәнен аңлау, ярату өчен җәй көннәрендә аның урманнарыннан җиләк авыз итәргә, челтерәп аккан чишмәләреннән көмештәй саф суын татып карарга, кыш көннәрендә киртләч тауларыннан чаңгы шуарга, көзге урманнарында йөрергә, җыр-моңнарын тыңларга кирәк.

1 а.б: Монда һәр тау итәге, һәр агач, болындагы һәр чәчәк, кыскасы, һәрбернәрсә иҗатка, моңга, шигъриятькә рухландыра. Никадәр талантлы кешеләр чыккан Сарманнан: Аяз Гыйләҗев, Мәдинә Маликова, Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Вәсимә Хәйруллина, Рәфкать Кәрами, Адлер Тимергалин, Дамир Гарифуллин, Гөлшат Зәйнәшева, Фәрит Яхин, Хәниф Хайруллин, Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шарифуллина, Гөлдания Хәйруллина, Фәридә Сафина, Илтөзәр Мөхәммәтгалиев, Гәфифә Гаффарова!

2 а.б: Мондый шәхесләр табигатьтән, тирә-як биргән гүзәллектән тирән ләззәт алып кына калмыйлар, үзләре дә матурлык тудыралар.

Шушы талантлы кешеләребезнең берсе – шагыйрә, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты -Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева. Бүген без сезнең белән шагыйрәнең иҗатына багышланган “Туган ягым – гөлләр иле” дип аталган кичәгә җыелдык. Бу кичәдә без Гөлшат Зәйнәшеваның иҗаты белән танышырбыз, укучылар башкаруында аның шигырьләрен тыңларбыз, аның сүзләренә язылган җырлар ишетербез

1а.б: Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 январенда Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә

районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

2а.б:1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аның  югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, соңыннан 1952-1963 нче елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият булегендә редактор булып эшли.

1 а.б: Гөлшат Зәйнәшеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

2 а.б: Гөлшат Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре үрнәгендә язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән шигырьләре музыкаль булуы белән аерылып торалар,хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды.Иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Гөлшат Зәйнәшева 1991 нче елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.  . Шагыйрәнең яшьлек елларында язылган “Күл буена килсәң иде” (Зиннур Гыйбадуллин көе) җырын укытучыбыз Габдрхманова Гөлназ Расит кызы  башкаруында тыңлап китәрсез.

1 а.б:  Халык күңелен яулап алган шагыйрьләр дә табигатьнең гүзәл, сирәк бүләкләре бит. Якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе ул – Гөлшат Зәйнәшева. Заман үзгәрсә дә, үзгәрми торган күңел кылларын тибрәтерлек шигырьләр язучы, үз тавышы булган шагыйрә бит ул. Сезнең игътибарга аның ”Мин тормышка гашыйк” шигырен укытучыбыз  Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы башкаруында тәкъдим итәбез.

Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, томышка.

Чишмәләрнең җырын отар идем
Җыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Озак яшәрмен диеп йөрәк тибә,
Ашкына күңелем һәр эшкә,
Әллә эшем бәхет китергәнгә,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

2 а.б: Гөлшат Зәйнәшева  туган ягын  якын итеп , үз итеп, аның хуш исле гөлләренә гашыйк булып, үзенең иң ягымлы шигырьләрен иҗат итә. Ә шигырьләре җырлап тора. Гөлшат Зәйнәшева  сүзләренә Сәлимә Шәмсина көй язган  “Гөлләр иле” җырын  2 нче класс укучысы Калимуллина  Эльвина башкаруында тыңлап китәрсез.

1.а.б: Шагыйрәнең күпләр яратып тыңлый, укыганда күздән яшьләр китерә торган “Аерылмагыз” дигән шигыренә Чулпан Зиннәтуллина көй язган. Ә бүген исә без бу  җырны укытучыбыз  Кызрачева Нурзия  Мәрвәр кызы башкаруында ишетербез

2 а.б: Күңелендә рухи төшенкелек вакытында Г .Зәйнашеваның шигырьләр җыентыгын кулыңа алсаң, бу шигырьләр уйландыра, моңландыра, сөендерә торган җылы хисләр уята. Аның шигырьләре туган илгә, туган телгә мәхәббәт белән сугарылган. Шундый шигырьләренең берсе – “Туган җирем - Татарстан”. Аңа Александр Ключарев көй язган . Ә хәзер 3нче сыйныф укучылары башкаруында тыңлап китик.

1.а.б: Гөлшат Зәйнәшева – җор, йөгерек телле балалар шагыйре ул. Аның шигырьләре балалар күңеленә бик җиңел үтеп керә. Юморга бай кызыклы шигырьләрен балалар бик теләп ятлыйлар. Шуларның кайберләрен укучыларыбыздан сөйләтәсе килә.

1.Калимуллин Данияр ” Тукран белән сөйләшү” шигырен сөйли”

2.Сәләхтдинов Тимур “Әбиемне яратам “шигырен сөйли

3.Ямалиев Раяз “ Бөҗәкләр концерты”

4.“ Кояш гомере “җыры башкарыла. (Ф.Әхмәдиев көе ) 2 класс укучылары

5. “ Зур тугел шул, бик кечкенә бөрлегән мин ,бөрлегән ,бөрлегән генә булсам да, бар эшкә дә өлгерәм “ дип җырлап йөрергә ярата Хисамиева Аделина. Сезнең игътибарга “Бөрлегән” җыры

2 а.б: Ата-анага булган чиксез хөрмәт, мәхәббәт, аларны ярату хисе – шагыйрә иҗатында бигрәк тә ачык чагыла. Шундый шигырьләрнең берсе – “Җырлыйм әнием турында”.

3 нче сыйныф укучысы Хисамиев Айнур башкаруында тыңлап китәрбез. (Фәтхерахман Әхмәдиев көе)

1 а.б: Табигать – гаҗәеп серле дөнья, аның гүзәллеге, камиллеге кемнәрне генә сокландырмый икән дә, кемнәрне генә кулына каләм алырга мәҗбүр итми икән... Гөлшат Зәйнәшеваның “Өй артыгыз гөлбакча” (Рамиль Курамшин көе) җырын 1 нче класс укучылары башкара

2 а.б: Туган җир... Туган туфрак... – һәркайсыбыз өчен иң изге төшенчәләрнең берседер. Шагыйрә туган ягыннан еракта булса да, күңеле белән туган ягында яши, аны сагына, юксына. Аның иҗаты безгә көч, дәрт, илһам бирә. Без, яшь буынны яшәргә, туган якны, тормышны яратырга өйрәтә.

1 а.б: Шагыйрә шулай ук патриотик тәрбиягә дә зур игътибар бирә. Аның әсәрләре, күп санлы шигырьләре сугыш еллары, ятим балалар, тол хатыннар тормышы, сугыш геройлары белән таныштыра. Менә алар: “Кырыгынчы еллар комсомолы”, “Ана турында баллада”, “Миләш”, “Һәйкәл җыры”, “Зоя кебек”, “Таш һәйкәлләр”, “Авыр сугыш елларында үстем”, “Солдат гармуны”, “Кайтыр кебек кош булып”. Хәзер Җиңү бәйрәменә багышлап язылган “Җиңү бәйрәме – изге бәйрәм” шигырен тыңлап үтәрбез

Йомгаклау

2.а.б: Халык шагыйрьләрсез яши алмый. Нинди генә авыр чорлар булмасын, күңелләребезне юатырлык шигырьләр кирәк. Дистәләгән китап авторы, күпләре халык теленнән төшмәгән, йөздән артык җыр текстын язучы Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатын өлкәннәр дә, балалар да бердәй яратып кабул итә. Шагыйрәнең исеме телдән төшми, каберенә эзләр суынмый. Ул халык хәтерендә яши. Бәйрәмебезне Гөлшат Зәйнәшеваның “Нәрсә калдырам?” шигыреннән өзек белән тәмамлыйсы килә

1 а.б: Нәрсә калдырам мин, китсәм,

Бу якты дөньядан дим?..

Яктыртыр өчен тагын да

Ни кылдым мин аңа дим?..

Калса калыр бәлки моңым,

Җырым кинәт бүленеп.

Туган як каеннарының

Яфрагына эленеп.

2 а.б: Гөлшат Зәйнәшева иҗатына багышланган әдәби музыкаль кичәгә килгән барлык китап сөючеләргә, шагыйрәнең иҗат җимешләрен халыкка җиткергән башкаручыларыбызга чын күңелдән рәхмәтебезне әйтәбез, барыгызга да саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар теләп саубуллашабыз, яңадан-яңа очрашулар насыйп булсын!

## What do you know about Gulshat Zainasheva?- Гөлшат Зәйнәшева иҗаты турынданиләр беләсез?

(Уен-викторина 9–10-х класслар өчен

татар әдәбияты һәм инглиз теле дәресе эшкәртмәсе (катнаш дәрес))

Габдрахманова Алина Марсель кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы, Сарман муниципаль районы

Фахразиева Наилә Рәис кызы,

Чуар-Абдул урта мәктәбе укытучысы, Азнакай муниципаль районы

Максат: Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшеваның тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк белү, шигырен, җырларын өйрәнү. Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү; уен барышында сорауларга җаваплар табу Укучыларда Гөлшат Зәйнәшеваның иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына мәхәббәт уяту.

ТБУУГ: Укытучының гади сорауларына инглиз һәм татар телләрендә җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу төрле һөнәрләр турында мәгълүматлы булу;

КУУГ: Аралашу күнекмәләрен формалаштыру, ике телдә сөйләм күнекмәләре булдыру, индивидуаль һәм күмәк эшли белү;

РУУГ: Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;

ШУУГ: Г.Зәйнәшева иҗатына кызыксыну уяту, туган җиргә, шагыйрьгә карата ихтирам хисе тәрбияләү, укуга карата уен аркылы кызыксыну формалаштыру;

Дәрес тибы: белемнәрне үзләштерү

Ресурслар: Проектор, экран, Гөлшат Зәйнәшеваның җырлары, китаплары, дәрескә презентация

Дәрес барышы:

1. - Исәнмесез, укучылар! Хәлләрегез ничек? Барыгызда дәрескә әзерме? Әдәбият дәресен башлыйбыз. Ягез әле, балалар, тактага карыйк әле. Анда ребус бирелгән. Әгәр бу ребусны дөрес итеп чишсәк, дәресебезнең темасын белә алырбыз (ребус чишелә). Без бүгенге дәресебездә яраткан шагыйрәбез Гөлшат Зәйнәшева турында сөйләшербез, аның тормыш юлы, иҗаты турында булган белемнәребезне кабатларбыз, искә төшерербез, белемнәребезне ныгытырбыз.

T.: Good afternoon, boys and girls and our guests! I'm very glad to see you at our lesson today! Today we'll have an unusual lesson. Today we are going to speak about Gulshat Zainasheva. We'll practice our skills in speaking and reading, listening and writing. I wish you to be calm and to work well.

T.: Let's begin our lesson with the most famous and well-known poem and at the same time song "Don't part with each other"- «Аерылмагыз».

(Укучыларга җыр сүзләре бирелә. Бергәләшеп җыр җырлыйлар)

| Аерылмагыз | Don't part with each other |
|---|---|
| Күл буенда ялгыз аккош | There's a lonely swan by the water, |
| Каерылган канатлары | Its wings are broken. |
| Канатларны каера ул | Torments of being apart – that's what |
| Аерылу газаплары | Breaks the wings. |
| Аерылмагыз, аерылмагыз | [Chorus: 2x] |
| Булса да сәбәпләре | Don't part, don't part with each other, |
| Канатларны каера ул, | Even if there's a reason! |
| Аерылу сәгатьләре | Reasons for being apart – that' what |
| Ят кошны пар итмәс ул кош | Breaks the wings. |
| Ялгыз канат какса да | The swan doesn't search for a pair, |
| Бездә бергә булалмабыз | Though it's flapping the wings all alone. |
| Сулар үргә акса да | And we won't be able to be together too, |
| Ялгыз аккош күргән саен | Even if the rivers start flowing back. |
| Өзелә бәгерләрем | [Chorus: 2x] |
| Нигә без бергә чакларнын | Everytime I see a lonely swan, |
| Белмийбез кадерләрен | My heart bleeds. |
| Күл буенда ялгыз аккош | Why we don't appreciate the moments |
| Каерылган канатлары | When we are together? |
| Канатларны каера ул | There's a lonely swan by the water, |
| Аерылу газаплары | Its wings are broken. |
| Аерылмагыз, аерылмагыз | Torments of being apart – that's what |
| Булса да сәбәпләре | Breaks the wings. |
| Гомерләрне кыскарта ул, | [Chorus: 2x] |
| Аерылу сәгатьләре | Don't part, don't part with each other,[24] |
| | Even if there's a reason! |
| | Reasons for being apart – that' what |
| | Shortens the lives. |
| | Reasons for being apart – that' what |
| | Shortens the lives. |
| | Don't part with each other, my friends |

T.: Great!!! Wonderful!! Thanks you all!!!   It is a great song. Now let’s remember who is Gulshat  Zainasheva . Pupils have prepared little information about her biography. Let’s listen to them together.  And let's look at some places related to her life.

(Укучылар Гөлшат Зәйнашеваның  иҗаты,тормышы турында белгәннәрен сөйлиләр).

Pupil 1. 

Gulshat  Zainasheva is one of the most famous poets of modern Tatar literature.  Gulshat Hisamovna Zainasheva (January 13, 1928 — April 1, 2005) was a Tatar poet and playwright. Gulshat Hisamovna Zainasheva was born in the village of Staroe-Klyanchino (now in the Tukayevsky district of the Republic of Tatarstan). She was born in a large peasant family. The father was dispossessed and exiled to Arkhangelsk, and Gulshat was given to another family for upbringing. Gulshat's childhood years were spent in the villages of Takerman, Kuzembetevo-1928 елның 13 гыйнварында Татарстан АССРның Чаллы кантоны (1930 елдан Сарман районы, 1937 елдан Ворошилов районы, хәзерге Тукай районы) Иске Теләнче исемле авылда урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. 1930 елда, авыл халкын күмәк хуҗалыкларга берләштерү чорында, гаиләләрне «кулак» тамгасы белән читкә сөргәндә, әти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә калдыралар. Балачагы шул авылда уза. Югары Тәкермәндә башлангыч, Хуҗамәттә җидеәллык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлагач, 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Pupil 2.

Gulshat Zainasheva graduated from the Menzelin Pedagogical College, then entered the Kazan State Pedagogical Institute at the Department of Tatar Language and Literature.

In 1949 Gulshat Zainasheva joined the radio committee as an editor of literary broadcasts. In 1952-1963, she worked as a literary editor of the Tatar Book Publishing House, then as an editor of musical broadcasts of the Tatar radio, director of the G.Tukai club of the Union of Writers of Tatarstan. In 1973-1983, the activity of G. H. Zainasheva was again associated with the Tatar Book Publishing House, with which most of her work biography is associated.

Pupil 3.

In the late 1959s, her publications appeared for the first time: her poetry collections «Моему современнику», «Жить с песней!», «Страна цветов». Many songs based on the poems of Gulshat Zainasheva were included in the golden fund of Tatar culture. Many of Gulshat Zainasheva 's poems are dedicated to her native places

Gulshat Zainasheva's work was also associated with Tatar drama.

His talent was admired by many people. Gulshat Zainasheva was also the author of screenplays, essays and documentary stories, which were devoted to the work of outstanding figures of Tatar culture.

Since 1969 — member of the Union of Writers of Tatarstan.

Беренче иҗат тәҗрибәләре — шигырь, җыр, эстрада әсәрләре,үзешчән драма түгәрәкләре өчен язган бер пәрдәле пьесалары — вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыккан. Зур күләмле «Рамай» пьесасы халык театрлары сәхнәсендә уңыш казана. 1958 елда лирик шигырьләре тупланган «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1958-2005 елларда авторның төрле жанрда язылган ике дистәдән артык китабы басылып чыккан.

Pupil 4.

Tatar literature and art have suffered a heavy loss. On April 1, Gulshat Hisamovna Zainasheva, a well-known Tatar poet and playwright, winner of the G. Tukai State Prize, died after a serious illness.

T.: Thank you. I hope, you've enjoyed it. Now it's turn to read an extract from her poems (Балаларга әсәрдән өзекләр таратыла )

Famous poems on which songs were written: «Тәкермән»

- «Җәйге урман»
- «Сәяхәтче җыры»
- «Минзәлә юллары»
- «Кайтырмын мин туган ягыма»
- «Ай кебек син»
- «Яшь гомер»
- «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә»
- «Урманнарда йөрдем»
- «Туган авылым урамы»

Performances:

- «Бәхет кошым»
- «Рамай»
- «Гайфи бабай, өйлән давай»
- «Язмышлар һәм ялгышлар»

Songs: Зәңгәр төймә
Зөһрә йолдыз
И Идел, Иделкәем
И, кадерле Норлатым
Идел кичтем, дәрья гиздем
Идел суы ага торыр
Илдарым
Илеш авылы
Иртә дә генә торам…
Иртәнге җыр
Исеңә төшәрмен

Бер күрешү — бер гомер
Буразналар
Бәхет кошым (беренче вариант)
Бәхет юллары
Бөрлегән (икенче вариант)
Бөтен нәрсә сине хәтерләтә
Вакытлыча түгел
Ветераннар җыры
Газинур урманы
Гармункаем, дускаем
Гармунчы
Гимназиядә дуслаштык
Гитара
Авылым гөлләре
Аерылмагыз (беренче вариант)
Ак пароход (беренче вариант)
Акбүз атлы егеткә
Акбүз атым (беренче вариант)
Аккошка әверелдең…
Акъяр көе
Ардуан батыр
Ат кирәк безгә!
Баулы (икенче вариант)
Без үзебез Камкалы
Без — Казан кызлары
Без — табигать дуслары
Безнең кардәшлек
Дустыма
Авыл көе (беренче вариант)

Бер атнада ничә көн?..
Гөлләр иле
Зәйнең үз акчарлагы

Т: Әйдәгез әле уен уйнап алыйк. Белемнәрегезне сынап карыйк.Әзерме? Киттек.

Quiz by Gulshat Zainasheva

1- INTELLECTUAL GAME – интеллектуаль викторина

Students, look at the board. You can see a table with 14 questions. Each team need to choose 5 questions.

If the team cannot answer one of these questions, other teams can continue to answer and get an additional point.

1.What was Gulshat  Zainasheva ? Гөлшат Зәйнәшева кем ул?

Tatar poet, playwright, editor, publicist, musicologist(музыковед)

2.  When was she born? Гөлшат Зәйнәшеваның туган көнен әйтегез.

13January, 1928

3.  Where was she born?Кайда туган?

Old Staroe-Klyanchino , TASSR

4.What is  her most famous work for children? Гөлшат Зәйнәшеваның  иң популяр эшен санагыз.

Don't fly away, nightingale.

5. Where did she live when she was a child?Балачагы кайда үткән?

Gulshat"s childhood years were spent in the villages of Takerman, Kuzembetevo, Menzelinsky district of the Tatar ASSR

6. What did she graduate from?

Menzelinsky Pedagogical College

7. Why couldn't she go to university in the beginning ?  Ни өчен ул университетка керә алмый?

Admission to the institute was initially prevented by her origin from a dispossessed family, but friends helped

8.When did her publications first appear? Аның басмалары кайчан барлыкка килгән ?At the end of 1959

9. What year was Gulshat Zainasheva awarded the honorary title of "Honored Artist of the Tatar ASSR" in? Ничәнче елда Гөлшат Зәйнәшева "Татарстан АССРның атказанган артисты" дигән мактаулы исемгә лаек булды?

1988

10.What was the name of Gulshat Zainasheva's daughter? Гөлшат Зәйнәшеваның кызының исеме ничек?

Her name was Asia(Асия)

11.How many grandchildren did Gulshat have? Гөлшатның ничә оныгы бар?

Two

12. What were the names of Zainasheva's grandchildren?

Damir and Kamil

13. What age did she die at?

77 years old

14. What year did Gulshat Zainasheva pass away in and where did she die? Гөлшат Зәйнашева ничәнче елда  һәм  кайда  вафат булды?

1April 2005/Kazan

2 – CAPTAIN'S COMPETITION-  капитаннар конкурсы

Now teams choose their captains. They  get the picture, it will be your task .You need to  explain to your group that depicted in the picture. May  use different synonyms.   You have 2 minutes for the preparation and 1 minute for an explanation.

3.-Find the name of song

Be very attentively. Now you can listen to different songs. You should find the name of songs. Бик игътибарлы булыгыз. Хәзер сез Гөлшат Зәйнәшева  җырларын тыңларсыз. Тыңлаганнан сон, сез җыр исемен табарга тиеш буласыз. Әзерме? Башладык.

Pr.: Our   judges will count the points  in three competitions  and decide which  team  is winner.

The jury: The first place is …

The second place is …

The third place is …

T.: I congratulate the winner . You have shown a good result. Thank you for taking part in these competitions. Have a good day.

Укучылар, бүген без сезнең белән Г Зайнәшева иҗаты турында сөйләштек. Гөлшат Зәйнәшева кебек талант ияләре безнең арабызда үзенең җырлары, шигырьләре, әсәрләре белән яши. Ул һәрвакыт безнең белән. Катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сау булыгыз!

(Викторинада җиңүчеләргә дипломнар һәм грамоталар бирелә)

**Гөлшат Зәйнәшева шигырьләренең тематикасы**

Семенова Гөлназ Дон кызы,

Җәлил бистәсенең 3 нче санлы «Алёнушка»

балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Teләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнәшева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнәшева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Гөлшат Зәйнәшева – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, җөмһүриятебездә генә түгел, аннан читтә дә танылган драматург, шигырьләре иң күп җырга әйләнгән шагыйрә. 2023 елда аңа 95 яшь тулган булыр иде. Шагыйрә буларак, Г.Зәйнәшеваның татар балалар поэзиясен үстерүгә керткән өлеше дә зур. Аның мәктәп яшендәге балаларга һәм нәниләргә адресланган җыр-шигырьләре «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган. Рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләре «Цветы КамАЗа» дигән җыентыкта (1996) тупланган. Г.Зәйнәшеваның иң зур иҗат казанышлары җыр жанры өлкәсенә туры килә. Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов сүзләре белән әйтсәк, «Гөлшат Зәйнәшева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда Язучылар союзына член итеп кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул иткән «Менәргә иде Урал тауларына», «Китмә, сандугач» кебек рухи бай, романтик җыр текстлары дистәләп. Сүзләренә тәңгәл

килә торган киң колачлы музыка белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп, бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр».

Ярты гасырдан артык дәвам иткән иҗат гомерендә Г.Зәйнәшеваның егермеләп китабы дөнья күрә. Шулардай уннан артыгы — шигырь-җыр җыентыклары.

Ул балаларга табигать турында, салават күпере төсләре белән танышу, Яңа ел җырлары язган. Табигать темасына мөрәҗәгать итү, әйләнә-тирә мохиткә соклану, аны зурлау балаларда бары тик уңай сыйфатлар гына тәрбияли, гүзәллекне күрә белергә өйрәтә, ә бу, үз чиратында, әти-әниләргә, туган телеңә, газиз халкына да мәхәббәт уята, дуслык бәйләнешләрен ныгыта. Барлык текстлар да балаларга аңлаешлы, җиңел тел белән язылган. Шигырьләрдә әдәби телнең образлылыгы үзенә тартып тора, шагыйрәнең баланың эчке дөньясын тоемлавы сокландыра. Гөлшат Зәйнәшеваның балалар өчен язылган шигырьләрендә балалар белән уйнау юк, барысы җитди, ул шигырьләр баланы үз итеп, шәхес буларак хөрмәт итеп язылган. Шуңа да аларны укыган саен укыйсы килеп тора. Нәни җырчыларга шигырьләр дә һәм заманча интонацияләр, ритмлы музыка да ошар дип уйлыйбыз. Ул бик күп җырларга көй язган композитор буларак билгеле. Аның җырлары үзенчәлекле һәм кабатланмас булуы белән аерылып тора. Аларны балалар бакчаларында да һәм мәктәпләрдә дә җырлыйлар. Аның җырлары көй аһәңлелеге белән үзенә җәлеп итә, ә бай гармоник теле, балаларның табигый тавышына тәңгәлләшүе белән җырлар күңелгә үтеп керә.

Балаларга саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен Гөлшат Зәйнәшева саннар турында шигырьләр язган.

Саннар саный башласак,
Иң беренче — бер саны.
Мактап әйткән кебек, без
«Беренче» дибез аны...
Бер саны ул бер генә,
Әни дә бит бер генә,
«Әнием – бергенәм» дип
Кадерлибез гел генә.

Г.Зәйнәшеваның бишек җырларның беренче иң гүзәл үрнәкләрен безгә Тукай, Дәрдемәнд кебек классикларыбыз бирде. Алар исә фольклордагы ифрат бай традицияләргә таянып эш иттеләр. Татар халык иҗатында бишек җырлары бик күптәннән гамәли-тәрбияви роль уйныйлар. Аларның моңлы салмак көе сабый күңеленә тынычлану, рәхәтлек китерә, көй ананың гади, матур, назлы сүзләре белән тулы гармония тудыра. Бала туган теленең эчке аһәңен тәүге кат бишектә ишетә. Нәкъ Тукай язганча: «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән». Әйе, «кеше тормышында бишек җырларының урыны дәрәҗәле. Аны һәркем сабый чакның якты истәлеге итеп гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә саклый. Ул җырлар «газиз ана», «туган ил», «туган тел» кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри» Г.Зәйнәшева бишек җырларының шәхесне кече яшьтән үк үз милләтенең, үз туган иленең чын патриоты итеп тәрбияләүдә, аның күңелен югары рухи-әхлакый сыйфатлар белән баетуда уйнаган зур ролен тирәнтен аңлый. Ул да, халык көенә нигезләнеп һәм халыкчан сурәтләрдән файдаланып, «Бишек җыры»н яза:

Бакчада кошлар тынган,
Гөлләр керфеген йомган
Син дә, кызым, йом күзең,
Йокла, нәни йолдызым
Ак күгәрчен чаклы син,
Бал-шикәрдән татлы син
Йоклый тәти курчагың,

Син дә йокла, йомшагым
Яңа туган аем син,
Бер йомарлам маем син
Йокласаң; дәү үсәрсең,
Үскәч, илләр гизәрсең »

Г.Тукайның «Авыл хатынының бала тирбәткәндәге өметләре» куплетларындагыча, Г.Зәйнәшеваның лирик герое да үз баласына матур киләчәк тели, сабые күңелендә актив тормышка, зур эшләргә омтылу хисләрен бөреләндерә. Шагыйрәнең «Асия» җыр-такмагында да шушы ук мотив яңгыраш таба:

Син әле кечкенә, кечкенә,
Чикләвек эчендә теш кенә
Үсәрсең, үсеп буй җитәрсең,
Туган илгә хезмәт итәрсең

Карап үтелгән җырлар өлкәннәрнең нәниләргә мөрәҗәгате рәвешендә язылганнар. Шуңа күрә дә алардагы киңәш, теләк, үгет-нәсихәт сүзләре бик табигый яңгырый. Күп кенә текстлар исә балалар сөйләмен тәшкил итә, шул сәбәпле аларга аеруча самимилек, ихласлык хас. Автор үзенең игелекле, миһербанлы, кешелекле нәни геройлары авызыннан өлкәннәргә һәм беренче чиратта ата-анага зур хөрмәт, ярату, рәхмәт сүзләрен әйттерә:

Сабый күңелем никтер ашкына
Айга үрелә, йолдызга менә.
Үссәм иде мин әткәй-әнкәйгә
Кайгы-хәсрәт китерми генә.
Рәхмәт, әнкәем, рәхмәт, әткәем,
Миңа бик матур исем тапкансыз
Айлы төннәрдә, керфек какмыйча,
Бишек тирбәтеп, мине баккансыз.

## Йөрткән сезне язмышлар...

(Дәрестән тыш чара эшкәртмәсе)

Нуртдинова Раушания Равил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы,
Кәлимуллина Әлфия Нәҗиб кызы, китапханәче,
Адлер Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

1 нче алып баручы. 30 октябрь – сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне. 1991 нче елдан башлап, 30 нчы октябрь – сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтелә. 1921-1953 нче еллардагы репрессияләр вакытында илебездә 6 миллионнан артык кеше зыян күргән дип санала. Төрле елларда илдә барган сәясәт нигезендә репрессияләнгәннәрне тагын бер кат искә алу көне бу. Мал - мөлкәтеннән, туган җиреннән мәхрүм ителеп, илнең тормыш итү өчен шартлары булмаган ерак төньяк һәм көнчыгыш төбәкләренә сөрелгән миллионлаган корбаннарның язмышын хәтердә яңарту көне. Бүгенге көнгә кадәр аларның саны да, исәбе дә төгәл генә билгеле түгел. Төрле чыганакларда мәгълүматлар төрлечә китерелгәнен күреп була: берничә йөз меңнәр белән, хәтта берничә миллион белән дә исәпләнә язмыш йөрткән гомерләр саны.

2 нче алып баручы.

Тарих сыры катлам-катлам...
Хаклык кайда?
Кайда ялган?
Үткәннәргә күз төшерсәк,
Анык түгел хаклык һаман.

1 нче алып баручы. Хәзерге хәбәрдәрлек чорында шәхес культы корбаннары турында тарихи дөреслекне торгызу, нахакка гаепләнгән язучыларның исемнәрен халыкка кайтару, аларның исемнәренә кайчандыр атылган кара тапларны юып төшерү – җәмгыятебез алдындагы зур бурычларның берсе. Аларны онытырга ярамый.

2 нче алып баручы. Башка халыклар кебек үк, татар халкы да тоталитар режим аждаһасына үзеннән күп корбаннар биргән. Татарстан Язучылар берлеге шушы елларда иң зур югалтуларга дучар була. 1934 нче елда СССР Язучылар берлеге төзелгәч, Татарстаннан әгъза яки әгъзалыкка кандидат итеп рәсмиләштергән 30 татар язучысының уналтысы репрессиягә эләгеп, унысы НКВД тырнаклары астында һәлак була. Язучылар берлегендә ниндидер сәбәпләр аркасында әгъза булып тормаган, әмма иҗатлары, исемнәре белән халыкка танылган башка репрессияләнгән каләм ияләрен дә кушсак, әлеге сан берничә дистәгә җитә.

1 нче алып баручы.

Шагыйрьләрне атып үтергәннәр,
Төрмәләрдә яшереп буганнар;
Җырын сагынып искә төшергәннәр,
Каберенә чәчәк куйганнар.
Шагыйрь егет балта астына яткан
Кылыч үтмәс җыры хакына;
Газиз җанын өзеп утка аткан,
Нуры төшсен диеп халкына.

2 нче алып баручы. Гадәттә, без репрессия корбаннарын бер калыптан карап күз алдына китерергә гадәтләнгәнбез: чын патриотны, ялкынлы коммунистны тик торганнан, бер гаепсезгә кулга алалар, бик каты кыйныйлар, җәзалыйлар, булмаган гаебен танырга мәҗбүр итәләр һәм ахырдан ул кешене юкка чыгаралар. Күпчелек очракта шулай булган да... Әмма арада чын көрәшчеләр дә, большевистик режимның асылын аңлап эш итүчеләр дә булган. Гаяз Исхакый премиясе лауреаты, талантлы язучы, татар әдәбиятында фәнни – фантастик жанрны үстереп җибәрүчеләрнең берсе – безнең авылдашыбыз Адлер Тимергалинны шундыйлар исәбенә кертеп була. Без мәктәбебез, мәктәптә урнашкан Адлер Тимергалин исемендәге авыл музее, туган тел кабинеты батыр йөрәкле, чын көрәшче исемен йөртү белән горурланабыз. Бүген без Адлер Камил улы Тимергалинны искә алып китмәсәк, бер дә дөрес булмас иде.

1 нче алып баручы. 1949 нчы елның ахырында Татарстан Дәүләт куркынычсызлыгы комитетына кулдан язылган өндәмәләр керә башлый. Дәфтәр битендәге өндәмәләрдә коточкыч, акылга сыймый торган нәрсәләр күрсәтелгән була. Хәтта бер өндәмә “Сталинга үлем!” дигән коточкыч лозунг белән тәмамлана. Кем икәнлеге бик тиз ачыклана. Ул Казан университеты физика факультетының икенче курс студенты авылдашыбыз Адлер Камил улы Тимергалин булып чыга, ул яшәгән фатирда тентү үткәрәләр. “Җинаятьче” баш тартмый, барысын да танырга мәҗбүр була. Көндәлекләрендә барысын да җентекләп язган: ничек итеп большевистик режимның җинаятьчел асылына төшенә башлаганнарын да, күмәк хуҗалык әгъзаларының нинди шартларда яшәүләре, татар халкының теле, мәдәнияте, киләчәге турында да – кыскасы, ничек итеп режимга каршы көрәшә башлавы – барысы да теркәлгән.

2 нче алып баручы. Шуннан китә инде дәһшәтле төрмә чынбарлыгы: сорау алулар, ялгыз камерада ярым ач тотулар, салкын карцерлар, йокысыз төннәр... Ул үзе бу турыда болай дип сөйләгән:

(А.Тимергалин булып, музейда саклана торган аның киемнәрен киеп, 9 сыйныф укучысы Булат чыга)

- Юк, кыйнау – фәлән дә, җәзалау да булмады...Ә нигә җәзаларга? Мин бит берсеннән дә баш тартмадым. Әйе, мин яздым, дим. Әйе, совет властен җаным сөйми, Сталинны күралмыйм... Халкым кичергән авырлыкларның барысына да ул гаепле... Кыскасы, җебеп төшмәдем, үземне шактый кыю, хәтта горур тоттым... Ни өченме? Беренчедән, бик яшь идем әле... Мине 2 нче гыйнварда кулга алдылар. 1 нче гыйнварда миңа унтугыз яшь тулган иде. Икенчедән, мин инде җанымны фида кылырга әзер идем. Мондый коллыкта, ачлыкта – ялангачлыкта яшәгәнче, үлүең мең кат яхшырак дип уйлый идем. Шуңа да Черек күл җәлладларының янауларына исем китмәде...

1 нче алып баручы. А.Тимергалинның сүзләрен аның белән бер чорда шул ук төрмәдә утырган районташыбыз А.Гыйләҗев, Г.Тавлин, С.Рәфыйковлар да раслаганнар. Алар әйтүенчә, Адлер Тимергалинның батырлыгына, үзен кыю, горур тотуына бөтен төрмә сокланган. Барлык тоткыннар да аны чын күңелдән ихтирам иткәннәр...

2 нче алып баручы. Тоткын Адлер Тимергалинның үзен шулай тотуына хәтта тикшерүчеләр дә аптырап калалар. Акылы сәламәт кеше үзен болай тота алмас, психик яктан зәгыйфь булган кеше генә үзен шулай тота алыр дип уйлыйлар. Моны сизеп алгач, ул үзе дә тиле булып кылана башлый. Башын юләргә салып, әллә нинди тузга язмаган сүзләр сөйли, тикшерүче белән шактый куркыныч уен алып бара. Әлбәттә, Дәүләт куркынычсызлыгы органнарында башын юләргә салучыларны гына аерырлык белгечләр юк түгел. Ләкин, күрәсең, аларның үзләре өчен дә тоткынны тиле итеп күрсәтү кулайрак була. “Сталинга үлем!” дигән сүзләр белән тәмамланган өндәмәләрне акыллы баштан язып булмый ич! Ә булса, алар нәрсә караган, обком кайда булган дигән сораулар туу ихтимал бит!

1 нче алып баручы. Кыскасы, медицина экспертизасы А.Тимергалинны акылы сау-сәламәт түгел, психик яктан зәгыйфь, димәк, кылган эшләре өчен җавап бирерлек түгел дип таба. Кем белә, бәлки, табиблар бу ябык, ак йөзле яшүсмер егетне жәлләп, тормыш юлын җимермәскә теләп тә шулай эшләгәннәрдер...

2 нче алып баручы. Экспертиза нәтиҗәсендә Адлер Тимергалинны җаваплылыктан азат итәләр һәм мәҗбүри рәвештә төрмә режимындагы махсус шифаханәгә дәваланырга җибәрәләр. Ул ел ярым гомерен психик авырулар хастаханәсендә үткәрә. Махсус лагерьдан чыгу белән, Адлер Тимергалин күпмедер вакыт безнең авылыбызда, укытучы ата – аналары янында яши, аннан соң Урта Азия якларына чыгып китә. Казанда барыбер көн күрсәтмәсләрен яхшы аңлый ул. Урта Азия якларында Адлер Тимергалин институт тәмамлый, укытучы булып эшли һәм акрынлап яза башлый, соңрак фантастик жанрда эшләүче иң актив, нәтиҗәле эшләүче язучы данын ала. Бүген Адлер Тимергалинны искә алуыбыз чын көрәшче, халык өчен җанын фида кылырга әзер булган авылдашыбызга дога булып ирешсен иде.

(Адлер Тимергалин булып киенгән 9 нчы сыйныф укучы Булат аның туган авылыбызга багышланган ”Нигезем синдә минем, туган ягым, сиңа кайта минем уйларым...” шигырен яттан сөйли)

1 нче алып баручы. Районташыбыз язучы Сөббух Һади улы Рәфыйковның тууына быел җәй уртасында (15 нче июльдә) 110 ел булачак. Сөббух ага Рәфыйковны да 15 елга якын төрмәләрдә газап чиктергәннәр, 20 ел буена туган ягын кайтып күрә алмаган. 1937 нче елның 17 нче октябренда яшь язучы НКВД тарафыннан кулга алына. Аны кулга

алганда Сөббух Рәфыйковка нибары 24 яшь була. Яшь шагыйрь, прозаик, журналист, “Кызыл яшьләр” газетасында бүлек мөдире, соңыннан Татарстан китап нәшриятында редактор... Педагогия институтының читтән торып уку бүлегенең икенче курс студенты. Берничә хикәя, бер шигырь җыентыгы авторы. Әле өйләнергә дә өлгермәгән ялгыз егет. Кулга алуның сәбәбе – ул бер төркем язучылар белән бергә Галимҗан Ибраһимовка 50 яшь тулу уңаеннан аны котлап язылган күмәк хатка имза куйган икән (әлбәттә, сәбәбе ул гына булмый). Совет хәрби мәхкәмәсе С. Рәфыйковны ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә, дигән карар чыгара. Яшь әдип башта Соловки концлагерена, аннан Төньяк Себердәге металлургия комбинаты төзелешенә җибәрелә. 1947 нче елда да хөкем ителгән вакытын тутыргач та аңа туган якларына кайтырга рөхсәт итмиләр. 1951 нче елның 9 нчы июнендә шул ук элекке “җинаятьләре” өчен яңадан хөкем ясалып, әдип этап белән Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла. Норильскига сөрелгәндә дә ул әле яшь-яшь, коңгырт кара чәчле, зур соргылт күзле, аксыл йөзле, һаман елмаеп тора торган дәртле егет була.

(Рафаэль Мостафин һәм Сөббух Рәфыйков булып киенгән 9 нчы сыйныф укучылары чыга, талгын музыка ишетелә)

- Сөббух Рәфыйков, кулга аласыларын алдан белә идегезме? Әллә бәла көтелмәгәндә башыгызга килеп төштеме?

- Сизендем, Рафаэль Мостафин, минем баш өстендәге болытлар 1937 нче елның башыннан ук куера башлаган иде. Комсомолдан гына да өч мәртәбә чыгардылар – март, июль, октябрь айларында. Әүвәле кулак малае, сәүдәгәр токымы дип бәйләнделәр. Урта хәлле крестьян баласы икәнемне исбат иткәч, яңадан торгыздылар. Аннан соң “троцкийчылар”, “халык дошманнары” белән бәйләнештә булуда гаепләделәр. Анысын да кире кактым. Ахырдан инде Галимҗан Ибраһимовны юбилее белән котлап язган адреска кул куйган өчен персональ эшемне тикшерделәр.

Комсомолдан чыгару – бер хәл, эшемнән кудылар, хезмәт иткән газетамда “мораль яктан череп таркалуда” гаепләп язып чыктылар. Ул вакытта шулай иде бит: синең турында газетада мәкалә чыкты исә, бер - ике көннән Черек күлдән килеп алып китәләр. Чөнки мәкаләне дә алар кушуы буенча бастыралар, барысы да план буенча эшләнә иде.

- Черек күл җәлладлары бар “гаепләрегезне танып”, кыйнап кул куярга мәҗбүр иттеләрме?

- Кыйнау, бозлы карцер, тәүлекләр буе стена янында бастырып тоту – бер хәл... Менә, әйтик, җәлладлар сине чишендереп идәнгә яткызып сала. Берсе итек үкчәсе белән синең җенси әгъзаларыңа китереп баса. Я хәзер үк барысына да кул куясың, я фәлән әйбереңне сытып ташлыйм, имеш. Шунда нишләр идегез?

- Тикшерүчеләрнең исем – фамилияләрен хәтерлисезме, Сөббух Рәфыйков?

- Үлгәнче онытасым юк! Ләкин әйтмим. Чөнки әйтмәскә дип кул куйдым. Казаннан мине атаклы СЛОН (Соловецкий лагерь особого назначения) лагерена, Соловкига алып киттеләр. Бер елдан соң Норильскида урнашкан зур лагерьга күчерделәр. Мин анда җир казыдым, никель рудасы чыгардым, металлургия комбинатын төзүдә катнаштым. Ниндидер могҗиза белән исән калдым. Яшьлегем, тазалыгым ярдәм иткән, күрәсең.

Ун елымны көне – сәгатенә кадәр тутырып, лагерьдан чыктым. Ләкин Норильскидан китәргә рөхсәт итмәделәр – тагын биш елга гражданлык хокукларымнан мәхрүм ителгән кеше буларак, мин шул ук комбинатта НКВД күзәтүе астында яшәргә тиеш булдым. Биш елның дүртесе үтеп, туган якларга кайту турында хыяллана башлагач, 1951 нче елның июнендә тагын бер суд булды. Монысында яңа гаеп эзләп тормадылар – иске “гаебем” өчен, элеккегә өстәп, мәңгелек сөргенгә хөкем иттеләр. Сөрген урыны итеп шул ук

Норильск комбинатын билгеләделәр. (Сөббух Рәфыйков булып киенгән укучы Сөббух Рәфыйковның “Ак төн” шигырен яттан сөйли)

- Сөрген вакытында ни белән шөгыльләнергә туры килде сезгә, Сөббух яшьтәш?

- Кырыгынчы еллар ахыры – илленче еллар башы булса кирәк. Сталин әле исән, һавалар йомшара башламаган чор. Мин Норильскида управдом булып эшли идем. Октябрь бәйрәме якынлашкач, кызыл флаглар эләргә куштылар. Ә кызыл материя юк – теләсәң кайдан тап! Ничектер кызыл буяу юнәттем дә, ак материяне кызылга манып, флаглар ясап элдем. Икенче көнне иртән иртүк, эле ашарга да өлгермәгән идем, зобанилар килеп җиттеләр. “Син, контра, панимаешь, нишләп кара әләм элдең? Әллә анархистлар яклымы?” Бернәрсә дә аңламыйм. Урамга алып чыгып күрсәттеләр. Чыннан да, мин элгән әләмнәр кап-кара. Коелдым да төштем... Ярый әле НКВД начальнигы ипле кеше булып чыкты. Өйдә калган кызыл материя кисәкләрен күрсәттем. Шулардан яңа әләмнәр ясап элеп карадык. Бер-ике сәгатьтән каралдылар да чыктылар. Җил юк, салкын томан, сарылы –яшелле төтеннәр бар да җиргә ята... Ул төтендә нинди генә газлар булмагандыр... Ниндидер химик реакция булган, күрәсең. Менә сиңа экология! Ул вакытта аны уйлаган кеше бар идеме соң...

Чираттагы бәйрәм алдыннан шуңа охшаш тагын бер вакыйга булды. Тоткыннар НКВД сакчылары өчен яңа торак йорты төзиләр. Шуны кабул итү комиссиясе белән карап йөргәндә, мин су кранын ачып карамакчы булдым. Әллә катырак борганмын, әллә эшләнеше шундый гына булган – мин кагылу белән, торба каерылды да чыкты. Китте шуннан су ташкыны. Шулкадәр каты басым астында акты – астан өскә кадәр бөтен катларны су басты. НКВД хезмәткәрләренең ачулары чыкты. Мине “корткычлыкта” гаепләп, атарга җыендылар... Экспертиза ярдәме белән генә хаклыгымны раслый алдым...

2 нче алып баручы. Кайгы – хәсрәт берүзе генә йөрми, диләр. Сөббух агага “халык дошманы” мөһере сугылгач, туганнарын төрлечә кимсетүләр, җәберләүләр башлана. “Халык дошманы туганының апасы, энесе” дигән тамга аларга тыныч яшәргә ирек бирмәгән. Шуларга түзә алмаган энесе Самат Сахалинга чыгып китә. Апасы Хәерлебанат Үзбәкстанда сыену урыны таба.

1 нче алып баручы. Туган якларына ул 20 ел үткәч – 1957 нче елда гына кайту бәхетенә ирешә. Нөркәйдәге Чагыл тау, Сабит чишмәсе кайчандыр итәгендә ялан тәпи атлар саклаган, чишмә буйларында су чәчрәтеп уйнаган улын сагынган, юксынган икән шул... Авыл халкы, мәктәп өчен ул бик олы кунак иде. Аның белән очрашырга халык болыт кебек агылып килде, тәбрикләү сүзләренең, чыгышларның иге-чиге булмады.

Сөббух Рәфыйков булып киенгән укучы чыга.

- Таһир абый (Нөркәй авылы укытучысы), сорау алганда нинди генә ерткычлыклар эшләмиләр анда. Тәнеңнең карар җире калмаганчы дагалы итекләр белән типкәләүләр дисеңме, тырнак астына күгәргән кадаклар кагу, борыс белән ишек арасына кысып кул бармакларын сындыру, ирләрнең ирлек сәләтен бетерү дисеңме, берсеннән дә чирканмыйлар җәлладлар. Шул җәзалаулар хакында ирекә чыккач беркемгә дә сөйләмәскә, авызны йозакта тотарга дип, ничәмә-ничә җиргә кул куйдырулар, кимсетүләр. Аларны искә төшерүгә тәннәр чымырдап китә, йөрәк күкрәк читлегеннән чыгардай булып дөпелди. Шуңа да бу тәмугны унга, йөзгә берәүләр, бик бәхетлеләр генә кичә...

2 нче алып баручы. Сөббух Рәфыйковның авылдашы, Нөркәй мәктәбендә укытучы булып эшләгән шагыйрә Нурия Гомәр кызы Гарифҗанованың “Төрмә, сөргеннәрне үтеп исән кайткан С.Рәфыйковны авылы танымаган, кул бирмәгән...” дип башланган “Гафу сорыйм, Сөббух абый” (50, 51 нче битләр) шигырен мәктәп китапханәчебез Әлфия Нәҗиб кызы яттан сөйли.

1 нче алып баручы. Сталин Сөббух Рәфыйковның каләмен алса да, рухын җимерә, күңелен төшерә алмаган, йөрәгендәге хисен сүндерергә көчсез булып калган. Туган ягына кайтканда такта чемоданында шигырьләре кайта. “Беренче яз” романының караламасы кайта, күпме әйтелмәгән сүзләре кайта. Алда әле аның 14 ел иҗат гомере булган. Зәй шәһәре аның өчен илһам чыганагы була, калган гомерен шушы шәһәрдә уздыра ул.

Китапханәче, презентация кулланып, Сөббух Рәфыйковның биографиясе белән таныштырып үтә, әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән күргәзмә белән таныштыра. (“Соңгы талпыну”, “Үсмерчак” хикәяләр җыентыклары, “Ак төннәр” шигырьләр җыентыгы, “Беренче яз”(3 тапкыр басылып чыккан), “Авыл иртәсе”, “Тын елга буенда” калын – калын романнары. “Гел юлда, гел хәрәкәттә” булган язучының республика газета-журналларында уннарча очерклар, йөзләгән мәкаләләр, фельетоннар, шигырьләр бастыруына аерым тукталып китә. Районташыбыз Дамир Хәйрулла улы Гарифуллинның Сөббух Рәфыйков турында язылган “Норильлаг тоткыны” китабына аерым туктала)

Сөббух (Габделсөббух) Рәфыйковның шәҗәрәсе белән (Дамир Гарифуллин төзегән) татар теле һәм әдәбияты укытучысы Раушания Равил кызы таныштыра (“Норильлаг тоткыны” китабындагы фотолардан ясалган презентация ярдәмендә). Ул аның әтисе Мөхәммәтһади, әнисе Мөһривафа, туганнары (энесе Самат, апасы Хәерлебанат), гаиләсе (хатыны Хәлимә, кызлары Әлфия, Нәфисә, Сания), нәселендәге күренекле, укымышлы кешеләргә туктала (Олы Нөркәй авылының типтәр мәхәлләсе имам – хатыйбы Салих Гатаулла улы Таишев, ТР ның атказанган укытучысы Мазһар Салих улы Таишев, ТР ның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1985-1999 нчы елларда Татарстан мәдәният хезмәткәре Таишев Марсель Мазһар улы һәм башка туганнары).

2 нче алып баручы. Шагыйрь, Сөббух Рәфыйков белән дустанә мөнәсәбәттә булган Галимҗан Шакир улы Латыйповның аның якты истәлегенә багышлап язган “Тау чишмәсе кебек идең” шигырен 9 сыйныф укучысы Гөлфия башкара.

1 нче алып баручы. Сөббух Рәфыйковның сөргендә чагында ук язган шигырь – поэмаларын уку да рәхәт. 20 ел туган ягын күрә алмаса да, ул сынмаган бит, туган иленә һәм газиз милләтенә булган мәхәббәтен берчак югалтмаган! Үзен ничә еллар буе тоткынлыкта интектергән партиягә, хөкүмәткә рәнҗү-үпкәләр юк. Аның инде иреккә чыккач тудырган әсәрләреннән дә якты киләчәккә ышаныч, туган иленә чиксез мәхәббәт хисләре чәчрәп – ташып тора. Асыл патриотлар, туган җирләренең чын уллары Сөббух Рәфыйков, Муса Җәлил, Абдулла Алиш шикелле булалардыр, димәк. “Ак төннәр” шигырьләр җыентыгыннан Сөббух Рәфыйковның сөрген вакытында язган шигырьләрен укучыларыбыз яттан сөйли. (“Тундрада җәй” (63 нче бит), “Енисей”(64 нче бит), “Тәрәзәгә кемнәр карамый” (66 нчы бит), “Көртлекләр” (71 нче бит), “Боланнар” (76 нчы бит)

2 нче алып баручы. Нахак тоткынлык, нахак газаплар эзсез узмаган шул. Тоткынлыкта алган таушалулар Сөббух аганы 58 яшендә үк якты дөньядан алып киткән. Шәм шикелле, факел шикелле, бик кыска гына ара янып алган да мәңгелеккә сүнгән. Аны үзе исән чагында да Казан каласында яшәгән әдипләр кебек күтәреп йөртмәгәннәр, күккә чөймәгәннәр. Әмма якты эзе, без дистә еллар сокланып укырлык әсәрләре калган. Ул һаман безнең арада. Татар теле исән чагында аның онытыласы юк. Бүген Сөббух Рәфыйковны искә алуыбыз аңа дога булып ирешсен иде.

1 нче алып баручы. Шагыйрь, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы районташыбыз Дамир Хәйрулла улы Гарифуллинның Сөббух Рафыйковка багышланган “Без догада сиңа” шигыре белән Дамир Гарифуллинның туганы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучыбыз Сәхәбиева Таңсылу Рамил кызы таныштыра.

Арабыздан иртә китеп барган

Сөббух абый сине юксынам.
Син булмагач, күңел китек инде,
Әллә нәрсә юк сыман.
Сталинның үлем лагерьларын
Айкап йөрим күңелем белән мин.
Нинди көчләр сине сау калдырган,
Шуны әле һаман беләлмим...
Татар җаны сиңа көч биргәндер,
Юк, башкача булмас, булалмас.
Сорар өчен үзең юк шул инде,
Тик исемең мәңге югалмас.
Исемең белән ГУЛАГ ишекләрен
Мин каерып - каерып ачтырам.
Хәсән Туфан белән гел янәшә,
Гел янәшә сине бастырам.
Үз улларын зурлау, искә алу
Электәнге изге йолабыз:
Сөббух абый, сиңа чын күңелдән,
Чын йөрәктән сәҗдә кылабыз.
Син бүген дә сихри тылсым белән
Уятасың татар йөрәген.
Мөстәкыйльлек яулый барган саен
Ныграк сизелә синең кирәгең.
Безгә кирәк синең көчле рухын,
Ихтыярың кирәк, ныклыгың.
Тормыштагы авыр мизгелләрдә
Бәгырьләрне өтә юклыгың.
Рәнҗеп киттең микән арабыздан,
Җавап эзлим кайчак шуңа да.
Бөтен халык белән, Сөббух абый,
Без догада сиңа, догада.

2 нче алып баручы. Татарларның тарихы бик күп фаҗигаләрдән тора. Аның күренекле шәхесләрен яки үтергәннәр, яки алар көрәштә һәлак булганнар, яки алар зинданнарда черетелгәннәр. (Презентациядә фотолары күрсәтелеп барыла) М. Солтангалиев, Һ. Атласи, Г. Гобәйдуллин, Г. Нигъмәти, Җ. Вәлиди, М. Галәү, К. Тинчурин, Г. Гали, Г. Толымбай, Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, М. Мутин, Ф. Бурнаш, Л. Гыйльми, С. Сүнчәләйләр Совет зинданнарында җәзалап үтерелде. Г. Хәсәнәт, М. Шабай, Г. Исмәгыйлев, К. Җаманаклы, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Б. Урманче, М. Әмир, Х. Туфан, А. Гыйләҗев, И. Сәләхов, А. Тимергалин, С. Рәфыйков, Г. Ильясов, Г. Тавлин Совет зинданнарында җәзаланды. Никадәр дәүләт эшлеклеләре, хуҗалык җитәкчеләре, мәдәният әһелләре, галим, язучы, мөгаллим, рәссамнар һәм башкалар башларын салганнар... Һәлак булганнарны бер минутлык тынлык белән искә алыйк... (Метроном)

**Гөлшат Зәйнашева эзләре буенча сәяхәт**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган

дәрестән тыш чараның план- конспекты)

Сәйфуллина Гөлназ Фирдәвес кызы,

Түбән Табын мәктәп-интернатының

югары категорияле укытучы-дефектологы, Мөслим районы

Тема: Гөлшат Зәйнашева эзләре буенча сәяхәт

Максат:

1.Укучыларны Гөлшат Зәйнашева иҗаты белән тирәнтен таныштыру.

2.Фикерләү сәләтләрен , сөйләм телләрен үстерү.

3.Гөлшат Зәйнашева җырлары, шигырьләре аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның портреты, шигырьләре, җырлары, интерактив такта, презентация.

Алым: техник чаралардан файдалану, әңгәмә, компьютердагы тестларга җавап бирү, укытучы сүзе, укучылар чыгышы, җыр тыңлау, дидактик уеннар.

Дәрестән тыш чараның планы һәм барышы

I. Оештыру

Укучыларда унай психологик халәт булдыру, укучыларнын фикерләү һәм күзаллау сәләтен үстерү.

II. Актуальләштерү.

Кая барсам, якын дуслар табам,

Дуслар белән озын юл кыска.

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Бу шигырьне кем язган ? Шигырьнең исемен атагыз (Укучылар җавабы)

Әйе, укучылар, бу Г.Зәйнашеваның “Мин тормышка гашыйк” шигыре.

Гөлшат апа Зәйнашеваның шигырьләре үзе исән чагында ук кечкенә генә авыл сәхнәсендә дә, олы-олы калаларның мәдәният йортларында да яңгырый-яңгырый өйләргә күчкән, күпләрнең йөрәк түрендә урын алган.

Укучылар, бүген без дистәләгән лирик җырлар иҗат иткән шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны искә алырбыз, аның кабатланмас иҗатына тукталып китәрбез.

III. Төп өлеш.

Укытучы сүзе: Шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. Сарман районында Иске Теләнче авылында 1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Әмма бала чагын моңлы-җырлы Сарманда түгел, Минзәлә якларында Югары Тәкермән авылында үткәргән. Ятимлек сәбәп моңа – моңлы ятимлек. Моңнар әнә каян килә ул Гөлшатка. Минзәләдә ул педагогия училищесын тәмамлый, Казанда педагогия институтында белем ала. Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында

эшли. Ихтимал, бик яшьли әдәбият белән җенләнеп йөрү, мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтылу, үзешчән сәнгать һәвәскәре авыл сәхнәләрендә, соңрак институт кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булгандыр.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашева 100ләгән шигырьләр авторы. Ләкин ул бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда чагыла.  Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары- бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Гөлшат Зәйнашеваның шигъри  иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт  үзенә тарта килде. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең 100гә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессиональ  җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнде.

- Казанда Гөлшат шагыйрьләр дөньясына эләгеп кенә калмый, музыкантлар, җырчылар,  композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Композитор Александр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар  куя. һәм ул «Туган җирем – Татарстан» җыры  белән бәйгедә җиңеп чыга. Бу җырның музыкасы дәртле, халык күңелендә туган җиренә булган изге тойгыларны әйтеп бирерлек моңлы.

*Җыр  «Туган җирем –Татарстан» Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе*

- Ә ни өчен без туган телебезне белергә тиеш?

- Чөнки без туган телдә сөйләшә, аралаша алабыз, иң беренче “әти, әни” дигән сүзләрне туган телдә әйтәбез.

Дөрес, укучылар,  туган телебез – безнең иң зур байлыгыбыз. Аннан кала тагын нинди зур байлыгыбыз бар соң безнең? Без һәрберебез туган җиребезне үзебезчә күз алдына китерәбез, үзебезчә яратабыз, аны иң матур сүзләр табып мактыйбыз. Г.Зәйнашеваның туган  җир, туган як турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйланадыр, минемчә. Чөнки туган як белән бәйле  тойгы һәркемнең  күңеленә газиз. Туган як кеше өчен  кадерле, изге  булырга тиеш. Туган як  темасы  язучы иҗатында зур урын алып тора. Укучылар, ә сез Г.Зәйнашеваның тагын нинди шигырьләрен, җырларын тыңлаганыгыз, укыганыгыз бар соң? Әйдәгез эле слайдларга күз салып үтик.

Популяр җырлар исемлеге: (2 слайд)

“Туган җирем- Татарстан” (А. Ключарев музыкасы)

“Китмә, сандугач” (Р. Яхин музыкасы)

“Менәргә иде Урал тауларына” (М. Мозаффаров музыкасы)

“Үз илемдә” (С. Садыйкова музыкасы )

“Зәңгәр төймә” (халык көе)

“Күл буена килсәң иде” (З. Гыйбадуллин музыкасы)

“Кичегеп килгән мәхәббәт” (Б. Гайсин музыкасы)

“Кояш гомере” (Ф. Әхмәдиев музыкасы)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина музыкасы)

“Туган авылым урамы” (Г. Сәйфуллин музыкасы)

Шушы һәм тагын бик күп җырлары татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.  Гөлшат Зәйнашева иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле

китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Аның иҗатына танылган язучы Гариф Ахунов менә нинди бәя бирә:

3 нче слайд: “Гөлшат Зәйнашева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда Язучылар союзына член итеп кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул иткән “Менәргә иде Урал тауларына”, “Китмә, сандугач” кебек рухи бай, романтик җыр текстлары дистәләп. Сүзләренә тәңгәл килә торган киң колачлы музыка белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп, бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр”.

*Гөлфия Султанова башкаруында “ Кайтырмын“ җыры башкарыла .*

- Укучылар, автор нинди хисләр кичерә?

- Туган авылыннан аерылып киткән лирик герой сагышлана, юксына.

- Моны автор нинди чагыштырулар белән бирә?

-Үзен тау башында ялгыз калган тургай белән чагыштыра, чит җирләрдә озак йөри алмам, кайтырмын мин туган ягыма, ди лирик герой.

- Укучылар, туган ни өчен газиз, кадерле соң ул?

- Туган якта әти-әниең, туганнарың. Туган ягыңда син үзең хуҗа. Аның хәтта һавасы да дәва бирә.

Димәк, Гөлшат Зәйнашева үзенең иҗатында туган як темасына зур урын биргән.

4 слайд*: «Гайфи бабай, өйлән давай!» спектакленнән 8нче сыйныф укучылары тарафыннан өзек күрсәтелә*

Шагыйрәнең драматургия өлкәсендә дә эшләве билгеле. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

Укытучы сүзе: Карап үткәнебезчә, алтын куллы, киң күңелле, җор телле, шаян-тапкыр Гайфи бабай инде үз өендә үзе артыкка әйләнә. Кызы аңа “бай кәләш” – фатирлы әби эзли. Ләкин үзсүзле, кире Гайфи бабай отышлы тәкъдимнәрдән баш тарта. Чөнки сөекле Сабирасына, гомер иткән хатынына охшаган сөйкемле Зәкия аның күңелен яулады инде. Нишләтәсең, мәхәббәтнең үз юлы, үз язмышы…

Искиткеч җылы, хәтта сентименталь, бу спектакль шаяру-көлке белән, талантлы артистлар башкарган моңлы җырлары белән тамашачының күңелен әсир итә.

Гөлшат апа үзнең күпкырлы, бай иҗаты белән татар теле, татар мәдәнияте һәм сәнгате сагында нык торды, аяусыз көрәште. Милләтебез һәм тарих алдында Гөлшат Зәйнашеваның йөзе ак, вөҗданы пакь булды, һәм ул шулай булып кала да.

Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итте. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, сынмады. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы – табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды.

5 слайд: Китап күргәзмәсе белән танышу.

Сезгә Г. Зәйнашеваның түбәндәге китапларын тәкъдим итәм. (Китап күргәзмәсе белән таныштыра). Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган. Г.Зәйнашева – 1969 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Татар

җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

6 слайд: Әйдәгез әле, укучылар, Г.Зәйнашеваның "Әбиемне яратам" китабына күз салыйк. Бу китап Казан шәһәрендә, Татарстан китап нәшриятында 1995 нче елда бастырылган, тиражы – 5 мең данә. Бу китапта Тукай бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнашеваның балалар өчен язган көлкеле, үзе гыйбрәтле шигырьләре, җырлары туплап бирелгән. Китапка керештә мондый сүзләр язылган: "Дөньяда иң кадерле, газиз балаларым – оныкларым Дания белән Камилгә багышлыйм". Рәссамы – Диләрә Нәүрузова. Китапның тышындагы картина балалар дөньясын сурәтли. Бу дөнья – хыялый дөнья. Рәсемдәге бала сабын куыклары очырып тора, бу – аның хыяллары. Ул авыл турында, шул авылда яши торган әбисендә кунакта булганы турында рәхәт чакларны искә төшерә. Китап ике бүлектән тора, беренче бүлеге – "Шигырьләр", икенче бүлеге – "Җырлар".

Укытучы. Шигырьләр белән танышканда игътибар итегез, автор балаларның нинди тискәре сыйфатларыннан көлә икән?

1 нче укучы."Тиктормас". Бу шигырьдә әби кечкенә оныкны тиктормас булган өчен кәҗә бәтие кебек бәйләп куйган. Ул аны хәйләләдем дип уйлый, ә чынында киресенчә: оныгы аның чүәкләренә ком тутыра, ул шуның өчен тыныч. (Чүәк рәсемен экранда карау).

2 нче укучы. "Спортсмен әби". Шигырьдә лирик герой – әби, автор гипербола алымы куллана, чиктән тыш арттыра. Әби – спортсмен булган, төрле кызык хәлләргә калган.

3 нче укучы. "Пенсиягә". Авторның табышы – ул кечкенә баланы пенсионер әби урынына куеп сурәтли, шулай көлке туа. Шигырьдә чагыштыру һәм арттыру алымы кулланылган.

4 нче укучы. "Конфет". Бу шигырь күп конфет ашаганга үсмичә калган малай турында. Чиктән тыш арттыру алымы кулланылган. Автор конфет яраткан балалардан яратып көлә.

5 нче укучы. "Сагыз". Бу шигырьдә автор гел сагыз чәйнәп йөргән балалардан көлә. Әбисе аларга чын сагыз - чыршы сагызы чәйнәргә куша, жевачка дигән сагыз ул – ялган сагыз, явыз, ди.

Сез ничек ничек уйлыйсыз, Г.Зәйнашева оныкларына карата нинди мөгаләмәдә булган? Ул кечкенә балалардагы нинди зарарлы гадәтләрдән көлә?. (Ялкаулык, сагыз чәйнәү, шоколад ярату кебек әхлак гадәтләрен төзәтергә һәм ул балаларның татар телен онытмауларын тели).

Аларның шигырьләрендә киләчәк буын өчен борчылу да, ана белән бала арасындагы мәхәббәт тә, табигатькә булган соклану да, самими, эчкерсез ярату хисе дә чагыла.

Әйдәгез, укучылар, Г.Зәйнашева иҗаты буенча бәйге оештырып алыйк. Сезгә хәзер җырлар тыңлатыла, ә сез җырның исемен әйтеп бирергә тиеш буласыз.

Дөрес җаваплар: “Аерылмагыз”, ”Кара мыек”, ”Туган җирем-Татарстан”, ”Җырлыйм әнием турында”, ”Нигә ашкынасың, йөрәк?”

Укытучы сүзе: Нигездә, мәхәббәт, туган җир, табигать, яшьлеккә бәйле темаларга язылган лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге һәм музыкаль аһәңе белән аерылып тора. “Кеше китә – җыры кала”, диләр. Әмма ләкин шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны китмәде диясе килә, чөнки әле ул моңлы җыр, шигърият булып бик озак еллар татар милләтендә яшәр.

- (7 слайд): Ә хәзер, балалар, белгәннәребезне ныгыту йөзеннән төркемнәрдә тест эшләп алабыз. Тизрәк һәм төгәлрәк башкарылган эшләргә балл куела. (Алты сорау – алты бүләк).

1. Г.Зәйнашеваның туган елы.

а. 1901 б. 1891 в. 1928 г.1885

2. Г.Зәйнашеваның туган авылы.

а. Тукай районы Иске Теләнче авылы

б. Минзәлә шәһәре

в. Минзәлә районының Югары Тәкермән авылы

3. Г.Зәйнашева хезмәт юлын кайсы эшчәнлектән башлый?

а. Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире булып

б. Профессионал язучы

в. Клуб директоры

4. Авторы Г.Зәйнашеваныкы булмаган сәхнә әсәрләрен билгеләгез.

а. “Рамай”

б. “Гайфи бабай, өйлән давай!”

в. “Әлдермештән Әлмәндәр”

5. “Илле җыр” исемле китабы өчен Г.Зәйнашева нинди бүләккә лаек була?

а.Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә

б.СССР (Татартсан) Язучылар берлеге әгъзәсе

в.Рәшит Гәрәй бүләге

6. “Минем исемем Айгөл” җырын кайсы җырчы башкара?

а. Хәния Фәрхи

б. Айгөл Хәйри

в. Айгөл Бариева

Нәтиҗә ясала һәм иң күп балл җыючы укучыларга истәлекле бүләкләр тапшырыла.

IV. Йомгаклау өлеше

Укучылар, без бүген:

- Чарада нәрсә турында сөйләштек?
- Чарага нинди максат куйган идек?

Үзебез өчен нинди нәтиҗәләр ясадык?

Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына кыскача күзәтү ясадык. Чыннан да, Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты сокланырлык. Ул татар халкына нинди зур, үлемсез мирас калдырып китте. Чарабызны язучы Роза Хафизованың сүзләре белән йомгаклыйсым киләː “Гөлшат Зәйнашева популяр җырлары, шигырьләре белән үзенә һәйкәл куйды”.

Сез бүгенге чарада үзегезнең алган белемнәрегезне, Г.Зәйнашева иҗатын бик тирән белүегезне күрсәттегез. Мин моңа бик шатмын. Бик зур рәхмәт сезгә, кадерле укучыларым.

**Җырларым бар, моңнарым бар йөрәк түремдә...**

(Дәрес-концерт)

Гильфанова Гөлия Рәис кызы,

Адлер Тимергалин исемендәге Иске

Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат:

Укучыларны Г.Зәйнашеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; якташ язучыларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләү; Гөлшат Зәйнашева җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Г. Зәйнашеваның портреты, китаплары күргәзмәсе, компьютерда презентация

Сәламләү.

*Иске Минзәләбаш мәктәбе укучылары Г.Тукай премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнашевага 95 яшь тулуга багышланган “Җырларым бар, моңнарым бар йөрәк түремдә” дәрес-концерт тәкъдим итә.*

*Җыр башкарыла «Очрашу»( Г. Зәйнашева сүзләре, И.Шакиров көе)*

1 нче алып баручы. Гөлшат апа Зәйнашева иҗаты өчен кайдан шулкадәрле көч, илһам алган икән? Югыйсә ул да гап-гади бер авыл баласы бит?! Әйдәгез шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли. 1964-1965 елларда ул яңадан радиокомитетта – музыкаль тапшырулар редакторы хезмәтендә. 1965-1966 елларда исә Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубы директоры булып тора. 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Г. Зәйнашева Татарстан китап нәшриятында кадрлар инспекторы вазифасын башкара. Г. Зәйнашеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга.

*Җыр башкарыла. «Туган җирем – Татарстан» (Г. Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе)*

2 нче алып баручы. Г.Зәйнашева – бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темалар гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Г.Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып килә. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессионал

җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнә. «Туган җирем – Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Б.Гайсин музыкасы), «Кояш гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Аерылмагыз» (Ч.Зин-нәтуллина музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы) кебек җырлар татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» (1988) исемле китабы өчен Г.Зәйнашева 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Әйдәгез берәр җырын тыңлап үтик.

*Җыр башкарыла «Кояш гомере» (Г.Зәйнашева сүзләре, Ф.Әхмәдиев музыкасы)*

1 нче алып баручы. Г.Зәйнашева әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗади активлык күрсәтә. Үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында ул әдәби тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә, көндәлек матбугатта басылган язмалары, сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул – сәнгать кешеләренә, җырчы артистларга, сәхнә фидакарьләренә, бигрәк тә сәнгатькяр хатын-кызлардан З.Басыйрова, Ә.Галимова, Ә.Афзалова, Р.Ибраһимова, Ф.Ильская, Х.Әхтәмова, Ф.Сөләйманова һәм башкаларның сәхнә эшчәнлекләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, шул җөмләдән мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймpraнованың, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың тормыш һәм иҗат юллары турында берничә монографик китап яза. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

*Җыр башкарыла «Тибрәнә җыр күңелдә» (Г.Зәйнашева сүзләре, З.Сәгыйтов көе)*

2 нче алып баручы. Шагыйрәнең драматургия өлкәсендә дә эшләве билгеле. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

Залда утырган укучылар белән “Туган авылым урамы” җырын өйрәнү.

Экранда күрсәтеп, җырның сүзләре белән таныштыру, текстны кабатлау, җырны тыңлау, рәтләп җырлау, караоке җырлау.

1 нче алып баручы. Шагыйрә туган ягыннан еракта булса да, гомере буе күңеле белән туган ягында яши, аны сагына, юксына. Без дә аны сагынабыз. Аның иҗаты безгә көч, дәрт, илһам бирә. Без, яшь буынны, яшәргә, туган якны, тормышны яратырга өйрәтә. Дәресебезнең ахырында Г.Зәйнашеваның „Мин тормышка гашыйк” шигырен укып үтәсем килә .

Кая барсам, якын дуслар табам,

Дуслар белән озын юл кыска..

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка .

Игътибарыгыз өчен рәхмәт! Шуның белән дәресебез тәмам! Яңа очрашуларга кадәр!

**Сталин культы корбаннары. Сөббух Рәфыйков.**

(Телдән журнал)

Гыйбадуллина Гөлия Марсил кызы,

Курса Почмак урта гомуми белем мәктәбенең татар теле

һәм әдәбияты укытучысы, Арча районы

Максат: Әдәбият өлкәсенә кире кайтарылган шәхес Сөббух Рәфыйков белән таныштыру.

Сталин культы корбаны булган язучыларның биографияләре тупланган “Репрессияләнгән татар әдипләре” альбомы һәм “Кире кайтарылган исемнәр” дигән китаплар күргәзмәсе әзерләнә.

1 нче укучы. Һәр заманның була гөнаһысы,
Һәр заманда була хаталар.
Шигырь өчен илдән сөреләләр,
Шигырь өчен терәп аталар.
2 нче укучы. Халык дошманына тиеш исем
Халык улларына тагылган...
Юасы бар әле чорыбызны,
Агартасы алар каныннан!

1 нче укучы. Бүген искә аласы шәхесебез – Сөббух Рәфыйков Сарман районы Нөркәй авылында туа. 1925-1930 елларда башта Чаллыда, аннан Алабугада тугызъеллык мәктәптә укый.

2 нче укучы. Сөббух Рәфыйковны кулга алганда аңа нибары егерме дүрт яшь була. Яшь шагыйрь, прозаик, журналист, “Кызыл яшьләр” газетасында бүлек мөдире, соңыннан Татарстан китап нәшриятында редактор... Педагогия институтында читтән торып уку бүлегенең икенче курс студенты. Барничә хикәя, бер шигырь җыентыгы авторы.

*Сәхнәдә яктыра.*

*Креслода бер ир-ат утыра. Күзлекле, кулында газета. Ул Сөббух Рафыйков булып сөйли. Хәбәрче аның белән әңгәмә оештыра.*

- Сөббух ага, кулга аласыларын алдан белә идегезме?
- Сизендем. Минем баш өстендәге болытлар 1937 елның башыннан ук куера башлаган иде. Комсомолдан гына да өч мәртәбә чыгардылар. Әүвәл кулак малае, сәүдәгәр токымы дип бәйләнделәр. Урта хәлле крестьян баласы икәнемне исбат иткәч, яңадан торгыздылар.
- Икенче тапкыр ни өчен?
- Аннан соң “троцкийчылар”, “халык дошманы” белән бәйләнештә булуда гаепләделәр. Ахырдан инде Галимҗан Ибраһимовны юбилее белән котлап язган адреска кул куйган персональ эшемне тикшерделәр.
- Гаепсезгә гаепләнүне ничек кабул иттегез?
- Комсомолдан чыгару – бер хәл, эшемнән кудылар, хезмәт иткән газетада “мораль яктан череп таркалуда” гаепләп язып чыктылар. 1937 елның 17 октябрендә кулга алдылар.
- Тикшерүчеләрнең исем-фамилияләрен хәтерлисезме, Сөббух ага?
- Үлгәнче онытасым юк! Ләкин әйтмим. Чөнки әйтмәскә дип кул куйдым.
- Суд кайчан булды?
- Суд 1938 елның 12 маенда булды. Мин аңа зур өметләр багладым: барысын да сөйләрмен, гаепсез икәнемне исбатлармын дип уйладым. Ләкин суд дигәннәре бары биш

минутлар тирәсендә генә булды. Гаепләү актын укып чыктылар. Шаһитләрне дә чакырып тормадылар, миңа да сүз әйтергә вакыт калдырмадылар. Чөнки ул көнне меңләгән тоткынның эше каралган булган. Миңа язмыш башкаларга караганда мәрхәмәтлерәк булды. Күбесен подвалга алып төшеп атып үтерделәр. Мине ун елга хөкем иттеләр.

- Сезне кая алып киттеләр?

- Мине атаклы СЛОН лагерына, Соловкига алып киттеләр. Бер елдан соң Норильскида урнашкан зур лагерьга күчерделәр. Мин анда җир казыдым, никель рудасы чыгардым, металлургия заводын төзүдә катнаштым. Яшьлегем, тазалыгым нык булу ярдәм иткәндер инде, исән калдым.

- Аннан туган якларга кайттыгызмы?

- Нинди кайту? Лагерьдан чыкканнан соң да Норильскидан китәргә рөхсәт булмады. Тагын биш елга гражданлык хокукыннан мәхрүм ителгән кеше буларак, шул ук комбината НКВД күзәтүе астында яшәдем. Инде иреккә чыгам дип хыялланып йөргәндә –1951 елда – яңадан суд булды. Монысында гаеп эзләп тә тормадылар: мәңгелек сөргенгә хөкем иттеләр. Норильски комбинатында эшче буларак, шунда калдырдылар.

- Ничә ел гомерегез тоткынлыкта һәм сөргенлектә үтте?

- Егерме елым... Бары тик Казанга, реабилитация алып, 1957 елның августында гына кайта алдым...

*Сәхнәдә ут сүнә*

1 нче укучы. Ниһаять, Сөббух Рәфыйков үз илендә...

2 нче укучы. Тормышының соңгы ундүрт елын ул Зәй якларында үткәрә. Иҗат эше белән шөгыльләнү аңа җан дәвасы бирә. Бер шигырь китабы, “Беренче яз” романын язып бастыра. Роман аеруча уңыш казана, кат-кат басылып чыга. Укучылар әлеге әсәрне яратып, кулдан-кулга йөртеп укыйлар.

1 нче укучы. Тән һәм җан әрнүләрен кичергән Сөббух Рафыйков, алтмыш яшен дә тутырмыйча, 1971 елның 21 ноябрендә Татарстанның Яңа Зәй поселогында вафат була.

2 нче укучы. Ул китабын күмде кара җиргә,
Җирләгән күк барак сердәшен.
Бер минуткамы соң, егерме ел
Тып-тын калды китап, сүз дәшми.

1 нче укучы. Әдәби мирасын барлап үтик: шигырь һәм хикәяләре тупланган “Үсү җырлары”, “Соңгы талпыну”, “Үсмерчак” җыентыклары, “Ак төннәр” шигырь китабы, “Беренче яз” романы.

2 нче укучы. Утыз җиденче һәм аннан соңрак елларда Сталинның үлем чалгысы һәм дә сугыш корбаннары булган язучыларны, галимнәрне, фән эшлеклеләрен санап бетерерлек түгел. Аларның исемнәре торган саен якты нур булып балкый бара.

## Сыйфат сүз төркемен гомумиләштереп кабатлау.

## Моңлы халыкның талантлы баласы.

(6нчы сыйныфның татар төркемендә татар теленнән дәрес конспекты.)

Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы,

Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбенең

татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Әлмәт районы

Тема: Сыйфат сүз төркемен гомумиләштереп кабатлау. Моңлы халыкның талантлы баласы. (Шагыйрәбез Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш һәм иҗат юлына багышлап.)

Максат: 1.Сыйфат-сүз төркеме турында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. 2. Иҗади фикерләргә, белемне башкалар белән уртаклашырга өйрәтү, күзәтү, хәтерләү, игътибар итү сәләтен үстерү, халкыбызның талантлы шагыйрәсе Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру, әлеге материалларны дәрес барышында куллану. 3. Шагыйрә иҗатындагы шигырьләр, җырлар аша балалар күңелендә шигъри әсәрләр белән кызыксыну, аларга хөрмәт тәрбияләү.

Көтелгән нәтиҗә: Метопредмет. Тексттан фактик мәгълүматны аерып алу; төркемнәрдә эшләү; үз фикереңне төгәл һәм ирекле җиткерә белү.

Предмет. Сыйфат сүз төркеме турында белү, сыйфат сүз төркеменә караган сораулар һәм билгеләрне аерып чыгару.

Шәхескә кагылышлы. Эстетик зәвык булдыру, шагыйрәбез иҗатына карата кызыксыну уяту.

Дәрес тибы: гомумиләштереп кабатлау.

Методлар: презентация карау, әңгәмә, индивидуаль эш, төркем белән эш, бирелгән тема буенча иҗади язма эш, тестлаштыру.

Җиһазлау: компьютер презентациясе ”Сыйфат сүз төркемен кабатлау”, тест сораулары, аудиоязма.

Дәрес барышы:

I Оештыру моменты.

Укучыларда уңай психологик халәт булдыру, эшләргә теләк уяту.

Укытучы: Исәнмесез, укучылар. Татар теле дәресебезне башлыйбыз.

Укучылар, әйдәгез, дәресебезне башлаганчы, дәрестә эшләү, утыру кагыйдәләрен искә төшерик.

- Үз урыныңда авышмыйча дөрес итеп утыр.
- Дәрескә күңел сал.
- Сораган сүзне дөрес аңлап, ачык тавыш белән җавап бир.
- Укытучының һәр сүзен мәхәббәт белән үтә.

- Рәхмәт, укучылар. Укучылар, беләсезме, бөек галимебез Риза Фәхретдин “Бала күңеле ак кәгазь кебек чиста, аңа ни язсаң шул уелып кала,”- дигән. Мин аның сүзләре белән килешәм, дөрестән дә, сезнең эчке дөньягыз язылмаган, сызгаланмаган, буялмаган ак кәгазь кебек. Сезгә бары тик өлкәннәр сүзен тыңлап, укытучылар биргән белемнәрне, тәрбия әхлакларын шунда язып барырга гына кирәк. Сез шуңа әзерме?

II. Белемнәрне актуальләштерү

- Укучылар, сезгә өй эшенә нинди бирем бирелгән иде?
- Танылган шагыйрәбез Гөлшат Зәйнәшева иҗатындагы шигырьләрне, җырларны барларга, аларда кулланылган сыйфатларны табарга.

Берничә укучыдан өй эше укытыла.

Дәреснең темасын, максатын җиткерү.

Илһам Шакиров язмасында “Менәргә иде Урал тауларына” (Г. Зәйнәшева сүзләре, М. Мозаффоров көе ) җыры яңгырый.

- Укучылар, әйтегез әле, бу җырны кем башкара?
- Җырчы Илһам Шакиров.
- Илһам Шакировның тавышы нинди?

- Матур, моңлы, көчле.

- Сез яңа гына әйткән сүзләр нинди сүз төркеменә карый?

- Сыйфат сүз төркеменә.

- Димәк, без дәрестә нинди темага сөйләшербез?

- Сыйфат темасына.

- Теоритик материалны кабатлау өчен безгә нинди лексик тема ярдәм итәр икән. Тактадагы теманы укыйк әле. “Моңлы халыкның талантлы баласы”.

- Укучылар, бүгенге дәрескә безгә күчтәнәч итеп, Гөлшат апа Зәйнәшева үзенең гомер китабын җибәргән. Әлеге китап битләрендә аның тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы мәгълүматләр бар. Без сезнең белән сыйфат сүз төркеме турында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау барышында танылган шагыйрәбезнең тормыш һәм иҗат юлы белән дә танышырбыз.

Сыйфат сүз төркемен кулланып, дәреснең лексик темасына бәйләп, үз төркемнәрегезгә исемнәр уйлагыз.

Беренче төркем: “Талантлы”. Икенче төркем: “Моңлы”

III. Кабатлау, ныгыту. (сыйфат турында белгәннәрне искә төшерү

Слайд №1-4

- Сыйфат нәрсәне белдерә?Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?

- Сыйфат предметның нинди билгеләрен белдерә?

- Сыйфатның төрләнеше турынданиләр беләсез?

- Нәрсә ул сыйфатланмыш?

- - Әйе, дөрес, балалар. Җавапларыбызның дөреслеген тикшереп алыйк.(слайдлар буенча тикшерү.)

- Укучылар, Гөлшат апаның гомер китабы битләренә күз салыйк әле.

Слайд № 5-10

- Әлеге җөмләләрне укып, сыйфатларның дәрәҗәләрен билгеләгез.

Интерактив тактада: 1. Халкыбызның *танылган* шагыйрәсе, драматург Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 январенда, *күренекле* шәхесләргә бай Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган.

2. Халыкка Гөлшат ханым берсеннән-берсе *матуррак* шигырьләре, җырлары белән танылa.

3. Кечкенә Гөлшат мәктәптә *яхшы* укучы була. Шигырьләрне бик матур итеп сөйли. Кирәк булса, җырлап та җибәрә.

4. *Зәңгәрсу* күкле, *җиләс* һавалы, талантларга бай туган ягы кызны илһамландыра, шигырь иленә илтә.

- Әлеге җөмләләрне укып, асыл һәм нисби сыйфатлар турында сөйләгез.

1. Ятимә Гөлшатның балачагы һәм яшүсмер чоры халык кичергән *авыр* елларга туры килә. Шул җитмәүчелек, фәкыйрьлек шартларында да *сәләтле, зирәк акыллы* кыз—белем алуга омтыла, бик күп әдәби китаплар укый.

2. Гөлшат апа *бөек* композитор Салих Сәйдәшев иҗатын бик ихтирам итә һәм ярата иде. Аның сүзләренә музыканы, гаҗәеп *моңлы* көйләрне нәкъ менә С. Сәйдәшев традицияләрен дәвам итүче композиторларыбыз иҗат итте.

2. - Сыйфатларның ясалышы.

1.Туган як дип, сагынып кайта,
Язлар җиткәч, *сайрар* кошлары.
Язлар *матур*, җәйләр *ямьле*,
Чыныктыра *салкын* кышлары. (Г. Зәйнәшева “Туган як”)

2. Хәзер дә аны *җылы* хисләр белән искә алам, ул һаман да күз алдына *җылы* шәлен ябынган "*җылы* апа" булып килеп баса. Юмор сөючән, *югары* культуралы, *җор* телле шәхес булды". (Айгөл Хәйри сөйләгәннәрдән.)

4. Гөлшат ханымның җырларын талантлы җырчылар башкаруында тыңлаганнан соң, *зур-зур* залларда яңгыраган алкышларны бергә тупласаң, Ниагара шарлавыгына тиң *кодрәтле* ташкын-күкрәү хасил булыр иде.

- Исемләшкән сыйфатларны табыгыз.

"Гөлшат Зәйнәшева *бик җитди* кеше иде, чөнки китап нәшриятында эшләү *зур* җаваплылыкны сорый (1952-1963 елларда ул китап нәшриятында әдәби редактор булып эшли – ИТ). Андагы *саллылык* һәм *таләпчәнлек* көчле: ул әйтсә, аны тыңларга туры килә иде. (Журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев)

Ә мин син йөрисе юл буенда,
Гөлләр булып үрелеп үсәрмен.
Я бер *моңлы* җырга әверелеп,
Көн дә синең исеңә төшәрмен. (Г. Зәйнәшева "Исеңә төшәрмен")

*Талантлының* таланты югалмас.
*Кадерлебез* Гөлшат Зәйнәшевага быел 95 яшь тула
- Әлеге җөмләләрдә сыйфатлар җөмләнең кайсы кисәге булып килгәннәр?

1. Бу дөньяда чибәрләр күп,
Сөйкемлеләр аз, диләр.
Син *чибәр* дә, *сөйкемле* дә,
Кемгә насыйп яр икән?!. (Г. Зәйнәшева "Син кемнең сандугачы?")

2. Идел ярларына нурлар сибеп
*Матур* булып ата бездә таң.
Таң шикелле *якты* Туган илем,
Бәхет биргән җирем — Татарстан. (Г. Зәйнәшева "Туган җирем - Татарстан")

3. *Асыл* ир-егетләр акыл белән
Алып бара бүген заманасын,
Хезмәт сөйгән халкым көче белән
Яшәрәсең, Казан, яңарасың!..(Г. Зәйнәшева "Яшәрәсең, Казан, яңарасың")

Бергәләп сыйфатка морфологик анализ ясау тәртибен искә төшерү.

Слайд №11

Карточкалар белән эш. Төркемнәргә карточкалар бирелә.

1 нче төркемгә карточка.

*Зур* түгел шул, бик *кечкенә,*
Бөрлегән мин, бөрлегән.
Бөрлегән генә булсам да,
Бар эшкә дә өлгерәм. (Г. Зәйнәшева "Бөрлегән")

2 нче төркемгә карточка. Гаять *зур диапазонлы, киң колачлы бай* репертуарга ия булган И. Шакиров башкаруында Гөлшат Зәйнәшеваның җырлары гаҗәеп бер үзенчәлек, моң, аһәң белән яңгырый.

2 сыйфатка морфологик анализ ясау. Ике укучыны такта янына чакыру.

Контроль: такта янындагыларны тикшерү.

Физминут Слайд№ 11

Төркемнәрдә иҗади эш. – Синквейн алымы кулланып, иҗат итеп алыйк.

Мин сезгә үзем төзегәнне укып күрсәтәм.

Гөлшат Зәйнәшева

Моңлы, талантлы.

Иҗат итә, мактала, яңа үрләр ала.

Аның иҗатына гашыйкбыз.

Талант.

Төркемнәрдә бергәләп язалар.

Контроль: Текстлар әзер. Танышып үтик.
- Бик матур иҗат җимешләре туган.Татар теленең сүз байлыгы чиксез шул.
- Теоретик белемнәрне гамәлдә ничек кулланырсыз икән, тест ярдәмендә тикшереп үтик әле. (Тест өләшү, укучылар индивидуаль рәвештә эшлиләр).

Тест.

1.Бу сыйфатлар предметның нинди билгесен белдерә: ачы, тәмле, төче.

а) төс б) тәм в) форма г) холкын

2.Бу сыйфатлар нинди дәрәҗәдә: бик уңган, кып-кызыл, иң кечкенә.

а) гади б) чагыштыру в) артыклык г) кимлек

3. Бу сыйфатлар нинди җөмлә кисәге булып килгән: Бүлмә якты. Төн караңгы.

а) ия б) хәбәр в) аергыч г) хәл

4. Бу сыйфатлар нинди җөмлә кисәге булып килгән: Әлфия матур бии. Алмаз җитез атлый.

а) ия б) хәбәр в) аергыч г) хәл

5.Бу сыйфатлар нинди җөмлә кисәге: Ямьле җәй җитәр. Аяз көннәр тора.

а) ия б) хәбәр в) аергыч г) хәл

6.Бу сыйфатлар ясалышы ягыннан нинди: кояшлы көн, язгы иртә, күңелсез чак, кисек бау.

а) тамыр б) ясалма в) кушма г) парлы

7.Бу сыйфатлар ясалышы ягыннан нинди: уенлы-көлкеле кичә, иләс-миләс уй, зур-зур шәһәрләр.

а) тамыр б) ясалма в) кушма г) парлы

8. Бу сыйфатлар ясалышы ягыннан нинди: эчпошыргыч фильм, беркатлы кеше, эчкерсез бала.

а) тамыр б) ясалма в) кушма г) парлы

9. Нисби сыйфатларны табыгыз.

а) аю өне б) яшел чирәм в) кыю кыз г) ак кар

10. Сыйфат нәрсәне белдерә

а) предметны б) эш-хәрәкәтне в) предметның билгесен г) хәлне

Слайд №18

Контроль: тестның дөреслеген тикшереп үтик:

1. – в “5”- 10 балл

2. – в

3. – б “4” -7-9 балл

4. – г

5. – в “3”- 4-6 балл

6. – б

7. – г “2”- 3тән түбән балл

8. – в

9. – а

10. - в

Эшләрне бер-берсе белән алмашып тикшерәләр.

Һәр дөрес җавап өчен 1 балл. Шулай итеп, әгәр сезнең 10 балл булса “5” була.

IV.Йомгаклау.

- Укучылар, дәресебез ахырына якынлаша. Безнең бүгенге дәресебез сезнең өчен нәрсә белән әһәмиятле?

Хәзер үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезгә бәя бирегез. (Һәр укучыга үзбәя карточкасы таратыла)

Үзбәя.

6нчы сыйныф. Исемем: _______________

| *Мин бу дәрестә актив катнаштым* | балл |
|---|---|
| | |
| *Биремнәрне үтәгәндә үземнән өлеш керттем* | |
| *Мин сыйфатка морфологик-синтаксик анализ ясый беләм* | |
| *Сөйләмем дөрес һәм тулы булды* | |
| *Сыйфатларны сөйләмдә дөрес итеп куллана беләм* | |

Һәр пунктка берешәр баллдан.

V. Өй эше. Слайд №19

“Моңлы халыкның талантлы баласы” темасы астында, сыйфатлар кертеп, кечкенә генә хикәя төзегез. Хикәягездә үзегезнең бүгенге дәрестә белгәннәрегез дә чагылыш тапсын.

“Моңлы халыкның талантлы баласы” темасына презентация ясарга. Барыгызга да катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сау-сәламәт булыгыз.

**Җырлы-моңлы иҗат иясе – Гөлшат Зәйнәшева**

(Г.Зәйнәшева иҗатын йомгаклау)

Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы,

Югары Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбе

татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Түбән Кама муниципаль районы

7нче сыйныфта туган тел әдәбияты фәне буенча дәрестән тыш эшчәнлек шөгыле – эшлекле уен (Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган стена газетасы чыгару)

Шөгыльнең тибы: әсәрне өйрәнүне йомгаклау

Шөгыльнең максаты:

1. Өйрәтү максаты: Г.Зәйнәшева иҗаты буенча белемнәрне актуальләштерү; монологик һәм диалог сөйләм телен үстерү өчен шартлар булдыру.

2. Белем үстерү максаты: укучыларны үз фикерләрен дөрес, эзлекле әйтә белергә өйрәнү, тексттан иң мөһим мәгълүматны аерып алу күнекмәләрен үстерү мөмкинлеге булдыру.

3. Тәрбияви: укучыларда дуслык, ярдәмләшү, җаваплылык кебек әхлаклылык сыйфатлары һәм эстетик тәрбия алу өчен шартлар булдыру.

Эш формалары: парларда, төркемдә эш.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Предмет: өйрәнелгән материалны үзләштерү, анализлый белү.

Танып белү: үз фикереңне дәлилләп анализлый белү; белем һәм күнекмәләрне дөрес итеп файдалана белү.

Предметара: татар теле, рәсем, музыка белән бәйләнеш.

Регулятив: бер-береңнең һәм үзеңнең дә эшләрен тикшерү, бәяләү; шөгыльнең максатына туры китереп биремнәрне үтәү.

Коммуникатив: төркемдә эшләгәндә, бер-береңә комачауламый, иптәшең белән килешә, тыңлый, нәтиҗә чыгара һәм аңлатып бирә белү.

Шәхси: иҗат, сәнагать ияләрен ихтирам итү, гүзәллек хисләре тәрбияләү; булган тискәре сыйфатларны бетерү өстендә эшләү; ярдәмчел, гадел һәм намуслы булу кебек сыйфатларны тәрбияләү.

Материаллар: биремле карточкалар, экрандагы язмалар, күрсәтмәлелек

Җиһазлау: Г.Зәйнәшева китаплары, портретлары, компьютер, принтер, шөгыль темасы буенча презентация, тавыш колонкалары.

План:

Уңай психологик атмосфера тудыру.

Уку мәсьәләсен кую.

Уку мәсьәләсен чишү.

Төркемнең биремнәр өстендә эшләве:

Төркем үз эшен күрсәтә – дөрес эш кәгазьдә принтер аша бастырылып чыга бара.

Г.Зәйнәшева әсәрләре күргәзмәсе оештыру.

Проектны яклау – стена газетасы чыгару

Рефлексия.

Бүген мин белдем.....

Миңа ошады....

Мин аңладым....

Хәзер мин эшли алам....

Йомгаклау.

Үз эшләрен үзара бәяләүләре.

Нәтиҗә.

Шөгыль барышы.

I. Уңай психологик халәт тудыру.

– Исәнмесез, кадерле укучылар. Хәерле көн! Хәлләрегез ничек? Бүгенге шөгыльне нинди кәеф белән башлыйбыз? (Экранда кояшлы матур рәсем һәм сәламләү сүзләре)

II. Уку мәсьәләсен кую.

1) Уку мәсьәләсен кую әңгәмәсе. (1-2 минут)

– Укучылар, без сезнең белән берничә шөгыль дәвамында кемнең иҗатын өйрәндек?

- *Гөлшат Зәйнәшева иҗатын өйрәндек, аның турында күп нәрсәләр белдек.*

- Берничә шөгыль дәвамында өйрәндек, ләкин нәтиҗә ясадыкмы?

- *Әлегә юк.*

- Бүгенге шөгыльгә ничек әзерләнергә иде?

- *Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында искә төшереп килергә, китапларын алып килергә иде.*

- Димәк, бүген нәрсә эшләрбез, шөгыльнең темасы нинди булыр?

- *Г.Зәйнәшева турында белгәннәребезне ныгытырбыз, йомгакларбыз, нәтиҗә ясарбыз. Шөгыльнең темасы "Гөлшат Зәйнәшева иҗатын йомгаклау" булыр.*

2) Эш тәртибен билгеләү. (5 минут)

- Бүгенге шөгылебез өйрәнгәннәрне үзләштерү дәрәҗәсен күрсәтү булыр. Әдәби хәзинәләребезне нәрсәләр белән баеттык икән? Әнә шуларны барларбыз, нәтиҗәләр чыгарырбыз. Бу максатка ирешү өчен нинди эш алымнарын сайларга мөмкин?

- *Сөйләп китәргә, төрле биремнәр өстендә эшләргә, сорауларга җавап табарга һ.б.*

- Ә белгәннәребез белән уртаклашу, башкаларга да җиткерү мөмкинме, кирәкме, ничек уйлыйсыз?

- *Әйе, кирәк, чөнки без күренекле шагыйрә белән таныштык, аның турында башкалар да белсә тагын да яхшырак.*

- Ничек уйлыйсыз нинди чаралар ярдәмендә үзең белгәннәр белән уртаклашып була? Мәгълүматны күп кешегә ничек җиткереп була?

- *Телевизор, телефон, интернет аша, җыелышларда сөйләргә мөмкин.*

- Дөрес, ләкин тагын бер үтемле чара бар, ул – газеталар, реклама язулары да. Ничек уйлыйсыз, без бүген бергәләшеп эшләсәк стена газетасы чыгара алыр идекме?

- *Әйе.*

Стена газетасы өчен җирлек (ватман кәгазе, тиешле үлчәмдә кисеп алынган обой яисә кесәләре булган әзер стенд) тәкъдим ителә.

- Уңышка ирешү өчен төркемдә эшлик. Үзара киңәшләшеп, мөхәррир һәм аның ярдәмчесен, сәркатип, корректор, рәссам һәм аның ярдәмчесе кебек һөнәр ияләрен билгели.

Экранда эш бүленеше чыгарыла.

Мөхәррир – редактор, редколлегия эшен җитәкләүче,

Мөхәррир ярдәмчесе – төркем эшендә актив катнашучы,

Сәркатип – хезмәтне бастырып чыгаручы (ноутбук һәм принтер белән эшләүче),

Корректор – эшләрнең төзеклеген тикшерүче,

Рәссам – бизәү эшен алып баручы

Рәссам ярдәмчесе – бизәү эшендә катнашучы

3) Вазифаларны бүлешү һәм түшләргә махсус тамгаларны беркетү (2-3 минут)

Уку мәсьәләсен чишү.

1) Газетага исем уйлау (4 минут) һәм принтер аша кәгазьдә чыгарып җирлеккә ябыштыру.

– Ә хәзер беренче эш белән танышыйк. Һәммәбез дә беләбез: һәр газетаның исеме була, ул исем җисеменә туры килергә тиеш, безнең газета нинди исем алыр, ни өчен?

Төркем алдында махсус конвертларда кисмә сүзләр, сүзтезмәләр бирелгән, шулардан матур яңгырашлы газета исеме төзергә кирәк. (2 минут)

Сүзләр: моңлы җырчы, балалар язучысы, Гөлшат Зәйнашева, күренекле шагыйрә, җырлар авторы, күпкырлы иҗатчы, безнең арада, моң иясе...

К/Җ:

“Гөлшат Зәйнәшева – балалар язучысы”

“Гөлшат Зәйнәшева – күренекле шагыйрә”

“Моң иясе Гөлшат Зәйнәшева”

“Гөлшат Зәйнәшева – моңлы җырчы”

“Гөлшат Зәйнәшева безнең арада”

“Гөлшат Зәйнәшева – күпкырлы иҗатчы”

Үз вариантларын тәкъдим итәләр, ни өчен бу исемне сайлауларын аңлаталар, дәлиллиләр.

Уңышлы исем газета исеме буларак билгеләнә, мөхәррир һәм сәркатип исемне принтердан чыгара, ә рәссам һәм ярдәмчесе газета җирлегенә ябыштыра. (2 минут)

(Бу вакытта төркемгә газетага беркетү өчен портретлар тәкъдим ителә).

2) Портрет сайлау. (4 минут)

- Күренекле шәхескә багышланган газетада һичшиксез нәрсә булырга тиеш, укучылар? Ни өчен?

-*Язучының портреты. Аны һәркем танырга өйрәнсен өчен, ерактан ук күренеп торсын өчен, хәтерләү өчен һ.б.*

Төркемгә экранда 5-6 портрет бирелә (арада берсе - Клара Булатова һәм берсе Лена Шагыйрьҗанныкы), алар Гөлшат Зәйнәшеваны танырга, уңышлысын сайларга, ни өчен икәнен аңлатырга тиеш, монда портретны телдән тасвирлауга да игътибар ителә. (2 минут)

Уңышлы портрет билгеләнә, мөхәррир һәм сәркатип портетны принтердан чыгара, ә рәссам һәм ярдәмчесе газета җирлегенә ябыштыра. (2 минут)

3) Тормыш юлы турында мәкалә язу. (5 минут)

- Газетаның төп вазифасы нәрсә дип уйлыйсыз? Һәр газета нинди эш башкара?

- *Төрле яңалыклар белән таныштыра, мәгълүмат җиткерә, кызыклы уеннар тәкъдим итә.*

- Димәк, алдагы бирем – язучының тәрҗемәи хәле турында мәгълүмат җыю белән бәйле.

Төркемгә Гөлшат Зәйнәшеваның биографиясе язылган карточкалар бирелә, мәгълүматлар янында кирәкле даталарны, кайбер атамаларны язып куярга кирәк. (3 минут)

Тәрҗемәи хәле

Шагыйрә Гөлшат _________ кызы Зәйнәшева ________ елның _____ гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы _________________ авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге _____________ районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, этисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп _____еллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын _________________________________ дәвам иттерә. 1945-1949 елларда _______ дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт _____________________ әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының _______________ бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән ____________________ – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнәшева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы _________________ исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр ______________ китап

нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

(Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Teләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга күчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, эти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнәшева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнәшева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.)

Җавапларны корректор чагыштырып тикшерә, төгәл җаваплы мәкаләне мөхәррир һәм сәркатип принтердан чыгара, ә рәссам һәм ярдәмчесе газета җирлегенә ябыштыра. (2 минут)

Ял минуты – музыкаль тәнәфес (2-3 минут)

Кайсы вакытта үткәрелүгә бәйле:

я) татарча җырлы бию (“Вак-тияк”, “Капкалы”)

я) музыка астында урыннарда атлау – хәрби-патриотик айлык булса

я) экрандагы анимациягә ияреп – музыкаль гимнастика

4) Иҗаты турында мәкалә язу. (5 минут)

- Ә алдагы бирем – язучының иҗаты турында мәгълүмат җыю белән бәйле.

Төркемгә Гөлшат Зәйнәшеваның иҗаты турында язылган карточка бирелә, мәгълүматлар янында кирәкле әсәр исемнәрен, жанрларын, елларын язып куярга кирәк. (3 минут)

Гөлшат Зәйнәшева иҗаты

Г.Зәйнәшеваның беренче иҗат тәҗрибәләре — шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары _______ елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда __________ исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана.

1958 елда яшь авторның _____________________ исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга.

Г.Зәйнәшева бигрәк тә ________ жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темала гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. «Туган жирем — ____________» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, ___________» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде ___________ тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз ___________» (С.Садыйкова музыкасы),

«____________ төймә» (халык көе), «________ буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «____________ гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Туган ____________ урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы) кебек җырлар татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Иң популяр җырлары тупланган ____________ (1988) исемле китабы өчен Г.Зәйнәшева ________ елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Г.Зәйнәшева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка», «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным җәл түгел сиңа» дигән ______________ төрле театр сәхнәләрендә уңыш белән бара. Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары исә шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш _________» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «__________ дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган.

(Г.Зәйнәшеваның беренче иҗат тәҗрибәләре — шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана.

1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга.

Г.Зәйнәшева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темала гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. «Туган жирем – Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кояш гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы) кебек җырлар татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» (1988) исемле китабы өчен Г.Зәйнәшева 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Г.Зәйнәшева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка», «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным җәл түгел сиңа» дигән комедияләре төрле театр сәхнәләрендә уңыш белән бара. Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары исә шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган.)

Җаваплар корректор һәм редактор, аның ярдәмчесе тарафыннан тикшерелә, төгәл җавап биргәч, төркем мөхәррире һәм сәркатибе мәкаләне принтердан чыгара, ә рәссам һәм ярдәмчесе газета җирлегенә ябыштыра. (2 минут)

5) Кроссворд тәкъдим итү (5 минут)

Бу вакытта рәссам һәм ярдәмче газетаны бизәү белән шөгыльләнә (орнамент кисү, ябыштыру, тышкы кайманы ябыштыру)

Төркемгә экранда һәм аерым карточка формасында кроссворд бирелә, алар җавапларын табарга тиешләр (3 минут)

*Вертикаль буенча*

1 Шагыйрәнең исеме (Гөлшат)
2 Шагыйрә туган районның элеккеге атамасы (Сарман)
3 Шагыйрә тәмамлаган югары уку йорты кайсы шәһәрдә урнашкан? (Казан)
4. Укучылар өчен язылган пьесалар җыентыгы “Мәктәп ...”(Мәктәп <u>сәхнәсе</u>)

*Горизонталь буенча*

1 Шагыйрәнең фамилиясе (Зәйнашева)
2 Иң популяр балалар җыры. “.... гомере” (<u>Кояш</u> гомере)
3.Шагыйрәнең туган авылы (Иске Теләнче)
4 Шагыйрә белем алган һөнәри училище шәһәре (Минзәлә)

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1 | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Г | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | ө | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | л | | | | 2 | | | | | | | | | | |
| | 2 | к | о | я | ш | | 3 | И | С | к | е | 3 | Т | е | л | ә | н | ч | е |
| 1 | З | ә | й | н | а | ш | е | в | а | | | К | | | 4 | | | | |
| | | | | | т | | | | р | | | а | | | с | | | | |
| | | | | | | | | 4 | М | и | н | з | ә | л | ә | | | | |
| | | | | | | | | | а | | | а | | | х | | | | |
| | | | | | | | | | н | | | н | | | н | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | ә | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | с | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | е | | | | |

Дөрес җавап биргәч, төркем мөхәррире һәм сәркатибе кроссвордны принтердан чыгара, ә рәссамнар газета җирлегенә ябыштыра. (2 минут)

6) Газетада бастыру өчен шигырь сайлау (4 минут)

Газетада бастыру өчен төркемгә кәгазьдә 4-5 шигырь тексты бирелә (мәхәббәт турындагы, әниләр турындагы һәм балалар өчен язылган шигырь, җыр текстлары), алар уңышлысын сайларга, ни өчен икәнен аңлатырга тиеш, монда шигырьнең укучылар өчен әһәмиятле булуы яки якынлашып килгән даталар белән бәйләп аңлатырга мөмкинлегенә дә игътибар ителә. (3 минут)

Төркем рәссамы һәм ярдәмчесе шигырь текстын газета җирлегенә ябыштыра. (1 минут)

Әзер газетаны тактага магнитлар белән беркетү һәм күмәк бәя бирү – нәтиҗә ясау. Бергәләп газета тирәсендә фотога төшү.

V. Рефлексия

Бүген мин белдем.....
Миңа ошады....
Мин аңладым....
Хәзер мин эшли алам....

Киләсе шөгыльгә үткәрү өчен биремнәр:

Я) Төбәк газетасы турында 2-3 минутлык чыгыш әзерләү (реклама формасында да ярый),

Я) Җирле язучыларыбызның берсе турында мәгълүмат алып килү,

Я) Әлеге шөгыль турында мәктәп стенгазетасына мәкалә язу.

VI. Йомгаклау

Һәр белгечнең эшләрен үзара бәяләүләре.

Нәтиҗә ясау.

**Гөлшат Зәйнәшева җырларына нигезләнеп төзелгән Әниләр**

**көненә багышланган кичә**

Гәрәева Миләүшә Равил кызы,

Җәлил бистәсенең 3 нче санлы «Алёнушка» балалар бакчасының

өлкән тәрбиячесе, Сарман районы

Бурычлар:

Ата-аналарны һәм балаларны Г.Зәйнәшеваның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам итү хисен тәрбияләү.

*Белем бирү бурычлары*: балаларның туган төбәгебез язучыларының иҗаты турындагы белемнәрен баету һәм камилләштерү;.

*Үстерү бурычлары*: әдәби әсәрләрне тыңлый һәм аңлый белү сәләтен, эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү. *Тәрбия бурычлары*: Г.Зәйнәшева иҗатына ихтирам, кызыксыну уяту. Өлкәннәрнең кадерле кешеләр булуын төшендерү, кечкенә дусларыбызга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

Көтелгән нәтиҗә: якташ язучыларны таный һәм хөрмәтли белү; иптәшләреңне тыңлый, ишетә, үз фикереңне ачык итеп әйтү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйли белү.

Җиһазлау: интерактив җайланмалар, магнитофон, Гөлшат Зәйнашева китаплары күргәзмәсе, балалалар рәсемнәре

Катнашучылар: тәрбияче, балалар, әниләр һәм әбиләр.

Эшчәнлек барышы

*Зал бәйрәмчә бизәлгән. Музыка уйный, балалар бүлмәгә керәләр.*

Тәрбияче: Хәерле иртә, балалар! Хәлләрегез ничек? Кәефләрегез яхшымы?

Балалар: Әйбәт, яхшы!

Тәрбияче: Мин бик шат! Балалар, карагыз әле безгә күпме кунаклар килгән. Кунакларыбызның күңелен күтәрү өчен әйдәгез аларга да хәерле иртәләр телик, матур итеп елмайыйк һәм аларга “Иртәнге җыр” бүләк итик!

Иртәнге җыр

*Гөлшат Зәйнәшева сүзләре Камил Хәсәнов көе*

Таңны мактап талларда
Кошлар канат кактылар.
Тамчы гөлләр тибрәнеп,
Алкаларын тактылар.
Күбәләкләр уянып,
Канатларын җилпеде.
Кондызлар җемелдәвек
Ефәк күлмәген киде.
Чәчәкләр чык суында
Коенып юындылар.
Бал кортлары безелдәп,
Чәчәкләргә кундылар.
Син дә, матур сеңелем,
Татлы йокыңнан уян.

Җәйге таңның ямена,
Гүзәллегенә куан.
Уян, сеңелем, күзең ач,
Җәйге иртә нурында.
Кояш чыкты алланып
Синең тәрәз турында.

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле безгә монда бер тартма калдырып киткәннәр. Хәзер мин сезгә бер табышмак әйтәм, әгәр дә табышмакның җавабын тапсагыз, тартмада нәрсә булуын белерсез.

Агач түгел – яфраклы,
Тун түгел тегелгән.
Ак җир, кара тап,
Нәрсә булыр? Уйлап тап.

Дөрес, балалар, бу – китап. Әйдәгез бу китап белән танышып алыйк.

Тәрбияче: Балалар, бу татар шагыйрәсе Гөлшат Зәйнәшеваның китабы. Ул балалар өчен дә, зурлар өчен дә шигырьләр язган. Композиторлар аның шигырьләренә көй язып бик матур җырлар иҗат иткәннәр. Без дә сезнең белән Гөлшат Зәйнәшева сүзләренә язылган бик күп җырлар беләбез. Бүгенге бәйрәмебез безнең Гөлшат Зәйнәшева җырлары белән үрелеп барыр.

Тәрбияче: Хөрмәтле әниләр, әбиләр, килгән кунаклар! Сезнең барыгызны да Әниләр бәйрәме белән котлыйбыз. Әни – гаиләдә иң якын, газиз кеше. Ул яшәргә дәрт, тормышка илһам өсти. Ана баласын күз нурын, бәгырь кисәген татлы сөенечләр белән кулына ала һәм аны нинди генә матур, кадерле сүзләр белән атамый. Ә хәзер мин әниләргә сорау бирергә телим. Кадерле әниләребез, сез дә үзегезнең балаларыгызны нинди матур сүзләр белән иркәлисез, яратысыз?

Әниләрнең җаваплары: бәләкәчем, йомшагым, алтыным, җимешем, күз нурым, былбылым, матурым һәм башкалар.

Тәрбияче: Әйдәгез әле, балалар, Гөлшат Зәйнәшеваның бик матур җырын җырлап күрсәтик әле.

*Кызлар башкаруында* “Бөрлегәнем”*җыры башкарыла*

*Гөлшат Зәйнәшева сүзләре Азат Хөсәенов көе*

1 нче бала: Бакча бүген гөрләп тора,
Шаулап тора күрегез.
Без бит бәйрәмгә җыелдык,
Әллә шуны белмисез.
Бу бәйрәмне барлык җирдә
Зурлап каршы алалар.
Бәхетле елмая бүген
Җирдә барлык аналар.
2 нче бала Әниләрне, әбиләрне
Кадерлибез, зурлыйбыз.
Чын күңелдән һәммәгезне
Бәйрәм белән котлыйбыз.
Әниләрнең бәйрәме ул
Безнең дә көткән бәйрәм.
Җырлап биеп күңел ачыйк
Бүген әниләр белән.
Бәйрәмебез гөрләп барсын ,

Уен-көлке күп булсын.
Әйдәгез, дуслар, биибез
Әниләр карап торсын.

Татар халык биюе

3 нче бала Дөньяда иң акыллы
Иң уңган безнең әни.
Менә шуңа синең яннан
Һич тә китәсе килми.
Без сине бик яратабыз
Бәйрәм белән котлыйбыз.
Бүләк итеп үзебезгә
Бер матур җыр җырлыйбыз.

Әниләр бәйрәме (*Луиза Батыр- Болгари көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре)*

4 нче бала Кем юата авыр чакта?
Әлбәттә инде, әни!
Мин бит әле аның өчен
Һаман да шулай нәни.
5 нче бала
Минем әнием – Миләүшә
Гөл булып үсә димәк.
Өебезнең яме, нуры-
Ул барыбызга кирәк.
Төрле гөлләр сыйфатына
Минем әнием ия.
Канәферләр кебек төгәл ,
Вакыт кадерен белә.
Ләләдәй яңарыш сөя,
Мәтрүшкәдәй дәвалый.
Роза күк ярата белә,
Кыңгыраудай җырлый.
Кашкарыйлар кебек озын
Гомерле бул, әнием.
Сәламәтлек бирсен Аллаһ,
Терәк булсын әтием.
6 нчы бала
Бик күңелле, бик тә рәхәт,
Әниләр карап торгач.
Эшләрендә булышырбыз
Үсеп зур кеше булгач.
7нче бала
Әнием минем матур,
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була
Әнием кайтып кергәч.
Җырлый –җырлый эшләгәндә
Йөзеннән нур тарата.
Мин дә аңа булышам,
Урын –җирне җыешам.
Өйләребез ялт итсен,
Әни бераз ял итсен.
8 нче бала:
Кояш кебек балкып тора

Әниемнең йөзләре.
Күңелләргә җылы бирә
Аның әйткән сүзләре.
Әниемне бик яратам,
Ул да мине ярата.
Эшеннән кайтып керә дә
Сагышларым тарата.
Әниемне беркайчан да
Борчымам юк-бар белән.
Әниемне котлыйм бүген
Матур бәйрәме белән.

Җырлыйм әнием турында
(*Гөлшат Зәйнәшева сүзләре Фәтхерахман Әхмәдиев көе)*

Тәрбияче: Дөньяда иң кадерле булган әти-әни турында без бик күп сөйлибез. Ә аналарның да, аталарның да әниләре булган, аларга тормыш биргән, аларны кеше итеп үстергән кешеләр – әбиләр турында бик аз искә алабыз. Ә бит әбисе булган кеше нинди бәхетле икәнен һәр бала белә.

Гомернең сикәлтәле юллары артта калган. Маңгайларга сырлар төшкән, чәчләргә ак кырау кунган. Күпне күргән, күпне кичергән дәү әниләребез, ак яулыклы әбиләребез!

Сезне әниләр бәйрәме белән котлыйбыз. Оныкларыгыздан бүген бәйрәм сәламнәре, шигъри юлларны кабул итеп алыгыз.

9 нчы бала

Әниемнең әнисе –
Әбием була минем .
Әби генә түгел әле
Ул минем дәү әнием.
Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.
Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә күз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.
10 нчы бала
Әби кеше гел яхшылык тели,
Гаебебез булса, кичерә.
Гомер буе калыйк тугрылыклы
Әби дигән изге кешегә.
Яшәгез сез мәңге яшь булып
Туган йортыгызга ямь булып.
Сез булсагыз таза – сәламәт
Оныкларга, безгә булыр бик рәхәт.
11 нче бала
Безгә терәк булып,
Яшәгез сез шатлыкта.
Сәламәтлек, ак бәхетләр
Юлдаш булсын картлыкта.
Картаймыйча шулай кояш кебек
Балкып торыгыз сез иртә-кич.

Яхшылыкны җирдә ятмый диләр
Онытмабыз сезне һич.
12 нче бала
Минем әби бик әйбәт,
Гел көлеп кенә тора.
Балакаем, дип әйтеп,
Сөеп, иркәләп тора.
13 нче бала
Гел яхшыга өйрәтәсез,
Тыңлыйбыз сезнең сүзне,
Һәр эштә үрнәк сез безгә
Хөрмәт итәбез сезне.
14 нче бала
Әбием һәркөн безгә
Тәмле ашлар пешерә,
Сөйкемле сүзләр белән
Безнең күңелне күрә.
Без әбине яратабыз,
Ул да безне ярата.
Безнен әбидән дә әйбәт
Кем бар икән дөньяда?
15 нче бала
Туган җирем ал чәчәкле,
Гүзәл гөлбакча булсын.
Җиребез, зәңгәр күгебез
Шат җырлар белән тулсын

Әбиемне яратам

Гөлшат Зәйнәшева сүзләре Асия Зәйнәшева сүзләре

Тәрбияче: Безгә Айгөл Гөлшат Зәйнәшева язган "Спортсмен әби"дигән шигырь сөйләп китә.

Айгөлгә җавап итеп аның әбисе Гөлшат Зәйнәшеваның оныгы турында язган “Тиктормас”шигырен сөйли.

Тәрбияче: Хөрмәтле әниләр, балалар! Ә хәзер без рәсем конкурсы үткәреп алабыз. Балалар рәсемне уң як өстәлдә, ә әниләр сул як өстәлдә ясыйлар. Рәсемнең исеме Гөлшат Зәйнәшева шигыре кебек үк “Үз илемдә” дип атала. Сезгә туган ягыбыз табигате сурәтләнгән бик матур рәсем ясарга кирәк булачак.

Г.Зәйнәшеваның “Үз илемдә” дигән җыры куела, ике команда да рәмемнәр ясый.

Тәрбияче: Бик матур рәсемнәр ясагансыз, әйдәгез без аларны мольбертка куйыйк. Без Гөлшат Зәйнәшева китапларын укырга, шигырьләрен ятларга тиешбез. Чөнки шагыйрә балаларны акыллы, тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди.Туган җирне яратырга чакыра. Әти-әниләрне олылауны, хөрмәт итүне таләп итә.

Без якташыбыз кебек шәхесләребез белән чиксез горурланабыз. Аларның исемнәренә тап төшермичә, тырышып эшләргә, укырга тиешбез!

Тәрбияче: Шулай итеп безнең бүгенге кичәбез ахырына якынлашты. Бүгенге кичәдә яңгыраган Гөлшат Зәйнәшева сүзләренә язылган җырлар бәйрәмебезне тагын да тулыландыргандыр, сезнең күңелегездә якты хисләр уяткандыр дип уйлыйбыз. Сау булыгыз!

**Мин тормышка гашыйк**

(Гөлшат Зәйнәшева тууына 95 ел тулуга багышланган тәрбия сәгате)

Адлер Эльвира Демьяновна,

Заһитова Ләйлә Азгаровна,

Мәлбагыш урта гомуми белем бирү мәктәбенең

башлангыч сыйныф укытучылары, Азнакай районы

Максат:

Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге белән таныштыру, шагыйрәнең иҗатына кызыксыну, ихтирам уяту;

Балаларның бәйләнешле, сәнгатьле сөйләм телен, хәтер сәләтен үстерү;

Гөлшат Зәйнәшева иҗаты аша балаларда әдәплелек, шәфкатьлелек, дуслык, татулык сыйфатлары тәрбияләү.

Материал: Г.Зәйнәшева портреты, Г.Зәйнәшева китапларыннан күргәзмә, проекторда – презентация «Г. Зәйнәшева иҗаты».

Тәрбия сәгате барышы.

Хәерле көн, балалар!

Кердем карурманнарга,
Калдым караңгыларга.
Газиз башлар сау булганда
Нигә ямансуларга?
Г.Зәйнәшева

Халыкның әнә шул тирәннән ургылып чыккан өмет-хыялын халык белән бергә бөтен шатлык-михнәтләрне кичкән кеше генә әйтә ала. Әнә шундый кешеләрнең берсе — җырчы-шагыйрә, драматург – Гөлшат Зәйнәшева.

-Укучылар, сезгә Г.Зәйнәшева исеме танышмы? Бүген без күп шигырьләр, 100гә якын лирик җырлар иҗат иткән шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева белән танышырбыз, аның кабатланмас иҗатына тукталып китәрбез.

Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше була. Тормыш аны төрлечә, ә кайчак аяусыз сыный. Әмма ул бөгелми, бөтен авырлыкларны җиңеп, алга омтыла.

Гөлшат апаның тагын бер матур якларыннан берсе – ул бик өлгер, җитез, кыю була. 55 яшендә җиңел автомобиль сатып алып, аны йөртергә өйрәнә, 70тә компьютерны үзләштерә, әсәрләрен шунда татар телендә яза. Бу нәрсә язучы өчен бик уңайлы, текстны төзәтү җиңел, дип мактый. Дөнья малына, байлыкка кызыкмый. Аның байлыгы – таланты, сәламәтлеге, гаиләсе һәм дуслары, халык мәхәббәте. Гөлшат апа бик бала җанлы кеше була. Кызы Асияне тәрбияләп үстерү, укыту өчен барысын да эшли. Асия Казан консерваториясен тәмамлап, дирижер белгечлеге ала, телестудиядә, соңрак татар музыка мәктәбендә эшли. Бердәнбер кызы Асия кияүгә чыга, бер-бер артлы оныклары Дания һәм Камил дөньяга килә. Гөлшат апа бик куанып аларны үстерергә ярдәм итә. Ә өзелеп яраткан оныклары университетны тәмамлап, юрист булалар, әтиләре юлыннан китәләр. Кияве

Рафаэльне ярата,  минем кияү чын кеше ул, дип еш кабатлый. Балалары, оныклары әниләрен, әбиләрен бик яраталар, хөрмәт итәләр, аны Гөл әни дип йөрткәннәр.

Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә.

Г.Зәйнәшеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана. 1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга. Ул 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була. Быел Гөлшат апа Зәйнәшевага 95 яшь тулган булыр иде...

Хәзер без Г.Зәйнашеваның "Әбиемне яратам" китабы белән танышырбыз.

Бу китап Казан шәһәрендә, Татарстан китап нәшриятында 1995 нче елда бастырылган, тиражы – 5 мең данә. Бу китапта Тукай бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнәшеваның балалар өчен язган көлкеле, үзе гыйбрәтле шигырьләре, җырлары туплап бирелгән. Китапка керештә мондый сүзләр язылган: "Дөньяда иң кадерле, газиз балаларым – оныкларым Дания белән Камилгә багышлыйм". Рәссамы – Диләрә Нәүрузова. Китапның тышындагы картина балалар дөньясын сурәтли. Бу дөнья - хыялый дөнья. Рәсемдәге бала сабын куыклары очырып тора, бу - аның хыяллары. Ул авыл турында, шул авылда яши торган әбисендә кунакта булганы турында рәхәт чакларны искә төшерә.

Укытучы. Шигырьләр белән танышканда Гөлшат апа кешеләрнең нинди сыйфатларын безгә күрсәтергә тели  икән?

1 нче шигырь  – "Тиктормас". Бу шигырьдә әби кечкенә оныкны тиктормас булган өчен кәҗә бәтие кебек бәйләп куйган.Ул аны хәйләләдем дип уйлый, ә чынында киресенчә: оныгы аның чүәкләренә ком тутыра. Ә әбигә оныгының исән-сау булуы кыйммәт.

2 нче шигырь - "Спортсмен әби". Шигырьдә  герой – әби – спортсмен булган, төрле кызык хәлләргә калган.

3 нче шигырь – "Пенсиягә". Авторның табышы - ул кечкенә баланы пенсионер әби урынына куеп сурәтли.

4 нче шигырь – "Камил үстергән көнбагышлар". Камил үстергән көнбагышларны чыпчыклар "пеләш" калдырган. Кошларның рәхмәте – изге эш.

5 нче шигырь – "Конфет". Бу шигырь күп конфет ашаганга үсмичә калган малай турында.  Автор конфет яраткан балалардан яратып көлә,баллы ризыкларны билгеле бер куләмдә  генә ашарга куша.

6 нче шигырь – "Сагыз". Бу шигырьдә автор гел сагыз чәйнәп йөргән балаларга чын сагыз - чыршы сагызы чәйнәргә тәкъдим итә, жевачка дигән сагыз ул – ялган сагыз, явыз ди.

7 нче шигырь – "Телен йоткан Халик". Бу шигырьдә автор"телне йоту" дигән тотрыклы сүзтезмәне оста куллана.

8 нче шигырь – "Татарча ничек?" Бу шигырьдә малайның туңдырма ашыйсы килү – - татарча белмәү каршылыкка килә. Әбинең "телеңне йотма" сүзенә ике төрле мәгънә салынган. Әби туган телеңне онытма, дип әйтергә тели.

Укытучы. Сез ничек ничек уйлыйсыз, Г.Зәйнәшева оныкларына карата нинди мөгалләмәдә булган? Ул кечкенә балалардагы нинди зарарлы гадәтләрдән көлә? (Ул балаларның туган татар телен онытмауларын, сагыз чәйнәү, күп итеп кәнфит ашарга ярату, ялкаулык кебек әхлак гадәтләрен төзәтергә тели).

Г.Зәйнәшеваның «Кем булырга?» шигыре белән тәрбия сәгатен төгәллибез.

- Шигырьдә сүз нәрсә турында бара? Малайга кем нинди һөнәр алырга куша? Балалар, әбинең әйткән сүзләрен тагын бер тапкыр укыйк. Нинди генә һөнәр алсаң да тырыш, җитди һәм кешелекле булырга кирәк, дигәнне төшендерә безгә Гөлшат апа.

Без Гөлшат Зәйнәшеваның биографиясе белән таныштык, Г.Зәйнәшеваның "Әбиемне яратам" китабына күзәтү ясадык.

Балалар, сезгә бу китап ошадымы? Кайсы ягы белән ошады? (Әйе, аның көлкеле шигырьләре күңелне күтәрә, тәрбияли).

Сез тагын Г.Зәйнәшева әсәрләрен укырга теләр идегезме? Аның китапларын дусларыгызга тәкъдим итәрсезме?

## Танылган шәхес -Сөббух Рәфыйков

(яңа белемнәрне ачу дәресе)

Шәфигуллина Гөлгенә Рифкать кызы,

Шәүкәт Галиев исемендәге Бакырчы төп гомуми

белем бирү мәктәбе укытучысы, Апас муниципаль районы

8нче сыйныфта туган(татар) тел әдәбияты дәресенең технологик картасы

Класс: 8 сыйныф

Уку предметы: туган(татар) тел әдәбияты

Дәреснең тибы: УМ кую һәм чишү. Формасы: эзләнү

Дәреснең темасы : “Танылган шәхес -Сөббух Рәфыйков”

Белем бирү максаты: (эчтәлек буенча) С.Рәфыйков турында мәгълүмат бирү, аның тормыш юлына, иҗатына күзәтү ясау.

(эшчәнлек буенча) таблица, карточка, текст, китап белән эш, читтән торын экскурсия ясау, аудиоязма тыңлау, терәк конспект, “Вакыйгалар панорамасы”н төзү аша укучыларның сәләтен формалаштыру;

Бурычлар: логик фикер йөртү сәләтен үстерү; сөйләм телен һәм сәнгатьле сөйләмне камилләштерү; горурлык хисләре тәрбияләү.

УУГ(УУД) формалаштыру:

- Шәхескә кагылышлы УУГ:

патриотик тәрбия: туган телгә, танылган шәхесләргә карата ярату, хөрмәт хисенә ия

булу.

Рухи-әхлакый тәрбия: үзеңнең һәм иптәшләреңнең тәртибен бәяли белүгә әзер булу.

Эстетик тәрбия: сүз, җыр сәнгатен эмоциональ кабул итә алу; үз төбәгең белән бергә башка халыклар иҗатын да үз итү.

Физик тәрбия: үз сәламәтлегеңә җаваплы карау.

Метапредмет нәтиҗәләр:

- Танып белү УУГ:

1. База логик гамәлләр: таныш һәм әлегә чаклы яңа булган билгеләрне ачыклау; күзәтүләр алып бару, эзлеклелек урнаштыру, табылган белемнәрдән нәтиҗә ясау.

2. База тикшеренү-эзләнү гамәлләре: бирелгәннәр буенча эзләнү эше алып бару; күзәтүләрдән чыгып, нәтиҗә ясый алу; үз фикереңнең дөреслеген дәлилләү.

3. Мәгълүмат белән эш:

Мәгълүмат эзләгәндә төрле эш формаларын, методларын куллану; сайлау, анализлау һәм системалаштыру.

Коммункатив УУГ:

1. Аралашу: фикерне кабул итү, эмоцияләрне чагылдыру; телдән һәм язмача үз фикереңне җиткерү; диалогта катнашу; сораулар бирү, сорауларга тулы җавап кайтару; иптәшләр алдында чыгыш ясау.

2. Үзара хезмәттәшлек: командада һәм аерым гына эшләү; рольләрне бүлешү; үзара аңлашу; фикерләрне гомумиләштерү; сөйләшүләр алып бару.

Регулятив УУГ:

1. Үзоешкалык: уку мәсьәләләрен кую; аерым гына, төркемнәрдә карарлар кабул итү; эшнең тәртибен-планын төзү;

2. Үзтикшерү: үзбәя, рефлексия формаларын белү; уңышларның һәм уңышсызлыкның сәбәбен аңлату; бәяләү.

3. Эмоциональ интеллект: үзеңнең һәм иптәшләреңнең хисләре белән идарә итү.

4. Үзеңне һәм башкаларны кабул итү: башка кеше фикере белән исәпләшү; җитешсезлекне тану.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Дәрес буенча: Сөббух Рәфыйков турында мөһим мәгълуматларны истә калдыру.

шәхси: эшләү барышында үз-үзеңә төгәл бәя бирү алу.

Предмет ара: Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү; Дәрестән тыш эшчәнлек, җыр дәресе белән бәйләнеш.

Кулланылган методлар: (иҗади характердагы) эзләнү, коммуникатив, әңгәмә, өлешчә проблемалы укыту.

Ярдәмче мотивлаштыру алымнары: “Терәк конспект”, “Микрофон”, “Вакыйгалар панорамасы”.


Төп алым: таблица, карточка белән эш, диалог, монолог, китап буенча эш

| **Дәреснең этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** |
|---|---|---|
| 1.Мотивлаштыру-ориентлашу (2 мин.)<br>1.*Уңай психологик халәт тудыру*.<br>Максат: уңай халәт тудыру аша уку | Укучыларны сәламләү. Дәрескә әзерлекне тикшерү. Психологик әзерлек.<br>-Хәерле көн, укучылар, исәнмесез. Кәефләрегез ничек? (яхшы, шәп, менә дигән! һ.б.) Минем кәефем дә бик күтәренке бүген.<br>Дәресебезне “Үз уңышына ышанган кеше уңышка ирешә” (К.Ф.Гебель)дигән канатлы сүзләр белән башлап җибәрәсем килә.(слайд) Укучылар, әлеге | Бер-берсен сәламлиләр; дәрескә әзерлекне тикшерәләр; җавап бирәләр |

<table>
<tr>
<td>эшчәнлегенә<br>әзерләү.</td>
<td>юлларның мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? (укучы җавабы)<br>Сезнең нинди уңышларга ирешкәнегез бар? (укучыларның җаваплары тыңлана)<br>-Афәрин, котлыйм. Сезнең арада оста шигырь иҗат итүчеләр дә, моңлы җырчылар да бар икән.<br>Эш барышында да үз уңышларыбызга ышана белик, ә килеп чыккан кимчелекләрнең бергәләп төзәтү юлларын табып, дәресебезне дәвам итик.</td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td>2.Өйрәнелгән УМ искә төшерү<br>(2 мин.)<br>Максат:<br>Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү: “Тау ягының танылган шәхесләре” темасы буенча (түгәрәк эшчәнлеге)укучыларның белемнәрен барлау.</td>
<td>Укучылар, һәр якның, һәр төбәкнең үзенә күрә танылган, зур уңышларга ирешкән шәхесләре бар. Алар ил тарихында, әдәбиятыбызда үзләреннән соң тирән эз калдыралар, аларның исемнәрен без бүген дә беләбез, тормыш баскычларын өйрәнәбез.<br>Әйдәгез, үзебезнең Тау ягы- Апас районының күренекле кешеләрен искә төшереп үтик әле. Сез кемнәрне беләсез икән? (Слайд)<br>Шагыйрьләр-<br>Җырчылар-<br>Композиторлар-<br>Сәхнә артистлары-<br>Галимнәр – һ.б.<br>Күрәсезме, укучылар, безнең Апас районыннан, алай гына да түгел, туган авылыбыз Олы Бакырчы авылыннан гына да (Ш.Галиев, Т.Әйди) бик күп таланлы шәхесләр чыккан. Без алар белән, әлбәттә, горурланабыз. Алар истәлегенә төбәкара фестивальләр, бәйгеләр оештырабыз.</td>
<td>“Горурлан!”<br><br>Апас районыннан чыккан танылган шәхесләрне искә төшерәләр</td>
</tr>
<tr>
<td>1. УМ куюга әзерлек: 7 мин<br>Максат: Туган тел(татар) әдәбияты, җыр дәресләрендә өйрәнелгән темаларны практикада кулланып, биремне үти алу, теманы ачыклау.<br><br>3.1. төркемнәрдә эш бүленеше<br>(2 мин)</td>
<td>Укучылар, үз ягыбызның талантлы шәхесләрен белү белән генә тукталып калсак – бер дә дөрес булмас. Башка районнарның да горурланырлык кешеләре бар. Менә шуларның берсе белән без бүген танышып та китәчәкбез.<br>Теманы ачыклау өчен, мин сезгә таблица тәкъдим итәм. Туган(татар) теле-әдәбияты, җыр дәресләрендә өйрәнелгән мәгълүматларга таянып, фотоларына карап, бирелгән шәхесләрнең исемнәрен 3нче баганага урнаштырабыз.<br>Әлеге биремне төркемнәрдә эшлибез. Таблицаның 1нче юлын -1 төркем, 2нче юлын- 2 төркем, ә 3нче юлны- 3нче төркем башкара.(төркемнәргә әлеге таблица чыгартып та бирелә, слайдта күрсәтелә)<br>Башладык. 2 мин вакыт бирелә.<br>Терәк карточкалар:
<table><tr><td>Сөббух Рәфыйков</td><td>Аяз Гыйләҗев</td><td>Гөлшат Зәйнәшева</td></tr></table>
Таблица:
<table><tr><td>Сәнгатьле итеп Укы!</td><td>Игътибар белән кара, Таны!</td><td>Сорауга җавап бир! Иремен урнаштыр!</td></tr></table>
</td>
<td>Игътибар белән тыңлау<br><br>Төркемнәрдә эшне бүлешәләр, эшлиләр<br><br>Фикерләр, искә төшерәләр.</td>
</tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1нче төркемгә куелган максат: дәрестә алган белемнәрне искә төшерү | Әдилә... Әдилә... бер-ике тапкыр чәчен тартып елатканым да бар... Ул үзгәргәндер, без дә үстек... “Алтын булып агаем ла... Көмеш булып тамаем!” Көн суык. Дамир- олаучы, ул безне Чаллыга хәтле илтергә тиеш. |  | Шәхеснең 2 фотосын чагыштыру аша анализлыйлар, җыр дәресендә, кичәдә өйрәнгән җырчының исемен ачыклыйлар. Истәлек буенча уйланалар. Фотога карап бәя бирәләр. Фикерләү сәләтен үстерә | Сорау: өзек кайсы әсәрдән? Авторы кем? |
| 2нче төркемгә куелган максат: Дәрестән тыш эшчәнлектә, җыр дәресендә алган белемнәрдә бәйләнеш булдыру. | Җырлар авторы 1928-2005нче еллар аралыгында гомер кичерә. Элекке Сарман якларыннан. “Кояш гомере”, “Туган җирем-Татарстан” һ.б. җырлар авторы. |  | | Сорау: кем турында сүз бара? Үзегез теләгән 1 җырын башкарып күрсәтегез. |
| 3нче төркемгә куелган максат: таныш булмаган шәхесне ачыклау. | Әлеге язучы киң җәмәгатьчелеккә “Беренче яз” (1958) романы белән таныла. “...Сарман районы Нөркәй урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытты. Берәр сөйкемле сөяге бар идеме, аны һәрчак балалар сырып алган булыр. Ул концертларда үзе дә катнаша, шигырьләрне аһәңле, сәнгатьле итеп сөйли иде”. - Таһир Шәрәфетдинов истәлегеннән. |  | | Әлеге шәхес кем булыр? Фотосына карап, аның турында тагын ниләр әйтә алырсыз? |
| 3.2.Төркемнәр чыгышы: (5 мин.) | (Укучылар эшләгәндә салмак кына “Кояш гомере” җырының музыкасы куела.)<br>Вакыт бетте. Сүзне 1нче төркемгә бирәбез. Калган укучылар иптәшләрен тыңлап утыра. Дөреслеген билгеләргә ярдәм итәбез.<br>(1нче төркемнең җавабы тыңлана. “Язгы кәрваннар” повесте турында сүз баруы ачыклана. Бу А.Гыйләҗев. чөнки яңа гына 8нче сыйныфта укыдылар.)<br>-Укучылар, кемнәр 1нче төркемнең фикере белән килешә-бастык.<br>-Бик әйбәт. Сүзне 2нче төркемгә бирик.<br>(2нче төркем чыгыш ясый. Әгәр укучылар белмәсәләр, ярдәмгә башка төркем укучылары килә.)<br>Бик дөрес. Сүз Гөлшат Зәйнәшева турында бара. Укучылар, бик тиздән кояшлы яз да килеп җитәр. Ә аның белән бергә, әлбәттә, әниләр, хатын-кызлар бәйрәме -8нче март. Әйдәгез әле, 2нче төркем белән килешкән барлык укучылар да “Кояш гомере” җырының 1 генә куплетын җырлап үтик. (бергә башкару, сүзләре слайдта)<br>-Афәрин. Сыйныфта оста җырчылар булганда, теләсә нинди җырны башкара алабыз без. | | Төркемнәр чиратлашып чыгыш ясый, калган укучылар игътибар белән тыңлыйлар.<br>“Кояш гомере” җырын җырлау<br>Сорауларга җавап бирәләр Фикерләрне белештерәләр, | |

| | | |
|---|---|---|
| -Җыр башкару<br>Максат: укучыларның кәефләрен күтәрү, сәләтен ачыклау.<br><br>3.Биремнәрне берләштерү-уртак сыйфатларын ачыклау. | Сүзне йомгаклап, 3нче төркемгә бирик. (кычкырып укыйлар, җавап бирәләр. Фотосына карап бәя биргәндә башка төркем укучыларын да катнаштырырга). Әлеге язучы сезгә танышмы? Аның әсәрләрен укыганыгыз бармы? (укучылар җавабы)<br>Укучылар, әлеге шәхесләрне барысын да нәрсә берләштерә? (җаваплар төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, танылган шәхесләр, уңышка ирешүчеләр, көләч йөзлеләр һ.б. ) Алар чыгышлары белән алар кайсы яктан? (...)<br>Бик дөрес. Укучылар, Сарман ягы да танылган шәхесләргә бик бай. Ул як без яратып укый торган шигырьләр, хикәя-повестьлар авторлары –Клара Булатова, Мәдинә Маликова, Аяз Гыйләҗев, әдәбият дәреслекләре авторы, галим Фәрит абый Яхинны һ.б. танылган кешеләрне бүләк иткән. (слайдта күрсәтелә)<br>"Сарман ягы - нурлы як!" дигән сүзләр бик тә туры килеп тора үзләренә. | уртак якларны ачыклыйлар |
| 4. Дәреснең темасын ачыклау.<br>10 мин<br><br>4.1.Дәфтәрләрдә число, тема язу.<br>максат: укучыларның яңа теманы ни дәрәҗәдә үзлектән аңлый алуларын бәяләү<br><br>4.2. УМ адымлап чишү. Теманы аңлау өстендә эш:<br><br>1нче төркем:<br>-"Читтән торып экскурсия"; | Укучылар, слайдка игътибар итик әле. Әлеге шәхесләрнең кайсысы сезгә таныш түгел? Төркемнәрдә фикерләшеп алыгыз. Шуннан чыгып, дәреснең темасын ачыклап китик. (Укучылардан сорау) Җавап:<br>-Без бүгенге дәрестә Сөббух Рәфыйков белән танышачакбыз.<br>Бик дөрес, Аяз Гыйләҗев белән күптән түгел генә таныштык, Г.Зәйнәшевага багышланган кичәдә катнаштыгыз. Сөббух Рәфыйков-безнең өчен тагын бер яңа шәхес.<br>Дәфтәрләрне ачып, бүгенге числоны һәм теманы язып куйыйк.<br>(Укытучы тактага яза, укучыларның матур язуына,дөрес утыруына игътибар итә)<br>Укучылар, дәрескә максатлар билгеләп алыйк әле. Парларда киңәшеп, алдыгызда яткан карточкаларга язып, тактага баганалап элеп куябыз. 2 минут вакыт бирелә. Тактага элгән вакытта һәр укучы үз максатын кычкырып укый. Мисал өчен,<br>Сөббух Рәфыйковның кем булуын ачыклау; иҗатына күзәтү ясау, истә калдыру; нинди жанрда иҗат итүен белү һ.б. әгәр бертөрле максатлар булса, алар берләштерелә.<br>Бик яхшы. Укучылар, әлеге максатларга ирешү өчен мин сезгә уңышлар телим.<br>Шәхес белән танышу өчен, төркемнәргә түбәндәге эш төрләрен тәкдим итәсем килә:<br>1нче юнәлеш: читтән торып экскурсия (заочная экскурсия)<br>С.Рәфыйков тормышы, иҗатына читтән торып экскурсия ясау.-1нче төркем. Укучылар кабинетта | сорауларга җавап бирү<br><br>укучылар теманы әйтәләр<br><br>дәфтәрләргә язу<br><br>парларда дәрескә максат кую<br><br>игътибар белән тыңлау<br><br>сорауларга җавап бирү<br><br>С.Рәфыйковның тормыш юлы, |

| | | |
|---|---|---|
| 2нче төркем:<br>-“Логик чылбыр”, “Сүзләр һавасы”<br><br>3нче төркем:<br>-“Эзләнү эше”.<br><br>4.3. Төркемнәр чыгышы<br><br>4.4.Ял итү.<br><br>4.4.Өстәмә материал.<br>Максат: сәләтле укучыларның белемнәрен тирәнәйтү<br><br>4.5. Дәреслек, әдәбият тарихы белән эш<br><br>4.6. Нәтиҗә ясау.<br>Максат: төркемнәрдә алынган яңалыкларны берләштерә алуларына ирешү | урнашкан “Язучылар почмагы”на чакырылалар. Анда С.Рәфыйков китаплары, портреты, аның турында галимнәр тарафыннан әйтелгән фикерләр тупланмасы, тормышы белән бәйле фотолар һ.б. куелган күргәзмәлек урын ала. Укучылар карап, укып, өйрәнеп, мәгълумат туплыйлар.<br><br>2нче юнәлеш: “Логик(Эзлекле) чылбыр”, “Сүзләр һавасы”<br>“С.Рәфыйковның тормыш сукмаклары” темасына “Эзлекле чылбыр”, “Сүзләр һавасы” тәкъдим ителә. Укучылар шуның аша Сөббух Рәфыйков белән танышалар.<br><br><br><br>3нче юнәлеш: “Эзләнү эше”<br>Сөббух Рәфыйков китапларыннан, татар әдәбияты тарихыннан һ.б. бирелгән китаплардан эзләнү эше оештыру.- 2нче төркем.<br>Эшебезне башладык. Төркемнәрдә эшне тигез бүлегез. Һәрбер кешенең уңышы-ул төркемнең дә уңышы. Сезгә 5 минут вакыт бирәм.<br>(салмак кына музыка куела. Бирелгән вакыт аралыгында укытучы төркемнәр арасында йөри, эшкә юнәлеш бирә.)<br>Вакыт чыкты. Сүзне 1нче төркемгә бирик. Аларны тыңлау өчен, барыгыз да “Язучылар почмагы”на рәхим итегез, хәрәкәтләнеп, ял да итеп алырсыз. Сәламәтлек һәркем өчен бик кирәк.<br>(1нче төркем экскурсия барышында С.Рәфыйков турында белгән яңалыклары белән уртаклашалар)<br>-Афәрин. Экскурсия бик уңышлы булды. Рәхмәт, укучылар. Урыннарга утырдык.<br>Сүзне 2нче төркемгә бирик. (Укучылар “Эзлекле чылбыр”ны тактага эләләр. Берәм-берәм | иҗаты белән танышалар. Бирелгән китаплардан эзләнү эше оештыралар, үзенчәлекле якларын билгелиләр. Төркемнәрдә эшлиләр. |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>иптәшләрен С. Рәфыйковның тормыш сукмаклары белән таныштыралар. Төркемдәге һәр укучы да катнаша!) Әлеге чылбырны истә калдырыгыз укучылар, бәйгеләрдә, олимпиадаларда катнашканда алар сезгә ярдәм итәчәк.<br>-укучылар, 2нче төркем сезгә нинди яңалыклар җиткерде? С.Рәфыйков кайларда укыган? (тиз-тиз 1нче һәм 3нче төркем укучыларына сорау биреп, тыңлау дәрәҗәсен тикшерү)<br>Бик шәп, 2нче төркем укучылары сезгә кирәкле мәгълүматлар бирделәр.<br>-рәхим итегез, 3нче төркем. Эзләнү барышында нинди яңалыклар таптыгыз. Шулар белән бүлешеп алыгыз әле.<br>(сөйлиләр, соңыннан 1-2нче төркемнәргә сорау бирү)<br>Булдырдыгыз, укучылар. Инде фикерләребезне берләштереп алыйк. Кем ул С.Рәфыйков? Ул кайда һәм кайчан туган? Ни өчен кулга алына? Нинди әсәре белән таныла? һ.б.<br>Игътибарлылыкка сорау:<br>Укучылар, быел С.Рәфыйковның тууына ничә ел булачак? (105 ел) Сарман районында аның туган көне быел да зурлап билгеләп үтеләчәк. Ел саен С.Рәфыйков исемендәге премияләр тапшыру тантанасы да оештырыла.<br>Димәк, юбилярлар рәтенә тагын бер язучыны өстәп куячакбыз.</td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td>5. УМ чишүне дәвам итү, ныгыту<br>12 мин.<br><br>5.1.“Терәк конспект” төзү. Максат: тыңлау аша укучыларның белемнәрен бәяләү<br><br>Укучылар-ның яңа теманы аңлау дәрәҗәсен тикшерү</td>
<td>Укучылар, хәзер мин сезгә “Шәхесләр” тапшыруыннан аудиоязма тыңларга тәкъдим итәм. https://1zolenta.com/name/-681056496.221274490-shheslr-sbbuh-rfyykov (9 мин)<br>Һәрберегезгә “Терәк конспект”лар таратам.(яки “Паспорт төзү”) Тыңлау барышында конспектларны тулыландырып барырга кирәк булачак. Игътибар белән тыңлап утырыгыз, бер-берегезгә комачауламагыз.<br>(аудиоязманы тыңлау, индивидуаль эшләү)
<table>
<tr><td colspan="3">(укучының исеме, фамилиясе) “Терәк конспект”</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Язучының исеме</td><td></td></tr>
<tr><td>2</td><td>Туган һәм үлгән елы</td><td></td></tr>
<tr><td>3</td><td>Туган авылы, районы, республикасы</td><td></td></tr>
<tr><td>4</td><td>Әти-әнисенең исеме</td><td></td></tr>
<tr><td>5</td><td>Балачагы</td><td></td></tr>
<tr><td>6</td><td>Беренче әсәре, шигыре</td><td></td></tr>
<tr><td>7</td><td>Кайсы газета-журналларда эшләве</td><td></td></tr>
<tr><td>8</td><td>Нинди тарихи вакыйгаларда катнашкан (сугыш...)</td><td></td></tr>
<tr><td>9</td><td>Әсәрләре, шигырьләре</td><td></td></tr>
<tr><td>10</td><td>Әдәбиятка алып кергән яңалыгы</td><td></td></tr>
<tr><td>11</td><td>Кайда үлгән (билгеле булса)</td><td></td></tr>
</table></td>
<td>Карточкага язу, биремне эшләү,<br><br>Кызыклы мәгълүматларны тыңлыйлар, Конспектка тиешле мәгълуматларны язалар<br><br>“Сорау-Җавап” әңгәмәсендә катнашалар,</td>
</tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| 5.2.Тикшерү, бәяләү | Әйдәгез, конспектларны тикшереп алыйк. 1нче биремгә җавапны _____әйтә. (2нче бирем, 3,4 һәм башкалар. Укучылардан берәм-берәм сорала. Җавабы булмаган укучыларга иптәшләре тарафыннан ярдәм ителә.)<br>Бик яхшы. Әлеге конспектларны дәфтәрегезгә куегыз, өй эшен әзерләгәндә ярдәм итәчәк.<br>Укучылар, без бүген кайсы як шәхесләре белән таныштык? Сарман ягыннан нинди шәхесләр чыккан? Кем ул С.Рәфыйков? (берәм-берәм сорау) | үзләрен бәялиләр |
| 6. Белемнәрне тикшерү.<br>5 мин.<br><br>6.1.“Вакыйгалар панорамасы” аша белемнәрне тикшерү.<br><br>6.2.Бәяләү.<br><br>7. Эмоциональ рефлексия<br>5 мин<br><br>7.1.Нинди УМ чиштек?-җавап бирү.<br>Дәрескә гомуми бәя<br>“Микрофон” алымы<br><br>3.Өй эше:<br>2 мин. | -Белемнәрегезне тикшереп алыйк. Слайдта “Вакыйгалар панорамасы” бирелгән. С.Рәфыйков тормышына караган карточкаларны, саннарны, рәсемнәрне эзлекле рәвештә язарга.( Укучылар урыннарда сыйныф эше дәфтәрләренә эшлиләр. Теләге булган 1 укучы такта янына чакырыла, бирелгән карточкалар, рәсемнәр тактага эленә. 1 укучы ноутбукта эшли.)<br><br><br>Вакыт бетте. Эталон буенча тикшереп һәм бәяләп алыйк. (слайдта бирелә) (урындагы укучылар эталон буенча, такта артындагы укучы бергә бәяләнә, ноутбукта эшләгән укучының билгесен компьютерүзе куя)<br>“5” билгесе алучылар, бастык. (барлык укучыларга да билгеләр куела)<br>Кемнәр бу дәрестә уңышка ирештек дип санийлар- үзләрен котлап кул чабалар. Афәрин, укучылар.<br>Дәресебезне “Үз уңышына ышанган кеше уңышка ирешә” дигән канатлы сүзләр белән башлап җибәргән идек. Бу фикерләрне алган билгеләрегез белән тагын бер кат дәлилләп куйдыгыз.<br>Инде дәресебезгә куйган максатларга әйләнеп кайтыйк әле. (максатларны берәм-берәм укыйлар, ирешелгән нәтиҗәләрне әйтәләр. Бу урында “Микрофон” алымын да кулланып була. Һәр укучы үз максатының нәтиҗәсен башкаларга микрофон аша җиткерә). Димәк, куелган максатларыбызга тулысынча ирештек.<br>Алдагы дәрескә өй эшен тәкъдим итәм. Сферумнан һәм көндәлекләрдән дә карый аласыз. (аңлатыла) | Үзлектән “Вакыйгалар панорама”сын төзиләр<br><br>Эталон буенча тикшерәләр<br><br>өй эшен тыңлау, аңлашылмаса сораулар бирү |

| | | |
|---|---|---|
| Йомгаклау. Алдагы дәрескә тәрбияви эмоциональ халәт тудыру | -С.Рәфыйков тормышы буенча төзелгән паспортны истә калдырырга.<br>-Тема буенча 2 сорау әзерләп килергә.<br>-С.Рәфыйковның балалар өчен язылган 1 шигырен яки хикәясен укырга.<br>Укучылар, әгәр сез бу тормышта ниндидер әһәмиятле уңышка ирешергә телисез икән, үз көчегезгә ышаныгыз, ярты юлда туктап калмагыз. Авырлыклар булса- янәшәгездә укытучыгыз, иптәшләрегез, әти-әниегез барын онытмагыз, сау-сәламәт булып, илебезнең ышанычлы кешеләре булыгыз!<br>Дәресебез тәмам. Актив катнашуыгыз өчен рәхмәт, киләчәктә уңышлар. | |

**Кулда каләм, телдә фикер...**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнәшевага багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Ганиева Алсу Сахиул кызы,

Менделеевск шәһәренең Советлар Союзы Герое М. С. Фомин исемендәге

1нче урта мәктәбе, Менделеевск районы

Максат: Күренекле шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнәшевның тормышы һәм иҗат юлы белән якыннан таныштыру, күренекле шәхесләребез турында укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, татар шигъриятенә мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау: Гөлшат Зәйнәшева портреты, шагыйрәнең тормышын һәм иҗатын чагылдыручы китаплар, газета- журнал материаллары, төрле елларда чыккан шигырь китаплары, плакатлар, презентация.

1 нче алып баручы. “...Гөлшат Зәйнәшева популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйды”, – дип язган язучы Роза Хафизова. Чыннан да, моның белән килешми мөмкин түгел.

2 нче алып баручы. Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми болай дигән: “Синең җырларыңның ... сихри бер үзенчәлеге, күңелне яулый торган көче бар...аларга гомумкешелек тойгылары салынган. Сәнгатьнең бөтен көче дә шунда түгелме соң?”

Җыр. ”Туган ягым – гөлләр иле” (Сәлимә Шәмсина музыкасы).

1 нче алып баручы. Г.Зәйнашева моңлы, матур тавышка ия була. Һәркем белә: җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле, чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне беркемнән яшермичә җыры аша әйтеп бирә.

2 нче алып баручы. “Шагыйрә буларак, Гөлшат апа бик бәхетле иҗатчы булды. Язмыш аны композиторлар: Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Сара Садыйкова, Бәхти Гайсин, Фәхерахман Әхмәдиев, Зиннур Гыйбадуллиннар белән очраштырды. Алар белән бергә иҗат иткән моңлы, дәртле җырларны башкарырга аның юлына атаклы җырчылар Әлфия Авзалова белән Илһам Шакировны чыгарып куйган,” – дип искә ала язучы Рабит Батулла.

1 нче алып баручы. Сарман районы Иске Теләнче авылында туган кечкенә Гөлшатны язмыш ничек кенә кыйнаса да, ул туган ягына мәхәббәтен югалтмый. Авылның матур табигате, чишмәләре күңеленә юаныч, илһам бирә.

1 нче укучы.
И авылым, тыныч,имин булсын
Ал таңнарың килер көннәрең.
Сула, шиңә генә күрмәсеннәр
Күкрәп чәчәк аткан гөлләрең.
2 нче укучы.
Төшләремә кереп йөдәтте.
Бәлки, ял иттерер авылым өе
Сагынулардан арган йөрәкне.
Чәчәк аткан яран гөле белән
Ямьле безнең авыл өйләре.

Җыр. ”Туган авылым урамы” (Ганс Сәйфуллин музыкасы).

2 нче алып баручы. Һәрвакыт белемгә омтылышы көчле булган кыз Хуҗәмәт авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннан Минзәлә педагогия училищесына укырга керә.

3 нче укучы.

Минзәлә дип җырлар җырлап
Үтте яшьлек елларым.
Кая китсәм дә, Минзәлә,
Сине сагынып җырлармын.
Минзәлә суы ярсыган,
Ярларыннан ташыган.
Мин юкта ниләр булган дип,
Минзәләгә ашыгам.

“Сәяхәтчеләр җыры” (З.Гыйбадуллин музыкасы).

1 нче алып баручы. Сугышның бөтен авырлыкларын Минзәләдә укыганда татый кыз, ләкин ул бирешми. Тулай торак бүлмәсендә мич чыгарып үзен дә, иптәшләрен дә салкыннан саклап кала.

4 нче укучы.

Авыр сугыш елларында үстем.
Балда-майда гына йөзмәдем.
Юлны шадралатып уелып калды
Чабатадан йөргән эзләрем.
Яңа чабатага ирешү дә
Бик зур шатлык иде ул чакта.
Алтын башмакмыни – чабатаны
Куана идек кысып кочакка.

2 нче алып баручы. 1945-49 елларда Г.Зәйнәшева Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала.

5 нче укучы.

Казан урамнары буйлап йөрим,
Әллә кемне эзли күзләрем.
Урам ташларына яфрак-яфрак
Уелып калган яшьлек эзләрем.

Күңелемдә яшьлек хатирәсе,
Чын мәхәббәт, татлы моң, сагыш.
Урамнарда күргән һәрбер кеше
Җанга якын, никтер бик таныш.

6 нчы укучы.

Яшәрәсең, Казан, яңарасың
Борынгы булсаң да картаймыйсың,
Нинди көдрәтләрдән дәрт аласың?
Әллә чибәр кызларың яшәртә? –
Яшәрәсең, Казан, яңарасың.
Иман нуры иңде – айлы иттек
Изге Сөембикә манарасын.

1 нче алып баручы. Бик яшьли әдәбият белән җенләнеп йөрү, мәктәптә укыганда ук шигырьләр язарга омтылу, үзешчән сәнгать һәвәскәре булып авыл сәхнәләрендә, институт кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булгандыр. Илленче елларда шигърияттә Гөлшат Зәйнәшева дигән йолдыз яна башлый.

7 нче укучы.

Кулда каләм,телдә фикер
Ак кәгазьгә талпына.
Тирбәнсен каләм бары тик –
Чын гүзәллек хакына!..
Чын гүзәллекме кәгазьдә,
Әллә булыр тап кына?
Сулыш алмаска разый мин
Чын гүзәллек хакына!

8 нче укучы.

Илләр матур җыр белән,
Юллар матур җыр белән,
Эшләп арсак, эштән соң
Ял итик без җыр белән.
Сандугач та җыр суза,
Карлыгач та җыр суза,
Сандугачлы бу илдә,
Һәр яфрак җыр суза.

Җыр “Күңелле ял итегез” (Зиннур Гыйбадуллин музыасы).

2 нче алып баручы. Г.Зәйнәшева Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында хезмәт куя. Г.Тукай клубы директоры булып эшли, ә 1983 нче елдан профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

1 нче алып баручы. Үз шигырьләрендә Г.Зәйнәшева ватанга бирелгәнлек, тормыш, аналар язмышы турында уйлануларын һәм мәхәббәт темаларын яктырта.

9 нчы укучы.

Мин тормышка гашыйк
Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, томышка.
Чишмәләрнең җырын отар идем

Жыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Жыр ”Кояш гомере” (Ф.Әхмәдиев музыкасы).

2 нче алып баручы. Драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре дә зур игътибарга лаек. Комедияләре һәм драмалары күп тапкырлар Минзәлә драма театрында, Казан театрларында куела.

1 нче алып баручы. Күпкырлы талантка ия булган шагыйрә әдәби тәрҗемә эше белән дә уңышлы шөгыльләнә.

10 нчы укучы.

Туып-үскән шушы гүзәл җирдән
Җырларыма дәртле моң алдым.
Ә җырларым алып керде мине
Бәхет бакчасының түренә.
Я, әйтегез, ни яхшылык эшлим
Җавап итеп туган җиремә!?

2 нче алып баручы. Әдәбиять һәм сәнгать өлкәсендәге олуг хезмәтләре өчен Г. Зәйнәшева Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе” дигән мактаулы исемгә, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

1 нче алып баручы. 1995 нче елда күңелгә якын әсәрләрен, моңлы җырларын калдырып, Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева якты тормыш белән хушлаша.

Жыр “Китмә, сандугач” (Р.Яхин музыкасы).

11 нче укучы.
Иң гүзәл биеклек кайда, дип,
Сорадым мин очар кошлардан.
Ә кошлар, сора син, диделәр,
Галәмне яулаучы дуслардан.
Галәмне яулаучы дусларым
Чакырды күк йөзен иңлә дип.
Йолдызга менсәң дә, онытма,
Иң гүзәл биеклек җирдә, дип!..
Иң гүзәл биеклек җирдә ул,
Хезмәттә, кешенең эшендә.
Кешеләр күңеленең түрендә,
Тормышка мәхәббәт көчендә.
12 нче укучы.
Җырлый-җырлый китәм, ерак елга,
Юл елмая кояш нурына.
Кояш балкый, кояш үзе җырлый,
Җылы бирдең минем җырыма.

2 нче алып баручы. Ул – сәнгать кешеләренә, җырчы артистларга, сәхнә фидакарьләренә, бигрәк тә сәнгатькәр хатын-кызлардан З. Басыйрова, Ә. Галимова, Ә. Афзалова, Р. Ибраһимова, Ф. Ильская, Х. Әхтәмова, Ф. Сөләйманова һәм башкаларның сәхнә эшчәнлекләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, шул җөмләдән мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймpraованың, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың тормыш һәм иҗат юллары турында берничә монографик китап яза.

13 нче укучы.

Бер күрешү – бер гомер
Кил, бер күрешеп сөйләшик дисәң,
Идел-диңгезләр кичәр идем мин.
Таңнан уянып, карлыгач кебек,
Синең янына очар идем мин.
Иң якын кешең, җан дустың белән
Бер күрешү ул бер гомер, диләр.
Иң якын кешең, дустың санасаң,
Мине чакырып син хәбәр җибәр.

1 нче алып баручы. Чыннан да, шагыйрә Г. Зәйнәшева бәхетен туган ягында, туган җирендә таба. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә яңгырый. Аның җырлары – мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә, аның җырлары да яшәячәк.

Идел ярларына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты тугын илем,
Бәхет биргән җирем Татарстан.
Кая гына китеп, кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын!..
Күпме җырлар җырлый халкым бүген.
Туган җирем синең турында.
Мин бәхетле сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.
Кая гына китеп, кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын!..

## Тыңлыйсызмы, мин сөйлимен...

(Гөлшат Зәйнашева иҗатында халык авыз җәүһәрләре чагылышы.

Рус мәктәбенең татар төркеме укучылары өчен дәрестән тыш эшчәнлеккә авторлык программасы)

Салихова Гөлнара Атлас кызы,

Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты, Әлмәт районы

Халык зур, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.
Г.Тукай

Аңлатма язуы

Халык авыз иҗаты – халкыбыз тарафыннан безгә мирас булып калган тапкыр, зирәк сүзләр, халык моңы, халык сагышы. Кичке уеннарда туган сихерле әкиятләр, мәзәкләр, халык баһадирларын, күңелләрдә мәңге яшәр ил улларын, ил кызларын данлыклап җырлаган дастан-риваятьләр. Халык иҗаты күпкырлы, аның әсәрләре иксез-чиксез халык уе океанын хәтерләтә. Һәр әсәр гасырлар буе бер буыннан икенчесенә, әби-бабаларыбыздан яшь-җилкәнчекләргә авыздан-авызга үгет-нәсыйхәт белән күчкән. Һәр әсәр – вакыт эчендә төрлечә үзгәреп, камилләшеп калган, вакыт белән сыналган шул океанның затлы энҗеләре. Борынгы бабаларыбыздан калган, кадерләп сакланган бәясез мирас, бәхәссез асылташлар буларак, алар хәзер дә һәркемнең тормыш нигезе, дусты, терәге булып торалар. Көндәлек тормышның һәр мизгелендә дә әһәмиятле алар: халык

акылын җыйган мәкальләр, сынамышлар, моң-хисләребезне белдерерлек, авыр вакытларда юатырлык җырлар, акыллылык, намуслылык, үз халкыңа, үз сүзеңә тугрылыкка үрнәк булырлык риваять-дастаннар, әкиятләр, легендалар. Әйе, бу энҗеләрнең һәммәсе дөрестән дә тормыш нигезе. Шуңа да аларны өйрәнү, шулай ук кадерләп саклау һәм киләчәк буынга түкми-чәчми җиткерү – безнең иң әһәмиятле бурычларыбызның берсе булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлек программасы Гөлшат Зәйнашева иҗатындагы халык авыз җәүһәрләренә нигезләнеп төзелде. Программа бүлекләрдән, темалардан һәм практик дәресләргә бүленде. Практик дәрестә иҗади эшләр дә каралды.

Программаның максаты:

- халыкыбызның асыл җәүһәрләренең Г.Зәйнашева иҗатында һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын, аның ни дәрәҗәдә дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда куллануның мөһим булганлыгын күрсәтү;

- Г.Зәйнашева иҗатын өйрәнү аша укучыларда Туган телгә, халкыбызның кабатланмас асыл җәүһәрләренә кызыксыну уяту.

Махсус программаны өйрәтү буенча көтелгән нәтиҗәләр:

Предмет нәтиҗәләре:

- әдәбият теориясе: фольклор, халык авыз иҗаты, поэзия, шагыйрь, шигырь;

- төркем эчендә әңгәмәгә катнашу, тема буенча үз фикереңне формалаштыру һәм аны төпле дәлилләр белән башкаларга җиткерә белү;

- уку максатын мөстәкыйль формалаштыра белү;

- максатка ирешү юлларын билгеләү;

- эшчәнлек алгоритмын мөстәкыйль төзү.

Метапредмет нәтиҗәләре:

- Г.Зәйнашева иҗатын халык авыз иҗаты белән бәйләп өйрәнү;

- укыган буенча кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

- уңай һәм тискәре сыйфатларны билгели алу, чагыштырып нәтиҗә ясый белү;

- кирәкле мәгълүматны аерып алып, чагыштырып нәтиҗә ясый белү;

- халык иҗатының бай мирасын өйрәнү;

- әхлак һәм эстетик тәрбия бирү;

- билгеле күрсәтмә нигезендә эшли белү, нәтиҗә ясау;

- укучыларда җыр, рәсем, театр сәнгате аша эстетик зәвык тәрбияләү,алар аша китап укуга кызыксыну уяту.

Шәхси нәтиҗәләр:

- укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү;

- балаларда Г.Зәйнашева һәм халык авыз иҗаты аша Туган җиребезгә, табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү,

- тормышта үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, яхшылык эшләргә өндәү;

- яшь буындакешелеклелек, намуслылык, гаделлек сыйфатларына карата хөрмәт тәрбияләү;

- укучыларда хөрмәтле язучыларыбызга, халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү;

- сөйләм культурасын үстерү;

- укучыларга, әсәрләрдән чыгып, кеше әйберен сораусыз алырга ярамаганлыкны аңлату;

- балаларда рәсем,җыр һәм театр сәнгатенә карата кызыксыну уяту;

- балаларда үз-үзләренә карата җаваплылык, олыларны хөрмәт итү хисе тәрбияләү.

Программаның эш этаплары.

I этап. Халык авыз иҗаты әсәрләре һәм жанрлары белән танышу. Халык авыз иҗатының эчтәлеге турында фикер алышу. Борынгы бабаларыбыздан калган, кадерләп сакланган бәясез мирас, бәхәссез асылташлар буларак әлеге хезмәтләр гасырлар дәвамында тупланган, халык тәҗрибәсенә нигезләнгән һәм ул – югары әхлакый шәхес тәрбияләүдә мөһим чыганак булып торуы хакында фикер алышу.

II этап.Күренекле татар шагыйрәсе, драматург, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе (1991), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1969 елдан). Татарстан АССР атказанган сәнгать эшлеклесе (1988) Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.

III этап. Практик эш. Г.Зәйнашева иҗатын халык авыз иҗаты белән бәйләп, теге яки бу темага иҗади эшләр башкарыла, әдәплелек дәресләре, түгәрәк өстәл янында сөйләшүләр үткәрелә. Әсәрләр сәхнәләштерелә, җырлар һәм шигырьләр өйрәнелә.

Программаның эчтәлеге

“Тыңлыйсызмы, мин сөйлимен...”

- Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.

Акыллы сүзгә ни җитә!

- Халык авыз иҗаты әсәрләре турында сөйләшү.

Белмәгәнгә – әкият, белгәнгә- чын!

- Халык авыз иҗатының бер төре буларак әкият жанры тарихы белән танышу.

- Г.Зәйнашева иҗатында әкият жанры алымнары.

...Халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер.

- Укучыларны халык җырлары төрләре белән таныштыру. Җыр турында галимнәр фикере.

- Г. Зәйнашеваның җыр өлкәсендә актив иҗаты белән танышу.

Әйтем-сүзнең бизәге,

Мәкаль-сүзнең җиләге.

- Халык авыз иҗатының энҗе бөртекләре, фикер җәүһәрләре: мәкаль, әйтемнәр.

- Г.Зәйнашева иҗатында – мәкаль һәм әйтемнәр.

Театр — яктылыкка, нурга илтә, Кире юлга җибәрми, уңга илтә. Театр көлдерәдер, уйнатадыр, Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

- Гөлшат Зәйнашеваның драматургия өлкәсендә казанышлары.

Мәзәк – халыкның җор теллелеге, тапкырлыгы күрсәткече.

- Мәзәкләрнең төрләре. Тематикасы.

- Гөлшат Зәйнашеваның тормышында булган мәзәк хәлләрне туплау. (Истәлекләр китабыннан файдалану)

Энҗе җыю юлында.

- Гөлшат Зәйнашева турында истәлекләрне барлау. “Истәлекләр” темасына проект эшләре, китапчыклар ясау.

- Халык авыз иҗатын өйрәнгән галимнәр эшчәнлеге белән танышу.

“Халык авыз иҗаты” темасына проектлар әзерләү.

Тематик бүленеш

| № | **Темалар** |
|---|---|
| | “Тыңлыйсызмы, мин сөйлим...” |
| 1 | Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.(стенгазета, телдән журнал чыгару) |
| | Акыллы сүзгә ни җитә! |
| 2 | *Фольклор.* Халык авыз иҗаты әсәрләре турында сөйләшү. |
| 3 | *Практик дәрес*<br>Китапчыклар ясау. “Халык авыз иҗаты” схемасы белән эш. Хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләре. |
| | Белмәгәнгә – әкият, белгәнгә- чын! |
| 4 | Халык авыз иҗатының бер төре буларак әкият жанры белән танышу. |
| 5 | Г.Зәйнашева иҗатында әкият жанры алымнары. (“Бар кошларга түрә булгач” мисалында) |
| 6 | *Практик дәрес.*“Яраткан әкиятем” |
| 7 | *Практик дәрес.* “Борын-борын заманда....” (әкият язу) |
| 8 | Рәссамнәр сәнгатендә әкияти образлар. |
| 9 | *Практик дәрес* “Мин-рәссам”(рәсем конкурсы) |
| | ...Халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. |
| 10 | Халык һәм тарихи җырлары. Җыр текстларын сәнгатьле уку. Җыр турында татар һәм рус галимнәре фикере. |
| 11 | Г. Зәйнашеваның җыр өлкәсендәге актив иҗаты белән танышу.Халык җырлары традицияләрендә язылган, мәхәббәт, туган җир, табигать, яшьлек темаларына багышланган лирик шигырьләре. |
| 12 | Нәниләргә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына атап язылган шигырьләре һәм җырлары «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) китапларына күзәтү ясау |
| 13 | *Практик дәрес*<br>Түгәрәк өстәл янында. Җыр тыңлау, әсәр буенча фикер алышу. Халык җырларын оста башкаручы җырчылар турында әңгәмә. |
| 14 | *Практик дәрес*<br>Җыр турында халык мәкальләрен табып, китапчыкка язу |
| | Әйтем – сүзнең бизәге,<br>Мәкаль – сүзнең җиләге. |
| 15 | Халык авыз иҗатының энҗе бөртекләре, фикер җәүһәрләре: мәкаль, әйтемнәр. |
| 16 | Алтын хәзинә. Г.Зәйнашева иҗатында – мәкаль һәм әйтемнәр. |
| 17 | *Практик дәрес*<br>“Кайсы – мәкаль, кайсы – әйтем” (бирелгән мәкаль-әйтемнәрне аерырга) |

| | |
|---|---|
| 18 | *Практик дәрес*<br>*“Тапкыр телле”хикмәтле карт. Мәкаль-әйтемнәр әйтешү ярышы* |
| | Театр – яктылыкка, нурга илтә, Кире юлга җибәрми, уңга илтә. Театр көлдерәдер, уйнатадыр, Тагы үткән гомерне уйлатадыр. |
| 19 | Гөлшат Зәйнашеваның драматургия өлкәсендә казанышлары. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл ?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак» һ. б. драма-комедияләре. |
| 20 | *Практик дәрес.Әсәрләреннән өзекләр сәхнәләштерү* |
| | Мәзәк – халыкның җор теллелеге, тапкырлыгы күрсәткече |
| 21 | Мәзәкләрнең төрләре, тематикасы. |
| 22 | Гөлшат Зәйнашеваның тормышында һәм иҗатында булган мәзәк хәлләрне туплау.(истәлекләр китабыннан файдалану) |
| 23 | *Практик дәрес.*Мәзәк геройлары. Мәзәк язып карау. |
| | Энҗе җыю юлында |
| 24 | Гөлшат Зәйнашева турында истәлекләрне барлау. “Истәлекләр” темасына проект эшләре, китапчыклар ясау. |
| 25 | Халык авыз иҗатын өйрәнгән галимнәр эшчәнлеге белән танышу. |
| 26 | “Халык авыз иҗаты” темасына проектлар әзерләү. |
| 27 | Проектлары буенча презентация ясау. |
| 28 | Проектларны яклау дәресе. |
| 29 | Авыл китапханәсенә экскурсия.Г.Зәйнашева иҗатына һәм фольклорга караган китаплар белән танышу. Йомгаклау дәресе. |

## Шигърият дөньясына сәяхәт

(Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Галиәкбәрова Илмира Мөзәккир кызы,

2 нче санлы "Лилия" балалар бакчасы тәрбиячесе,

Сарман районы

Шигърият дөньясына сәяхәт
(Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Максат: балаларны Гөлшат Зәйнәшеваның иҗат юлы белән таныштыру, иҗатына кызыксыну уяту; сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен үстерү; балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам итү хисен тәрбияләү.

Җиһазлау: Г.Зәйнәшева портреты, китап күргәзмәсе, Г. Зәйнәшеваның тормыш һәм иҗат юлына багышланган рәсемнәр.

Кичә барышы:

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Түрдә Г.Зәйнәшеваның портреты эленгән, иҗатын чагылдырган рәсемнәр, китаплар күргәзмәсе.

Балалалар ярымтүгәрәк ясап утыралар, кайберләре Г.Зәйнәшева шигырьләрендәге персонажлар булып киенгәннәр.

Алып баручы.

Кадерле балалар, мин сезнең барыгызны да тылсымлы “Шигърият дөньясына” сәяхәткә чакырам.

Анда шундый күңелле булачак. Ни өчен дисезме? Җавабым гади: анда безне өлкәннәр һәм нәниләр ярата торган шагыйрәнең шигырьләре көтеп тора. Ә аның кем булуын менә шушы шигъри юллар әйтеп бирер.

Туган җирем кайда дип сорасаң,
Туган җирем Сарман ягында.
Бер кая да китмәм Сарманнан дип,
Уйлый идем бала чагымда.
Ләкин киттем, сүнеп юкка чыкты,
Хыяллары бала чакларның.
Бала чагым белән бергә сагынам
Чишмәләрен туган якларның.
Күңелемдә мәңге чыңлап торыр
Сарман чишмәләре тавышы.
Нигә моңлы син дип сорамагыз,
Җырларымда Сарман сагышы.

Балалар, бу шигырь юлларын безгә, күренекле татар шагыйрәсе – Гөлшат Зәйнәшева язган.

*Балалар “Гөлләр иле”җырын башкаралар. Кушымта 1.*

Алып баручы: Гөлшат апа Зәйнәшева иҗаты өчен кайдан шул кадәрле көч, илһам алган икән? Югыйсә, ул да гап-гади бер авыл баласы бит?!

Шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. Сарман районында Иске Теләнче авылында 1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Әмма бала чагын моңлы-җырлы Сарманда түгел, Илһам Шакиров төбәгендә түгел, Минзәлә якларында Югары Тәкермән авылында үткәргән.

Ә хәзер Г.Зәйнәшева язган “Бер атнада ничә көн?” шигырен тыңлап китик.

*Атна көннәре булып киенгән җиде бала шигырь сөйли.*

Бер атнада ничә көн?
Бер атнада 7 көн.
7 төрле исеме,
7 сен дә яттан бел.
Дүшәмбе, сишәмбе,
Чәршәмбе, пәнҗешәмбе,
Җомга, шимбә,
Якшәмбе.
Онытма шуны, яме.

Алып баручы: Балаларга саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен Гөлшат Зәйнәшева саннар турында шигырьләр язган. Әйдәгез, шигырьләрне сөйләп күрсәтик әле.

*Балалар саннар маскасын кигәннәр.*

1 санын кигән бала:

Саннар саный башласак,
Иң беренче – бер саны.
Мактап әйткән кебек, без
«Беренче» дибез аны...
Бер саны ул бер генә,
Әни дә бит бер генә,

«Әнием – бергенәм» дип
Кадерлибез гел генә.

2 санын кигән бала:
Табигатьтә бөтен нәрсә
Ике төрле килгән безгә.
Бер чорлары кара булса,
Икенчеләре ап-ак төстә.

3санын кигән бала:
Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле өчпочмакларны
Әни йөри пешереп.

4 санын кигән бала:
Түп-түгәрәк җир шары,
Аның да бар дүрт ягы.
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы.

5 санын кигән бала:
Әнкәй пешерә ял көнне безгә
Бишбармак бишебезгә:
Әткәй, әнкәй, абыйга,
Сеңелем белән миңа.

Алып баручы: Г.Зәйнәшева – җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес. Аның иҗатында туган якны ярату һәм сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, олы мәхәббәт хисләре, аналар язмышы, тарихи шәхесләр, тормыш, заман асылы турында уйланулар, мәхәббәт лирикасы, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Балалар “Кояш гомере” җырын җырлыйлар. Кушымта 2.

Алып баручы: Әниләргә багышлап нинди матур җыр язган безнең күренекле шагыйрәбез. Балалар, безнең әниләребез кебек үк якын, алар кебек үк назлы, сөйкемле дәү әниләребез дә бар бит әле. Әйдәгез алар турында да Гөлшат Зәйнәшева язган “Әбиемне яратам” җырын башкарыйк.

Балалар “Әбиемне яратам” җырын җырлыйлар. Кушымта 3.

Алып баручы: Рәхмәт, балалар. Ә хәзер табышмаклар чишәргә вакыт җитте. Табышмаклар төсләр турында. Һәр малайда бер төс бар, әгәр дә җавабын дөрес әйтсәгез, алар сезгә Гөлшат Зәйнәшева язган шигырьне сөйләячәк.

Малайлар шигырь сөйләгәч, шигырьдәге төс турында лента кияләр, тезелеп басып баралар.

Алып баручы: Беренче төс турында табышмакны тыңлыйбыз.

Беренче табышмак:

Күрә аласыз мине

Алмада һәм чәчәктә,

Карлыганда, җиләктә,

Помидорда бигрәк тә. (Кызыл)
1 нче малай.
Җырлый-җырлый җиләк җыям,
Кызыл каен җиләген.
Кып-кызыл җиләкләр белән
Тула инде чиләгем!..
Алып баручы:
Икенче табышмак: Мин урманнарны бизим,
Көзне чакырып китерәм,
Әйтә алсагыз мине,
Сезгә яфрак бүләк итәм. (Кызгылт-сары)

2 нче малай.
Алтын төсле матур яфрак,
Җәйдән көзгә бүләктер,
Көзләр мул уңышлы булсын
Дигән изге теләктер.
Һәр агач моңаеп кына
Кызгылт-сары яфрак коя.
Бала чага, шатланышып,
Кызгылт-сары яфрак җыя!
Алып баручы:
Өченче табышмак:Мин иң матур төс,
Иң якты төс,
Кояшта күреп була,
Лимон белән банан да
Минем төсне ярата. (Сары)

3 нче малай.
Сары чәчәктән чәчәккә
Оча сары күбәләк.
Сары күбәләк шатлана,
Сары күбәләк шатлана,
Чәчәк белән бергәләп.
Алып баручы:
Дүртенче табышмак: Мин урман төсе, яфраклар төсе,
Җирдә үсүче хәтфә чирәм төсе. (Яшел)

4 нче малай.
Язлар җитте, бар табигать:
«Без яшәрәбез,» - диде.
Урман, болыннар, тугайлар
Яшел киемен киде.
Алып баручы:
Бишенче табышмак: Сезнең өстегездә мин
Гөмбәз булып торам,
Яңгыр тамчысы белән
Уеннар да уздырам. (Ачык зәңгәр)

5 нче малай.
Күк йөзе күксел томан,
Күксел болытлар сыман...

Күксел диңгезләр дәшә,
Еракта уйный рәшә.

Алып баручы:

Алтынчы табышмак: Кайгырмагыз, дусларым,
Мине күргәч болытта,
Минем төсемне хәтта
Әйберләр дә ярата. (Зәңгәр)

6 нчы малай.
Зәңгәр елга өсләреннән
Агыла зәңгәр болыт.
Әллә шуңа бөтен нәрсә
Күренә зәңгәр булып.

Алып баручы:

Җиденче табышмак:Исемем минем кызык,
Шуңа күрә дә балалар,
Бик тиз алалар отып.
Тәмле җимешләремне,
Торалар бик озак көтеп. (Шәмәхә)

7 нче малай.
Шәмәхә төс – матур төс ул,
Шәмәхә төс яратам.
Урманга барсам шәмәхә
Чәчәкләр җыеп кайтам,
Чәчәкләр җыеп кайтам.

Алып баручы: Булдырдыгыз! Барлык төсләрне дә таптыгыз. Балалар, әйтегез әле без бу төсләрне барысын бергә кайда күрә алабыз?

Балалар: Салават күперендә.

Алып баручы: Дөрес, балалар! Ә хәзер без тагын бер конкурс үткәреп алабыз, рәсемнәр ясыйбыз. Кызлар рәсемне уң як өстәлдә, ә малайлар сул як өстәлдә ясыйлар. Рәсемнең исеме Гөлшат Зәйнәшева шигыре кебек үк “Без – табигать дуслары” дип атала. Салават күперендә күргән барлык төсләрне кулланып, сезгә бик матур рәсем ясарга кирәк булачак.

Г.Зәйнәшеваның “Тибрәнә җыр күңелдә” дигән җыры куела, ике команда да рәсемнәр ясый.

Алып баручы: Бик матур рәсемнәр ясагансыз, әйдәгез без аларны мольбертка куйыйк.

Балалар, ә сез беләсезме, Гөлшат Зәйнәшева уңган, тырыш балаларны кем дип атаган? Юкмы? Әйдәгез әле, балалар, Гөлшат Зәйнәшеваның бик матур җырын җырлап күрсәтик әле.

Балалар түгәрәккә басып, хәрәкәтләр ясый- ясый “Бөрлегәнем” җырын башкаралар. Кушымта 4.

Алып баручы: Менә, балалар, нинди күңелле шигырь кичәбез ахырына да җитте. Мин сезнең белән саубуллашам.

Барысы бергә: Сау булыгыз!

Кушымта1.

Гөлләр иле.
Туган ягым — гөлләр иле,
Гөлләр, сөмбелләр иле.
Гөлгә кунып сайрап кына
Үскән былбыллар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Туган ягым — гөлләр иле,
Гөлгә тиң таллар иле.
Ефәк кебек сызылып кына
Аткан ал таңнар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Туган ягым — гөлләр иле,
Борынгы Болгар иле.
Бүген көрәштә, хезмәттә
Җиңгән батырлар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.
Кушымта2.
Кояш гомере.
Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк диеп,
Өйрәткән энесенә:

Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим
Мин, әнием, сиңа!

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар:

Кушыл син дә, җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын!
Кушымта3.

Әбиемне яратам.
Мин үзем шәһәрдә яшим,
Авылга кайтам җәен.
Чөнки ул авылда яши
Яраткан әбекәем.

Әбиемне яратам, яратам,
Әбием янына кайтам.
Әбием анда ялгыз яши,
Миңе сагынып көтә.

Мин кайткач, шатланып йөри,
Мине бик кунак итә.
Әбиемне яратам, яратам,
Әбием янына кайтам.

Мин үскәч, әбием белән
Авылда торачакмын.
Әбием картаеп киткәч,
Ярдәмче булачакмын.
Әбиемне яратам, яратам,
Әбием янына кайтам!..

Кушымта4.

Бөрлегәнем.
Бөрлегәнем, җиләгем, дип
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.
Зур түгел шул, бик кечкенә
Бөрлегән мин, бөрлегән.
Бөрлегән генә булсам да,
Һәр эшкә дә өлгерәм.

**Туган җирем – изге җир**

(Гөлшат Зәйнәшеваның туган көненә багышланган шигырь бәйрәме)

Гаскәрова Ләйсән Минифәвис кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы,

Сарман районы

Максат: Гөлшат Зәйнәшеваның тормышына, иҗатына кызыксыну уяту; укчыларда аның мирасына тирән ихтирам тәрбияләү.

Җиһазлау: кичә уздырыла торган зал Г.Зәйнәшева иҗатына багышланган китап күргәзмәсе, укучыларның шагыйрә иҗатына караган иҗади эшләре белән бик матур итеп җиһазлана. Сәхнә уртасына Г.Зәйнәшева портреты элеп куела.

1 нче а.б. Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, укытучылар, укучылар!

Бүген мәктәбебездә бик олы бәйрәм – сөекле шагыйрәбез Гөлшат Зәйнәшева хөрмәтенә багышланган Шигырь бәйрәме.

2 нче а.б. Күренекле шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый.

1 нче а.б. Туган як һәркем өчен яшәргә көч һәм дәрт бирүче, иҗат итәргә илһам чыгынагы булган. Гөлшат Зәйнәшева туган җиргә багышлап үзенең иң яхшы шигырьләрен иҗат иткән.

1 нче укучы “Туган җирем –Татарстан”җырын башкара.

2 нче а.б. Туган авыл...Туган җир ... Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр . Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезе урнашкан кадерле туган авылы бар . Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Гөлшат Зәйнәшева иҗатында авыл темасы зур урын алып тора.

2 нче укучы “Авылым гөлләре”шгырен укый

Тагын кайттым әле авылыма –
Төшләремә кереп йөдәтте.
Бәлки ял иттерер авылым өе
Сагынулардан арган йөрәкне.
Чәчәк аткан яран гөле белән
Ямьле безнең авыл өйләре.
Күп күрдем мин тәрәз төпләрендә
Гөл үсмәгән чит-ят җирләрне.
Тыныч, имин булсын авылымның
Ал таңнары, килер көннәре.
Җырларыма күчә, моңнар булып
Күкрәп чәчәк аткан гөлләре.

1 нче а.б. Туган җирне, туган якны ярату, сагыну, ихтирам итү кеше күңелендә бирелгән иң гүзәл хисләрнең берсе.

3 нче укучы“Гөлләр иле” җырын башкара.

2 нче а.б. Адәм баласы кай тарафларда гына йөрсә дә, кайда гына яшәсә дә, аның уенда, йөрәгендә һәрчак кендек каны тамган газиз туган иле, туган җире. Ул анда беренче авазларын әйткән, беренче адымнарын атлаган, анда газиз әти-әнисе.

4 нче укучы“Җырлыйм әнием турында” җырын башкара.

1 нче а.б. Һәркемгә үз туган иле йөрәгенә бик якын һәм кадерле. Кайда гына йөрсәң дә, нинди генә матур җирләрне күрсәң дә, күңел барыбер үз туган иленә тартачак.

5 нче укучы“Үз илемдә” җырын башкара.

2 нче а.б. Бәйрәмебез ахырга якынлашты. Гөлшат Зәйнәшеваның туган көненә багышлап уздырылган шигырь бәйрәменә килүегез, катнашуыгыз өчен зур рәхмәт.

**Гөлшат Зәйнашеваның “Бер атнада ничә көн ?” шигырен уку**

(Мәктәпкә әзерлек төркемендә ана теленнән белем бирү эшчәнлеге)

Афзалова Алия Мөнәвир кызы,

Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге

1 нче “Каенкай” балалар бакчасы тәрбиячесе,

Сарман районы

Максат: 1.Балаларны Г.Зәйнашеваның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам итү хисен тәрбияләү. 2.Атна исемнәре турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. 3. Уеннар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү, татарча матур һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү.

Җиһазлау: Тылсымлы чәчәк, слайдлар, аудиоязма

Методик алымнар: сөйләү, күрсәтү, сорау-җавап, әдәби сүз, техник чаралар куллану , аңлату, күрсәтмәлелек, матур әдәбият уку.

Сүзлек эше: шәмәхә, кызгылт, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе, мәңге

Методик әдәбият:

1. Зарипова З.М. “Туган телдә сөйләшәбез”( 5 – 7 яшь), Казан, 2012.

2. Зарипова З.М.”Татарча сөйләшәбез” (6-7 яшь), Казан, 2012.

3. Закирова К.В. “Балачак аланы”, Казан, 2011, 445 б.

Эшчәнлек барышы:

I.Кереш өлеш.

Кояш булып киенгән тәрбияче керә :

- Хәерле көн, дусларым! Бүген мин сезне күреп сокландым һәм сезнең янга кунакка килдем. Әйдәгез, без дә бер-беребезне сәламләп алыйк! (Балаларны активлаштыру)

Сәлам юллыйк дусларга,

Яхшы кәефләр телик!

Туган телем – ана телен

Өйрәнергә дип килдек!

- Бүген бер-берегез белән дус булып, көнегезне күңелле итеп үткәрүегезне телим!

II.Төп өлеш.

Кояш:

- Мин бит кояш,

Нурларымны кызганмыйча тараттым,

Шуңа күрә көннәребез

Бик нурлы һәм бик якты!

- Дусларым,  нурларым белән җылытып, мин бик матур бер чәчәк үстердем. Карагыз әле, мин сезгә  аны  алып  та килдем. Бу гади генә чәчәк түгел, тылсымлы чәчәк. Ул чәчәкнең таҗлары төрле төстә. Нинди төсләрне күрәсез, әйтегез әле? (Балалар җаваплары: сары, яшел, зәңгәр, ал, шәмәхә, кызыл, кызгылт)

Кояш:

- Дөрес, дусларым! Чәчәк  ничә төстән тора,санагыз! (Балалар җаваплары)

- Әйе, чәчәк җиде төсле, аның исеме дә шулай: Чәчәк-Җидетөс (Цветик-семицветик) Мин үземнең нурларым белән чәчәк таҗларын төрле төсләргә буядым, алар  тылсымлы, һәрберсе сөйләшә белә! Әйдәгез,  тыңлап карыйк (слайдлар күрсәтелә, аудиоязма) :

1 нче сары таҗ – дүшәмбе, 2 нче яшел таҗ – сишәмбе, 3 нче зәңгәр таҗ – чәршәмбе, 4 нче ал таҗ – пәнҗешәмбе, 5 нче шәмәхә таҗ – җомга, 6 нчы таҗ –  шимбә, 7 нче кызгылт таҗ – якшәмбе

Кояш:  Әйдәгез әле, бу сүзләрне  без дә кабатлыйк. (Балаларны активлаштыру)

- Ничек уйлыйсыз, бу нинди сүзләр, нәрсәне аңлаталар?

- Дөрес, атна  көннәренең  исемнәре.

-  Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева бу көннәр турында бик матур шигырь язган, әйдәгез тыңлыйбыз.

Шигырь уку. Г.Зәйнашева.”Бер атнада ничә көн? “
Бер атнада ничә көн?
Бер атнада җиде көн.
Җиде төрле исеме —
Җидесен дә яттан бел:
Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе,
Пәнҗешәмбе, җомга,
Шимбә, якшәмбе —
Онытма мәңге!..

Шимбә белән якшәмбе —
Икесе ял көннәре.
Ял көннәре атнаның —
Чәчәкләре, гөлләре.

Ял көннәре атнаның
Чәчәкләре, гөлләре.
Атнаның яфраклары,
Димәк, калган көннәре.

Балаларга сораулар:

- Бер атнада  ничә көн? (Балаларның җаваплары.)

- Нинди көннәр ул? Әйдәгез, искә төшерик. (Балаларның җаваплары.)

- Ничә ял көне ? (Балаларның җаваплары.)

- Эш көннәрендә сез нишлисез? (Балаларның җаваплары.)

- Ә ял көннәрендә? (Балаларның җаваплары.)

- Ял көннәре атнаның чәчәкләре , гөлләре дигәнне ничек аңлыйсыз?

- Балалар, атна дәвамында,  җиде көн эчендә, бик күп яхшы эшләр башкарырга һәм ял итәргә була.Әйдәгез, без дә ял итеп алыйк!

Хәрәкәтле уен «Атна көннәре»

Дүшәмбе су коендым, (Йөзеп күрсәтәләр.)

Сишәмбе рәсем ясадым, (Рәсем ясап күрсәтәләр.)

Чәршәмбе озак итеп юындым, (Юынып күрсәтәләр.)

Пәнҗешәмбе футбол уйнадым, (Бер урында йөгерәләр.)

Җомга көнне сикердем, йөгердем, (Бер урында сикерәләр.)

Озак итеп биедем. (Бер урында әйләнәләр.)

Шимбәдә һәм якшәмбедә (Кулларны чәбәклиләр.)

Көннәр буе ял иттем. (Утыралар һәм йокыга талалар.)

Дидактик уен: “Атна көннәре”

Тәрбияче чәчәктәге саннарны күрсәтә, балалар шул санга туры килүче атна көненең исемен әйтеп утыра баралар. Мәсәлән: атнаның икенче көне – Сишәмбе. (Өстәмә сораулар: Бер атнада ничә көн? Ничә ял көне? Ничә эш көне?…)

III. Йомгаклау

- Дусларым, бүген без нинди яңа сүзләр белән таныштык?

- Бер атнада ничә көн?

- Атна көннәре ничек атала?

- Атна көннәре турында кем шигырь язган?

- Бүгенге шөгылебез тәмам, сау булыгыз!

## Гөлшат Зәйнашеваның иҗат кичәсе

(Иҗади кичә)

Хакимова Гөлүсә Габдулла кызы,

Җәлил бистәсенең 3нче санлы «Аленушка» балалар

бакчасының тәрбиячесе, Сарман районы

Кичәнең максаты: балаларга Гөлшат Зәйнашева иҗаты аша аның шигырьләренә һәм китапларына кызыксыну уяту.

Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк өйрәнү.

Кичәгә әзерлек чаралары һәм җиһазлар.

Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган күргәзмә. Түрдә Г.Зәйнашеваның портреты эленгән, иҗатын чагылдырган рәсемнәр, китаплар күргәзмәсе.

плакатлар:

1) «Бәхетемне синдә таптым…»

2) «Тәрәз төбемдә гөлем бар,

Күчереп утыртсам, сула.

Йөрәгем – шул гөл яфрагы –



Ерак калса ил туфрагы,

Өзелеп төшәрдәй була…»

1 а. б.: Яңгырасын көйләр, шат көлүләр,

Тирә-юньгә бүген таралсын.

Кемнәр болар – бәхетлеләр диеп,

Бөтен кеше безгә карасын!

Җыр башкарыла «Очрашу» \ Г. Зәйнашева сүзләре, И.Шакиров көе\

2 а.б.: Гөлшат апа Зәйнашева иҗаты өчен кайдан шулкадәрле көч, илһам алган икән? Югыйсә ул да гап-гади бер авыл баласы бит?!

Шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. Сарман районында Иске Теләнче авылында 1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Әмма бала чагын моңлы-җырлы Сарманда түгел, Илһам Шакиров төбәгендә түгел, Минзәлә якларында Югары Тәкермән авылында үткәргән.

1 а. б.: Ятимлек сәбәп моңа – моңлы ятимлек. Моңнар әнә каян килә ул Гөлшатка. Минзәләдә ул педагогия училищесын тәмамлый, Казанда педагогия институтында белем ала. Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында эшли.

2 а.б.: Ихтимал, бик яшьли әдәбият белән җенләнеп йөрү, мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтылу, үзешчән сәнгать һәвәскәре авыл сәхнәләрендә, бераз соңрак институт кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булгандыр.

1 а. б.: Казанда Гөлшат шагыйрьләр дөньясына эләгеп кенә калмый, музыкантлар, җырчылар, композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Композитор Алесандр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар куя. һәм ул «Туган җирем – Татарстан» җыры белән бәйгедә җиңеп чыга. Бу җырның музыкасы дәртле, халык күңелендә туган җиренә булган изге тойгыларны әйтеп бирерлек моңлы.

Җыр башкарыла «Туган җирем – Татарстан»\Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе

2 а.б.:Җыр төгәллекне, гадилекне, хакыйкатьне таләп итә. Гадилек… Моңа Гөлшат беренче җырларыннан ук төшенә. Аның җырларын халык бик яратып кабул итүенең сәбәбе, мөгаен, шулдыр: әлеге җырларның сүзе гади-тормышчан, ә музыкаль аһәңнәре халык рухына туры килә, сүзләргә салынган мәгънәне дулкынландыргыч итеп ачып бирә белүендә.

Җыр башкарыла. «Тибрәнә җыр күңелдә» \Г.Зәйнашева сүзләре, З.Сәгыйтов көе

1 а. б.: Г.Зәйнашева – җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес. Аның иҗатында туган якны ярату һәм сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, олы мәхәббәт хисләре, аналар язмышы, тарихи шәхесләр, тормыш, заман асылы турында уйланулар, мәхәббәт лирикасы, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Шигырьләрен уку, җырларын тыңлау

1. «Конфет»

2. Кояшлы яңгыр» \музыкаль композиция

3. « Корбан исемле малай турында әкият»

4. «Сөембикә» \музыкаль композиция

5. «Кояш гомере» \Ф. Әхмәдиев көе

6. «Аерылмагыз»\Ч.Зиннәтуллина көе

2 а.б.: Шагыйрәнең драматургия өлкәсендә дә эшләве билгеле. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

1 а. б.: Г. Зәйнашева – әдәбиятның төрле жанрларына караган ике дистәдән артык китап авторы. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» исемле китабы өчен Г. Зәйнашева 1991 нче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

2 а.б.: Җырлы һәм моңлы як кызы Гөлшат Зәйнашеваның эшчәнлеге үзе тудырган «буразналарны» хәтерләтә.

1 а. б.: Яхшы итеп, мул итеп, тирән итеп сөрелгән бу буразналар мул уңыш бирде, халык күңеленә хуш килде.

Җыр башкарыла. «Туган ягым – гөлләр иле»

**Сөббух Һади улы Рәфыйковның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган КВН кичәсе**

Гарифуллина Әлфинур Флер кызы,

Харисова Илсөяр Мөҗәһит кызы,

Икенче санлы Җәлил урта

гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат:

1. КВН кичәсендә Сөббух Рәфыйковның трмыш һәм иҗат юлын өйрәнү, язучы иҗатының төп үзенчәлекләрен аерып чыгару өчен җирлек тудыру;

2. Укучыларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү, сәнгатьле уку күнекмәләрен камилллләштерү;

3. Сөббух Рәфыйковның иҗаты белән кызыксыну уяту.

Җиһазлау: Сөббух Рәфыйковның портреты, фоторәсемнәре, китаплары, магнитофон, сәяхәт картасы, компьютер, язучыныҗ иҗатын, тормыш юлын чагылдырган электрон презентация.

Кичәнең барышы.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Уртада Сөббух Рәфыйковның портреты эленгән һәм язучы әсәрләреннән китап күргәзмәсе куелган.

Укытучының кереш сүзе.

Бүгенге Сөббух Рәфыйковның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган кичәбез КВН формасында узачак. Соббух Һади улы Рәфыйков – танылган татар язучысы, СССР Язучылар берлеге әгъзасы. Быел язучының тууына 110 ел тула. Без бүген сезнең белән бергәләп әлеге уен формасында аның тормышындагы төп вакыйгаларны, аның иҗатының үзенчәлекләрен, әсәрләренең төп геройларын искә төшерербез.

Инде менә командаларыбызга сүз бирер вакыт та җитте. Алар безне үзләре белән таныштырып үтәрләр. Дусларыбыз, КВНда катнашучы уенчыларыбызга сәламләү өлеше

өчен биремнәр алдан бирелгән иде. Алар безне хәзер үзләренең командаларының исеме, эмблемасы, девизы белән таныштырырлар. Һәм инде уңышлы чыгыш ясаган очракта бирем өчен иң югары балл – 3 балл алачаклар.

Сәламләү өлеше.

Укытучы: Киләсе бирем язучының биографиясенә һәм иҗатына багышланган:

1. Язучы Татарстанның кайсы районында туган? (Сарман)

2. Кайсы елларда Яр Чаллы һәм Алабуга татар мәктәпләрендә белем ала? (1925-1930 елларда).

3. Ул ВЛКСМ әгъзасы булганмы? (Әйе).

4. 1931 елда нинди өлкә газетасы белән хезмәттәшлек итә башлаган? (“Колхоз”).

5. Язучының иҗади эшчәнлеге нәрсәдән башланган? (Күп төрле  газета редакторы).

6. Язучы югары белем ала алганмы? (Әйе, читтән торып).

7. С. Рәфыйковның беренче шигырьләр җыентыгы ничек аталган? (“Рост җырлары”).

8. Кайсы елда Сталин репрессияләренә эләккән һәм кайсы шәһәргә? (1937 елда, Норильскига).

9. С. Рәфыйков Гулагта ничә ел булган? (20 ел)

10. СССР Югары Судының Хәрби коллегиясе карары нигезендә реабилитация турында карар кайсы елда кабул ителә? (1956 елның 9 мае).

11. Лагерьларда булганнан соң язучы Коммунистлар партиясенә керәме? (1958 ел).
12.Язучы кайсы газетаның штаттан тыш хәбәрчесе  була? (“Социалистик Татарстан”)

13. С. Рәфыйковның танылган әсәрләренең берсе ничек аталган? ("Ак төннәр").

14. 1958 елда язучы гаиләсе белән күченгән шәһәрнең исеме ничек? (Зәй).

15. Иң популяр әсәрләрен атагыз? ("Беренче яз», "“Авыл иртәсе”, “Тын елга буенда”).

Һәр исем өчен команда 1 балл ала.

Әлеге конкурска йомгак ясала.

Укытучы: Дусларым, инде менә икенче өйгә бирелгән биремне  күрсәтергә вакыт җитте. Ә бирем С. Рәфыйковның кайсы да булса  әсәреннән өзек  сәхнәләштерүдән гыйбәрәт иде. Бу бирем өчен максималь балл – 5.

Командалар өй эшләрен тәкъдим итәләр: спектакльнең оригинальлеге, текстның уйнау төгәллеге, актерлык осталыгы исәпкә алына.

Укытучы: киләсе бирем: сезгә С.Рәфыйковның  “Тын елга буенда” романыннан 10 җөмлә бирелгән, аларны  бәйләмле текст ясарлык итеп җыярга  кирәк. (Һәр командага бер төсле 10 тәкъдим җыелмасы бирелә. Тизлек һәм дөрес башкару исәпкә алына). Максималь баллар саны – 3.

Матур гына башланган кояшлы көн кинәт куе кара болытлар чыгып, өермәләнеп бозылып киткән сыман, Васил өчен кичкә таба бүгенге ял көне дә шундыйрак бер төс алды. Саф һава иснәп, ләкин күңелгә тынгысыз яна уйлар, яңа исәпләр салып урманнан чыкканнан соң, юлдашлары Игнат борылмалы тыкрык буенча үз өйләренә китеп барды. Васил белән Зиннур барак-гостиницага кайтып керделәр. Ләкин ни күзләре белән күрсеннәр: баскыч төпләре, коридор тулы халык. Баракның икенче башындагы торак хуҗалыгы конторасында да шундый ук хәл. Шуларны күрүгә Васил пошына калды.

Килүчеләр арасында кызлар да бар иде. Яшьләр белән сөйләшкәннән соң, ул аларның күбесен бетончы, ташчы, штукатурчылар икәнен белде. Төзелештән кайчандыр биргән заявка буенча аларны Казан шәһәреннән оешкан төстә җибәргәннәр икән. Ул кешеләр киләчәге турында моңарга кадәр дә ишеткән, ләкин аларны бүген яки иртәгә килерләр дип уйламаган иде.

Конкурска нәтиҗәләр ясала һәм игълан ителә.

Укытучы: Киләсе биремебезнең нәтиҗәсе ярдәмендә без абсолют җиңүче команданы билгели алырбыз. Ә бирем җиңелләрдән түгел. Татар әдәбиятында Сөббух Рәфыйковның урыны турында эссе язарга. Максималь балл – 5

Җиңүче команданы билгелиләр.

Укытучы: Менә безнең КВН ахырына җитте. Әйдәгез, тәэсирләр белән уртаклашыйк.

Рефлексия.

## Гөлшат Зәйнашева “Кем булырга?”

( 6 сыйныфның рус төркемендә туган (татар) әдәбияттан дәрес эшкәртмәсе)

Лифантьева Лилия Гарифулла кызы,

М.С. Устинова исемендәге гимназия укытучысы, Казан шәһәре

Максат:

1. Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү; “Кем булырга?” шигыре белән танышу.

2. Укучыларның тыңлап аңлау, фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмнәрен үстерү.

3. Шигъри әсәрләр укуга кызыксыну уяту, поэзиягә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; белемле һәм һөнәрле булуның – бәхет, шатлык, хөрмәт чыганагы икәнлегенә төшендерү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

Шәхескә кагылышлы: шигъри әсәрләр укуга кызыксыну уяту, поэзиягә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; белемле һәм һөнәрле булуның - бәхет, шатлык, хөрмәт чыганагы икәнлегенә төшендерү.

Метапредмет нәтиҗәләр*:*

Танып-белү УУГ: Тыңлап аңлау, текстта кирәкле мәгълүматны таба һәм билгели белү, нәтиҗә чыгара һәм гомумиләштерүләр ясый белү.

Коммуникатив УУГ: Тыңлый һәм башкаларның сорауларына җавап бирә белү, үз фикерләрен тәгъбир итә белү.

Регулятив УУГ: Уку мәсьәләсен куя белү, эшне планлаштыру һәм оештыра белү, үзбәя.

Предмет буенча: Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу; “Кем булырга?” шигыренең эчтәлеген белү, анализлый алу.

Җиһазлау: Портрет, китаплар, проектор, ноутбук, презентация.

Дәрес тибы: Яңа белемнәрне үзләштерү дәресе.

Материал: дәреслек: Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Э.Х.Гыйзәтуллина. Татар әдәбияты. 6 нчы сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 2 кисәктә. 2 нче кисәк. Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшрияты, 2017. – 36 бит.

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| Оештыру<br>Мотивлаштыру<br>(1-2 мин) | Исәнләшү.<br>Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыру.<br>Дәрескә әзерлекләрен тикшерү. | Сыйныф эшкә әзерләнә.<br>Укытучыны сәламлиләр.<br>сорауларга җавап бирәләр. | ШКУУГ: үзмаксат кую, укытучы һәм иптәшләрен хөрмәт итү;<br>ТБУУГ: тыңлап аңлау, нәтиҗә чыгару<br>КУУГ: укытучы һәм сыйныфташлар белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.<br>РУУГ: эшчәнлекне оештыра белү. |
| Белемнәрне актуальләштерү | Өй эшен тикшерү:<br>- Нәрсә ул мәкальләр һәм әйтемнәр?<br><br><br><br>- Һөнәр белән бәйләнешле нинди мәкальләр, әйтемнәр беләсез? | Укучылар җаваплары:<br>Мәкальләр -акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланыла торган, кыска, тирән мәгънәле халык авыз иҗаты әсәрләре.<br>Әйтемнәр- халык авыз иҗатының образлы фикер йөртүгә корылган, күчерелмә мәгънәдә кулланылган, сөйләмнең эмоциональ көчен арттыра торган жанр.<br><br>- *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.*<br>- *Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.*<br>- *Һөнәр утта янмый, суда батмый торган хәзинә.*<br>- *Һөнәр үзе ашата.*<br>- *Һөнәрле үргә йөзәр.*<br>- *Оста кулда һөнәр бар.* | ШКУУГ: татар халык авыз иҗатын өйрәнергә кызыксынуны арттыру<br>КУУГ: башкаларны тыңлый белү, сорауларга җавап бирү.<br>РУУГ: җавапларны дөресли һәм бәяли белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Уку мәсьәләсен кую | - Рәсемнәргә карагыз, әле, сез кемнәрне күрәсез? (1 слайд)<br>-Нинди бер сүз белән аларны берләштерергә була? (Һөнәр)<br><br>- Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (Уку мәсьәләсен билгеләтү) | Җаваплар: укытучы, төзүче, чәчтараш, тегүче, сатучы, пешекче, табиб, очучы<br><br>Тема буенча фаразлар ясыйлар, уку мәсьәләсен билгелиләр. | ШКУУГ: мәкаль һәм әйтемнәр төшенчәләрен белү.<br>ТБУУГ: танып белү максатын аңлау, гомумиләштерүләр ясау, нәтиҗә чыгара белү.<br>КУУГ: тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу.<br>РУУГ: фаразлау, уку мәсьәләсен кую. |
| Уку мәсьәләсен адымлап чишү | 1. Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләү.<br>а) презентация ярдәмендә тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү. (2 слайд )<br><br>2. “Кем булырга?” шигырен уку.<br>а) сүзлек эше;<br>б)  текстны укучыларның аңлап укулары;<br>в) Сорауларга җавап бирү:<br>Шигырьдә нинди һөнәрләр турында сүз бара?<br> г) төркемнәргә бүленеп эшләү һәр төркем белән әңгәмә кору.<br>1 нче төркемгә сораулар:<br>Әти малайның кем булуын тели? Ни өчен? Бу һөнәр өчен нәрсәләр белергә, нәрсәгә өйрәнергә кирәк? | 1. Г.Зәйнашева турында тыңлау, презентация карау, әңгәмәдә катнашу.<br><br>2. а) Яңа сүзләрне үзләштерү: тыңлау, дөрес итеп кабатлау, язу.<br>б) Текстны уку һәм аңлау.<br><br>в) Сорауларга җавап бирү<br><br>г) Төркемнәргә бүленеп эшләү..<br>Сорауларга җавап бирү. | ШКУУГ:<br>шигъри әсәрләр укуга кызыксыну уяту, поэзиягә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; кешелекле булырга кирәк икәнен аңлау<br>ТБУУГ: уку мәсьәләсен аңлау, тексттан төп фикерне аерып чыгару, нәтиҗә ясау.<br>КУУГ: сорауларга төгәл җавап бирә белү, әңгәмәдә катнаша алу, төркемнәрдә эшли белү, үз фикерләрен дәлилле итеп җиткерә алу, хезмәттәшлек итү.<br>РУУГ: анализ барышын төзү, җавапларны бәяли алу.<br>Предмет нәтиҗәләр: Г.Зәйнашева турында мәгълүматлы булу, “Кем булырга?” шигыренең эчтәлеген белү, идеясенә төшенү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2 нче төркемгә сораулар:<br>Әни малайның кем булуын тели? Ни өчен? Бу һөнәр өчен нәрсәләр белергә, нәрсәгә өйрәнергә кирәк? | | |
| Яңа белемнәрне беренчел ныгыту | 1. Әңгәмә үткәрү: Малайның кем булуын телиләр? Сезнеңчә кайсы һөнәр яхшырак? Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?<br><br>2. Бирелгән сүзләрне укыгыз, тәрҗемә итегез. Кайсы һөнәр нинди?<br>(3 *слайд )*<br><br>3.Шигырь буенча сораулар бирү. (укучылыр чылбыр буенча сорау бирәләр)<br><br>4. Монологик сөйләмне камилләштерү: Шигырь нәрсә турында? Ул сезгә ошадымы? Ни өчен?<br><br>5. - Сез кем булырга телисез? Бу һөнәр өчен нәрсәләр белергә, нәрсәгә өйрәнергә кирәк?<br><br>6. Укучылар, Каюм Насыйриның “Тәрбия китабы”на | 1. Әңгәмәдә катнашу<br><br>2. Сүзләр: иҗади, акчалы, җиңел, абруйлы, дәрәҗәле, мактаулы, җитди, авыр, сирәк, катлаулы, куркыныч, җаваплы<br>3.Укучыларның чылбыр буенча бер-берсенә сораулар бирү.<br><br>4. Индивидуаль эшләү.<br>Кешелекле, һөнәрле булу- бәхет, шатлык, хөрмәт чыганагы .<br><br>5. Укучыларның фикерләрен әйтү. | ШКУУГ: белемле, тәрбияле, кешелекле, һөнәрле булырга кирәк икәнен аңлау, тормышта үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын таба белү.<br>ТБУУГ: төп фикерне билгели белү, мөстәкыйль рәвештә нәтиҗә чыгара белү<br>КУУГ: сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү, башкаларны тыңлый һәм аңлый белү.<br>РУУГ: эшчәнлекне оештыра белү, мөстәкыйль эшли белү.<br>Предмет нәтиҗәләр: Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу; “Кем булырга?” шигыренең эчтәлеген белү, анализлый алу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мөрәҗәгать итик әле.<br>*Бер хәким балаларга шундый хикәят сөйләде. “Әй җаннарым, угланнарым, хикәятемне ишетегез – һөнәр өйрәнегез. Дөньяның байлыгына ышанырга ярамый. Алтын – көмешләр кеше өчен хәтәрдер. Йорт – җире булган кеше өчен аның тагын бер хәтәр ягы бар: аны я карак алып китә, я утта янып бетә. Әмма һөнәр бер агым судыр, ышанычлы дәүләттер. Һөнәр иясе байлыгын югалтса да кайгырмас. Әй угыл, син дә шулай һөнәр өйрән, тәрбияле бул, белем ал.”*<br>*(4 слайд)*<br>- Бу хикәятне ничек аңлыйсыз? | 6. К. Насыйри һөнәргә өйрәнергә куша. Тәрбияле дә, белемле дә булыгыз, ди.<br>Һөнәрле кеше – бай кеше. Малы югалса да, ул үзе югалмый. Баланы кечкенәдән һөнәргә өйрәтергә кирәклеген әйтә. | |
| Өй эше | 1. шигырьне сәнгатьле укырга;<br>2. Әти-әниегезнең һөнәре турында монолог языгыз. | Өй эшен язып алалар, аңлашылып бетмәгән өлешен сорыйлар. | ТБУУГ: биремне аңлау.<br>РУУГ: эшчәнлекне планлаштыра белү. |
| Рефлексия | 1. Дәрескә йомгак ясап, рефлексия үткәрү.<br>-Дәрестә нәрсә белдегез, нәрсәгә өйрәндегез?<br>-Моңа нинди юллар белән ирештек?<br>2. Белемнәрне бәяләү, | Үз фикерләрен әйтәләр, сорауларга җавап бирәләр, үз эшчәнлекләрен бәялиләр. | ШКУУГ: белемле, тәрбияле, һөнәрле булырга кирәк икәнен аңлау, тормышта үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын таба белү.<br>ТБУУГ: гомумиләштерүләр ясау,<br>нәтиҗә чыгару |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | билгеләр кую.<br>3. Саубуллашу. | | КУУГ: сорауларга җавап<br>бирү, фикерләрне<br>дәлилле итеп<br>җиткерү.<br>РУУГ: җавапларны<br>бәяли белү, үзбәя. |

1 слайд



2 слайд



3 слайд




Кайсы Һөнәр нинди?

4 слайд

*Бер хәким балаларга шундый хикәят сөйләде. “Әй җаннарым, угланнарым, хикәятемне ишетегез – һөнәр өйрәнегез. Дөньяның байлыгына ышанырга ярамый. Алтын – көмешләр кеше өчен хәтәрдер. Йорт – җире булган кеше өчен аның тагын бер хәтәр ягы бар: аны я карак алып китә, я утта янып бетә. Әмма һөнәр бер агым судыр, ышанычлы дәүләттер. Һөнәр иясе байлыгын югалтса да кайгырмас. Әй угыл, син дә шулай һөнәр өйрән, тәрбияле бул, белем ал.”*

## Якташыбыз С.Рәфыйков – «Тамчы» газетасы битләрендә

(Pablischer программасында юбиляр язучыга багышланган газета саны эшләү буенча түгәрәк яки дәрестән тыш эшчәнлек дәресе)

Шәйдуллина Ландыш Камил кызы,

Шәйдуллина Чулпан Камил кызы,

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары,

Сарман районы

Максат: эзләнүле эшчәнлек алып бару аша алга куелган бурычны адымлап чишәргә өйрәтү, укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру, газета-журналлар белән кызыксындыру аша якташ язучылар иҗаты белән таныштыру, аны пропагандалау.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

танып-белү: мәгълүмат ташкынында кирәкле материалны табу юлларын ачу, интернет программаларын өйрәнүне дәвам итү.

гомуми белем күнекмәләре: практик эш, анализлый белү, кирәкле материалны сайлау; үз фикереңне яклый белү, иҗади фикерләү.

Регулятив: булачак һөнәрең турында уйлану, үзеңне сынап карау

Дәрес тибы: уку мәсьәләсен кую һәм аны практик эшчәнлектә чишү.

Җиһазлау: «Сарман районы әдипләре» картасы, китапханәдәге китаплар тупламасы, проектор, компьютер, ноутбуклар

Дәрес барышы:

I. 1.Оештыру

а) психологик уңай халәт тудыру.

ә) укытучының кереш сүзе.

Укучылар, исәнмесез. Безнең алга зур бурыч куелды. Безгә якташ язучыбызның юбилеена багышлап мәктәп газетасы санын чыгарырга кирәк. Тиз генә үзебезнең кагыйдәләребезне кабатлап алыйк әле. (Җаваплар тыңлана)

- Язмалар кызыклы, төгәл булырга тиеш;
- Газета үзенә җәлеп итеп торсын
- Олыга да, кечегә дә аңлаешлы булырлык итеп эшлибез
- Язмалар арасында рәсемнәр, фотолар кыстыру укучының игътибарын көчәйтә.

I.2. Кабинеттагы «Сарман районы әдипләре» карта-күргәзмә стенды белән эшләү

- Кагыйдәләрне искә төшердек. Тик сез бер төп мәгълүматны төгәл итеп сорамадыгыз. Нәрсәне белмисез? (Җаваплар тыңлана)
- Карта янына килегез әле, укучылар. Кайсы язучыларыбызның юбилейлары якынлаша? (Җаваплар тыңлана)
- Нәкъ үзе, укучылар. Безнең газетабыз Сөббух ага Рәфыйковка багышланырга тиеш. 2023 елның 15 июнендә аның тууына 110 ел тула. Эшне нәрсәдән башлыйбыз? (Җаваплар тыңлана)

- Димәк, мәгълүмат тупларга кирәк. Моның өчен безгә ике мөмкинлек ачылган. Беренчесе – Интернет челтәренә мөрәҗәгать итәбез. Икенчесе – мәктәп китапханәсеннән аның турында булган китапларны алабыз. Безгә ике төркемгә бүленеп эшләргә туры килер кебек. Кемнәр Интернет дәрьясына чума, алар кабинетта калалар һәм эшкә тотыналар. Калганнар белән мин китапханәгә киттем.

I.3. Тупланган белешмә материал белән эшләү.

- Кемдә нинди тәкъдимнәр бар, укучылар? Газетаның макетын төзер вакыт җитте. (Фикерләрне тыңлау һәм газетаның макетын булдыру)

1.4. Газета санының макетын төзү.

1. Әдип турында кыскача гына биографик белешмә.

2. Сөббух Рәфыйков – репрессия корбаны, шуңа күрә репрессия еллары хакында мәгълүмат кирәк.

3. Аның иҗатына күзәтү, китапларының рәсемнәрен күрсәтү.

4. Аның турындагы истәлекләр, фотолар.

5. Сөббух Рәфыйков исеме ничек мәңгеләштерелгәнен тикшерү.

I. 5. Төркемнәрдә эшләү.

Эш мәйданы әзер булды, укучылар, эшкә тотынсак була. Ул озакка сузылмасын дисәк, безгә шушы макет темалары буенча төркемнәргә бүленергә кирәк. Кайсысы җаныгызга якын, шул өлкәне сайлап алабыз да җиңнәрне сызганабыз.

Төркемнәрдә эшләү, темалар буенча материаллар туплау һәм язмалар әзерләү.

I.6. Проблемалы сорауны чишү.

Укучылар, без менә хәзер сезнең белән бер өлкәне колачлый алмыйбыз. Ничек уйлыйсыз, мине нәрсә борчый? (Җаваплар тыңлана). Сөббух Рәфыйков әсәрләре дәреслекләргә кертелмәгән, мәктәптә өйрәнелми. Тик бу безгә киртә була алмый. Китапханәдә, Интернет челтәрендә авторның әдәби әсәрләре бар. Шуңа күрә кызыксынып укырсыз дип ышанып калам.

II.Гамәли өлеш.

Материалларны бергә туплау һәм газета битләренә урнаштыру.

III. Дәрескә йомгак.

- Укучылар, газетаның бу санын без Зәй шәһәренә җибәрәбез. Ни өчен? (Җаваплар тыңлана). Зур Нөркәй мәктәбенә бирәбез. Ни өчен? ((Җаваплар тыңлана). Классларга таратабыз. Ни өчен? (Җаваплар тыңлана).

- Дөрес, укучылар. Туган якның тарихын, аның әдәби һәм табигый мирасын барлау, өйрәнү, саклау, башкаларга да сөйләү, белдерү – безнең барыбызның да бурычы.

**Кояш гомере телим**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗатына багышланган кичә)

Тәҗмиева Рушания Миннахмәт кызы,

Бөреле гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы,

Биектау районы

Максат:укучыларны Гөлшат Зәйнәшеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

Җиһазлау : Гөлшат Зәйнәшеваның портреты, китаплары күргәзмәсе, компьютерда презентация, язучы иҗатына багышлап чыгарылган стенгазеталар, Гөлшат Зәйнәшеваның портреты

Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, укытучылар! Бүген без "Кояш гомере телим" дип аталган Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби-музыкаль кичәгә җыелдык . (Укучылар сөйләгән вакытта слайдлар күрсәтелә )

Минзәлә – талантларга бик бай як .Кайсы гына язучыны алма, сөйләп, язып бетерә алмаслык зур шәхес . Бүген без якташыбыз, шагыйрә, драматург, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы Гөлшат Зәйнәшева турында сөйләрбез .

Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 январенда Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

Зәйнәшева Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза:" 14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесендә укыдым. 1942-1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астыдагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшь үсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек ...."

1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

Гөлшат Зәйнәшеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Әхәзер шул җыентыкка кергән берничә шигырен тыңлап китәрбез.

Һаваларда болыт,
Ак җилкәннәр булып,
Кая бара, кая агыла?..
Юк, йөрмәмен озак,

Чит жирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма!..
Тау башында тургай,
Ялгыз калган бугай,
Очам, диеп, канат кагына.
Юк, йөрмәмен озак,
Чит жирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма!..
Дуслар исән микән?..
Хат алалмыйм күптән,
Әллә кемне күңел сагына.
Юк, йөрмәмен озак,
Чит жирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма!..
Поездларга карыйм,
Вагоннарын саныйм,
Кайтыйм дисәң, юллар табыла.
Юк, йөрмәмен озак,
Чит жирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма!!..

Гөлшат Зәйнәшеваның туган җир, туган як турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйланадыр, минемчә .Чөнки туган як белән бәйле тойгы һәркеменң күңеленә газиз . Туган як кеше өчен кадерле, изге булырга тиеш. Туган як темасы язучы иҗатында зур урын алып тора.

“ Туган җирем – Татарстан “ җыры башкарыла. А.Ключарев көе

Гөлшат Зәйнәшеваның шигырьләре күңелгә үтеп керердәй халыкчан гадилеге, ачык аңлаешлы, музыкаль аһәңе белән аерылып тора һәм бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп , популяр җырлар язганнар . Иң популяр җырлар туплаган “Илле җыр“ (1998) исемле китабы өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә җырын тыңлап китәрбез.

“Туган авылым урамы“ җыры башкарыла.

Гөлшат Зәйнашева иҗатында яшь буынга багышлап язылган шигырьләр дә шактый урын алып тора. Мәсәлән: ”Тукран белән сөйләшү”, “Кояш гомере“, “Әбиемне яратам“ һәм башка бик күп шигырьләрен яратып укыйбыз, яттан сөйлибез, җыр итеп җырлыйбыз. .

“Әбиемне яратам" шигыре укыла.

“ Кояш гомере “җыры башкарыла. Ф.Әхмәдиев көе

---

Гөлшат Зәйнәшеваның үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга . Аның “ Бәхет кошым”, “Рамай”, “Гайфи бабай, өйлән давай”, “Язмышлар һәм ялгышлар” һәм башка пьесалары тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

Гөлшат Зәйнәшеваның Минзәләгә атап язган хатында шундый юллар бар:

Барасызмы Минзәләгә?
Мин барам Минзәләгә.
Минзәләне күрер өчен,
Үзәгем өзгәләнә.

Минзәлә – сугыш елы Минзәләсе минем күңелемдә кайгы, сагышлы, ачлы туклы, шуңа да карамастан нindидер шатлыклы, өметле бер туган як, туган туфрак булып калган һәм еш кына төшләремә керә, сагындыра ...” - дип яза шагыйрә.

Шагыйрә туган ягыннан еракта булса да, күңеле белән туган ягында яши, аны сагына, юксына. Без дә аны сагынабыз. Аның иҗаты безгә көч, дәрт, илһам бирә. Без, яшь буынны, яшәргә, туган якны, тормышны яратырга өйрәтә. Кичәбезнең ахырында Гөлшат Зәйнәшеваның ,,Мин тормышка гашыйк” шигырен укып үтәсем килә .

Кая барсам, якын дуслар табам,
Дуслар белән озын юл кыска.
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

**Тарихның “кара таплары”...**

(С. Рәфыйков истәлегенә багышланган ачык чарага сценарий)

Шайхулова Айгөл Илдар кызы,

Яңа Кәшер урта мәктәбенең тарих һәм

җәмгыять белеме укытучысы, Әлмәт районы

Гаҗәп нәрсә хәтер!
Кеше күңеленә
Бөтен бер дөньяны сыйдыра.
Хәтер миңа оста фотограф,
Оста актер булып тоела,-

дип язган иде шагыйрә Энҗе Мөэминова. Әйе, хәтер барсын да саклый. Бигрәк тә “Үлем уены”н үз йөрәкләре аша уздырган буын хәтер сагында уяу тора.

Х. Туфан сүзләренә язылган “Агыла да болыт агыла җыры” яңгырый. Музыка астында репрессияләнгән язучыларның фотографияләре слайдта чыгып бара. Алар арасында Муса Җәлил, Г.Ибраһимов, Ф.Кәрим, Җ.Вәлиди, М.Галәү, Н.Исәнбәт, Б.Урманче, М.Әмир, Х.Туфан, А.Гыйләҗев, А.Тимергалин, Г.Ильясов, Г.Тали, С.Рәфыйков.

Хәтер. Әлеге фотосурәтләрдә күрсәтелгән язучыларыбыз тарих дулкынында дөньяны тетрәткән шәхес культы афәтенә юлыгып һәлак булган ватандашларыбыз. Кайбер галимнәрнең раславы дөрес булса, 1917 елдан башлап илдә урнашкан тоталитар режим шартларында язмышлары пыран-заран килгән – махсус оештырылган ачлык фаҗигаләрендә һәлак булган, йорт-җир һәм туган төбәкләреннән сөрелгән яки, бер гаепсезгә кулга алынып, нахак хөкем карары белән гомерләре киселгән, концлагерьларга озатылып, ерак Себер тайгаларында, кырыс табигатьле төньяк өлкәләрдә, Казакъстанның сусыл далаларында иза чиккән, авыр кол хезмәтеннән, кыйнау-рәнҗетелүләрдән шунда әҗәлен тапкан яисә, иреккә сәламәтлекләрен тәмам югалтып, инвалид булып, рухи сүнеп чыккан кешеләрнең, ягъни репрессия корбаннарының, гомуми саны утыз-кырык миллионга җитә икән. Бу – ил халкының якынча чирege дигән сүз. Сталин репрессияләре бер генә төбәкне, бер генә халыкны, бер генә милләтне дә читләтеп узмаган.

Тарих. Башка халыклар кебек татар халкы да тоталитар режим аждаһасына үзеннән күп корбаннар биргән, шулар арасында татар милләтенең йөзек кашы булган, милләтпәрварлык рухы белән янып йөргән бик күп язучыларыбыз да бар.

1934 елда СССР Язучылар берлеге төзелгәч, Татарстаннан әгъза яки әгъзалыкка кандидат итеп рәсмиләштергән утыз татар язучысының уналтысы репрессиягә эләгеп, шуларның унысы НКВД тырнаклары астында һәлак була. Язучылар берлегендә теге яки бу сәбәп белән әгъза булып тормаган, әмма иҗатлары, исемнәре белән халыкка танылган башка репрессияләнгән каләм әһелләрен дә кушсак, әлеге сан берничә дистәгә җитә (тынлык эчендә залның төрле почмагыннан репрессияләнгән татар язучыларының исем - фамилияләре яңгырый: Г. Ибраһимов. К. Тинчурин, Ф. Кәрим, Г. Толымбай, Х. Туфан, Г. Мөхәммәтшин, С. Атнагуллов, Л. Гыйльми, А. Тимергалин, С. Батыршин, С. Сүнчәләй, С. Баттал, М. Әмир, Г. Гали, Ф. Аглиев, А. Гыйләҗев, М. Галәү, Г. Иделле, Ф. Кәрими, Ярлы Кәрим, И. Сәләхов, Г. Тавлин, С. Җәләл, Ф. Бурнаш һ. б.).

Хәтер. Бу исемлекне әле дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Алар истәлегенә бер минутлык тынлык игълан итик әле.

Тарих. Бүгенге искә алу кичәсе татар халкының күренекле шагыйре, прозаик, журналист Сөббух Һади улы Рәфыйковка багышлана. С.Рәфыйковның фотосурәте укучыларга слайдлар ярдәмендә тәкъдим ителә. Сыйныфта бер укучыга алдан С.Рәфыйков роле билгеләнә. Ул рольгә кереп С.Рәфыйковның тормыш юлы белән таныштыра, укучы сөйләме слайдтагы язулар һәм рәсемнәр белән үрелеп бара.

С.Рәфыйков. Мин 1913 елның 15 июлендә Минзәлә өязе Нөркәй волосте (хәзерге Татарстанның Сарман районы) Нөркәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә тудым.

1925-1930 елларда башта Яр Чаллыда һәм Алабугада тугызъеллык мәктәптә, аннары Казанда югары уку йортында хәзерләү курсларында укыдым. 1931 елдан башлап ул журналистлык эшендә: республика “Колхоз гәзите” редакциясендә әдәби хезмәткәр (1931-1932), Сарман районында чыга торган “Комбайн” газетасында җаваплы редактор урынбасары (1932-1934), республика комсомол газетасы “Кызыл яшьләр” редакциясендә бүлек мөдире (1934-1937) һәм Татарстан дәүләт нәшриятында редактор (1937) вазыйфаларын башкардым. 1934-1937 елларда, хезмәтемнән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогика институтының тел-әдәбият бүлегендә белем алдым.

Тарихчы. Язучының алдагы тормышы турында совет заманында чыккан белешмәләрдә «оялып кына» язалар: 1937-1957 елларда Сөббух Рәфыйков Татарстаннан читтә – төньяк өлкәләрдә һәм Красноярск краенда яши һәм эшли.

С.Рәфыйков. Чынлыкта мин исә 1937 елның 17 октябрендә кулга алындым. 1938 елның 12 маенда мәхкәмә карары белән террорист һәм корткыч-диверсант буларак (РСФСР ҖК, 58-8, 58-11 матдәләр) 10 елга иректән һәм тагын 5 елга хокуклардан мәхрүм иттеләр.

Тарихчы. 1951 елда Сөббух Рәфыйков кабат кулга алына һәм Красноярск краена сөргенгә җибәрелә.

С.Рәфыйков. 1957 елда исә мин яңадан Татарстанга кайттым һәм озак еллар “Социалистик Татарстан” газетасының башта Зәй төбәгендәге үз хәбәрчесе (1958-1961), аннары штаттан тыш хәбәрчесе хезмәтендә булдым.

Хәтер. Сөббух Рәфыйков 1930 елда яза башлый. 1931-1937 еллар арасында шигырь һәм хикәяләре тупланган өч җыентыгы (“Үсү җырлары”, “Соңгы талпыну”, “Үсмерчак”), сугыштан соң, 1957 елда, “Ак төннәр” исемле шигъри китабы дөнья күрә.

Сөббух Рәфыйков язучы буларак киң җәмәгатчелеккә “Беренче яз” (1958) романы белән танылa. 1920-1930 еллардагы татар авылында социаль күренешләрне шул заманга хас реаль күренешләр һәм образлар аша чагылдырган бу роман 60нчы еллар татар прозасының авыл темасына багышланган күренекле әсәрләреннән берсе итеп бәяләнә.

Хәтер. Суның кадерен чүлдән,

Юлчылардан сорап бел.

Дусларыңның кем икәнен

Авырлыкта сынап бел!

I группа сугыш инвалиды, сугыш һәм мәгариф ветераны Таһир Шәрәфетдинов истәлекләре белән танышу. Бер укучы Таһир Шәрәфетдинов ролендә Сөббух Рәфыйков турында истәлекләрне яңарта.

Таһир Шәрәфетдинов. Сөббух абыйны мин кече яшьтән беләм. Бертуган Зиннәт абыемның якын дусты иде. 1930-1931 елларда Сөббух абый Нөркәй урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытты. Берәр сөйкемле сөяге бар идеме, башка сәбәпме, аны һәрчак балалар сырып алган булыр. Сәләтле укучыларны үз тирәсенә оештырып, әдәби түгәрәк эшләтеп җибәрде. Анда каләм тибрәтүче балаларның язмаларын тикшерәләр, стена газеталары чыгаралар, сәнгатьле сөйләргә өйрәнәләр, концертлар әзерлиләр иде.

Хәтеремдә, Сөббух абый ул концертларда үзе дә катнаша, Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан шигырьләрен аһәңле, сәнгатьле итеп сөйли иде. Ни кызганыч, яраткан укытучыбыз кулы астында без мәктәпне тәмамлый алмадык. 1932 елда аны Сарманда чыга торган "Комбайн" газетасына мөхәррир урынбасары итеп эшкә чакырдылар. Сөббух абый чикләре хәзерге Азнакай районының Чуар Абдул авылыннан Зәйнең Баграж, Әлмәт-нең Яңа Михайловка һәм Гөлбакча авылларыннан Минзәлә чигендәге Удельный Сөренчәккә кадәр сузылган районны җәяү дә, атта да аркылыга-буйга иңләде. Халык арасында кайнап яңа тормыш төзү, күмәкләшү турында ялкынлы мәкаләләр язды, поэмалар, хикәяләр иҗат итте.

Тарихчы. Алтын җирдә ятмый, диләр. Сөббух Рәфыйковның талантын Казанда да тиз күреп алалар. 1934 елда ул Сарман, туган ягы белән саубуллашып, "Кызыл яшьләр" (бүгенге "Татарстан яшьләре") газетасында эшли башлый. Шул елларда педагогия институтын тәмамлый

Таһир Шәрәфетдинов (сөйләм музыка белән үрелеп бара). Ил өстендә репрессияләр болыты куерды. Җәмгыятьнең асыл затларын, каймагын: күренекле партия һәм дәүләт эшлеклеләрен, талантлы шагыйрьләрен һәм язучыларын, фән эшлеклеләрен һәм хәрби начальникларын юк итү башланды. Татарстанда да репрессия машинасы туктаусыз, рәхимсез эшләде. Сөббух абый, халык дошманы дип, кулга алынды. Өчлек суды аңа 10 ел төрмә, 5 елга хокукыннан мәхрүм итәргә, иленә кайтармаска, язучылык белән шөгыльләнмәскә, дигән карар чыгарды. Сөббух абый этап белән Себергә, котып ягына – Норильскига озатылды. 1957 елга кадәр, шәхес культына дучар ителгән меңләгән шәхес белән бергә, төрле лагерьларда газап чикте.

Тарихчы. Ил өстендә саф җилләр исә башлап шәхес культы фаш ителгәч, Сөббух абый да тулысынча акланып Татарстанга, 1957 елны туган авылы Нөркәйгә кайта. Авыл халкы, мәктәп өчен ул бик олы кунак була. Аның белән очрашырга халык болыт кебек агыла, тәбрик сүзләренең, чыгышларның иге-чиге булмый.

Таһир Шәрәфетдинов. Очрашудан соң Сөббух абыйны үзебезгә кунакка алып кайттым. Өйгә килеп керүгә авылның ипи пешерә торган мичләренә кадәр сагынуын, ирек һавасының бер йотымының алтыннардан да кыйммәтрәк булуын кайта-кайта сөйләде, саран гына төрмә хәлләрен искә төшерде:

С.Рәфыйков. Сорау алганда нинди генә ерткычлыклар эшләмиләр анда. Тәнеңнең карар җире калмаганчы дагалы итекләр белән типкәләүләр дисеңме, тырнак астына күгәргән кадаклар кагу, борыс белән ишек арасына кысып кул бармакларын сындыру, ирләрнең ирлек сәләтен бетерү дисеңме, берсеннән дә чирканмыйлар җәлладлар. Шул җәзалаулар хакында иреккә чыккач беркемгә дә сөйләмәскә, авызны йозакта тотарга дип, ничәмә-ничә җиргә кул куйдырулар, кимсетүләр. Аларны искә төшерүгә тәннәр

чымырдап китә, йөрәк күкрәк читлегеннән чыгардай булып дөпелди. Шуңа бу тәмугны унга, йөзгә берәүләр, бик бәхетлеләр генә кичә...

Тарихчы. Гомеренең соңгы елларында әдип Татарстанның көнчыгыш төбәгендә Зәй гидростанциясе төзүче эшчеләр тормышыннан «Тын елга буенда» исемле өченче романын эшли. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында (1971, № 2–6) дөнья күреп, соңыннан, авторның вафатыннан соң (1972), Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга. Егерме ел тоташ тоткынлык җәфаларыннан сәламәтлеге какшаган язучы 1971 елның 21 ноябрендә Яңа Зәй шәһәрчегендә вафат була.

Хәтер.   Ул елларда илдән намус, иман качты,

Бәйрәм итте заман ялгышлары.

Җан өстенә Дәҗҗал булып басты

Корбаннарның ачы язмышлары

Тарих. Әйе, Россия тарихында “кара таплар” җитәрлек. Ә менә Сталин хакимияте тудырган золым – халыклар төрмәсенең иң хурлыклысыдыр, мөгаен. Сәяси репрессия чорында нахакка гаепләнүчеләрнең саны бүгенгәчә төгәл билгеле түгел. Шулай булуга карамастан, тарих, әдәбият битләрендә бүгенге көнгәчә исемнәре язылган репрессия корбаннары бик күп. Без аларны белергә һәм алар белән горурланырга тиеш.

## Шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага 95 яшь

Хасанова Миләүшә Мисалих кызы,

Иске Ибрай урта мәктәбе укытучысы, Аксубай районы

Максат: Балаларны Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты белән таныштыру. Шагыйрә иҗатына кызыксынучанлык тәрбияләү. Иҗади сәләтне үстерү өчен мәйдан ачу, этәргеч бирү.

Җиһазлау: Гөлшат Зәйнәшеваның портреты, китапларыннан күргәзмә, шигырь юлларыннан плакатлар, шигырьләре буенча ясалган рәсемнәр, җыр язмалары, презентация.

### Кичә барышы.

Тыныч кына Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган җыр яңгырый.

Кичәне татар теле һәм әдәбияты укытучы Хәсәнова Миләүшә Мисалих кызы Гөлшат Зәйнашеваның шигыре белән башлап җибәрә:

Бер күрешү – бер гомер
Кил, бер күрешеп сөйләшик дисәң,
Идел-диңгезләр кичәр идем мин.
Таңнан уянып, карлыгач кебек,
Синең яныңа очар идем мин.
Иң якын кешең, җан дустың белән
Бер күрешү ул бер гомер, диләр.
Иң якын кешең, дустың санасаң,
Мине чакырып син хәбәр җибәр.
Сөйләр сүзләрем шундый күп минем,
Күңелем тулы җыр һәм моң кебек.
Ләкин сүземнең иң кирәклесен
Никтер әйтәлмый калырмын кебек.

Иң якын кешең, җан дустың белән
Бер күрешү – ул бер гомер, диләр.
Иң якын кешең, дустың санасаң,
Мине чакырып син хәбәр җибәр.

Кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар! Бүгенге кичәбез “Бер күрешү – бер гомер“ исемле әдәби кичәгә чакырдык. Бүген тормыш авырлыкларын җиңеп, олы җанлы кеше булып яшәргә көч тапкан, корыч ихтыярлы, изге җанлы шагыйрә, язучы, драматург Гөлшат апа Зәйнашеваның тормыш юлына, иҗаты буенча сәяхәт итәрбез.(Слайд)

1 нче укучы.

Яңгырасын көйләр, шат көлүләр,

Тирә-юньгә бүген таралсын.

Кемнәр болар-бәхетлеләр диеп,

Бөтен кеше безгә карасын!

Җыр башкарыла «Туган җирем-Татарстан» Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе .

2 нче укучы.

Шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. 1928 нче елның 13 нче гыйнвары. Кышның чатнама суык көнендә Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә бер кыз дөньяга килә. Аңа Гөлшат дип исем бирәләр.

3 нче укучы.

Әмма балачагын моңлы – җырлы Илһам Шакиров төбәгендә түгел, Минзәлә якларында үткәрә. Гөлшат апа гади авыл кызы булгангамы, иҗатында көч һәм илһам бик тирән ята.

4 нче укучы.

Иртә дә генә торам, юлга чыгам,
Иңнәремә шәлем ябынам. Кемне сагынасың, дип
сорамагыз, Күк күгәрченемне сагынам.
Иртә дә генә торам, юлга чыгам, Юл
буйлары яшел өрәңге. Нигә ялгыз син, дип сорамагыз,
Гомерем буе көтәм берәүне. Иртә дә генә торам, юлга чыгам,
Курай кисеп алам камыштан. Нигә моңлы син, дип сорамагыз,
Моңлы бала булдым тумыштан.

5 нче укучы.

Ятимлек сәбәп моңа – моңлы ятимлек. Моңнар әнә каян килә ул Гөлшатка. 1930 елда, авыл халкын күмәк хуҗалыкларга берләштерү чорында, гаиләләрне «кулак» тамгасы белән читкә сөргәндә, әти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, Минзәлә якларында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә калдыралар.

6 нчы укучы.

Бу, һичшиксез, аның шигъриятендә һәм җырларында чагылыш таба. "Моңлы авыл Тәкермән", "Минзәлә юллары", "Ык буйлары", "Туган җиремә", "Туган авылым Салих-Тукай", "Үз илемдә" һәм башка күп шигырьләрендә һәм җырларында туган якның сагышы, матурлыгы, кешеләрнең хезмәт сөючәнлеге һәм табигатькә мөнәсәбәте гаять зур осталык һәм эчке җылылык белән сурәтләнә.

7 нче укучы

Башлангыч, җидееллык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлагач, 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Җыр башкарыла. «Үз илемдә» Г. Зәйнашева сүзләре, С. Садыйкова көе.

8 нче укучы.

Бөек Ватан сугышының бөтен авырлыкларын Минзәләдә укыганда татый Гөлшат апа, ләкин тырыш, уңган кыз бирешми. Тулай торак бүлмәсендә мич чыгарып үзен дә, иптәшләрен дә салкыннан саклап кала.

Авыр сугыш елларында үстем.

Балда-майда гына йөзмәдем.

Юлны шадралатып уелып калды

Чабатадан йөргән эзләрем.
Яңа чабатага ирешү дә
Бик зур шатлык иде ул чакта.

Алтын башмакмыни-чабатаны

Куана идек кысып кочакка.

9 нчы укучы.

Г.Зәйнашеваның үзенең туган төбәген, туган ягын сагына. Минзәләгә атап язган хатында шундый юллар бар:

“ Барасызмы Минзәләгә?

Мин барам Минзәләгә .

Минзәләне күрер өчен ,

Үзәгем өзгәләнә.

Минзәлә – сугыш елы. Минзәләсе минем күңелемдә кайгы, сагышлы, ачлы туклы, шуңа да карамастан ниндидер шатлыклы, өметле бер туган як, туган туфрак булып калган һәм еш кына төшләремә керә, сагындыра...” - дип яза шагыйрә.

10 нчы укучы

Мин тормышка гашыйк
Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.
Чишмәләрнең җырын отар идем
Җыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.
Озак яшәрмен диеп йөрәк тибә,
Ашкына күңелем һәр эшкә,
Әллә эшем бәхет китергәнгә,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

1 нче укучы.

Тормышны ярату,бик яшьли әдәбият белән җенләнеп йөрү, мәктәптә укыганда ук шигырьләр язарга омтылу, үзешчән сәнгать һәвәскәре булып авыл сәхнәләрендә, институт

кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булгандыр. 50 нче елларда шигърияттә Гөлшат Зәйнашева дигән йолдыз яна иде.

Җыр башкарыла. «Сәяхәтче җыры » Г.Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин көе .

2 нче укучы.

Г.Зәйнашева иҗатында яшь буынга багышлап язылган шигырьләр дә шактый урын алып тора. Мәсәлән: ”Тукран белән сөйләшү”, “Кояш гомере“,“Әбиемне яратам“, “Тәти сеңлем“ һәм башка бик күп шигырьләрен яратып укыйбыз, яттан сөйлибез, җыр итеп җырлыйбыз .

”Тәти сеңлем” шигыре укыла

5 нче укучы

Г.Зәйнашева – җыр текстлары өлкәсендә эшләүче шагыйрә булып танылган шәхес. Җыр барлыкка китерү өчен аерым талант, үзенчәлекле образлы фикерләү сәләте, халыкчанлык, гадилек, тумыштан күңелгә салынган музыкальлек кирәктер. Аның иҗаты туган җир, мәхәббәт, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән, гадилеге һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар.

6 нчы укучы.

Драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре зур игътибарга лаек. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле Комедияләре һәм драмалары күп тапкырлар Минзәлә драма театрында, Казан театрларында куелды.

«Күктән төшкән кияү» спектакленнән өзек күрсәтелә.

7 нче укучы.

Гөлшат Зәйнашева шигырьләре үзе исән чагында ук кечкенә генә авыл сәхнәсендә дә, олы-олы калаларның мәдәният йортларында да яңгырый-яңгырый өйләргә күчкән, күпләрнең йөрәк түрендә урын алган.

8 нче укучы.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге олуг хезмәтләре өчен Г.Зәйнашева Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

9 нчы укучы
Тыңлыйсыңмы, мин сөйлимен
Үткән гомер турында.
Үткәннәрем бер җыр,бәет,

Барысы чагыла җырымда.

1995 елда күңелгә якын әсәрләрен,моңлы җырларын калдырып, Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева безнең арабыздан китте.Казанның Яңа бистәдәге татар зиратындагы кабер өстендә гранит һәйкәлгә Гөлшат апаның үз кулы белән кәгазьгә язып, васыять итеп калдырган сүзләр уелган: “Кешеләр, яратыгыз бер-берегезне, ярату озынайтыр гомерегезне”.

10 нчы укучы.
Җырларым бар, моңнарым бар

Йөрәк түремдә.
Җыр белән чын дуслар таптым
Туган җиремдә.

Г. Зәйнашева арабыздан китсә дә, дуслары, замандашлары, каләмдәшләре аны бик сагынып искә алалар, Гөлшат апа турында истәлекләр, мәкаләләр язалар. Җырчы Искәндәр Биктаһиров: “Әлбәттә, аның безнең арабыздан, күңелебездән һич кенә дә киткәне юк! Чөнки ул һәрвакыт үзе турында җырлары белән искә төшереп тора. Мәңге яшь булып кал, Гөлшат апа, җырларың белән!”- дип яза. Яшәрәм, дусларым, чөнки

Гүзәл яшьлеккә гашыйк мин.
Шуңа күрә картаерга
Бер дә ашыкмыйм!- дип язган шагыйрә.
Җыр башкарыла «Туган ягым – гөлләр иле» Г.Зәйнашева сүзләре, С. Шәмсина көе.

**Кояш гомере**

(Мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркеме балалары белән Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган күңел ачу кичәсе)

Латыпова Дания Фатых кызы,

Тимербаева Зөлфия Зөлфәт кызы,

Җәлил бистәсенең 6 нчы санлы “Теремкәй” балалар бакчасы тәрбиячеләре,

Сарман районы

Максат:

Балаларны Г.Зәйнашеваның иҗаты белән таныштыру. Балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам итү хисен тәрбияләү. Саннар, төсләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Татарча матур һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү.

Җиһазлау: интерактив җайланмалар, магнитофон, Гөлшат Зәйнашева портреты һәм китаплары күргәзмәсе, шагыйрә иҗатына багышланган стенд, балалар рәсемнәре, бүләккә китап, буяулар, клей, А2 форматында альбом битләре.

Кичә барышы:

*Бүлмә бәйрәмчә бизәлгән. Музыка уйный, балалар бүлмәгә керәләр.*

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле безгә күпме кунаклар килгән. Кунакларыбызның күңелен күтәрү өчен, әйдәгез исәнләшәбез һәм аларга карап елмаябыз!

Балалар: Исәнмесез!

Тәрбияче: Балалар ишетәсезме? Безнең ишегебезгә кемдер шакый бугай. Әйдәгез сорыйбыз, кем бар икән анда?

Балалар: Кем бар анда?

Тәрбияче: Керегез, рәхим итегез.

Айсылу: Исәнмесез, балалар!

Менә ниһаять килеп тә җиттем. Ә хәзер танышыйк. Минем исемем Айсылу, мин сезгә әкиятләр дөньясыннан кунакка килдем. Мин әкиятләр, шигырьләр укырга яратам, җырлар да җырларга яратам. Балалар, әйтегез әле, ә сез шигырьләр тыңларга, сөйләргә яратасызмы соң?

Балалар: Әйе.

Айсылу: Бу шигырьләрне сезгә кемнәр укыйлар?

Б: Шигырьләрне миңа әнием укый.

Б: Ә миңа шигырьләрне дәү әнием укый.

Айсылу: Балалар, ә шигырьләр белән беррәттән сез җырлар җырларга, уеннар уйнарга яратасызмы?

Балалар: Яратабыз.

Айсылу: Болай булгач, бүген без вакытыбызны бик күңелле үткәрәчәкбез. Хәзер мин сезгә бер табышмак әйтәм. Ә сез аның җавабын табыгыз. Әгәр дә табышмакның җавабын дөрес әйтсәгез, минем серле сандыгымнан ул әйбер чыгачак (экранда серле сандык ).

*Беренче слайд.*

Юк аягы, теле юк,

Сөйләмәгән сүзе юк.

Телгә аннан оста юк,

Аннан якын дус та юк. (Китап)

*2 слайд.*

Айсылу: Дөрес, балалар, карагыз әле, безнең серле сандыгыбыздан китап килеп чыкты. Бу китапта нәрсәләр турында язылганын белү өчен, әйдәгез аны ачып карыйбыз.

*3 слайд.*

Айсылу: Балалар, бу кем?

Балалар: Гөлшат Зәйнашева – татар язучысы.

Айсылу: Дөрес. Ул нәрсәләр язган?.

Балалар: Шигырьләр язган. Җырларга сүзләр язган.

Айсылу: Әйе. Бик дөрес. Аның сүзләренә җырлар да язылган. Минем дусларым Гөлшат Зәйнашеваның бик күп шигырьләрен беләләр дип ишеткән идем. Бу сүз дөресме?

Тәрбияче: Әйе. Балалар Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләрен яттан беләләр.

Айсылу: Болай булгач, әйдәгез ярыш үткәреп алабыз. Балалар, сез ризамы?

Тәрбияче: Балаларга саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен, Гөлшат Зәйнашева саннар турында шигырьләр язган. Әйдәгез, балалар, шигырьләрегезне сөйләп күрсәтегез әле.

Балалар Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләрен сөйлиләр.

Айсылу: Безнең балаларыбыз бик уңган булып чыктылар. Әйдәгез әле, балалар, Гөлшат Зәйнашеваның бик матур җырын җырлап күрсәтик әле.

Балалар түгәрәккә басып, хәрәкәтләр ясый-ясый “Бөрлегәнем” җырын башкаралар.

Айсылу: Ә хәзер табышмаклар чишәргә вакыт җитте. Табышмаклар төсләр турында. Һәр балада бер төс бар, әгәр дә җабын дөрес әйтсәгез, ул төс турында бала Гөлшат Зәйнашева язган шигырьне сөйләячәк. Беренче төс турында табышмакны тыңлыйбыз.

Беренче табышмак: Күрә аласыз мине
Алмада һәм чәчәктә,
Карлыганда, җиләктә,
Помидорда бигрәк тә. (Кызыл)

4 слайд

Бала: Җырлый-җырлый җиләк җыям,
Кызыл каен җиләген.
Кып-кызыл җиләкләр белән
Тула инде чиләгем!..

Айсылу:

Икенче табышмак: Мин урманнарны бизим,
Көзне чакырып китерәм,
Әйтә алсагыз мине,
Сезгә яфрак бүләк итәм. (Кызгылт-сары)

5 слайд.

Бала: Алтын төсле матур яфрак,
Җәйдән көзгә бүләктер,
Көзләр мул уңышлы булсын
Дигән изге теләктер.
Һәр агач моңаеп кына
Кызгылт-сары яфрак коя.
Бала чага, шатланышып,
Кызгылт-сары яфрак җыя!

Айсылу:

Өченче табышмак:Мин иң матур төс,
Иң якты төс,
Кояшта күреп була,
Лимон белән банан да
Минем төсне ярата. (Сары)

6 слайд.

Бала: Сары чәчәктән чәчәккә
Оча сары күбәләк.
Сары күбәләк шатлана,
Сары күбәләк шатлана,
Чәчәк белән бергәләп.

Айсылу:

Дүртенче табышмак: Мин урман төсе, яфраклар төсе,
Җирдә үсүче хәтфә чирәм төсе.

7 слайд.

Бала: Язлар җитте, бар табигать:
«Без яшәрәбез,» – диде.
Урман, болыннар, тугайлар
Яшел киемен киде.

Айсылу:

Бишенче табышмак: Сезнең өстегездә мин
Гөмбәз булып торам,
Яңгыр тамчысы белән
Уеннар да уздырам.

8 слайд.

Бала:Күк йөзе күксел томан,
Күксел болытлар сыман...
Күксел диңгезләр дәшә,
Еракта уйный рәшә.

Айсылу:
Алтынчы табышмак: Кайгырмагыз, дусларым,
Мине күргәч болытта,
Минем төсемне хәтта
Әйберләр дә ярата.

Төсләрне дә таптыгыз. Балалар, әйтегез әле без бу төсләрне барысын бергә кайда күрә алабыз?

Балалар: Салават күперендә.

Тугызынчы слайд.

Тәрбияче: Дөрес балалар! Ә хәзер без тагын бер конкурс үткәреп алабыз, рәсемнәр ясыйбыз. Рәсемнең исеме Гөлшат Зәйнашева шигыре кебек үк “Без – табигать дуслары” дип атала. Салават күперендә күргән барлык төсләрне кулланып, сезгә бик матур рәсем ясарга кирәк булачак.

Г.Зәйнашеваның “Тибрәнә җыр күңелдә” дигән җыры куела,балалар рәсемнәр ясый.

Тәрбияче: Бик матур рәсемнәр ясагансыз, әйдәгез без аларны мольбертка куйыйк.

Тәрбияче: Айсылу, безнен балалар сина бүләккә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган җырны әзерләделәр. Әйдәгез, аларны тыңлыйбыз.

“Кояш гомере” җыры башкарыла

Тәрбияче: Шулай итеп Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган кичәбез ахырына якынлашты. Без сезнең белән саубуллашабыз.

Барысы бергә: Сау булыгыз!

## Балачак җырчысы – Гөлшат Зәйнашева

(Гөлшат Зәйнашева иҗаты буенча квест-кичә)

Сафина Резеда Рашат кызы,

Күәм урта гомуми белем мәктәбе башлангыч

сыйныфлар укытучысы, Әтнә районы

Максат: укучыларны Г.Зәйнашева иҗаты белән таныштыруны дәвам итү; уен ярдәмендә китап укуга кызыксыну арттыру; фикерләү, сәнгатьле сөйләм, төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү; аралашу культурасы, балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам хисе тәрбияләү.

Аудитория: башлангыч сыйныф укучылары

Гөлшат Зәйнашева китапларыннан күргәзмә, презентация.

Алып баручы. Хәерле көн, балалар. Кичәбезне җыр тыңлаудан башлыйк әле. Әлеге җырның авторлары кемнәр икәнен әйтеп бирә алырсызмы?

Идел ярларына нурлар сибеп,

Матур булып ата бедә таң.

Таң шикелле якты Туган илем,

Бәхет биргән җирем – Татарстан!

А.б. Я, кем, әйтеп бирә?

- Гөлшат Зәйнашева шигыре, А.Ключарев көе.

А.б. Бик дөрес, укучылар. Без бүген танылган шагыйрә, бик күп халыкчан җырлар, драма әсәрләре авторы, Гөлшат апа Зәйнашеваның тууына 95 ел тулу уңаеннан квест-кичәгә җыелдык. Сезгә алдан ук Гөлшат апаның шигырьләре, җырлары белән танышу бурычы куелган иде. Хәзер ике укучыбыз сезне кыскача гына Гөлшат апаның тормыш юлы белән таныштырып китәр.

1 укучы. Булачак шагыйрә Гөлшат Хисам кызы 1928 нче елның 13 гыйнварында Сарман районы Иске Теләнче авылында хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. 1930 елда гаиләсен кулак дип сөргенгә сөргәндә, 2 яшьлек Гөлшатны Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага биреп калдыралар. Гөлшат апа шушы авылда башлангыч мәктәпне гел “5”легә генә тәмамлый.

2 укучы. Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1942 елда, 14 яшендә Минзәлә педучилищесына укырга керә. Авыр сугыш еллары була. Ашарга икмәк, ягарга утын булмый. Хәтта укучы кызларга тулай торакта мич чыгарырга да туры килә.

1 укучы. 1945 елда Гөлшат Хисам кызы Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә, аны тәмамлагач Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963 елларда) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

2 укучы. Г. Зәйнашеваның беренче шигырьләре, җырлары, пьесалары узган гасырның илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

1 укучы. Гөлшат апаның 1967 нче елда «Замандашыма», 1977 нче елда «Гөлләр иле», 1984 нче елда «Бөҗәкләр концерты», 1988 нче елда «Илле җыр» исемле китаплары басыла. “Илле җыр” китабы өчен Г.Зәйнашева 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

А.б. Без бүген сезнең белән язучы Роза Хафизованың Гөлшат апа турында әйткән сүзләрен эзләрбез. Һәрбер уеннан без берәр сүз табарбыз. Ә ул сүзләрдән җөмлә төзелер. Башладыкмы?

I.Беренче уеныбыз “Пазл җыям” дип атала. Бу уенга 2 төркемгә 5әр укучы кирәк була. (балалар җыела) Ике төркемгә дә пазллар бирелә, алардан сезгә тоташ картина җыярга кирәк булачак.

(Укучылар Гөлшат Зәйнашеваның китап тышлыкларын җыялар.

Бу – беренче чишелеш була. Гөлшат Зәйнашева).






Музыкаль пауза. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган “Гөлләр иле” җырын тыңлау.

II. Икенче уеныбыз – кроссворд чишү. (слайдта)

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1.с | **п** | о | р | т | с | м | е | н |
| | 2.к | | **о** | н | ф | е | т | | | |
| 3.ө | ч | | **п** | о | ч | м | а | к | | |
| | 4.н | | **у** | р | | | | | | |
| 5.б | о | | **л** | ы | н | н | а | р | | |
| | | | **6.я** | ң | а | | | | | |
| 7.б | ө | | **р** | л | е | г | ә | н | е | м |

1.Чаллы, Чистай, Казан үтеп,
Җиттем, ди, Әчтерханга!
Әкият түгел, чындыр, чын,
Әби булган ...!

2. Түгел борын заманда,
Кичә генә Казанда
Бер танышларга кердем,
... хәтле кыз күрдем.

3.Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле ...ларны
Әни йөри пешереп.

4. Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге ... сибә;
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

5. Язлар җитте, бар табигать:
«Без яшәрәбез,» - диде.
Урман, ... , тугайлар
Яшел киемен киде.

6.Җырлыйк ... Әтнә җырын,
Үзәкләрне өздереп.
Яшик сөйгән ярлар белән

Аерылмаска сүз биреп.

7. ... , җиләгем, дип
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.

Икенче чишелеш – ПОПУЛЯР сүзе төзелә.

Шигъри пауза – ике укучы "Тукран белән сөйләшү" шигырен башкара.

III. Өченче уеныбыз барлык балалар өчен. Әзерләнгән укучылар Гөлшат апаның шигырьләрен укый яисә җырын башкара. Сез аның исемен әйтәсез. Мин әйткән хәрефләрдән өченче чишелешне эзлибез.

1 укучы җырлый:
Җырлап кайтып киләм борма юлдан,
Мең тавышлы көен көйли урман.
Яшел аланнары чиккән юрган,
Сабый чагым, әллә шунда калган?
Әй , урман, урман. Җәйге урман,
Йөгереп үтәр идем юлыңнан.
Каршы чыкса сабый чагым,
Шушы урман юлыннан.
(Җәйге урман шигыре. Беренче хәреф - ж)
2 укучы сөйли:
Бик сагындым Ык буйларын,
Ашыгып аккан суларын;
Ык сулары басар төсле
Йөрәгем ярсуларын.
Йөрер идем тугаенда,
Кайтсам Ык буйларына;
Яшел болын, бөдрә таллар
Гел минем уйларымда.
(Ык буйлары шигыре. Беренче хәреф - ы )
3 укучы сөйли:
Бөрлегәнем, җиләгем, дип,
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.
Зур түгел шул, бик кечкенә
Бөрлегән мин, бөрлегән.
Бөрлегән генә булсам да,
Һәр эшкә дә өлгерәм.
(Бөрлегән шигыре. Өченче хәреф – р)
4 нче укучы җырлый:
Күңелле безнең туган шәһәр,
Ямьле язларда килсәң әгәр.
Идел тулып акканда,
Акчарлаклар кайтканда
Күңелле безнең шәһәр.
Күңелле безнең туган шәһәр,
Кояшлы җәйдә килсәң әгәр.
Гөл-чәчәкләр үскәндә,

Алма, чия пешкәндә
Күңелле безнең шәһәр.
(Күңелле безнең шәһәр җыры. Бишенче хәреф – л)
5 нче укучы сөйли:
Тагын кайттым әле авылыма –
Төшләремә кереп йөдәтте.
Бәлки ял иттерер авылым өе
Сагынулардан арган йөрәкне.
Чәчәк аткан яран гөле белән
Ямьле безнең авыл өйләре.
Күп күдем мин тәрәз төпләрендә
Гөл үсмәгән чит-ят җирләрне.
(“Авылым гөлләре” шигыре. Беренче хәреф - а)
6 нчы укучы җырлый:
Керкәле авылы кайда –
Биек тау итәгендә.
Тауларын да сагынып кайтам –
Читләргә китәмен дә.
Керкәле таулары биек,
Биек булса да меник.
Туган якның, сөйгән ярның,
Дусларның кадерен белик.
(“Керкәле таулары” җыры. Өченче хәреф - р)
7 нче укучы сөйли:
Туган ягымда бер күл бар,
Күл эчендә кондыз бар.
Туган якта бер җыр оттым,
Җыр эчендә йолдыз бар.
Җыр эчендә йолдыз булмый,
Җыр эчендә моң була.
Бергә чакның кадерен белик,
Аерылгач соң була.
(“Җыр эчендә йолдыз бар”  шигыре. Икенче хәреф - ы)

ЖЫРЛАРЫ сүзе төзелә.

IV. Дүртенче уен – математик марафон. (Шифр бирелә)

Бирелгән сорауга җавап табып, ул сандагы барлык цифрларны кушарга, килеп чыккан санга туры килгән хәрефне табарга кирәк.

1 төркем Килеп чыккан саннарны кими бару тәртибендә язарга.

1. Гөлшат Зәйнашеваның туган елы (1928 – 1+9+2+8=20 – 2+0=2)
2. Гөлшат Зәйнашева пединститутка укырга кергән ел(1945 - 1)
3. Беренче китабы басылган ел(1958- 5)
4. “Бөҗәкләр концерты” китабы чыккан ел(1984- 4)
5. Шагыйрә вафат булган ел(2005 - 7)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| н | ә | ж | л | е | и | б | р | у |

БЕЛӘН  сүзен төзиләр

2 төркем Килеп чыккан саннарны үсә бару тәртибендә язарга.

1. Гөлшат Зәйнашеваның туган көне (13 – 1+3=4)
2. Гөлшат Зәйнашева педучилищега укырга кергән ел(1942 - 7)

3. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган ел(1991- 2)
4. Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли башлаган ел(1952 -8)
5. “Гөлләр иле” китабы басылып чыккан ел(1977 - 6)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| к | ү | л | з | и | е | н | ә | п |

ҮЗЕНӘ сүзен төзиләр

Музыкаль пауза. “Яңа Әтнә ” җыры башкарыла

V. Бишенче уен – ребус чишәргә.




ҺӘЙКӘЛ сүзен төзиләр

Монолог. 5 нче сыйныф укучысы Гөлшат Зәйнашеваның балачак истәлекләренән өзек – мич чыгару вакыйгасын сөйли.

VI. Алтынчы уен – Гөлшат Зәйнашеваның “Чәчтем шалкан” дип исемләнгән шигыренә яшерелгән артык хәрефләрне табып, сүз ясау.

Чәчтем шалккан, чыкты кишер,
Җыеп алдым чөгендер.
Кып-кызыл эре чөгендер,
Һич тә ялган туүгелдер.
Чөгендерне каййнаттым да,
Ясадым ап-ак шикәр.
Шундый тәмле шикәр чыкты,
Исең-акылың китәр!
Шикәрнең вак-вак кисәгген
Чәчтем җиргә мин кабат.
Түтәл, түтәл, түтәл булып
Үсте җирдә шоколаад!
И йөрим, йөрим бакчада
Ашап шоколад кынна.
Һич тә ялган сөйләмимен,
Арттырамын чак кына!
КУЙГАН сүзе төзелә.
Укучылар тапкан сүзләрдән җөмлә төзиләр:

“ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА – ПОПУЛЯР ҖЫРЛАРЫ БЕЛӘН ҮЗЕНӘҺӘЙКӘЛ КУЙГАН”

(Роза Хафизова)

Алып баручы: Кадерле укучылар, чыннан да, танылган шагыйрә, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, үлемсез җырлар авторы Гөлшат Зәйнашева турында язучы Роза Хафизова: “Гөлшат Зәйнашева – популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйган” дип язган. Без бүген әлеге сүзләрнең хаклыгына тагын бер тапкыр инандык. Бүгенге квест-уен сезгә ошагандыр, шагыйрәбез турында сез яңа мәгълүмат алгансыздыр дип ышанам. Аның иҗатын өйрәнүне дәвам итәрсез дип уйлыйм. Әйдәгез, кичәбезне аның иң матур җырларының берсе – “Туган җирем – Татарстан” җыры белән тәмамлыйк.

Күмәк җыр. “Туган җирем – Татарстан”

**Гөлшат Зәйнашеваның әдәби кунак бүлмәсендә очрашу**

(Сыйныф сәгате конспекты)

Галиәхмәтова Гөлнара Илшат кызы,

Бариева-Саетгараева Гүзәл Фирдәвес кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат: Укучыларны шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлшат Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты белән таныштыру;

Бурычлар:

1. Гөлшат Зәйнашеваның шәхес һәм иҗатына кызыксыну уяту;

2. Язучының гениальлеген һәм эчке көчен күрсәтү;

3. Укуга һәм китапларга мәхәббәт тәрбияләү.

Материаллар һәм җиһазлар: Гөлшат Зәйнашеваның портреты һәм китаплары, башка татар язучыларының портретлары, А3 форматындагы битләр, төсле карандашлар, буяулар.

Чараның барышы:

Укытучының кереш сүзе.

Исәнмесез, кадерле укучылар! Бүгенге класс сәгате - әдәби кунак бүлмәсендә очрашу.

Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Безнең якташ язучылар портретларына карагыз. Аларның барысы да сезгә яхшы танышмы? Алар арасында сезнең өчен әлегә аз билгеле булганнары юкмы? (Укучылар язучыларны атый һәм Гөлшат Зәйнашеваның портретын аерып чыгара). Гөлшат Зәйнашева кем ул? (Драматург, публицист, Татартсанның атказанган эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты).

Язучының тормышы һәм иҗаты. (Укучылар әзерләгән презентация кулланып сөйлиләр).

Беренче укучы: Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Тукай (элек Сарман) районының Иске Келәнче авылында бай игенче гаиләсендә туа. 1930 елда күмәк хуҗалыклар оешкан вакытта авыллардан кулак гаиләләре

куып чыгарылу, Г.Зәйнашева гаиләсенә дә кагылды. Ике яшьлек кызны һәм аннан өлкәнрәк балаларны әти-әниләре күрше Минзәлә районының Иске Тәкермән авылында яшәүче этисенең бер туганына калдыралар. Гөлшатның балачагы шушы авылда уза, монда ул башлангыч мәктәптә укый, аннары күрше Хуҗәмәт авылында җиде еллык мәктәпне тәмамлый. Аннан соң Минзәлә педагогия училищесында укуын дәвам итә. 1945-1949 елларда Зәйнашева Казан дәүләт педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Диплом алганнан соң Г. Зәйнашева хезмәт эшчәнлеген башлый. Башта ул Татарстан радиокомитетында әдәби радиотапшырулар мөхәррире булып эшли, аннары унбер ел дәвамында (1952-1963) Татар китап нәшриятында фантастика бүлеге мөхәррире вазыйфаларын башкара. 1964-1965 елларда ул янә радиокомитетта – музыкаль радиотапшырулар мөхәррире булып эшли. 1965-1966 елларда Зәйнашева – клуб директоры. Ә 1973 елдан 1983 елга кадәр ул Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы булып эшли. Аннан соң ул профессиональ язучы була һәм иҗади эшчәнлек белән генә шөгыльләнә.

Икенче укучы: Г.Зәйнашеваның беренче әсәрләре (үзешчән театр коллективлары өчен язылган шигырьләр, җырлар, кыска пьесалар) илленче еллар азагында вакытлы матбугат битләрендә һәм «Көмеш сәхнә», «Эстрада», «Сәхнә», «Клуб сәхнәсе» җыентыкларында басыла. Шул ук елларда күп кенә халык театрлары зур уңыш белән сәхнәдә аның «Рамай» пьесасын куялар. 1958 елда аның беренче лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. 1957-2005 елларда Г.Зәйнашеваның егермедән артык китабы нәшер ителә. Г.Зәйнашева җыр жанрында бик актив эшли. Аның лирик таланты һәм иҗади үзенчәлекләре монда иң ачык күренә. Халык җырлары традицияләрендә язылган шигырьләрендә ул мәхәббәт, туган җирнең якынлыгы, яшьлек темасын ача. Аларның аергыч үзенчәлеге – гадилек, ритмик тулылык, идея һәм хисләр бердәмлеге, оригиналь чагыштыру куллану һәм музыкаль кыска булу. Г. Зәйнашеваның шигырьләре һәрвакыт музыкантларның игътибарын җәлеп итте. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары аның йөздән артык шигыренә җырлар яздылар. Аларның күбесе бик тиз популярлашты һәм тулыландырылды.

Өченче укучы: Г. Зәйнашева драматургиядә һәм балалар әдәбиятында актив эшли. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?» «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» драмаларын һәм комедияләрен Минзәлә һәм башка бик күп театрлар куйды. «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным җәл түгел сиңа» комедияләре һаман да театр сәхнәсендә уңышлы күрсәтелеп бара. Балалар өчен шигырьләр һәм җырлар «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) китапларында дөнья күрә. Узган гасырның 50-60 нчы елларында Г. Зәйнашева әдәби тәрҗемә өлкәсендә актив эшли башлый. Татар периодикасында аның мәкаләләре барлыкка килә, ул радиода ешрак чыгыш ясый. Аның күп мәкаләләре җырчыларга, актерларга, мәдәният эшлеклеләренә багышланган. Г.Зәйнашева эшчәнлегендә хатын-кыз сәнгать эшлеклеләренә багышланган материаллар аерым урын алып тора, алар арасында З. Басыйрова, А. Галимова, А. Афзалова, Р. Ибраһимова, Ф. Ильская, Х. Әхтамова, Ф. Сөләйманова бар. Ул шулай ук легендар җырчы Гөлсем Сөләйманова, композитор Сара Садыйкова тормышы турында берничә монография яза. 1988 елда татар җырын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен ала.

Гөлшат Зәйнашева китапларына күргәзмә һәм күзәтү.

Укытучы: Балалар, хәзер мин кунагыбызга – китапханәче Алинә Илдар кызына сүз бирергә телим. Ул күргәзмәдә тәкъдим ителгән Гөлшат Зәйнашева китапларына күзәтү ясаячак.

Иҗади остаханә.

Укучылар китапны иҗат итү процессы белән шөгыльләнәләр. Балалар өч төркемгә бүленәләр (1 – иллюстратор-рәссамнар, 2 – редакторлар, 3 – нәширләр). Төркемнәргә биремнәр: 1 төркем – Гөлшат Зәйнашева шигырьләрендә төп геройлар образлары белән иллюстрацияләр булдыра, 2 төркем – булачак китап тышлыкларын рәсмиләштерә, 3 төркем – китапны алга этәрү өчен реклама уйлап таба).

Эшне башкаруга 10 минут бирелә. Эш беткәч, укучылар үз проектларын яклыйлар. Нәтиҗәләр ясау.

Укытучы: Менә безнең әдәби кунак бүлмәсендә очрашуыбыз тәмамланды. Ул кызыклы булгандыр дип ышанап калам. Сездә Гөлшат Зәйнашеваның китапларын уку теләге уянгандыр дип уйлыйм.

Очрашуны Рене Декартане әйткән сүзләр белән тәмамлыйм: "Яхшы китаплар уку – ул үткән заманның иң яхшы кешеләре белән сөйләшү, өстәвенә, алар безгә әңгәмәдә үзләренең иң яхшы фикерләрен генә хәбәр итәләр".

## Гаилә иминлеге кем кулында?

(Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында якташыбыз Гөлшат Зәйнәшева иҗатына нигезләнеп төзелгән ата-аналар белән түгәрәк өстәл эшкәртмәсе)

Харисова Илзирә Алмас кызы,

Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы,Сарман районы

Максат: Дин, аң, милек, нәселне саклау гаранты, Аллаһ каршында зур савап алу чыганагы булган гаилә, аның кыйммәтләре турында уйландыру, аны сакларга чакыру

Чара барышы

“Бер кыз бала җыр чыгарган” (Г.Зәйнәшева сүзләре, музыкасы) җыры яңгырый. (Кызын җитәкләгән әни кеше җырлый)

Укытучы. Хәерле кич, хөрмәтле әти-әниләр һәм килгән барлык кунаклар! Без сезнең барыгызны үзебезнең Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында үткәрелгән гаилә кыйммәтләренә багышланган Түгәрәк өстәлебездә күрүебезгә бик шат. Сезнең күңел җылысыннан, күркәмлектән сыйныф бүлмәбез дә яктырып киткән кебек булды. Гаиләләрнең җылысы бөтен тирәне җылытып, матурлатып җибәрде. Чыннан да, гаилә – кечкенә генә бер дәүләт, тормышыбызның нигезе. Биредә берсен-берсе яраткан, хөрмәтләгән, бер-берсенә ярдәмгә килгән, бер йодрык булып берләшкән кешеләр яши. Шундый гаиләләр безнең дәүләтебезнең киләчәген булдырырга сәләтле, Шундый гаиләләр соклану уята. Мондый гаиләләр күбрәк булган саен дәүләтебез көчлерәк, тормышыбыз матуррак була. Тату гаиләләрдә акыллы, эшчән, тырыш, уңган, тәрбияле балалар үсә. Ә балаларыбызны тәрбияле итү – һәрберебезнең изге бурычы. Димәк, гаиләләребезне ныклы итү дә – безнең бурычыбыз булып чыга. Без бүген сезнең белән гаилә ныклыгының кем кулында булуы турында сүз алып барырбыз. Язучы Ф.Бәйрәмова сүзләре белән әйтсәк: “Бу дөньяда адашмыйча-саташмыйча, ялгыш юлларга кереп китмичә, кадерсезлекләргә төшмичә, санап кына бирелгән шушы гомерне ничек мәгънәле, файдалы, бәхетле итеп уздырырга? Иминлекнең, кадер-хөрмәтнең ачкычы кем кулында?” Дөрес, тәртипле итеп яшәр өчен кемнәрдән, нәрсәдән өйрәнергә соң?

Өйрәнер өчен ярдәмлекләр дә, үрнәк булырлык гаиләләр дә мулдан. Кадер-хөрмәтнең ачкычы кемдә икәнлеген без хәзер бүгенге чараның кунагы – китапханәчебездән сорыйк әле.

Китапханәче чыгышы.

(Ул күренекле мәгърифәтче Р.Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнеп, иң кадер-хөрмәтнең ачкычы тәрбияле балада булуын дәлилли).

Укытучы. Кадерле әти-әниләр. Р.Фәхреддин хезмәтләре – бервакыт кыйммәтен югалтмый торган мирасыбыз. Хәзер аларны Интернет челтәрләреннән дә табып була, китап кибетләрендә дә бар. Алар сезнең кул астыгызда булса бер дә зыян итмәс иде.

Шушы урында балаларыбыз әзерләгән бер тамашаны карап алыгыз әле.

(А.Алишның “Куян кызы” әкияте сәхнәләштерелә. Тамаша ахырына Р.Фәхреддин хезмәтләреннән тәрбияле балалар хакында берничә фикер өстәлә).

1.Тәрбияле бала ата-анасының күңелләрен калдырырлык нәрсәләрне һич эшләмәс. Ата һәм анасы: «Ул эшне мин яратмыйм», - дисәләр, тәрбияле бала ул эшне эшләү түгел, күңеленә дә китермәс

2.Тәрбияле бала әти-әнисе кушкан йомышларны күңел белән башкарыр. Әгәр дә үзеннән берәр нәрсә сорасалар, ачык йөз белән җавап бирер.

3.Тәрбияле бала, ялгышлык белән тиешсез бер эш эшләгән булса, аның ярамаганлыгын кешеләрнең күз каравыннан ук белер, аңлар, шунда ук оялыр һәм кызарыр, әгәр дә берәрсе үзенә киңәш бирсә, аңа һич тә карышмас, каршы әйтмәс, бәлки киңәш бирүчегә: «Бу эшем тиешсез икәнен үзем дә белдем, моннан соң икенче мәртәбә эшләмәм, әйткәнең өчен сиңа рәхмәт, синнән Аллаһы Тәгалә риза булсын!» - дип әйтер.

4.Тәрбиясез бала хаталарын аңлау түгел, әйткәндә дә белмәс, үзенең кимчелекләрен төзәтү исәбендә булмас. Киңәш бирүчегә яман сүзләр белән җавап бирер.

Укытучы. Татар халкында «Оясында ни булса, очканында шул булыр» дигән мәкаль бар. Оядагы тәртипне өлкәннәр күрсәтә. Әгәр без гаиләбезнең үткәненә хөрмәт тәрбияли алабыз икән, балалар шул ук хөрмәтне киләчәк буыннарга тапшырачак. Ә тарих – шәҗәрәләрдә.

Хәзер шәҗәрәләр остасы булган тарих укытучыбызны тыңлап алыйк әле. Аның да сезнең белән уртага салып сөйләшәсе килгән фикерләре байтак.

Тарих укытучысы чыгышы

Укытучы. Хәзер бераз гына ял итеп, сынау биремнәрен үтәп алырга чакырабыз.(Әби, бабай, кайнана, кайната, каенсеңел, килен, кияү, килендәш, балдыз, баҗай, түтәй, җизни, матур апа (абый), чәчәк апа, җиләк апа, яшь әби (бабай), алма апа, зур абый (апа) кебек туганлык атамаларын аңлатырга кирәк).

Укытучы. ...Кычкырып елап, дөньяга бала килә. Әйе, бала туу өйгә, гаиләгә ямь, юаныч, куаныч, бәхет өсти. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә алып килә. Аларның иң беренчесе – балага исем кушу. Исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм аның гомерлек юлдашына әверелә. Балага нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, аларның якыннарын уйландыра, борчый.

Бүген бездә кунакта авылыбызның абыстае, хөрмәтле ак әбисе. Сүзне зур хөрмәт белән аңа бирәсе килә.

Галия абыстай сөйләве:

Безнең бөтен тормышыбыз – әхирәткә әзерләнү. Баланы туганчы ук тәрбияли башларга кирәк, аңа дүрт ай да ун көн дигәндә җан керә. Сабый туганчы ук бер малай, бер

кыз исеме әзерләп кую яхшы. Җиде көн булгач, сул колагына азан әйтеп, исем кушыла. Бала шуннан соң тынычланып кала, исеме аны шайтаннан саклый. Кыз бала туса, аның хөрмәтенә – бер, ә малай кеше туса, ике корбан чалына. Ата-ана өч төп вазыйфаны җиренә җиткереп башкарырга тиеш: балага матур исем кушу, әйбәт тәрбия бирү һәм яхшы кеше белән никахлаштыру. Менә шул турыда онытмагыз.

“Минем исемем Айгөл” (Гөлшат Зәйнәшева сүзләре, Гөлнара Беляева көе) яңгырый.

Әнкәем белән әткәем миңа

Айгөлем диеп исем кушканнар.

Берсе аем дип, берсе гөлем дип,

Куеннарына назлап кочканнар.

Кушымта. Рәхмәт, әнкәем, рәхмәт, әткәем,

Миңа бик матур исем тапкансыз.

Айлы төннәрдә керфек какмыйча,

Бишек тирбәтеп, мине баккансыз.

Тал бишек түгел, миңа гөл бишек –

Былбыл оясы ясаган әткәм.

Ай кебек нурлы, гөл кебек моңлы

Булып үс, диеп җырлаган әнкәм.

Кушымта.

Сабый күңелем никтер ашкына,

Айга үрелә, йолдызга менә.

Үссәм иде мин әткәй-әнкәйгә

Кайгы-хәсрәт китерми генә.

Кушымта.

Укытучы. Гөлшат Зәйнәшева шигырендә исемнең мәгънәсен дә ачып салган. Ә сез исемнәрегезнең мәгънәләрен беләсезме? Әйдәгез, тикшереп карыйбыз.

Исемнәрнең мәгънәләрен ачу буенча бирем үтәлә.

Укытучы. Ата-ананың баласына биргән тагын бер зур байлыгы ул – туган тел. Ә сез гаиләдә матур итеп сөйләшә, бер-берегезгә тәмле сүзләр әйтә беләсезме икән, сынап карыйк әле!

Бер-берсенә ничек эндәшүләре хакында бирем үтәлә.

Укытучы. Татар теле һәм әдәбияты укытучысыннан сезгә бер биремебез дә бар. Сезгә мәкальләрнең ахырын табарга һәм мәгънәләрен аңлатып бирергә кирәк булачак.

- Кем эшләми... (шул ашамый.)

- Беләге юан берне егар ... (белеме булган меңне егар.)

- Һөнәрле үлмәс ... ( һөнәрсез көн күрмәс.)

- Казаныңа ни салсаң ... (кашыгыңа шул чыгар.)

- Ана күңеле балада ... (бала күңеле далада.)

- Ата – ананы тыңлаган адәм булган ... (тыңламаган әрәм булган.)

- Атасына карап ... (баласын коч.)

- Оясында ни күрсә ...(очканда шул булыр.)

- Ата – анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач үзе дә ... (игелек күрмәс.)

- Үзеңне үзең мактама ... (кеше сине мактасын.)

- Игелекле бала үстерсәң ... (картлыгың бәхетле булыр.)

Укытучы. Безнең әңгәмәбез ахырына якынлаша. Әти-әниләргә, әби- бабайларга әйтәсе килгән фикерләрне ишеткәнсездер. Балалар – безнең киләчәгебез. Аларны яратыгыз, мәрхәмәтле, тәүфыйклы итеп үстерергә тырышыгыз! «Тәүфыйклы бала – бәхетле бала» дип, борынгылар юкка әйтмәгән. Ә балаларыбызга бәхетле булу өчен тагын нәрсә кирәк икән?

(Чара алдыннан төшерелгән видеоролик күрсәтелә).

-Җирдә сезгә ни кирәк? - Әти һәм әни кирәк.

-Җирдә сезгә ни кирәк? - Без яшәрдәй өй кирәк.

-Җирдә сездә ни кирәк? - Туган үскән ил кирәк.

-Җирдә сезгә ни кирәк? – Туган телебез кирәк.

Укытучы. Әйе, хөрмәтле әти-әниләр, балаларыбыз дөрес әйтә. Туган телебез булган һәм гаиләләребез нык булганда гына киләчәгебез бар.

Чара Гөлшат Зәйнәшеванын «Тыныч булсын таңнар!»җыры белән тәмамлана

## Г.Зәйнашева – күренекле шагыйрә

(Шагыйрәнең иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби- музыкаль кичә конспекты)

Якупова Гүзәлия Фаиз кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы,

Сарман районы

Максат:Укучыларны Г. Зәйнашеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Якташ язучыларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләү.

Җиһазлар:Г. Зәйнашеваның портреты, китаплары күргәзмәсе, презентация, язучы иҗатына багышланган стенгазеталар, язучының Минзәләгә атап язган хатының күчермәсе.

1 а.б. Хәерле кич, хөрмәтле укучылар, укытучылар, килгән кунаклар! Бүген без “Мин тормышка гашыйк” дип аталган Г. Зәйнашева иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби- музыкаль кичәгә җыелдык. (Укучылар сөйләгәндә слайдлар күрсәтелә).

2 а.б. Минзәлә – талантларга бик бай як. Кайсы гына язучыны алма, сөйләп, язып бетерә алмаслык зур шәхес. Буген без шагыйрә, драматург, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы Г. Зәйнашева турында сөйләрбез.

1 а.б. Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 январенда Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы

Минзәлә районының  Югары Тәкермән авлында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне. Аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

2 а.б. Г. Зәйнашева Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза: “14-15 яшемнән мин Мизәлә училищесында укыдым. 1942-45 еллар иде. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астындагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшь үсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп. Үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек”.

1 а.б. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

2 а.б. Г.Зәйнашеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырында көндәлек матбугатта һәм “Күңелле сәхнә”, “Мәктәп сәхнәсе”, “Эстрада”. “Клуб сәхнәсе” кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда “Тыңларсынмы җырларымны” исемле беренче җыентыгы дөнья күргән. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә шигырен тыңлап китәрбез.

“Күпме йөрдем”, “Кайтырмын мин туган ягыма” шигырьләрен сөйлиләр.

1 а.б. Г.Зәйнашеваның туган җир, туган як турында шигырьләрен укыганда, һәркем уйланыр, минемчә. Чөнки туган як белән бәйле тойгы һәркемнең күңеленә газиз, туган як кеше өчен кадерле. Изге булырга тиеш. Туган як темасы язучы иҗатында зур урын алып тора.

“Минзәлә юллары“ шигырен сөйләнә.

“Туган җирем – Татарстан” җыры башкарыла(А. Ключарёв көе)

“Тәкермән” шигырен сөйлиләр.

2 а.б. Г.Зәйнашеваның шигырьләре күңелгә үтеп керердәй, халыкчан гадилеге, ачык аңлаешлы, музыкаль аһәңе белән аерылып тора һәм бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп популяр җырлар язганнар, иң популяр җырлар тупланган “Илле җыр” (1998) исемле китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә җырын тыңлап китәрбез.

“Сәяхәтче җыры”, “Туган авылым урамы” җыры башкарыла.

1 а.б. Г. Зәйнашева иҗатында яшь буынга багышлап язылган шигырьләр дә шактый урын алып тора. Мәсәлән “Тукран белән сөйләшү”, “Кояш гомере”, “Әбиемне яратам” һәм башка бик күп шигырьләрен яратып укыйбыз, яттан сөйлибез, җыр итеп җырлыйбыз.

“Тукран белән сөйләшү”, ”Әбиемне яратам” шигыре сөйләнә.

“Кояш гомере” җыры башкарыла.(Ф. Әхмәдиев музыкасы)

2 а.б. Г. Зәйнашеваның үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырында көндәлек матбугатта һәм “Күңелле сәхнә” кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. Аның “Бәхет кошы”, “Рамай”, “Гайфи бабай, өйлән давай”, ”Язмышлар һәм ялгышлар” һәм башка пьесалары тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

1а.б. Г. Зәйнашеваның Минзәләгә атап язган хатында шундый юллар бар

- Барасызмы Минзәләгә,

Мин барам Минзәләгә,

Минзәләне күрер өчен, Үзәгем өзгәләнә.

Минзәлә – сугыш елы Минзәләсе минем күңелемдә кайгы, сагышлы, ачлы туклы, шуңа да карамастан ниндидер шатлыклы, өметле бер туган як, туган туфрак булып калган һәм еш кына төшләремә керә, сагындыра,”- дип яза шагыйрә.

2 а.б. Шагыйрә туган ягыннан еракта булса да, күңеле белән туган ягында яши, аны сагына, юксына. Без аны сагынабыз. Аның иҗаты безгә көч, дәрт, илһам бирә. Без, яшь буынны, яшәргә, туган якны, тормышны яратырга өйрәтә. Кичәбез ахырында Г. Зәйнашеваның “Мин тормышка гашыйк” шигырен укып китәсем килә

Кая барсам, якын дуслап табам,

Дуслар белән озын юл кыска.

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.

**Тыңларсыңмы җырларымны?!**

(Тәрбиячеләр арасында Гөлшат Зәйнәшева

тормышы һәм иҗатына багышланган КВН)

Хәлиуллина Рүзилә Рубирт кызы,

Җәлил бистәсенең 6 нчы санлы “Теремкәй” балалар бакчасы

өлкән тәрбиячесе,Сарман районы

Максат: Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрне ныгыту.

Бурычлар: Шагыйрәнең әсәрләренә кызыксыну уяту. Якташ язучылар иҗатын өйрәнүне дәвам итү. Туган ягыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү, аны ярату, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияләү.

Кирәкле җиһазлар: Гөлшат Зәйнәшева портреты, китаплар күргәзмәсе.

Алдан эшләнгән эш: Гөлшат Зәйнәшева тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән танышу, педагоглар өчен “Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗаты” дигән консультация әзерләү, китаплар күргәзмәсе оештыру.

Уен барышы:

1 нче алып баручы: Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли.

2 нче алып баручы: Сарман районы үзенең мәшһүр җырчылары, бию осталары, язучылары, шагыйрьләре, театрда уйнаучы артистлары белән данлыклы. Ә шушы җирлектә туып- үскән, гомерләрен иҗат эшенә багышлаган якташларыбыз булуы күңелдә горурлык хисе уята. Шуларның берсе – шагыйрә Гөлшат апа Зәйнәшева .

1 нче алып баручы: Хөрмәтле педагоглар, килгән кунаклар, без сезнең белән шушы мәшһүр шагыйрәбез турында белемнәрне тагын да тулыландырырга – КВН үткәрергә җыелдык.

2 нче алып баручы: Бүген була КВН

Бу бик күңелле уен.

Бу бит бик зур тамаша!

Тәрбиячеләр көч сынаша,

1 нче алып баручы: Бу уенда үзебезнең педагогларыбыз көч сынаячаклар. Әйдәгез әле, алкышлар белән уенчыларыбызны бирегә чакырыйк. "Зәңгәр төймә" һәм "Илле җыр" командалары бирегә рәхим итегез. (Һәр командада 3 әр тәрбияче катнаша).

2 нче алып баручы: Безнең командаларны бәяләп баручы жюриларыбыз да бар. (Жюри составы белән таныштырыла)

1 нче алып баручы: Гөлшат апа Зәйнәшева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла.

2 нче алып баручы: Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темала гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Гөлшат Зәйнәшеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып килә. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессионал җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнә

1 нче алып баручы: Уеныбызны өй эше тикшерүдүн башлап җибәрәбез. (Өй эше итеп Гөлшат Зәйнәшеваның бер җырын җырлап күрсәтергә бирелә ).

2 нче алып баручы: Булдырдыгыз, афәрин! Жюри 1нче турга үзенең бәясен куяр. Без 2нче турга күчәбез. 2нче тур - “Сорау бездән, җавап сездән” дип атала. Сезгә Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗаты буенча сораулар бирелә. Сез шул сорауларга җавап бирергә тиеш буласыз (һәр командага 4 әр сорау бирелә).

"Зәңгәр төймә" командасына сораулар:

1. Гөлшат Зәйнәшева кайчан һәм кайда туа?( Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә).

2.Шагыйрә нинди гаиләдә дөньяга килә? (Шагыйрә урта хәлле игенче гаиләсендә туа).

3. Гөлшат Зәйнәшеваның беренче язмалары ничәнче елда басыла һәм ул җыентык ничек атала? (Шагыйрәнең «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1958 елда дөнья күрә).

4. Шагыйрә нинди китабы өчен 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була? (Гөлшат Зәйнәшева иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» китабы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була).

“Илле җыр" командасына сораулар:

1. Гөлшат Зәйнәшеваны ни өчен Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар? (Авыл халкын күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930нчы елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә калдыралар).

2. 1988 нче елда шагыйрәгә нинди исем бирелә? (Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә).

3. Гөлшат апа Зәйнәшеваның 5 җырын санап китегез әле. («Китмә, сандугач», «Менәргә иде Урал тауларына», «Үз илемдә», «Кояш гомере», «Аерылмагыз»).

4. Гөлшат Зәйнәшева үзенең хезмәт юлын кем булып башлап җибәрә? (Шагыйрә диплом алгач, мөхәррир булып эшли башлый).

1 нче алып баручы: Безнең уенчыларыбыз бик күп беләләр. Афәрин, Афәрин! Уеныбызның 3нче туры “Бер-бер артлы сана” дип атала. Командалар бер-бер артлы шагыйрәбезнең җыентык исемнәрен әйтешәләр, чират кемдә кала – шул команда җиңелә. Уеныбызны “Зәңгәр төймә” командасы башлап җибәрсен әле. («Тыңларсыңмы җырларымны», Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе» һ.б.)

2 нче алып баручы: Безнең хөрмәтле жюри әгъзалары бу ярыш өчен үзләренең бәяләрен куяр.

1 нче алып баручы: 4 нче турга күчәбез. Хөрмәтде педагогларыбыз, бу тур «Дөрес әйт» дип атала. Сезнең бурычыгыз – укылган шигырь юлларының кайсы әсәрдән икәнен билгеләү.

Сандугач, сандугач.
Китмә, китмә, сандугач!

Канатларын талдырып,

Туган җирне калдырып
Бездә туып үстең син.
Чык суларын эчтең син. («Китмә, сандугач!»шигыреннән)

2 нче алып баручы:
Юллар уздым, илләр гиздем,
Юкка гына гизмәдем.
Юллар узып, илләр гизеп,

Мин бит сине эзләдем. («Син икәнсең...»

2 нче алып баручы: Уен турлары тәмам. Нәтиҗәне чыгарыр өчен сүз жюрига бирелә.

1 нче алып баручы: Гөлшат Зәйнәшева әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗади активлык күрсәтә. Үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында ул әдәби тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә, көндәлек матбугатта басылган язмалары, сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә.

2нче алып баручы: Хөрмәтле педагогларыбыз, килгән кунаклар, якташ язучыларыбызны онытмыйк, аларның иҗаты белән танышып торыйк. Якташ язучыларыбыз белән горурланыйк!

**Гөлшат Зәйнашева «Кем булырга?»**

(дәреснең технологик картасы)

Чернова Ирина Григорий кызы,

Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбенең

татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Зәй районы

Технологик карта

<table>
<tr><td>Максат</td><td colspan="3">1. Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү,<br>2. Сөйләм телен, логик фикерләрен үстерү, тыңлап, укып аңлау.<br>3. Тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.</td></tr>
<tr><td>Планлаштырган нәтиҗәләр</td><td colspan="3">Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: башка телләргә, мәдәниятенә ихтирам уяну. Төрле һөнәр ияләренең мөһим икәнлеген аңлау. Тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәнү.<br>Метапредмет нәтиҗәләр:<br>Танып-белү УУГ: проблема кую, хәл итү, өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү, нәтиҗә чыгара белү; сәнгатьле уку.<br>Коммуникатив УУГ: проблеманы бергәләп чишүдә катнашу; үз фикереңне тулы һәм дөрес әйтә белү, әңгәмәдә катнашу.<br>Регулятив УУГ: уку мәсьәләсен аңлау, чишү юлларын таба белү.<br>Предмет буенча: Гөлшат Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында белү, “Кем булырга?” шигыренең эчтәлеген укып аңлау, идеясенә төшенү.</td></tr>
<tr><td>Дәреснең тибы</td><td colspan="3">Яңа белемнәрне үзләштерү дәресе</td></tr>
<tr><td>Төп төшенчәләр</td><td colspan="3">Савыктыру, иң элек, һөнәр.</td></tr>
<tr><td>Предметара бәйләнеш</td><td colspan="3">Татар теле,</td></tr>
<tr><td>Эшне оештыру</td><td colspan="3">Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль</td></tr>
<tr><td>Материал</td><td colspan="3">Сүзлек, Мотыйгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г., Гыйзәтуллина Э.Х. “Татар әдәбияты” дәреслеге, Казан “Мәгариф – Вакыт”нәшрияты, 2014.</td></tr>
<tr><td>Җиһазлау</td><td colspan="3">Мультимедия проекторы, экран, Г.Зәйнашева тормышы турында презентация, китаплар күргәзмәсе, сүзлекләр, төрле һөнәрләр ясалган рәсемнәр.</td></tr>
<tr><td>Дәрес этаплары</td><td>Укытучы эшчәнлеге</td><td>Укучы эшчәнлеге</td><td>Универсаль уку гамәлләре (УУГ)<br><u>Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр</u> (ШУУГ)<br><u>Метапредмет нәтиҗәләр</u><br>Танып-белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ)<br>Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ)<br>Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ)<br>Предмет буенча нәтиҗәләр.</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Оештыру Мативлаштыру (1-2 мин)** | Исәнләшү.<br>Психологик уңай халәт тудыру.<br>Дәреснең эпиграфы белән таныштыру.<br>Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.<br>Әңгәмә оештыра. | Исәнләшләр.<br>Дәрескә әзерлекне күрсәтәләр.<br>Мәкальне тыңлап сорауларга җавап бирәләр. | ШУУГ: барлык һөнәрләрнең дә мөһим булуын аңлау;<br>ТБУУГ: текстны тыңлап аңлау;<br>КУУГ: сорауларга җавап бирә алу, әңгәмәдә катнаша алу, үз фикерен дөрес әйтә алу;<br>РУУГ: эшкә әзерлекле булу. |
| **Белемнәрне актуальләштерү** | Өй эшен тикшерү. (36 бит, 4нче бирем)<br>Әңгәмә оештыру.<br>-Әти-әниләрегез кайда эшлиләр?<br>-Алар нинди һөнәр ияләре?<br>-Аларның һәнәрләре кирәклеме? | Өй эшенә җавап бирү.<br>Әти-әнисенең кайда һәм нинди һөнәр ияләре булуны әйтү.<br>Әңгәмәдә катнашу. | ШУУГ: эшкә җаваплылык хисен аңлау;<br>ТБУУГ: сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрү;<br>КУУГ: әңгәмәдә катнаша алу;<br>РУУГ: башкаларның җавапларын бәяли, дөресли белү. |
| **Уку мәсьәләсен кую** | Уку мәсьәләсен формалаштырып әйттерү.<br>- Без бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез?<br>-Һөнәрләр белү киләчәктә ни өчен кирәк?<br>-Әйдәгез шушы сорауларга җавапларны без Г.Зәйнашеваның “Кем булырга?” дигән шигыреннән табыйк. | Һөнәрләр белү турында уку мәсьәләсен аңлап әйтү. | ШУУГ: максатчан була белү;<br>ТБУУГ: уку мәсьәләсен таба белү, нәтиҗә чыгара белү;<br>КУУГ: үз фикереңне дөрес һәм матур итеп җиткерә алу.<br>РУУГ: уку мәсьәләсен куя белү. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү** | Г.Зәйнашева турында кыскача белешмә бирү. (презентация)<br>Әңгәмә оештыру.<br>-Г.Зәйнашева кем ул?<br>-Ул нәрсәләр яза?<br>-Ул кемнәр өчен шигырьләр язган?<br>-Ничек уйлыйсыз, ни өчен балалар | Тыңлау.<br>Сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу.<br>-Г.Зәйнашева шагыйрә.<br>-Ул шигырьләр һәм җырлар язган.<br>- Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә язган. | ШУУГ: һөнәрләрнең барысы да кирәкле, үзенчәлекле икәнен аңлау; тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын таба белү;<br>ТБУУГ: аңлап уку, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлау, синтез, нәтиҗә чыгару;<br>КУУГ: әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дәлилиле итеп җиткерә белү, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өчен дә шигырьләр язган?<br>- Әйе, балаларны яраткан, алар өчен төрле матур шигырьләр, җырлар язган. Менә шуларның берсе “Кем булырга?” шигыре белән танышып китик.<br><br>Шигырьне укый. Сүзлек эше үткәрү Тәрҗемә итү. Беренчел тәэсирне уртаклашу.<br>-Шигырьдә сүз нәрсә турында?<br>-Малайның гаиләсендә кемнәр бар?<br><br>-Малайның кем булуын телиләр?<br>-Сезнеңчә кайсы һөнәр яхшырак?<br><u>Проблема чыгару.</u><br>-Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?<br>Ничек инде ул, кеше булу?<br>-Ә сез үскәч кем булыр идегез?<br>-Бу һөнәрләр өчен нәрсәләр белергә, нәрсәләр өйрәнергә кирәк? | -Чөнки балаларны яраткан.<br><br>1-2 яхшы укучы бала шигырьне укыйлар. Сорауларга җавап бирәләр.<br>-Кем булу турында.<br>-Абыйлары, әтисе, әнисе, апасы һәм әбисе.<br>-Баянчы, шофёр, табиб, сатучы булуын телиләр.<br><br>-Укырга, белем алырга, тырышырга, күп белергә, куркак булмаска кирәк. | башкаларның фикерләрен тыңлый белү, сораулар бирергә өйрәнү;<br>РУУГ: уку мәсьәләсен чишә белү, анализ барышын төзи белү, контроль, корекция, башкаларның фикерләрен дөресли белү;<br>Предмет: Г.Зәйнашева иҗаты турында белешмә алу, шигырьнең эчтәлеген укып аңлый белү. Әсәрнең идеясенә төшенү. |
| **Ял минуты** | | | ШУУГ: позитив үзара бәйләнеш;<br>-әхлакый-этик бәяләү;<br>РУУГ: үзрегуляция |
| **Яңа теманы ныгыту** | Һөнәрләр турында әңгәмә оештыру.<br>-Тагын нинди һөнәрләр беләсез? (рәсемнәр)<br>-Кайсы һөнәр нинди?<br>38 бит, 5нче биремне эшләтү. | Әңгәмәдә катнашалар, кайсы һөнәрнең нинди булуын билгелиләр. Җөмләләр, диалог төзиләр, парлап | ШУУГ: һәр һөнәрнең авыр, җаваплы эш икәнен аңлау; кешеләрнең эшен хөрмәтли белү; һөнәрле булу өчен кеше булырга, белем алырга, күп белергә кирәклекне аңлау; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 38 бит, 6нчы күнегү буенча диалог төзү.<br>“Барлык һөнәрләр дә яхшы,<br>Барлык һөнәрләрләр кирәк” мәкале<br>белән ныгыту. | сөйләшергә өйрәнәләр. | ТБУУГ: сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлау, нәтиҗә чыгара белү;<br>КУУГ: фикереңне дәлилле итеп җиткерү, диалогка керә белү;<br>РУУГ: башкаларның фикерләрен дөресли белү, үз эшчәнлегенә бәя бирү;<br>Предмет: әсәрнең идеясенә төшенү. |
| **Өй эше** | Өй эшен, белем дәрәҗәләренә карап, һәр укучы үзе эшли алырлык эш тәгъдим итә:<br>1) (мәҗбүри) Г.Зәйнашева турында укырга, шигырьне сәнгатьле укырга.<br>2) (иҗади) үзегезгә охшаган һөнәргә реклама ясарга (рәсемнәр, презентация, фотолар)<br>3) һөнәрләр турында диалог төзергә. | Өй эшен аңлый, сайлый, көндәлекләргә язып куя. | ШУУГ: мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер булу;<br>ТБУУГ: дәреслектән кирәкле информацияне табу һәм аңлау;<br>КУУГ: диалог төзи белү;<br>РУУГ: үз эшчәнлеген контрольдә тоту;<br>Предмет: Г.Зәйнашева иҗаты турындагы мәгълүматны белү. |
| **Рефлексия, бәяләү, үзбәя** | Сораулар биреп йомгак ясау.<br>- Укучылар, бүгенге дәрестә нинди яңалык алдык? Дәрестә нәрсәгә өйрәндек? Һөнәрле булу өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Киләчәктә һөнәр белү кирәкме? Дәрес сезгә файдалы булдымы? Дәреснең уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? Үзегезнең эшчәнлегегезгә бәя бирегез. | -Мине .... гаҗәпләндерде.<br><br>-Миңа күбрәк ... ошады.<br><br>-Миңа .... эшләү авыр булды.<br><br>-Миңа дәрестә ... кызык булды.<br>-Минем ... өчен рәхмәт әйтәсем килә.<br>Үзбәя бирә. | ШУУГ:<br>-үз уңышларың (уңышсызлыкларың) сәбәпләрен әйтә алу;<br>ТБУУГ: нәтиҗә чыгару;<br>КУУГ: үз фикереңне дөрес итеп җиткерә алу; төрле фикерләрне кабул итү; иптәшеңне тыңлый белү.<br>РУУГ: бәяләү, үзбәя. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Укытучы дәрестәге эшчәнлеккә объектив бәя бирә. Балаларны мактый. | | |

**Сарман ягы-талантларга бай як**

(Сыйныф сәгате)

Гыймадеева Римма Зөфәр кызы,

Гыйлфанова Ильмира  Альберт кызы,

Сарман гимназиясенең  башлангыч сыйныф укытучылары,

Сарман  районы

Максат:

- Сарман районының язучысы, шагыйрә, драматург, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты белән якыннан танышу, шигырьләрен уку, җырларын башкару, тыңлау;
- Сарман районының танылган җырчысы Илһам Шакиров, шагыйрьләр Вәсимә Хәйруллина, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Клара Булатова турында укучылар чыгышын тыңлау;
- туган якка багышланган шигырьләрне уку;
- укучыларда туган якка, туган җиргә, аның халкына мәхәббәт, горурлык, соклану хисләре тәрбияләү;
- сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру;
- укучыларның эстетик зәвыкларын үстерү.

Материал:  якташ язучыларның, шагыйрьләрнең портретлары, китаплары, компьютер,

Дәреснең барышы: (Слайд1,2)

Магнитофоннан " Шушы яктан, шушы  туфрактан без" дигән җыр яңгырый. Рәис Нәгыймов көе, Клара Булатова  сүзләре.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк — шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә дәшеп кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр зурлап чакыра.

1нче укучы		Читтә йөргән чакта, сагындырып,

Керер өчен төнлә төшеңә.

Алсу таңлы, биек зәңгәр күкле

Туган ягы кирәк кешегә.

2нче укучы		Зур уңышлар яулап заманалар

Матур бәя бирсә эшенә,

Шатлыкларын уртаклашыр өчен

Туган ягы кирәк кешегә.( Ф.Яруллин)

Укытучы: - Әйе, безнең туган ягыбыз – Сарман ягы, җырларда җырланган сандугач сайрар ягыбыз. Сарман ягы талантларга искиткеч бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 30га якын шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Бу кадәр язучының әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Безнең як Илһамнары, Зөһрәләре белән мактана ала. Безнең якта туып-үсеп, канат чыгарган Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Әзһәр Габиди, Клара Булатова, Мәдинә Маликова, Гөлшат Зөйнәшева, Хәниф Хәйруллиннар күренекле язучы, шагыйрьләр булдылар. Алардан алган эстафетаны Дамир Гарифуллин, Вәсимә Хәйруллина, Гөлнара Якуповалар үз кулларына алдылар. Кыскасы, Сарманда әдәбият-сәнгать дөньясы туктаусыз гөрләп тора. Сарман ягы талантларга бай.

Әкрен генә музыка агыла. Илһам Шакиров башкаруында “Туган җирем – Татарстан” җыры яңгырый. (Экранда күрсәтелә)(Слайд3)

- Балалар, җыр нәрсә турында? ( Татарстан, туган ил, туган җир)

- Туган ил, туган җирне ярату ничек сурәтләнгән?

- Туган авылны икенче төрле ничек әйтеп була? ( Туган җир, туып үскән җир)

- Җырны кем башкара? (Илһам Шакиров)

- Аның турында ниләр беләсез? (Илһам Шакиров турында 2 укучының чыгышы) (Слайд 4-6)

- Халкыбызның мәшһүр җырчысы, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Гыйльметдин улы Шакиров 1935 елның 15 февралендә Татарстан АССРның Сарман районы Яңа Бүләк авылында тимерче гаиләсендә туа. Яшьтән үк җыр, музыка белән мавыга. 1954 елда Теләнче-Тамак урта мәктәбен тәмамлагач, шул елда ук ул Казан музыка училищесына укырга керә. Бер елдан соң Казан дәүләт консерваториясенең вокал факультетына күчә һәм аны 1960 елда тәмамлап, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә солист булып эшли башлый. Татар җыр сәнгатендә иң күренекле, иң атаклы, үз җырлау манерасы, үз мәктәбе, үз юлы булган җырчы ул – Илһам Шакиров. Гаять зур диапазонлы, киң колачлы бай репертуарга ия булган И.Шакиров башкаруында халкыбызның теләсә кайсы җыры да гаҗәеп бер үзенчәлек, моң, аһәң белән яңгырый. Ул халкыбызның хәтер түрендә онытылып яткан әллә никадәр көй-җырларын казып чыгарып, яңадан халкына кайтарып бирде. «Кара урман», «Син сазыңны уйнадың», «Әллүки», «Туган тел», «Сәрбиназ», «Туган авыл», «Кораб», «Бер алманы бишкә бүләек» кебек элекке матур көйләр халык арасына таралып китәләр.

- 2019 нчы елның 30 нчы августында – Республика көнендә Сарманда зур тантана үткәрелде: Сарман балалар сәнгать мәктәбенә бөек җырчыбыз – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, “Алтын аполлон” һәм башка мактаулы исемнәр һәм бүләкләр иясе Илһам Шакиров исеме бирелде һәм бөек җырчыбызга бюст ачылды. (Слайд7)

- Илһам абый дигәч тә, күңелгә «Сарман сандугачы» дигән сүз килеп баса. Сарман турындагы җырларның беренче башкаручысы, халыкка җиткерүчесе дә Илһам Шакиров бит.

Укытучы: Балалар, ә җырга көйне кем язган? Аның турында нәрсәләр беләсез? (2 укучы чыгышы) (Слайд 8-11)

- Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка

балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә.

- 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә.

- 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Г.Зәйнашеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана. 1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга.

- Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темала гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Г.Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып килә. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессионал җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнә. «Туган жирем –Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Б.Гайсин музыкасы), «Кояш гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Аерылмагыз» (Ч.Зин-нәтуллина музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы) кебек җырлар татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» (1988) исемле китабы өчен Г.Зәйнашева 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

- Г.Зәйнашева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» һ.б. драма һәм комедияләре үз заманында Минзәлә театры һәм башка татар театры сәхнәләрендә уйналып йөри, «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным җәл түгел сиңа» дигән комедияләре әле дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

- Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары исә шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984),

«Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган.

Магнитлы тактага "Туган авыл", "Туган җир" дигән сүзләр куела.

- димәк, бүген сыйныф сәгатендә без нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (....)

- Укучылар, бүген сүз нәрсә турында барачак? (*Туган авыл, туган җир , Туган ягыбызда иҗат иткән язучылар, җырчылар турында сүз барачак*)

- Әйе, без бүгенге сыйныф сәгатендә үзебезнең туган ягыбыз, туган ягыбызда иҗат иткән язучыларыбыз турында сөйләшәчәкбез, аларның шигырьләрен тыңлаячакбыз. Ләкин безнең дәрес үзенчәлеклерәк булыр, без рәсем дә ясарбыз, шигырьләр дә укырбыз, кроссворд та чишәрбез, үзебезне шагыйрь итеп тә сынап карарбыз. Зур юлга кузгалыйк әле.

1нче тукталыш – (слайдта Сарман гербы ) рәссам тукталышы, (слайд 12)

Безгә сары, яшел, кара, кызыл карандашлар кирәк була. Сезнен алдыгызда Сарман районы гербы,

- Татарстан Республикасының Сарман муниципаль районы гербы

“Караңгы кызыл җирлектә – җырлаучы сандугач; аскы ягында щитның ике почмагы да яшел төс белән, түгәрәкләп һәм аска чыгып китә торган ике фигура белән аерымланган: уңнан – алтын башак, сулдан –кара ташкын белән”.

Герб символикасын нигезләү:

Кошлар кешеләрдә һәрвакыт гадәти булмаган хисләр тудыра. Җирдән өскә күтәрелеп оча алуларыннан чыгып, алар бик күп төрле, бигрәк тә рухи үсеш һәм иҗат белән бәйле сыйфатларга ия, дип исәпләнгәннәр. Символ буларак, кошлар күп нәрсәне аңлаткан. Сарман районы гербында сандугач күтәренкелек, иҗат итү һәм алга омтылыш символы булып тора. Җырлаучы сандугач җирле халыкның мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге уңышларын күрсәтә. Кызыл төс сандугач символикасын тулыландыра, шулай ук Сарман табигатенең матурлыгын һәм халыкның хезмәт сөючәнлек, ныклык, оптимизм кебек сыйфатларын чагылдыра.

Районның икътисади үсешен, аның хуҗалык итү нигезен тәшкил иткән авыл хуҗалыгы алтын башак һәм табигать, сәламәтлек, уңдырышлылык, тормыш үсеше символы булган яшел төс белән чагылдырылган. Алтын – байлык, тотрыклылык, ихтирам һәм акыл символы. Район икътисадының икенче өлеше – нефть тармагы – кара ташкыннар белән күрсәтелгән. Кара төс – тыйнаклык, акыллылык, яшәешнең мәңгелеге символы.

Шулай итеп, герб символлар теле белән һәм аллегорияләр аша районның мәдәни, табигый һәм икътисади үзенчәлекләрен чагылдыра.

Авторлар төркеме:

Герб составында Рамил Хәйретдинов (Казан), Радик Салихов (Казан), Илнур Миңнуллин (Казан), Константин Моченов (Химки), Кирилл Переходенко (Конаково), Оксана Афанасьева (Мәскәү), Раил Ямашев (Җәлил бистәсе), Эльмира Аскарова (Сарман) булган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы һәм Россия Геральдачылары союзы тарафыннан эшләнде.

*(*Парларда эш: гербны слайдта күрсәтелгәнчә буяу, эш беткәч рәсемне магнит тактага беркетү)

2нче тукталыш. Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты. Туган якка багышланган җырлары. (слайд 13,14)

1 укучы җырлый: “Үз илемдә” Сара Садыйкова көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре

«Керкәле таулары» Айдар Галимов башкаруында Илгиз Закиров көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре. «Авыл көе» Татар халык көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре

1 укучы башкаруында “Гөлләр иле” Сәлимә Шәмсина көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре

Гөлшат Зәйнашеваның балаларга язган җырлары: (слайд 15,16)

Җыр башкару. "Гимназиядә дуслаштык" Сафьян Ибраһимов көе.

“Әбиемне яратам” Асия Зәйнашева көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре

“Өй артыгыз гөлбакча” Рамил Курамшин көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре

Гөлшат Зәйнашеваның балалар өчен язган шигырьләре. (слайд 17)

1 нче укучы."Тиктормас" шигырен сөйли.( Бу шигырьдә әби кечкенә оныкны тиктормас булган өчен кәҗә бәтие кебек бәйләп куйган.Ул аны хәйләләдем дип уйлый, ә чынында киресенчә: оныгы аның чүәкләренә ком тутыра, ул шуның өчен тыныч.

2 нче укучы. "Спортсмен әби" шигырен сөйли. ( Шигырьдә лирик герой – әби. Әби-спортсмен булган, төрле кызык хәлләргә калган.

4 нче укучы. "Пенсиягә" шигырен сөйли.

5 нче укучы. "Камил үстергән көнбагышлар". Камил үстергән көнбагышларны чыпчыклар "пеләш" калдырган.

6 нчы укучы. "Чәчтем шалкан". Бу шигырь халык экиятләренә охшаган. Анда лирик герой чөгендердән шикәр ясаган, шикәрне чәчкән - шоколад үскән. Автор гадәттән тыш арттыру алымы кулланылган.

7 нче укучы. "Конфет". Бу шигырь күп конфет ашаганга үсмичә калган малай турында.

8 нче укучы. "Сагыз". Бу шигырьдә автор гел сагыз чәйнәп йөгән балалардан көлә. Әбисе аларга чын сагыз - чыршы сагызы чәйнәргә куша, жевачка дигән сагыз ул - ялган сагыз, явыз ди.

9 нчы укучы. "Телен йоткан Халик" шигырен сөйли.

11 нче укучы."Татарча ничек?" Бу шигырьдә малайның туңдырма ашыйсы килү - татарча белмәү каршылыкка килә.

3 нче тукталыш Яшь шагыйрьләр Синквейн алымы белән шигырь төзү

(Слайд 18) 1нче юл-1 исем, 2нче юл-2 сыйфат, 3 нче юл -3 фигыль, 4нче юл- 1 җөмлэ язарга. 5 нче юл- 1 сүз белэн әйтү

Тема: Туган авыл

Туган авыл

Кадерле, якын

Яратам, горурланм, сөенәм

Туган авылымны яратам, горурланам

Җылылык

4 нче тукталыш. Якташ язучы, шагыйрь, җырчыларларны таны

(портретларын магнит тактага беркетү) (слайд 19)

1)1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа

күрә аңа бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчен йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның кезеннән хезмәт юлын башлый. ”Шушы яктан шушы туфрактан без” шигыренең авторы (Клара Гариф кызы Булатова). (Слайд 20)

2) 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап, фронтка китә һәм, яраланып, госпитальләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла. Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без яз дуслары», «Югалган кояш», “Күлдәвектә кояш көлә” китаплары дөнья күргән. (Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин ) (Слайд 21)

3) 1928 нче елның 17 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Урта мәктәпне Сарманда тәмамлый. (Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев) (Слайд22)

4) Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында игенче гаиләсендә туа. (Мәдинә Габделхак кызы Маликова) (Слайд 23)

5) Кайткан чакта Сарман буйларына

Чыгарсыңмы каршы алырга?... җырының авторы, язучы-журналист, шагыйрь, һәвәскәр археограф, Сарман тарихчысы, галим (Дамир Хәйрулла улы Гарифуллин) (Слайд24)

6) 1943 елның 28 октяберендә Сарман районының Чураш авылында туа. Шагыйрә, балалар язучысы, укытучы.(Хәйруллина (Талипова) Вәсимә Лотфулла кызы) (Слайд25)

-Ә хәзер Фәнис Яруллинның “Туган ягы кирәк кешегә” шигырен тыңлап китик. (Слайд26)

Читтә йөргән чакта, сагындырып
Керер өчен төнлә төшенә,
Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле
Туган ягы кирәк кешегә.
Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,
Шатлыкларын ишеттерер өчен
Туган ягы кирәк кешегә.
Йөри-йөри күңелең тупасланса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,
Күңелләрне сафландырыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.
Яшәр өчен бетмәс көч алырга,
Олысына һәм дә кечесенә
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә

Һәр кеше өчен туган як газиз булган кебек, һәр мәртәбәле, данлыклы шәхес туган төбәкнең бизәге булып тора. Бүген без районыбызның йөзек кашы булырдай кешеләре белән таныштык, шигырьләрен укыдык. Туган якның горурлыгы булган шагыйрьләре белән таныштык. Туган як белән горурлану хисе тагын да артты.

Нәтиҗә ясату.

Без үзебезнең авыл, аның уңган, күренекле кешеләре белән горурланырга тиешбез. Шушы якта, шушы җирдә туып үскән балалар буларак, без аларның йөзенә, әти-әниләргә, әбиләргә, бабайларга кызыллык китермәскә тиешбез.

Йомгаклау. "Туган ягым" проект ясап килергә (төркемнәрдә эш.) (Слайд27)

**Туган ягыбызның моңлы шагыйрәсе**

(шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы,

Җиһангиров Айдар Фаиз улы,

А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми

белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат. Якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты белән таныштыру, күренекле шәхесләребез турында укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, балаларның сөйләм телен үстерү, дөньяны танып-белү, күзаллауларын арттыру, туган телебезгә, татар шигъриятенә, сәнгатькә аңлы караш, мәхәббәт тәрбияләү, кызыксындыру уяту.

Җиһазлау. Гөлшат Зәйнашева портреты, иҗатына багышланган презентация, "Гөлшат Зәйнашева" истәлекләр китабы, "Казан утлары", "Сөембикә" журналлары, шагыйрәнең шигырь җыентыклары.

"Ходай аны бу дөньяга җыр чишмәсе итеп яраткан бит!
Кайсы гына җыр текстын укып чыкма, күңелдә яңа көй уяна башлый.
Шуңа күрә композиторлар аның тирәсенә елыша"
Сибгат Хәким

"Гөлшат Зәйнашева татар җыр поэзиясенә үзеннән лаеклы өлеш кертте. Аның җырларын
халык үз җыры итеп кабул итте, яратты"
Гариф Ахунов

Укытучы. Исәнмесез, укучылар, килгән кунаклар! Бүгенге кичәбезне без ярты гасыр дәвам иткән күпкырлы иҗаты, йөздән артык җәүһәрдәй җырлары белән шигърияттә мәйдан тотып, татар халкының тирән ихтирамын казанган туган ягыбызның моңлы шагыйрәсе Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева иҗатына багышлыйбыз. Белгәнебезчә, күптән түгел аның 95 еллык юбилеен билгеләп үттек.

"Җырлыйм әнием турында" җыры (Ф. Әхмәдиев көе) яңгырый.

1 нче алып баручы. Эчтәлеге белән бик гади, самими дә һәм бик гүзәл шигърияте бу җырның гомере озын була. Ничә буын балаларның яраткан җырына әверелә.

2 нче алып баручы. Җыр кеше йөрәгендә туа. Кешенең барлык кичерешләрен, барлык тойгыларын җиткерә белүче шагыйрь һәм композитор йөрәгендә. Әйе, туа! Дөньяга адәм баласы туган кебек, җир куенында орлык яралып, шытып чыккандай, җир астыннан чишмә бәреп чыккан шикелле. Җыр әнә шулай туа.

1 нче алып баручы. Барыбыз да беләә: һәммәбез дә яратып җырлый торган, чын мәгънәсендә популяр булган "Туган җирем – Татарстан" (А. Ключарев көе), "Менәргә иде Урал тауларына" (М.Мозаффаров көе), "Китмә, сандугач" (Р.Яхин көе), "Үз илемдә", "Ак пароход" (С.Садыйкова көе), "Туган җиремә", "Яшь гомер", Күл буена килсәң иде",

“Гармунчы”, “Күңелле ял итегез” (З.Гыйбадуллин көе), “Гөлләр иле” (С.Шәмсина көе), “Кукмара” (М. Имашев көе), “Туган авылым урамы” (Г.Сәйфуллин көе), халык көйләренә иҗат ителгән “Туй җыры”, “Зәңгәр төймә”, “Урманнарга кердем”, Иртә дә генә торам”, “Сәфәр” һәм башка җырлары татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

“Туган авылым урамы” (Г.Сәйфуллин көе) җыры башкарыла.

2 нче алып баручы. Гади генә сүзләр белән кеше күңеленең нечкә хисләрен кузгата шагыйрә. Аның бөтен осталыгы шунда: шул олы хис бөтенләе белән сине биләп ала, биеклеккә күтәрә. Шуңадыр аның шигырьләренә композиторларыбыз еш мөрәҗәгать итә һәм искиткеч моңлы-сагышлы, бәйрәм рухлы якты җырлар иҗат итә.

1 нче алып баручы. Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Сарман районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә. Урта хәлле крестьян Хисам абый, көчләп оештырылган колхозга кергән булса да, 1930 нчы елда кулак дип Архангельск өлкәсендәге җанкыйгыч Соловки лагерена озатыла, шунда һәлак була. Репрессия корбаны буларак соңрак аклана.

2 нче алып баручы. Берсенән-берсе кечкенә биш бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган Әнвәр апа ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы – Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһнуй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Чаллы – Минзәлә юлыннан ерак түгел урнашкан матур табигатьле бу авыл балачак хатирәсе булып Гөлшат күңелендә гомерлек якты эз калдыра.

1 нче алып баручы

Нинди авыл ул, дисәгез,
Моңлы авыл Тәкермән.
Китсәң, сагынып кайтасың,
Мәңге чыкмый хәтердән.

Күп еллардан соң, инде танылган шагыйрә “Моңлы авыл Тәкермән” дигән җырында (Ринат Гобәйдуллин көе) авылын әнә шулай сагына.

2 нче алып баручы. Ятимә Гөлшатның бала чагы һәм яшүсмер чоры авыр елларга туры килә. Җитмәүчелек, фәкыйрьлек шартларында да сәләтле, зирәк акыллы кыз укуга, белем алуга омтыла, бик күп әдәби китаплар укый. Башлангыч мәктәптәге сыйныфташы Хәсән ага Гәрәев (Казанда яши): “Гөлшат гел “бишле”гә генә укыды, һәрчак беренче рәттәге партада утырыр иде”, дип искә ала. Башлангыч мәктәпне тәмамлагач, кыз күрше Хуҗамәт авылындагы җидееллык мәктәпкә биш чакрым җәяү йөреп укый.

1 укучы Гөлшат Зәйнашеваның балачак истәлекләрен сөйли.

Мин унөч-ундүрт яшемнән үзбашыма көн күрә башладым: туган тиешле апам тәрбиясендә үсеп буй җиткәч, өйдән чыгып киттем. Минзәләгә барып педагогика училищесына укырга кердем, тулай торакта яшәп укыдым.

1942-1943 нче еллар сугышның иң авыр еллары иде. Өс-баш ярлы, ашарга юк. Авылдан, өйдән бернинди ризык килми. Мин, аркага киндер капчыктан биштәр ясап, шуңа бераз бәрәңге салып өйдән чыгып киткән яшүсмер кыз бала, Минзәләдә кеше идәннәрен юып, кешегә бәрәңге утыртышып, бәрәңге казышып тамак туйдыра идем. Атнага бер тапкыр фотография идәнен юып чыгара идем. Фотограф абый шуның өчен бераз акча бирә иде. Шул акчага, базарга чыгып, берәр ризык алып ашый идем.

Безнең тулай торак янгын сүндерү бинасының, ягъни пожарныйның аскы катында иде, аны каланча дип йөртәләр иде. Янгын сүндерү бинасы булгангамы, аның миче юк иде, тулай торак ягылмый иде. Без, студентлар, кышкы салкын көннәрдә, дәрестән кайтып кергәч, чишенмичә генә дәрес хәзерли идек, тамакка нәрсә бар, шуны капкалап, ашап ала

идек. Өскә – бишмәт, аякка киез итек кигән килеш, башка мамык шәлләр урап ятып йоклый идек. Шулай киенгән булсак та, юрганнар ябынып ятсак та, барыбер туңа идек. Чөнки ягылмаган тулай торак ат абзары кебек салкын, котсыз иде. Кайвакытларда юрганнарыбыз белән тәрәзәләребезне каплый, томалый торган идек. Чөнки Минзәлә каласында кайчакларда “маскировка” була торган иде, ягъни фашист самолетлары шәһәрне күрмәсен өчен, төннәрен ут яндырмаска, яндырсаң тәрәзәләрне томаларга кирәк иде.

Уйладым-уйладым да тулай торакка мич чыгарырга булдым. Минзәләдә җимерек йортлар бар иде. Шул йортлар янында кирпеч ватыклары, калай кисәкләре аунап ята. Шул кирпеч ватыкларын, ташлар, калайлар җыеп алып кердем дә бер почмакка мич чыгарып куйдым. Ул мич, кыек-мыеграк булса да, хәйран җылыта иде. Калай кисеп, плитә дә әмәлләп куйдым. Шунда аш, бәрәңге пешерәбез.

Шулай бер-ике көн яшәгән идек, пожарниклар килеп керде. Аһ-ваһ килеп безнең мичкә карап торалар болар. “Кем чыгарды моны?” – диләр. Без дәшмибез. Иптәш кызларым мине сатмыйлар. Без үзара бик дус, тату яши идек.

1 нче алып баручы. Гөлшат апа Зәйнашева Минзәлә педагогика училищесын уңышлы тәмамлап, 1945 нче елда Казан педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Бик яхшы билгеләренә генә укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, кыскасы, менә дигән студентка була.

2 нче алып баручы. Институтны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

1 нче алып баручы. Г.Зәйнашева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында ул әдәби тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә, көндәлек матбугатта басылган язмалары, сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул — сәнгать кешеләренә, җырчы артистларга, сәхнә фидакарьләренә, бигрәк тә сәнгатькяр хатын-кызлардан З.Басыйрова, Ә.Галимова, Ә.Афзалова, Р.Ибраһимова, Ф.Ильская, Х.Әхтәмова, Ф.Сөләйманова һәм башкаларның сәхнә эшчәнлекләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймpraнованың, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың тормыш һәм иҗат юллары турында берничә монографик китап яза.

2 нче алып баручы. Гөлшат апаның акылы-фигыле искиткеч күркәм, бай рухлы, ул киң күңелле, кешеләрне яратучан, алар белән җылы мөгамәләдә, ярдәмчел була. Һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы булганлыктан, аның үзен дә яраталар, хөрмәт итәләр, киңәш-табышка киләләр. Тормышта ул күпләргә үрнәк, ә сәнгатькә әле генә аяк баскан яшьләргә ышанычлы терәк була. Бигрәк тә яшь шагыйрьләр, җырчылар аны үз итәләр, аңа тартылалар, ә ул аларга ихлас күңелдән ярдәм итә.

1 нче алып баручы. Гөлшат апа бик тыйнак, хәтта артык тыйнак кеше була. Үзенә, иҗатына багышланган шау-шулы тантаналарны яратмый. Ә концертларда, радио-телевидениедә, төрле кичәләрдә үз җырлары, шигырьләре яңгыраса, сәхнәдә спектакльләре уйналса, чын күңелдән шатлана белә.

2 нче алып баручы. Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше була.Тормыш аны төрлечә сыный, ә кайчакта – бик аяусыз. Әмма ул бөгелми, сынмый, бөтен авырлыкларны җиңеп, урман эченнән чабып баручы зифа боландай алга омтыла. “Үзем турында” дигән шигырендә ул үзенең бөтен гомерен күздән кичерә, яшәвенең юкка түгел икәнен әйтә.

1 укучы “Үзем турында “ шигырен сөйли.

1 нче алып баручы. Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның җырлары – милли рухи хәзинәбез ул. Туган җиргә мәхәббәт, Ватанга бирелгәнлек, халкыбыз язмышы турында кайгырту, намуслы хезмәткә өндәү, кешелек дөньясы кабул иткән югары әхлакка чакыру – аның җырларының төп сыйфатлары.

“Туган җирем – Татарстан” (А. Ключарев көе) җыры яңгырый.

2 нче алып баручы. Гөлшат Зәйнашева иҗатында мәхәббәт һәм гаилә җырлары да киң урын алып тора. Мәхәббәт темасына шагыйрә гомере буена тугрылыклы булып калды. Аны, хаклы рәвештә, “мәхәббәт җырчысы” дип тә йөртәләр.

1 нче алып баручы. 1988 нче елда җыр өлкәсендәге казанышлары өчен шагыйрә “Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе” дигән мактаулы исемгә һәм 1991 нче елда иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» (1988) исемле китабы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә лаек була.

2 нче алып баручы. Гөлшат Зәйнашеваның җырлары халыкчан, шуңа күрә дә халык аларны яратып тыңлый һәм җырлый. Халык шагыйре М. Әгъләмов сүзләре белән әйткәндә: “Гөлшат Зәйнашеваның җырларын халык җырлады һәм җырлаячак”.

## Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты

(5 нче сыйныфта үткәрелгән сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)

Загидуллина Рүзилә Фирдәвес кызы,

А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш

төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы

Тема: Г.Зәйнашеваның иҗаты

Дәреснен максаты: Г.Зәйнашеваның төрле елларда чыккан шигырь җыентыклары белән танышу

Бурычлары: Г.Зәйнашева иҗаты турында әнгәмә үткәрү; укучыларнын сөйләм телен үстерү һәм баету; укучыларда татар җырларына, сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның төрле елларда чыккан шигырь җыентыклары, слайдлар.

Укыту методлары: сөйләү

Дәрес планы.

1. Исәнләшү.
-Исәнмесез, укучылар! Хәерле иртә!
-Хәерле иртә!
-Яхшы, барыгыз да исән-сау сәламәт булуыгызга мин бик шат. Укучылар, дәресебез башында сезнең белән бер видиоролик карап үтик әле. ( видиоролик карала)
-Әйтегез әле, ролик нәрсә турында?

- Шагыйрә Г.Зәйнашева турында.

- Кем соң әле бу шагыйрә? Әйдәгез әле анын турында сөйләшик.

Г.Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туа. Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр. 2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тегермән авылында уза. Ләкин апасының ире бу баланы яратмый, аны хәтта кайчакларда кыйный да.

Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була. Минзәләдән артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр. 4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар. Спектакь караганнан соң артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, ул артист булып уйнарга ярата.

Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң башта педагогия училищесын тәмамлый, аннары 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бер үк вакытта театр училищесына йөреп, дәресләр ала. Әмма аңа я институтны, я театр училищесын сайларга кушалар. Ул институтны сайлый, ләкин концерт бригадалары белән бергә авылларга чыгып йөри, концертлар алып бара. Институтны тәмамлый. Г.Зәйнашева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре, җырлары матбугат битләрендә күренә башлый. 1958 нче елда "Тыңларсыңмы җырларымны" исеме белән беренче китабы басылып чыга.

Педагогия институтында укый башлагач та, җиңел булмый аңа. Иң башта фронтта бер кешең дә юк дип, тулай торактан урын бирмиләр. Гөлшат бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри, бер елдан соң гына урын бирәләр аңа. Бик яхшы укыганы, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә.

Г.Зәйнашева моңлы, матур тавышка ия була. Һәркем белә:җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле,чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне беркемнән яшермичә җыры аша әйтеп бирә.

2. Актуальләштерү.

- Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аны, шаяртып, "татарның җыр сандыгы" дип тә атыйлар. Туган җиренең бөтен табигатен, гүзәллеген, үз җаны аша үткәреп, халкына бүләк иткән шагыйрә ул. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган, алар халык арасында киң таралган: (экраннан укып танышалар):

«Туган жирем – Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Б.Гайсин музыкасы), «Кояш гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Аерылмагыз» (Ч.Зиннәтуллина музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы).

Әйе, укучылар, чыннан да, шагыйрә Г.Зәйнашева бәхетен туган ягында, туган җирендә тапты. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә яңгырый. Аның җырлары-мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк. Мин ышанып калам: киләчәктә сез дә талантлы шагыйрә Г.Зәйнашева иҗаты белән кызыксынырсыз,аның җырларын өйрәнерсез..

3. Рефлексия

1. Без бүген дәрестә нинди темега сүз алып бардык?
2. Шагыйрәнең иҗаты сезгә ошадымы?

4.Йомгаклау

Үзегезгә ошаган берәр шигырьне ятлап килегез. Бергәләп тыңларбыз.

Дәресебез тәмам. Мин сезнең барыгызга исәнлек-саулык телим. Сау булыгыз.

## Сөббух Рәфыйков иҗатына багышланган конференция

(Сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)


Нуртдинова Гөлнар Сәлихҗан кызы,

Салихова Айгөл Роберт кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы


Максат: Сөббух Рәфыйков иҗаты белән якыннан танышу; аның әсәрләренә карата кызыксыну уяту; укучыларда китап укуга мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау. Соббух Рәфыйков портреты; Сөббух Рәфыйковның төрле елларда басылып чыккан китаплары күргәзмәсе, әсәре буенча ясалган презентация

Конференция барышы:

Укытучы сүзе. Язучы, шагыйрь Сөббух Һади улы Рәфыйков исеме әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Шигъри җыентыгы («Үсү җырлары») һәм «Соңгы талпыну» (1932), «Үсмерчак» (1937) дигән хикәя китаплары, күпсанлы шигырьләр, романнар авторы буларак билгеле ул безгә. Бүгенге китап укучылар конференциясен аның иҗаты белән танышуга багышлыйбыз.

1. Сөббух Һади улы Рәфыйковның тормышы турында. (1 нче укучы сөйли)

Язучы, шагыйрь Сөббух Һади улы Рәфыйков 1913 елның 15 июлендә Татарстанның Сарман районы Нөркәй авылында игенче гаиләсендә туа. 1925–1930 елларда-Татарстанның Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендә гомуми белем бирү мәктәбендә, аннары Казанда югары уку йортына әзерлек сыйныфларында укый. 1931 елдан ул район һәм республика газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы мөхәррир урынбасары, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара. 1934–1937 елларда, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтында укый. Шул чорда аның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләреннән шигъри җыентыгы («Үсү җырлары») һәм «Соңгы талпыну» (1932), «Үсмерчак» (1937) дигән хикәя китаплары басылып чыга.

2. Сөббух Һади улы Рәфыйков-«халык дошманы» (2 нче укучы сөйли)

1937 елның 17 октябрендә әле егерме дүрте тулып кына өлгергән яшь язучы һәм китап нәшрияты мөхәррире кинәт НКВД чекистлары тарафыннан кулга алына. Сәбәбе: ул бер төркем яшь язучылар белән бергә татар әдәбиятының классигы Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулу уңаеннан аны котлап язылган күмәк хатка имза куйган икән. Ә бу вакытта Г.Ибраһимов инде кулга алынып, әле хөкем карары булмаса да, җәмәгатьчелеккә инде «халык дошманы» дип игълан ителгән була. Менә шул «зур җинаять»не сәбәп итеп, совет хәрби мәхкәмәсе С.Рәфыйковны ун елга иреген мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән карар чыгара. Яшь әдип башта мәшһүр Соловки концлагерена, аннан Төньяк Себердәге металлургия комбинаты төзелешенә җибәрелә. 1947 елда хөкем мөддәтен тутыргач та аңа туган якларына кайтырга рөхсәт итмиләр. 1951 елның 9 июнендә шул ук элекке «җинаятьләре» өчен яңадан хөкем ясалып, әдип этап белән Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла. Туган якларына ул фәкать егерме ел үткәч – 1957 елда гына кайту бәхетенә ирешә. Шул ук елда әдипнең сөргендә чагында иҗат иткән шигырьләреннән сайлап тупланган «Ак төннәр» исемле җыентыгы дөнья күрә.

3.Сөргенлектән соң иҗади эшчәнлеге (3 нче укучы сөйли)

Сөргеннән кайткач, С.Рәфыйков, Татарстанның Зәй шәһәрендә төпләнеп, берникадәр вакыт (1958–1961) «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының Зәй төбәгендәге үз хәбәрчесе, аннары штаттан тыш хәбәрчесе булып эшли. Язучы буларак С.Рәфыйковның бу еллардагы әдәби иҗаты, нигездә, проза жанрына карый. Киң җәмәгатьчелеккә ул илленче-алтмышынчы елларда иҗат иткән өч романы белән таныла. «Беренче яз» исемле тәүге романында (1958) әдип егерменче-утызынчы елларда татар авылы кичергән социаль үзгәрешләрне, аерым хуҗалыктан күмәк хуҗалыкка күчү процессындагы каршылыкларны шул заманга хас реаль күренешләр һәм кеше образлары аша сурәтләргә омтыла. «Авыл иртәсе» романында исә (1966) алтмышынчы елларда совет хакимияте тарафыннан көчләп тагылган күмәк хуҗалыкларны эреләндерү тәҗрибәсе үзәккә алынып, бу тәҗрибәнең авыл халкы тормышына алып килгән катлаулы нәтиҗәләре, шул шартларда хуҗалык белән җитәкчелек итү, хезмәтне оештыру кебек производство мәсьәләләре яктыртыла. Гомеренең соңгы елларында әдип Татарстанның көнчыгыш төбәгендә Зәй гидростанциясе төзүче эшчеләр тормышыннан «Тын елга буенда» исемле өченче романын эшли. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында (1971, № 2–6) дөнья күреп, соңыннан, авторның вафатыннан соң (1972), Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга. Егерме ел тоташ тоткынлык җәфаларыннан сәламәтлеге какшаган язучы 1971 елның 21 ноябрендә Яңа Зәй шәһәрчегендә вафат була. С.Рәфыйков – 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

4. «Беренче яз» романы турында.(4 нче укучы сөйли)

Сөббух Рәфыйков язучы буларак киң җәмәгатчелеккә “Беренче яз” (1958) романы белән таныла. 1920-1930 еллардагы татар авылында социаль күренешләрне шул заманга хас реаль күренешләр һәм образлар аша чагылдырган бу роман 60 нчы еллар татар прозасының авыл темасына багышланган күренекле әсәрләреннән берсе итеп бәяләнә.

«Беренче яз» исемле тәүге романын әдип егерменче-утызынчы елларда татар авылы кичергән социаль үзгәрешләрне, аерым хуҗалыктан күмәк хуҗалыкка күчү процессындагы каршылыкларны шул заманга хас реаль күренешләр һәм кеше образлары аша сурәтләргә омтыла.

«Авыл иртәсе» романында исә (1966) алтмышынчы елларда совет хакимияте тарафыннан көчләп тагылган күмәк хуҗалыкларны эреләндерү тәҗрибәсе үзәккә алынып, бу тәҗрибәнең авыл халкы тормышына алып килгән катлаулы нәтиҗәләре, шул шартларда хуҗалык белән җитәкчелек итү, хезмәтне оештыру кебек производство мәсьәләләре яктыртыла. Гомеренең соңгы елларында әдип Татарстанның көнчыгыш төбәгендә Зәй гидростанциясе төзүче эшчеләр тормышыннан «Тын елга буенда» исемле өченче романын эшли. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында  дөнья күреп, соңыннан, авторның вафатыннан соң , Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.

5.Сөббух Рәфыйков – журналист. (5 нче укучы сөйли)

1931 елдан ул район һәм республика газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы мөхәррир урынбасары, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара.

6. Сөббух Рәфыйков – шагыйрь (6 нчы укучы сөйли)

Юкка гына әйтмәгәннәр: малын җыйган җиде ел елар, иленнән аерылган – гомер буе. Дөнья киң. Адәм баласы бер урында гына тормый. Ул кайтарафка гына барып чыкмый. Әмма ул һәрчак кендек каны тамган җирен – изге туган ягын сагынып кайта. Чөнки аның бәхете – туган илендә, туган җирендә”, - дип яза язалар. Әйдәгез, аның туган ягын яратуы турындагы берничә шигырен тыңлап үтик. («Ак төннәр» шигырьләре китабыннан)

7. Сөббух Рәфыйков исеме  мәңгеләштерелгән. (7 нче укучы сөйли)

1991 елдан башлап мәдәният, әдәбият, сәнгать, тарих үсешенә зур өлеш керткән язучыларга Сөббух Рәфыйков исемендәге премия тапшыру традициясе яши. Бүген бу мактаулы исемлектә рәссамнар, журналистлар, язучылар, артистлар, спортчылар, фәнни хезмәткәрләр, аграр сектор, предприятие җитәкчеләре, иҗат коллективлары һәм хәтта академик бар. Премия ике елга бер тапкыр бирелә. Зәйдә  Сөббух Рәфыйков исеме белән урам һәм Үзәк китапханә исемендә мәңгеләштерелә. Сөббух Рәфыйков 1957 елдан бирле яшәгән йортта мемориаль такта урнаштырылган.

8. Сөббух Рәфыйков китаплары күргәзмәсе. Китапханәче чыгышы.

- «Соңгы талпыну»: хикәя. ( 1932 ел)

-«Үсмерчак: хикәяләр»(1937ел )

-« Ак төннәр» шигырьләр.(1957 ел )

- «Беренче яз» роман(1962 ел)

- «Авыл иртәсе» роман ( 1966 ел)

- « Беренче яз» роман ( 1970ел)

- «Тын елга буенда»  роман  (1972ел)

- « Беренче яз» роман  (1979ел)

Укытучының йомгаклау сүзе.

Сөббух Рәфыйков әсәрләрен иренми тәфсилләп, сабыр-салмак итеп, бер үк вакытта сак, сизгер булып, укучы күңеленә барып җитәрлек итеп язган. Аның әсәрләрендә әхлакый-эстетик, кешелеклелек сыйфатлары да шактый ук үзенчәлекле итеп куела.

Бүгенге китап укучылар конференциясе сездә Сөббух Рәфыйков әсәрләренә кызыксыну уяткандыр дип ышанып калам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт! Киләсе очрашуларга кадәр.

## Голшат Зэйнашева – татарнын жыр сандыгы

Гыймранова Эльвина Фәнис кызы,

6 нчы  санлы балалар  бакчасы  тәрбиячесе,  Әлмәт районы

Г.Зәйнашева – җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аны, шаяртып, "татарның җыр сандыгы" дип тә атыйлар. Туган җиренең бөтен табигатен, гүзәллеген, үз җаны аша үткәреп, халкына бүләк иткән шагыйрә ул. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган, алар халык арасында киң таралган:  «Туган җирем – Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Б.Гайсин музыкасы), «Кояш гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Аерылмагыз» (Ч.Зиннәтуллина музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы)

Г.Зәйнашева сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул – сәнгать кешеләренә, артистларга багышланган мәкаләләр, мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймановага, җырчы һәм композитор Сара Садыйковага багышланган китаплар яза. Замандашлары күңелендә Гөлшат Зәйнашева – татар халкының иң күркәм сыйфатларын үзендә туплаган олы җанлы, эчкерсез күңелле зыялы кеше булып саклана.

Г.Зәйнашева – 1969 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Г.Зәйнашеваның сәхнә әсәрләре дә бар. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка», "Язмышлар һәм ялгышлар" драма һәм комедияләре үз заманында Минзәлә театры һәм башка татар театры сәхнәләрендә уйналып йөри. «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным жәл түгел сиңа» дигән комедияләре әле дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

Г. Зәйнәшева әле бик бәхетле әни дә була, кызы Асияның балалары – Дамир белән Камилгә әле ул дәү әни дә була. Алар аны, яратып, "Гөләни" дип йөртәләр. Г.Зәйнашеваның шигырьләр китабы да "Әбиемне яратам" дип атала, һәм ул, билгеле, аның оныкларына багышланган.

Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, хатын-кызлардан беренче булып, 1991 елда «Илле җыр» исемле китабы өчен Г.Зәйнашевага бирелә.

**Күңелләрдә яши моңнары**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗаты багышланган әдәби кичә)

Галләмова Гөлназ Мөбәрәк кызы,

Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Актаныш районы

Максат: күренекле шагыйрә Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнәшевның тормышы һәм иҗат юлы белән таныштыру; күренекле шәхесләребез турында укучыларның белемнәрен тирәнәйтү; татар шигъриятенә, татар музыкасына мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлар: Г.Зәйнәшева портреты, шагыйрәнең китаплары, презентация.

Плакат. Җырладым илемне мактап,

Җырга бирдем бар көчем.

Илемнең күге, халкымның

Күңеле яктыртсын өчен.

Кичә барышы:

Җыр яңгырый “Тибрәнә җыр күңелдә” (З.Сәгыйтов көе)

1 нче укучы. Татар әдәбиятында халык күңелендә, халык хәтерендә тирән эз калдырган шагыйрьләр, әдипләр бар. Бүгенге кичәбез шундый шәхесләрнең берсе- күренекле татар шагыйрәсе, драматург, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнәшева иҗаты багышлана.

2 нче укучы. Гөлшат Зәйнәшеваның бала чагы авырлыкта уза, бик иртә ата-ана назыннан мәхрүм кала. Халык дошманы баласы дип кагыла, уку йортыннан куыла. Ләкин ул үҗәт була, тырышып укый, тормыш авырлыкларына каршы барырга үзендә көч таба.

Ватанымның гади бер кызы мин,

Туып үстем Идел буенда;

Чәчәк җыйдым хәтфә болыннарда,

Җыр өйрәндем сабан туенда.

3 нче укучы. Сөйлә дисәгез, сөйлимен

Үткән гомерем турында.

Үткән гомерем бер җыр, бәет-

Барсы чагыла җырымда.

Булды кагылып-сугылып,

Ятимлекләр күргән чагым.

Күгәрчен баласы кебек,

Йортсыз-җирсез йөргән чагым,-дип яза шагыйрә “Үзем турында” дигән шигырендә.

4 нче укучы. Гөлшат апа Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Тукай районы Иске Теләнче исемле авылда урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. 1930 елның язында әтисен халык дошманы дип кулга алалар. Гөлшат апаны Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбияләп үстерә. Балачагы шул авылда уза. Югары Тәкермәндә башлангыч, Хуҗамәттә җидееллык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогия училищесында белем ала.

5 нче укучы. Юллар ерак алып китсә,

Йөрим бик күп калада.

Минзәләгә кайткач кына,

Кайгыларым тарала. (“Минзәлә юллары”)

6 нчы укучы. 1945нче елда Г.Зәйнәшева Казанга килә, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Казан урамнары буйлап йөрим,

Әллә кемне эзли күзләрем.

Урам ташларына яфрак-яфрак

Уелып калган яшьлек эзләрем.

Күңелемдә яшьлек хатирәсе,

Чын мәхәббәт,татлы моң, сагыш.

Урамнарда күргән һәрбер кеше

Җанга якын, никтер бик таныш.(“Казан – минем язмышым”)

7 нче укучы. Укыганда Гөлшат бик елгыр, җитез кыз була, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар стена газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга.

8 нче укучы. Булды эш, хезмәттә җиңеп,

Данга ирешкән чакларым.

Якын дуслар белән шатлык,

Бәхет бүлешкән чакларым. (“Үзем турында”)

1 нче укучы. Г.Зәйнашева хезмәт юлын 1949нчы елда Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире буларак башлый. Аннары унбер елга якын Татарстан китап

нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта -музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

2 нче укучы. Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның бик күп шигырьләре көйгә салынган. Әлеге җырлар үзе исән чагында ук кечкенә генә авыл сәхнәсендә дә, олы-олы калаларның мәдәният йортларында да яңгырый-яңгырый өйләргә күчкән, күпләрнең йөрәк түрендә урын алган. Гөлшат апа сүзләрне энҗе кебек тезеп куючы булган.

3 нче укучы. Шагыйрәнең мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Г.Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып килә.

Җыр. “Сәяхәтче җыры” (З.Гыйбадуллин көе)

4 нче укучы. Туган як, туган җир, туган авыл... Болар һәрбер кеше өчен иң кадерле әйберләр. Туган ягына мәхәббәт аның шигъриятендә һәм җырларында чагылыш таба. "Моңлы авыл Тәкермән", "Минзәлә юллары", "Ык буйлары", "Туган җиремә", "Туган авылым Салих-Тукай", "Үз илемдә" һәм башка күп шигырьләрендә һәм җырларында туган якның сагышы, матурлыгы, кешеләрнең хезмәт сөючәнлеге һәм табигатькә мөнәсәбәте гаять зур осталык һәм эчке җылылык белән сурәтләнә.

5 нче укучы. Туган ягым – гөлләр иле,

Гөлләр, сөмбелләр иле.

Гөлгә кунып сайрап кына

Үскән былбыллар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,

Болыннарны буйладым.

Туган якның гүзәллеген

Мәңге күреп туймамын. (“Гөлләр иле”)

6 нчы укучы. И авылым, уйлый күрмә мине

Оныткан дип авылы турында.

Ничек онытыйм- алтыннардан өстен

Син үстергән икмәк кулымда. (“Татар авылы”)

Җыр . “Үз илемдә” (С.Садыйкова көе)

7 нче укучы. Җырларым бар, моңнарым бар

Йөрәк түремдә.

Җыр белән чын дуслар таптым,

Туган җиремдә”, - дип язган иде ул “Хушлашмый китәм” шигырендә.

8 нче укучы. Шагыйрә буларак, Гөлшат апа бик бәхетле иҗатчы булды. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган.

Аларның күбесе, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессионал җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнә.

1нче укучы. Язмыш аны композиторлар: А.Ключарев, Р. Яхин, М.Мозаффаров, С.Садыйкова, Б.Гайсин, Ф.Әхмәдиев, З.Гыйбадуллиннар белән очраштырды. Халкыбыз күңеленә үтеп керерлек, татар җыр сәнгатенең классикасына әверелгән “Туган җирем – Татарстан”, “Китмә, сандугач”, “Менәргә иде Урал тауларына”, “Күл буена килсәң иде”, “Кояш гомере”, “Аерылмагыз”, “Туган авылым урамы” кебек җырлар иҗат ителде.

Җыр “Туган авылым урамы” (Г.Сйфуллин көе)

2нче укучы. Гөлшат апа үзенең күпкырлы, бай иҗаты белән татар теле, татар мәдәнияте һәм сәнгате сагында нык торды, аяусыз көрәште. Милләтебез һәм тарих алдында Гөлшат Зәйнашеваның йөзе ак, вөҗданы пакь булды, һәм ул шулай булып кала да.

3нче укучы. Рухыбызда туган тел син,

Җаныбызда туган тел .

Ясалма килмешәк түгел.

Каныбызда туган тел.

Рухыбызда туган тел син,

Әткәм-әнкәмнең теле.

Борынгы бабабыз теле,

Болгар бабабыз теле. (“Туган телем”)

4 нче укучы. Г.Зәйнашева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Аның драма һәм комедияләре Минзәлә, К.Тинчурин театрлары сәхнәләрендә уңыш белән барды. Шушы киң колачлы иҗатында ул балаларны, сабыйларны да онытмый, алар өчен шаян, гыйбрәтле шигырьләр, җырлар яза.

Җыр ”Кояш гомере” ( Ф.Әхмәдиев көе)

5 нче укучы. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» исемле китабы өчен 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

6 нчы укучы. Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итте. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, сынмады. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы- табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды.

7 нче укучы.Кайда барма чын дусларны табам,

Дуслар белән озын юл кыска,

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.( “Мин тормышка гашыйк”)

8 нче укучы. Гөлшат апа Зәйнашева 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була. Үзе үлсә дә, аның җырлары халкыбыз күңелендә мәңге яшәр.

Җырладым илемне мактап,

Җырга бирдем бар көчем.

Илемнең күге, халкымның

Күңеле яктыртсын өчен.
Үзем китсәм, калыр  моңым,
Җырым кинәт бүленеп,
Туган як каеннарының
Яфрагына эленеп.(“Нәрсә калдырам?”)

Җыр “Китмә, сандугач” (Р.Яхин көе)

**И гүзәл туган ягым...**

(Гөлшат Зәйнашева иҗатына күзәтү. 3 нче сыйныфта туган тел дәресе план-конспекты)

Абдуллина Кадрия Галимҗан кызы,
Күтәмәле төп гомуми белем бирү мәктәбе
башлангыч сыйныфлар укытучысы, Сарман районы

| |
|---|
| Туган тел, 3 нче сыйныф |
| И гүзәл туган ягым... |
| 1)  Г.Зәйнашева иҗатына тулырак мәгълүмат бирү;<br>2)Укучыларның иҗади фикер йөртү сәләтләрен, мөстәкыйльлекне, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү.<br>3)Бер-береңә һәм башкаларга карата ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләү, сөйләм культурасын өйрәнү, туган телгә карата уңай караш булдыру, укучыларда татар җырларына,сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү. |
| Шәхескә кагылышлы: итагатьле әңгәмәдәш булу, аралаша белү сәләтен үстерү, әдәп кагыйдәләренең кирәклеген аңлау.<br>Метапредмет:<br>Танып-белү УУГ: логик фикерләү күнекмәләрен үстерү, дәрестә алган мәгълүматлардан файдаланып, сорауларга җавап бирү.<br>Коммуникатив УУГ: әңгәмәдәшеңне тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне җиткерә белү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү, парларда эшли белү, коммуникатив максатка нигезләнеп, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.<br>Регулятив УУГ: дәреснең темасын һәм максатын формалаштыру, укытучы һәм сыйныфташлар белән уртак эшчәнлек булдыру, үзбәя бирә белү.<br>Предмет буенча: “И гүзәл туган ягым...”темасы буенча лексик-грамматик материалны сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү, тема буенча диалог төзи алуны камилләштерү, телдән аралашу күнекмәләре булдыру, Гөлшат Зәйнашеваның иҗатын  тирәнтен өйрәнү. |
| Белем һәм осталыкны системалаштыру |
| Әдәпле, тәрбияле, исәнмесез, рәхмәт, сау булыгыз., туган ягым, шагыйрә, шигырь, композитор |
| Татар теле,  әйләнә-тирә дөнья |
| Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль |
| Дәреслек: дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен төзелгән һәм Татарстан Республикасы Мәгариф  һәм фән министрлыгы  рөхсәте белән басылган «Уку китабы» Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек. II – кисәктә. |
| Проектор, ноутбук, презентация, Г.Зәйнәшева китапларыннан күргәзмә |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| 1.Оештыру. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру. | Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыру. Дәрескә әзерлекләрен тикшерү.<br>Укучылар белән әңгәмә үткәрү.<br>-Исәнмесез,укучылар!<br>-Хәерле көн сезгә!<br>-Кәефләрегез ничек?<br>Фонетик зарядка ясату.<br>- Әйе, урамда яз.<br>-Я, балалар, карагыз,<br>Тышта килде матур яз!<br>-Я, әйтегез, сөйләгез, ничек килә икән яз?<br><br>Дежур укучы белән сөйләшү.<br>-Бүген ничәсе?<br>-Атнаның кайсы көне?<br>-Һава торышы нинди?<br>-Хәзер елның кайсы фасылы? | Сыйныф эшкә әзерләнә<br>Укытучыны сәламлиләр, дежур укучы укытучы сорауларына җавап бирә, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар.<br><br><br>-Исәнмесез!<br>-Хәерле көн!<br>Яз турындагы шигырьне бергәләп сөйлиләр:<br>-Әйе,әйе беләбез,яз килгәнен күрәбез.<br>- Тамчы тама тып та тып!<br>Булмый аны туктатып.<br>Зәңгәр күктә кояш балкый<br>Ул бит безгә ишек шакый |
| 2. Уку мәсьәләсен кую | Дәресебезне "Туган җирем - Татарстан" җыры белән башлыйк әле. ( А .Ключарев музыкасы, Г.Зәйнашева сүзләре).<br>Җырны тыңлаганнан соң укучылар белән әңгәмә үткәрелә.<br>1. Бу җыр нәрсә турында?<br>2.Нәрсә соң ул Туган җир?<br>3.Сез туган җиребезне яратасызмы соң?<br>Укытучы сүзе: Әйе,укучылар без барыбызда туган җиребезне яратабыз. Ә шагыйрә Гөлшат апагыз бу турыда ничек әйткән соң?<br>4.Сезгә бигрәк тә кайсы юллар ошады?<br>Презентация белән эшләү. Уку мәсьәләсен билгеләү.<br>(Слайд №1)<br>Сезгә өй эше итеп, әле генә без тыңлап киткән җырның авторы- шагыйрә Г.Зәйнашева турында мәгълүматлар тупларга, үзегезгә ошаган шигырьләрне ятлап килергә кушылган иде. | Укучылар "Туган җирем – Татарстан" җырын башкаралар<br><br><br><br><br>- Туган җиребез Татарстан турында.<br>- Ул – безнең туган җиребез, ул – безнең торган җиребез һ.б.<br>Туган җиребезне ярату турындагы юллар укыла.<br><br>Сорауларга җавап бирәләр. Дәреснең темасын, уку мәсьәләсен, билгелиләр.<br><br>Берничә укучы шигырь сөйли.<br>1-2 укучы Г.Зәйнашеваның биографиясе белән таныштырып китә.<br>1нче укучы җавабы: Г.Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнваренда Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр. 2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тегермән авылында уза. Ләкин апасының ире бу баланы яратмый, аны хәтта кайчакларда кыйный да. Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була. Минзәләдән |

| | | |
|---|---|---|
| | Укытучы сүзе: Педагогия институтында укый башлагач та, җиңел булмый аңа. Иң башта фронтта бер кешең дә юк дип, тулай тораклан урын бирмиләр. Гөлшат бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри, бер елдан соң гына урын бирәләр аңа. Бик яхшы укыганы , җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә. Тагын шуны өстәп әйтәсем килә: Г.Зәйнашева моңлы,матур тавышка ия була. Һәркем белә: җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле, чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне беркемнән яшермичә җыры аша әйтеп бирә. | артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр. 4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар. Спектакь караганнан соң артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, ул артист булып уйнарга ярата. Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.<br>2 нче укучы җавабы: Мәктәпне тәмамлаганнан соң башта педагогия училещесын тәмамлый, аннары 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бер үк вакытта театр училещысына йөреп, дәресләр ала. Әмма аңа я институтны, я театр училещысын сайларга кушалар. Ул институтны сайлый, ләкин концерт бригадалары белән бергә авылларга чыгып йөри, концертлар алып бара. Институтны тәмамлагач, Г. Зәйнашева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре, җырлары матбугат битләрендә күренә башлый.<br>1958 нче елда "Тыңларсыңмы җырларымны" исеме белән беренче китабы басылып чыга. |
| 3. Белемнәрне актуальләштерү. | 1. Укучылар, без Г.Зәйнашева иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез. Ә хәзер шигырьләр тыңлап китик әле.<br>"Шаулый урман "шигыре тыңланыла.<br>Укучылар, шигырьне игътибар белән тыңлагыз, шагыйрә нәрсә әйтергә тели, нинди проблема күтәрә?<br>"Футбол" шигыренә анализ бирелә.<br>- Шагыйрә нәрсә әйтергә тели? Сезгә туп тибеп йөрергә генә кушамы, яки тырышып укырга да кушамы? | Табигатьне саклау проблемасын күтәрә.<br><br>Укучыларның җавапларын тыңлаганнан соң нәтиҗә ясала. |

| | | |
|---|---|---|
| 4. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру. Тиешле дәрәҗәдә яңадан үзләштерү | (Слайд №3)<br>Г.Зәйнашеваның "Әби һәм онык " скетчы тыңланыла һәм укучылар белән әңгәмә үткәрелә. (Бу скетч сәхнәләштерелә).<br>а) Сездә онык нинди тәэсир калдырды? Сез аңа охшарга теләр идегезме?<br>Укытучы сүзе: Әйе, укучылар, без сезнең белән Татарстан Республикасында яшибез. Безнең республикада татар һәм рус телләре-дәүләт телләре ител санала. Без сезнең белән үзебезнең туган телебез- татар телен дә һәм рус телен дә бик әйбәт белергә тиешбез.<br>Ә.Ерикәй дә әйткән бит: "Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел, икесе дә безнең өчен иң кирәкле яхшы тел"<br>20 гасыр башында иҗат иткән күренекле шагыйрь Дәрдемәнднең сүзләре дә шуңа туры килә.<br>"Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,<br>Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.<br>Катыштырма вәләкин телгә телне<br>Тел уйнатмак, наданлыктан әсәрдер".(әсәрдер-билгеседер).<br>- Сезгә бу малайның тагын кайсы ягы ошамады?<br>-Онык дөрес эшлиме? | Укучыларның җавапларыннан соң укытучы нәтиҗә ясый.<br>Үзбәя.<br><br>Әбисе кесәсеннән акча урлавы.<br>Юк, ул әбисен хөрмәт итми, яратмый. |
| Физкультминутка | Физкультминутка үткәрүче укучының эшен оештыра. | Бер укучы такта алдына чыга һәм тиешле хәрәкәтләр белән физкультминутка үткәрә.<br>-Тәрәзә каршына кунган сыерчык.<br>Мине чакыра: чык әле, чык!<br>-Алдый ул, беләм, гел шулай итә.<br>Йөгереп чыксам, оча да китә. |
| 6. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану. | Укытучы сүзе: Әйе, укучылар, без олыларны хөрмәт итәргә тиеш. Укучылар, без сезнең белән шагыйрә Г.Зәйнашеваның ике шигыренә күз салдык, аның сүзләренә язылган җырны тыңладык. Ә шигырьләргә музыканы кем яза соң? (композиторлар). Әйтегез әле, | Укучыларның җаваплары тыңланыла.<br><br>Үзбәя. |

| | | |
|---|---|---|
| | сез нинди композиторларны беләсез? -Гөлшат Зәйнашева сүзләренә җырлар язган композиторларыбыз бик күп. Минем бу урында Г.Зәйнашеваның композитор С.Садыйкова белән дуслыгы турында әйтеп үтәсем килә. Алар иҗатташ дуслар гына түгел, җан дуслар булалар. Сара апа каты авырып киткәч, аның янында Гөлшат булды. Соңыннан С.Садыйкова вафат булгач, ул кадерле дусты, иҗатташының якты образын мәңгеләштереп китап язды. Бу китап-авторның проза өлкәсендә дә уңыш белән эшли алу мөмкинлеген сөйли. (Г.Зәйнашеваның "Сара Садыйкова" китабы күрсәтелә). | Диалог төзиләр. (парларда эшлиләр). Бер-берсен бәялиләр.<br><br>Китаплар күргәзмәсе белән эш. |
| 7.Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, җибәрелгән хаталар буенча фикерләшү һәм аларны төзәтү. | (Слайд №4, 5)<br>Һәрбер партага Г.Зәйнашеваның "Йөзе кара" шигыре таратыла. 1-2 укучы укыганнан соң укучыларга түбәндәге сорауларны бирергә мөмкин.<br>-Йөзе кара дип нинди кешеләргә әйтәләр?<br>-Әбисе аны нинди булырга өйрәтә?<br>5."Гөлләр иле" исемле шигырьләр җыентыгыннан табышмаклар тәкъдим итәргә була.<br>Укучылар, бу дәрестә без шагыйрә Г.Зәйнашева иҗатына кыскача күзәтү ясадык. Билгеле, бер дәрестә без аның иҗатын-ул язган шигырьләрне, җырларны һ.башкаларны карап бетерә алмыйбыз.<br>Г.Зәйнашева-әдәбиятның төрле жанрларына караган китап авторы. Аның драма әсәрләре ("Гайфи бабай,өйлән давай" комедиясе К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында сәхнәсеннән төшмичә уйналып килә). Аның балалар өчен, зурлар өчен язган шигырьләре бик күп. Г.Зәйнашева бигрәк тә | Фикерләр алышу.<br><br>Кара йөзле дип кешеләргә юл бирмәгән, кеше өлешен тартып алган, кешеләргә яхшылык эшләмәгән,үзендә булмаган акылны кешеләргә өйрәткән кешеләргә әйтәләр.<br>Табышмакларга җаваплар табалар. |

| | | |
|---|---|---|
| | җыр жанрында актив иҗат иткән шагыйрә. Бер генә концерт та Г. Зәйнашева җырларыннан башка узмый. Шунысы билгеле: һәрбер язылган шигырь җыр булып китә алмый, һәм шулай ук һәрбер шагыйрь дә җыр текстлары яза алмый. Ә Г.Зәйнашеваның һәр шигыре диярлек көйгә салынган. Җыр барлыкка китерү өчен аерым талант кирәк һәм шагыйрә шул талантка ия була (аерым талант ул-үзенчәлекле фикерләү сәләте,гадилек, тумыштан күңелгә салынган музыкальлек булу).Тактага язылган юлларга игътибар итик әле (бер бала эпиграфны укып китә).<br>Әйе, укучылар, чыннан да, шагыйрә Г.Зәйнашева бәхетен туган ягында,туган җирендә тапты. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә яңгырый. Аның җырлары-мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк. Мин ышанып калам: киләчәктә сез дә талантлы шагыйрә Г.Зәйнашева иҗаты белән кызыксынырсыз дип. | "И гүзәл туган ягым,<br>И ямьле туган ягым,<br>Бәхетемне читтә түгел<br>Мин синдә таптым!" |
| 8.Өйгә эш бирү. | Өй эше бирә, аны башкару ысулын аңлата.<br>Гөлшат Зәйнашеваның бер шигырен ятларга. | Өй эшен көндәлекләренә язалар. |
| 9.Рефлексия | Дәрестә туган авырлыклар турында сорый, нәтиҗә ясый.<br>-Укучылар, без бүген нәрсә турында сөйләштек?<br>-Нәрсәне яхшы эшләдек?<br>-Нәрсә кыен булды?<br>-Нинди нәтиҗәгә килдек?<br>Дәрестәге эшчәнлегегезне бәяләгез.<br>Бер-берегезнең эшчәнлеген бәяләгез.<br>Укучыларның дәрестәге эшен бәяли. | Укучылар үз фикерләрен әйтәләр.<br>Нәтиҗә ясыйлар.<br><br>- Илебезнең гүзәллеге турында сөйләштек. Гөлшат Зәйнашева иҗаты белән таныштык.<br><br>Максат һәм нәтиҗәләрдән чыгып үз эшчәнлекләрен һәм бер-берсенең эшчәнлеген бәялиләр. |

**Балачакның матур китабы.**

( Китапнамә ясау. Гөлшат Зәйнашева. "Асия")

Әминова Рима Сөнгатулла кызы, Рәхимова Ризәлә Камил кызы,

Р.И.Зарипов исемендәге Байлангар урта мәктәбе

башлангыч сыйныф укытучылары, Кукмара районы

Тема: Балачакның матур китабы.( Китапнамә ясау. Гөлшат Зәйнашева. "Асия")

Максат: Гөлшат Зәйнәшева иҗаты турында белемнәрне киңәйтү; шагыйрәнең "Асия" китабындагы әсәрләре белән таныштыру; мактанмау, масаймау, кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү

Барышы:

"Үз илемдә" җырын тыңлау.

- Сез тыңлаган җырда сүз нәрсә турында бара? (бер кош сайрый бакчамда, бәрәңге бакчасы, кипарислар, хөрмәләр, Туган ил)

- Без иркен, киң җиребездә рәхәтләнеп уйныйбыз, җырлыйбыз, китаплар укыйбыз.

- Бу җырның авторларын искә төшерегез әле? ( Г.Зәйнашева)

- Сыйныфтан тыш уку дәресендә аның нинди китапларын укыдык?


- Укыган китаплар арасыннан рәсемнәре һәм эчтәлеге белән кайсы китап җәлеп итте? Бу китап белән сезнең энеләрегезне, сеңелләрегезне мавыктырыр өчен без бүген китапнамә (буктрейлер) төзибез.

- Әйдәгез, беренче биткә елның беренче бәйрәме персонажы кергән шигырьне алыйк.

1 нче укучы.

Кар кызы җыры
Кар-буранда тудым мин,
Кар биләүдә үстем мин,
Кар биләүләрдә үстем мин,
Кар сулары эчтем мин.
Карлы-бозлы күлмәгем,
Капрон челтәр итәгем.
Ап-ак күлмәгем өлгесен
Сезгә бүләк итәрем.
Мин биимен, җырлыймын
Буран уйнап торганда.
Биеп аргач ял итәмен
Чыршы үскән урманда.
Мин курыкмыйм бураннан,
Мин кар- буран яратам.
Бизәп йөрим бар дөньяны,
Кар бөртеге таратам!

- -Рәсемдәге Кар кызы хәзерге Кар кызларына охшаганмы?


КАР КЫЗЫ ҖЫРЫ

...р-буранда тудым мин,
... биләүдә үстем мин,
... биләүләрдә үстем мин,
Кар сулары эчтем мин.

Кырлы-бозлы күлмәгем,
Капрон чалтәр итәгем.
Ап-ак кү мәгем өлгесен
Сезгә бүләк итәрем.

Мин биимен, җырлыймын
Буран уйнап торганда.
Биеп аргач ял итәмен
Чыршы үскән урманда.

Мин курыкмыйм бураннан,
Мин кар-буран яратам.
Бизәп йөрим бар дөньяны,
Кар бөртеге таратам!

- Кышка багышланган тагын бер шигырьне тыңлыйк.

Әлеге шигырь нәрсәгә өйрәтә?

2 нче укучы:

Кышкы салкын бер иртә,
Буран битне чеметә.
Исе китми буранга,
Чыкты Нияз урамга.
Торды капка төбендә,
Ап-ак бәс керфегендә.
Туңды бите-куллары,
Чана шуып булмады.
Бер малай юк урамда,
Чыкмаганнар буранга,
Йөри тик бер күгәрчен,
Һич тә туңмый күрәмсең.
Тәпиләре ялангач,
Бүреге юк, яланбаш.
Гөр-гөр-гөр-гөр-гөр-гөр, ди.
Нияз өйгә кер, кер, ди
Йөрмә туңып дер-дер, ди,
Гөр-гөр-гөр-гөр-гөр-гөр, ди.


- Бу шигырьдән без кышкы иртәнең малай өчен дә, күгәрчен өчен дә матур икәнен күрәбез. Салкында балаларга урамда йөрисе түгел икәнен күгәрчен үз телендә әйтеп бирә.

-Ә салкында кошлар да туңмый микән? Бу хакта Гөлшат Зәйнәшеваның “Перәннек” шигырендә җавап бар.

3 нче укучы:

Рөстәм чыкты урамга,
Кулга тотып перәннек.
Баллы-майлы перәннекне
Чыпчыкларга бирәм дип.
Перәннекне ваклап Рөстәм,
Шатланды җиргә сибеп.
Перәннек ашый башладылар,
Чыпчыклар чыр-чыр килеп.
Рөстәмне дәү әбисе

Чакырып алды янына.
Әрләмәде оныгын,
Сүз башлады җай гына:
- Улым, - диде, - перәннекне
Җиргә ташлама алай.
Перәннек кадерле ризык,
Син бит акыллы малай.
- Мин бит чыпчыклар туйдырам,
Җиргә ташламыйм тиккә.
Чыпчыклар ачыккан әнә,
Ашыйсы килгән бик тә.
Шулай диеп нәни Рөстәм
Җавап бирде әбигә.
Әби әйтте: - Кошка ризык
Болай да күп бит җирдә.
Һәм ул нәни Рөстәмнең
Башыннан сыйпап сөйде.
- Перәннек ашагач, чыпчыкның
Эче авыртыр,- диде. -
Чөнки, - диде, - чыпчыкларның
Тешләре юк бит, җаным,
Чәйнәмичә йота алар,
Бозып ашказаннарын!



Шулай диеп нәни тәм
Җавап бирде әбигә.
Әби әйтте: — Кошка ризык
Болай да күп бит җирдә.

Һәм ул нәни Рөстәмнең
Башыннан сыйпап сөйде.
— Перәннек ашагач, чыпчыкның
Эче авыртыр,— диде.—

Чөнки,— диде,— чыпчыкларның
Тешләре юк бит, җаным,
Чәйнәмичә йота алар,
Бозып ашказаннарын!

-Рөстәм бу шигырьдә кошлар ашатуның нинди кагыйдәләрен белми?

( Кошларга ашлык, кипкән җиләк-җимеш, миләш, көнбагыш орлыклары сибәргә була. Кайберләренә туңмай, татлы камырлар ярамый)

- Гөлшат Зәйнәшева шигырьләренең төп геройлары – бөҗәкләр һәм кошлар. Барлык тереклек ияләренең яшәү урыны булган табигатьне шагыйрә аңлаешлы итеп күрсәтә белә.


НИ БУЛГАН?

Язгы җылы бер ирт
Алсу китте мәктәп
Бөтен җирдә ап-ак
Күренми мәктәп х

Ерактан күренә иде
Кызыл матур йорт бу
Әллә Алсуны шаярта,
Бүген кинәт юк булып?..

Әллә инде адаштым дип,
Алсу калды аптырап.
Мәктәбемне тапмадым дип
Кире кайтты ул елап.

— Мәктәп кая югалган, ди,
Урамга, ди, ни булган?..
Әнкәсе житәкләп бара:
— Җиргә төшкән, ди, томан!..

4 нче укучы
Язгы җылы бер иртәдә
Алсу китте мәктәпкә.
Бөтен җирдә ап-ак төтен,
Күренми мәктәп хәтта.
Ерактан күренә иде
Кызыл матур йорт булып,
Әллә Алсуны шаярта,
Бүген кинәт юк булып?
Әллә инде адаштым дип,
Алсу калды аптырап.
Мәктәбемне тапмадым, дип
Кире кайтты ул елап.
- Мәктәп кая югалган, ди
Урамга, ди, ни булган?..
Әнкәсе җитәкләп бара:
- Җиргә төшкән, ди, томан!
- Укучылар, кем җавап бирә ала, урамда ни булган соң?
- Алсуга ничек ярдәм итик?

Томан ул – җир өслегендәге болыт. Күктәге болыт белән томан арасында бернинди аерма да юк. Болыт җир яисә сулык өслегендә булганда, без аны «томан» дип атыйбыз. Гадәттә томан төнлә яисә иртән-иртүк пәйда була. Ул җылы җир яисә су өстенә төшүче салкын һава нәтиҗәсендә барлыкка килә. Томанны еш кына күз күне күрергә мөмкин. Бу вакытта һава җир яисә суга караганда тизрәк суына. Җылы һава белән салкын һава кушылганда, томан барлыкка килә дә инде.

- Шагыйрә начар гадәтләрне, ярамаган эшләрне балалар теле белән әйттерә. Шигырьдән шырпы, ут белән уйнарга ярамауны аңлыйбыз.

5 нче укучы



Шырпы уенчык түгел

Әнием әйтте аркамнан сөеп:
- Шырпы уенчык түгел ул, - диеп.

Ләкин бер көнне шырпы сыздым мин,
Янып беткәнче карап тордым мин.
Ялкыны тиеп бармагым пеште,
Күмәчтәй булып кабарып шеште.
Ай-яй-яй сызлый пешкән бармагым,
Шырпыга хәзер якын бармамын!..

- Тырышып уку, куелган максатка омтылу тәрбияләп язылган шигырьләре дә бар Гөлшат Зәйнәшеваның. Шигырьне игътибар белән тыңлагыз. Әсәрдәге Дилбәр нинди кыз?

6 нчы укучы:

Билгеләр.

Бер, ике, өч, дүрт һәм бишле
Кызыл-кызыл билгеләр,
Җыелдылар, киңәштеләр,
бер фикергә килделәр.
Кызык итәргә Дилбәрне,
Мыскылларга булдылар.
Бишесе бергә җыйналып,
Көндәлеккә тулдылар.
Вәгъдә бирештеләр болар
Гел бергә дус булырга.
Көндәлеккә һәрчак шулай
Җитәкләшеп тулырга.
Берле, икеле, өчле һәм
Дүртле, бишле билгеләр
Көндәлекне тутырдылар,
Нишләргә белми Дилбәр.

7 нче укучы:

Көндәлек битенә Дилбәр
Гел бишле алыр иде.
Отличник булып класста
Иң алдан барыр иде
Тырышмый шул кайвакыт ул,
Ялкаулана, иренә.

Укымый, эшләми өйдә
Тик болганып йөренә.
Шулай йөри торгач бер көн
Дилбәр уйланып куйды.
Болганып тик йөрүдән дә,
Ялкаулыктан да туйды.
Тырышырга булды Дилбәр,
Тупларга барлык көчне
Куды ул көндәлегеннән
Берне, икене, өчне.
Тырыша торгач, куды ул
Хәтта дүртле билгене.
Җиңел генә булмады бу,
Күп көч куйды, билгеле.
Калды көндәлектә бер көн
Бердәнбер бишле билге.
Ялгыз бишле япа-ялгыз
Берүзе нишләр инде?
Моңаеп берүзе калгач,
Бишлегә әйтте Дилбәр:
- Сиңа иптәшкә алырмын
Гел, гел бишле билгеләр!
Берле, икеле, өчлене
Кертмәс минем көндәлек.
Үзеңә тиң чын дусларны
Бишлеләрне көн дә көт!
Сиңа тиң түгел берлеләр,
Икелеләр, өчлеләр.
Алар биш һәм дүрт янында
Хыянәтче төслеләр!..
Йомгаклау.

- Укучылар, китаптагы телен йоткан Халик, ялкаурак Дилбәр, шәфкатьле Рөстәмнәр турында башкалар да белсен өчен, рәсемнәр ясап, китапнамәгә кертәбез. Сезнең хәзергә укый белми торган энеләрегез, туганнарыгыз китапнамә буенча Гөлшат Зәйнашева шигырьләрен табып кызыксынып укырлар дип ышанабыз!

## Г.Зәйнашева иҗатына багышланган әдәби кичә

(ачык дәрес сценариясе)

Галиәхмәтова Гөлнара Илшат кызы,

Бариева-Саетгараева Гүзәл Фирдәвес кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Класста Г.Зәйнашеваның портреты урнаштырылган, почмакта иҗатын чагылдырган китаплар күргәзмәсе куелган. Салмак кына көй уйный. Килгән кунаклар класска кереп утырышалар. Экранда презентация күчерелеп бара.

8 сыйныф укучысы башкаруында “Китмә, сандугач» җыры яңгырый.

Дәрес барышы:

Укытучы: Хәерле көн хөрмәтле кунаклар, кадерле укытучылар, укычылар. Гөлшат Зәйнашева иҗатын яратып, рухын хормәтләп килгән барчагызга чиксез рәхмәтлебез, сезне белән очрашуыбызга бик шатбыз. Әлеге үлмәс җырларда ничәмә-ничә буын тәрбияләнде?

Укучылар җавабы: Безнең әби-бабабларыбыз, әти-әниләребез.

Укытучы: Бик дөрес! Килешәм сезнең җавап белән. Гөлшат апа Зәйнашева иҗаты өчен кайдан шулкадәрле көч, илһам алган икән? Ул бит гап-гади бер авыл баласы?!

Экранда видеодан өзек бара.

1 укучы чыгышы: Шагыйрәнең тормыш юлына күз салсак, кечкенә Гөлшат Сарман районы Иске Теләнче авылында 1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Аның иҗатында: “Бәхетемнең бишегеннән балачакта егылып тошкәнмен,- дигән юллар бар. Ятимлек сәбәп моңа, моңлы ятимлек. Әтисе Хисаметдин аганы 1930 нчы елда Архангель өлкәсенә Соловки лагерына соргенгә озаталар, берсеннән-берсе кечкенә бала белән йорт-курасыз, тол калган әнисе-Әнвәрә апа, 2 яшлек Голшатны иренең туганнарына асрамага бирергә мәҗбүр була.

2 укучы чыгышы: Кечкенә Гөлшатның балачагын Минзәлә якларында, Югары Тәкермән авылында үткән, һәм нәкъ тә шушы авылны туган авылы дип усә шагыйрә. Җырга, шигырьгә салынган моңнары әнә каян килә ул! Үсеп буйган җиткән Гөлшат Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый, Казанда педагогия институтында белем ала. Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында эшли.

Укытучы чыгышы: Гөлшат Зәйнашева иҗатының илһам чишмәсенең чыганагы – мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтылуы белән, үзешчән сәнгать һәвәскәре авыл сәхнәләрендә, бераз соңрак институт кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булып торгандыр.

Казанда шәһәрнедә шагыйрә музыкантлар, җырчылар, композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Бөек композитор Алесандр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар куя. һәм ул «Туган җирем – Татарстан» җыры белән бәйгедә җиңү яулый. Бу җырның дәртле музыкасы, халык күңелендә туган иленә булган хис-тойгыларны әйтеп бирерлек моңга ия.

8 нче сыйныф укучысы башкаруында «Аерылмагыз» җыры яңгырый.

1 укучы: Җырда иң мөһиме, төгәллек, хакыйкать, һәм әлбәттә гадилек.

Гадилеккә Гөлшат апа беренче җырларыннан ук төшенә. Аның җырларын татар иленең яратып кабул итүенең сәбәбе, мөгаен, шулдыр: әлеге җырларның сүзе гади – тормышчан, ә көе халык рухына туры килә, сүзләргә салыган мәгънәне ачып бирә белүендә.

5 сыйныф укучысы «Конфет» шигырен укый.

2 укучы чыгышы: Г.Зәйнашева җыр текстлары өлкәсендә актив эшли.Аның иҗатында туган якка, туган илгә булган мәхәббәт, сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, бөек, даһи шәхесләр, үткән,алдагы тормыш турында уйланулар, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Экранда видео язма кушыла.

4 сыйныф укучысы башкаруында «Кояш гомере» җыры яңгырый.

Укытучы: Шагыйрәнең драматургия өлкәсендә дә башкарган эшләре дә бихисап. Узешчән драма коллективлары өчен язылган пьесалары күмәк җыентыкларда бастырылып чыга. «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен», «Нәрсә булды

безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Язмышлар һәм ялгышлар», исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә бүгенге көндә дә зур уңыш белән бара.

10а сыйныф укучылар тарафыннан әзерләнгән «Язмышлар һәм ялгышлар» спектакленнән өзек күрсәтелә.

Укытучы: Сандугачка титул кирәкми дигән сузләр бар халыкта! Г. Зәйнашева әдәбиятның төрле жанрларына караган ике дистәдән артык китап авторы,композиторлар белән дус, иҗат тормышы белән яши. Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» исемле китабы өчен Г. Зәйнашева Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Шушы җыентыктан «Туган авылым» җырын тәкъдим итәбез.

«Туган авылым» җыры башкарыла. Г.Зәйнашева сүзләре.

1 укучы. Җырлы һәм моңлы як кызы Гөлшат Зәйнашеваның эшчәнлеге үзе тудырган «буразналарны» хәтерләтә.

2 укучы. Яхшы итеп, мул итеп, тирән итеп сөрелгән бу буразналар мул уңыш бирде, халык күңеленә хуш килде.

8 сыйныф укучысы башкаруында «Син кемнең сандугачы» җыры яңгырый Г.Зәйнашева сүзләре, А.Шакиров көе.

1 укучы: Кеше китә, җыры кала, диләр, шулайдыр, әмма ләкин шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны – китмәде, диясе килә! Чөнки ул – моңлы җыр, шигърият булып бик озак еллар милләтебездә яшәячәк!

2 укучы:

Нәрсә калдырам мин китсәм, бу якты доньяга дим?

Яктыртыр өчен тагында,ни кылдым аңарга дим?

Гашыйк булып бу дөньяга,тик җырлап үтте бу гомер

Кемнәр моңлы, шулар гына хәлемне белсә белер...

Укытучы:

Җырладым илемне мактап,

Җырга бирдем бар көчем.

Илемнең күге, халкымнең

Күңле яктырсын өчен.

Үзем китсәм, калыр моңым.

Җырым кинәт бүленеп

Туган як каеннарының яфрагына эленеп.

Йомгаклау җыры «Туган җирем – Татарстан» Музыка мәктәбе укучылар хоры чыгышы Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе.










**Гөлшат Зәйнәшеваның 95 яшьлек юбилей кичәсе**

Каримова Регина Нәфис кызы,

2 нче санлы Түбән Мактама мәктәбе укытучысы, Әлмәт районы

Зал бәйрәмчә бизәлгән.

Түрдә Г.Зәйнәшеваның портреты элены, иҗатын чагылдырган рәсемнәр, китаплар күргәзмәсе; плакатлар:

1) «Бәхетемне синдә таптым…»

2) Сандугач-сандугач,

Китмә, китмә, сандугач.

1 нче алып баручы

Яңгырасын көйләр, шат көлүләр,

Тирә-юньгә бүген таралсын.

Кемнәр болар – бәхетлеләр диеп,

Бөтен кеше безгә карасын!

2 нче алып баручы

Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, кадерле укытучылар! Рәхим итегез! Бүгенге кичәбез Гөлшат апа Зәйнәшеваның иҗатына багышлана.

1нче укучы. Иртә дә генә торам, юлга чыгам,

Иңнәремә шәлем ябынам.

Кемне сагынасың, дип сорамагыз,

Күк күгәрченемне сагынам.

Иртә дә генә торам, юлга чыгам,

Юл буйлары яшел өрәңге.

Нигә ялгыз син, дип сорамагыз,

Гомерем буе көтәм берәүне.

Иртә дә генә торам, юлга чыгам,

Курай кисеп алам камыштан.

Нигә моңлы син, дип сорамагыз,

Моңлы бала булдым тумыштан.

1 алып баручы: "Моңлы бала булдым тумыштан", - шулай дип яза "Иртә дә генә торам" дигән шигырендә ата-ана назыннан бик иртә аерылган Гөлшат Зәйнәшева, моңлы-сагышлы балачагын искә алып. Ул 1928 елның 13 гыйнварында Сарман районы Иске Теләнче авылында туа. Әмма урта хәлле, нык тормышлы әтисе Хисам абый һәм әнисе Әнвәр апаның биш балалы гаиләсендә аңа үсәргә насыйп булмый. 1930 елның язында НКВД ялчылары өйгә бәреп керәләр дә, дошман, авыл кулагы дип, мылтык түтәсе белән төрткәли-төрткәли, балалары белән саубуллашырга да ирек бирмичә, хуҗаны төпсез караңгылыкка алып китәләр. Шул китүдән Хисам агай Соловки лагерьларында адәм баласы түзә алмаслык шартларда эшләп, чирләп вафат була. Күп еллар үткәч, репрессия корбаны булып аклана. Әмма күмәкләшү чорында Иске Теләнчедә йорты тартып алынган, ризыксыз калган Зәйнәшевләр гаиләсенә тормышны алып бару, очын-очка ялгау нык авырлаша. Әнисе Әнвәр апа ике яшь тә өч айлык Гөлшатны әтисенең бертуган сеңлесе Маһру апага асрамага илтеп бирергә ризалаша. Бу гаилә Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яши торган була. Матур табигатьле бу авыл, балачак хатирәсе булып, Гөлшат Зәйнәшева күңелендә гомерлек эз калдыра.

Укучы "Моңлы авыл Тәкермән" шигырен сөйли

2 нче алып баручы. Өйләре клуб янәшәсендә була аларның. Минзәләдән артистлар килсә, аларга фатирга төшәләр. Кичләрен артист Сабир Өметбаев аны күтәреп клубка алып керә. Спектакль тәмамланганнан соң, артистлар аны, урындыкка бастырып, шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, кечкенә кыз Гөлшат артист булып уйнарга ярата. Мич аралыгына корылган чаршау артыннан чыгып, яшелле-күкле тавыш белән: "Кәнсиртебезне башлыйбыз! Җырлый Гөлшат Зәйнәшева", - дип белдерү ясый.

Г.Зәйнәшева җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес. Аның иҗатында туган якны ярату һәм сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, олы мәхәббәт хисләре, аналар язмышы, тарихи шәхесләр, тормыш, заман асылы турында уйланулар, мәхәббәт лирикасы, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Җыр. “Әни турында җыр” 5 а сыйныфы

1 нче алып баручы . Башлангыч мәктәпне авылда тәмамлагач, кечкенә Гөлшат күрше Хуҗамәт авылындагы җидееллык мәктәпкә биш чакрым йөреп укый. Аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. Ул чордагы кичергән авырлыкларны шагыйрә болай искә ала:

“Мин 13-14 яшемнән үзбашыма көн күрә башладым. 1942-1943 еллар сугышның иң авыр еллары иде. Өс-баш ярлы, ашарга юк. Авылдан, өйдән бернинди ризык килми. Мин, аркага киндер капчыктан биштәр ясап, шуңа бераз бәрәңге салып өйдән чыгып киткән яшүсмер кыз бала, Минзәләдә кеше идәннәрен юып, кешегә бәрәңге утыртышып, бәрәңге казышып тамак туйдыра идем. Атнага бер тапкыр фотография идәнен юып чыгара идем. Фотограф абый шуның өчен бераз акча бирә иде. Шул акчага, базарга чыгып, берәр ризык алып ашый идем.

Безнең тулай торак пожарныйның аскы катында иде, ул ягылмый иде, аның миче юк иде. Без, студентлар, кышкы салкын көннәрдә, дәрестән кайтып кергәч, чишенмичә генә дәрес хәзерли идек. Өскә – бишмәт, аякка киез итек кигән килеш, башка мамык шәлләр урап, ятып йоклый идек. Юрганнар ябынып ятсак та, барыбер туңа идек.

Уйладым-уйладым да мин, мич чыгарырга булдым. Минзәләдә җимерек йортлар бар иде. Шул йортлар янында кирпеч ватыклары, калай кисәкләре аунап ята. Шул кирпеч ватыкларын, ташлар, калайлар җыеп алып кердем дә бер почмакка мич чыгарып куйдым. Ул мич, кыек-мыеграк булса да, хәйран җылыта иде. Бер-ике көннән пожарниклар килеп керде һәм мичне сүтеп ташларга куштылар. Ләкин берсе: "Менә сиңа кызлар! Балалар гына бит әле болар! Шулай да югалып калмаганнар! Молодцы! Эх, сугыш... сугыш... Әйдә киттек!" - дип, усал пожарникны алып чыгып китте.

Укучы «Мин тормышка гашыйк» шигырен сөйли

2 нче алып баручы . Гөлшат Зәйнәшеваны язмыш гел сынап тора. Казанга килеп, педагогия институтында укый башлагач та, аңа, халык дошманы кызы дип, тулай тороктан урын бирмиләр, ул бер ел буена урындыкларда йоклап йөрергә мәҗбүр була. Нәкъ шул елларда алдынгы студентларга Г.Тукай исемендәге махсус дәүләт стипендиясе бирергә дигән карар чыга, стипендияне беренче булып Г.Зәйнәшевага бирәләр. Шунысы да кызыклы: Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге дә, хатын-кызлардан беренче булып, 1991 елда «Илле җыр» исемле китабы өчен Г.Зәйнәшевага бирелә.

Җыр. “ Үз илемдә”

1 нче алып баручы .Шагыйрәнең драматургия өлкәсендә дә эшләве билгеле. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

«Гайфи бабай, өйлән давай!» спектакленнән өзек күрсәтелә (укучылар)

2 нче алып баручы. Г.Зәйнәшева сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул – сәнгать кешеләренә, артистларга багышланган мәкаләләр, мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймановага, җырчы һәм композитор Сара Садыйковага багышланган китаплар яза. Замандашлары күңелендә Гөлшат Зәйнашева – татар халкының иң күркәм сыйфатларын үзендә туплаган олы җанлы, эчкерсез күңелле зыялы кеше булып саклана. Ул 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була.

Г. Зәйнәшева әле бик бәхетле әни дә, кызы Асияның балалары – Дамир белән Камилгә әле ул дәү әни дә була. Алар аны, яратып, "Гөләни" дип йөртәләр.

1 нче алып баручы. Җырлы һәм моңлы як кызы Гөлшат Зәйнашеваның эшчәнлеге үзе тудырган «буразналарны» хәтерләтә.

2 алып баручы. Яхшы итеп, мул итеп, тирән итеп сөрелгән бу буразналар мул уңыш бирде, халык күңеленә хуш килде.

«Туган ягым - гөлләр иле» җыры

**Иң элек син Кеше бул, балам!**

(Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?”шигыре буенча

6 нчы сыйныфта үткәрелгән дәрес планы)

Йосыпова Руфина Рим кызы,

2 нче санлы Урыссу гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Ютазы районы

Максат: Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү; һөнәр сайларга әзерләү;тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

<u>*ТБУУГ:*</u> Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу, төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүматлы булу;

<u>*КУУГ:*</u> Аралашу күнекмәләрен формалаштыру, парларда һәм күмәк эшли белү;

<u>*РУУГ:*</u> Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;

<u>*ШУУГ:*</u> Укуга карата кызыксыну формалаштыру;

<u>*Дәрес тибы*</u>: яңа белемнәрне үзләштерү

Материал:Мотыйгуллина Ә.Р дәреслеге (2нче кисәк,36-38 нче битләр)

Җиһазлау: Проектор, экран, Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?” шигыре, Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында презентация, видеоролик,стакан белән су,шикәр комы,ташлар.

Дәреснең барышы:

I.Мотивлаштыру – ориентлаштыру

**1.** Оештыру өлеше.

Исәнләшү. Кәефләрне белешү. Психологик уңай халәт булдыру.

Хәерле иртә балалар !

Исәнмесез, саумысез!

Күтәренке кәеф белән

Дәресебезне башлыйбыз!

Укучылар! Бер-берегезгә хәерле көн теләгез.

- Бүген сыйныфта кем дежур?

- Бүген ничәсе?

- Атнаның нинди көне?

- Сыйныфта кем юк?

- Урамда көн нинди?

**2.** Актуальләштерү.

1) Өй эшен тикшерү. Әйдәгез әле, өй эшен тикшереп алыйк. Үткән дәресләрдә без сезнең белән өч хикәя укыган идек. Иң беренче без сезнең белән “Чүкеч” хикәясен

укыдык, аннан соң “Әни ялдан кайткач” хикәясен һәм өченчесе “Кояштагы тап” хикәясен укыдык.

- Укучылар! Бу әсәрләрне кемнәр язган? Балалар җавабы ( “Чүкеч” – Габделхәй Сабитов хикәясе, “Әни ялга киткәч” – Абдулла Алиш хикәясе, “ Кояштагы тап” – Фәнис Яруллин хикәясе.

- Миндә шушы язучыларның фоторәсемнәре. Кайсы – кем? Язучыларның фоторәсемнәрен исем фамилияләре астына куегыз әле.

- Ә хәзер мин сезгә шушы хикәяләрдән алынган өзекләр өләшәм. Сез шушы өзекләрне укып, кайсы хикәядән алынган икәнен әйтерсез. (Балалар өзекләрне укыйлар, кайсы хикәядән алынганын әйтәләр, хикәянең исеме янына магнитлар белән куялар).

- Бик әйбәт, балалар. Сезнең һәрберегезнең алдында үзбәяләү карточкалары бар. Хәзер шунда үзегезгә билгеләр куегыз. Бик әйбәт “5”ле билгесе, яхшы - “4” ле, ярыйсы – “3”ле, начар –“2”ле билгесе куела.

Уку мәсьәләсе кую.

Хәзер ролик карап китегез. «Кем булырга?» ролик карау. (ролик карау) Укучылар сез үскәч, кем булырга телисез? Сезнең уйланганыгыз бармы? Роликта нәрсә турында сүз бара? Һөнәр сайлау турында. Димәк, без сезнең белән бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшербез инде? (Балалар җавабы: Һөнәрләр турында)

2.Язучылар, шагыйрьләр һөнәрләр турында әсәрләр язалармы? Әйе, бик дөрес язалар. Бүген без танышачак шагыйрә дә һөнәр сайлау турында язган. Тактага карагыз, бу кем портреты? ( Гөлшат Зәйнашева портреты)

Димәк, без бүген дәрестә кем иҗаты белән танышырбыз?Аның кайсы шигырен өйрәнербез?

Без Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?” шигырен өйрәнәбез.

III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.

- Әйдәгез, хәзер укучылар шагыйрәнең кыскача тормыш юлы белән танышыгыз. Сезнең алдыгызда шагыйрәнең тормыш юлы турында текст ята. Сез укып чыгыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.

- 1) Шагыйрә кайчан һәм кайда туа?

- 2) Ул кайларда укый?

- 3) Ул кайда эшли?

- Укучылар җавапларын әйтәләр. Рәхмәт укучылар, булдырдыгыз.

2. Ә хәзер, төркемнәрдә эшлибез. Һәр төркем сүзләр тәрҗемә итә. 2 төркемгә дә сүзләр әйтелә. Өстәлдә сүзлекләр ята.

- 1 төркем

- кем булырсың? [кэм булырсың] – кем будешь?

- баянчы[бåйанчы] – баянист

- табиб[тåбиб], табибә[тåбибә]-врач

- сатучы[сåтучы]-продавец

- 2 төркем

- дәвалый[дәwалый], савыктыра[сåwықтыра]- исцеляет, лечит

- иң элек[иң элэк]- сначала, сперва

- Ходай[ходай]- Господь, Бог

- Әйдәгез, тикшерәбез. Слайд күрсәтелә.

- Сүзләрнең татар телендәгесе хор белән кабатлана.

- Ә хәзер дәреслекләрнең 37нче битен ачабыз. Анда безнең “Кем булырга?” шигыре бирелгән. Шигырьнең исемен ничек аңлыйсыз? Ул нәрсә турында булырга мөмкин? Кем быть? (Балалар җавабы: Һөнәрләр турында)

- Әйе, балалар, һөнәрләр турында.

Шигырь өстендә эш.

1) Шигырьне укытучы укый балалардан сорауга җавап сорый. (Шигырдә сүз нәрсә турында барачак? Малайга кемнәр киңәш бирә?)

2) Укучылар үзләре эчтән укый, игътибар белән укыгыз: малайга нинди киңәшләр бирәләр?

3) Шигырьне чиратлап сәнгатьле итеп укыйлар.

Беренчел ныгыту

Төркемнәрдә эш.

1 өстәл беренче 8 юлда нинди һөнәрләр ишеттегез? 1 минут эчендә һөнәр исемнәрен языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (баянчы, артист, шофер).

2 өстәл 1 минут эчендә шигырьнең калган өлешендә ишеткән һөнәр исемнәрен һәм алар башкарган эшне языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (Табиб , сатучы)

5. Мөстәкыйль эш. Сорауларга җавап бирү.

1. Малайга кем нинди һөнәр алырга куша?

Әтисе

Әнисе

Апасы

Артистлар

Әбисе

(Һәр төркемнән 1 укучы җавап бирә)

- Ә кеше һөнәрме ул? (БҖ: Юк).

- Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Әңгәмә оештыру. Кеше булу, димәк, кешеләргә ярдәм итү, тәртипле булу, намуслы, гадел, эшчән, акыллы, тәрбияле булу...

- Укучылар! Һөнәр сайлау белән түгел.Кайда гына эшләсәгез дә, кешелекле булырга кирәк, кешеләр белән матур сөйләшергә, аларны ямьсез сүзләр әйтеп рәнҗетмәскә.

- Хәзер без сезнең белән тәҗрибә үткәреп алырбыз. Тәҗрибә үткәрү өчен стакан белән су, шикәр комы, ташлар кирәк.Күз алдыгызга китерегез әле, бу стакан белән су – сезнең күңелегез, ә шикәр комы – бу яхшы, йомшак, матур сүзләр, ә менә ташлар – безне ачуландыра торган, елата торган, әшәке сүзләр. Стакан белән суга әз генә шикәр комы салыйк. Нәрсә булды дип уйлыйсыз? Шикәр эреде, су тәмле, баллы булды. Күңелгә рәхәтме? Әлбәттә.

Ә хәзер шул суга ташларны салып карыйк әле, нәрсә күрәбез? Төбенә төшеп утырды, стакан авырайды, су пычранды, ташлар баллы суны тәмсез ясады. Ә күңелебез ни хәлдә, кәефегез ничек? Авыр, начар. Чыннан да,  авыр, кәефебез төшә. Ә ташларны кире күңелдән чыгарып буламы? Юк. Эзе кала, тап бетми.

Бу тәҗрибә сезне нәрсәгә өйрәтә? (Аралашканда матур сүзләр белән сөйләшергә кирәк икәнен аңларга өйрәтә)

- Чыннан да укучылар, яхшы сүзне барыбыз да яратабыз, ягымлы сүз ишетсәк, күңелебезгә рәхәт булып китә.

Яхшы сүзне  җаның тели синең,

Начарлыктан күңелең көрсенә.

Ә син үзең андый яхшы сүзне

Әйтәсеңме башка кешегә?

- Ә хәзер үзегезнең үзбәя битләрен алыгыз һәм дәрестәге эшчәнлегегезгә билге куегыз.

III. Рефлексив бәяләү.

1. Рефлексив кабатлау.

- Балалар, без бүген дәрестә нинди яңа шагыйрә турында белдек? (БҖ: Гөлшат Зәйнашева. Тактага шагыйрәнең портреты куела).

- Без аның нинди шигырен укыдык? (БҖ: “Кем булырга? шигырен. Тактага шигырь язылган бит куела).

- Шигырьдә кем турында сүз бара? (БҖ: Малай турында. Малай рәсеме куела).

- Малайны кем итеп күрәләр? (БҖ: Баянчы, шофёр, табиб, сатучы)

- Болар нәрсәләр? (БҖ: Һөнәрләр).

- Без дәрестә нәрсәләр турында сөйләштек инде? (БҖ: Һөнәрләр турында, шагыйрь турында, шигырь укыдык).

2. Өй эше бирү

1) “Кем булырга?” шигырен сәнгатьле итеп укырга (37б.)

2) Дәреслекнең 38б., 5нче, 6нчы биремнәр ярдәмендә парлап сөйләшергә әзерләнергә

3) Иҗади бирем. Үзегезгә ошаган һөнәргә реклама ясарга (презентация, рәсемнәр, фотолар, сөйләү)

3.  Дәрескә йомгак ясау. Әңгәмә оештыру

- Миңа .... ошады.

- Мин үземә “....”ле куйдым, чөнки ..... .

(Бәяләү. Билгеләр кую. Үзбәя битләре ярдәмендә укучыларга билгеләр куела).

- Без бүген сезнең белән бик әйбәт эшләдек. Миңа сезнең белән эшләве бик рәхәт булды. Барыгызга да зур рәхмәт. Дәрес тәмам. Сау булыгыз, балалар! (Балалар җавабы: Сау булыгыз!)

## Г.Зәйнашева “Тукран белән сөйләшү”

(интеллектуль карта төзү. 2 нче сыйныф укучылары өчен әдәби уку дәресе)

Мияссарова Ләйлә Кәбир кызы, Шангараева Нәзифә Наил кызы,

икенче санлы Җәлил урта мәктәбе башлангыч

сыйныф укытучылары, Сарман районы

Максат: Г.Зәйнашеваның “Тукран белән сөйләшү” шигыре белән танышу аша функциональ грамоталылык формалаштыру өстендә эш алып бару.

Регулятив универсаль уку гамәлләре: укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; укудагы уңышларга, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.

Танып белү универсаль уку гамәлләре: сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу; тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру; укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре: күмәк эшне планлаштыру; әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү.

Планлаштырылган нәтиҗә: укучыларның эзлекле фикерләү сәләтен, аңлап уку күнекмәләрен үстерү.

Җиһазлау:

**1.** Такмаза язылган карточкалар (һәр укучыда);

**2.** карлыгач, тургай, тукран, сыерчык, аккош рәсемнәре+ кош исемнәре язылган карточкалар;

**3.** Г. Зәйнашева портреты;

**4.** Г.Зәйнашеваның китапларыннан төзелгән күргәзмә;

**5.** имән, каен агачларының кайрылары;

**6.** ватман (һәр төркемгә 1), клей, фломастерлар;

**7.** “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” 1нче том, 310 бит.

**8.** Карта ясау өчен крточкалар.

Дәреснең барышы

**1.** Оештыру моменты. Уңай психологик халәт тудыру.

Хәерле көн, алсу таңнарга!

Хәерле көн, сайрар кошларга!

Хәерле көн, зәңгәр күкләргә!

Хәерле көн, якын дусларга!

Хәерле көн, матур кызларга!

Хәерле көн, батыр улларга!

- Исәнмесез,укучылар. Хәерле көн. Утырыгыз. Әйдәгез, бер-беребезгә карап елмаеп алыйк әле. Карагыз: булмәбез тагы да яктырып, жылынып китте.

2. Фонетик зарядка."Тукран". Такмаза.

А) -Балалар, ишетәсезме, ниндидер кош тавышы килә! (аудиоязма тыңлау).

https://zvukipro.com/ptici/39-zvuki-dyatla.html

-Тукран тукылдый.

Ә) Тукран турында такмаза өйрәнеп китик эле. (карточкага язылган текст белән эшләү)

(Пышылдап уку, 3 тапкыр кул чабып иҗекләргә бүлеп уку-һәр укыган саен уку темпын кызулатып).

- Кайсыгыз такмазаны сөйләп күрсәтә? (2-3 укучыны тыңлау).

3.Уку мәсьәләсен кую.

-Балалар. Бүген дәрестә без сезнең белән төркемнәрдә иҗади эш эшлибез (төркемнәрне билгеләү).

-Тактага карыйк эле, нәрсәләр бу?(Кошлар)

- Кошларны таныйсызмы?







(Һәр рәсем астына кошның исеме язылган карточкалар беркетү) карлыгач, тургай, тукран, сыерчык, аккош.

- Нинди кош артык? Ни өчен? (Тукран, чөнки ул кышлаучы кош, ә калган кошлар – күчмә.)

- Бүген без Гөлшат Зәйнашеваның тукран турында бик матур шигыре белән танышырбыз. Укылган әсәр буенча иҗади эш башкарырбыз. (Тактада тукран рәсеме генә кала).

4.Дәреснең темасы буенча эш.

А) Г. Зәйнашева турында белешмә бирү.(Өйдә чыгыш әзерләгән укучылыр сөйли).

1.Тактада Г.Зәйнашеваның портреты.

2. Чыгышларны тыңлау.




Зәйнашева Гөлшат Хисам кызы Иске Теләнче авылында (хәзер Татарстан Республикасының Тукай районында) туа. Күп балалы крестьян гаиләсендә туа. Әтисе кулак була һәм Архангельскига сөргенгә җибәрелә, ә Гөлшат башка гаиләгә тәрбиягә бирелә. Балачак еллары Гөлшат Тәкермән, Хуҗәмәт авылларында уза.

Гөлшат Зәйнашева Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый, аннары Казан дәүләт педагогия институтына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

1959 еллар ахырында беренче тапкыр аның басмалары дөнья күрә. Аның белән Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова һәм башка җыр жанры осталары хезмәттәшлек итте. Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә язылган күп җырлар татар мәдәниятенең алтын фондына керде.

Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты татар драматургиясе белән дә бәйле. Аның пьесалары 1960 елларда ук Минзәлә татар драма театрында куела. Аның пьесалары буенча спектакльләр Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә, К.Тинчурин театрында, «Әкият» Татар дәүләт курчак театрында уңышлы бардылар.

3.Күргәзмә белән танышу.

4.Чыгышларны игътибар белән тыңладыгызмы? Үзегез өчен нинди яңа мәгълүмат белдегез? (Фикер алышу)

Ә) Дәреслекләрне ачып, яңа әсәр белән танышыйк. Аның исеме ничек? (“ Тукран белән сөйләшү”)

Шигырьдә сүз нәрсә турында булыр микән? (Фикер алышу).

Шигырьне укып карыйк.(Хор белән уку).

Кайсыбызның фикере дөрес булды?

Б) Сүзлек эше.

Укыганда нинди сүзләр аңлашылмады?

Мин сезгә имән, каен агачларының кайрыларын алып килдем. Әсәрдә “кайры” сүзе бар. (Кайрыларны тотып карау.) Ул сүз нәрсә дигәнне аңлата? (Агач кабыгы).

В) Иҗади эш.

Хәзер инде дәресебезнең төп эшенә күчәбез. Шигырьне укыйбыз, анализлыйбыз һәм интеллектуаль карта ясыйбыз).

| № | Сораулар | Эш төре | Җиһаз |
|---|---|---|---|
| 1 | - Шигырьнең исеме ничек? Аның авторы кем? | Карточкалар арасыннан дөрес җавапларны сайлап алу. Ватмангаябыштыру . | Кызыл карточкалар.<br>1.Г.Зәйнашева<br>2.М.Маликова<br>3.Э.Мөэминова<br>4.”Тукран”<br>5.”Тукран белән сөйләшү”<br>6. “Тук-тук тукран” |
| 2 | Әсәрнең төзелешенә карыйк әле. Аның нинди үзнчәлеген курдегез. (Диалог, сөйләшү формасында язылган). Сөйләшүне кемнәр алып бара? | “Г.Зәйнашева “Тукран белән сөйләшү” язуыннан 2 ук төшерелә. Тукран, бала рәсемнәре ябыштырыла. | Тукран, бала рәсемнәре |
| 3 | | Анлатмалы сүзлек белән эшләү,җавп табу, уку. “Диалог нәрсә ул?<br>Әңгәмә формасында | “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”-301 бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | язылган әдәби әсәр”- карточкасын ябыштыру | |
| 4 | Рольләргә буленеп уку (кызлар-малайлар хор белән, парлап, 2 парны тыңлау). Сәнгатьле уку күнегүләре. | Уку | |
| 5 | Вакыйга кайда бара? Урман нинди өлешләргә бүленә? | 1.Урман рәсемен ябыштыру.<br>2.” агачлар, куаклар, үләннәр”- сүзләрен язу | Шәһәр, авыл, урман, күл рәсемнәре |
| 6 | Тукран нинди? Лирик герой (бала) нинди? | Яшел карточкаларны 2 төркемгә бүлү, ябыштыру | Тырыш, сизгер, чуар,чыдам, кызыксынучан, аралашучан, игътибарлы |
| 7 | Соңгы репликаны укыйк эле? Сез аны ничек аңлыйсыз?Тукранны урманның кеме дип йөртәләр? Ул нинди файда китерә? | “Урман санитары” исемле текст төзү, аны картага урнаштыру.<br>Кирәкле сүзләрне шигырьдән алырга кирәк була! | Сары карточка<br>“ Урман санитары<br>...-урман санитары.<br>Ул ... утыра.<br>Агачның кайрысын тишеп ... . Зарарлы ... чүпли.” |
| 8 | Ә сез урманда йөрергә яратасызмы? Ни өчен? Урманда ннди кагыйдәләр үтәргә кирәк? | 1.Схемалар буенча кагыйдәләр төзү.<br>2.Һәр укучы узе бер схема ясый<br>3. Ясалган рәсемнәрне картага ябыштыру | <br>.<br>1.Таблица<br>2. Рәсем ясау өчен 5*5см шакмаклар<br>3.Фломастерлар |
| 9 | Урман кешегә нинди файда китерә? | Синквейн төзү кагыйдәләрен искә төшерү<br>Синквейн төзү<br>Картага ябыштыру | Синквейн ясау өчен карточка |

5. Рефлексия. “Комплимент” күнегүе.

Дәресебез азагында эшебезгә йомгак ясыйк.  Эшләгән эшкә комплимент  ясыйк әле. Кайсы эш сезгә күбрәк ошады?

6. Йомгаклау.

(Интеллектуль карталар тактага куела.)  Дәрестә нинди әсәр белән таныштык? Аның авторы  кем? Үзегез өчен нинди файдалы белемнәр тупладыгыз?


7.Өй эше

Ошаса, шигырьне ятларга яки урманда үсүче берәр дару үсемлеге турында чыгыш әзерләргә

Үрнәк

**“Г.Зәйнашева**

**“Тукран белән сөйләшү”**

| | | |
|---|---|---|
|  | **Диалог нәрсә ул?**<br>**Әңгәмә формасында язылган әдәби әсәр** |  |
| **тырыш**<br>**Сизгер**<br>**Чуар**<br>**чыдам** |  | **кызыксынучан**<br>**аралашучан**<br>**игътибарлы** |
| **Урман санитары**<br>**Тукран урман санитары.**<br>**Ул агачта утыра.**<br>**Агачның кайрысын тишеп куптар**<br>**Зарарлы кортларны чүпли.** |  | **Синквейн**<br>**1.Урман**<br>**2.Куе, зур**<br>**3. Ашата, саклый, өйрәтә**<br>**4. Зәңгәр планетабызның "үпкәсе"**<br>**5.Яшел аптека** |

**Безнең уен**

(Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган интеллектуаль уен)

Хәйруллина Гөлнар Илдар кызы,

Балтач урта гомуми белем мәктәбе укытучысы, Балтач районы

Хезмәтнең максаты: Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗатына тулырак мәгълүмат бирү; авторның төрле иҗат жанрларында уңышлы иҗат итүен ассызыклау; укучыларда татар җырларына, театр сәнгатенә кызыксыну тәрбияләү.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның төрле елларда чыккан шигырь җыентыкларыннан күргәзмә, проектор, ноутбук

| тема | сораулар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Даталар | 10 | 20 | 30 | 50 | 70 |
| 2. Шигырьләр | 10 | 20 | 30 | 50 | 70 |
| 3. Жырлар | 10 | 20 | 30 | 50 | 70 |
| 4. Пьесалар | 10 | 20 | 30 | 50 | 70 |

Уенны башлыйбыз:

Тема “Даталар”

10 балл

Сорау: Гөлшат Зәйнашеваның туган елы, көне

Җавап:1928 елның 13 гыйнвары

20 балл

Сорау: Шагыйрә кайда һәм кайчан вафат була?

Җавап: 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була

30 балл

Сорау: Яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы ничәнче елда дөнья күрә?

Җавап: 1958 нче елда

50 балл

Сорау: «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем ничәнче елда бирелә?

Җавап: 1988 нче елда

70 балл

Сорау: 1930 нчы елда шагыйрә тормышында нинди вакыйга була?

Җавап:1930 елда гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, нәни Гөлшатны әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар

Тема “Шигырьләр”

10 балл

Сорау: «Пенсиягә» шигырендә нәни кыз кем исемле?

Җавап: Илсөя

20 балл

Сорау: Камил бакчасында нәрсәләр үстергән?

Җавап: көнбагышлар

30 балл

Сорау: Шагыйрә кайсы шигырендә ничә тапкыр гашыйк булдым дип яза?

Җавап: «Җиде тапкыр»

50 балл

Сорау: Бик тәртипсез малай Корбан турында шигырьнең исеме?

Җавап: «Корбан исемле малай турында әкият»

70 балл

Сорау: Рәсим кайсы фәнне сөйми?

Җавап: рәсем

Тема “ Җырлар”

10 балл

Сорау: Җырның исемен ата:

“...Кая гына китеп, кайларга бармадым,

Сагынып кайттым Иделем таңнарын...”

Җавап: «Туган җирем – Татарстан»

20 балл

Сорау: Кыз бала әнисенә өйрәнгән җырны кемгә өйрәтә?

Җавап: энесенә

30 балл

Сорау: Әйтеп бетер: «Менәргә иде …тауларына»

Җавап: Урал

50 балл

Сорау: «Кара мыек» җырының көен кем язган?

Җавап: Бәхти Гайсин

70 балл

Сорау: Әлеге юллар кайсы җырдан?

“...Яшьли сөйгән яр да

Ятка калды анда,

Әллә язмыш, әллә бер ялгыш булып...”

Җавап: «Яшь гомер»

Тема “Пьесалар”

10 балл

Сорау: «Гайфи бабай, өйлән давай!» нинди жанрда?

Җавап: комедия

20 балл

Сорау: К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән барган комедиясе

Җавап: «Гайфи бабай, өйлән давай»

30 балл

Сорау: «Тузган тораклар бетсен!» комедиясе Татарстандагы нинди зур вакыйгага багышлап язылган?

Җавап: Казан шәһәренең 1000 еллыгына

50 балл

Сорау: Хәдичә, Кәрим (Кәтүк), Касыйм (Касьян)нар кайсы спектакльдән?

Җавап: «Тузган тораклар бетсен!»

70 балл

Сорау: «Язмышлар һәм ялгышлар» драмасында кайсы сугышлар афәте сурәтләнә?

Җавап: Әфган, Чечня

Викторинага нәтиҗә ясау

**Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган**

әдәби кичә

(план- конспект)

Шакирҗанова Гүзәлия Зиннур кызы, Галимова Роза Зәкәрия кызы,

Мөхәммәдиева Дамира.Заһит кызы,

Кече Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Юґазы районы

**Тема:** Туган ягым – гөлләр иле

**Максат:** Укучыларны Гөлшат Зәйнашева иҗаты белән тирәнтен таныштыру. Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты аша укучыларда туган җиргә мәхәббәт, татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты буенча ясалган презентация, компьютер, мультимедия, китап күргәзмәсе.

Кичәнең барышы

I.Кереш өлеш

Кичә «Очрашу» (Г. Зәйнашева сүзләре, И.Шакиров көе) җыры белән башлана.

**Укытучы:** Хәерле көн, укучылар. Бүгенге әдәби кичә бик матур җыр белән башланып китте. Әлеге җырның авторларын беләсезме? Дөрес, “Очрашу “ җырының сүзләрен талантлы шагыйрә, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы Г.Зәйнашева язган. 13 нче гыйнварда Г.Зәйнашеваның тууына 95 ел.

1 нче слайд: «Тәрәз төбемдә гөлем бар,

Күчереп утыртсам, сула.

Йөрәгем – шул гөл яфрагы, –

Ерак калса ил туфрагы,

Өзелеп төшәрдәй була…» дип яза Гөлшат апа.

- Бу шигырь юлларын сез ничек аңлыйсыз? ( Гөлшат Зәйнашева туган җирен бик яраткан). Дөрес, укучылар. Шагыйрәнең бик күп шигырьләре туган якка мәхәббәт белән сугарылган.

- Ә хәзер 4 нче сыйныф укучылары безне Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы белән таныштырып китәрләр.

**1 укучы:** Г.Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр.2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында уза. Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була. Минзәләдән артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр. 4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар. Спектакль караганнан соң артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр. Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә яхшы билгеләргә генә укый.

**2 нче укучы**: Мәктәпне тәмамлаганнан соң башта педагогия училещесын тәмамлый, аннары 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бер үк вакытта театр училищесына йөреп, дәресләр ала. Әмма аңа я институтны, я театр училищесын сайларга кушалар. Ул институтны сайлый, ләкин концерт бригадалары белән бергә авылларга чыгып йөри, концертлар алып бара. Институтны тәмамлагач, Г. Зәйнашева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре, җырлары матбугат битләрендә күренә башлый.

1958 нче елда "Тыңларсыңмы җырларымны" исеме белән беренче китабы басылып чыга.

**Укытучы:** Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә шигырен тыңлап китәрбез .

“Күпме йөрдем“, “Кайтырмын мин туган ягыма“ шигырьләрен сөйлиләр.

**Укытучы:** Г.Зәйнашеваның туган җир, туган як турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйланадыр. Чөнки туган як белән бәйле тойгы һәркемнең күңеленә газиз. Туган як кеше өчен кадерле, изге булырга тиеш. Туган як темасы язучы иҗатында зур урын алып тора .

**“Туган җирем – Татарстан“ җыры** башкарыла ( А.Ключарев көе )

**Укытучы:** Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашева 100ләгән шигырьләр авторы. Ләкин ул бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда чагыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея- хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Гөлшат Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тарта килде. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең 100 гә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессиональ җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнде.

“Илле җыр” исемле китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия. Аның иҗатына танылган язучы Гариф Ахунов менә нинди бәя бирде:

“Гөлшат Зәйнашева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда Язучылар союзына член итеп кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул

иткән “Менәргә иде Урал тауларына”, “Китмә, сандугач” кебек рухи бай, романтик җыр текстлары дистәләп. Сүзләренә тәңгәл килә торган киң колачлы музыка белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп, бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр”.

Гариф Ахунов, Татарстанның халык язучысы. 1970 нче ел.

**Укытучы:** Әйдәгез, укучылар, хәзер “Күңелле безнең шәһәр” дигән җырны тыңлап китик әле. (1 нче сыйныф укучылары башкара)

**Укытучы:** Экранда Гөлшат Зәйнашеваның туган якка багышлап язылган популяр җырлар исемлеген күрәсез

“Туган җирем – Татарстан” (А. Ключарев көе)
“Китмә, сандугач” (Р. Яхин көе)
“Менәргә иде Урал тауларына” (М. Мозаффаров көе)
“Үз илемдә” (С. Садыйкова көе )
“Авылым гөлләре” (Фәрит Хатыйпов көе )
“Туган авылым урамы” (Г. Сәйфуллин көе)
“Газиз туган як” (Виталий Агапов көе)
“Гөлләр иле” (Сәлимә Шәмсина көе)

“ Яшел үзәнлек” (А. Хөсәенов көе)

“Таулар моңы” (И. Мәҗитов көе)

“Хәерле юл” (Ш. Капкаев көе

“Шундый безнең туган як” (А. Фәйзрахманов көе )

**Укытучы:** Бу җырлар туган якка мәхәббәт белән сугарылган. Туган җир, туган як, туган авыл... Һәркем өчен изге, газиз, кадерле ул. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, туган авылы бар. Кая гына барсак та, дөньяның иң матур җирләрендә йөрсәк тә, туган ягыбызны сагынып кайтабыз.

**“Сәяхәтче җыры “ башкарыла**.

**Укытучы:** Әйе, укучылар, чыннан да, шагыйрә Г.Зәйнашева бәхетен туган ягында, туган җирендә тапкан. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә дә яңгырый. Аның җырлары – мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк.

Җыр башкарыла. «Гөлләр иле» Г.Зәйнашева сүзләре, Сәлимә Шәмсина көе.

## Туган ягым – гөлләр, сөмбелләр иле

(Дәрестән тыш эшчәнлек, сыйныф сәгате, түгәрәктә куллану өчен методик эшкәртмә)

Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы,

«Адымнар – Әлмәт» полилингваль гимназиянең

башлангыч сыйныфлар укытучысы, Әлмәт районы

Максат: әдәбият, сәнгать әсәрләре, данлыклы шәхесләр эшчәнлеге аша туган якка, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү, данлы кешеләребезнең данлы эшләрен дәвам итәргә өндәү, лаеклы алмаш булу турында уйландыру

Җиһазлау: туган якка багышланган презентацион материал, шагыйрә Г.Зәйнәшева иҗатын яктыртучы буклет, плакатлар, “Нәрсә берләштерә?” уены өчен материаллар.

Дәрес барышы.

Укытучы. Туган ил! Нәрсәдән башлана соң ул? Туган ил “әннә” дип ачылган туган телдән, әни укыган әкиятләрдән башлана, минемчә. Бүген безнең класс сәгатенең темасы “Туган ягым – гөлләр, сөмбелләр иле”. Моның шулай булуын раслау өчен, экранда барган презентацияне карау да җитәр дип уйлыйм.

(Презентацияне карау)

Укытучы. Укучылар, дәресебезнең атамасы презентациянең соңгы слайдында да кабатладым. Ни өчен дип уйлыйсыз?

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Әдәбиятта эпифора дигән төшенчә бар. Әйдәгез “Әдәбият сүзлеге”ннән аңлатмасын карап алыйк әле. (“Әдәбият сүзлеге” белән эш).

Укытучы. Эпифора аша без игътибар итәргә кирәкле мәгълүматны күрсәтәбез. Хәзер менә шушы слайд белән әлеге портретны нәрсә бәйләвен аңлатып карагыз әле.

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Игътибарны тагын экранга юнәлтәбез.

(Г.Зәйнәшева турында мәгълүмат бирелә)

Укытучы. Хәзер менә бу ике рәсемне нәрсә бәйләвен ачыклап карагыз әле, укучылар. (Г.Зәйнәшева портреты һәм нота станы рәсеме күрсәтелә).

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Г.Зәйнәшева – бик күп җырлар авторы. Аның шигырьләренә бик күп композиторлар көй язган. Дәресебезнең темасы булган юллар да бик матур җыр сүзләре. Шушы матур җырны тыңлап алыйк.

(“Гөлләр иле” җыры яңгырый. Сәлимә Шәмсина көе, Гөлшат Зәйнәшева сүзләре)

Укытучы. Бик матур җыр яңгырады, укучылар. Инде хәзер алдагы бирем. Бу ике рәсемне нәрсә берләштерә икән? (Г.Зәйнәшеваның җырлары җыентыгы һәм Г.Тукай рәсеме күрсәтелә)

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Г.Зәйнәшеваның Җырлар җыентыгы әдәбият өлкәсендәге иң зур бүләккә – Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Хәзер республикабыз картасына игътибар итегез әле, укучылар. Гөлшат Зәйнәшеваны Сарман районы, Тукай районы, Минзәлә төбәге дә үз шагыйрәсе дип саный. Ник икәнен беләсегез килсә, классташыгызны тыңлыйбыз.

Алдан әзерләнгән укучы Г.Зәйнәшеваның балачагы турында сөйли.

Укытучы. Инде, укучылар, менә бу ике рәсемне нәрсә берләштерә микән? (Сара Садыйкова белән Г.Зәйнәшева рәсемнәре күрсәтелә).

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Сара Садыйкова – татар халкының йөзек кашы. Ул безгә бик тә бай рухи милли хәзинә калдырып китте. “Сара апа үзенә һәм башкаларга таләпчән, халыкка тирән ихтирамлы, югары музыкаль белемгә ия, сәхнә аның стихиясе, сизгер күңелле, җор телле, хәрәкәтчән, дәртле, зыялы,” - дип язды аның турында шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева. Сара

апа дан-шөһрәт алдында да баш имәгән горур һәм мәгърур җан. Бөтен гомере буе сәнгатькә гашыйк, сәнгатькә хезмәт иткән, кырык ел сәхнәдән төшмәгән, зарланып, елап, йөрәк әрнүләрен кешегә күрсәтеп яшәмәгән. Сара апа бик күп йөри, йөрергә бер дә иренми торган җан иясе була. Ул Татарстанны аркылыга, буйга йөреп чыга. Гөлшат апа белән аларны әнә шундый сыйфатлар берләштерә. Г.Зәйнәшева –легендар шәхесләребез турында хатирәләр дә туплап калдырган шагыйрә.

Г.Зәйнәшева белән С.Садыйкова иҗат иткән җырлардан өзекләр тыңлатырга мөмкин.

Укытучы. Хәзер бу рәсемнәрне карагыз. Бу ике шәхесне нәрсә берләштерә?

(А.Ключарев белән Г.Зәйнәшеваның рәсемнәре күрсәтелә).

Укучыларның җавапларын тыңлау.

Укытучы. Аларны укучылар, шундый матур бер җыр берләштерә. "Туган җирем – Татарстан" дип аталучы бу җыр бөтен бәйрәмнәрдә яңгырамый калмый. Шушы җыр белән бүгенге дәресебезне тәмамлыйбыз. Туган җирдә, тынычлыкта яшик, данлыклы милләтәшләребезгә алмаш булыйк, аларны хөрмәт итик.

"Туган җирем – Татарстан" җыры яңгырый.

## Тел өйрәнгәндә Гөлшат Зәйнашева иҗаты һәм фигыль турында төшенчә бирү

(4 нче сыйныфның татар төркемендә туган (татар) тел дәресе)

Шакирова Эльмира Финус кызы,

Җәлил гимназиясе укытучысы, Сарман районы

Тема: Тел өйрәнгәндә Гөлшат Зәйнашева иҗаты һәм фигыль турында төшенчә.

Максат: тел өйрәнгәндә Гөлшат Зәйнашева иҗатын файдалану һәм фигыль турында төшенчә бирү.

Планлаштырылган нәтиҗә: Г.Зәйнашева шигырьләреннән фигыльләрне таба, башка сүз төркемнәреннән аера һәм куллана белү .

Танып-белү: эзләнү, җавап бирү өчен Г.Зәйнашева шигырьләреннән кирәкле мәгълүматларны табу, фигыль моделен төзү, кагыйдәне чыгару.

Коммуникатив: укытучы белән диалогка керү, төркемнәрдә фикер алышуда катнашу, үз фикереңне әйтү.

Регулятив: укытучы күрсәткән ориентирны аңлау, укытучы белән берлектә яңа материалны ачу.

Шәхси: якташыбыз Г.Зәйнашева иҗатына кызыксыну белдерү, туган төбәгең өчен намуслы хезмәт итү теләге уяту, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләүгә шартлар тудыру.

Дәрес тибы: яңа белемне үзләштерү дәресе.

Җиһазлау: компьютерда слайдлар, карточкалар, тест сораулары, "Сүз төркемнәре" модельләре, Г.Зәйнашева портреты, китаплары, рәсемнәр, ребус.

Дәрес барышы.

I.Психологик уңай халәт тудыру. (Талгын гына музыка уйный.)

- Хәерле көн, укучылар! Мин сезнең иң тырыш, иң булган укучылар икәнегезне беләм. Күзләребезне йомдык. Минем арттан кабатлыйбыз һәм куллар белән күрсәтәбез.

- Мин гимназиядә.

- Мин күп белергә телим.


- Мин игътибарлы.

- Минем кәефем шәп!
Бер-беребезгә карап, иптәшләребезгә елмаю бүләк итик әле.
II.Актуальләштерү. 1. “Тиз җавап” уены
Ла-ла-ла
Казан безнең башкала.
Та-та-та
Туган ягын ярата.

2.Өй эшен тикшерү. Якташыбыз Г.Зәйнашева иҗатыннан алмашлыклы шигырь исемнәрен язып алырга. (Укучылар укыйлар: “Шундый безнең туган як”, “Кем булырга?” , “Әллә кемне күңел сагына” “Син икәнсең”, “Мин бит кара карлыгач” "Безнең бакчада", “Татарча ничек?”...)

3. “Кем тизрәк?” уены.
- Әйдәгез, ребусны чишик әле. Монда кем турында сүз бара?
Слайд №2 Ребус чишү.

-Аны ничек




Гөлшат Зәйнашева Татарның жыр сандыгы


- Әйе, Г.Зәйнашеваны татарның җыр сандыгы дип атаганнар. Чөнки ул бик күп җырларның авторы. Аның илле җырдан торган китабы да чыккан. Бик күп композиторлар аның сүзләренә язылган шигырьләргә көйләр иҗат иткәннәр. Җырчыларыбыз бүген дә Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырларны бик яратып башкаралар, ә без рәхәтләнеп тыңлыйбыз.

Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

1. Картинаны җанландыр! Слайд №3,4

- Укучылар, картинада нәрсәләр күрәсез? ( Төн. Утлар. Авыл. Йолдызлар. Җил. Агачлар.) - Ә хәзер җөмләләрне җанландырыгыз. (Төн житте. Утлар сүнде. Авыл йоклый. Йолдызлар җемелди. Җил исә. Агачлар селкенә. Тиздән таң атар. ) -Нинди сүзләр картинаны җанландырды? Алар нәрсәне белдерә? Бу сүзләр ничек атала? Фигыль турында нәрсәләр беләбез? Нинди сорауларга җавап бирә? Хикәя фигыль нәрсәләр белән төрләнә?

( Кагыйдәне чыгару, дәреслектән уку, модельләштерү) Слайд №5



2.Матур язу күнегүләре. Кк Җҗ Сс Уу Яя Шушы хәрефләр белән башланган предметның эшен һәм хәрәкәтен белдергән сүзләрне язарга. (Киенә, җырлый, сибә, утыра, яра.) Үзбәя.

3. Күнегүләр эшләү. Карточкада бирелгән Г.Зәйнашеваның "Татарча ничек?" дип исемләнгән шигырен уку. Сүзләргә сорау куеп язарга, фигыльләрнең астына ике сызык сызарга.

- Бу шигырьдә нәрсә турында сүз бара?

- Бу шигырьдә малайның туңдырма ашыйсы килә, ләкин ул татарча белми. Әбинең "телеңне йотма" сүзенә ике төрле мәгънә салынган. Әби туган телеңне онытма, дип әйтергә тели.

- Әйе, без сезнең белән үзебезнең туган телебез – татар телен бик әйбәт белергә тиешбез.

4. Г.Зәйнашеваның "Кояш гомере" шигыре өстендә парларда эш.

Шигырьнең эчтәлеге буенча предметны белдергән сүзләргә эшне белдергән сүзләрне табып язарга.

Кояш гомере

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп,
Өйрәткән энесенә:
"Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә;
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!"
Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар.

Слайд №6

| Кояш | Кыз | Чишмәләр | ... |
|---|---|---|---|
| балкый | чыгарган | ишеткән | ... |
| сибә | өйрәткән | | |
| ... | ... | | |

-Шагыйрь бу шигыре белән безгә нәрсә әйтергә тели?

-Әниләр безнең иң кадерле кешеләребез. Без аларны тыңларга, кадерләргә тиеш.

Ял минуты

5. 242 нче күнегү. (1) 1 укучы тактада , башкалар урыннарда.

(2) укучылар мөстәкыйль эшлиләр, парларда тикшерәләр.

6. Карточкалар белән төркемнәрдә эш. (Сыйныфтагы укучылар тел белгечләренә, тикшерүчеләргә, корректорларга бүленә)

1. Тел белгечләре. Шигырьнең авторын һәм исемен әйтегез. Астына сызылган сүзләрнең фигыль икәнен исбатлагыз. (Нинди фигыль, заманы, зат-саны, барлыкта яки юклыкта.)

Әбиемне яратам

Мин үзем шәһәрдә яшим,

Авылга кайтам җәен.

Чөнки ул авылда яши

Яраткан әбекәем.

Мин үскәч, әбием белән

Авылда торачакмын.

Әбием картаеп киткәч,

Ярдәмче булачакмын. (Г.Зәйнашева)

2. Тикшерүчеләр. Шигырьдән фигыльләрне табып, зат-санын һәм заманнарын билгеләгез.

Йокла, куяным!

Аю, төлке, бүре, керпе-

Барчасы йоклап киткән.

Бишек җыры җырлый, әнә,

Йолдызлар зәңгәр күктән.

Ай калыкты, төн җитте,

Йоклыйк инде, куяным,

Үз яныма сиңа да

Урын җәеп куярмын. (Г.Зәйнашева)

3.Корректорлар. Шигырьнең авторын һәм исемен әйтегез. Күп нокталар урынына тиешле фигыльләрне куегыз һәм аларның юклык формаларын әйтегез.

Иртәнге җыр

Таңны мактап талларда

Кошлар канат _______ .

Тамчы гөлләр тирбәнеп,

Алкаларын _________ .

Күбәләкләр уянып,

Канатларын _________.

Кондызлар җемелдәвек

Ефәк күлмәген ______.

Чәчәкләр чык суында

Коенып ________.

Балкортлары безелдәп

Чәчәкләргә _______.  (Г.Зәйнашева)

(Белешмә өчен сүзләр: тактылар, кундылар, җилпеде, юындылар, кактылар, киде.)

7. – Укучылар, без кайсы шагыйрәнең шигырьләре белән таныштык? Аның турында сез нәрсәләр беләсез?  (Укучылар җавабы)

Сарман ягы талантларга бик бай. Бүгенге көндә Сарман районыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыккан. Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр, сәхнә әсәрләре дә иҗат иткән  Гөлшат Зәйнашева да бар.

(Г.Зәйнашеваның  тормышы һәм иҗаты турында  кыскача мәгълүмат бирелә)

8. Рәсемнәргә карап, Г.Зәйнашева турында җөмләләр төзергә. Җөмләләрдә фигыльләрне  өч заманда  да кулланырга. Слайд №7




9.Дәфтәргә әйтеп яздыру.

Гөлшат Зәйнашева Иске Теләнче  авылында туган. Ул балалар өчен “Асия”, “Кояш гомере”, “Әбиемне яратам”  китапларын чыгара. Киләчәктә дә  балалар Г.Зәйнашеваның шигырьләрен яратып укырлар. (Фигыльләрнең асларына ике  сызык сызарга, заманын, зат-санын билгеләргә)

Укытучы.  Укучылар, без үзебезнең Сарман районында яшәвебез белән хаклы рәвештә горурланабыз. Г.Зәйнашева, С.Рафыйков, Ә. Габиди, Х.Хәйруллин, Ф. Яхин, Д.Гарифуллин, А. Гыйләҗев, М.Маликова, И. Шакиров, Зөһрәләр исеменә тап төшермичә тырышып укырга, тәртипле, тәрбияле булырга тиешбез.

IV. Рефлексив  кабатлау.

- Без бүген фигыль турында нәрсәләр  белдек? Ничек белдек?  (Фигыль моделен парларда төзү) Фигыль турында без барысын да белеп бетердекме әле? (Алдагы дәрескә проблемалы сорау кую)

Яшел түгәрәк – дәрестә миңа күнегүләрне эшләргә җиңел булды, белгәннәремне башкаларга да аңлата алам.

Сары  түгәрәк – мин аңладым, барлык күнегүләрне дә үзем эшләдем.

Кызыл түгәрәк – мин күнегүләрне иптәшләрем ярдәмендә эшләдем.

Өстәлдәге смайликларны сайлап эшегезне бәяләгез,  түгәрәкләрне тактага элебез

V.  Йомгаклау.  Билгеләр кую.

Өй эше: 1. Г.Зәйнашеваның  "Чәчтем шалкан"  шигыреннән хикәя фигыльләрне табарга һәм юклык формасына куеп  язарга,  2) Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырларны тыңларга, исемнәрен дәфтәргә язарга

## Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә иҗат ителгән җырлар тарихы

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган

әдәби кичәнең план-конспекты)

Ганиуллина Римма Ясир кызы,

Сарман гимназиясе педагог-китапханәчесе,

Хаҗиева Равия Рафаиль кызы,

Сарман гимназиясе башлангыч сыйныфлар укытучысы

Максат: Укучыларны Гөлшат Зәйнашева иҗаты белән тирәнтен таныштыру. Гөлшат Зәйнашева җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану якташ язучыларыбыз белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Әдәби-музыкаль кичә “Җыр бүләк итәм”

(өлкән сыйныфлар өчен)

Җиһазлау: Г.Зәйнашева китапларыннан күргәзмә, якташ язучыларыбыз иҗатына багышлап чыгарылган стена газетасы, иҗади эшләр, мультимедейный проектор, презентация, плакат, аудиоязмалар.

Плакат: Тагын күрешергә булсын,

Хушлашмый китәм.

Искә алып бер җырларсыз -

Җыр бүләк итәм.

Җырларым бар, моңнарым бар

Йөрәк түремдә.

Җыр белән чын дуслар таптым

Туган җиремдә.

(Г.Зәйнашева “Хушлашмый китәм”)

Кичә барышы:

Язмада Марат Файрушин башкаруында “Чишмә башы” җыры яңгырый Гөлшат Зәйнашева сүзләре.

1нче алып баручы: (Плакатны кычкырып укый) дип яза Г.Зәйнашева үзенең “Хушлашмый китәм” җырында. Әйе, искә алып бер генә түгел күп тапкырлар җырлар өчен халык күңеленә үтеп керерлек җырлар бүләк итеп калдырды шагыйрә Гөлшат Зәйнашева.

Җырларда җырланган зәңгәр таулы Сарманнан булуыбыз белән горурланабыз без. Челтерәп аккан чишмәләре, киң кырлары, халкының күңел байлыгы, туган телгә мәхәббәте күпме җырчыларга, шагыйрьләргә, язучыларга илһам биргән. Элеккеге Сарман районы ИскеТеләнче авылы кызы Гөлшат Зәйнашева турында сүз кузгалганда да горурлык хисләре кичерәбез. Бала чагы, яшьлеге Минзәлә районы авылында үтсә дә чишмә башы Сарман җирендә бәреп чыккан шул.

2нче алып баручы: 2023 елның 13 гыйнваренда Гөлшат Зәйнашевага 95 яшь тулды. Әлбәттә, шушы юбилей көннәрендә якташыбызны искә алмый мөмкин түгел.

Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес.Ул 1960-1990 елларда татар җыр сәнгатен тулысынча биләп ала. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан Г.Зәйнашева шигырьләренә йөзгә якын көй язылган. Һәр җырчы аның иҗатыннан үзенең репертуарын баета, концерт программасын бизи.

Шагыйрәнең җыр текстлары йөрәккә үтеп керердәй мәгънәле һәм гади, халыкчан, ачык аңлаешлы, музыкаль аһәңе белән аерылып тора торган итеп язылган. Шуңа күрә, композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп популяр җырлар язганнар. Иң популяр җырлар тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Гөлшат Зәйнашева Республикада хатын-кызлардан беренче булып 1991 елда Г.Тукай исемендге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Ә хәзер шул җыетыкка кергән һәм соңыннан да иҗат ителгән берничә җырнын тарихына күз салыйк.

Сөембикә журналында даими чыгып килүче “Бер җыр тарихы” рубрикасын дәвам итеп без Гөлшат Зәйнәшева җырларының язылу тарихы турында сөйләшербез, ул җырлар сәхнәдән дә, аудиоязма буларак та яңгырар.

Моңлы авыл Тәкермән җыры

(Гөлшат Зәйнашева. Истәлекләр, мәкаләләр. Казан, ТКН,2011. Марс Гаитов “Җырга багышланган гомер”, 11нче бит)

1нче алып баручы: 1930 елда Гөлшат Зәйнашеваның әтисен Хисам абыйны кулак дип Архангельск өлкәсенә сөрәләр. Берсеннән-берсе кечкенә 4 бала белән йорт-җирсез, ач, ялангач калган әнисе ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы Минзәлә районы югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Бу авыл, балачак хәтирәсе булып, булачак шагыйрә күңелендә гомерлек якты эз калдыра.

Нинди авыл ул дисәгез

Моңлы авыл Тәкермән.

Китсәң- сагынып кайтасың

Мәңге чыкмый хәтердән .

Бик күп еллардан соң, инде танылган шагыйрә Гөлшат апа “Моңлы авыл Тәкермән” дигән Ринат Гобәйдуллин көен язган җырында үскән авылын әнә шулай зурлый.

“Моңлы авыл Тәкермән” җырының аудиоязмасын тыңлау

Буразналар җыры тарихы

(Марс Гаитов. “Казан утлары” № 1, 2008)

2нче алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның туганы Марс Гаитов әлеге җыр туу тарихы турында истәлекләр белән уртаклаша: “Ә менә бер мәгълүм җыры - нәкъ менә безгә килүе истәлеге. 1963 елда без хатыным Венера, шул елны туган кызыбыз Алсу белән Минзәлә янындагы совхозда яшәгәндә, Гөлшат апа, юл уңае дип, бер генә кичкә безгә килде. Дүрт чакрым араны ул кичен, кояш баеп караңгы төшә башлагач, юлы-ние белән яңа гына сөрелгән басу аша буразналар таптап, җәяү үткән. Зарланмады, уфтанмады, ә без аның килүенә бик шатландык.

Соңыннан үзе сөйләде, “Буразналар” җырының сүзләре аның күңелендә шул чакта басуда туган икән. Буразналарны ул гармун сыры белән чагыштыра, көмеш сабаннар җыры итеп тыңлый һәм хезмәт шавы, кошлар җыры белән баета:

Буразналар, буразналар

Йөгерек дулкыннар.

Буразнамда игенкәйләр

Күкрәп уңсыннар!

Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи бу сүзләргә дәртле, матур көй язды, оста җырчылар башкаргач, ул популяр җыр булып китте.”

Укучылар башкаруында “Буразналар” җыры яңгырый

1нче алып баручы: Алдагы рубрикабызны “Көйне таны” дип атадык. Тәнкыйтьчеләр ялгышкан дип тә атыйсым килә минем аны.

( Сагыналар сине якын дуслар. Г.Зәйнашева “Сагыну”, Казан,ТКН, 1991)

Алга таба тарихлары сөйләнәчәк җырларның көйләрен танырга кирәк булачак. Шуңа күрә игътибар белән тыңлавыгыз сорала..

2нче алып баручы: а) Җырчы шагыйрьләрне күбрәк мәхәббәт җырлары яза дип шелтәлиләр. Алар турында матбугатта язып, язучылар җыелышларында сөйләп шау-шу күтәрүләр булып ала. Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, Н.Дәүли кебек олпат язучылар да Г.Зәйнашеваны җырлар авторы буларак танырга теләмәгәннәр.

Ул үзе бу турыда болай дип әйтә: “Яза башлавымның беренче елларында, минем иҗатыма еш кына усал-усал тәнкыйть сүзләре яудыралар иде. Җыелышларда яшь язучылар турында сүз чыкса, тәнкыйть өчен мисал итеп минем берәр шигыремне яки җырымны алалар да теткәләп ташлыйлар. Мин өемә кайтып җиткәнче елый-елый кайта идем. “Менәргә иде Урал тауларына” җырым өчен, йә Хода, күпме эләкте миңа?! “Хәзер без космоска менәбез, ә Гөлшат тауга да менәлмәү турында яза”, - диделәр өлкән язучыларыбыз”. Нәкъ шушы җыр аны - җыр язучы шагыйрә, Илһам Шакировны зур җырчы итеп танытты. Композитор Мансур Мозаффаров белән бергә иҗат иткән бу әсәр - җыр сәнгатебезнең алтын фондына кертелде

1нче алып баручы: б) Аналарга багышлап 1960 елда язылган һәм тиз арада җырлана башлап, популяр булып киткән “Кояш гомере” җыры да тәнкыйтькә эләгә. “Кояш гомере диган сүз юк бездә, халыкта булмаган сүзне кертеп җыр язмыйлар”, - дип чыгыш ясый язучылар җыелышында бер тәнкыйтьче. Ярамыйга карамый: җыр күңелләрне яулады, аны балалар гына түгел, олылар да җырлый. Ансат кына истә кала торган, татар телен камил өйрәнергә булыша торган җыры ул шагыйрәнең. Фәтхерахман Әхмәдиев көй язган бу җыр әнкәйләргә карата булган олы хөрмәт һәм мәхәббәт белән сугарылган , бүгенге көндә дә әнкәйләргә гимн булып яңгырый.

2нче алып баручы: в) Күренекле композиторыбыз Сара Садыйкова турында Гөлшат Зәйнашева: “Кайвакыт ул миңа әнием кебек тоела иде. Әллә әнисез үскәнгә, мин аңа әниемә елышкан кебек . серләремне сөйли идем, кайгы-хәсрәтләрем белән уртаклаша идем”,- дип яза. Яза башлавының беренче елларында усал тәнкыйтьчеләрдән саклап, яклап килә ул аны. Бу урында “Үз илемдә” (С.Садыйкова музыкасы) җырының тарихы кызыклы. Язучылар Фатыйх Хөсни, Нурихан Фәттах “ничек инде таллар кипаристан матуррак булсын, бәрәңге бакчасына дан җырлый, тар фикер йөртә”, - дип тәнкыйть итәләр. Ә Сара Садыйкова телефоннардан шалтыратып “исебез китми ул банан диган нәрсәгә., безнең кара ипиебез, бәрәңгебез яшәсен! Бәрәңге бакчасы, ындыр арты - безнең туган җиребез ул”, - дип бәхәсләшә. Җырны аңламый бер яклы фикер йөртә дип Нурихан Фәттахның үзенә тәнкыйть утлары яудыра.

1нче алып баручы: Гимназиябезнең музыка укытучысы Гөлнара Рәис кызы бездә кунакта. Ул синтезаторда шушы өч җырның көен уйнар. Ә сез нинди җыр икәнен әйтегез. Кушылып җырларга да мөмкин.

Димәк өч җырның “Менәргә иде Урал тауларына”, “Кояш гомере”, “Үз илемдә” җырларының көйләре яңгырый. Нинди көй икәнен әйтергә тырышыгыз.

(көйне танучыларга истәлек бүләкләре тапшырыла)

“Хушлашмый китәм” җыры

(Зөһрә Сәхәбиева Җыр бүләк итәм Сөембикә журналы, гыйнвар, 2018)

2нче алып баручы: Тукай районы белән Сарман районы чиге җирләре чишмәсе дә үзгә булгандыр мөгаен. Салих-Тукай кызы Зөһрә Сәхәбиеваны, Яңа Бүләк улы Илһам Шакировны, Теләнче-Тамак кызы Гөлшат Зәйнәшеваны туган җир генә түгел, җырга, моңга мәхәббәт, искиткеч талант та берләштерә. Язмыш аларны шагыйрә сүзләренә язылган җырлары аша да бәйли. Шагыйрә сүзләренә язылган җырларны Илһам Шакиров, Зәһрә Сәхәбиева җырлый. Зөһрә Сәхәбиева үзенең истәлекләрендә “Хушлашмый китәм” җыры тарихы турында мондый истәлекләр белән уртаклаша. “Без, артист халкы, көн саен, авыл саен күңелләрне алгысыта торган менә шундый дулкынландыргыч минутлар кичерәбез. Гастрольләребез икешәр-өчәр айга сузыла. Җыр-моң яраткан халкыбыз каршында ялындырып та тормыйбыз – күңелләре булганчы җырлыйбыз. Мин концертта егермеләп җыр башкарам. Татар халык көйләре, композиторларыбыз әсәрләре. Арада Гөлшат апа Зәйнашева сүзләренә язылганнары да шактый. Кайберләрен Гөлшат апа махсус миңа дип атап язды. Андый җырлар байтак. Искә төшереп утырам да менә хәзер, һәрберсенең кызыклы тарихы бар икән бит.

Алкышларга күмеп сәхнәдән җибәрми утырган тамашачыларыма саубуллашканда тагын киләбез тагын күрешәбез дигән мәгънә салып җырлыйсы килде. Баянчыбыз Рамил Курамшинга миңа яңа бер җыр кирәк дим. Ул бер көй язып тыңлатты. Ә сүзләр юк. Туктале, дим Гөлшат апа бар бит безнең язса – ул язар!”. Икенче көнне Гөлшат Зәйнашева Зөһрә Сәхәбиевага телефоннан әйтеп торып әзер көйгә “Хушлашмый китәм” җырының сүзләрен яздыра. Ә соңыннан бу җыр Хәйдәр Бигичев репертуарында да еш яңгырый башлый.

Гөлнара Раисовна башкаруында җыр “Хушлашмый китәм”

Туй җыры тарихы

(Ихсанова Л. "Җырны тиккә җырламыйлар". Г.Зәйнашевага 70 яшь // Сөембикә, 1998, №1, 166 нчы б.)

1 нче алып баручы: Гөлшат Зәйнашева үзе җыр яза башлавына җырчы Зифа Басыйрова сәбәпче дип саный. Бер көнне Зифа Басыйрова кереп, туйда булуын, матур көй отып кайтуын сөйли. Көйләп тә күрсәтә. “Яз әле шуңар бер матур шигырь”, - дип шагыйрәдән үтенә. Күп тә үтми, “Туй җыры”ның шигъри сүзләре туып, җыр сәхнәдән яңгырый башлый.

Икәү бергә утыргансыз,

Бергә булсын уегыз,

Икегез дә пар килгәнсез,

Котлы булсын туегыз. (Халык көе).

Туй җырының аудиоязмасы яңгырый

“Аерылмагыз” җыры тарихы

(Зөһрә Сәхәбиева “Җыр бүләк итәм”, Сөембикә журналы, февраль, 2018)

2нче алып баручы: Күренекле җырчы Әлфия Авзалова репетуарындагы җырларның 80%ы Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган җырлар була. Күбесенең авторлары Гөлшат

Зәйнашева һәм Зиннур Гыйбадуллин. Әлфия Авзалованың дусты, шагыйрә Гөлшат апа җыр текстын яза; аның ире, Әлфия Афзалова концертларында баянчы булып йөргән Зиннур Гыйбадуллин шул шигырьгә көй иҗат итә. Башта җырчыга күрсәтеп, җырлатып карыйлар, ул әйткәнчә үзгәртәләр, төзәтәләр.

1982 нче елда Әлфия Авзалова кызы Зөлфия кияүгә чыга. Яшь парлар үпкәләшеп йөргән көннәрнең берсендә Гөлшат Зәйнашева Зөлфия Авзалова-Нигъмәтҗановага "Тыңла әле, сезгә багышлап шигырь яздым!", - ди. Һәм "Аерылмагыз, булса да сәбәпләре...", - дип укый башлый. Әлфия Авзалова кызы белән киявен шулай дуслаштыра ул. Бераздан ул шигырьгә Чулпан Зиннәтуллина көй яза. "Аерылмагыз!" дигән популяр җыр - безнең җыр! Равил белән бергә яши башлаганга да 37 ел тулды. Ике кызыбыз, дүрт оныгыбыз бар. Ә җыр безнең гаиләнең кадерле бер ядкаре булып, - дип истәлекләре белән уртаклаша Зөлфия Авзалова.

Зал белән "Аерылмагыз" җырын башкару. Сүзләре алдан таратыла.

1 нче алып баручы: Шагыйрә буларак, Гөлшат апа бик бәхетле иҗатчы була. Язмыш аны композиторлар: Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Сара Садыйкова, Бәхти Гайсин, Фәтхерахман Әхмәдиев, Зиннур Гыйбадуллиннар белән очраштыра. Алар белән бергә иҗат иткән моңлы, дәртле җырларны башкарырга аның юлына атаклы җырчылар Әлфия Авзалова белән Илһам Шакировны чыгарып куйган.

2 нче алып баручы: Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше була. Тормыш аны төрлечә, ә кайчак аяусыз сыный. Әмма ул бөгелми, бөтен авырлыкларны җиңеп, урман эченнән чабып баручы зифа боландай алга омтыла. "Үзем турында" дигән шигырендә ул үзенең бөтен гомерен күздән кичерә, яшәвенең юкка түгел икәнен әйтә:

"Булды эш, хезмәттә җиңеп,

Данга ирешкән чакларым.

Якын дуслар белән шатлык,

Бәхет бүлешкән чакларым...".

1 нче алып баручы: Гөлшат апаның тагын бер матур ягы – ул бик өлгер, җитез, кыю була. Шушы урында аның тормышыннан кызыклы вакыйгаларны искә төшерәсе килә. 1942-1943 елларда Минзәләдә укыганда ягылмый торган тулай торакта яшүсмер кыз баланың мич чыгарып куюы, Актаныштa гастрольләр вакытында үтүк өстендә коймак пешерүе үзе генә дә аның характерын өр-яңа яктан ача. 55 яшендә җиңел автомобиль сатып алып, аны йөртергә өйрәнә, 70тә компьютерны үзләштереп, әсәрләрен шунда татар телендә яза башлый. Дөнья малына, байлыкка кызыкмый. Аның байлыгы – таланты, сәламәтлеге, гаиләсе һәм дуслары, халык мәхәббәте була. Васильево бистәсе тирәсендә, Идел буенда башка сәнгать әһелләре белән бергә җир кишәрлеге алып, бакча булдыра. Чәчәк үстерергә ярата, бигрәк тә хуш исле, ак төстәге сиреньнәрне.

2нче алып баручы: Гөлшат Зәйнашева алда телгә алынган җыр текстларын берсен дә иҗат итмәгән булса да, бары тик аның сүзләренә атаклы композиторыбыз Рөстәм Яхин иҗат иткән "Китмә, сандугач" җыры Гөлшат Зәйнәшеваның исемен мәңгеләштерелгән булыр иде. Бу җыр үлемсез. Бу җыр һәр концертта башкарылып килә һәм башкарылачак. Җырчыларның таланты шушы җырны башкару осталыгы белән билгеләнә. Татар милләтенең үлемсез җырлары: "Гөлҗамал", "Зиләйлүк", "Карурман", "Салкын чишмә" кебек җәүһәрләре белән рәттән "Китмә, сандугач" та гасырларда сакланыр.

"Китмә, сандугач" җырының аудиоязмасы

Җыр яңгыраганда кичә истәлеге итеп кәгазьдән ясалган ак сирень чәчәге тарату.

1 нче алып баручы: “Кеше китә – җыры кала” диләр. Әмма шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны китмәде диясе килә, чөнки әле ул моңлы жыр, шигърият булып бик озак еллар татар милләтенең йөрәгендә яңгырар, югалмас, яшәр.

**Туган ягым – гөлләр иле**

(9-11 нче сыйныф укучылары өчен Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына

багышланган әдәби –музыкаль кичә)

Шәймарданова Лилия Нур кызы, Соловьева Фәнүзә Фәнис кызы,

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми

белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат: Үзебезнең җирлектән, Сарман районыннан чыккан әдипләрнең иҗатлары белән таныштыруны дәвам итү. Укучыларның сөйләм телләрен үстерү, туган якка карата күңелләрендә ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Беренче алып баручы: Җырлы – моңлы Сарман ягыннан без.

Безнең нәсел монда көн иткән,

Кендек каны безнең монда тамган

Тамырлар да монда береккән

Икенче алып баручы: Сандугачлы Сарман ягы бит ул

Бәллүр сулы бездә чишмәләр

Сусаганга салкын суын бирер

Җыры белән җанны иркәләр

Беренче алып баручы: Зәңгәр таудан сиңа яулык болгар

Чыршы-нарат, сылу каеннар

Без дә генә печәннәре җиткән

Ал чәчкәле иркен болыннар

Икенче алып баручы: Күпме талант, күпме йолдыз чыккан

Шушы яктан, шушы туфрактан

Кеше иткән безне, моңлы иткән

Газиз, гүзәл җирем син – Сарман (Фәнүзә Соловьева шигыре)

Укучылар башкаруында Гөлшат Зәйнашеваның “ Гөлләр иле” җыры яңгырый. Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сәлимә Шәмсина көе.

Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлләр, сөмбелләр иле.
Гөлгә кунып сайрап кына
Үскән былбыллар иле.
Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.

Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.
Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлгә тиң таллар иле.
Ефәк кебек сызылып кына
Аткан ал таңнар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Туган ягым – гөлләр иле,
Борынгы Болгар иле.
Бүген көрәштә, хезмәттә
Җиңгән батырлар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Укытучы сүзе: Хәерле кич, кадерле балалар,хөрмәтле укытучылар, безне зурлап килгән кунаклар. Без бүген үзебезнең туган җиребез, моңлы җырларга күчкән сандугачлы Сарман ягыннанан чыккан талантларыбызны барлауны, аларның иҗатлары белән танышуны дәвам итәбез. Бүгенге кичәбезнең исемен юкка гына “Туган ягым – гөлләр иле “ дип атамадык.

Бу җырның сүзләрен Гөлшат апа Зәйнашева иҗат иткән, Сәлимә Шәмсина аны моңлы көйгә салган.

- Әйе, туган ягым – гөлләр иле. Туган як дип без бу якты дөньяга тәүге аваз салган һәм кендек каны тамган җирне атыйбыз. Гөлшат апа да 1928 нче елның энҗе ап-ак карлар явып торган бер матур ак мизгелендә 13 нче гыйнварында үзебезнең Сарман районы Иске Теләнче авылында якты дөньяга тәүге кат аваз салган. Тугач нәни кызчыкны ак биләүләргә биләгәннәрдер, тик менә:”Бәхетле бул, бәбкәм”, - дияргә онытканнар кебек. Шулкадәр ачы, мәрхәмәтсез язмыш аны киләчәктә үз кочагына алыр дип кем уйлаган? Бабасына хаҗ сәфәренә барган, кибет тоткан, тырыш кеше булганы өчен кулак дигән кара тамга тагыла. Инде туксанны куып барган картны авыл халкы җәлләп, аның урынына сөргенгә улын, Гөлшатның әтисен, җибәрергә дигән карарга киләләр. Менә шул чакта башлана да инде шагыйрәнең ачы язмышы. Ике яшьтә әтисез-әнисез калып, әтисенең апасы тәрбиясендә үсә Гөлшат.

Нәни кызчык, әнкәң назларыннан
Мәхрүм иткән сине ачы язмыш
Йөрәгеңдә булган сагынулардан
Йөзләреңне сарган сары сагыш
Елаганда, бәбкәм, елама дип
Юатучың булды микән, сабый ?
Газизләрен көткән яшьле күзен
Ул юллардан көн-төн ала алмый.
Төннәрендә кочагына алып
Җылытучы булды микән сине?
Җаннарыңны өшеткәндер, беләм

Ятимлекнең салкын, ачы җиле.
Сыналгансың ләкин сынмагансың
Тормыш дигән олы бу диңгездә
Авырлыклар сине чыныктырган
Синең юлың бүген үрнәк безгә (Фәнүзә Соловьева шигыре)

Әйе, балалар, Гөлшат апа авырлыкларны күп күрә. Минзәләдә укыган елларында бүлмәне җылытыр өчен таш һәм кирпеч ватыкларын җыеп алып кереп үзе мич чыгара, калай куеп, ашарга пешерер өчен урын да көйли. Бүлмәдәш кызларын шулай итеп туңулардан саклап кала ул. Кайнар ризык ашарга да мөмкинлек була кызларның.

Кая гына барса да, нинди генә эшләр башкарса да, кулак кызы дигән кара тамга аның артыннан калмый. Ул бу каршылыкларны да җиңәрлек көч-куәт таба үзендә.Ул аларны үзенең ялкынлы, дәртле әсәрләре белән һәрдаим җиңеп килә,бирешми.

Әйдәгез, балалар, Гөлшат апаның шул матур, дәртле шигырьләренә янәдән әйләнеп кайтыйк. Сезнең өчен җырлый татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәнүзә Фәнисовна. Гөлшат Зәйнәшева сүзләре, Рәүф Адилов көе,

Чишмә башы
1)Кайда безнең чишмә башы
Туктап калган агышы
Югалган чишмәләр кебек
Безнең милләт язмышы.
Кушымта
Таннарда чыгып эзләсәм,
Табармын чишмә башын.
Кайда безнең чишмә, диеп,
Сайрыйдыр минем сандугачым.
2)Балтырганнар өзә идем
Су буенда таллыкта.
Юлсыз жирләрдә адаштым
Сукмак эзләп бардым да.
Кушымта Таннарда чыгып эзләсәм,
Табармын чишмә башын.
Кайда безнен чишмә диеп,
Сайрыйдыр минем сандугачым.
3)Табар идем чишмә башын
Улаклар куяр өчен.
Шул чишмә буена килеп
Сабырлык жыяр өчен.
Кушымта Таннарда чыгып эзләсәм,
Табармын чишмә башын.
Кайда безнең чишмә диеп,
Сайрыйдыр минем сандугачым.

Укытучы сүзе : Нинди моңлы җыр.Бу җырга туган ягыбызның гүзәл табигате дә, милләтебезнең ачы язмышы да салынган. Рәхмәт,Фәнүзә Фәнисовна.Ә хәзер дәвам итеп укучыларыбыз башкаруында Гөлшат апаның төрле елларда иҗат ителгән шигырьләрен тыңлап үтик.

1 нче укучы:
Биек тауга менеп бер җырладым
Биек тауга менеп бер җырладым,
Таулар белсә белер хәлемне.
Йөрәгемнән ярсып чыккан җырым

Кыяларга барып бәрелде.
Ярсуларым инде чиктән ашты,
Яңа җырым ничек башларга?
Әллә үзем барып бәрелим микән
Шул таудагы кыя-ташларга?!
Кыяларга карап бер уфтандым,
Утлар булып чыкты сулышым.
Җырласам да, ярсып җыласам да,
Юк басылмас йөрәк сагышым.
Ярсуларым инде чиктән ашты,
Яңа җырым ничек башларга?
Әллә үзем барып бәрелим микән
Шул таудагы кыя-ташларга?!
2 нче укучы:
Иртәнге хисләр
Җырлый-җырлый чыгам язгы таңда
Хәтфә кебек, Идел кырына
Иртән сайрый сабан тургайлары,
Җылы бирдең минем җырыма.
Җырлый-җырлый китәм, ерак елга,
Юл елмая кояш нурына.
Кояш балкый, кояш үзе җырлый,
Җылы бирдең минем җырыма.
Җырлый-җырлый китәм урманнардан
Яз гөлләре үткән юлыма.
Бар табигать язгы вальсны көйли
Җылы бирдең минем җырыма.
3 нче укучы:
Мин тормышка гашыйк
Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.
Чишмәләрнең җырын отар идем
Җыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.
Озак яшәрмен диеп йөрәк тибә,
Ашкына күңелем һәр эшкә,
Әллә эшем бәхет китергәнгә,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Ә хәзер, укучылар, туган илебезнең икенче гимнына әйләнгән җырны тыңлап узыйк.Башкара 11 нче сыйныф кызлары.

Туган җирем – Татарстан
Идел ярларына нурлар сибеп
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем – Татарстан
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым

Иделем таңнарын.
Биш диңгезгә карап елмайгандай,
Балкый безнең Казан ерактан.
Коры җирне шаулы диңгез итә
Хезмәт сөйгән халкың, Татарстан.
Күпме җырлар җырлый халкым бүген,
Туган җирем, синең турында.
Мин бәхетле сине сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.

Укытучы сүзе: Укучылар, Гөлшат апаның драматургия өлкәсендә дә эшләве билгеле. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?», «Күктән төшкән кияү», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Тузган тораклар бетсен» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр халык театрлары сәхнәсендә зур уңыш белән бара.

Ә хәзер әйдәгез, 10 нчы сыйныф укучылары башкаруында“Язмышлар һәм ялгышлар” драмасыннан өзекне карап китик.

“Язмышлар һәм ялгышлар” драмасыннан өзек күрсәтелә.

(Авыл. Кичке эңгер-меңгер. Сәрвиназ яшәгән йортның капка төбе. Капкага велосипед сөялгән. Сәгатенә карап, Илсур басып тора. Велосипедка магнитафон куелган. “Сәрвиназ” җыры яңгырый. Сәрвиназ керә.)

Сәрвиназ. Илсур! ... Сәлам! Сәлам!

Илсур. Сәлам! Ай-һай, озак кайтасың эштән! Мәктәбеңә кердем, әллә кайчан кайтып китте, диделәр. Кайда йөрисең?

Сәрвиназ.Гуляйть итәм. Нигә ашыгып кайтыйм? Көтеп торучым юк ла.

Илсур. Ә мин? Мин?

Сәрвиназ. Син килерсең дип уйламадым да. Кичә сөйләштек бит инде, килмәскә диеп... Бу нинди концерт?

Илсур. Сиңа багышлап җыр чыгардым.

Сәрвиназ. Миңа багышлап? Рәхмәт! Әллә кайчангы бу иске җырны син чыгардыңмыни? Белми идем.

Илсур.Иске җыр димә. Бу җыр мәңге искермәячәк. Чөнки ул синең турында, Сәрвиназ! Сәр-ви-наз исеме гүзәл кыз турында! Кпзанга баргач, ярты зарплатамны түләп яздырып алып кайттым.Көне буе, төне буе тыңлыйм.

Сәрвиназ. Бичара! Мендәр урынына шушы тимер-томырны баш астына салып йоклыйсыңмы? Йә, йә, житте! Минем капка төбендә уйнатмый тор инде, авыл кешеләреннән уңайсыз! ( Магнитафонны туктата).

Илсур.Йә, хәлләр ничек? Ни яңалыклар бар?

Сәрвиназ. Кичә генә күрештек бит әле, ул арада нинди яңалык булсын? Менә синдә ни хәлләр бар? Кара давылда, коеп яңгыр яуганда кайтып киттең.

Илсур. Син шундый шәфкатьтез, мәрхәмәтсез булгач.....кундырмыйча....куып җибәргәч... Алты чакрымны саз ерып кайттым....велосипедымны өстерәп...

Сәрвиназ. Кундырмыйча... Кайда кунар идең?

Илсур. Әнә шул чоланда, шунда почмакта... бер мендәр жәлләдең.

Сәрвиназ. Илсур! Мин сиңа кичә дә әйттем бит, йөрмә, зинһар килеп...үтенәм синнән, килмә!

Илсур. Көн дә бер сүз: килмә дә килмә! Ничек инде килмим?

Сәрвиназ. Килмә дигәч килмә!

Илсур. Яратмыйсың син мине, яратмыйсың!

Сәрвиназ. Бәлки..Бәлки, минем сине яратырга хакым юктыр...

Илсур. Ничек инде хакың юктыр?

Сәрвиназ. Мин.. ни..

Илсур. Ярар, өзеп кенә әйт – яратмыйм мин сине, диген! Бу сүзне ишетү авыр булса да, түзәрмен.

Сәрвиназ. Илсур, син ачуланма миңа, үпкәләмә, мин сиңа турысын, дөресен әйтергә тиешмен... Без бит очраклы рәвештә генә танышкан кешеләр....

Илсур. Танышулар шулай очраклы рәвештә генә буладыр инде. Казаннан бер купеда кайтырга туры килүе очраклылык булса да, язмышыбыз булгандыр... Шул көннән соң мин бөтенләй яңа дөньяда яшим... Яңа кеше булдым. Моңа кадәр кемнедер яратам дип йөрүем ярату булмаган, мин чын ярату белән... чын мәхәббәт белән сине яратам! Яратам!

Сәрвиназ. Әкрен! Зинһар, әкрен!

Илсур. Давыл котырсын, яңгыр түгел, таш яусын! Алты түгел, алтмыш чакрым булсын – һәр кичне мин синең яныңа киләм.

Сәрвиназ. Хуҗа Насретдин ишәккә атланып йөргән, син велосипедка атланып... Хи-хи-хи!

Илсур. Әллә минем велосипедка атланып йөреүмнән хурланасың инде? Машинам да булыр әле, ашыкма!

Сәрвиназ. Юк ла! Нинди хурлану ди...

Илсур.Нигә килмә дип бәйләнәсең син миңа?

Сәрвиназ. Ах, Илсур! Сәбәпләре бар, сәбәпләре..

Илсур. Әһә! Вәгъдә биргән егетең бар? Шулаймы?

Сәрвиназ. Күпме әйттем инде – юк, минем бернинди дә егетем юк! Юк! Бу авылга килеп эшли башлаганыма ел ярым, укытучылардан башка кешеләрен дә белмим әле... Клублары ачылмый... Ачылса да бармасидем... Беркая йөрисем килми... Бер ямь таба алмыйм... Мин бит эшкә дә аптыраганнан гына килдем бу авылга, җанны кая куярга белмәгәннән.

Илсур. Күңелеңдә синең нindидер серләр бар, серләр... Сөйләмисең генә...

Сәрвиназ. Сөйли алмыйм! Илсур, бар кайт инде, фатир хуҗаларыннан уңайсызланам, көн дә киләсең!

Илсур. Ишәгеңә атланып....

Сәрвиназ. Йә, йә, ачуланма, шаярып кына әйттем бит....

Әнә тагын болытлар куера. Тагын яңгыр явар....

Беренче алып баручы: Сәрвиназ белән Илсур, кызганычка каршы, бергә була алмыйлар, Әфганстандагы сугыш аларны мәңгегә аера. Илсур һәлак була.

Укытучы сүзе: Рәхмәт, балалар. Бик оста башкардыгыз.

Менә, балалар, бүген сез Гөлшат апаның нинди күпкырлы талант иясе икәнен белдегез. Әйе, нинди генә авырлыклар күрсә дә бирешмәгән, горур булган, тормышны чын мәгънәсендә яраткан көчле шәхес ул. Аның тормыш юлын үзегезгә маяк, өлге итеп алыгыз, кадерле балалар.  Ә моңлы, дәртле җырлары кергән “Илле җыр” китабы өчен 1991 нче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды Гөлшат апабыз.

Бүгенге кичәбезне Гөлшат апаның “Авылым гөлләре” дигән җыры белән тәмалыйбыз

Гөлшат Зәйнәшева сүзләре,Фәрит Хатыйпов көе

Илләребез, күкләребез тыныч, аяз булсын. Һәр өйдә бәхетле, Әти-әниле, сәламәт сабыйлар көлүе яңгырасын дигән теләктә бүгенге кичәбезне тәмамлыйбыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Көн исемнәре**

(Зурлар төркеме балалары белән үткәрелгән шөгыль конспекты)

Нуриева Миләүшә  Вәгыйз  кызы,

Җәлил бистәсенең  5нче номерлы” Әкият”

балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Шөгыльнең максаты:

–атна көннәренең исемнәрен дөрес әйтү  күнегүләре аша яңа сүзләр өйрәнү, балаларның  истә калдыру, ишетү  сәләтләрен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү;

сүзләрне авазларга таркату, грамматик яктан дөрес итеп җөмлә төзү башлангыч күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү;

кул чукларының һәм бармакларның хәрәкәтчәнлеген камилләштерү.

Җиһазлау.  Саннар макеты, уен өчен туп, “Бер атнада ничә көн?” җырының язмасы.

Шөгыль барышы

I. Оештыру  өлеше.

- Исәнмесез, балалар. Сез бүген бигрәк матурлар. Барыгыз да чиста-пөхтә киенгәнсез. Шуңа да әнә безгә тәрәзәдән кояш карап, елмаеп карап тора.

Балалар, тактадагы схемага карагыз әле. Бу схемада безнең саннар бирелгән. Әйдәгез бергәләп санныйбыз. (10га кадәр санау оештырыла).  Безнең 10 санныбыз 10 фатирда яши. Шуларның өчесе кунакка киткән дә кайтмаган. Ә сез ял көннәрендә кунакка бардыгызмы? (Балалардан сораштыру үткәрелә. Җөмләләрнең  дөрес төзелгән булуына игътибар итәбез).

Ә менә өч сан кунактан кайтмаган. (8, 9, 10 саннары ябыла). Әйдәгез бергәләп калган саннарны әйтеп чыгабыз. Бергәләп саныйбыз. (Санау оештырыла)

Менә бу җиде сан янына бүген кунаклар килгән, балалар. Болар без сезнең белән үткәрә торган көннәр. һәр көннең исеме була.

(1 санын алып ) Менә бу сан янына дүшәмбе кунакка килгән. Кабатлагыз әле. (Кабатлау күнегүләре). Ялдан соң беренче көн бу, балалар. Бүген менә дүшәмбе көн.

(2 санын алып) Менә бу сан янына сишәмбе кунакка килгән (кабатлау күнегүләре). Иртәгә безнең сишәмбе булачак.

(3 санын алып). Менә монысы янына чәршәмбе кунакка килгән (кабатлау күнегүләре). Алар бергәләп чәй эчәләр.

(4 санын алып) Менә бу сан янына пәнҗешәмбе кунакка килгән (кабатлау күнегүләре).

(5 санын алып) Менә бу сан янына җомга кунакка килгән (кабатлау күнегүләре). Бабайларыгыз бу көнне күбесе мәчеткә бара, шулай бит?!

(6 санын алып) Менә бу сан янына шимбә кунакка килгән (кабатлау күнегүләре). Әй күңелле көн бу. Авылга кайта торган, юына торган көн.

(7 санын алып) Менә бу сан янына якшәмбе кунакка килгән (кабатлау күнегүләре). Бу көнне бөтен гаилә белән җыелабыз. Ял итәбез.

Ялларны ничек үткәрдегез соң, балалар? (1-2 баладан сорашу, җөмләләрнең дөрес төзелгән булуына игътибар итәбез).

II. Ял моменты

Кулларны алга сузыгыз, балалар. Бармакларны җәябез дә, бармаклар белән көн исемнәрен санап барабыз.

III. Музыкаль өлеш.

Минем сезгә бер күчтәнәчем бар. Иркенләп утырыгыз әле, балалар. Аркаларыгызны урындыкка терәгез. Күчтәнәчем – бик матур җыр. Сез тыңларга әзерме? (“Бер атнада ничә көн?” җыры яңгырый. Г.Зәйнәшева сүзләре, Екатерина Шатрова музыкасы)

Җырны аңладыгызмы? Ул без өйрәнгән көннәр турында, шулаймы? Матур җырмы, балалар? Аны менә шушы шагыйрә апабыз язган (портреты күрсәтелә). Гөлшат апагыз Зәйнәшева бу. Аның шигырьләре бик күп. Аларның күбесе җыр булып киткән. Әле генә без аның бер җырын ишеттек.

IV. Уеннар.

а) - Әйдәгез хәзер уйнап алабыз. Мин сезгә җөмләнең башын әйтәм, ә сез әйтеп бетерегез, яме.

Дүшәмбе көнне без ....... (Берничә көн атамасы белән җөмләләр төзиләр).

ә) “Әйтеп бетер” уены.

Дү (шәмбе), си(шәмбе), чәр (шәмбе) һ.б.

б) “Туплы уен”

Балалар, әйдәгез түгәрәк булып басыйк әле. Мин тупны берегезгә ыргытам һәм бер сан әйтәм. Сез миңа кире тупны ыргытасыз һәм шул сан белән туры килгән көн исемен әйтәсез. (Бер- дүшәмбе, ике – сишәмбе һ.б.)

V. Йомгаклау өлеше.

Балалар, урыннарга утырышабыз. Көн исемнәрен кабатламасак, онытылалар. Кич белән эти-әниләрегезне, әби-бабайларыгызны тикшереп карагыз әле. Алар көн исемнәрен беләләр микән? Русча әйтмәсеннәр, татарча әйтсеннәр. Белмиләр икән, өйрәтегез. “Бер атнада ничә көн?” дигән җырны тыңлатырга да онытмагыз.

**Талант иясе Гөлшат Зәйнашева**

( Шагыйрәнең туган көнен билгеләп үтү кичәсе)

Шәймарданова Ландыш Атлас кызы,

Түбән Мактама 1 нче мәктәбе укытучысы, Әлмәт районы

Залда Г.Зәйнашева портреты, тормыш юлы һәм иҗаты белән бәйле презентация

Кичә барышы.

1 а.б Идел ярларына нурлар сибеп
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем –Татарстан

2. а.б. Күпме җырлар җырлый халкым бүген,
Туган җирем, синең турында.
Мин бәхетле сине сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.

1. а.б. Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа

2. а.б. 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, эти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә

1. а.б. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыга.

2. а.б. Г.Зәйнашеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар.

1 а.б. 1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга.

2 а.б. Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм, нигездә, мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темала гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары-бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Г.Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып килә.

1.а. б. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән

һәм профессионал җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнә.

2.а. б. Менә без яраткан шагыйрәбез, хәзер инде халык шагыйре, драматург Г.Зәйнашеваның тормыш юлы белән таныштык. Бүген аның туган көне. Шул уңайдан хәзер бераз аның иҗаты, шигырьләре буенча ярыш оештырып алырбыз. Уен өчен 5 кеше кирәк була. Хәзер музыка уйнаганда сезнең арада серле тартма йөри. Көй туктаганда ул кемдә кала, шул кешеләр бирегә чыга.

1.а.б. Сезнең арадан "Иң күп белүче", "Иң сәнгатьле шигырь сөйләүче" һәм "Иң тапкыр" сайлап алыначак. Беренче ярыш-блиц турнир. Хәзер мин тиз генә сораулар бирәм. Алар Г.Зәйнашева иҗатына, тормыш юлына караган. Кем күбрәк дөрес җавап бирер икән.

2. Гөлшатның балачагы кайда үтә?
3. Кайда җидееллык мәктәпне тәмамлый?
4. Кайсы училищеда укый?
5. Кайсы елларда КДПИ да укый?
6. Аның әсәрләре нинди җыентыкларда басыла?
7. Беренче шигырьләр җыентыгы ничәнче елда чыга, исеме ничек атала?
8. Нинди шигырьләренә көйләр язылган?
9. Кайсы композитор турында китап яза?
10. Кайсы елда вафат була?

2 а.б. Ә хәзер сез шигырь юлларыннан аның шигырь исемен әйтеп карарсыз.

1) Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, томышка.

("Мин тормышка гашыйк")

2) Юллар уздым, илләр гиздем,
Юкка гына гизмәдем.
Юллар узып, илләр гизеп,
Мин бит сине эзләдем.

("Син икәнсең")

3)Идел суы ага торыр,
Алысларга бара торыр.
Кылыч тотып килсә дошман,
Идел-суга бата торыр.
Кылыч тотып килсә дошман,
Идел-суга бата торыр.

("Идел суы ага торыр")

1а. б. Хәзерге уеныбыз шигырь язу. Сезгә конвертта 1 куплет шигырь бирелә. Сез аларны дөрес итеп тезәргә һәм шигырь юллары туры килергә тиеш.

2а. б. Без бүген Г.Зәйнашева турында истәлекләр белдек. Аның шигырьләре белән таныштык. Гөлшат апа Зәйнашева шигырьләрен тагын да күбрәк өйрәник.

**Беренче яз – колхоз оешунын беренче язы**

(Сөббух Рәфыйковның "Беренче яз" әсәре буенча

10 нчы сыйныф татар төркемендәге сыйныфтан тыш әдәби уку дәресе)

Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Зиннәтуллина Алина Илдар кызы,

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Дәреснең максаты:

- күзәтүләргә таянып, беренче яз турында сөйли белү һәм аның белән бәйле булган тойгы-кичерешләрне аңлаешлы итеп җиткерә алуга ирешү;
- сәнгатьле, аңлап уку күнекмәләрен, сөйләм телен, фикерләү сәләтен үстерү;
- язгы матурлыкны язучы күзе белән күрә белү, яз турында образлы кузаллау, соклану хисләре булдыру;
- күзәтүчәнлек, игътибарлылык сыйфатлары, табигатькә мәхәббәт тәрбияләү. Эстетик тәрбия бирү.

Җиһазлау: Сөббух Рәфыйковның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган китап күргәзмәсе, презентацион материал, төркемнәрдә эшләр өчен таратма материал, мультимедиа проекторы.

Дәреснең актуальлеге: Районыбыз җирлегендә туып-үскән күренекле язучы, журналист Сөббух Рәфыйковның иҗаты үрнәгендә без бер буын вәкилләрең яхшы тормышка омтылуын, бердәмлеген, киләчәгенең якты булуына ышануын күзаллый алабыз.

I.Оештыру моменты

Сөббух Рәфыйковның "Беренче яз" романын башыннан ахырынача укып чыктык. Бүген безнең дәрес әңгәмә, фикерләрне туплау,тарихи яңа фикерләр булдыру дәресе булыр.

II. Белемнәрне актуальләштерү

Укытучы: Иң матур җир – Туган җиребез турында бөек шагыйребез Тукай: "Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава, җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява", - дигән матур сүзләр язып калдырган. С.Рәфыйковның бу әсәрендә табигать күренешләрен сурәтләү бик матур бирелгән.

III. Яңа тема

1 алып баручы: Менә ямьле яз да җитә. Әкрен генә җир кардан арчылып, яшел чирәмнәр баш төртә башлый. Аннан агачларның бөреләреннән яфраклар күренә башлар.

2 алып баручы: Ә син яз турында берәр сынамыш беләсеңме?

1 алып баручы: Әйе. Язның бер көне ел туйдыра.

2 алып баручы: Әби-бабайлар гомер-гомергә шушы сынамышлар буенча яшәгәннәр. Ә хәзер һәр көн телевизордан һава торышының нинди булачагын әйтеп торалар. Ягез әле, дусларым, телевизорда бүген-иртәгә һава торышы нинди булачак дип хәбәр иттеләр. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

1 алып баручы: Һава торышы турындагы мәгълүматны тыңлап, сынамышларны сынап, язның ничек үткәнен дә сизми калырбыз әле.

2 алып баручы: Һәр ел фасылы үзенчә ямьле. Мин язны бик яратам.

Дәреснең максаты белән таныштыру

Укытучы: Без Сөббух Рәфыйковның “Беренче яз” романын укыдык. Андагы вакыйгалар колхозлар төзелә башлау чоры турында язылган. Төп герой булып Гыймазов тора. Ул бу авылга кинәт килеп төшә. Аның килүе белән авылда үзгзрешләр башлана. Тормыш рәвеше һәм гаилә хәле турында автор бик тәфсилләп яза.

Укытучының сораулары:

1. Сезгә әсәрдәге кайсы герой ошады?

2. Нинди геройларны уңай геройлар рәтенә кертәсез?

3. Кайсы геройларны тискәре герой итеп тасвирлый?

4. Әсәрдән сезне аеруча дулкынландырган өлешләрне укып китегез.

5. Әсәрнең ахыры сезгә ошадымы?

Укучыларның җаваплары:

1. Әсәрдә Гыймазов һәм Гөлчирә исемле геройлар бик матур сурәтләнә. Аеруча, кимсетелгән кыз язмышының уңай якка үзгәрешен автор оста сурәтли.

2. Сәйдә җиңги, Вәлиев, Сәгыйтов,Закирҗанов – уңай геройлар.

3. Сәхап бай, Хәйдәр мулла, Шәвәли, Бүре Абдул, Исхак тискәре геройлар.

4. Сәмигулла исемле кешенең бай – муллаларның хатын илтүе һәм кибетләргә кергәч, аннан бернәрсәсез чыгуы. Бу кеше ипинең , ризыкның шәһәр кешеләренә җитмәвенә үз күзләре белән күреп ышануын автор 180 -181 нче битләрдә язган.

Янгын чыгу – кеше мунчасына ут төртү.

Исхакның атта баручыларга мылтыктан атуы.

5. Әйе, бик ошады. Гыймазов һәм Гөлчирә бергә калалар.

IV. Төркемнәрдә мөстәкыйль эш

Укытучы: Ә хәзер төркемнәрдә эшлибез.

Ике төркем татар теленнән алган белемнәрне һәм бүгенге әсәрне ничек аңлауларын күрсәтәләр. (Биремнәр карточкаларда бирелә)

1нче бирем: Романнан әйтемнәр һәм мәкальләрне табабыз. (Ир канаты – ат).

2 нче бирем: Эндәш сүзләрне табарга. (Туганай).

V. Төркемнәрнең җавапларын тыңлау

Укучы: 1нче биремнең җаваплары: Атсыз тормыш тәгәрәми. Тамак тәмугка кертә.

Үлмәс җанга бер сәбәп. Саклаганны Ходай саклый. Тисә тиенгә, тимәсә борчакка. Әйткән – өзгән. Кеше баласы – кешегә, үз телемең түгел, чит телем. Чирен яшергән үләр.

2 нче биремнең җаваплары: җиңги, күрше-күкерт, маңка, калай әтәч, тонган күз, җизни, энем Гыймаз, сеңлем.

VI. Өй эше бирү. Берәр геройга характеристика бирергә.

VII. Үзбәя бирү. Укучылар, кайсыгыз үзеннән бүгенге дәрестә канәгать?

VIII. Билге кую

IX. Йомгаклау

- Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Дәреснең кайсы өлеше сезгә аеруча ошады? Ни өчен? (Җаваплар тыңлана)

- Ни өчен беренче яз гади генә түгел икән?

Сөббух Рәфыйковның “Беренче яз” романы татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алган. Авыл халкының коллективлаштыру чорын тасвирлаган китап белән танышып, өйрәнеп һәм аның үрнәгендә үскән талантлы тулы бер буын вәкилләре барлыкка килгәнен белдек. Чөнки язучы үзенең әсәрләрендә төрле күңелле һәм шатлыклы хәбәрләрне халыкка ирештерү, басу-кыр эшләрендә күмәкләшеп эшләү, бәйрәмнәр оештыру һәм башка илдә барган яңалыкларны тасфирлап яза.

**Адашкан йолдыз**

(Адлер Тимергалин иҗаты буенча)

Сәлимгараева Әлфия Мидхәт кызы, Халикова Лиза Әхәт кызы,

икенче санлы Җәлил урта гомуми

белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат: Адлер Тимергалин иҗаты белән танышу; аның әсәрләренә карата кызыксыну уяту; укучыларда китап укуга мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау: йолдызлар картасы, кояш системасының моделе; Сарман районның энциклопедиясе; Адлер Тимергалин портреты; Адлер Тимергалин турында презентация.

Язучы-прозаик, тел һәм мәдәният тарихы белгече Адлер Камил улы Тимергалин 1931 елның 1 гыйнварындаТатарстанның Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1948 елда урта мәктәпне тәмамлагач,яшьтән үк тел-әдәбият белән кызыксынган, әмма мәктәпнең югары сыйныфларында укыганда төгәл фәннәргәдә мәхәббәте уянган Адлер, Казанга килеп, университетның физика-математика факультетының астрономия бүлегенә укырга керә.

1950 елның 2 гыйнварында, университетның икенче курсында укыган чагында, А. Тимергалинны кинәт Советка каршы пропаганда алып баруда гаепләп кулга алалар. Ул заманнарда Советка каршы гамәлдә булмаган төрле сәяси актлар да гаепләнеп нахактан кулга алынган бик күпләрдән аермалы буларак, студент егетнең чыннан да совет режимы каршында зур гаебе була: ул совет хакимиятенең, коммунистлар партиясенең халыкны бөлгенлеккә төшергән ике йөзле, шовинистик сәясәтен тәнкыйтьләгән, хезмәт хакларын арттыруны, налогларны киметүне, азык-төлек, әйбер бәяләрен төшерүне таләп иткән листовкалар язып, аларны халык арасында таратып йөри. Листовкаларның кайберләре хәтта «Сталинга үлем!» дигән өндәмә белән тәмамланган була. Егетне Казан урамында нәкъ шундый листовкаларны таратып йөргән вакытта тотып алалар да. Репрессия корбаннарының барысына да хас булганча, Адлер Тимергалин да һәр төрле җәбер-золымны үз җилкәсендә татый, әмма намусына тап төшерми, туры сүзгә тугрылыклы кала.

Сарман районының ЛәшәүТамак җидееллык мәктәбендә берничә ай рус теле укытучысы булып эшләгәннән соң, А.Тимергалин 1952 елда Урта Азиягә китә һәм икееллык Ташкент укытучылар институтының физика-математика факультетына укырга керә. Институтны тәмамлагач, туган якларына кайтып, 1953–1955 елларда Минзәләбаш

җиде еллык мәктәбендә физика һәм математика фәннәре укыта. 1956 елдан ул – Казанда, әүвәл бер ел чамасы Пионерлар йортында балаларның фән-техника түгәрәге җитәкчесе, аннары унике елдан артык Татарстан китап нәшриятының фән-техника редакциясендә өлкән мөхәррир булып эшли. 1970–1978 елларда А. Тимергалин – профессионал язучы, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә, ә 1979 елның гыйнварыннан туксанынчы елларга кадәр янә Татарстан китап нәшриятындагы мөхәррирлек хезмәтен дәвам иттерә.

Адлер Тимергалин 1981 елдан «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә.

Адлер Тимергалин 2013 елның 16 гыйнварендә Казан шәһәрендә вафат була. Адлер Тимергалин – Сөббух Рәфыйков белән уртак язмышлы әдип. Алар районыбызның гаепсездән гаерле булган шәхесләре. Язмабыз рухларына дога булсын.

А.Тимергалин – 1975 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

Оча һәм йөзә торган модельләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1956. – 47 б. – 3000 д.

Оста куллар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1959. – 80 б. – 5000 д.

Пәһлеван кабере: мажаралы, фантастик хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1960. – 64 б. – 8000 д.

Ике хикәя, бер хыял. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1965. – 72 б. – 8000 д.

Ерак планетада: фантастик хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1967. – 155 б. – 13000 д.

Мәңгелек хатирәләр: мажаралы, фантастик хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1969. – 195 б. – 13000 д.

Кохау ронго-ронго: мажаралар, фантастика. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1972. – 160 б. – 11000 д.

Космостан кунаклар: мажаралы, фантастик хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1974. – 152 б. – 11000 д.

Адашкан йолдыз: фантастик, мажаралы хикәяләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1978. – 176 б. – 13000 д.

## Гөлшат Зәйнашева

(«Кем булырга?» шигыре, «What do you want to be? The world of professions»

темасы буенча 6 сыйныф, рус төркеме өчен татар әдәбияты һәм инглиз теле дәресе эшкәртмәсе (катнаш дәрес))

Закирова Әлфия Ринат кызы,

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы,Сарман районы

Аскарова Люция Фирдинат кызы,

Күлле гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы,

Биектау районы

Максат: Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү; тормыш өчен һөнәр сайларга әзерләү; киләчәктә үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

*ТБУУГ:* Укытучының гади сорауларына инглиз һәм татар телләрендә җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу төрле һөнәрләр турында мәгълүматлы булу;

*КУУГ:* Аралашу күнекмәләрен формалаштыру, ике телдә диалогик сөйләм күнекмәләре булдыру, парларда һәм күмәк эшли белү;

*РУУГ:* Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;

*ШУУГ:* Укуга карата кызыксыну формалаштыру;

*Дәрес тибы*: яңа белемнәрне үзләштерү

Ресурслар: Проектор, экран, Гөлшат Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигыре, дәрескә презентация, дәреслекләр: «Татар әдәбияты»: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен), 2нче кисәк / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Э.Х.Гыйззәтуллина; «Spotlight» Английский язык. 6 класс / Ваулина Е.Ю., Дули Д. и др.

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

1. Дәресне оештыру: -Исәнләшү. Кәефләрне белешү. Психологик уңай халәт булдыру. -Хәерле иртә балалар! Good morning dear children!

- Дәресебезне башлыйбыз! Today we’ll have an unusual lesson. Укучылар! Бер-берегезгә хәерле көн теләгез.

2.Актуальләштерү.

- Бүген без эшне төркемнәрдә оештырабыз. Төркемдә эшләү кагыйдәләрен онытмагыз. Сез барлык биремнәрне бергә киңәшләшеп эшлисез. Сез үзегезнең командирны сайлагыз.

Тактада төрле һөнәр рәсемнәре эленгән (һөнәр рәсемнәре) Рәсемнәргә карагыз, әле, сез кемнәрне күрәсез? (Укытучы, сатучы, табиб, рәссам, баянчы, шофер, җырчы, язучы, шәфкать туташы) Нинди бер сүз белән аларны берләштерергә була?

- Болар – һөнәрләр.

-Yes, we will talk about jobs and professions. They are teacher, doctor, artist, postman, waiter, mechanic, driver, writer, poet, nurse, singer, sportsman, librarian, cook, shop assistant, bayanist.

-Нәрсә соң ул һөнәр? Сорау-җавап алу. Әңгәмә

-What are you going to be? (answers)

3.Уку мәсьәләсен кую.

1.Язучылар, шагыйрьләр һөнәрләр турында әсәрләр язалармы? Әйе, бик дөрес язалар. Бүген без танышачак шагыйрә дә һөнәр сайлау турында язган. Тактага карагыз, бу кем портреты? (Гөлшат Зәйнашева портреты) Димәк, без бүген дәрестә кем иҗаты белән танышырбыз? Без Гөлшат Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигырен өйрәнәбез.

- Эшне без ничек оештырабыз? «Кем булырга?» шигырен сәнгатьле укырбыз, сорауларга җавап бирербез, төрле һөнәр ияләре турында сөйләшербез.

II.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.

-Әйдәгез, хәзер укучылар шагыйрәнең кыскача тормыш юлы белән танышыгыз. Сезнең алдыгызда шагыйрәнең тормыш юлы турында текст ята. Сез укып чыгыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

Г.Зәйнашева Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза: «14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесендә укыдым. 1942- 1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астындагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшь үсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек ... »

1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

Г. Зәйнашеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

Г.Зәйнашеваның туган җир, туган як турындагы шигырьләрен укыганда, һәркем уйланадыр. Чөнки туган як белән бәйле тойгы һәркемнең күңеленә газиз. Туган як кеше өчен кадерле, изге булырга тиеш. Туган як темасы язучы иҗатында зур урын алып тора .

Г.Зәйнашеваның шигырьләре күңелгә үтеп керердәй, халыкчан гадилеге, ачык аңлаешлы, музыкаль аһәңе белән аерылып тора һәм бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп, популяр җырлар язганнар. Иң популяр җырлар туплаган «Илле җыр» (1998) исемле китабы өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Ә хәзер шул җыентыкка кергән берничә җырын тыңлап китәрбез.

Г. Зәйнашеваның үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга . Аның «Бәхет кошым», «Рамай» , «Гайфи бабай, өйлән давай», «Язмышлар һәм ялгышлар» һәм башка пьесалары тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

1) Шагыйрә кайчан һәм кайда туа?

2) Ул кайларда укый?

3) Ул кайда эшли?

4)Where and when was Gulshat Zaynasheva born?

5)Where did she study?

6)Where did she work?

7)How many books did she write?

Укучылар җавапларын әйтәләр. Рәхмәт укучылар, булдырдыгыз.

2. Укытучыдан өстәмә мәгълүмат бирелә.

3. Ә хәзер сезнең белән төркемнәрдә эшлибез. Һәр төркем сүзләр тәрҗемә итә. 2 төркемгә дә сүзләр әйтелә. Өстәлдә сүзлекләр ята.

1 төркем: кем булырсың? [кэм булырсың] – кем будешь?

баянчы[бåйанчы] – баянис табиб[тåбиб], табибә[тåбибә]-врач

сатучы[сåтучы]-продавец

2 төркем:дәвалый[дәwалый], савыктыра[сåwыķтыра]- исцеляет, лечит

иң элек[иң элэк]- сначала, сперва Ходай[ходай]- Господь, Бог

- Әйдәгез, тикшерәбез. (Сүзләрнең татар телендәгесе хор белән кабатлана.)

3.-Әйдәгез, Г.Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигыре белән танышыйк.

1) Шигырьне укытучы укый, балалардан сорауга җавап сорый. (Шигырьдә сүз нәрсә турында барачак? Малайга кемнәр киңәш бирә?)

2) Укучылар үзләре эчтән укый, игътибар белән укыгыз: малайга нинди киңәшләр бирәләр?

3) Шигырьне чиратлап сәнгатьле итеп укыйлар.

4. Төркемнәрдә эш.

-1 өстәл беренче 8 юлда нинди һөнәрләр ишеттегез? 1 минут эчендә һөнәр исемнәрен языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (баянчы, артист, шофер).

-2 өстәл 1 минут эчендә шигырьнең калган өлешендә ишеткән һөнәр исемнәрен һәм алар башкарган эшне языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (Табиб, сатучы)

5. Мөстәкыйль эш. Сорауларга җавап бирү.

-Малайга кем нинди һөнәр алырга куша? (Һәр төркемнән 1 укучы җавап бирә)

-Әтисе , әнисе, апасы, артистлар, әбисе

6. Үрнәк буенча парлап сөйләшү.

- Син кем булырга телисең?

-Мин очучы булырга телим.

- Ни өчен?

-Миңа бу һөнәр бик ошый.

- What do you want to be?

-I want to be a doctor.

- Why?

-Because I like this job.

7.Төркемнәрдә эш.

Проект эше. Табиб, сатучы һөнәр ияләренә туры килгән сүзләрне аерыгыз һәм сүзләрне битләргә беркетегез. Һәр төркем үзенең проектын яклый. (иҗади, җинел,

дәрәҗәле, мактаулы, авыр, куркыныч, җаваплы, акчалы, абруйлы, җитди, сирәк, катлаулы)

Бер төркем инглизчә ясый (creative, easy, difficult, interesting, boring, responsible, serious, dangerous, modern)

III. Өй эшен аңлату

«Әти-әниемнең һөнәре ни өчен миңа ошый яки ошамый?» темасына инша язып килергә (можно на английском)

IV. Рефлексив бәяләү.

1. Рефлексив кабатлау.

- Без бүген дәрестә нәрсәләргә ирештек? Сезнең карточкалар бар, шуларга җавап языгыз. Әйдәгез, укыгыз. Без Гөлшат Зәйнашеваның биографиясе белән таныштык, «Кем булырга?» шигырен сәнгатьле укыдык, төрле һөнәрләр турында сөйләштек. Балалар әбинең әйткән сүзләрен тагын бер тапкыр укыйк. Нинди генә һөнәр алсаң да тырыш, җитди булырга һәм кешелекле булырга кирәк. Дәресебезне Г. Зәйнашеваның шигырендәге юллар белән тәмамлыйсы килә:

Иң элек син
Кеше бул, улым.
Ходай бирер сиңа шулчак
Бәхетнең зурын!..
Г. Зәйнашева

- Балалар, дөньяда һөнәрләр бик күп, кайсын гына сайласаң да, яхшы кеше булып калырга кирәк!

2. Билгеләр куела.

## Тамчы – шоу бәйгесе

(3-4нче сыйныф укучылары өчен класстан тыш чара)

Фәрхетдинова Т.Ф., Хамидуллина А.Х.

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат: укучыларда якташ язучыларыбыз иҗатына кызыксыну уяту, аларга карата ихтирам, хөрмәт, горурлык, мәхәббәт хисләре тәрбияләү; укучыларның сөйләм телен, дөньяны танып – белү, күзаллауларын арттыру, баету; эзләнергә, мөстәкыйль эшләргә өйрәтү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр.

Метапредмет: якташларыбыз турында мәгълүмат алу.

Регулятив универсаль уку гамәлләре: чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

Танып белү универсаль уку гамәлләре: тиешле мәгълүматны табу, объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре: фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.

Предмет: үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

Шәхескә кагылышлы: дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү.

Җиһазлау: якташ язучыларыбыз китапларыннан күргәзмә, сораулар язылган карточкалар, компьютер, төрле рәсем слайдлары, Гөлшат Зәйнәшева, Сөббух Рәфыйков портретлары, презентация.

Уенда 2 команда катнаша. Өй эшенә: визитка әзерләү, исем, девиз сайлау, якташ язучыларның биографияләрен, әсәрләрен өйрәнү һәм командирларга татар халык мәкальләре бәйгесенә әзерләнүләр кирә. Командалар исемнәренә туры китереп төрле костюмнар да әзерли ала.

Уен барышы

Алып баручы: Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар! “Тамчы - шоу” бәйгесен башлап җибәрәбез. Безнең бүгенге уеныбыз якташ язучыларга багышлана. Бәйгедә 3, 4 сыйныф укучылары катнаша.

Бәйге булгач, бәйге инде. Уенчыларыбызны бәяләү өчен безгә жюри сайларга кирәк.

Хәзер үзләре белән таныштыру өчен сүзне командаларга бирәбез. Сүз беренче командага бирелә.

Безнең исем: Тапкырлар!

Безнең девиз:

Тапкыр җиңәр, оттырмас,
Сезгә куып тоттырмас.
1.Мин – Кадрия, бик күп укыйм
Быел бик тә тырышам.
Отличник укучылардан
Бераз гына калышам.
2. Рамазан булам, Җәлилдән,
Мин дүртенче сыйныфта.
Бик яратам җырларга,
Тырышам шәп укырга.
3.Ә мин, Риназ, шук малай,
Өлгер малай, ут малай.
Кайчак мине кисәтәләр
Аңламыймын, ник алай.
4. Өченче сыйныфта укыйм
Рузил булам, дусларым,
Биим дә мин, җырлыйм да мин
Спортны да яратам.
Барысы бергә:
Барыбыз да дус һәм тату
Командада дүрт бала.
Сер бирмәскә тырышырбыз –
“Тапкырлар” сезнең алда.
Безнең исем: Зирәкләр!
Безнең девиз:
Зирәк һәр җирдә кирәк,
Тик зирәк ул бик сирәк.
**1.** Мин – Муса, беркайчан да
Девизымны онытмыйм.

Чиста, пөхтә, тиз язам
Өлгер белән дуслашам.
2. Мин, Илназ, бик тырышам,
Һәр көн саен алга барам.
Иптәшләрне дә калдырмыйм,
Үзем белән бергә алам.
3.Исәнмесез, барыгыз да!
Минем исемем – Ләйсән.
Туган илемне яратам,
Күгебез булсын аяз.
4. Минем исемем Румиль
Үзем һәр яктан камил.
Куамын көнчелекне,
Яратам дөреслекне.
Барысы бергә:
Без дә бик тырыш балалар
Командада дүрт кенә.
Көч сынашырга әзер без
Дүрт булсак та төш кенә.
I тур. Батыр – берне, белемле – меңне егар.

Мин сезгә мәкальләрнең беренче өлешен әйтәм, ә сез икенче өлешен әйтеп бетерергә тиеш буласыз.

1 команда җавап бирә.

Кем эшләми –.... (шул ашамый)
аткан ук)

Калган эшкә –..... Дөрес сүзгә-.... (җавап юк)

Иле барның –.... (теле бар)

2 команда җавап бирә.

Агач җимеше белән мактана –-... (кеше эше белән)

Әйткән сүз –... ( (кар явар)

II тур. Язучыны таны.

- Менә без икенче турга да аяк бастык. Конвертта язучыларның биографияләреннән өзек бирелгән. Өзекне укып, экраннан шул язучыны табып әйтергә.

... 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек кызны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Аның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыга. (Гөлшат Зәйнәшева)

... 1913 елның 15 июлендә Минзәлә өязе Нөркәй волосте (хәзерге Татарстанның Сарман районы) Нөркәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1925-1930 елларда башта Яр Чаллыда һәм Алабугада тугызъеллык мәктәптә, аннары Казанда югары

уку йортында хәзерләү курсларында укый. 1931 елдан башлап ул журналистлык эшендә: республика “Колхоз гәзите” редакциясендә әдәби хезмәткәр (1931-1932), Сарман районында чыга торган “Комбайн” газетасында җаваплы редактор урынбасары (1932-1934), республика комсомол газетасы “Кызыл яшьләр” редакциясендә бүлек мөдире (1934-1937) һәм Татарстан дәүләт нәшриятында редактор (1937) вазыйфаларын башкара. 1934-1937 елларда, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогика институтының тел-әдәбият бүлегендә укый. (Сөббух Рәфыйков )

... 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була. Ул башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962—1965 елларда ул яңадан мәктәптә — Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. Шигырьләре «Гел кояшка карап» исемле күләмле китабында урын алган. (Клара Булатова)

... – Бөек Ватан сугышында катнаша, 17 яшьтә ул армия сафларына алына. 1945 елда япон сугышында бик каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1946 елда үз туган авылына кайта. Ул 20 дән артык китаплар авторы, шигырьләрнең тематикасы күбрәк аның туган авылы табигатенә багышлана. Балалар шагыйре булып танылса да, аның олылар өчен язылган китаплары да бар (мәсәлән, “Урман читендәге имәннәр без” дип исемләнгән китабы). (Әзһәр Габиди)


1


2


3


4

I , II турлар буенча йомгак ясау өчен сүз жюрига бирелә.

III тур. Игътибарлылык ярышы.

Экранда сез рәсемнәр күрерсез. Шул рәсемнәрне игътибар белән карап, мөмкин кадрәр истә калдырырга тырышыгыз.

Сораулар:

1 командага – Әлеге рәсемнәрдә сез ничә малай күрдегез. (Өч)

2 командага – Әлеге рәсемнәрдә сез ничә песи күрдегез. (Алты)

IV тур. Видеосорау

- Игътибар белән тыңлагыз, Г.Зәйнәшева сүзләренә язган җырларны атагыз.

1 команда “Без — табигать дуслары” Г. Зәйнәшева сүзләре , Г. Беляева көе.

2 команда “Бер атнада ничә көн?..” Г. Зәйнәшева сүзләре , Е. Шатрова көе.

V тур. Капитаннар ярышы.

- Сорауларга “әйе” яки “юк” дип җавап бирергә

“Зирәкләр” командасы капитанына сораулар:

1. Гөлшат Зәйнәшева Сарман районында туган. (әйе)
2. Сөббух Рәфыйков Нөркәй авылы егете. (әйе)
3. Без Азнакай районында яшибез (юк)
4. Г.Зәйнашева 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була (әйе)
5. Сөббух Рәфыйков балалар өчен табышмаклар язган (юк)
6. Клара Булатова урта белемне Азнакай урта мәктәбендә алып чыга. (юк)
7. Мәктәбебез М.Җәлил урамында урнашкан. (юк)

“Тапкырлар” командасы капитанына сораулар:

1. Клара Булатованың әти – әнисе укытучылар була .(әйе)
2. Әзһәр Габиди 1950 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. (әйе)
3. Якшәмбе – ял көне (әйе)
4. Сөббух Рәфыйков 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. (әйе)
5. К. Булатова 40 елдан артык укытучы булып эшли. (әйе)
6. Г.Зәйнашева тумышы белән Мөслим районыннан (юк)
7. Без Әлмәт районында яшибез. (юк)

VI тур. Өзекләрнең авторын әйтеп бир.

Игътибар экранга.

“Тапкырлар” командасына:
Яшь чакларым кайта язлар белән,
Яз китерә дәрт һәм батырлык.
Алып килә һәр яз үзе белән
Кабатланмый торган матурлык... (Сөббух Рәфыйков “Яз килә”)
“Зирәкләр” командасына:
Бөрлегәнем-җиләгем, дип
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни. (Гөлшат Зәйнәшева “Бөрлегән”)
“Тапкырлар” командасына:
Йолдызың якты булсын,
Юлларың яхшы булсын;
Сүзләрең затлы булсын,
Телләрең татлы булсын. (Клара Булатова “Күкләргә кара, улым”)
“Зирәкләр” командасына:
Тәңкә карларны себереп,
Тышта буран котыра,
Тәрәзә төбендә гөлем
Ал чәчәктә утыра. (Әзһәр Габиди “Минем гөлем”)
- Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез. Рәхим итегез!
- Бүгенге “Тамчы – шоу “ уеныбыз ахырына якынлашты. Татар телен яратыгыз, якташ язучыларыбызны белегез, туган телдә аралашыгыз, бер-берегез белән дус яшәгез.
Җирне саклап кала алмабыз,
Дуслашмаган килеш без.
Шуңа күрә барыбыз да,
Дус булырга тиеш без.
Үскәч тә без дошман булмыйк
Беребез дә.
“Дуслык” сүзе булсын безнең – ТЕЛЕБЕЗДӘ!

## Югары сыйныфларда функциональ грамоталылыкны тикшерү өчен эшләнгән биремле текстлар

Шакирова Эльмира Шәрифулла кызы,
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Сезгә Сөббух Рәфыйков турында мәгълүматлар тупланган 2 текст тәкъдим ителә. Шушы текстлар белән танышып, бирелгән сорауларга җавап бирергә тырышыгыз.

Эшләү вакыты – 45 минут

1 нче текст

Биографик белешмә

Язучы, шагыйрь Сөббух Һади улы Рәфыйков 1913 елның 15 июлендә Татарстанның Сарман районы Нөркәй авылында игенче гаиләсендә туа. 1925–1930 елларда – Татарстанның Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендә гомуми белем бирү мәктәбендә, аннары Казанда югары уку йортына әзерлек сыйныфларында укый. 1931 елдан ул район һәм республика газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, бүлек

мөдире, җаваплы мөхәррир урынбасары, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара. 1934–1937 елларда, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтында укый. Шул чорда аның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләреннән шигъри җыентыгы («Үсү җырлары») һәм «Соңгы талпыну» (1932), «Үсмерчак» (1937) дигән хикәя китаплары басылып чыга.

1937 елның 17 октябрендә яшь язучы һәм китап нәшрияты мөхәррире кинәт НКВД чекистлары тарафыннан кулга алына. Сәбәбе: ул бер төркем яшь язучылар белән бергә татар әдәбиятының классигы Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулу уңаеннан аны котлап язылган күмәк хатка имза куйган икән. Ә бу вакытта Г.Ибраһимов инде кулга алынып, әле хөкем карары булмаса да, җәмәгатьчелеккә инде «халык дошманы» дип игълан ителгән була. Менә шул «зур җинаять»не сәбәп итеп, совет хәрби мәхкәмәсе С.Рәфыйковны ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән карар чыгара. Яшь әдип башта мәшһүр Соловки концлагерена, аннан Төньяк Себердәге металлургия комбинаты төзелешенә җибәрелә. 1947 елда хөкем мөддәтен тутыргач та аңа туган якларына кайтырга рөхсәт итмиләр. 1951 елның 9 июнендә шул ук элекке «җинаятьләре» өчен яңадан хөкем ясалып, әдип этап белән Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла.

Туган якларына ул фәкать 1957 елда гына кайту бәхетенә ирешә. Шул ук елда әдипнең сөргендә чагында иҗат иткән шигырьләреннән сайлап тупланган «Ак төннәр» исемле җыентыгы дөнья күрә. Сөргеннән кайткач, С.Рәфыйков, Татарстанның Зәй шәһәрендә төпләнеп, берникадәр вакыт (1958–1961) «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының Зәй төбәгендәге үзхәбәрчесе, аннары штаттан тыш хәбәрчесе булып эшли.

Язучы буларак С.Рәфыйковның бу еллардагы әдәби иҗаты, нигездә, проза жанрына карый. Киң җәмәгатьчелеккә ул илленче-алтмышынчы елларда иҗат иткән өч романы белән танычла. «Беренче яз» исемле тәүге романында (1958) әдип егерменче-утызынчы елларда татар авылы кичергән социаль үзгәрешләрне, аерым хуҗалыктан күмәк хуҗалыкка күчү процессындагы каршылыкларны шул заманга хас реаль күренешләр һәм кеше образлары аша сурәтләргә омтыла. Бу романдагы вакыйгалар аның туган авылында бара, һәм геройларның да прототиплары – шул авыл кешеләре. «Авыл иртәсе» романында исә (1966) алтмышынчы елларда совет хакимияте тарафыннан көчләп тагылган күмәк хуҗалыкларны эреләндерү тәҗрибәсе үзәккә алынып, бу тәҗрибәнең авыл халкы тормышына алып килгән катлаулы нәтиҗәләре, шул шартларда хуҗалык белән җитәкчелек итү, хезмәтне оештыру кебек производство мәсьәләләре яктыртыла. Гомеренең соңгы елларында әдип Татарстанның көнчыгыш төбәгендә Зәй гидростанциясе төзүче эшчеләр тормышыннан «Тын елга буенда» исемле өченче романын эшли. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында (1971, № 2.6) дөнья күреп, соңыннан, авторның вафатыннан соң (1972), Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.

Күп еллар тоташ тоткынлык җәфаларыннан сәламәтлеге какшаган язучы 1971 елның 21 ноябрендә Яңа Зәй шәһәрчегендә вафат була.

С.Рәфыйков – 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Сораулар һәм биремнәр.

1.Тексттан алынган мәгълүматларга нигезләнеп, таблицаны тутырыгыз

| | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| Сөббух Һади улы Рәфыйков Татарстанның Сарман районы Нөркәй авылында туа. | | |
| Аның гаиләсе терлекчелек белән шөгыльләнә | | |

| | | |
|---|---|---|
| 1937 елның 17 октябрендә яшь язучы НКВД чекистлары тарафыннан кулга алына. | | |
| 1947 елда хөкем мөддәтен тутыргач та аңа туган якларына кайтырга рөхсәт итәләр. | | |
| Күп еллар тоташ тоткынлык җәфаларыннан сәламәтлеге какшаган язучы 1972 елның 21 ноябрендә Яңа Зәй шәһәрчегендә вафат була. | | |

2. Кулга алынганда С.Рәфыйковка ничә яшь була? ________________________

3.Сөббух Рәфыйковның кулга алыну сәбәбе нинди була? ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________

4. Ул Г.Ибраһимов белән таныш буламы?

а) әйе

б) юк

в) тектта мәгълүмат бирелмәгән бирелмәгән

5. Язучы гомеренең ничә елы төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә уза? _____________________________________________________________________

6. С.Рәфыйковның иҗаты нигездә кайсы жанрга карый?___________________

7. Язучының өченче романының исеме нинди елга белән бәйле дип уйлыйсыз? _____________________________________________________________________

8. Язучы ничә яшендә вафат була? _______________________________________

2 нче текст

Чагыл тау сагына

Язучы Сөббух Рәфыйков турындагы истәлекләрдән

Сөббух абыйны мин кече яшьтән беләм. Бертуган Зиннәт абыемның якын дусты иде ул. (Сүз уңаенда, Зиннәт Шәрәфетдинов – кызыл командир, фин сугышында катнаша. 1941 елның июнендә немец-фашист илбасарларының беренче ударларын кабул итә. Аның ротасының батырлыгы турында белорус язучысы Александр Капустин "Тозлы чык" исемле повестенда тәфсилләп яза. Зиннәт сугышны лейтенант булып башлый, подполковник дәрәҗәсендә, полк командиры булып тәмамлый. Күп санлы сугышчан орден-медальләр белән бүләкләнә. Берсен хәтта М.И.Калининның үз кулыннан ала. Район газетасы бу хакта 1985 елның 9 май санында "Кем син, Зиннәт?" исемле очеркта да язып чыкты.)

1930-1931 елларда Сөббух абый Нөркәй урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытты. Берәр сөйкемле сөяге бар идеме, башка сәбәпме, аны һәрчак балалар сырып алган булыр. Сәләтле укучыларны үз тирәсенә оештырып, әдәби түгәрәк эшләтеп җибәрде. Анда каләм тибрәтүче балаларның язмаларын тикшерәләр, стена газеталары чыгаралар, сәнгатьле сөйләргә өйрәнәләр, концертлар әзерлиләр иде.

Хәтеремдә, Сөббух абый ул концертларда үзе дә катнаша, Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан шигырьләрен аһәңле, сәнгатьле итеп сөйли иде. Ни кызганыч, яраткан укытучыбыз кулы астында без мәктәпне тәмамлый алмадык. 1932 елда аны Сарманда чыга торган "Комбайн" газетасына мөхәррир урынбасары итеп эшкә чакырдылар. Сөббух абый чикләре хәзерге Азнакай районының Чуар Абдул авылыннан Зәйнең Баграж, Әлмәтнең Яңа Михайловка һәм Гөлбакча авылларыннан Минзәлә чигендәге Удельный

Сөренчәккә кадәр сузылган районны җәяү дә, атта да аркылыга-буйга иңләде. Халык арасында кайнап яңа тормыш төзү, күмәкләшү турында ялкынлы мәкаләләр язды, поэмалар, хикәяләр иҗат итте.

Алтын җирдә ятмый, диләр. Сөббух абыйның талантын Казанда да тиз күреп алдылар. 1934 елда ул Сарман, туган ягы белән саубуллашып, "Кызыл яшьләр" (бүгенге "Татарстан яшьләре") газетасында эшли башлады. Шул елларда педагогия институтын тәмамлады.

Шигырьләреннән һәм хикәяләреннән өч җыентык бастырып чыгарды.

1937 ел. Ил өстендә репрессияләр болыты куерды. Җәмгыятьнең асыл затларын, каймагын: күренекле партия һәм дәүләт эшлеклеләрен, талантлы шагыйрьләрен һәм язучыларын, фән эшлеклеләрен һәм хәрби начальникларын юк итү башланды. Татарстанда да репрессия машинасы туктаусыз, рәхимсез эшләде. Сөббух Рафиков, халык дошманы дип, кулга алынды. Өчлек суды аңа 10 ел төрмә, 5 елга хокукыннан мәхрүм итәргә, иленә кайтармаска, язучылык белән шөгыльләнмәскә, дигән карар чыгарды.

Сөббух абый этап белән Себергә, котып ягына – Норильскига озатылды. 1957 елга кадәр, шәхес культына дучар ителгән меңләгән шәхес белән бергә, төрле лагерьларда газап чикте.

Кайгы-хәсрәт берүзе генә йөрми, диләр. Сөббух абыйга "халык дошманы" мөһере сугылгач, туганнарын төрлечә кимсетүләр, җәберләүләр башланды. Шуларга түзә алмаган энесе Самат Сахалинга чыгып китте. Апасы Банат та Үзбәкстанда сыену урыны тапты.

Ил өстендә саф җилләр исә башлап шәхес культы фаш ителгәч, Сөббух абый да 1957 елны, тулысынча акланып, Татарстанга, туган авылы Нөркәйгә кайтты. Авыл халкы, мәктәп өчен ул бик олы кунак иде. Аның белән очрашырга халык болыт кебек агылып килде, тәбрик сүзләренең, чыгышларның иге-чиге булмады.

...Очрашудан соң Сөббух абыйны үзебезгә кунакка алып кайттым. Өйгә килеп керүгә ул авылның ипи пешерә торган мичләренә кадәр сагынуын, ирек һавасының бер йотымының алтыннардан да кыйммәтрәк булуын кайта-кайта сөйләде, саран гына төрмә хәлләрен искә төшерде:

«Сорау алганда нинди генә ерткычлыклар эшләмиләр анда. Тәнеңнең карар җире калмаганчы дагалы итекләр белән типкәләүләр дисеңме, тырнак астына күгәргән кадаклар кагу, борыс белән ишек арасына кысып кул бармакларын сындыру дисеңме, берсеннән дә чирканмыйлар җәлладлар. Шул җәзалаулар хакында ireккә чыккач беркемгә дә сөйләмәскә, авызны йозакта тотарга дип, ничәмә-ничә җиргә кул куйдырулар, кимсетүләр. Аларны искә төшерүгә тәннәр чымырдап китә, йөрәк күкрәк читлегеннән чыгардай булып дөпелди. Шуңа бу тәмугны унга, йөзгә берәүләр, «бик бәхетлеләр» генә кичә...

Шул очрашуда Сөббух абый миңа үзенең "Ак төннәр" исемле шигырьләр китабын бүләк итте. Аны хәзер дә иң кадерле ядкарь итеп саклыйм. 50 нче еллар ахырында язучы Зәйгә барып урнашты. Әмма туган авылын онытмады, һәр елны кайтып, авылдашлары белән очрашып, төрле өмәләрдә катнашты. Истәлекле мизгелләр, авылның матур эшләре турында шигъри репортажлар, очерклар яза иде.

1971 елны Казанда белем күтәрү курсларында укыганда аның белән янә очраштык. Бауман урамыннан барганда кинәт кенә аркамнан берәү кага. Әйләнеп карасам, Сөббух абый.

«Кичә "Беренче яз" романымның икенче басмасын чыгару, "Тын елга буенда"ны китап итеп бастыру мәшәкатьләрен бетердем,» – диде ул. Аннан сүз киләчәк планнарга күчте.

«Күп эшләрне бетерә алмадым, туган. Сөргенгә тикле язганнарым югалып беткән. Кайберләре Ленинградта сакланган, диләр. Мин анда бара алмам инде,» — диде Сөббух абый, авыр сулап. Аның тавышында үткәннәр өчен сыкрану, язмышына үпкә һәм нәфрәт хисе кайный кебек тоелды. Әйтерсең, ни котәсен алдан белеп йөргән. Шул очрашу соңгысы булды. Сөббух абый арабыздан китте...

...Чагыл тау күкрәгендәге әби чәчләрен тарап талгын җил исә. Арырак – Сабит чишмәсе. Тау һаман шул. Чишмә дә, эшем кешеседәй ашыгып, ага да ага. Барысы да кайчандыр итәгендә ялан тәпи атлар саклаган, чишмә буйларында су чәчрәтеп уйнаган улын сагына, Сөббухын юксына кебек.

(Таһир Шәрәфетдинов, I группа сугыш инвалиды, сугыш һәм мәгариф ветераны. "Мәйдан" № 1, 2003.)

Сораулар һәм биремнәр.

1. Истәлек авторы Сөббух Рәфыйков белән ничек таныш? ________________________________________________________________

2. Нөркәй урта мәктәбендә эшләгәндә С.Рәфыйков нәрсә белән шөгыльләнә? ________________________________________________________________

3. Сөббухның бертуганнары турында ниләр белдегез? _________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

4. Язучының якын дусты турында булган мәгълүматларның кайсылары дөрес?

| | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| Зиннәт Шәрәфетдинов — кызыл командир, фин сугышында катнаша. | | |
| 1943 елдан Бөек Ватан сугышында катнаша. | | |
| Аның ротасының батырлыгы турында белорус язучысы Александр Капустин "Тозлы чык" исемле повестенда тәфсилләп яза. | | |
| Зиннәт сугышны лейтенант булып тәмамлый | | |
| М.И.Калинин үз кулы белән аңа медаль тапшыра. | | |

5. Истәлектә нинди топономик атамалар очрый? Бу атамалар кайсы авыл белән бәйле? _____________________________________________________________________________________________________________________________________

6. Т.Шәрәфетдинов истәлекләрендә язучының кайсы романы телгә алынмый, ни өчен дип уйлыйсыз? _____________________________________________________________________________________________________________________________________

7. Беренче текстта “1951 елның 9 июнендә шул ук элекке «җинаятьләре» өчен яңадан хөкем ясалып, әдип этап белән Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла” дигән җөмлә бар. Язучы ничек туган якларына кайту бәхетенә ирешә? ______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

8. Илебездә булган сәяси репрессия ничәнче елларда дәвам итә?

9. Репрессия корбаннары булган тагын нинди татар язучыларын һәм шагыйрьләрен беләсез?

________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

10. Т.Шәрәфетдинов истәлеге нинди журналда басыла? ____________________

11. Бу мәкалә журналда нинди уңайдан басыла дип уйлыйсыз? _______________________________________________________________________________________________________________________________

## Тибрәнә җыр күңелдә...

(Рус мәктәбендә укучы башлангыч сыйныф укучылары белән үткәрү өчен әдәби-музыкаль тәнәфес)

Шәйхелисламова Л.Ф., Бариева Ф.Ф.,

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбенең

башлангыч сыйныфлар укытучылары, Сарман районы

- Исәнмесез, балалар!

- Безнең бүгенге әңгәмәбез, “Тибрәнә җыр күңелдә” дип атала. Бу юллар безнең якташ, күренекле татар шагыйрәсе, драматург Гөлшат апагыз Зәйнәшева шигыреннән алынган. (слайд 1)

Тибрәнә җыр күңелдә (бер укучы яттан сөйли)



Язын сыерчыклар кайтып,
Оясын тапса,
Бакчаларда алмагачлар
Шау чәчәк атса,
Кояш көлсә, ай елмайса
Илем күгендә, —
Тибрәнә җыр дулкыннары
Минем күңелемдә!
Бәхетле елмаеп, ана
Баласын кочса,
Тыныч күктә ак юл сызып,
Самолет очса,
Дуслар гөрләшеп утырса
Табын түрендә, —
Тибрәнә җыр дулкыннары
Минем күңелемдә

- Гөлшат Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның, ул вакытта Чаллы кантоны (*1930-1936 елларда Сарман районы)* Иске Теләнче исемле авылда дөньяга килә. 1930 елда аларның гаиләсен чит якларга сөрәләр. Әти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыкмас өчен, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә калдыралар. Балачагы шул авылда уза. Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.(слайд 2)




- Гөлшат Зәйнәшеваның бик күп шигырьләренә җырлар язылган. Бу җырларны балалар да, татар халкы да, үзешчән һәм һөнәри җырчылыр да күп еллар инде яратып башкаралар.

- 1988 елда аңа, татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССР атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.(слайд 3)



- 1991 елда Гөлшат Зәйнәшева, иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» китабы өчен, Тукай премиясенә лаек була. (слайд 4)




"Җырлыйм әнием турында" (Г.Зәнәшева сүзләре, Ф . Әхмадиев музыкасы)

җыры башкарыла

- Гөлшат Зәйнәшева туган як, Татарстан, безнең республиканың күп авыллары турында матур-матур шигырьләр язган. Бу шигырьләрдә туган якка мәхәббәт, аның гүзәллеге белән соклану чагыла.

Газиз туган як. (бер укучы яттан сөйли)
Иделе киң, диңгезгә тиң,
Ямьле безнең туган ягыбыз.
Башка бер ил кирәк түгел,
Шунда үтсен тормыш юлыбыз.
Туган як дип сагынып кайта,
Язлар җиткәч, сайрар кошлары.
Язлар матур, җәйләр ямьле,
Чыныктыра салкын кышлары.
И туган як, газиз туган як,
Бишегемә былбыл кунган як.
Сандугачлар белән сайрашып,
Сабый чагым узган як.

- Шагыйрәбезнең балалар өчен язылган әсәрләре дә байтак. Алар балаларны әйләнә-тирә дөнья белән генә таныштырып калмыйлар, дус-тату булырга, өлкәннәрне ихтирам итергә, туган якны сөяргә өйрәтәләр.

Әбиемне яратам (бер укучы яттан сөйли)
Мин үзем шәһәрдә яшим,
Авылга кайтам җәен.
Чөнки ул авылда яши
Яраткан әбекәем.
Әбием анда ялгыз яши,
Миңе сагынып көтә.
Мин кайткач, шатланып йөри,
Мине бик кунак итә.
Мин үскәч, әбием белән
Авылда торачакмын.
Әбием картаеп киткәч,
Ярдәмче булачакмын.

- Гөлшат Зәйнәшева драма әсәрләре дә иҗат итә. Аның әсәрләре буенча куелган театрларны тамашачылар бик яратып карыйлар.

- 2005 елның 1 апрелендә Казан шәһәрендә шагыйрә якты дөнья белән хушлаша.



- Кичәбезне Гөлшат Зәйнәшева сүзләренә язылган “Туган җирем – Татарстан” (А.Ключарёв музыкасы) җыры белән тәмамлыйбыз. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Гөлшат Зәйнәшева – яралы язмышлы шагыйрә**

(эшлекле уен)

Хәсәншина Фирая Зәкәрия кызы

Гомуми үстерү төрендәге"Лилия" №2 балалар бакчасы тәрбиячесе,

Сарман районы

Максат: Педагогларның күренекле шәхес – Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрен ачыклау һәм киңәйтү, һөнәри осталыгын арттыру.

Уен барышы:

Үзләре артыннан гаҗәеп бай мирас калдырган шәхесләр була. Шундыйларның берсе, татар дөньясы күгендә йолдыз булып балкыган шагыйрә – Гөлшат Зәйнашева. Аның иҗаты балаларда якты һәм матур тойгылар тәрбияли. Кешеләрдәге һәм тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлыкны яратырга өнди.

Хөрмәтле коллегалар! Безнең эшлекле уеныбыз татар халкының талантлы кызы Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган. Балалар бакчасында Гөлшат Зәйнәшеваның мәгънәле шигырьләреннән, күңелле, тирән эчтәлекле җырларыннан башка бер генә бәйрәм иртәсе дә узмый, ә аның үзе турынданиләр беләсез икән, үзегезне сынап карагыз әле, хөрмәтле педагоглар.

Педагоглар ике командага бүленеп ярыша. Ярыш дәвамында иң күп балл җыйган команда, әлбәттә, җиңү яулаячак.

<u>**1.**</u> <u>Бирем. Сорау-җавап</u> (Кайсы команда беренче җавап бирә, шул командага балл куела).

1) Гөлшат Зәйнәшева кайчан һәм кайда туган ?

(1928 елның 13 гыйнварында Тукай районы Иске Теләнче авылында туа)

2) 2 яшьлек кечкенә Гөлшат нинди сәбәп аркасында асрамага бирелә?

(Әтисе Хисам абый сөргенлеккә озатыла.Әнисе Әнвәрә апа өч баланы үстерә алуына ышанмый.Шунлыктан Гөлшат әтисе ягыннан туганнарына асрамага бирелә.)

3) Кайда һәм нинди уку йортларын тәмамлаган?

(Минзәлә педагогия училищесын һәм Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый).

4) Укуны тәмамлагач кайда һәм нинди һөнәр белән шөгыльләнә?

(Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире булып хезмәт куйган)

5) 1958 елда дөнья күргән беренче шигырьләр китабының исеме?

(беренче китабы «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле була)

6) Гөлшат Зәйнәшева 1988 нче елда нинди мактаулы исемгә лаек була?

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | и | к | ы | з | ы | к | **ш** | ү | р | ә | л | е | | | | | | | |
| т | у | г | а | н | ж | и | р | е | м | т | а | т | **а** | р | с | т | а | н | | | | | | | |
| | | | | | | | | | к | о | я | ш | **г** | о | м | е | р | е | | | | | | | |
| | | | | | | к | а | л | ф | а | к | л | **ы** | с | а | н | д | у | г | а | ч | | | | |
| | | | | | | | | | ш | а | г | ы | **й** | р | ь | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | к | л | ю | ч | е | **р** | е | в | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | **ә** | б | и | е | м | н | е | я | р | а | т | а | м |

(«Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә ).

7) 1991 елда Гөлшат Зәйнәшевага «Илле җыр» исемле китабы өчен нинди Дәүләт бүләге тапшырыла?

(Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе тапшырыла)

8) Казанның 13 нче китапханәсе Гөлшат Зәйнәшева белән ничек бәйле?

(Казанның 13 нче китапханәсендә Гөлшат Зәйнашева музее эшли)

Бирем: кроссворд чишү. (Дөрес чишсәгез Гөлшат Зәйнашевага бәйле сүз укырсыз. Кайсы команда бу сүзне беренче таба шул командага балл бирелә.)

1) Гөлшат Зәйнәшева Татар дәүләт «Әкият» курчак театры өчен иҗат иткән спектакльнең исеме. (И, кызык шүрәле!)

2) Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган, Татарстан родиосының позывное булган, рәсми чараларны ачып җибәрүче җырның исеме . (Туган җирем – Татарстан)

3) Гөлшат Зәйнашеваның Әниләргә гимн дип йөртелә торган җырының исеме. (Кояш гомере)

4) Гөлшат Зәйнашеваның Сара Садыйковага багышлап язган китабының исеме.(Калфаклы сандугач)


5) Дөньядагы бөтен һөнәрләрнең
иң сәере, иң-иң көмешсезе,
иң-иң өлешсезе тиде миңа...
Минем «һөнәр» – шигырь язучы...(авторның һөнәре ? ) (шагыйрь)

6) Гөлшат Зәйнашеваның бик күп җырларына көй язган атаклы композитор. (Ключарев)

7) Гөлшат Зәйнашеваның оныклары Дания белән Камилгә багышлаган балалар китабының исеме. (Әбиемне яратам)

3. Бирем: Ребус чишү. (Ребус дөрес чишелсә Гөлшат Зәйнашеваның Казаныбызның 1000 еллыгына багышлап иҗат иткән җырының исемен табарсыз. Кайсы команда беренче чишеп бетерә, шул командага балл куела. )

1)




(«Яшәрәсең, Казан, янарасың»)

4. Бирем: Серле тартма.

Бу тартма эчендә язчы белән турыдан туры бәйләнгән предмет яшерелгән. Сезгә аны тасвирлап күрсәтәм, ә сез аңларга тырышыгыз һәм нәрсә икәнен язызгыз.

Бу предметның тарихы кешелек барлыкка килү белән башлана. Борынгы заманнарда бу предметны таш, сөяк, агач, күмер алыштыра. Вакыт уза, бу предмет та үзгәрә, камилләшә. Тора-бара аны каз каурыеннан ясый башлыйлар. Вакыт узу белән бу предмет тагы да камилләшә бара, ләкин ул куллану өчен бик уңайлы булмый. Кулланыр алдыннан аны манчып алырга туры килә. Күп тә үтми аның манчымыйча гына кулла торганын уйлап табалар, ләкин чит илдә. Ә безнең илдә ул 1960 елның ахырында күренә башлый. Аны чит илгә чыгу бәхетенә ирешкән дипломант, спортчылар, сәнгать кешеләре алып кайта. Бәхеткә каршы 1965 елда бу предметны үзебезнең илдә дә җитештерә башлыйлар. Ләкин аның бәясе шактый кыйммәт була. Ул 2 сум тора. Тора-бара аның бәясе 1 сумга һәм ниһаять 35 тиенгә төшә. Язучылар, шагыйрьләр өчен ул – эш коралы. Алар бу предметны бик яратып «тибрәтәләр». Яшь, талантлы язучыларга аның бәллүрен, алтынын, көмешен бирәләр. Хәзерге заманда аннан башка тормышны күз алдына китереп булмый дисәм, бәлки ялгышырмын.... Чөнки кулларыбызда телефон, өсталлардә компьтерлар тора. Серле тартма эчендә нәрсә? (язу каләме)



5. Кроссенс “Гөлшат Зәйнашева”. Командаларга бирем – кроссенс төзү.

| | | |
|---|---|---|
|  **Минзәлә педагогия училищесы** |  **Казан дәүләт педагогия институты** |  |
|  |   |  |
|  **Минзәлә дәүләт театры** | ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ • СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА |  |

6. Бирем:“Шагыйрә ,   син  нинди?”

Безнең уенның  исеме  “Гөлшат Зәйнашева  – яралы язмышлы шагыйрә” дип атала. Татарстанның  күренекле   шагыйрәсе Гөлшат апа Зәйнашева. Нинди ул ?  Алдагы бирем:

шагыйрә  сүзенең һәр хәрефенә Гөлшат Зәйнашевага   хас сыйфатлар уйлап әйтергә кирәк.

(Ике комндага да балл куела)

Ш – шаян, шифалы, А –  акыллы, алыштыргысыз, Г –  гади, гармонияле, Ы – ышанычлы, ыспай, Й –  йомшак күңелле, йолдызлы, Р – риясыз, рухлы, Ә –  әдәпле, әһәмиятле.

7. Йомгаклау.  (Нәтиҗә чыгырыла һәм җиңүче команда билгеләнә)

Уеныбызны  Гөлшат Зәйнашеваның  шигырь  юллары белән тәмалыйсым кылә:

Җырладым илемне мактап,

Җырга бирдем бар көчем,

Илемнең — күге,  халкымның

Күңеле яктырсын өчен.

Үзем китсәм, калыр моңлы

Җырым  кинәт бүленеп,

Туган як каеннарының

Яфрагына эленеп,  - дип язган  ул.

Ул һәрчак безнең хәтерләрдә, күңелебез түрендә.  Гөлшат Зәйнашева кебеп талат ияләренең  безнең арабыздан китсәләр дә тормышлары дәвам итә. Үзләре калдырган бай мирас  аларны халкының  күңел  түрләрендә  яшәтә. Ул үзенең җырларында, ул үзенең шигырьләрендә,  үзенең әсәрләрендә .... Ул һәрвакыт безнең белән. Бу һичшиксез  шулай. Мин моңа чын күңелем белән ышанам! Катнашуыгыз өчен рәхмәт, уен кызыклы һәм файдалы булгандыр дип ышанып калам, барыгызга да уңышлар телим. Сау  булыгыз!

**Шат күңелле, кояшлы шагыйрә**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның тууына

95 ел тулуга багышланган  әдәби-музыкаль кичә)

Сәгъдиева Эльмира Кашаф кызы,   Хәкимҗанова Гөлнара Фәрид  кызы

Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбе, Биектау   районы

Максат: Шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру;  шагыйрә иҗатына кызыксыну уяту, сәнгатьле сөйләм күнекмәсен камилләштерү; укучыларда шагыйрә иҗатына карата ихтирам,  мәхәббәт хисен тәрбияләү.

Сәхнә бизәлеше: стенада зур чәчәкләр, “Гөлшат Зәйнәшеваның  тууына  95 ел” дип  язылган  плакат, шарлар эленгән. Шагыйрә китапларыннан  оештырылган күргәзмә, шигырьләренә укучылар  ясаган  рәсемнәр.

Бәйрәм барышы

Сәхнәдә “Тәфтиләү” көе яңгырый. 2 алып баручы чыга.

1 алып баручы. Газиз туган җирем – бәхет илем,

Гөлбакчалы алтын бишегем!

Синдә тудым, синдә яшимен мин!

Сиңа баглыйм иҗат җимешен! – дип язган күренекле шагыйрә, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнәшева.

2 алып баручы. Шагыйрь күңелендә балкый кояшлы күк,

Сайрап тора тургай, былбылы.

Әллә ничә төрле көй чыгара

Шагыйрь йөрәгенең мең кылы.

Анда шаулый Идел дулкыннары,

Анда җырлый Урал таулары,

Анда чәчәк ата саф мәхәббәт,

Анда – яшьлек кыңгыраулары...

1 алып баручы. Туган ягына, мәхәббәткә, матурлыкка дан җырлаучы сандугачыбыз, халкыбызның асыл кошы Гөлшат Зәйнәшеваның тууына быел 95 ел.

2 алып баручы. Татар сәнгате, мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән шагыйрәбезнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган кичәбезне башлыйбыз.

Концерт номеры. Сезнең игътибарга 9 нчы сыйныф кызлары “Очрашу” җырын бүләк итә. Рәхим итеп тыңлагыз.

1 алып баручы. Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында хәзерге Тукай районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә. Әтисе урта хәлле крестьян Хисам абый 1930 нчы елда кулак дип гаепләнеп, Архангельск өлкәсендәге Соловки лагерена озатыла. Күпләр бу лагерьдан кире кайта алмыйлар. Хисам абыйга да кайту насыйп булмый.

2 алып баручы. Биш бала белән йорт-җирсез, хәерче хәлендә калган әнисе Әнвәрә апа 2 яшьлек Гөлшатны туганы Маһнуй апага асрамага бирергә мәҗбүр була. Ятимә Гөлшатның бала чагы һәм яшүсмер чоры бик авыр елларга туры килә.

1 алып баручы. Сыйныфташы Хәсән ага Гәрәев: “Гөлшат гел “5” легә генә укыды, һәрчак беренче рәттәге партада утырыр иде”, - дип искә ала. Гөлшат күрше Хуҗәмәт авылына 5 чакрым җәяү йөреп белем ала. Аннан соң 1942-1945 елларда Минзәлә педагогика училищесында (хәзер көллият) 14 яшеннән үз көнен үзе күреп, бик яхшы укый. Кешеләргә идән юып, бәрәңге бакчаларын казып җан асрый. Берничә кыз янгын сүндерүчеләр каланчасы астындагы җылытылмый торган бүлмәдә яшиләр. Кышкы салкыннарга түзәр чама калмагач, Гөлшат, кирпеч ватыклары җыеп, кечкенә генә галанка миче чыгарып куя. Моңа янгын сүндерүче абыйлар да шакката. Ә иптәш кызлары чиксез шатлана.

2 алып баручы. Гөлшат бик елгыр, җитез кыз була, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар стена газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга.

Концерт номеры. (Салмак көй яңгырый.) Укучылар “Бер дус кешемә”,

“Эзлим әле” шигырьләрен сөйлиләр.

1 алып баручы. Гөлшат апа Зәйнәшева 1945-1949 елларда Казан педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Институтны тәмамлагач, бик җаваплы эшләрдә хезмәт итә. Татарстан радиосында 16 ел дәвамында башта әдәби-драматик, соңрак музыкаль тапшырулар мөхәррире була, вазифаларын иҗади якын килеп, җиренә җиткереп башкара. Бирелә ул язучылар, күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралаша, үзе дә иҗатка кереп китә.

2 алып баручы. 1958 елда аның «Тыңларсыңмы җырымны?» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә, иҗат дәверендә нәшер ителгән аерым китаплар саны 25кә җитә. Бик күп җырлары күмәк җыентыкларда миллионнарча тираж белән басылып чыга.

Ә хәзер сүзне мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучысына бирәбез. Ул сезне Гөлшат Зәйнәшева турындагы истәлекләр белән таныштырыр. (Укытучы шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның исән чакта районыбыз мәктәпләрендә укучылар белән очрашуларда булуы, күрше авылыбыз Дөбьяз мәктәбенә дә килүе турында сөйләде. )

1 алып баручы. Гөлшат апаның акылы-фигыле искиткеч күркәм, бай рухлы була. Киң күңелле, кешеләрне яратучан, ярдәмчел һәм игътибарлы булганга, аның үзен дә яраталар, хөрмәт итәләр. Гөлшат Зәйнәшева ихласлылыгы белән һәркемне үзенә җәлеп итә. Тормышта ул күпләргә үрнәк шәхес.

Шагыйрә күңеленә туган ягы табигате илһам, көч бирә. Тирән мәгънәгә ия булган лирик шигырьләре һәркемнең күңел кылларын тибрәтә. Аның иҗатында яшьлек дәрте дә, мәңгелек мәхәббәт темасы да, тормышчанлык та чагылыш таба.

2 алып баручы. (Чишмә агышы тавышы, кошлар сайравы ишетелә.) Сезне 7 нче сыйныф укучылары “Безнең инеш”, “Гөлҗимеш” шигырьләре белән таныштыра.

Концерт номеры. Сезнең каршыгызда 8 нче сыйныф укучылары Гөлшат апа Зәйнәшеваның “Гөлләр иле” җырын башкара.

( Сәхнәгә ике кыз бала чыга. Үзара уйнап-шаярышып йөриләр, берсе “Туган авылым урамы” җырын көйли:

- Дустым, син нинди җыр көйлисең?

- И-и, минем әни гел шушы җырны җырлап йөри. Мин дә аннан отып алдым.

- Минем дә кайдадыр ишеткәнем бар бу җырны. Кара, нинди матур җыр!

- Әнием бу җырны Гөлшат Зәйнәшева язган, ди. Миндә аның китабы да бар.

- Яле, күрсәт әле! (Китапны киштәдән алып күрсәтә.)

- Кара әле, монда никадәрле җырлар бар, йөзләп җыр! Бусын мин дә беләм. (Җырларын карыйлар. Икесе бергә “Җырлыйм әнием турында” җырын башкаралар.)

1 нче алып баручы.

Күрәсезме, киң мәйданга

Шигырь килә!

Шигырь тыңлап, җилләр исә,

Кояш көлә.

Зәп-зәңгәр күк, нур балкытып,

Шигырь тыңлый.

Әйләнәдә илаһият,

Рәхәт шундый…

Сәхнәдә башлангыч сыйныф укучылары.

(Укучылар шагыйрәнең “Телен йоткан Халик”, “Шырпы уенчык түгел” шигырьләрен яттан сөйлиләр.)

2 нче алып баручы. Ә хәзер сезгә 4 нче сыйныф укучылары “Алтын куллар кирәк” шигырен сәхнәләштереп күрсәтәләр. Рәхим итеп карагыз!

1 нче алып баручы. Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итә. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сыный. Әмма ул бөгелми, сынмый. Малга, байлыкка кызыкмый. Аның байлыгы – табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте. Шагыйрәнең иҗаты бүген дә актуаль, шигырь, җыр сөючеләрне үзенә тарта, тормышка ямь өсти.

2 нче алып баручы. Татар халкының олуг мәхәббәтен казанган Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшеваның якты истәлеге киләчәк буыннарның да хәтерендә яшәр! Халкыбыз олы җанлы, игелекле, тынгысыз, һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы булган талантлы кызын онытмас!

1 нче алып баручы. Гашыйк булып бу дөньяга,

Тик җырлап үтте гомер.

Кемнәр моңлы, шулар гына

Хәлемне белсә белер.

Җырладым илемне мактап,

Җырга бирдем бар көчем.

Илемнең күге, халкымның

Күңеле яктырсын өчен.

Үзем китсәм, калыр моңым,

Җырым кинәт бүленеп,

Туган як каеннарының

Яфрагына эленеп.

(Кичәдә катнашкан укучылар барысы да хор белән кичәне йомгаклап, ”Сәяхәтче җыры”н башкаралар.)

**Барлык һөнәрләр дә яхшы, барлык һөнәрләрләр кирәк**

Сиразетдинова Гөлшат Рәис кызы

Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге

6 нчы санлы "Теремкәй" балалар бакчасы, Сарман районы

Максат: балаларның һөнәрләр турындагы белемнәрен үстерү.

Бурычлар:

1. Балаларның һөнәрләр турындагы күзаллауларын камилләштерү, сүзлек байлыгын арттыру.

2. Күзәтүчәнлекне, танып белү үзенчәлеген, сөйләм телен үстерүне камилләштерү.

3. Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү. «Кем булырга?» шигыре өстендә эшләү;

Җиһазлау: туп, төрле һөнәр ияләренең рәсемнәре, каләмнәр, карточкалар, Гөлшат Зәйнәшеваның “Кем булырга?” шигыре, Г.Зәйнәшеваның тормышы һәм иҗаты турында презентация, кояш рәсемнәре (шат, моңсу).

Эшчәнлек барышы:

1.Оештыру моменты.

Балалар бүлмәгә кереп түгәрәк ясап басалар.

- Хәерле көн, балалар!

- Исәнмесез!

- Бергәләшеп без басыйк

Бик зур түгәрәк ясыйк,

Куллар җылысын тойыйк,

Шатланышып елмайыйк,

Бер-беребезгә хәерле иртә,

Имин көннәр теләп,

Шөгылебезне башлыйк

- Сез шөгыльгә әзерме?

2. Актуальләштерү: Презентациядә төрле һөнәр рәсемнәре бирелгән ( 1 слайд һөнәрләр рәсемнәре)

- Балалар, рәсемнәргә карагыз, әле, сез кемнәрне күрәсез? (укытучы, төзүче, чәчтараш, тегүче, сатучы, пешекче,табиб, очучы). Нинди бер сүз белән аларны берләштерергә була?

- Болар – һөнәрләр.

- Нәрсә соң ул һөнәр?

- Әгәр дә кеше нинди дә булса бер һөнәр сайлаган икән, димәк ул шул өлкәдә белем алган. Кеше үз һөнәрен яратып, белеп башкарса гына зур уңышларга ирешә ала.

- Әйтегез әле, сез нинди һөнәрләр беләсез? (Балаларның җаваплары).

- Балалар, нинди һөнәр ияләре кайда эшли икән, әйдәгез уйлап карыйк. Туп белән уен “Кем кайда эшли?”

- Рәхмәт сезгә, балалар. Әйдәгез хәзер шөгылебезне өстәлләр артына утырып дәвам итик. (Утыралар). Уен: “Һәр һөнәр иясенең үз эш коралы”. Рәсемдә күрсәтелгән һәр һөнәр иясенең эш коралларын туры китереп беркет.

Ял минуты:

***- Әйдәгез, кулларыбызны ял иттереп алыйк әле.***

***Бу куллар – алтын куллар (****кулларны алга сузып аска, өскә әйләндерәбез****)***

***Аларны без күтәрик*** *( өскә күтәрәбез)*

***Яратыйк һәм иркәлик (****алга сузып, җилпәзә ясыйбыз)*

***Юк алар белмәгән эш (****кулларны бер – берсенә ышкыйбыз)*

***Ялт итә ул торткан төш (*** *кулларны ике якка сузып җибәрәбез).*

- Урыннарыбызга утырыйк.

- Балалар, хәзер сезнең белән Гөлшат Зәйнәшеваның «Кем булырга?» шигыре белән танышып китәрбез. Бу шигырьне шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева язган (слайд 2. Гөлшат Зәйнәшева фоторәсеме). Ул 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Мәктәпне тәмамлагач, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Гөлшат Зәйнәшева бик күп шигырьләр яза. Аның күп кенә шигырьләренә композиторлар көйләр язалар.

- Хәзер мин сезгә «Кем булырга?» шигырен укып китәм. ( Тәрбияче шигырьне сәнгатьле итеп укый).

- Бик матур һәм мәгънәле шигырь, балалар.

- Шигырьдә сүз кем турында бара? (БҖ: Малай турында). (слайд 3. Малай рәсеме сорау билгесе белән)

Шигырь өстендә эшләү. Сорау – җавап.

- Малайның кем булуын телиләр?

- Артист абыйлар кем диләр? – Баянчы (слайд)

- Әтисе кем ди? – Шофер (слайд)

- Әнисе кем ди? – Табиб (слайд)

- Апасы кем ди? – Сатучы (слайд)

- Әбисе кем ди? – Кеше (слайд)

- Шигырьдә нинди һөнәрләр турында әйтелә? (БҖ: Баянчы, шофёр, табиб, сатучы).

- Ә кеше һөнәрме ул? (БҖ: Юк).

- Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Әңгәмә оештыру. Кеше булу, димәк, кешеләргә ярдәм итү, тәртипле булу, намуслы, гадел, эшчән, акыллы, тәрбияле булу...

- Ә сез кем булырга телисез? (Парларда эш. – Син кем булырга телисең?

- Мин .... булырга телим. Ә син?

- Ә мин ... булырга телим.

- Бик әйбәт, балалар.

3. Рефлексив бәяләү.

– Балалар, без бүгенге шөгыльдә нәрсәләр эшләдек? (Балаларның җаваплары).

- Нәрсә соң ул – һөнәр?

- Балалар, без бүген нинди яңа шагыйрә турында белдек?

- Без аның нинди шигырен укыдык?

Үз-үзләрен бәяләү (шат кояш, моңсу кояш).

**Туган җирнең сайрар былбылы**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗаты буенча класстан тыш чара эшкәртмәсе)

Баязитова Гөлфинә Фәһим кызы,

Казан шәһәре 117нче гомуми урта белем бирү мәктәбе

Максат: Татар шагыйрәсе Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру; аның җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү; татар шигърияте карата мәхәббәт уяту.

Сәхнә түренә кичә исеме язылган плакат эленә.

Эпиграф :
Сөйлә, дисәгез, сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткән гомерем бер җыр, бәет-
Барысы чагыла җырымда.

“Әллә кемне күңел сагына” җыры яңгырый ( Г. Зәйнашева сүзләре. М. Имашев музыкасы)

Тын гына халык көе агыла. Сәхнә артында укучы Г. Тукайның “Шагыйрь” исемле шигырен укый. Сәхнә алдына 2 алып баручы чыга.

1нче алып баручы. Әйе, бөек Тукаебызның әлеге шигъри юллары бик төгәл әйтелгән. Чынлап та, әгәр шагыйрьләр күңеле аяз булмаса, безнең йөрәкләребзгә үтеп керә алырлык гүзәл юллар иҗат итә алмаслар иде.

2нче алып баручы: Әйтерсең лә шагыйрьләр гади кешелек тормышында түгел, ә әллә кайларда, безнең төшләребезгә дә кереп карамаган хыял дөньясында, мәңге яшел болыннары булган зәңгәр томаннар артында яшиләр. Ә безгә шушы кешеләрнең иҗатларына баш иярге генә кала. Ләкин ни кызганыч, безнең күбебез шигърият дөньясын онытты, әллә нишләдек без.

Сәхнә артыннан шигырь сөйләгән ишетелә.

Җан ачына, сүзләр усаллана

Кырыс җилләреннән тормышның.

Асылыңа кайт, кардәш, бер сәгатькә

Онытып торыйк дөнья мәхшәрен.

Илһам чишмәсенең тылсымы

Дәрт өстәсен синең күңелгә.

Шатлык бүләк иткән шагыйрәләр

Балкысыннар иҗат күгендә.

1 алып баручы: Хәерле көн, кадерле укучылар, кунаклар. Һәр халыкның үз каһарманнары бар. Ул каһарманнарның төп бурычларыннан берсе- Ходай тәгалә биргән акылын һәм физик куәтен милләтенә багышлау, шул юлда фидакарьләрчә хезмәт итү. Татар халкы, шөкер, андый шәхесләргә бай. Әдәбият-сәнгатебездә дә, фән, музыка өлкәсендә дә. Татар шигъриятендә дә үз йөзен тапкан шәхесләребез аз түгел. Бүгенге бәйрәм кичәбез татар шагыйрәләре иҗатына багышлана.

2 алып баручы: Әйе, шулар арасында Гөлшат Зәйнашева иҗаты аерым урын алып тора. Чыгышы белән Гөлшат моңлы нурлы, гүзәл Сарман якларыннан. Гомумән, Сарман

ул –ямь-яшел урманнары, бормаланып аккан елга-күлләре, оста куллы, җор телле кешеләре белән дан тоткан, әле татарлыгын югалтмаган искиткеч гүзәл як.
1 алып баручы: Чыннан да, Сарман күренекле шәхесләргә, талантлы җырчыларга, язучылар, шагыйрьләргә бик бай як. Татарстанның Г. Тукай, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, халык язучысы Аяз Гыйләҗев, Татарстанның атказанган артисты, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, татар халкының моңлы сандугачы Илһам Шакиров, Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Шәрифуллина – Сарманның данын еракка таратучылар.

9 нчы сыйныф укучысы башкаруында "Шушы яктан, шушы туфрактан без" җыры башкарыла. (К. Булатова сүзл, Ф. Хатипов муз)

1алып баручы: Моңлы ятимлекне күреп үскән, яшьтән үк әдәбиятны яраткан, үзешчән сәнгать һәвәскәре булып авыл сәхнәләрендә, соңрак композиторлар, җырчылар белән тыгыз аралашып яшәүче талант иясе ул – Сарман кызы Гөлшат Зәйнашева.

2 алып баручы: Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнашева – төрле әдәби жанрларда иҗат иткән шагыйрә.

1 алып баручы: Уңдырышлы җирләре, киек-кошларга бай урманнары, елга-сулары белән борынгы бабаларыбызны үзенә җәлеп иткән, җырларда җырланган Сарман якларында бик матур авыл бар. Исеме – Иске Теләнче. Тирә- як ап-ак карга күмелгән экияти серле вакытта, 1928 нче елның 13 нче январенда Иске Теләнче авылында Хисами гаиләсендә бер кыз бала дөньяга аваз сала. Аңа Гөлшат дигән бик матур исем бирәләр.
2 алып баручы: 30нчы еллар – куркыныч еллар, әле дә күпләр күңелендә үзенең кара эзен җуймаган еллар. Тырышып гомер иткән булдыклы гаиләне дә кара болытлар чолгап ала.. Авылда кибет тотулары аркасында Хөснетдин бабасын кулак дип сөргенгә сөрмәкче булалар. Әмма 82яшьлек бабасы урынына Гөлшатның әтисе Хисамины кулак дип Архангельгә озаталар. Мал-мөлкәтләрен тартып алалар, әтисез гаилә урамда кала. Балалар ачтан үлмәсен дип, 2 яшьлек Гөлшатны әнисе Әнвәрә апа Югары Тәкермән авылындагы гаиләгә асрамага бирә.. Шуңа күрә аның балачагы Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында уза. Чит-ят гаиләдә Гөлшатның балачагы авыр була, ятим бала күңеле китек, әти-әни назы җитми сабыйга.

1 алып баручы: Шушы ук авылдагы башлангыч мәктәптә, аннан Хуҗамәт авылындагы җидееллык мәктәптә укый, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Менә шунда инде татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөхәммәт Гарифуллин булачак шагыйрәдә әдәбиятка мәхәббәт уята.

6 нчы сыйныф укучысы Гөлшат Зәйнашеваның истәлекләреннән өзек сөйли: "Безнең тулай торак яңгыр сүндерү бинасының, каланчаның аскы катында иде. Аның миче юк иде. Тулай торак ягылмый иде. Без, студентлар, кышкы салкын көннәрдә чишенмичә генә дәрес әзерли идек. Өскә бишмәт, аякка киез итек кигән килеш, башка шәлләр урап, ятып йоклый идек. Шулай да барыбер туңа идек. Уйладым-уйладым да мич чыгарырга булдым. Кирпеч ватыклары, ташлар җыеп алып кердем дә, бер почмакка мич чыгарып куйдым.Ул мич кыек-мыеграк булса да, хәйран җылыта иде. Калайдан плитә дә әмәлләп куйдым. Шунда аш, бәрәңге пешерә башладык."

1 алып баручы: Менә шундый авыр шартларда да кыз яктылыкка, белем алырга омтыла. Ләкин кызны авыр тормыш әле күп тапкырлар сыный. "Кулак кызы", "халык дошманы баласы" дигән гыйбарәләр тормышта аңа күп киртәләр тудыра. Ләкин ул авырлыклар алдында сынмый, сыгылмый.

2 алып баручы: 1945-1949нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, Татарстан радиокомитетында әдәби

музыкаль тапшырулар мөхәррире, 1952-1963нче елларда Татар китап нәшриятының редакторы, аннан Татарстан язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубы директоры.1973-1983 елларда аның исеме янә Татарстан китап нәшрияты белән бәйләнә.

1 алып баручы: Беренче шигырьләре, пьесалары илленче елларда ук көндәлек матбугатта һәм "Күңелле сәхнә", "Мәктәп сәхнәсе", "Эстрада", "Клуб сәхнәсе" кебек җыентыкларда басыла. Ә 1958 елда Гөлшат Зәйнашеваның "Тыңларсыңмы җырларымны" дигән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә.
2 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның шигърияте – чын, ихлас, хисләргә бай, табигый ачышлы шигърият. Аның шигыръләрен укыгач, матур урманнар, уңдырышлы кыр-басулар, иркен тугайлар, саф сулы чишмәләр күз алдына килә.Туган якны ныграк ярата башлыйсың, табигате белән хозурланасың.Төнбоеклы, мәтрүшкәле, яшь наратлы, салават күперле җанга якын туган җир күңелдә шатлык, ярату, соклану хисләре уята.
1 алып баручы: Чыннан да, Гөлшат Зәйнашеваның шигърияте табигыйлеге, ихласлыгы белән үзенә тартып тора**.** Бигрәк тә балалар өчен язылган шигырьләре күңелгә якын. Балаларда миһербанлылык, кешелеклелек тәрбияләүне шагыйрә төп бурычларыннан берсе итеп ала.

2 алып баручы: Шагыйрә шигырьләрендә балаларны милләтебезгә хас күркәм гореф-гадәтләр, халкыбыз мирасына ихтирам белән карарга өйрәтә, аның нәни геройлары туган якның шифалы яңгырларын, назлы кояшын, җылы җилләрен тоя, чишмә суларын эчеп көч җыя.

1 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләре музыкаль аһәңе белән дә аерылып тора. Шуңа күрә аның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә җәлеп итте. Татарстан һәм Башкорстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзләгән шигыренә көй язылган. Алар арасында танылган композиторлар – Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Әхмәт Фәйзи, Александр Ключарев, Сара Садыкова. Алар аның шигъри юлларга салынган әсәрләренә көй язып аларны дөньяга танытты.

2 алып баручы: Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Хәйдәр Бигичев, Фәридә Кудашева кебек татар халкының моңлы сандугачлары башкаруында алар музыкаль поэтик шедеврларга әйләнделәр.

Язмада "Китмә, сандугач" җырыннан өзек яңгырый.

алып баручы: Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган лирик шигырьләре халыкчан, алар искиткеч гади, ритмик яктан төзек, хисчән.
2 алып баручы: Әйе, Гөлшат Зәйнашева – иң популяр җырлар авторы. Бер карасаң, җыр язуның әллә ни авырлыгы да юк кебек. Ләкин, башта сүзләр шагыйрәнең күңелендә бөреләнәләр, аннан чәчәк аталар, бары шуннан соң гына йөрәк түреннән ургылып чыгып шигъри юлларга салыналар.

2 алып баручы: Язучы Гариф Ахунов аның иҗатын югары бәяләп "Гөлшат Зәйнашева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда Язучылар союзына член итеп кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул иткән "Менәргә иде Урал тауларына", "Китмә, сандугач" кебек бай, романтик җырлары дистәгә якын. Сүзләренә тәңгәл килә торган киң колачлы музыка белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп, бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр".
1алып баручы:

Менәргә иде Урал тауларына,
Басарга иде кыя ташына.
Шул кыядан кушылып җырлар идем
Урал бөркетләре тавышына.

Әлеге юллар заманында тәнкыйть утына да эләгә. Янәсе, без космоска менү турында уйлыйбыз, ә Гөлшат өчен тау башына менү дә ниндидер хыял гына. Ләкин болар шигырьнең дәрәҗәсен төшерә алмый. Киресенчә, бу шигырь күренекле композитор Мансур Мозаффаровның игътибарын җәлеп итә. Бу искиткеч матур шигырьгә көй языла һәм татарның моңлы сандугачы Илһам Шакиров репертуарына килеп керә.Бөек җырчы башкарган җырның киләчәге инде бәхетле.

2 алып баручы: Ә бит бу җырның мәгънәсе тауга менү яки менмәү генә түгел, кеше күккә-биеккә ашкына, ул канатлы булып яшәргә тели.

10нчы сыйныф укучысы сәхнәдә “Менәргә иде Урал тауларына” җырын башкара.

1 алып баручы: Мәхәббәт – кеше тормышында була торган иң гүзәл хис. Гөлшат Зәйнашеваның күп кенә җырлары мәхәббәт турында. “Кичегеп килгән мәхәббәт”, “Аерылмагыз”, “Зәңгәр төймә”, һ. б. Автор өчен мәхәббәт, ярату, сөю – кешене бәхет канатларында йөздерүче төшенчәләр. Гашыйк булган һәм ярата белгән, яратыла алган кеше генә чын мәгънәсендә бәхетле була ала. Сезнең өчен 9 нчы сыйныф укучысы “Мин бит кара карлыгач” җырын башкара. ( Ш. Тимербулатов көе)
1алып баручы: Шагыйрә яктырткан темаларның берсе туган җиргә, табигатькә мәхәббәт.
2 алып баручы: Туган як һәркем өчен бик кадерле, газиз. Туган якта әти-әниең, туганнарың. Туган ягыңда син иркенләп сулыйсың, шуңа күрә аның һавасы да сиңа дәва бирә. Хәзер

Гөлшат Зәйнашева

Якты киләчәкле телем,

Саф, пакъ телем, бай телем.

Җаннарыңны эретерлек

Йомшак сары май телем.

1нче алып баручы: Әйе, балалар, туган телебез хәзинәсен шундый матур шигырьләр ярдәмендә өйрәнәсез икән, афәрин, телебез югалмас.

2 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның җырлары җаннарны иркәли, назлый. Күңелләргә дәрт бирә. Аның иҗатын Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми бик югары бәяләде.

2 алып баручы: “Гөлшат Зәйнашева җырларының сихри бер үзенчәлеге, күңелне яулый торган сихри көче бар. Аларга гомумкешелек тойгылары салынган. Сәнгатьнең бөтен көче дә шунда түгелме соң?” Сезнең өчен сәхнәдә “Үз илемдә” җыры яңгырый.
1 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның танылган шәхесләргә багышлап язылган җырларын да халык яратып тыңлый.Алар арасында- “Ак болан”, “Хәйдәр җыры” аеруча күңелдә кала.

“Күлмәе”

3 алып баручы: Әни, әнием, “Әнкәй” сүзе үзенчә йомшак, ягымлы, олы бер мәгънәгә лаек искиткеч матур сүз. Берни белән дә тиңли алмаслык газиз, бердәнбер кадерле кеше! Кешедә булган бөтен гүзәллек әнидән килә. Әнисез шагыйрь дә, батыр да юк.
4 алып баручы: Әни назын күреп үсмәсә дә, Гөлшат Зәйнашева иҗатында әниләр темасы аерым урын алып тора. Сезнең өчен “Җырлыйм әнием турында” җыры яңгырый.

(Г. Зәйнашева сүзл., Ф. Әхмәдиев муз)

1 алып баручы:”Гөлшат Зәйнашева популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйды!” - дип юкка гына әйтмәгән Роза Хафизова да. Шагыйрәнең шушы һәм тагын бик күп җырлары татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итә.

“Йөрдем”

2 алып баручы: Гөлшат Зәйнашева иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

8 нче сыйныф укучысы “Туган авылым урамы” җырын башкара ( Г. Сәйфуллин көе)

4 алып баручы: Гөлшат Зәйнашева драматургиядә дә көч сынаган, бик матур ягымлы, укучы күңеленә үтеп керә торган пьесалар язып калдырган язучы. Аның “Бәхет кошым”, “Рамай”, “Ирексездән әрәмтамак”, “Гүзәл” пьесалары 1960 нчы елларда Минзәлә драма театры сәхнәләрендә гөрләп барды. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәләрендә “Гайфи бабай, өйлән давай”, “Җаным җәл түгел сиңа” спектакле бүген дә зур уңыш белән бара. Ул “Әкият” курчак театры өчен дә әсәрләр язган. Бигрәк тә Тукайның “Шүрәле”. “Татарстанның Яңа гасыр” телеканалында Г. Зәйнашева сценарие буенча

3 алып баручы:. Әйе, Гөлшат Зәйнашева – җырчы-шагыйрә. Аның бик күп җырлары татар музыка сәнгатенең алтын фондына кергән. Республикабызның беренче президенты Минтимер Шәймиев аның иҗатын югары бәяләде: ”Гөлшат Зәйнашева үз-үзенең бәһасен белә торган хатын-кыз гына түгел, иҗат кешесе буларак та шәхес тә. Ә бит аның тормышын карасаң, анда әчесе күбрәк, төчесенә караганда,”- дип әйтте ул.

Идел ярларына нурлар сибеп,  
Матур булып ата бездә таң.  
Таң шикелле якты туган илем,  
Бәхет биргән җирем – Татарстан.

Әлеге җырлап торган юлларга композитор Александр Ключарев көй язган. Бу җыр Татарстан АССРның төзелүенә 40 ел тулу уңае белән оештырылган конкурста җиңеп чыккан. Заманында Татарстан гимнын үтәгән.

Сәхнәдә 9нчы сыйныф укучысы “Туган җирем – Татарстан” җырын башкара.

3 алып баручы: Гөлшат Зәйнашеваның шигърияте кешенең күңелен күтәрә, рухын баета, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Ул шигырьләрендә, җырларында, әсәрләрендә, татар күңелендә мәңге яшәр.

2 алып баручы: Шуның белән шагыйрә иҗатына багышланган кичәбез тәмам. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.

**Гөлшат Зәйнәшева тормышына - иҗатына багышланган башваткыч уены**

Мәхмүтова Резедә Рафаэль кызы,

Вахитов районының 14 нче номерлы рус-татар мәктәбе

Казан шәһәре

Максат: Укучыларны Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗаты белән таныштыру, шигырьләрен сәнгатьле уку, сәхнәләштерү, җырларын җырлау. Шагыйрә иҗатына мәхәббәт уяту.

Җиһазлау: проектор, презентация, Г.Зәйнәшева портреты, китапларыннан күргәзмә.

Уенның барышы

Алып баручы:

Сөйлә, дисәгез сөйлимен

Үткән гомерем турында.

Үткәннәрем – бер җыр, бәет,

Барысы чагыла җырымда...

Исәнмесез, хөрмәтле укытучылар, укучылар һәм уеныбызда катнашучылар! Бүген "Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе», Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗатына багышланган Башваткыч уенын уйнаячакбыз. Уен булгач, катнашучылар булырга тиеш, шулай бит. Әйдәгез үзләре белән якыннан танышыйк. (Катнашучы укучылар белән таныштырыла).

Алып баручы: Мин сезне уенның тәртибе белән таныштырып үтәм. Экрандагы шакмакларга 20 сорауның җавабы яшерелгән. Җавапны белсәгез, өстәлдәге уен коралларын яңгыратасыз һәм җавапны әйтәсез. Һәр җавап өчен бер балл. Сез җавап бирә алмаган сорауларга җанатарларның җавап бирә ала. Һәм ул баллны алар үзләре теләгән уенчыга тапшырырга мөмкин. Иң күп балл җыйган уенчыбыз җиңүче. Аның супер-уенда катнашу мөмкинлеге бар. Әгәрдә экранда язылган мәкальне дә әйтеп бирсә, аннан да бәхетле кеше булмаячак. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылача. Тапшыруның төп призы, супер уенда җиңүчегә махсус бүләк.

Алып баручы: Уеныбызны башлыйбыз!

Сулдан уңга 1нче сан, 7 хәреф

Гөлшат Зәйнәшева туган авылы? (Теләнче)

Алып баручы: Кайсыгыз төгәлрәк итеп әйтә ала?

Көтелгән җавап: Гөлшат Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа.

Алып баручы: Дәвам итәбез. Уңнан сулга 5 нче сан, 5 хәреф

1930 елда Гөлшат Зәйнәшеваның әтисе авылдан куарга сәбәп иткән нәрсә. (кулак)

Алып баручы: Әйе, 1930 елда авыл халкын күмәк хуҗалыкларга берләштерү чорында, Гөлшатларның гаиләсен «кулак» тамгасы белән читкә сөрәләр.

Дәвам итәбез.

Уңнан сулга 8 нче сан, 3 хәреф

Хисам абыйны авылдан куганда Гөлшатка ничә яшь була? (ике)

Алып баручы: Афәрин.

Өстән аска 1 нче сан, 8 хәреф

Ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмиләр. Кайсы авылда калдыралар? (Тәкермән)

Алып баручы: Чыннан да, әти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак, юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә калдыралар. Алдагы сорау. Сулдан уңга 11 нче сан, 6 хәреф

Әлеге апаның исеме? (Маһнуй)

Алып баручы: "Берсеннән-берсекечкенә биш кыз бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач,

хәерче хәлендә ялгыз калган Әнвәр апа ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы - Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһнуй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була”, – дип яза туганы Марс Гаитов “Җырга багышланган гомер” мәкаләсендә. Балачагы шул авылда уза. Шунда башлангыч, Хуҗамәттә җидееллык мәктәпне, аннан Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлый.

Өстән аска 6 нчы сан, 5 хәреф

Укуын кайсы шәһәрдә дәвам иттерә? (Казан)

Алып баручы: Афәрин. Төгәлрәк итеп әйтеп бирә алмыйсынмы?

Көтелгән җавап: 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Алып баручы: Бүгенге көндә КДПУ ничек атала? Кайда урнашкан?

Көтелгән җавап: Казан Федераль Университеты , Татарстан урамы, 2 нче йорт.

Алып баручы: Укып бетергәч, диплом алгач нишлиләр?

Көтелгән җавап: эшли башлыйлар.

Алып баручы:

Өстән аска 4 нче сан, 8 хәреф

Гөлшат Зәйнәшева кем буларак эшли башлый? (мөхәррир)

Алып баручы: Әйе, Гөлшат апа 1949 елдан Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, 1952-1963 елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият мөхәррире, 1964-1965 елларда Татарстан радиокомитетында музыкаль тапшырулар мөхәррире булып эшли.

Сулдан уңга 15 нче сан, 6 хәреф

Шагыйрь нәрсә яза? (шигырь)

Алып баручы: Шигырь дигәннән, сез Гөлшат апа Зәйнәшеваның нинди шигырьләрен беләсез? (Бер яки берничә укучы шигырь сөйли)

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшева шигырь, җыр, эстрада, драма әсәрләре иҗат итә. Беренче иҗат тәҗрибәләре вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. Сез газета-журналлар укыйсызмы?

Көтелгән җавап: “Сабантуй”, “Ялкын”, “Татарстан яшьләре” һ.б.

Алып баручы:

Өстән аска 16 нчы сан, 5 хәреф

Зур күләмле драма әсәре. (“Рамай”)

Алып баручы: Афәрин. Зур күләмле «Рамай» пьесасы халык театрлары сәхнәсендә уңыш казана. 1958 елда лирик шигырьләре тупланган «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1958-2005 елларда авторның төрле жанрда язылган ике дистәдән артык китабы басылып чыга. Г. Зәйнәшева җыр өлкәсендә актив иҗат итә. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан йөзгә якын шигыренә көй язган.

Сулдан уңга 10 нчы сан, 9 хәреф

Җырның исемен дәвам ит! «Туган җирем – ... (Татарстан)

Без шул җирлектә яшибез.

Алып баручы: Көйнең авторын әйтә аласызмы?

Көтелгән җавап: Александар Ключарев.

Алып баручы: Әйе. Аның шигырьләренә танылган композиторлар көйләр язалар. Рөстәм Яхин «Китмә, сандугач", Мансур Мозаффаров «Менәргә иде Урал тауларына», Сара Садыйкова «Үз илемдә» җырлары. Әйдәгез әле, "Үз илемдә" җырың тыңлап китик. (Катнашучы укучы яисә җанатар җырларга мөмкин, аңа 1 балл өстәлә).

Алып баручы:

Сулдан уңга 2 нче сан, 7 хәреф

Су ләласы (төнбоек).

Алып баручы: Төнбоекны күргәнегез бармы? Гөлшат Зәйнәшеваның да бу матур чәчәккә багышланган шигыре – җыры бар.

Йөрим таңда су буенда,

Тирә-ягым гөл-чәчәк.

Шул гөл-чәчәк арасында

Ошый миңа бер чәчәк.

Ул ак чәчәк – ак төнбоек,

Тибрәнә таң нурында.

Ак чәчәк дип юри җырлыйм,

Бәгърем, синең турында.

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшеваның халык язган җырлары да бар.

Өстән аска 3 нче сан, 8 хәреф

Төшеп калган сүзне бел. (карурман)

Кердем __________,

Калдым караңгыларга.

Газиз башлар сау булганда,

Нигә ямансуларга.

Алып баручы: Бу җыр нәрсә турында?

Көтелгән җавап: сагыну, сагыш турында

Алып баручы:

Өстән аска 7 нче сан, 5 хәреф

Карт Гайфи кем була? (бабай)

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшеваның драматург буларак таныткан драма әсәре ул "Гайфи бабай, өйлән, давай" комедиясеедер. Чөнки бүгенге көндә дә Тинчурин театры сәхнәсендә уйнала. Шул ук театрда «Җаным җәл түгел синә» комедиясе дә уңыш казана. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак» һ. б. драма-комедияләре Минзәлә һ. б. татар театрлары сәхнәсендә күрергә мөмкин.

Алып баручы:

Башваткычның яртысын чишеп тә чыктык. Кемнең ничә балл җыйганын карап алыйк әле. (Уйнаучыларның баллары әйтелә)

Алып баручы:

Уеныбызны дәвам итик.

Султан уңга 9 нчы сан, 3 хәреф.

Чиктәш республиканың башкаласы. (Уфа)

Алып баручы:

Уфада яшәп иҗат итүче танылган җырчыларыбыз – Айдар Галимов, Фидан Гафаров репертуарларында да Г.Зәйнәшеваның җырлары бар. Мисал өчен “Кәркәле таулары”

Керкәле таулары биек,
Биек булса да меник.
Туган җирнең, сөйгән ярның,
Дусларның кадерен белик...

Алып баручы:

Султан уңга 13 нче сан, 6 хәреф

Уйна фигыле юклыкта. (уйнама)

Алып баручы:

Башка кызлар җырлаганда,
Гармуныңда уйнама.
Миннән башка бер генә дә
Кыз турында уйлама.

Син гармунчы, мин җырчы,
Мин җырчы, син гармунчы.
Гармуныңда матур итеп
Гел уйнап кына торчы, - дип яза шагыйрә.

Алып баручы:

Султан уңга 17 нче сан, 6 хәреф

Дәвам ит.

Салават... (күпере)

Алып баручы: Күпер турында әдәбиятыбызда шигырьләр шактый. Гөлшат Зәйнәшеваның да шигыре – җыры бар. “Минзәлә күпере” дип атала.

Минзәлә күперен кичтем

Пар атларды очып кына.

Яшьлектә сөйгән ярымның

Билләреннән кочып кына.

Алып баручы:

Султан уңга 19 нчы сан, 5 хәреф

Гөлшат Зәйнәшева җырыннан...

Лирик герой кайда адашып йөргән? (урман)

Анда агачлар күп үсә. Җәен гөмбәгә, җиләккә барабыз...

Алып баручы:

Җырның исемен кайсыгыз белә?

Көтелгән җавап: “Урманнарда йөрдем”, халык көе

Алып баручы:

Җырлыйбызмы бу җырны? (Җыр бер  катнашучы тарафыннан я күмәкләшеп җырланыла).

Алып баручы:

Сулдан уңга 21 нче сан, 6 хәреф

Дәвам ит. Зөһрә_________ (йолдыз).

Алып баручы: Зөһрә йолдыз турында төрле варианттагы легендалар бар. Сез кайсын беләсез?

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшеваның да Зөһрә йолдыз дигән шигыре-җыры бар.

Зөһрә йолдыз – таң йолдызы,

Таң беленгәч сүнер ул.

Кунак булып кына, дуслар.

Килә икән яшь гомер.

Алып баручы:

Сулдан уңга 22 нче сан, 6 хәреф

Төшеп калган сүзне тап.

Мин бит кара карлыгач,
Канатым кыйгач-кыйгач;
Канатсыз калырмын, бәгърем,
Мин _______ аерылгач (синнән)

2 зат алмашлыгы, чыгыш килешендә .

Алып баручы: бу җырны кайсыгыз белә. Ничек атала?

Көтелгән җавап: “Мин бит кара карлыгач”, Шамил Тимербулатов көе

Алып баручы:

Өстән аска 18 нче сан, 5 хәреф

Синонимын әйтергә. Узган (үткән)

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшеваның  “Аерылмагыз” җырын беләсезме? Танылган җыр.

Сулдан уңга 20 нче сан, 5 хәреф

“Аерылмагыз” җырында автор кешене нинди кош белән чагыштырга?(Аккош)

Алып баручы: Безнең берничә сорау гына калып бара.

Гөлшат Зәйнәшеваның шәхси тормышына күчәбез.

Өстән аска 12 нче сан, 4 хәреф

Гөлшат апаның кызының исеме? (Асия)

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшеваның кызы Асия, оныклары Дания белән Камил.

Алып баручы:

Өстән аска 18 нче сан, 4 хәреф

Язның беренче ае (март)

Алып баручы: Гөлшат Зәйнәшева 1983 елдан һөнәри язучы буларак әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

2005 март аеның тулы ай яшәп, шагыйрәбез 1 апрелендә Казан шәһәрендә шагыйрә якты дөнья белән хушлаша.

Алып баручы: Соңгы сорау.

Сулдан уңга 7 нче сан, 5 хәреф

Куркакның синонимы. (батыр)

Алып баручы: Нинди кешене батыр дип атыйлар? Гөлшат Зәйнәшева да батыр, кыю йөрәкле була. Аны “халык дошманы” дигән сүз озак еллар буе эзәрлекләсә дә, ул югалып калмый. Үз дигәненә ирешә, иҗат итә. Сугыш елларында Минзәләдә укыганда аларның бүлмәсе бик салкын була, кыю Гөлшат шул вакытта мич чыгарып куя. Ул тырыш та, юмарт та була...

Алып баручы: Менә башваткычыбызның бөтен шакмаклары да ачылып бетте. Уеныбыз тәмам. Кемнең күпме балл җыйганын игълан итәм. _____.

Бәйгенең иң матур мизгелләре – бүләк тапшыру. (Бүләкләр тапшырыла, җиңүчегә супер уен тәкъдим ителә)

Сезнең супер уенда катнашу мөмкинлегегез бар. Экранда Г. Зәйнәшеваның шигыреннән бер өзек биреләчәк. Аның бер сүзе генә ачылган. Әгәр шул өзекне тулысынча укып, шигырьнең төгәл исемен белсәгез, менә бу төп приз – автомобиль (уенчык) сезнеке! Әйтә алмасагыз, ни кызганыч машина бездә кала, бүләгегез белән дә хушлашырга туры килер. Уйнап карыйбызмы?

Алып баручы:

_________ __________ __________


Кабат-кабат ___________.


Туган авылым урамы.


Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады –
Бәхетемә юрадым)

Алып баручы: Хөрмәтле уенчыларыбыз, кадерле укытучылар, укучылар. “Башваткыч” уены бүгенгә тәмам. Барыгызга да зур рәхмәт! Гөлшат Зәйнәшеваның күп җырлары мәхәббәт, сагыш турында. Аның җырлары озак еллар җырланыр дигәндә теләктә калам. Уеныбызны танылган “Аерылмагыз” җыры белән тәмамларга чакырам!

(“Аерылмагыз” җыры җырланыла)






## Г. Зәйнәшева иҗаты белән таныштыру

( 3 нче сыйныфта әдәби уку дәресе)

Кашапова Гөлназ Марс кызы,

Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе,

Сарман районы

Дәрес тибы: яңа белемнәрне ачу дәресе.

Җиһазлау: проектор, ноутбук.

Материал: 3 нче сыйныф өчен дәреслек, кук китабы, карточка.

Максат: Г.Зәйнашеваның “ Безнең  семья”, “ Кояш  гомере” шигырьләре белән танышу, авторның  иҗатын  һәм биографиясен тирәнтен өйрәнү.

*Планлаштырылган нәтиҗәләр*: Предмет – яңа лексиканы актуальләштерү, татар әдипләре иҗаты үрнәкләре белән таныштыру.

*Шәхескә кагылышлы* – татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру, укуга мәхәббәт тәрбияләү.

Метапредмет нәтиҗәләр:

*Регулятив универсаль уку гамәлләре:* эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую  һәм эшне планлаштырырга өйрәнү; эш тәртибен аңлап, куку эшчәнлеген оештыра белү; билгеләнгән критерийларга  таянып эш сыйфаларын бәя бирә белү.

Танып белү универсаль уку гамәлләре: аңлап уку; төп мәгълүматны аеру; фикерләрне логик чылбырга салу; эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре: әңгәмәдәш белән аралашу калыбын  төзү; аралашу.

Дәрес барышы:

1.Оештыру өлеше.

Белем иле кайчак миңа

Никтер серле урман кебеку

Ә юллры кызыктырып,

Гел чакырып торган  кебек.

2. Актуальләштерү.

Өй эшләрен тикшерү

3. Проблемалы ситуация тудыру һәм дәреснең темасын ачыклау.

Дәресебезне “Конэрс” уены белән дәвам итәрбез. Экрандагы юллар кем турында бара икән, шул авторның портреты янына басабыз, һәм ни өчен шушы авторны сайлавыбызны аңлатабыз.( Портретлар кабинетның 4 урынына эленгән)

1.Ул – герой – шагыйрь. “ Моабит дәфтәре”нең авторы. Без аның “Бакчачы”, “Кечкенә дуслар”, “ Күке” шигырьләрен өйрәндек.( Муса Җәлил)

2. Ул бик аз гына гомер эчендә бик күп шигырьләр һәм әкиятләр язып калдырган.Аның  “Шүрәле” , “Су анасы” әкиятләре безгә күптәннән таныш.          (Г. Тукай)

3. Бу язучы минем иң яраткан язучыларымның берсе. Армиядә хезмәт иткәндә аның белән бәхетсезлек очрагы була.( Ф.Яруллин)

4.  Бу шагыйрә 1928 елның 13 январенда Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза. ( Г.Зәйнәшева)

Бу автор сезгә танышмы? Аның турында нәрсә әйтә аласыз?

4. Дәрес темасы буенча эшләү.

1. Гөлшат  Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган презентация карау.

Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 январенда Татарстанның  элеккеге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә

районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

Г.Зәйнәшева Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза: ”14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесендә укыдым. 1942-1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде. Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астыдагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк иде. Яшүсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек ....”

1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

“ Кояш гомере “җыры башкарыла. (Ф.Әхмәдиев көе )

2. Табышмаклар уку.

Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә

Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул.( Әби)

Ул бик күпне күргән, сугышта да булган ул.

Йөзе нурлы айдай… Кем дисезме? Ул минем (Бабай).

Ул зирәк тә, шаян да, акыллы да, әйбәт тә!

Иң – иң батыр кеше ул, минем (Әти), әлбәттә!

Мин аны бик сагындым, күңелем әрни, уйлый әллә ни.

Кем соң аны белми? Ул бит минем (Әни).

Бу җавапларны берләштереп, нинди сүз белән әйтеп була? ( Гаилә)

Дәресебезне дәвам итеп нинди темага карата шигырьләр укырбыз икән.

3. “Безнең семья” шигыре белән таныштыру һәм фикер алышу.

Укытучы. Шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен? Анда сүз кемнәр турында бара? Сез нинди исем бирер идегез?

Хор белән уку һәм анализлау.Рифмаларын билгеләү. Шигырьнең эчтәлеге турында нәрсә әйтер идегез? (Һәрбер гаилә үзенчә бәхетле. Мондый бәхетле гаиләләрне күреп күгәрченнәр дә гөрләшә, матур гөлләрдә үсә)

Укытучы .Автор бу шигыре аша безне нәрсәгә өйрәтә?(Һәрбәр гаилә бәхетле булсын иде)

4. “Кояш гомере” шигыре буенча эш оештыру.

А) шигырьне эчтән уку һәм сорауларга җавап бирү.

Укытучы. Шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен? Анда сүз кемнәр турында бара? Сез нинди исем бирер идегез?

Б) Шигырьне берничә укучыдан укыту һәм эчтәлегенә карата телдән “рәсем ясату”

- Шигырьне укыганда яки тыңлаганда сезнең күз алдына нәрсә килә?

- Әгәр дә сез рәссам булсагыз, нәрсә эшләр идегез?

В) Шигырьне хор белән уку һәм үз әниләре турында сөйләтү. Аларга нинди ярдәм күрсәтәсез?


Физкультминутка.

“Ярый – ярамый” уены. ( Слайдтагы рәсемнәргә карап, гаилә әгъзаларына карата фикерләрен хәрәкәтләр белән күрсәтү. Әгәр дә рәсемдә сүрәтләнгән вакыйга уңай булса – кул чабалар, ә тискәре дип уйласалар – сикерәләр.

5. Алган белемнәрне ныгыту.

1. “ Буталган юллар” уены . Парларда эшләү. Г. Зәйнәшеванең “ Кояш гомере” шигырен шигъри юллар язылган карточкалар ярдәмендә төзү.

2. Кластер төзү.




(Партада төрле сүзләр язылган сүзләр, шулар арасында Гөлшат Зәйнәшева га туры килгән сүзләрне сайлап алып кояш ясыйбыз: язучы, шагыйрә, артист, укытучы, редактор, җырчы, әни, композитор).

6. Рефлексия

Г.Зәйнәшеванең “ Кояш гомере” шигырен анализлау.

| Әсәрнең исеме | Авторы | Жанры | Геройлары | Темасы | Төп фикере |
|---|---|---|---|---|---|

7.Йомгак.

Дәрес турында фикер алышу.

Укытучы. Бүгенге дәрес ахырына якынлаша. Сез үзегезгә берәр яңалык алдыгызмы? Дәрестә иң кызыклы нәрсә булды? Шагыйрә турында ниләр истә калды?

8. Өй эше. Шигырьне яттан сөйләргә

**Гөлшат Зәйнашева. Гөлләр иле**

(Китапханә дәресе)

Ситдыйкова Эльвера Дамир кызы,

Мөслим лицее Мөслим районы

Кереш

Хәзерге гасырны чын мәгънәсендә мәгълүмат гасыры дип атап була: мәгълүмат ташкыны көннән-көн арта. Заман мәктәбенең иң зур бурычы – уйларга, фикер йөртергә сәләтле, заман сулышын тоеп, алга атлаучы, уйлап табучан, югары әхлаклы, үз халкының тарихын, мәдәниятен белүче иҗади шәхес тәрбияләү. Технологик алгарыштагы һәр яңалыкка балалар сокланып карый, һәм, әлбәттә, аларның кызыксынучанлыгын һәм танып-белү активлыгын үз шәхесләренең максатчан үсешенә юнәлдерү мөһим.

Язучыларны рәсми сайтларын, мәгълүмати чыганакларны, иллюстратив, аудио һәм очрашулардан тупланган видеоматериалларны электрон күргәзмәгә урнаштырып, аларның иҗатын укучыларга танытуны максат итеп куйдым.

Электрон күргәзмә (виртуаль) – ул мәгълүмат тапшыруның өр-яңа электрон ысуллары синтезы. Виртуаль күргәзмә мобиль, компактлы, эчтәлекле һәм киң мәгълүмат агымы булып тора. Электрон күргәзмә аша без, язычыларның әсәрләренә укучыларның игътибарын җәлеп итеп, әхлакый яктан формалашырга, үсәргә булышабыз. Укучыларны китап укуга тартып, китап укуның әһәмиятен күтәреп, гаилә белән укуга киң җәмәгатьчелекне җәлеп итәбез.

Материал туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары, сыйныфтан тыш эшне оештыручылар өчен кызыклы булачак.

Максат: Сарман районыннан чыккан Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Гөлшат Зәйнашеваның виртуаль күргәзмәсен булдыру, аның иҗатын укучыларга таныту.

Төп бурычлар:

• Сарман районыннан чыккан Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Гөлшат Зәйнашеваның иҗатын укучыларга таныту.

• укучыларда якташ язучыларның әсәрләренә кызыксыну формалаштыруга йогынты ясый торган төрле эшчәнлек төрләрен оештыру;

• федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру өчен мәктәп педагогларына методик ярдәм күрсәтү, республика туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучылары алдында тәҗрибә тарату;

• балаларны туган-якның мәдәни мирасына тарту; укучыларга рухи-әхлакый тәрбия бирү;

Чараның барышы.

I.Оештыру моменты.

- Исәнмесез, укучылар. Сезне безнең чарада күрүемә мин бик шат.

II. Мотивация, эмоциональ караш.

(Музыка яңгырый “Гимназиядә дуслаштык” Сафьян Ибраһимов көе¸ Гөлшат Зәйнашева сүзләре)

- Зинһар, күзләрегезне йомыгыз, нурлары белән сезне юаткан якты язгы кояшны күз алдыгызга китерегез... Хәзер күз алдыгызга китерегез, сезнең эчегездә дә кояш бар, ул сезне һәм сезнең тирәдәге кешеләрне җылытып җибәрә... Бу җылылыкның безнең чарада гына түгел, ә көне буе саклануын телим!

III. Белемнәрне актуальләштерү.

- Сезне әдәби залда күрүемә мин бик шат! Укучылар, нәрсә ул китапханә? (Балалар җаваплары). Китапханә дәресен сез ничек күз алдыгызга китерәсез?

- Бүген без китапханәдә талантлы бер кеше турында сөйләшергә җыелдык. Кем соң ул шагыйрь?

*Кайда барма чын дусларны табам,*

*Дуслар белән озын юл кыска,*

*Әллә җирдә дуслар күп булганга,*

*Мин тормышка гашыйк, томышка*.

- Укучылар, бу шигырь юллары сезгә танышмы? Бүген без сезнең белән кем турында сөйләшәчәкбез? (Балалар җаваплары)

- Дөрес, Гөлшат Зәйнашева турында! Ә сез беләсезме, 13 гыйнварда шагыйрәнең тууына 95 ел булды?! (Балалар җаваплары)

- Бүгенге чарада без Гөлшат апаның иҗат эшчәнлегенә күзәтү ясарбыз, аның матур әсәрләре турында сөйләшербез, Гөлшат апаны искә алырбыз. Бүгенге китапханә дәресендә безгә Виртуаль күргәзмә ярдәм итәр. (Слайд 1)

-Хөрмәтле укучым! Безнең күргәзмәбез Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышлана. Татар халкы, әдәбият, сәнгать сөючеләр, бигрәк тә җыр яратучылар аны яхшы белә. Үзенең халыкчан, оптимистик киңкырлы (шигърият, драматургия, публицистика) иҗаты белән ул күпләр күңелендә. (слайд 2)

-Укучылар, әйдәгез бергәләп Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы бүлегенә күз салыйк. (Слайд 3, 4)

1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында дөньяга килгән. Минзәләдә ул педагогия училищесын тәмамлый, Казанда педагогия институтында белем ала. Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында эшли.( слайд 5)

- Укучылар, килешәсезме, без фотолар аша кайвакыт кешеләр турында теләгәннән күбрәкне аңлыйбыз. Фотолар безгә нәрсә турында сөйли ала? Киң һәм еш елмая, бәхет нуры чәчә торган кешеләр безгә дә уңай йогынты ясый. Истәлекле фотолар бүлегенә күзәтү ясыйк.

Балачак (Слайд 6)

Бөрлегән (Г.Зәйнашева)

Бөрлегәнем-җиләгем, дип

Иркәли мине әни.

Мин бит әле бик кечкенә,

Мин бит әле бик нәни.

Зур түгел шул, бик кечкенә,

Бөрлегән мин, бөрлегән.

Бөрлегән генә булсам да,

Бар эшкә дә өлгерәм.

Кыңгыраулы мәктәп еллары (слайд7) Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Башта Югары Тәкермән авылында башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый.

Студент еллары (слайд 8) Гөлшат Зәйнашева укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта – музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай

исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. (слайд 9)

Кайда барма чын дусларны табам,

Дуслар белән озын юл кыска,

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Гаилә — җылы учак. (слайд 10, 11) Учак янына гаиләдәге һәр кеше җыела. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчлерәк була. Ә ана кеше үзенең бөтен күңел байлыгын, матурлыгын үз нарасыена бирә.

Кешеләр, яратыгыз бер-берегезне,

Ярату озайтыр гомерегезне..

- Укучылар, алдгы бүлектә без шагыйрәнең Иҗаты белән танышырбыз. Презентациядәге гиперсылтама безгә аның китаплары белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. (слайд 12) Г.Зәйнашева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. (слайд 13) Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» һ.б. драма һәм комедияләре үз заманында Минзәлә театры һәм башка татар театры сәхнәләрендә уйналып йөри, (слайд 14) «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным җәл түгел сиңа» дигән комедияләре әле дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара. (слайд 15) Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары исә шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган.

Г.Зәйнашева җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес. Аның иҗатында туган якны ярату һәм сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, олы мәхәббәт хисләре, аналар язмышы, тарихи шәхесләр, тормыш, заман асылы турында уйланулар, мәхәббәт лирикасы, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Видеоязмалар бүлегеннән шигырьләрен уку, җырларын тыңлау. (*Укучылар сайлый)*

М-н : "Китмә, сандугач" (Рөстәм Яхин көе; Гөлшат Зәйнәшева сүзләре)

-Укучылар, без Г.Зәйнашева иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез. Ә хәзер Зәмирә Рәҗәпова укуында Гөлшат Зәйнашеваның «Туган телем» шигырен тыңлап китик әле.

Уен (Слайд 20, 21)

-Укучылар, бүгенге китапханә дәресендә Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты буенча алган белемнәребезне кроссворд һәм ребус ярдәмендә ныгытырбыз.

Нәтиҗә ясыйбыз Сүзләр болыты (Облако слов) (слайд 22)

## Кем булырга?

(Г.Зәйнәшева)

Баһавиева Лилия Данис кызы, Вәлиева Зөлфия Фәргат кызы,

Яңа Савин районының 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре

Дидактик максат: Укучыларның татар халкының танылган шагыйрәсе Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты буенча алган белемнәрен тикшерү, ныгыту һәм яңа мәгълүматлар белән баету;

Үстерешле максат: Укучыларның сорауларга тулы, дөрес җавап бирүләрен һәм уйлау, логик һәм иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эшләү; . Һөнәр сайларга әзерләү; тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

Тәрбияви максат: Укучыларда Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксынуга, аның шигырьләренә мәхәббәт тәрбияләүгә җирлек әзерләү.

МАТЕРИАЛ: Презентация.

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру- ориентлаштыру

1.Дәресне оештыру.

Исәнләшү, психологик уңай хәләт тудыру.

1 слайд

2.Дәреснең эпиграфы:

Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, томышка. (Г.Зәйнәшева)

3 . Актуальләштерү.

Укытучы юнәлдерүче сораулар ярдәмендә укучыларның алдагы сыйныфларда өйрәнгәннәрен искә төшерә.

- Өй эше тикшерелә.


II. Уку мәсьәләсен кую.

1. Исәнмесез, укучылар! 2 – 4 слайд

2. Ребус чишү;

-Балалар, экрандагы сүзләргә карыйк әле. Монда ребус чишәргә бирелгән. Әйдәгез шушы рәсемнәргә карыйк, аларны атыйк ребусның беренче хәрефләрен шакмакларга язып барыйк әле, нәрсә килеп чыгар икән? (Рәсемнәрне әйтә баралар, хәрефне яза баралар)





**ГӨЛ** **ӨЙ** **ЛИМОН**








**ШАР** **АЛМА** **ТРАКТОР**







**ЗОНТИК** **ӘБИ** **ЙОМГАК**







**НАРАТ** **ӘТӘЧ** **ШАЛКАН**







**ЕЛАН** **ВЕРТОЛЁТ**

**АТ**

5 слайд Гөлшат Зәйнәшеваның портреты

Укытучы: Кемнең исем – фамилиясе килеп чыкты?

Көтелгән җавап: Гөлшат Зәйнәшева

Укытучы: Әйе, дөрес. Гөлшат Зәйнәшева. Димәк, дәресебезнең темасы ничек булыр? Нинди максатлар куябыз? Дәрестә нәрсәләр эшләрбез?

Көтелгән җавап: Бүген без дәрестә Гөлшат Зәйнәшева турында сөйләшербез, аның тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннанрак танышырбыз. 6 – 7 слайд

Укытучы: Гөлшат Зәйнәшева кем соң ул? Җавабы менә монда яшерелгән. Шуны укыгыз. (Анда шагыйрә дигән сүзләр язылган)

Укытучы: Укучылар, сезгә өй эше итеп Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннанрак танышыйк. (Берничә укучы Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында чыгыш ясыйлар).

Көтелгән җавап:

1 укучы. Гөлшат Хисам кызы Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның хәзерге Тукай районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә. Ул үзенең балачагы турында "бала чакта бәхетем бишегеннән егылып төшкәнмен" дип әйтә торган була. 1930 елда, колхозлашу елларында, Г.Зәйнәшеваның әтисе Хисам абыйны, кулак исеме тагып, Архангельск өлкәсендәге Соловки лагерына сөрәләр. Берсеннән-берсе кечкенә биш бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган Әнвәр апа ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы – Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Матур табигатьле бу авыл, балачак хатирәсе булып, Гөлшат Зәйнашева күңелендә гомерлек эз калдыра.

Нинди авыл ул, дисәгез,

Моңлы авыл Тәкермән.

Китсәң, сагынып кайтасың,

Мәңге чыкмый хәтердән.

2 укучы. Өйләре клуб янәшәсендә була аларның. Минзәләдән артистлар килсә, аларга фатир төшерәләр. Кичләрен артист Сабир Өметбаев аны күтәреп клубка алып керә. Спектакль тәмамланганнан соң, артистлар аны, урындыкка бастырып, шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, кечкенә кыз Гөлшат артист булып уйнарга ярата. Мич аралыгына корылган чаршау артыннан чыгып, яшелле-күкле тавыш белән: "Кәнсиртебезне башлыйбыз! Җырлый Гөлшат Зәйнашева", - дип белдерү ясый.

Башлангыч мәктәпне авылда тәмамлагач, кечкенә Гөлшат күрше Хуҗамәт авылындагы җидееллык мәктәпкә биш чакрым йөреп укый. Аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. Ул чордагы кичергән авырлыкларны шагыйрә болай искә ала:

3 укучы. Мин 13-14 яшемнән үзбашыма көн күрә башладым. 1942-1943 еллар сугышның иң авыр еллары иде. Өс-баш ярлы, ашарга юк. Авылдан, өйдән бернинди ризык килми. Мин, аркага киндер капчыктан биштәр ясап, шуңа бераз бәрәңге салып өйдән чыгып киткән яшүсмер кыз бала, Минзәләдә кеше идәннәрен юып, кешегә бәрәңге утыртышып, бәрәңге казышып тамак туйдыра идем. Атнага бер тапкыр фотография идәнен юып чыгара идем. Шул акчага, базарга чыгып, берәр ризык алып ашый идем.

Безнең тулай торак пожарныйның аскы катында иде, ул ягылмый иде, аның миче юк иде. Өскә - бишмәт, аякка киез итек кигән килеш, башка мамык шәлләр урап, ятып йоклый идек.

4 укучы. Уйладым-уйладым да мин, мич чыгарырга булдым. Минзәләдә җимерек йортлар бар иде. Шул йортлар янында кирпеч ватыклары, калай кисәкләре аунап ята. Шул кирпеч ватыкларын, ташлар, калайлар җыеп алып кердем дә бер почмакка мич чыгарып куйдым. Ул мич, кыек-мыеграк булса да, хәйран җылыта иде. Бер-ике көннән пожарниклар килеп керде һәм мичне сүтеп ташларга куштылар. Ләкин берсе: "Менә сиңа кызлар! Балалар

гына бит әле болар! Шулай да югалып калмаганнар! Молодцы! Эх, сугыш... сугыш...Әйдә киттек!" - дип, усал пожарникны алып чыгып китте.

5 укучы. Гөлшат Зәйнашеваны язмыш гел сынап тора. Казанга килеп, педагогия институтында укый башлагач та, аңа, халык дошманы кызы дип, тулай торактан урын бирмиләр, ул бер ел буена урындыкларда йоклап йөрергә мәҗбүр була. Нәкъ шул елларда алдынгы студентларга Г.Тукай исемендәге махсус дәүләт стипендиясе бирергә дигән карар чыга, стипендияне беренче булып Г.Зәйнашевага бирәләр. Шунысы да кызыклы: Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге дә, хатын-кызлардан беренче булып, 1991 елда «Илле җыр» исемле китабы өчен Г.Зәйнашевага бирелә.

6 укучы. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта - музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара.

7 укучы. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Г.Зәйнашеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана. 1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә.

8 укучы. Г.Зәйнашева драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә иҗат активлыгы күрсәтә. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» һ.б. драма һәм комедияләре үз заманында Минзәлә театры һәм башка татар театры сәхнәләрендә уйналып йөри, «Гайфи бабай, өйлән давай» һәм «Җаным жәл түгел сиңа» дигән комедияләре әле дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара. Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары исә шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган.

9 укучы. Г.Зәйнашева әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗади активлык күрсәтә. Үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында ул әдәби тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә, көндәлек матбугатта басылган язмалары, сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул – сәнгать кешеләренә, җырчы артистларга, сәхнә фидакарьләренә, бигрәк тә сәнгатькяр хатын-кызлардан З.Басыйрова, Ә.Галимова, Ә.Афзалова, Р.Ибраһимова, Ф.Ильская, Х.Әхтәмова, Ф.Сөләйманова һәм башкаларның сәхнә эшчәнлекләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, шул җөмләдән мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймpraнованың, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың тормыш һәм иҗат юллары турында берничә монографик китап яза. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. Ул 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була.

8 слайд

Биографиясе буенча сорауларга җавап бирәләр (укучылар сорауларга язмача җавап бирәләр, бер – берсенең җавапларын тикшерәләр(парлап эшлиләр):

1. Гөлшат Зәйнәшева кайчан һәм кайда туган?

2. Гөлшат Зәйнәшеваның лирик шигырьләре тупланган беренче китабы ничәнче елда дөнья күрә?

3. Гөлшат Зәйнәшева кайларда эшли?

4. Гөлшат Зәйнәшева балалар әдәбиятында нинди шигырләре белән танылa?

5. Ничәнче елда вафат була?

6. Гөлшат Зәйнәшеваның нинди шигырьләрен беләсез?

Укытучы: Гөлшат Зәйнәшеваның шигырьләренә композиторлар бик күп матур көйләр язганнар.Аның балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә язган көлкеле, үзе гыйбрәтле шигырьләре, җырлары күп. Ул, тормышның кызыклы якларын табып, балалар белән бүлешә, аларны рәхәтләнеп көлдерә. Шуңа да шагыйрә сурәтләгән хәлләр үтемле булып йөрәккә керә, онытылмый, гел укучыны үзенә тарта.

“Туган авылым урамы” җыры тыңлана. (Г.Зәйнәшева сүзләре).

III.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

9 слайд

Дәрестә Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышуны дәвам итеп, аның “Кем булырга?” шигырен өйрәнәчәкбез.

Сүзлек эше. (Дәфтәргә язу)

“Кем булырга?” шигыре өстендә эш:

- укучылар сүзләрне укыйлар, сүзтезмәләр, җөмләләр төзиләр;

- укытучы сәнгатьле итеп укый;

- укучылар сәнгатьле итеп укый.

“Кем булырга?”(Г.Зәйнәшева)

“Кем булырсың син үскәч?” – дип,
Миннән сорыйлар.
“Баянчы бул, энекәш”, - ди
Артист абыйлар.
Әти әйтә: ”Минем улым
Шофёр була, - ди, -
“КамАЗ” машинасын йөртә
Борып кына”, - ди.
Әни әйтә: “Минем улым
Табиб була, - ди, -
Кешеләрне дәвалый һәм
Савыктыра”, - ди
Апам әйтә: “Минем энем

Сатучы була.

Акчаны күп итеп алып

Кайтучы була”.

Әби әйтә: “Иң элек син

Кеше бул, улым.

Ходай бирер сиңа шулчак

Бәхетнең зурын!...”

Укытучы: Ә хәзер төркемнәрдә эшлибез, һәрбер төркем лидерларын сайлый. (Лидерлар сайлыйлар).

1 ТӨРКЕМ беренче 8 юлда нинди һөнәрләр ишеттегез? 1 минут эчендә һөнәр исемнәрен языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (баянчы, артист, шофер).

2 ТӨРКЕМ

1 минут эчендә шигырьнең калган өлешендә ишеткән һөнәр исемнәрен һәм алар башкарган эшне языгыз. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез. Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (Табиб, сатучы)

Бер – беребезгә шушы әсәр буенча сораулар бирешәсез.

1 төркем: Малайга артистлар нинди һөнәр сайларга куша?

Көтелгән җавап: Баянчы булырга кушалар.

2 төркем: Малайга әтисе кем булырга куша?

Көтелгән җавап: Шофёр булырга куша.

3 төркем: Малайга әнисе ни өчен табиб булырга куша?

Көтелгән җавап: Чөнки табиб кешеләрне дәвалый һәм савыктыра.

4 төркем: Малайга апасы кем булырга киңәш бирә?

Көтелгән җавап: Сатучы булырга киңәш бирә.

5 төркем: Малайга әбисе нәрсә ди?

Көтелгән җавап: Иң элек улым, син кеше бул ди.

Укытучы: Малай үскәч, нинди кеше булыр икән? Нинди һөнәр иясе булыр дип уйлыйсыз? Ә сез кем булырга телисез? Бу турыда уйлаганыгыз бармы? Нинди нәтиҗә ясыйбыз?

Көтелгән җавап:

10 слайд

Ситуатив күнегүләр эшлиләр

Найдите предложение где говорится о том, что:

- “Будь баянистом,” – говорят артисты

- мой сын будет шофером

- будь врачом, он лечит людей

- мой братишка будет продавцом

- в первую очередь будь человеком

Рефлексия

Бүгенге дәрестә без кем турында сөйләштек? Аның нинди шигырен өйрәндек? Бу дәрестә максатка ирештекме? Нәрсәләр аңлашылмады? Нинди авырлыклар туды? Дәресне ничек аңлавыгызны тикшерәбез (гугл форма). 11 – 12 слайд

| **Сораулар** | **Әйе** | **Юк** |
|---|---|---|
| Гөлшат Зәйнәшева – танылган шагыйрә. | + | |
| Гөлшат Зәйнәшева Казанда туа. | | + |
| Гөлшат Зәйнәшеваның балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә шигырьләре күп | + | |
| Гөлшат Зәйнәшеваның шигырьләренә композиторлар көй язган. | + | |
| 2003 елның 7 маенда вафат була. | | + |
| Малай укытучы булырга тели. | | + |
| Малайга әбисе кеше булырга куша. | + | |

13 слайд

Өй эше:

1) шигырьне яттан сөйләргә;

2) “Һөнәрләр дөньясында” проет эше эшләргә;

3) “Мин кем булырга телим?” дигән темага инша язарга.

Билгеләр кую.

14 слайд

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

**Гөлшат Зәйнәшева-халыкчан шагыйрә**

(класс сәгате эшкәртмәсе)

Корбыева Гөлчәчәк Фаил кызы, Шәйдуллина Гөлназ Ришат кызы

Ләшәү-Тамак төп гомумбелем бирү мәктәбе

Сарман районы

Максат: Укучыларда Гөлшат Зәйнашева иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына мәхәббәт уяту. Гөлшат Хисам кызы Зәйнашеванын тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк өйрәнү.

Җиһазлау:

Талгын көй, шагыйрьнең портреты, «Җир кешеләр белән матур» исемле китап күргәзмәсе, укучылар тарафыннан ясалган рәсемнәр, проектор, презентация.

1.а.б. Халкыбыз мәхәббәте лауреаты, мәшһүр шагыйрә җыр шигъриятендә ярты гасыр дәвамында бик уңышлы эшләп мәйдан тотты, милләтебезгә олуг мирас калдырды. Аның иҗаты белән телевидение, концерт залларында яңгырый торган, Тукай әйткәнчә,«җәүһәр вә кыйммәтле» җырлары аша танышырга була.

2.а.б Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкын күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар.

1.а.б. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый: әүвәл берникадәр вакыт Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли.

2.а.б 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта - музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

1.а.б. Г.Зәйнашеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган бер пәрдәле пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Шул елларда «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана. 1958 елда яшь авторның «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Тулаем алганда, 1957-2005 еллар арасында авторның төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып чыга.

2.а.б.  Г. Зәйнашева әдәбиятның төрле жанрларына караган ике дистәдән артык китап авторы.

Иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» исемле китабы өчен Г. Зәйнашева 1991 нче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Казанда Гөлшат шагыйрьләр дөньясына эләгеп кенә калмый, музыкантлар, җырчылар, композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Композитор Алесандр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар куя. һәм ул «Туган җирем -Татарстан» җыры белән бәйгедә җиңеп чыга. Бу җырның музыкасы дәртле, халык күңелендә туган җиренә булган изге тойгыларны әйтеп бирерлек моңлы.

Җыр башкарыла «Туган җирем –Татарстан»\Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе

1.а.б Җыр төгәллекне, гадилекне, хакыйкатьне таләп итә.

Гадилек… Моңа Гөлшат беренче җырларыннан ук төшенә. Аның җырларын халык бик яратып кабул итүенең сәбәбе, мөгаен, шулдыр: әлеге җырларның сүзе гади-тормышчан, ә музыкаль аһәңнәре халык рухына туры килә, сүзләргә салыган мәгънәне дулкынландыргыч итеп ачып бирә белүендә.

Җыр башкарыла. «Тибрәнә җыр күңелдә» \Г.Зәйнашева сүзләре, З.Сәгыйтов көе

2.а.б Г.Зәйнашева җыр текстлары өлкәсендә эшләүче актив шагыйрә булып танылган шәхес. Аның иҗатында туган якны ярату һәм сагыну, әнкәйләргә булган олы хөрмәт, олы

мәхәббәт хисләре, аналар язмышы, тарихи шәхесләр, тормыш, заман асылы турында уйланулар, мәхәббәт лирикасы, балаларның серле һәм кызыклы дөньясы кызыл җеп булып үрелгән.

Шигырьләрен уку, җырларын тыңлау

1. «Конфет»

2. «Кояшлы яңгыр» \музыкаль композиция

3. « Корбан исемле малай турында әкият»

4. «Сөембикә» \музыкаль композиция

5. «Кояш гомере» \Ф. Әхмәдиев көе

6. «Аерылмагыз»\Ч.Зиннәтуллина көе

https://lemuzika.pro/search/Г.Зайнашева

1.а.б  Г. Зәйнашеваның үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. Аның “Бәхет кошым”, “Рамай” , “Гайфи бабай, өйлән давай”, “Язмышлар һәм ялгышлар” һәм башка пьесалары тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителә.

«Гайфи бабай, өйлән давай!» спектакленнән өзек күрсәтелә

https://yandex.ru/video/preview/7544572148268705479

2. а.б. Г.Зәйнашева әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗади активлык күрсәтә. Үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында ул әдәби тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә, көндәлек матбугатта басылган язмалары, сәхнәдән һәм радиодан ясаган чыгышлары белән халык арасында сәнгатьне пропагандалауга үзеннән сизелерлек өлеш кертә. Ул – сәнгать кешеләренә, җырчы артистларга, сәхнә фидакарьләренә, бигрәк тә сәнгатькяр хатын-кызлардан З.Басыйрова, Ә.Галимова, Ә.Афзалова, Р.Ибраһимова, Ф.Ильская, Х.Әхтәмова, Ф.Сөләйманова һәм башкаларның сәхнә эшчәнлекләренә багышланган күпсанлы мәкаләләр, шул җөмләдән мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләйманованың, җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың тормыш һәм иҗат юллары турында берничә монографик китап яза. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Һәркайсыбызга бик тә таныш, якын булган, үзенең фәлсәфи-лирик, нәфис-тәэсирле шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм Г. Зәйнашева бу якты дөньяда юк инде. 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була.

Г. Зәйнашева – 1969 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

## Гөлшат Зәйнашева – якты йолдыз

(шагыйрә Гөлшат Зәйнашева  иҗатына багышланган дәрестән тыш чара план-конспекты)

Абдуллина Эльмира Валера кызы,

Носы төп гомуми белем мәктәбе, Арча   районы

Максат:

- укучыларны Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру;

- эзләнү ярдәмендә мөстәкыйль фикер йөртү сәләтен һәм танып-белү активлыгын үстерү;

- Гөлшат Зәйнашева җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: маркер, кассета, тартма, А3 форматындагы ике бит, Г.Зәйнашева турында язылган мәгълүматлы карточкалар, ноутбук, аудиоязмалар, динамик.

Чара барышы

**I.** Оештыру өлеше

Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез әле, бер-беребезне сәламлик, бер-беребезгә карап елмаеп алыйк. Утырыгыз. Бүген без сезнең дәрестән тыш чарага җыйналдык.

Кеше белән очрашкач, бездә ул кеше турында ниндидер фикер туа, ләкин ул фикер күп вакытта дөреслеккә туры килеп бетми.

Бу тартмада бер предмет бар. Сезнең бурыч: ярыктан карап, предметның үзен атамыйча, аның билгеләрен генә атау. Өстәл янына өч укучыны чакырам. Рәхим итегез. (укучылар ярыктан карыйлар, билгеләрен атыйлар)

Ничек уйлыйсыз, бу тартмада нәрсә икән? (фикерләр тыңлана)

(Предметны күрсәтеп) һәр өч укучы да бу әйбернең билгеләрен атадылар, ләкин нәрсә икәнен төгәл әйтеп биреп булмады. Ә бу Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырлар кассетасы. Шулай булгач, беренче алган тойгыларга гына ышанып бетәргә ярамый, бигрәк тә сүз кеше турында барганда.

Теманы ачыклау: Ничек уйлыйсыз, без бүген кем турында сөйләшербез икән? Темабыз нинди булыр? (җаваплар тыңлана)

Әйе, дөрес әйттегез. Бүген без дистәләгән лирик җырлар иҗат иткән шагыйрә Гөлшат Зәйнашева турында, аның иҗаты турында сөйләшербез.

II. Төп өлеш

Бүген без сезнең белән төркемнәргә бүленеп утырдык. Һәр төркемгә эшләр бүленеп бирелгән иде. Хәзер без сүзне I төркемгә бирербез.

1. Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу

(I төркем укучылары Гөлшат Зәйнашеваның биографиясе һәм иҗаты турында презентация ярдәмендә чыгыш ясый. Калган төркемнәрдәге укучылар проект эше башкаралар. Аларга А3 форматындагы бит һәм Г.Зәйнашева турында мәгълүматлар бирелә. Тыңлаганнардан чыгып, мәгълүматны тиешле урынга ябыштырып баралар. II төркемнең Г.Зәйнашеваның тормыш юлы турында, III төркемнең Г.Зәйнашеваның иҗаты турында иҗади проект эшләре барлыкка килә).

Укучылар чыгышы: Гөлшат Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Татарстанның хәзерге Тукай районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. Аның балачагы Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә уза. Югары Тәкермәндә башлангыч, Хуҗәмәттә җидееллык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлагач, 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аның хезмәт юлы: 1949 нчы елдан Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире; 1952-1963 нче елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият мөхәррире; 1964-1965 нче елларда Татарстан радиокомитетында музыкаль тапшырулар мөхәррире; 1965-1966 нчы елларда Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г. Тукай исемендәге клуб мөдире;

1973-1983 нче елларда Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге мөдире; 1983 елдан һөнәри язучы буларак әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Кызганычка каршы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә Казан шәһәрендә шагыйрә вафат була.

Бүләкләре, мактаулы исемнәре: татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1988 нче елда Татарстан АССР атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелә, 1991 нче елда иң популяр җырлары тупланган «Илле җыр» китабы өчен Тукай премиясенә лаек була.

I иҗат тәҗрибәләре – шигырь, җыр, эстрада әсәрләре, үзешчән драма түгәрәкләре өчен язган бер пәрдәле пьесалары – вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыккан. Зур күләмле «Рамай» пьесасы халык театрлары сәхнәсендә уңыш казана. 1958 нче елда лирик шигырьләре тупланган «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1958-2005 нче елларда авторның төрле жанрда язылган ике дистәдән артык китабы басылып чыккан. Гөлшат Зәйнашева җыр өлкәсендә актив иҗат иткән. Халык җырлары традицияләрендә язылган, мәхәббәт, туган җир, табигать, яшьлек темаларына багышланган лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, матур чагыштыруларга бай булуы белән аерылып тора. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан йөзгә якын шигыренә көй язылган. Мәсәлән, «Туган җирем – Татарстан» (Александр Ключарев), «Китмә, сандугач» (Рөстәм Яхин), «Менәргә иде Урал тауларына» (Мансур Мозаффаров), «Үз илемдә» (Сара Садыйкова), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Кояш гомере» (Фәтхерахман Әхмәдиев), «Туган авылым урамы» (Ганс Сәйфуллин) һ. б. җырлары үзешчән һәм һөнәри җырчыларның озак еллар башкара торган репертуарына кергән.

Драматургия өлкәсендә дә актив иҗат итә. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл ?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак» «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Җаным җәл түгел сиңа» комедияләре дә аныкы. 1950-1960 елларда тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Сәнгать кешеләренә (Зифа Басыйрова, Әлфия Галимова, Әлфия Авзалова, Рокыя Ибраһимова, Фатыйма Ильская, Хәдичә Әхтәмова, Флера Сөләйманова һ. б.) сәхнә эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр, Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова тормышы һәм иҗаты турында китаплар яза.

2. Ял минуты

Хәзер физкультминутка үткәреп алырбыз. Төркемләп бер-бер артлы тезелеп басасыз. Гөлшат Зәйнашеваның «Сәяхәтче җыры»на көй туктаганчы һәр төркемдәге беренче укучы күнегүләрен кабатлап биисез, көй туктагач, икенче укучы күнегүләр күрсәтә һәм шулай дәвам итәбез.

Рәхмәт. Төркемләп өстәл артына утыруыгызны сорыйм.

3. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә иҗат ителгән җыр өстендә эш.

Сүзне II төркемгә бирәбез.

(II төркем «Туган авылым урамы» җырын башкаралар)

Җыр буенча әңгәмә үткәрелә:

- Җыр нәрсә турында?

- Җыр сездә нинди хисләр уятты?

- Лирик геройның хисләре турында нәрсә әйтә аласыз? (җаваплар тыңлана)

4. «Җырның исемен таны» уены.

III төркемгә сүз бирелә. Алар Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырлардан берәр куплет җыр тыңлаталар, калган укучылар җырның исемен әйтәләр. Уен шулай дәвам итә. Җиңүчеләр билгеләнә.

III. Рефлексия

Укучылар, бүген без Г.Зәйнашева турында, аның иҗаты турында сөйләштек. Сезгә бирем: һәр төркем бүген исендә калдырган, аның өчен иң кызыклы булган мәгълүматны әйтергә тиеш. Төркемнәрдә киңәшләшү өчен бер минут вакыт бирелә, һәр төркемнән бер укучының җавабы тыңлана.

Чара Г.Зәйнашеваның «Очрашу җыры»н башкару белән тәмамлана.

## Барысы да чагыла җырымда

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган әдәби кичә)

Даутова Роза Могайяр кызы,

Кәүҗияк төп гомуми белем бирү мәктәбенең беренче категорияле

татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Сарман районы

Максат :Укучыларны Г.Зәйнашеваның иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; аның җырлары аша татар җырына, моңына соклану хисе тәрбияләү, якташ язучыларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләү .

Җиһазлау : Г.Зәйнашеваның портреты,китаплары күргәзмәсе, компьютерда презентация, язучы иҗатына багышлап чыгарылган стенгазеталар.

Хәтер. Кайбер галимнәрнең раславы дөрес булса, 1917 елдан башлап илдә урнашкан тоталитар режим шартларында язмышлары пыран-заран килгән – махсус оештырылган ачлык фаҗигаләрендә һәлак булган, йорт-җир һәм туган төбәкләреннән сөрелгән яки, бер гаепсезгә кулга алынып, нахак хөкем карары белән гомерләре киселгән, концлагерьларга озатылып, ерак Себер тайгаларында, кырыс табигатьле төньяк өлкәләрдә, Казакъстанның сусыл далаларында иза чиккән, авыр кол хезмәтеннән, кыйнау-рәнҗетелүләрдән шунда әҗәлен тапкан яисә, иреккә сәламәтлекләрен тәмам югалтып, инвалид булып, рухи сүнеп чыккан кешеләрнең, ягъни репрессия корбаннарының, гомуми саны утыз-кырык миллионга җитә икән. Шушы 30-40 миллионнар арасында Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның әтисе дә бар. Гөлшат апабыз гомер буе диярлек (1989 елда әтисе реабилитацияләнгәнче) Сталин, НКВД нахак яла яккан, ул елларда бик куркыныч ярлык –«халык дошманы» кызы саналды. Шул җинаятьче, җанкыйгыч даирәләр күзәтчелеге астында укыды, эшләде, иҗат итте, күп кыерсытуларга дучар булды.

1укучы.

Сөйлә, дисәгез,сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткән гомерем бер җыр, бәет-
Барысы чагыла җырымда

Г.Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Сарман (Тукай)районы Иске Теләнче авылында туа. Әмма урта хәлле, нык тормышлы әтисе Хисам абый һәм әнисе Әнвәр апаның биш балалы гаиләсендә аңа үсәргә насыйп булмый. Ире кулга алынгач, берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән йорт-җирсез, ач, ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган әнисе ике

яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче баласыз Маһнуй (тулы исеме Өммеһани) апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Гөлшат бу гаиләдә ачлы-туклы үсә, апасының икенче ире, эш сөймәүче Хөрмәкәй эчүгә сабыша, еш тавыш чыгара, мәктәптә бик яхшы укучы балага дәрес хәзерләргә комачаулый. Башлангыч мәктәптән соң, Гөлшат күрше Хуҗәмәт авылына 5 чакрым җәяү йөреп белем ала. Аннан соң 1942-1945 елларда Минзәлә педагогика училищесында (хәзер көллият) 14 яшеннән үз көнен үзе күреп, бик яхшы укый. Кешеләргә идән юып, бәрәңге бакчаларын казып җан асрый. Берничә кыз янгын сүндерүчеләр каланчасы астындагы җылытылмый торган бүлмәдә яшиләр. Кышкы салкыннарга түзәр чама калмагач, Гөлшат, кирпеч ватыклары җыеп, кечкенә генә галанка миче чыгарып куя. Моңа янгын сүндерүче абыйлар да шакката. Ә иптәш кызлары чиксез шатлана. Гөлшат бик елгыр, җитез кыз була, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар стена газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга. Ә НКВД Гөлшатны даими күзәтү астында тота. Чөнки 1937 елның 15 августында сәяси репрессияләр тарихында иң рәхимсез боерык чыгарыла, ә партия Үзәк Комитеты аны хуплый. Ялган «юридик» төшенчә уйлап чыгаралар – имеш, репрессиягә дучар ителгәннәрнең балалары да «социаль куркыныч балалар» икән. Әлеге карар нигезендә, 15 яшьтән өлкәнрәк балалар кулга алынып, хезмәт белән төзәтү лагерьларына ябылырга, ә кечерәкләре, бертуганнарыннан аерып, төрле төбәкләрдәге балалар йортларына урнаштырылырга тиеш була.

“Иртә дә генә торам”, “ Минзәлә юллары”, “Тәкермән” шигырьләрен сөйләү.

2 укучы..1945 елда Гөлшат, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тик аңа тулай торакта урын бирмиләр. Сәбәбе – сугышта беркеме дә катнашмаган. Ул бик кимсенә, бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри,бер елдан соң гына урын бирәләр. Гөлшат Зәйнашева бик тырыш, пөхтә студентка була, «бик яхшы» билгеләренә генә укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә моңлы итеп җырлый, шигырьләр сөйли. Бик яхшы укыганы, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә.

“Авыр сугыш елларында үстем”шигыре

3 укучы. «Халык дошманы» кызы ... һәм менә бервакыт аны институт директоры кабинетына чакыртып, тетрәндергеч хәбәр әйтә: «Гөлшат, мин Сезне институттан чыгарырга мәҗбүр, НКВД таләп итә». Гөлшатны «халык дошманы» кызы булуда һәм институтка кергәндә әлеге фактны яшерүдә гаеплиләр. Гәрчә, ике яшьтә эти-әнисеннән аерылуга дучар ителгән ятим бала этисен бөтенләй хәтерләмәсә дә, ул совет власте өчен бик куркыныч җан иясе булып чыга. Бу җан әрнеткеч вакыйганы яшь кыз бик авыр кичерә, әмма югалып калмый. Шунда ук Казан театр училищесына укырга керә. Берничә айдан соң институт директоры Гөлшатны эзләтеп таба һәм яңадан укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә. 1949 елда институтны тәмамлагач, бик җаваплы эшләрдә хезмәт итә Гөлшат апа. Татарстан радиосында 16 ел дәвамында башта әдәби-драматик, соңрак музыкаль тапшырулар мөхәррире була, вазифаларын иҗади якын килеп, җиренә җиткереп башкара. Биредә ул язучылар, күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралаша, үзе дә иҗатка кереп китә, җыр текстлары, шигырьләр яза.

“Гөлләр иле” җыр

4 укучы. 21 ел Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, кадрлар бүлеге башлыгы, язучыларның Тукай клубы директоры булып бик нәтиҗәле эшли, иҗатта да үрләр яулый. 1958 елда аның «Тыңларсыңмы җырымны?» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә, иҗат дәверендә төрле әдәби жанрларга караган ике дистәдән артык китабы басылып

чыга. Бик күп җырлары күмәк җыентыкларда миллионнарча тираж белән басылып чыга. 1969 елда Гөлшат Зәйнашеваны Язучылар берлегенә гына кабул итәләр..

"Әби һәм онык " скетч

5 укучы. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, туган табигать, яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея- хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштырулары- бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып торалар. Шуңа күрә Гөлшат Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә тарта килде. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең 100 гә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм профессиональ җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарына әйләнде. ( слайдта популяр җырлар исемлеге күрсәтелә, укчы аларны укып бара)

“Туган җирем – Татарстан” (А. Ключарев музыкасы)

“Китмә, сандугач” (Р. Яхин музыкасы)

“Менәргә иде Урал тауларына” (М. Мозаффаров музыкасы)

“Үз илемдә” (С. Садыйкова музыкасы )

“Зәңгәр төймә” (халык көе)

“Күл буена килсәң иде” (З. Гыйбадуллин музыкасы)

“Кичегеп килгән мәхәббәт” (Б. Гайсин музыкасы)

“Кояш гомере” (Ф. Әхмәдиев музыкасы)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина музыкасы)

“Туган авылым урамы” (Г. Сәйфуллин музыкасы)

“ Яшел үзәнлек” (А. Хөсәенов музыкасы)

“Таулар моңы” (И. Мәҗитов музыкасы)

“Хәерле юл” (Ш. Капкаев музыкасы)

“Шундый безнең туган як” (А. Фәйзрахманов музыкасы )

“Син кемнең сандугачы?” (А. Шакиров музыкасы)

“Мәхәббәтең алда әле” (Р. Вәлиев музыкасы)

“Син икәнсең” (Г. Сәйфуллин музыкасы)

“Өй артында гөлбакча” (Р. Курамшин музыкасы)

“Мин бит кара карлыгач” (Ш. Тимербулатов музыкасы)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина музыкасы)

Шушы һәм тагын бик күп җырлары татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Гөлшат Зәйнашева иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

“ Кояш гомере телим” җыры

5 укучы. Гөлшат апа үзнең күпкырлы, бай иҗаты белән татар теле, татар мәдәнияте һәм сәнгате сагында нык торды, аяусыз көрәште. Милләтебез һәм тарих алдында Гөлшат Зәйнашеваның йөзе ак, вөҗданы пакь булды, һәм ул шулай булып кала да. Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк

булып гомер итте. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, сынмады. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы – табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды.

Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. Ул 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була.

“Сәяхәтче җыры”

Укытучы. Һәркем белә: җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле, чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне, беркемнән дә яшермичә, җыры аша әйтеп бирә ала. Ә Гөлшат Зәйнашеваның күңел тойгылары тирән, йөрәк серләре күп, әйтәсе сүзләре дә чиксез. Шагыйрәнең җырларын тыңлаган кеше, дөньясын онытып, Туган ягында йөри, балачак мизгелләренә кабат кайта, хезмәт кешесе тудырган хәзинәләргә карап соклана, кош, чишмә тавышларын ишетеп моңлана. Шуңа күрә дә бу олуг шагыйрәнең җырлары олысын да, кечесен дә дулкынландыра: ул җырлар һәркемнең күңелендә гомер буе яши.

Әйе, укучылар, чыннан да, шагыйрә Г.Зәйнашева бәхетен туган ягында, туган җирендә тапты. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә яңгырый.Аның җырлары – мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк. Мин ышанып калам: киләчәктә сез дә талантлы шагыйрә Г.Зәйнашева иҗаты белән кызыксынырсыз дип.

## Иң элек син Кеше бул, балам!

Гөлшат Зәйнашева иҗаты.“Кем булырга?” шигыре.

Хәмидуллина Алсу Тәкъсин кызы,

Урыссу бистәсенең 3 нче санлы урта гомуми белем

бирү мәктәбе, Ютазы районы

*Планлаштырылган нәтиҗәләр.*

*Метапредмет:* һөнәр сайларга әзерләү.

*Предмет:* Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

*Шәхескә кагылышлы*: тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

ТБУУГ: Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу, төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүматлы булу;

КУУГ: Аралашу күнекмәләрен формалаштыру, парларда һәм күмәк эшли белү;

РУУГ: Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;

ШУУГ: Укуга карата кызыксыну формалаштыру;

Дәрес тибы: яңа белемнәрне үзләштерү

Ресурслар: проектор, экран, Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында презентация, видеоролик,китаплар күргәзмәсе, ноутбуклар.

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

2. Дәресне оештыру

Исәнләшү. Кәефләрне белешү. Психологик уңай халәт булдыру.

-Хәерле иртә балалар!

-Хәерле иртә!

-Кәефләрегез ничек?

-Кояшлы иртә кебек.

2.Актуальләштерү.

-Укучылар, сезгә сүзләр болытыннан һөнәр ияләре атмаларын гына җыеп әйтергә кирәк.




*Укучылар чиратлашып һөнәр исемнәрен әйтеп чыгалар.*

-Ә нәрсә соң ул һөнәр? *Укучылар җавабы.*

-Балалар, аңлатмалы сүзлектән мәгънәсен карыйк әле.

*Бер укучы кычкырып укый.*

- Һөнәр- ул нәрсә дә булса җитештерү, ясау өчен осталык,күнекмә һәм махсус белем таләп итә торган эш, шөгыль.

**3.Уку мәсьәләсен кую**.

-Язучылар, шагыйрьләр һөнәрләр турында әсәрләр язалармы?

- Әйе, фикерләрегез дөрес. Бүген без танышачак шагыйрә дә һөнәр сайлау турында шигырь иҗат иткән. Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?” шигырен өйрәнербез.

**II.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1.Автор белән танышу.

Укытучы Г.Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыра. Аңа багышланган күргәзмә оештырыла.

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 январенда Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗәмәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

1945—1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлап чыккач, берничә ел Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар редакторы, соңыннан (1952—1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор булып эшли.

Г. Зәйнашеваның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм үзешчән драма коллективлары өчен язган пьесалары илленче елларның ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

Г.Зәйнашеваның шигырьләре күңелгә үтеп керердәй , халыкчан гадилеге , ачык аңлаешлы , музыкаль аһәңе белән аерылып тора һәм бик тиз истә кала торган итеп язылган. Шуңа күрәдер композиторларыбыз аның шигырьләренә бик күп , популяр җырлар язганнар . Иң популяр җырлар туплаган “ Илле җыр “ ( 1998) исемле китабы өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була .

- Ә хәзер шул җыентыкка кергән бер җырын тыңлап китәрбез .


*“ Туган авылым урамы“ җыры тыңланыла.*




Укучыларга шагыйрәнең иҗатына багышланган буклет таратыла.Укучы QR аша чыгып, шагыйрәнең иҗаты һәм биографиясе турында өстәмә материал белән таныша ала. Шигырь белән танышканда да шушы буклет белән эшләргә мөмкин.

Дәреслектә бирелгән шагыйрә турында белешмә кычкырып укыла. Китапларны ябып, «Plickers кушымтасы ярдәмендә укучыларның аңлау дәрәҗәсе тикшерелә.

https://www.plickers.com/library




Телефон (планшет) камерасы ярдәмендә укытучы укучылар күтәргән QR –кодлы карточкаларны сканер аша үткәрә.Әлеге карточкада номер һәм 4 инглиз хәрефе язылган. Номер укучының сыйныф журналындагы номерына туры килә. Ә инде җавап биргәндә, укучы бирелгән җавап вариантларының кайсын дөрес дип саный, шуңа туры килгән хәрефне күтәрә. Эшне төгәллләгәч, шунда ук тактада кемнең дөрес, кемнең ялгыш җавап биргәнен күрергә мөмкин була.


- Рәхмәт укучылар, булдырдыгыз.

2. “Кем булырга” шигырен укуга әзерлек, сүзлек өстендә эш.

-Укучылар сезнең өсталлләрдә QR штрих-код ята. QR штрих-кодны уку өчен смартфон яки планшетта «Сканер штрих кодов» дигән кушымтаны йөкләтәбез һәм LearningApps.org сервисына чыгабыз. Анда бирелгән биремне үтибез.

Бирем: бирелгән сүзләрнең дөрес тәрҗемәләрен табарга.

Укучылар тәрҗемәләрне дөрес билгеләсә, пазл ачылып афәрин дигән язу һәм елмаю смайлигы чыгарга тиеш була.




*https://learningapps.org/watch?v=pkj654n8323*

Биремне үтәгәч, сүзләр хор белән кабатлана.

3. Г.Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигыре белән танышу.

-Шигырьне укытучы үзе сәнгатьле итеп укый.

-Шигырьне укучылар үзлекләреннән укый.

- Төркемнәрдә иптәшләренә шигырьне кычкырып сәнгатьле итеп укыйлар.

4. Сорауларга җавап бирү.

-Малайның кем булуын телиләр?

-Сезнеңчә кайсы һөнәр яхшырак?

-Әбинең сүзләрен ничек аңлыйсыз?

-Сез кем булырга телисез? Бу һөнәр өчен нәрсәләр белергә кирәк?

5. Төркемнәрдә эш.

Укытучы, табиб һөнәр ияләренә кергән сүзләрне аерыгыз һәм сүзләрне битләргә беркетегез. Һәр төркем үзенең кечкенә проектын яклый.

Сүзләр: иҗади, катлаулы, җаваплы, акчалы, җиңел, абруйлы, дәрәҗәле, сирәк, авыр, җитди, мактаулы, куркыныч.

Укучылар өстәлләрдә яткан сүзлекләрдән сүзләрнең тәрҗемәләрен карый ала.

6. Парлап сөйләшү.

Мисал:

-Син кем булырга телисең?

-Мин рәссам булырга телим.

- Ни өчен?

-Миңа бу һөнәр бик ошый. Бу һөнәр кызыклы, иҗади........

III. Рефлексив бәяләү.

- Дәреснең уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? Нинди яңа мәгълүматлар алдыгыз?

- Балалар, әбинең әйткән сүзләрен тагын бер тапкыр укыйк әле . Шулай итеп, нинди генә һөнәр алсаң да тырыш, җитди булырга һәм кешелекле булырга кирәк.

Һөнәрләр бик күп. Кайсын гына алсак та, аларның һәрберсе җәмгыятебез өчен бик кирәкле. Һөнәре булган, кулыннан эш килгән кешенең җирдә һәрвакыт үз урыны, үз юлы, үз һөнәр җимешләре була. Нинди генә чорда яшәсәк тә, без намуслы хезмәт кешеләре булып көн итәргә тиешбез. "Тырышкан табар, ташка кадак кагар" дигән мәкаль һөнәр белгән һәр кешегә туры килә. Һөнәрегез булса, авырлыктан курыкмасагыз, эш яратсагыз, сез үзегезне иң бәхетле кеше дип саный аласыз._

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларның эшчәнлеген бәяләү.

3.Өй эше.

-Үзегезгә охшаган һөнәргә реклама ясарга (презентация, рәсемнәр, фото, сөйләү)

**Гөлшат Зәйнашеваның «Кем булырга»? шигыре**

(Дәреснең технологик картасы)


Хәсәнова Гадения Газизҗан кызы,

Кече Лызи урта гомуми белем бирү мәктәбе,

Балтач муниципаль районы


Дәреснең максаты: 1) Һөнәр сайларга әзерләү; 2) Г.Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү. "Кем булырга?" шигыре өстендә эшләү; 3) Тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

Планлаштырган нәтиҗәләр:

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәнү.

Метапредмет нәтиҗәләр:

Танып-белү УУГ: проблема кую, хәл итү, өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү, нәтиҗә чыгара белү; сәнгатьле уку.

Коммуникатив УУГ: проблеманы бергәләп чишүдә катнашу; үз фикереңне тулы һәм дөрес әйтә белү, әңгәмәдә катнашу.

Регулятив УУГ: уку мәсьәләсен аңлау, чишү юлларын таба белү.

Предмет буенча: Гөлшат Зәнашеваның тормышы һәм иҗаты турында белү, "Кем булырга?" шигыренең эчтәлеген укып аңлау,

Дәреснең тибы: яңа теманы аңлату .

Материал: Мотыйгуллина Ә.Р. дәреслеге (2нче кисәк, 36-38б.)

Җиһазлау: мультимедиа проекторы, экран, презентация, Г.Зәйнашева китаплары, Г.Зәйнашеваның портреты, ватман, рәсемнәр.

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | Универсаль уку гамәлләре (УУГ)<br>Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр (ШУУГ)<br>Метапредмет нәтиҗәләр<br>Танып-белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ) |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ)<br>Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ)<br>Предмет буенча нәтиҗәләр. |
| **Оештыру Мотивлаштыру** | Исәнләшү.<br>Психологик уңай хәләт тудыру.<br>Әңгәмә оештыру.<br>-Укучылар, без үткән дәресләрдә нинди хикәяләрне укыдык? Авторын һәм хикәянен исемен әйтегез.<br>-Сез  ничек уйлыйсыз, «Чүкеч », «Әни ялга киткәч» , «Кояштагы тап» хикәяләрендәге малайлар, үскәч, нинди кеше булырлар икән? Нинди һөнәр  иясе булырлар дип уйлыйсыз? Бу һөнәрләр турында  нәрсәләр беләсез? Алар тормышта кирәкме? | Исәнләшәләр.<br>Дәрескә әзерлекне күрсәтәләр.<br>Әңгәмәдә катнашу. | ШУУГ: барлык һөнәрләрнең дә мөһим булуын аңлау;<br>ТБУУГ: текстны тыңлап аңлау;<br>КУУГ: сорауларга җавап бирә алу, әңгәмәдә катнаша алу, үз фикерен дөрес әйтә алу;<br>РУУГ**:** эшкә әзерлекле булу. |
| **Уку мәсьәләсен кую.** | -Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән?<br>-Һөнәрләр белү киләчәктә ни өчен кирәк?<br>-Әйдәгез шушы сорауларга җавапларны без Г.Зәйнашеваның “Кем булырга?” дигән шигыреннән табыйк. | Һөнәрләр белү турында уку мәсьәләсен аңлап фикер йөртү. | ШУУГ: максатчан була белү;<br>ТБУУГ: уку мәсьәләсен аңлап фикер йөртү, нәтиҗә чыгара белү;<br>КУУГ**:** үз фикереңне дөрес һәм матур итеп җиткерә алу.<br>РУУГ**:** уку мәсьәләсен куя белү. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү** | Г.Зәйнашева турында кыскача белешмә бирү, китаплары белән таныштыру. (презентация) Әңгәмә оештыру.<br>-Г.Зәйнашева кем ул?<br>-Ул нәрсәләр яза?<br>-Ул кемнәр өчен шигырьләр язган?<br>- Ничек уйлыйсыз, нигә балалар өчен дә шигырьләр язган?<br>- Әйе, балаларны яраткан, алар өчен төрле матур шигырьләр  язган. Менә шуларның берсе “Кем булырга?” шигыре белән танышып китик. | Тыңлау.<br>Сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу.<br><br>-Г.Зәйнашева шагыйрә. -Ул шигырьләр яза.<br>- Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә язган.<br>- Чөнки балаларны яраткан. | ШУУГ: һөнәрләрнең барысы да кирәкле, үзенчәлекле икәнен аңлау; тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын таба белү;<br>ТБУУГ: аңлап уку, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлау, синтез, нәтиҗә чыгару;<br>КУУГ: әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дәллиле итеп җиткер белү, башкаларның фикерләрен тыңлый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Шигырьне уку.<br>Сүзлек эше.<br>Тәрҗемә итү.<br>Әңгәмә кору.<br><br>-Шигырьдә сүз нәрсә турында?<br>-Малайның гаиләсендә кемнәр бар?<br><br>-Малайның кем булуын телиләр?<br>-Сезнеңчә кайсы һөнәр яхшырак? Проблема чыгару.<br>-Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?<br>Ничек инде ул, кеше булу?<br>-Ә сез үскәч кем булыр идегез?<br>- Бу һөнәрләр өчен нәрсәләр белергә, нәрсәләр өйрәнергә кирәк? | Шигырьне чылбыр буенча укыйлар.<br>Сорауларга җавап бирәләр.<br>-Кем булу турында.<br>-Абыйлары, әтисе, әнисе, апасы һәм әбисе.<br>-Баянчы, шофёр, табиб, сатучы булуын телиләр.<br><br>-Укырга, белем алырга, тырышырга, күп белергә, куркак булмаска кирәк. | белү, сораулар бирергә өйрәнү;<br>РУУГ: уку мәсьәләсен чишә белү, анализ барышын төзи белү, контроль, корекция, башкаларның фикерләрен дөресли белү;<br>Предмет: Г.Зәйнашева иҗаты турында белешмә алу, шигырьнең эчтәлеген укып аңлый белү. |
| **Ял минуты** | -Ул киемнәр тегә. Бу кем?<br>-Ул балалар тәрбияли. Бу кем?<br>-Ул кешеләрне дәвалый. Бу кем? | -Тегүче.<br><br>-Тәрбияче.<br><br>-Табиб. | |
| **Яңа теманы ныгыту** | Һөнәрләр турында әңгәмә оештыру.<br>-Тагын нинди һөнәрләр беләсез? (рәсемнәр буенча эш)<br>-Кайсы һөнәр нинди?(38 бит, 5нче биремне эшләтү).<br><br>38 бит, 6нчы күнегү буенча диалог төзү. | Иҗади, авыр, сирәк, катлаулы, акчалы, дәрәҗәле, җитди, мактаулы, җаваплы, абруйлы, куркыныч, җиңел<br><br>- Үрнәк буенча парлап сөйләшү.<br>1 бала. - Син кем булырга телисең?<br>-Мин очучы булырга телим.<br>- Ни өчен?<br>-Миңа бу һөнәр бик ошый. | ШУУГ: һәр һөнәрнең авыр, җаваплы эш икәнен аңлау; кешеләрнең эшен хөрмәтли белү; һөнәрле булу өчен кеше булырга, белем алырга, күп белергә кирәклекне аңлау;<br>ТБУУГ**:** сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлау, нәтиҗә чыгара белү;<br>КУУГ: фикереңне дәлилле итеп җиткерү, диалогка керә белү;<br>РУУГ: башкаларның фикерләрен дөресли белү, үз эшчәнлегенә бәя бирү;<br>Предмет: әсәрнең идеясенә төшенү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 2 бала.- Син кем булырга телисең?<br>-Мин чәчтараш булырга телим.<br>- Ни өчен?<br>-Миңа бу һөнәр бик ошый.<br><br>Әңгәмәдә катнашалар, кайсы һөнәрнең нинди булуын билгелиләр. Җөмләләр, диалог төзиләр, парлап сөйләшергә өйрәнәләр.<br><br>1нче төркем чыгыш ясый. | |
| | Төркемнәрдә мини проект эше.<br><br>- Гөлшат Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигырендә нинди һөнәр исемнәре бар? Бу һөнәрләр нинди? (авырмы? җиңелме?) Алар нишлиләр?<br><br>-Сезнең үскәч кем буласыгыз килә?(4 һөнәр турында)<br>Бу һөнәрләр нинди? (авырмы? җиңелме?) Алар нишлиләр? | 2нче төркем чыгыш ясый<br><br>Үз фикерләрен әйтәләр. | |
| **Рефлексия, бәяләү, үзбәя.** | Сораулар биреп йомгак ясау<br>Укучылар, “Барлык һөнәрләр дә яхшы, Барлык һөнәрләрләр кирәк” мәкале белән килешәсезме?<br><br>- Укучылар, бүгенге дәрестә нинди яңалык алдык? Дәрестә нәрсәгә өйрәндек? Һөнәрле булу | Мине .... гаҗәпләндерде.<br><br>-Миңа күбрәк ... ошады.<br><br>-Миңа .... эшләү авыр булды.<br><br>-Миңа дәрестә ... кызык булды. | ШУУГ:<br>үз уңышларың (уңышсызлыкла- рың) сәбәпләрен әйтә алу;<br>ТБУУГ: нәтиҗә чыгару;<br>КУУГ: үз фикереңне дөрес итеп җиткере алу;<br>төрле фикерләрне кабул итү;<br>иптәшеңне тыңлый белү.<br>РУУГ: бәяләү, үзбәя |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Киләчәктә һөнәр белү кирәкме? Дәрес сезгә файдалы булдымы? Дәреснең уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? Үзегезнең эшчәнлегегезгә бәя бирегез.<br>Укытучы дәрестәге эшчәнлеккә объектив бәя бирә. Балаларны мактый.<br><br>Өй эшен, белем дәрәҗәләренә карап, һәр укучы үзе эшли алырлык эш тәгъдим итә:<br>1)(мәҗбүри) Г.Зәйнашева турында укырга, шигырьне сәнгатьле укырга.<br>2) (иҗади) 38 бит, 7нче бирем (үзегезгә охшаган һөнәргә реклама ясарга (рәсемнәр, презентация, фотолар)<br>3)һөнәрләр турын да диалог төзергә. | -Мин ... өчен рәхмәт әйтәсем килә.<br>Үзбәя бирә.<br><br>Өй эшен аңлый, сайлый, көндәлекләргә язып куя. | ШУУГ:мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер булу;<br>ТБУУГ:дәреслектән кирәкле информацияне табу һәм аңлау;<br>КУУГ: диалог төзи белү;<br>РУУГ: үз эшчәнлеген контрольдә тоту;<br>Предмет: Г.Зәйнашева иҗаты турындагы мәгълүматны белү |

**Иң элек син Кеше бул, балам!**

(Дәреснең технологик картасы)


Романова Галина Николай кызы,

6 нчы гомуми урта мәктәп, Зәй шәһәре


| **Дәреснең тибы** | Яңа материалны аңлату |
|---|---|
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы:** Укуга карата кызыксыну формалаштыру, һөнәр сайларга әзерләү, тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.<br>**Метапредмет:**<br>*Танып-белү УУГ:* укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу, төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүматлы булу;<br>*Коммуникатив УУГ:* Аралашу күнекмәләрен формалаштыру, парларда һәм күмәк эшли белү;<br>*Регулятив УУГ:* Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;<br>**Предмет буенча:** Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, парлап, төркемнәрдә, индивидуаль |

| | |
|---|---|
| **Җиһазлау** | 6 нчы сыйныф дәреслек (2 нче кисәк, 36—38 нче битләр), эш дәфтәрендә 39, 40 нчы битләр, проектор, экран, Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында слайдлар. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| **Оештыру.**<br>**Мотивлаштыру (1мин)** | Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек? Дәресебезне башлыйбыз. Игътибарыгызны экранга юнәлтегез. | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр) |
| **2. Белемнәрне актуальләштерү(4 мин)** | Өйрәнгәннәрне искә төшерү. Рәсемнәргә карагыз, әле, сез кемнәрне күрәсез? Ә аларны нәрсә бәйли? Болар – һөнәрләр.<br>Нәрсә соң ул һөнәр? | Укучылар төшеп калган сүзләрне куеп язалар. Экраннан иллюстрацияләр карау. сорауларга җавап бирәләр, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар<br>Укытучының сорауларына җавап бирәләр. |
| **3.Уку мәсьәләсен кую (2)** | Укучылар сез үскәч, кем булырга телисез? Сезнең уйланганыгыз бармы? Әти-әниләрегез кем булып эшли? «Кем булырга?» ролик карау. Роликта нәрсә турында сүз бара? Һөнәр сайлау турында.<br>2. Бүгенге дәрестә без нәрсә турында сөйләшербез? | Бирелгән сораулардан чыгып, дәреснең темасын билгелиләр. |
| **4. Уку мәсьәләсен адымлап чишү(22 мин)** | 1.Автор белән танышу. Дәреслектәге белешмә укыла.<br>2.Китапларны ябып, кечкенә тест белән аңлау дәрәҗәсе тикшерелә.<br>3.Г.Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигырен уку.<br>4.Эчтәлек буенча әңгәмә.<br>**Төркемнәрдә эш.** | Парларда, төркемнәрдә иптәшләренә шигырьне кычкырып, сәнгатьле итеп укыйлар.<br>-Һәр төркемнән 1 укучы кычкырып укый.<br>1 минут эчендә һөнәр исемнәрен һәм 1 җөмлә белән алар башкарган эшне язалар. |
| **5. Мөстәкыйль эш. (4)** | Дәреслектәге 1—6 нчы сорауларга җавап бирү. Җөмләләр төзиләр.<br>1) Малайның кем булуын телиләр?<br>2)Сезнеңчә, кайсы һөнәр яхшырак? Тагын нинди һөнәрләр беләсез?<br>3) Әбинең сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?<br>Карточкалардагы сорауларга җавап бирү.<br>-Һөнәрләр нинди була? Сыйфатларны тәрҗемәләре белән тоташтырыгыз. | Укытучының сорауларына җавап бирәләр. |
| **6.Ныгыту. (9)** | Үрнәк буенча парлап сөйләшү.<br>- Син кем булырга телисең?<br>-Мин ... булырга телим. | Укучылар карточкалардагы сорауларга җавап бирә, сыйфатларны тәрҗемәләре белән тоташтыралар. |

| | | |
|---|---|---|
| | - Ни өчен?<br>-(Миңа бу һөнәр бик ошый. Бу һөнәр кызыклы, акчалы, иҗади, мактаулы, җаваплы ... Минем әтиемнең һөнәре.)<br>- ... булу өчен нишләргә кирәк, беләсеңме?<br>- Беләм. (Яхшы укырга, куркак булмаска, күп белергә, тырыш булырга, тарихны, математиканы, инглиз телен .... белергә кирәк) | Парларда сөйләшү оештыралар |
| **Рефлексия. (3)** | Төркемнәрдә эш.<br>1 төркем<br>Үзегезгә ошаган һөнәрнең сыйфатларын языгыз. Тактага чыгып урнаштырыгыз.<br>2 төркем<br>Үзегезгә ошаган һөнәргә яисә әти-әниегез эшләгән һөнәргә реклама ясагыз.<br>3минут вакыт бирелә, һәр өстәлдән 1 чыгыш тыңлана.<br>Йомгаклау: Афәрин, укучылар. Сез дәрестә дәрестә актив катнаштыгыз, матур итеп җавап бирдегез, булдырдыгыз. Рәхмәт, укучылар.<br>Үзбәя. Ә хәзер үзегезгә бәя бирегез. | ШУУГ: активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәнү; хезмәтне ярату хисләре булдыру.<br>ТБУУГ: төп фикерне аерып чыгара белү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне дәлилләп башкаларга җиткерә белү;<br>РУУГ: мөстәкыйль эшли белү; үзбәя; |

## Мин тормышка гашыйк

(Гөлшат Зәйнашева тормышы һәм иҗатына багышланган әдәби квест)

Хәсәнова Э.Г., Гыйләҗева Ф.Х.,

икенче санлы Лениногорск урта гомуми белем бирү мәктәбе

Максат:

1. Укучыларны Г.Зәйнашеваның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, аның иҗатына карата кызыксыну уяту, аның иҗатын пропагандалау.

2. Укучыларда укуга, татар теле һәм әдәбияты фәненә, сәнгатькә карата аңлы караш тәрбияләү.

3. Укучыларның сөйләм телен, дөньяны танып-белү, күзаллауларын арттыру, үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, сәләтләрен үстерү өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыру;

Кичәгә әзерлек максатыннан укучыларга Гөлшат Зәйнашева турында укырга, иҗаты белән якыннанрак танышырга һәм Интернеттан «Язмышлар һәм ялгышлар» видеоязмасын карарга тәкъдим ителә. (https://yandex.ru/video/touch/preview/14449713437829115105)

Әдәби квестның барышы

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Кичә буласы залга интерактив такта, слайдта Г.Зәйнашева портреты, аның янында кичәнең эпиграфы язылган(... Гөлшат Зәйнашева популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйды. Р.Хафизова, язучы.1990нчы ел). М.Якупов язмасында Г.Зәйнашева шигыренә Мансур Мозаффаров иҗат иткән ” Мин тормышка гашыйк”җыры яңгырый.

Мин тормышка гашыйк.
Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Чишмәләрнең җырын отар идем
Җыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Озак яшәрмен диеп йөрәк тибә,
Ашкына күңелем һәр эшкә,
Әллә эшем бәхет китергәнгә,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Бәйрәмчә киенгән укучылар чыга. Алар 2 команда булып сафларга тезелгән.

Алып баручы. Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар, килгән кунаклар! Г.Зәйнашева тормышы һәм иҗатына багышланган әдәби квестны башлыйбыз! Алып баручы уен тәртибе белән таныштыра. Күренекле шәхесебез һәм милли моң-көйләребез турында зирәклектә, тапкырлыкта көч сынашырбыз. ”Гөл”, “Шат” командаларына сүз бирелә.

1 нче тукталыш. “Г.Зәйнашеваның популяр җырлары”.

Диварларда популяр җырларның куар-кодлары эленгән. Шуларны табып, исемнәрен кәгазь битенә язып, жюри әгъзаларына тапшыралар.

Музыкаль номер. Музыка мәктәбендә укучылар башкаруында Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырлардан тезмә. (Уен коралларыннан баян, гитара, фортепиано, скрипка)

2 нче тукталыш. “Мин тормышка гашыйк”

Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрне тикшерү.

“ Гөл” командасына сораулар

1. Г.Зәйнашева ничәнче елны дөньяга килә*?(13нче гыйнвар,1928нче ел)*

2. Г.Зәйнашева кем тәрбиясендә үсә?*(әтисе ягыннан туган апасында, Минзәлә районы, Югары Тәкермән авылында)*

3.Минзәлә педагогия училищесына ничәнче елда укырга кергән*?(1945 нче елда)*

4. Аның беренче китабы кайчан басыла? (*1958нче елда.)*

5. Г.Зәйнашева кайчан Язучылар берлегенә кабул ителә*?(1969нчы елда)*

“Шат” командасына сораулар

1. Г.Зәйнашеваның туган авылы, районы? *(Сарман районы, Иске Теләнче авылы)*

2. Г.Зәйнашеваның әтисенең исеме?(*Хисам)*

3. Минзәлә педагогия училищесын ничәнче елда тәмамлый?*(1949нчы елда)*

4. Г.Зәйнашевага кайчан Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була? *( 1991нче елда)*

5. Ул кайчан вафат була? (*2005 елның 1нче апрелендә.)*

Музыкаль номер. “Үз илемдә” (Г.Зәйнашева сүзләре, С.Садыйкова көе) Укучылар башкаруында җыр.

3 нче тукталыш. “Җырның исемен тап!”

Г.Зәйнашева сүзләренә язылган җырлар яңгырый, җырның исемен табарга кирәк.

“Гөл” командасына :

1. Зур түгел шул, бик кечкенә
Бөрлегән мин, бөрлегән.
Бөрлегән генә булсам да,
Һәр эшкә дә өлгерәм. *(“Бөрлегәнем”)*

2. "Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә;
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!" *(“Кояш гомере”)*

“Шат” командасына сораулар:

1. Әй гитара, әй гитара,
Көмеш микән кыллары?
Гитара уйный бер егет —
Бар микән сөйгән яры? *(“Гитара”)*

2. Буразналар, буразналар —
Йөгерек дулкыннар.
Буразнамда игенкәйләр
Күкрәп уңсыннар!.. *(“Буразналар”)*

Музыкаль номер.“ Туган җирем - Татарстан” җыры. Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе. Экранда –Хәйдәр Бигичев башкаруында видеоязма.

4 нче тукталыш. ”Шәхесләрне таны” бәйгесе

Бирелгән фотолардан Г.Зәйнашева белән бәйле булган кешеләрне танырга.

1  2  3  4 

Җаваплар:

1. Сара Садыйкова
2. Александр Ключарев
3. Рөстәм Яхин
4. Әлфия Афзалова

5 нче тукталыш. “Җырлар дөньясында”

Командаларга битләр таратыла, бирелгән вакыт аралыгында Г. Зәйнашева шигырьләренә язылган җыр исемнәрен язарга. Куллану өчен “Җырлар китабы”н бирергә була.

Командалар биремне башкарганда, 2 нче сыйныф укучылары саннар турында Г.Зөйнашева язган шигырьләр сөйли.

1 нче укучы

Саннар саный башласак,
Иң беренче — бер саны.
Мактап әйткән кебек, без
«Беренче» дибез аны...
Бер саны ул бер генә,
Әни дә бит бер генә,
«Әнием — бергенәм» дип
Кадерлибез гел генә.

2 нче укучы

Табигатьтә бөтен нәрсә
Ике төрле килгән безгә.
Бер чорлары кара булса,
Икенчеләре ап-ак төстә.

3 нче укучы

Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле өчпочмакларны
Әни йөри пешереп.

4 нче укучы

Түп-түгәрәк җир шары,
Аның да бар дүрт ягы.
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы.

5 нче укучы

Әнкәй пешерә ял көнне безгә
Бишбармак бишебезгә:
Әткәй, әнкәй, абыйга,
Сеңелем белән миңа.

6 нчы тукталыш. “Исемен тап”

Рәсемгә карап нинди җыр икәнен әйтергә.

1. 

2. 
3. 
4. 

5. 
6. 
7. 
8. 

Җаваплар: 1.“Бер атнада ничә көн”. 2 “Гармункаем, дускаем”. 2.”Кара урман”. 3.”Китмә, сандугач”. 4.“Ак пароход”. 5.” Зәңгәр төймә”. 6.” И Казан, Казан”.7.“ Минем иркәм- биюче”. 8.”Әбиемне яратам”

7 нче тукталыш. “Сүзләр болыты”на яшерелгән шигырь юлларын укыгыз.




Җаваплар:

1. Ап-ак тун киеп, кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава. (“Кыш килде”)
2. Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк –
Безнең иң якын дуслар. (“Кыш килде”)

Алып баручы: җюри әгъзалары нәтиҗә ясаганчы, без сезгә Гөлшат апа Зәйнашеваның “ И, кызык Шүрәле” мюзиклыннан өзек карарга чакырабыз. Композиторы - Луиза Батыр-Болгари.

Хөрмәтле җюри әгъзалары! Йомгаклау өчен сүз Сезгә бирелә.

Әдәби квест барлык укучылар, килгән кунаклар белән бергәләп “Керкәле таулары” җырын җырлап тәгалләнә. Аның өчен экранга җырның караокесы куела.

**Motherland is… (Родина – это…) из произведений Г. Зайнашевой.**

(технологическая карта урока)

Вәлиәхмәтова Заря Азат кызы,

16 нчы санлы Әлмәт урта гомуми белем бирү мәктәбе

Нуретдинова Айгөл Гамирҗан кызы,

икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Класс: 10

Цели деятельности учителя:

Организовать деятельность учащихся по поиску и обработке информации; обобщению способов действия; постановке цели урока, расширить лексический запас слов у учащихся.

Тип урока: урок открытия новых знаний

Планируемые образовательные результаты:

Предметные:

Ученик научится:

- работать с адаптированным текстом литературного произведения;

- использовать языковые средства текста в устной монологической и диалогической речи;

- группировать полученные сведения по изученному тексту.

Ученик получит возможность научиться:

делать литературный перевод на основе прочитанного.

Личностные:

-умение вести диалог на основе взаимного уважения и принятия другой стороны;

-умение осмыслить ошибки и устранить ошибки, объяснять самостоятельно изученные грамматические правила и подбирать конкретные примеры.

Метапредметные:

-Регулятивные УУД: Определение и прогнозирование трудностей при работе с текстовой информацией, способность осуществлять самокоррекцию и самопроверку устного сообщения; умение продуктивно общаться и взаимодействоватьв процессе совместной деятельности, учитывать позиции других участников деятельности, эффективно разрешать конфликты, адекватно самостоятельно оценивать правильность выполнения действия и вносить необходимые коррективы.

-Коммуникативные УУД: умение читать и понимать адаптированный текст; читать с пониманием основной идеи и с извлечением специальной информации; логично строить развернутое высказывание; подбирать синонимы, заменять слова; умение соблюдать формат устного высказывания; умение осознанно строить речевое высказывание в устной форме в соответствии со стилем общения и нормами языка; умение слушать собеседника и проявлять уважительное отношение к нему, работать в сотрудничестве, уметь литературно переводить текст.

-Познавательные УУД: умение строить логическое рассуждение (учебнопознавательная компетенция); умение работать с печатным текстом; умение выделять необходимую информацию; использовать приобретенные знания в практической деятельности;

Используемые методы и технологии обучения:

Технологии уровневой дифференциации, здоровьесберегающие технологии, игровые технологии, технология развития критического мышления

Наглядно-демонстрационный материал:

Интерактивная доска, портрет Г. Зайнашевой

Основные понятия, с которыми идет работа на уроке:

Синквейн, литературный перевод, «мозговой штурм»

| Этап урока | Действия учителя | Действия учеников |
|---|---|---|
| 1) Организационный момент | Приветствие. | Приветствие. |
| 2) Постановка цели и задач урока. Мотивация учебной деятельности учащихся. | Прием «мозговой штурм»: На доске написано слово native land (родной край)<br>-Учитель просит учащихся назвать как можно больше слов по данной тематике и записывает примеры на доске (схема)<br>T: Have a look at the screen and read some information about G. Zainasheva.<br>(На экран выводится фото Г. Зайнашевой и небольшая информация о ее биографии) (Приложение 1)<br>Задается вопрос:<br>-What is the theme of our lesson?<br>-The theme of our lesson is G. Zainasheva and her works about native land.<br><br>Учитель подводит учащихся к постановке целей урока применяя вопросно-ответную работу.<br>What do you expect to learn at this lesson? | Предлагают свои варианты: -nation<br>-landscape<br>-peace<br>-family<br>-country, etc.<br><br>Изучают информацию о писательнице и определяют тему урока.<br><br>-I want to know about her works.<br>-I would like to get more information about her family<br>- I want to know whom did she write about in her works. |
| 3) Открытие новых знаний. | Работа над стихотворением Г. Зайнашевой «The street of the native village» (прил.2) Снятие лексических трудностей (на экране фразы с переводом)<br>a blooming garden \| ˈbluːmɪŋ ˈɡɑːd(ə)n \| - цветник<br>although \|ɔːlˈðəʊ\| - хотя<br>prodigal \|ˈprɒdɪɡ(ə)l\| - блудный (сын)<br>poplar \|ˈpɒp.lər\| - тополь<br>tongue \|tʌŋ\| - язык | Хором отрабатывают фразы |

| | | |
|---|---|---|
| | Учитель читает текст стихотворения на английском языке (Прил. 2)<br>Настраивает учащихся на работу со стихотворением, задавая вопрос и побуждая к высказыванию своего мнения: What do you think the author felt when she wrote this poem?<br><br>Учитель просит одного ученика прочитать оригинал на татарском языке (Прил. 2)<br>Учитель дает задание на поиск в произведении слов - синонимов.<br>Match the words in bold to their meanings. Use each one in a sentence of your own.<br>1. ordinary (usual)<br>2. native (home)<br>3. although (though)<br>4. old (ancient)<br>5. homeland (motherland)<br>6. tongue (language)<br>7. melodious (tuneful) | Ученики слушают чтение учителем стихотворения.<br><br>Ученики читают отрывок, отвечают на вопросы учителя и предлагают свои варианты:<br>- She loved nature.<br>- I suppose she considered nature to be her friend.<br>-I think she was proud of her native land.<br><br>Находят в тексте слова синонимы и составляют письменно свои предложения с ними и зачитывают их. |
| 4) Первичная проверка понимания и первичное закрепление. | Организуется беседа по уточнению и конкретизации первичных знаний.<br>Work in groups. Translate the extract into Russian, give a literary translation. | Высказывают свои предположения в группах и делают литературный перевод выделенного отрывка |
| 5) Закрепление изученных способов действия | Выдвигает проблему и напоминает обучающимся о необходимости применения изученных лексических единиц, контролирует выполнение работы.<br>Учитель раздает половинки пословиц о мире, родной земле и природе, запечатанных на отдельных листочках. Затем учитель просит учеников найти себе пару из другого ряда и сесть рядом (данное упражнение направлено на формирование пар и зарядки для тела).<br><br>Find the pair from the next row and read out the proverb. | Ученики находят себе пару и вслух читают получившиеся пословицы.<br>1)East or west – home is best. – В гостях хорошо, а дома лучше<br>2) Home is home though it be never so homely. - Своя земля и в горсти мила.<br>3) The wider we roam, the welcomer home. - Всякому мила своя сторона.<br>4) A man without a Motherland is like a Nightingale without a song. - Человек без родины, что соловей без песни. |

| | | |
|---|---|---|
| | Express your opinion what about the connection of the proverb and the content of the poem. | Работают в парах и обсуждают связь пословиц с содержанием стихотворения.<br>Оба ученика высказывают свои мысли. |
| 6) Рефлексия (подведение итогов занятия) | Подводит обучающихся к выводу о главной идее стихотворения.<br><br>What is the main idea of the poem «The street of the native village» by G. Zainasheva?<br><br>Учитель организует работу учащихся с целью контроля и выявления степени усвоения учебного материала (метод синквейна)<br>-Существительное<br>-2 прилагательных<br>-3 глагола<br>-Фраза из 4 слов<br>-Синоним<br><br>Учитель проводит рефлексию деятельности на уроке (прием «Продолжи фразу»):<br>1. It was interesting for me ….<br>2. Today we have discussed …<br>3. I have understood that…<br>4. It was difficult for me … | Высказывают свое мнение<br>I think she wrote about connection of a person with nature.<br>I suppose she showed the attitude to the native land.<br><br>Излагают содержание учебного материала на тему изученного отрывка<br><br>-Motherland<br>-native, great<br>- love, save, protect<br>-we are proud of it<br>-home<br><br>Формулируют свое отношение к результатам урока<br>-It was interesting for me to make a literary translation/ to learn Zainasheva's biography…<br>-Today we have discussed the moral of the poem, the author`s feelings …<br>-I have understood that nature is very fragile and we should take care of it |
| 7) Объяснение домашнего задания | Объясняет дифференцированное домашнее задание:<br>Your hometask is to make your own translation of the poem.<br>If you want to get "5" you should translate 12 lines words.<br>"4" – 8 lines.<br>"3" – 4 lines. | Задают вопросы, если есть непонятные моменты |

Приложение 1

Биография Г. Зайнашевой.

The biography of G. Zainasheva (**13 января 1928 — 1 апреля 2005)**

Gulshat Hisamovna Zainasheva was born in the village of Staroe-Klyanchino (now in the Tukayevsky district of the Republic of Tatarstan). She was born in a large peasant family. The

father was dispossessed and exiled to Arkhangelsk, and Gulshat was given to another family for upbringing. Gulshat's childhood years were spent in the villages of Takerman, Kuzembetevo.

Gulshat Zainasheva graduated from the Menzelin Pedagogical College, and then entered the Kazan State Pedagogical Institute at the Department of Tatar language and Literature.

In 1949 G. Zainasheva joined the radio committee as an editor of literary broadcasts. In 1952-1963, she worked as a literary editor of the Tatar Book Publishing House, then as an editor of musical broadcasts of the Tatar radio, director of the G.Tukai club of the Union of Writers of Tatarstan. In 1973-1983, the activity of G. H. Zainasheva was again associated with the Tatar Book Publishing House, with which most of her work biography is associated.

Gulshat Zainasheva's work was also associated with Tatar drama. Her plays were staged at the Menzelinsky Tatar Drama Theater already in the 1960s. Performances based on her plays ("I'm not sorry for your Soul" and "Gayfi Babai, Get Married") were successfully performed on the stage of the Tatar State Drama and Comedy Theater named after K. Tinchurin. She also wrote for the Tatar State puppet theater "Ekiyat" — one of the oldest theaters in Tatarstan.

Gulshat Zainasheva was also the author of screenplays, essays and documentary stories, which were devoted to the work of outstanding figures of Tatar culture.

Since 1969 — member of the Union of Writers of Tatarstan.

G. Zainasheva - poet, playwright, publicist, Honored Artist of the Republic of Tatarstan, awarded the State Prize of the Republic of Tatarstan named after G.Tukai.

G. Zainasheva died in April 1, 2005.

Приложение 2

| На английском языке | На татарском языке |
|---|---|
| The street of the native village<br><br>This is an ordinary village,<br>The place where I was born and grew up.<br>But when spring comes<br>It becomes a blooming garden.<br><br>The street of my native village<br>I went around it again.<br>A bird sang over my head<br>And brought me happiness.<br><br>Although the houses here are new<br>My village is old.<br>Don`t forget me, my homeland<br>I`m your prodigal son.<br><br>Poplars in my village<br>I don`t know who`s planted them.<br>It is heard from every house<br>The mother tongue, melodious language. | Туган авылым урамы<br><br>Туган җирем, үскән җирем —<br>Гади генә бер авыл.<br>Гади булса да, яз җиткәч,<br>Гөл бакчасы була ул.<br><br>Туган авылым урамын<br>Кабат-кабат урадым.<br>Баш очымда кош сайрады —<br>Бәхетемә юрадым.<br><br>Йортлары яңа булса да,<br>Минем авылым борынгы.<br>Онытма, туган авылым.<br>Яуда калган улыңны.<br><br>Авылымның топольләрен,<br>Белмим, кемнәр утырткан.<br>Туган телем, моңлы телем<br>Ишетелә һәр йорттан. |

**Мин тормышка гашыйк...**

(Якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнашеваның

95 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Мөхәммәтдинова Эльмира Феликс кызы,

Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе филиалы

Каташ-Каран төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы

Максат:

1. Укучыларны якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнашева иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.

2. Укучыларда сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү, сөйләмнәрен баету.

3. Укучыларны Гөлшат Зәйнашева шигырьләре үрнәгендә тәрбияләү: туган якка мәхәббәт, әниләргә, хезмәт кешеләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның портреты, китаплары күргәзмәсе, компьютерда презентация, язучы иҗатына багышлап чыгарылган стенгазеталар.

Кичәнең барышы:

Кичә буласы залда Гөлшат Зәйнашеваның китапларыннан күргәзмә оештырыла. Мультимедиа проекторы буенча слайдларда шагыйрәнең тормыш һәм иҗат юлы күрсәтелеп барыла.

“Мин тормышка гашыйк” көе яңгырый

Алып баручы:С өекле һәм талантлы якташ шагыйрәбез, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган, дистәләгән китап авторы Гөлшат Зәйнашевага багышланган кичәне башлыйбыз.

1 нче укучы:

Алтын телле иҗат алып килеп,
Дәртле, моңлы, көчле халыкка,
Азмы гәүһәр өстәдең син, Гөлшат апа,
Ук та атмый, туп та ватмый торган
Тукай әйткән рухи байлыкка.
2 нче укучы:

Гөрләп, дөрләп яна-яна яшәп,

Гаҗәп гүзәл иҗат юлында
Азмы байлык өстәдең син, Гөлшат апа
Халкыбызның алтын фондына.

3 нче укучы: Бездә бәйрәм. Шигърият һәм җыр бәйрәме. Якташ шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашеваның тууына гыйнвар аенда 95 ел тула.

Алып баручы: Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның хәзерге Сарман районы Иске Теләнче авылында крестьян гаиләсендә туган. Бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә уза, шунда башлангыч, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне, аннары Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый.

Г.Зәйнашева Минзәләдә укыган еллары турында үзенең хатында болай дип яза: “14-15 яшемнән мин Минзәлә педучилищесендә укыдым .1942-1945 еллар иде бу. Бик авыр еллар иде.Училище бинасы кышларын ягылмый иде. Язу каралары катып боз булган классларда укый идек. Каланча астыдагы тулай торак та ягылмый иде, аның миче дә юк

иде. Яшь үсмер кызлар урамнан таш, кирпечләр җыеп кереп, үзебез мич чыгарып, шунда ашарга пешереп, җылынып яши идек...”

2 нче укучы: Югары Тәкермән авылында аның балачагы, үсмерчагы узган. Г.Зәйнашева бөтен барлыгы-җаны, тәне, акылы, күз карашлары, атлап йөрүләре, елмаюы – туган җиренә, басуларына, чишмәләренә, кешеләр күңеленә килеп тоташа. Бу аның шигырьләрендә аның сүзләренә язылган җырларда да бик ачык күренә. Ә хәзер, әйдәгез. аларны тыңлап карыйк.

3 нче укучы:
“Туган җиремә” шигыре
Тугай ярып аккан чишмәләр кебек,
Саф хисләрем җырыма талпына.
Җырым кайнар чишмә булса,
Татлы суын үзем эчми,
Бирер идем хезмәт сөйгән халкыма.
Һәрбер шатлык, кояш нурлары булып,
Үрли минем күңелем түренә.
Йөрәк җырларым да шулай,
Кояш кебек якты нурлар
Сипсен иде туып-үскән җиремә!..

“Моңлы авыл Тәкәрмән” җыры башкарыла

3 нче укучы:
“Сарман сагышы” шигыре
Туган җирең кайда, дип сорасаң,
Туган җирем Сарман ягында.
Беркая да китмәм Сарманнан, дип
Уйлый идем бала чагында.
Ләкин киттем, сүнеп юкка чыкты
Хыяллары бала чакларның.
Бала чагым белән бергә сагынам
Чишмәләрен туган якларның.
Яшьлегем дә әллә ничек булды,
Шатлык килсә, сөенә алмадым.
Бер чишмәнең суын эчеп үскән
Сөйгәнемнән сөелә алмадым.
Күңелемдә мәңге чыңлап торыр
Сарман чишмәләре тавышы.
Нигә моңлы син, дип сорамагыз,
Җырларымда сарман сагышы.

“Туган авылым урамы” җыры башкарыла

3 нче укучы:
“Газиз туган авылым” шигыре
И авылым, газиз туган авылым,
Сине сагынып кайтып килешем.
Каршы алды мине күз яшьләре
Кипкән кебек сусыл инешең.
Тал-тирәкле иде су буйларың,
Яшел чирәм иде урамың.
Сазлык булып беткән урамыңда
Сүзсез калып бертын җылыдым.
Көзге яфрак кебек сибелдек без,
Нинди җилләр безне таратты?
Оясыннан куган бер кошыңның

Баласы мин сыңар канатлы.
Белсәң иде, авылым, чит-ят җирдә
Бу башымнан ниләр кичкәнен.
Эчимсәнә бер йотым суыңны,
Ярларына ятып чишмәңнең.

4 нче укучы: “Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше иде. Тормыш аны төрлечә сынады, ә кайчакта – бик аяусыз. Әмма ул бөгелмәде, сынмады, бөтен авырлыкларны җиңеп, урман эченнән чабып баручы зифа боландай алга омтылды...” – дип искә ала Татарстанның атказанган икътисадчысы Марс Гаитов.

5 нче укучы:
“Үзем турында” шигыреннән өзек
Сөйлә, дисәгез, сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткән гомерем бер җыр, бәет –
Барсы чагыла җырымда.
Булды кагылып-сугылып,
Ятимлекләр күргән чагым.
Күгәрчен баласы кебек,
Йортсыз-җирсез йөргән чагым.
Булды ачлык тырнагында
Җан бирергә җиткән чагым.
Дусларны әҗәлдән йолкып,
Кан бирергә әзер чагым.
Булды сандугачлар белән
Бергә сайрашкан көннәрем.
Җирдәге бәхеттән күккә –
Йолдызга ашкан төннәрем.
Булды эш, хезмәттә җиңеп,
Данга ирешкән чакларым.
Якын дуслар белән шатлык,
Бәхет бүлешкән чакларым.
Булды коега төшкәндәй,
Кайгыга баткан көннәрем,
Ай ярылган, йолдыз сүнгән
Шикелле кара төннәрем.
Тыңлыйсызмы мин сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткәннәрем бер җыр, бәет,
Барысы чагыла җырымда.

Алып баручы: Гөлшат апа Зәйнәшева шигырьләрендә татар халкының киләчәге турында зур уйлану, аның сәнгате турында борчылу, иң якын дусларын юксыну күзгә бәрелеп тора – болар барысы да шагыйрә йөрәге аша шытып чыккан. Безнең өчен иң газиз кешеләребез – кадерле әниләребез. Алар турында, үзенең әнисе турында сагынып, аларны хөрмәт итеп күп кенә шигырьләр иҗат иткән шагыйрь.

“Әнкәй җыры” җыры башкарыла

Алып баручы: “Гөлшат апаның иң кыйммәтле сыйфаты, мөгаен, кешеләрне ярата белүе булгандыр. Бу кешелекне ярату дигән гомуми сүзләр генә түгел, шагыйрьнең һәр кешедә шәхесне күрә белүе, аралашу сәләтенә ия булуы. Барлык таныш-белешләренә җитәрлек мәхәббәт сыйдырган, даладай киң күңелле бер генә затны беләм мин. Ул – Гөлшат Зәйнәшева”, – дип искә ала аның турында Рафаэль Сальмушев.

1нче укучы:

“Тагын елмай ” шигыре
Читтән генә карап бер елмайдың,
Күз карашың шундый ягымлы.
Дөнья балкып китте, әйтерсең дә
Арабызда йолдыз кабынды.
Дөнья яктылыгын күрә алмас
Бер халәттә иде күңелем.
Елмаюың белән аңлаттың син
Алай яшәү – яшәү түгелен.
Тагын елмай, арабызда йолдыз
Тиккә генә нурын сипмидер
Бу күңелгә башка беркем түгел,
Синең елмаюың җитмидер.

“Син икәнсең” җыры башкарыла

Алып баручы: “Г.Зәйнәшевага бөтен халык соклана иде, һәм ул, бәхеткә, исән чакта бәясен дә алды – җыр текстлары язучылардан беренче булып Г.Тукай бүләгенә лаек булды.

Без якын дуслар-сердәшләр булып китә алмадык, чөнки Гөлшатның иҗатташ дуслары бик күп иде. Сара Садыйкова, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова... Санап кына бетерерлек түгел, һәммәсе татар сәнгатенең күгендә йолдыз булып балкыган шәхесләр. Бу яктан да мин аңа һәрчак сокланып һәм бераз көнләшеп карый идем”, – дип яза аның турында Мәдинә Маликова.

2 нче укучы:

“Ни хәлдә яшисең?..” шигыре
– Ни хәлдә яшисең? – дидем
Бик якын бер танышыма.
– Барам әкрен, әкрен, – диде, –
Барам кояш баешыма...
Нишлисең, ялгызым, – диде, –
Күңелсез дә, ямансу да.
Яшим истәлекләр белән,
Яшьлектә калды барысы да...
Яшьлегем истәлекләре –
Бу тормышта юанычым.
Баеп барган кояш инде
Үзем дә, – диде танышым.
– Баеса да, кояш сүнми, –
Дип, дустыма мин кул бирдем. –
Кояш кебек без дә шулай
Сүнмик әле, дускай, – дидем.

Алып баручы: Гөлшат апаның халкыбыз хатын-кызларына хас иң гүзәл сыйфатлары безнең буын өчен тәрбия үрнәге булып торды. Үтә тыйнак, сабыр холыклы, ярдәмчел гади татар кызы милләттәшләренең иң тирән, бай хисләрен гап-гади сүзләр белән, мәңге онытылмаслык итеп әйтеп бирә алган зур шагыйрә булып истә калды. Кызыгырлык! Шулай яшәп, шулай китсәң иде дөньядан!..

Шушы көннәрдә шагыйрәгә 95 яшь тулыр иде. Без Гөлшат апаның иҗатына, шигъриятенә гашыйк җаннар якташыбыз белән чын күңелдән горурланабыз.

Рәхмәт сиңа канатлы якташыбыз!

Кичә “Мин тормышка гашыйк” җырын җырлап тәмамлана

**Иң гүзәл биеклек**

(Күренекле шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашеваның тууына 95 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Магданурова Гөлназ Файз кызы,

Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Актаныш районы

**Максат:**

- Татар халкының яраткан шагыйрәсе, бик күп танылган җырлар авторы Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты белән тирәнтен танышу;

- Гөлшат Зәйнашева җырлары аша укучыларда, авыл халкында, әти-әниләрдә татар җырына, моңына мәхәббәт тәрбияләү;

- Татар теленә, туган җиребезгә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Кичәдә мәктәп укучылары, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, әти-әниләр,авылдашлар катнаша.**

**Җиһазлау:** Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты буенча ясалган презентация, компьютер, мультимедия, китап күргәзмәсе.

Кичәнең барышы:

1 нче слайд:

Гөлшат Зәйнашеваның портреты һәм түбәндәге язма:

Иң гүзәл биеклек җирдә ул,

Хезмәттә,кешенең эшендә.

Кешеләр күңеленең түрендә,

Тормышка мәхәббәт көчендә!..

Г.Зәйнашева

Әкрен генә Мансур Мозаффаровның Гөлшат Зәйнашева сүзләренә иҗат ителгән “Мин тормышка гашыйк” җырының көе яңгырый.

Алып баручы. Хәерле көн, хөрмәтле авылдашлар, укытучылар, укучылар! Бүген без сезнең белән җырлы-моңлы кичәгә җыйналдык. Яраткан шагыйрәбез, халкыбыз арасында бик тә популяр җырлар авторы Гөлшат апа Зәйнашеваның туган көне уңаеннан әзерләнде бу кичә. Сезгә Гөлшат Зәйнашева исеме танышмы?

Ә бүген без менә шушы залдагы апалар, абыйлар, сезнең әти-әниләрегез күңелендә сакланган лирик җырлар иҗат иткән шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны искә алырбыз, аның кабатланмас иҗатын тагын бер кат күздән кичерербез.

Авылыбыз мәдәният йорты каршында оешкан “Хәзинә” вокаль ансамбль башкаруында “Очрашу” җырын тыңлап үтик. Илһам Шакиров көе, Г.Зәйнашева сүзләре.

“Мин тормышка гашыйк”җырының көе ишетелә.

2 слайд.Болын һәм анда йөрүче акбүз ат рәсеме.

Алып баручы. Халык күңеленә кереп,сеңеп кала торган җырлар була. Бер карасаң, сүзләре дә гади генә кебек. Ә менә шул сүзләр күңелгә бик тә якын, алар сине юата, иркәли, уйландыра, алга дәшә. Шул сүзләр, шул шигырь көй сорый, аның моңга әверелеп еракларга яңгырыйсы, авыл болыннарыннан әйләнеп кайтасы килә. Ярый әле күренекле шагыйрәнең шигырьләрен күренекле көй авторларыбыз вакытында күргән. Ярый әле бу искиткеч җырлар дөньяга туган.

Фәнәвис Ахунов башкаруында җыр. “Акбүз атым”. Ганс Сәйфуллин музыкасы, Г.Зәйнашева сүзләре.

Алып баручы. Яраткан шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашева биографиясе күпләребезгә таныштыр. Безнең укчыларыбыз бүген тагын бер кат кыскача гына шагыйрәнең биографиясенә тукталып китәрләр. 7 класс укучысы Садертдинова Таңсылуга сүзне бирик.

Слайдлар күрсәтелә.

Г.Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнваренда Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган. Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр. 2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тегермән авылында уза. Ләкин апасының ире бу баланы яратмый, аны хәтта кайчакларда кыйный да. Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була. Минзәләдән артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр. 4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар. Спектакь караганнан соң артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, ул артист булып уйнарга ярата.

Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була. Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң башта педагогия училищесын тәмамлый, аннары 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бер үк вакытта театр училищесына йөреп, дәресләр ала. Әмма аңа я институтны, я театр училещысын сайларга кушалар. Ул институтны сайлый, ләкин концерт бригадалары белән бергә авылларга чыгып йөри, концертлар алып бара. Институтны тәмамлагач, Г.Зәйнашева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре, җырлары матбугат битләрендә күренә башлый.

1958 нче елда "Тыңларсыңмы җырларымны" исеме белән беренче китабы басылып чыга.

Педагогия институтында укый башлагач та, җиңел булмый аңа. Иң башта фронтта бер кешең дә юк дип, тулай торактан урын бирмиләр. Гөлшат бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри, бер елдан соң гына урын бирәләр аңа. Бик яхшы укыганы, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә.

Тагын шуны өстәп әйтәсем килә: Г.Зәйнашева моңлы, матур тавышка ия була. Һәркем белә: җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле, чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне беркемнән яшермичә җыры аша әйтеп бирә.

“Туган җиремә” Зиннур Гыйбадуллин музыкасы, Г.Зәйнашева сүзләре.

Башкара кызлар триосы.

Алып баручы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда чагыла. Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, гүзәл табигать, яшьлек матурлыгына, дәртенә бәйле темаларны ачкан лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, яңгыравыклы аһәңе белән аерылып торалар. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең 100 гә якын шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң таралып, үзешчән һәм

профессиональ жырчыларның озак еллар буе даими башкара торган тотрыклы репертуарында урын алды.

Слайд: популяр җырлар исемлеге:

“Туган җирем - Татарстан” (А. Ключарев музыкасы)

“Китмә, сандугач” (Р. Яхин музыкасы)

“Менәргә иде Урал тауларына” (М. Мозаффаров музыкасы)

“Үз илемдә” (С. Садыйкова музыкасы )

“Зәңгәр төймә” (халык көе)

“Күл буена килсәң иде” (З. Гыйбадуллин музыкасы)

“Кичегеп килгән мәхәббәт” (Б. Гайсин музыкасы)

“Кояш гомере” (Ф. Әхмәдиев музыкасы)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина музыкасы)

“Туган авылым урамы” (Г. Сәйфуллин музыкасы)

Гөлшат Зәйнашева иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Аның иҗатына танылган язучы Гариф Ахунов менә нинди бәя биргән (Слайдта): “Гөлшат Зәйнашева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда Язучылар союзына член итеп кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул иткән “Менәргә иде Урал тауларына”, “Китмә, сандугач” кебек рухи бай, романтик җыр текстлары дистәләп. Сүзләренә тәңгәл килә торган киң колачлы музыка белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп, бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр”. Гариф Ахунов, Татарстанның халык язучысы. 1970 нче ел.

Җыр.Башкара Альмира Ямалиева. “Туган авылым урамы”.Г.Сәйфуллин көе. Слайдта Г.Зәйнашеваның шигырьләренә балалар ясаган рәсемнәр.

Шигъри тәлгәшләр. Укучылар тарафыннан Г.Зәйнашеваның балалар өчен иҗат иткән шигырьләре яки шигырьдән өзекләр укыла.

“Тукран белән сөйләшү”,“Кышкы салкын бер иртә”,“Татарча ничек?”, “Кем булырга?”, “Спортсмен әби”, “Пенсиягә”,“Гөлүсә”, “Сагыз”,“Бияләй түгел, перчаткы”, “Алтын куллар кирәк”.

Алып баручы. Хәзер без әти-әниләребезнең яшьлек җырларын искә төшереп хисләнеп, моңланып алырбыз. “Көйне таны” уенына уенчыларны гадел юл белән бүлү эшен балаларга тапшырам. Укучылар киселгән сүрәтләрне тоташтыру юлы белән командаларны бүләләр. Исем сайлыйлар. Командалар чиратлап яңгыраган көйне әйтәләр, бер куплетын бергә башкаралар.

Слайдларда җаваплар чыга.

“Сәяхәтче җыры” З.Гыйбадуллин музыкасы

“Уз илемдә” С.Садыйкова музыкасы

“Керкәле таулары” И.Закиров музыкасы

“Гөлләр иле” С.Шәмсина музыкасы

“Буразналар” Җ.Фәйзи музыкасы

“Күл буена килсәң иде” З.Гыйбадуллин музыкасы

“Тибрәнә җыр күңелдә” З.Сәгыйтов музыкасы

“Бәхет юллары” Л.Батыр-Болгари музыкасы

“Сәфәр чыксам” Халык көе

“Өй артыгыз гөлбакча” Р.Курамшин музыкасы

“Мин бит кара карлыгач” Ш.Тимербулатов музыкасы

“Аерылмагыз” Ч.Зиннәтуллина музыкасы

Алып баручы. Афәрин, булдырдыгыз. Рәхмәт сезгә. Күңелләрдә сакланган, онытылмас җырларны искә төшердегез. Бу җырлар – халыкчан, бу җырлар – яңгырашлы, бу җырлар – яшьлек хисләрен саклаучылар.

Слайдта авылыбыз фотолары.

Җырлый Эльмира Муллаянова. “Баш очымда кош сайрады” Г.Сәйфуллин музыкасы.

Слайдта шигырь юллары.

Ничек үтәр иде гомер,

Булмаса шул мәхәббәт?

Кешене кеше итүче

Мәхәббәткә мең рәхмәт!

*Гөлшат Зәйнашева*

Алып баручы. Мәхәббәт, тигезлек, сөю – кеше гомерен бәхетле итүче төшенчәләр. Гашыйк булган һәм ярата, яратыла алган кеше генә чын мәгънәсендә бәхетле була ала, ди ул. Аның шигырьләре, җырлары туган җиргә, чишмә һәм урманнарга, басу-кырларга, аның алтын куллы хезмәт ияләренә,иҗат кешеләренә, әнкәйләргә мәхәббәт белән сугарылган. Мәхәббәт ул – бөек көч. Чыннан да, Гөлшат Зәйнашева үзенең җырлары белән җаннарны иркәли, күңелләргә дәрт бирә. Аның җырларын Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми дә югары бәяли. (Слайдта): “Гөлшат Зәйнашева җырларының сихри бер үзенчәлеге, күңелне яулый торган көче бар. Аларга гомумкешелек тойгылары салынган. Сәнгатьнең бөтен көче дә шунда түгелме соң?..” Нажар Нәҗми, Башкортстанның халык шагыйре. 1991 нче ел.

“Китмә,сандугач!..”(Р.Яхин музыкасы”)Х.Бигичев язмасында видеоязмада тыңланыла.

Нәфис сүз.Укый Ләйсән Акмалова

Алып баручы. Балачактан күңелгә кереп калып мәңге онтылмый торган бер җыр бар. Ул җыр “Җырлыйм әнием турында” дип атала.Бүгенге чарада олы йөрәкле,киң күңелле Ана – үз балалары янына унбиш ятимне сыйдырган, үстергән Фәнзилә апа Шәйхетдинова да катнаша.Алар барысы бергә бу җырны башкарырлар. Рәхим итегез.

Алып баручы.Чыннан да, Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты сокланырлык. Ул татар халкына нинди зур, үлемсез мирас калдырып китте. Кичәбезне язучы Роза Хафизованың сүзләре белән йомгаклыйсым килә. (Слайдта): “Гөлшат Зәйнашева популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйды”. Язучы Роза Хафизова

Кичәбез “Иң гүзәл биеклек”дип аталды.Шул биеклектән безгә бүген елмаеп шат күңелле Гөлшат апа кул изи сыман. Татар халкы яшәгәндә аның җырлары, шигырьләре үлемсез булып калыр. Әби-бабаларыбыздан әти-әниләребезгә, алардан балаларга күчәр. Мәгънәле, халыкчан, моңлы җырлар күчәр.

**Бер күрешү – бер гомер**

(Аулак өй кичәсе - бөек шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның тууына 95 ел тулуга багышлана)

Хәбибулхакова Иркә Мөхәмәтнаил кызы,

Петровка завод урта гомуми белем бирү мәктәбе

Сарман муниципаль районы

Максатлар: бөек шагыйрәбез Гөлшат апа Зәйнәшеваның иҗатына карата ихтирам, якташ язучыларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләү. Татар халыкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрне яңарту; укучыларда татар халык традицияләре, гореф-гадәтләре аша татар теленә мәхәббәт хисләре уяту; татар халык уеннарын өйрәтү аша әдәплеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олылырны хөрмәт итәргә өйрәтү

Зал авыл өе күренеше итеп бизәлә (чиккән сөлгеләр, борынгы сандык, кулъяулыклар, самавыр, чынаяклар куела)
Кичә барышы.

Алсу: Исәнмесез мөхтәрәм кунаклар, укытучылар, укучылар. Бүген бездә – аулак өй. Аулак өй турында ишетмәгән кеше сирәктер. Ишеткәнегез булмаса, әйдәгез аулак өйгә рәхим итегез, без сезне аулак өйгә чакырабыз, әби-бабаларыбыздан калган йола, уен, бәйрәмнәрне искә төшерәбез.Әйе, гомер узган, тула оек белән чабаталар тузган. Ә халкыбыз мирасына булган мәхәббәт йөрәкләребездә саклансын.

“Хәтерләүдән курыкмагыз сез!

Үткәнегезне онытмагыз сез.

Белегез сез ерак бабаларның,

Ничек итеп көн иткәнен...

Ни иккәнен, ни чиккәнен,

Бөек олы шәхесләрнең

Нинди җырлар, нинди моңнар

Безгә калдырып киткәнен.

Сәхнәдә өй күренеше. Кызлар сөйләшеп керәләр.

Наилә: Кызлар, минем бер уем бар. Аулак өй оештырып алсак, ничек булыр икән? Күптән күрешеп,рәхәтләнеп сөйләшеп серләшеп утырганыбыз юк. Кул эшләрегезне дә алып килерсез.

Язилә: Мин риза. Бик рәхәтләнеп...

Нәргизә: Мин дә киләм, кызлар. Илмираны да чакырыйммы?

Наилә: Әлбәттә. Мин сыйныфташларыма да эндәшәм. Әйдәгез, 16 сәгатьтә бездә очрашыйк. Әнием каршы булмастыр дип уйлыйм. Без аның белән бу турыда сөйләшкән идек инде.

Язилә: Ярый, очрашканчыга кадәр, кызлар.

Кызлар җыелышалар. Араларында берничә егет тә бар. Кул эшләре тотканнар, күчтәнәчләре дә бар.

Наилә: Хәерле кичләр, дусларым! Әйдәгез, түрдән узыгыз. Бик зур рәхмәт сезгә күчтәнәчләрегез өчен, мин дә коймак пешердем. Озакламый әнинең бәлеше өлгерә.

Алсу: Әйдәгез бераз кул эшләре белән шөгыльләнеп алыйк.

Язилә: Кызлар-егетләр, әйдәгез җырлый-җырлый эшлик әле.
Барысы: Әйдәгез, әйдә.(кул эшләрен алып, утырышалар.Наилә экранда татарча җырлар җыелмасы-караоке куя,бергә кушылып җырлыйлар )
Кайда барма чын дусларны табам,
Дуслар белән озын юл кыска,
Әллә җирдә дуслар күп булганга,
Мин тормышка гашыйк, томышка.

Чишмәләрнең җырын отар идем
Җыр өйрәнер идем һәр коштан,
Әллә кошлар матур сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, тормышка.

Озак яшәрмен диеп йөрәк тибә,
Ашкына күңелем һәр эшкә,
Әллә эшем бәхет китергәнгә,
Мин тормышка гашыйк, тормышка. ("Мин тормышка гашыйк" Г.Зәйнәшева сүзләре)

Наилә: Афәрин, дусларым !Бик матур җыр, әйеме? Бу җырның авторын беләсезме? Бу җырны якташ шагыйрәбез Гөлшат апа Зәйнәшева язган.

Язилә: Иркә Наиловна безгә Гөлшат Зәйнәшева иҗаты турында сөйләгән иде бит.

Нәргизә: Мин китапханәдән аның шигырьләр җыентыгын алдым. Г.Зәйнәшеваның шигырьләрен әнием дә яратып укый икән. Кич белән без аның шигырьләрен укыйбыз.

Марат: Алдагы җыр тагын да матуррак булырга ошаган. Әйдәгез бергәләп җырлыйбыз.

Син кемнең сандугачы?" җыры яңгырый.

Кызлар кул эшләре эшлиләр.

Алия: Әйдәгез, бераз уйнап алыйк әле.
Башкалар: Әйдәгез! Нинди уен уйныйбыз соң?
Алия: Әйдәгез, йөзек салыш уйныйбыз!

Йөзек салыш уены башлана.

Яшьләр тезелешеп утыралар,берәү" йөзек салучы" була. Ул кулларын кушучлап утырган кешеләрнең барысына да йөзек салып чыга. Йөзекнең кемгә туры килүен берәү дә сизмәскә тиеш. Аннан соң үзе бер кырыйга китеп:"Йөзек кемдә,сикереп чык",- ди. Йөзекле кеше сикереп торганда ике як күршесенең берсе тотып кала алса, йөзекле кешегә җәза бирелә. Мәсәлән: әтәч булып кычкырырга, ат булып кешнәргә, биергә, җырларга һ.б.ш.
Нәргизә: Әйдәгез инде "Капкалы" уенын да уйнап алабыз. Түгәрәкләнеп басыгыз әле.(түгәрәкләнеп басалар, бер пар уртада кала.) Уртада калган парларга җәза бирелә.
Алинә: Борын белән кар алып керсеннәр!
Алия: Яле күрсәтегез әле тапкырлыгыгызны.
Булат: Сез дигәндә аяк идәндә.Хәзер алып керәбез аны (Чыгып китәләр, аяк киеменең башына эләктереп кар алып керәләр).
Ренат: (күкрәк кагып) Күрдегезме безнең егетләрне!?
Уен дәвам итә.Уртада калучылрга тагын шундыйрак җәзалар бирәләр. Башыңны түшәмгә тидер! (Бүреген түшәмгә тидереп ала). Елаучының күз яшен сөрт! (Тәрәзә парын сөртә һ.б.)

Наилә: Дусларым, Г.Зәйнәшеваның туган илгә багышланган шигырьләре шактый. Менә берсен тыңлап карагыз әле.

“Туган җирем – Татарстан” җыры яңгырый..

Алсу: Бигрәк матур укыйсың да соң, Наилә.Тыңлаган саен, тыңлыйсы килеп тора.

Наилә: Хикмәт миндә түгел, дусларым. Гөлшат Зәйнәшева шулай йөрәкләргә үтәрлек итеп язган ул шигырьләрне.

Илмира: Дусларым, минем репертуарымда да Г.Зәйнәшева сүзләренә язылган җыр бар.Тыңлыйсызмы, җырлап үтәм.

Барысы: Бик рәхәтләнеп, Илмира.

(Илмира Г.Зәйнәшева сүзләренә язылган "Авыл көен" башкара).

Наилә: Бик булдыклы егетләр, уңган кызлар икәнсез. Ничек рәхәт итеп утырабыз. Рәхмәт, сезгә!

Нәргизә: Мин картинама күпме сөйлән тездем, карагыз әле?

Язилә: Ә мин картинамны буяп бетерә яздым, матур буламы?

Барысы: Шаккаткыч!
Алия: (оялып) Арытты. Инде бераз ял итеп чәй эчеп алмыйбызмы?
Илназ: Без чәйләп утырмабыз инде, кызлар. Мичтәге бәлешне култык астына кыстырыйк та без тайыйк. (Егетләр җырлый)

Алай итәргә кирәк,
Болай итәргә кирәк.
Хуҗаларга рәхмәт әйтеп
Кайтып китәргә кирәк.

Наилә: Әйдәгез бергәләп чәй эчик. Аннары таралышырбыз.
Алия: Кызлар, әйдә булышыгыз.

(Күңелле музыка башлана. Кызлар чыр-чу килеп өстәл әзерлиләр).
Әмирә: Бигрәк күңелле булды.Рәхмәт инде, Наилә.

Алинә: Рәхмәт, Наилә.Мин әнидән Г.Зәйнәшеваның шигырьләр җыентыгын сатып алуын сорыйм. Аның шигырьләре әниемә дә һичшиксез ошаячак.

Илмира:Мин Г.Зәйнәшева сүзләренә язылган җырларны репертуарыма күбрәк кертергә кирәк, дип уйлыйм.

Наилә:Рәхмәт сезгә, дусларым.Бик күңелле утырдык. Ә хәзергә хушлашыйк. Киләсе очрашуларга кадәр.

Алсу: Ә сезгә күңелле булдымы, ошадымы аулак өй? Ошаса, иртәгә Алияләрдә аулак өй. Тагын килерсез яме. ( Күмәк җыр.”Күңелле ял итегез" Г.Зәйнәшева сүзләре).

## Әдәбият дәресләрендә – тарихи чынбарлык

Г.Г.Хәлиуллина, Илексаз төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы,

Сарман районы

Укучыларның дөньяга ачык карашын булдыруда туган тел һәм әдәбият мөһим урын алып тора. Дәресләрдә өйрәнелә торган әдәби әсәрләрдә халыкның күпгасырлык акылы, тәҗрибәсе, тормышны аңлавы, кабул итүе чагылыш таба. Шуларны өйрәнү барышында укучылар төрле гыйбрәтле тарихи сәхифәләр, аерым кешеләр тормышына бәйле хәл-күренешләр белән таныша,

аларны бәяли, билгеле бер нәтиҗәләр ясый. Шулай укучы шәхесе формалаша. Бу формалашу күп тапкыр кабатлаулы эш-гамәлләр аша бара. Ә укытуның яңа стандартлары уку-укыту процессының эчтәлеген һәм формасын үзгәртү аша укучының шәхесенә йогынты ясауны, аның бүгенге катлаулы дөньяда үз-үзен табып яши алуын күздә тота. Безнең моны Д. Гарифуллинның «Норильлаг тоткыны» әсәрен өйрәнү барышында күрсәтәсебез килә. Кызганычка каршы, бу әсәр әдәбият дәреслекләренә кертелмәгән. Ләкин безгә дәрестән тыш эшчәнлек дәресләре, китапханә дәресләре ярдәмгә килә ала.

Дәрес җитди әзерлек алып баруны, укучыларның әсәрне укып килүләрен, фикер алышырга әзер булуларын таләп итә. Дәреснең шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәсе милли үзаң формалаштыру белән бәйле.

Бергәләп шартлы рәвешле «Якташыбыз Соббух Рәфыйков – Норильлаг тоткыны» дип аталган дәреснең план-макетын төзеп карыйк. Дәресне «Дамир Гарифуллинның «Норильлаг тоткыны» әсәре» дип тә атап була. Моннан аның эчтәлеге артык үзгәрми. Дәресне җиһазлауга да игътибар зур булырга тиеш. Дамир Гарифуллинның хезмәтләре күргәзмәсе, ул чордагы хезмәт белән төзәтү лагерьлары хакында мәгълүматларга таяну мөһим. Дәреснең этаплары аша үтик:

I.Актуальләштерү

Якташыбыз Д.Гарифуллин турында мәгълүмат бирү. Моның өчен 1-2 укучыны алдан әзерләп куябыз. Берсе Дамир Гарифуллинның шагыйрь булуы турында сөйли. Аның шигырь җыентыклары белән таныштыра. Икенче укучы Дамир Гарифуллинның туган төбәкне өйрәнүче тарихчы булуы турында сөйли һәм аның Сарман белән бәйле хезмәтләре белән таныштыра.

III. Төп өлештә уку мәсьәләсен куюга игътибар итәргә кирәк, чөнки уку мәсьәләсен чишү дәреснең төп өлешен били. Укытучы алдында җитди сорау-биремнәр ярдәмендә укучыларны әңгәмәгә, эзләнүгә тарту бурычы тора. Өйрәнелә торган әсәргә бәйле түбәндәге сорау-биремнәрне куярга була:

1. Әсәрдә нинди вакыйгалар сурәтләнә? Алар турында моңа кадәр укыганыгыз бар идеме? 2. Әлеге вакыйгаларның тарихи нигезе нидән гыйбарәт?

3. Әсәрнең төп герое кем? Аның турында текстта нинди мәгълүмат бирелә?

4. Тексттагы хикәяләүче һәм аның янындагыларга нинди бәя бирелә?

5. Әсәр синдә нинди хис-тойгылар, уй-фикерләр уятты?

Куелган сорауларга җавап эзләгәндә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк:

1. Әсәрдә нинди вакыйгалар сурәтләнә? Алар турында моңа кадәр укыганыгыз бар идеме? Әлеге сорауга бәйле төп вакыйгалар искә төшерелә. Язучының «Норильлаг тоткыны» хикәясендә Сталин хакимияте оештырган репрессия тоткыннарының ачы язмышы сурәтләнә. Вакыйгалар сугыштан соңгы елларда бара. Нәрсә соң ул Норильлаг? Әлеге лагерь – шәхес культы елларындагы кешелексез тарихыбыз сәхифәләрен үз эченә сыйдырган урыннарның берсе. Без мондый тарих белән И. Сәлаховның «Колыма хикәяләре», А. Гыйләҗевнең «Йөгез, бер дога!» әсәрләрен укыганда танышкан идек. Бу әсәрләрдә хезмәт һәм төзекләндерү лагерьлары тормышы турында сүз бара.

Шушы урында информацион технологияләренә мөрәҗәгать итәбез. Укучыларга компьютердан файдаланып, Норильлаг турында мәгълүмат тупларга кушырга була. Табылган мәгълүматны берләштерәбез. Әлеге лагерьдагы тормыш кырыслыгы белән аерылып торган. Бу алар тоткыннары, русча әйтсәк, первопроходцы булалар. Аларга кадәр зур промышленность объектларын поляр түгәрәк артында төзү тәҗрибәсе дөньяда гомумән булмый. Менә Норильлаг тоткыннары котчыкмалы начар, кешелексез шартларда әлеге эшне башкаралар. Алар мәңгелек бозлык шартларында Норильск комбинатын төзиләр. Кул кораллары, палаткалары гына булган бу кешеләр эшкә куыла... Бөек Ватан сугышы елларында, Википедия чыганакларына караганда,

биредә 7223 кеше вафат булган. Алар ачтан үлгәннәр. Интернет-ресурста мондый мәгълүмат та бар:

- тоткыннарга 800 грамм ипи тиеш була, ә алар бары 700 грамм ипи алалар;

- бернинди витаминнар да бирелми, бары чүпрә генә;

- киемнәр җитми, ә бирелгәннәре берничә срок файдаланыла.

Нәтиҗәдә, тоткыннар йөрәк-кан авыруларыннан кырылалар, дистрофия, үпкә авырулары тарала. Тоткыннарны вәхшиләрчә кыйныйлар, аларны котыртылган этләр талый. Конвой офицерлары һәм солдатлары белән килешмәүчәнлек килеп чыкса, тоткыннар шул ук минутта юк ителә. Ә актта бу үлем «Тоткын эш коралы белән дөрес эшләмәгән» дип аңлатыла.

2. Әлеге вакыйгаларның тарихи нигезе нидән гыйбарәт? Сорау үткәннәрне искә төшерүне таләп итә. Димәк, бергәләп чор үзенчәлекләре ачыклана. Автор тарихка таяна. Әлеге афәтнең тарихи нигезе бар. Гомумән, тарихилык – Д. Гарифуллин иҗаты һәм эшчәнлегенең үзенчәлекле ягы. Әдәбият сүзлегенә мөрәҗәгать итик: «Тарихилык ул – язучының үз әсәрендә документаль, хроник, мемуар чыганакларга, тарихи легенда һәм мифларга нигезләнеп кайсы да булса дәверне, ерак яки якын үткәнне тудыруы, әсәр тукымасына тарихи персонажларны, чынбарлыкта яшәгән шәхесләрне кертүе, кайбер очракларда сюжет нигезе итеп тарихи вакыйгаларны һәм фактларны файдалануы».

3. Әсәрнең төп герое кем? Аның турында текстта нинди мәгълүмат бирелә? Әсәрнең төп герое – танылган язучы Сөббух Рәфыйков. Укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә тарту максатында С. Рәфыйков турында берничә укучыдан материал әзерләп килүне оештыру да уңышлы. Укучылар чыгышы тыңлана һәм фактлар гомумиләштереп дәфтәрләргә языла. Иң элек Сөббух Рәфыйковның ни рәвешле «Норильлаг тоткыны»на әверелү тарихын карыйк. Әлбәттә, монда шәхеснең гаебеннән бигрәк тарихи фактлар зуррак роль уйный. Дошманнар, көнләшүчеләрнең төрле әләкләре аркасында иркеннән мәхрүм ителгән фән, мәдәният эшлеклеләренең, атаклы шәхесләрнең санын ул елларда дистәләп түгел, йөзләп санарга булыр иде. «Җинаятьләр кодексы»ның дәһшәтле 58 нче маддәсе буенча гаепләнеп хөкем ителгән меңнәрчә шәхесләр арасында С. Рәфыйков та була. Язучының «гаебе» турында геройның эчке монологы рәвешендә әсәрдә мондый мәгълүмат бирелә: «Ә бит әллә нинди гаепләр тактылар. «Имеш, мин ун троцкийчы буржуаз милләтчедән торган контрреволюцион оешмада булганмын», – дип әйтеп куйды ул үз-үзенә. «Мин хәзер дә белмим андый оешма булганлыгын», дип өстәде. «Галимҗан Ибраһимовка язылган котлау хатында да контр нәрсә юк! Юбилее белән генә котладык, Октябрьнең XX еллыгы белән тәбрикләдек, шул гына!» Сөббух кулындагы ипигә сөйли иде бу вакытта. Ул авыр сулап куйды да кружкага тагын шәраб салды. «Башларым ГУЛАГка китәрлек гаебем нәрсәдә иде соң минем?»

4. Тексттагы хикәяләүче һәм аның янындагыларга нинди бәя бирелә?

Бу - иң авыр сорауларның берсе. Безгә укучыларның үзләрен активлыкка тартырга кирәк. Укучылар үз фикерләрен әйтсеннәр, бәхәсләшсеннәр. Укучылар әсәрдән өзекләр табып укыйлар. Күп вакытны текст белән эшләүгә бирергә кирәк. Укучылар язучы язган сүзләрнең мәгънәсен ачсыннар иде.

Менә әсәрдән өзекләр: «Сөббух шәхес культы чорының үлеш-бетеш сәясәтенә нәфрәтен белдерә. Аш табынында Банат апасы аларны «шомлы сүзләр»дән туктата туктатуын. Әмма Галимҗанны озата чыккач, шактый гына төшереп алган Сөббух йөрәк ярсуына чыдый алмый: чирәмгә ятып совет властен сүгә, чит илне мактап ташлый, илдә мондый власть озак яшәмәс, ди».

«Гаеп» дип атарлык башка фактлар да искә төшә башлый: кемгәдер Фәтхи Бурнашны кысалар, дигән ул; шагыйрь Мансур Крымовны үзенең остазы дип таныган; Татарстан язучылары җитәкчесе Ләбиб Гыйльмановның халык дошманы булуына шик белдергән һ.б. Нәтиҗәсе – шул еллар өчен типик: төнлә килгән «кара козгын» машинасы аны еракка алып китә.

Билгеле, фикер алышу төрле юнәлештә булырга мөмкин. Укытучы исә әлеге елларның каршылыгын ача. Кешеләрнең пропагандага ышанырга мәҗбүр булулары турында сөйли.

Д. Гарифуллин хикәясендә сәяси тоткыннарның язмышы бөтен трагизмы белән сурәтләнә. Мәсәлән, тоткыннар азат ителгәч, алар «чит элемент», кирәксез, төрмәдә утыру белән тапланган кеше буларак кабул ителәләр. Моның ачысын үз вакытында Хәсән Туфан да, Аяз Гыйләҗев тә татып карыйлар. Сөббух Рәфыйковка да бу күренешнең шаһиты булырга туры килә. Д. Гарифуллин бу хакта язмаса да, китапта язучының авылдашы Н. Гарифҗанованың әрнү тулы шигыре теркәлә. Н. Гарифҗанова, эпиграф рәвешендә «Төрмә, сөргеннәрне үтеп исән кайткан С.Рәфыйковны авылы танымаган, кул бирмәгән...» дип язып куя. Еллар аша ул Сөббух Рәфыйковка мөрәҗәгать итә: «... Әйе, Сөббух абый, гафу сорыйм. Менә күпме шаһит каршында...».

5. Әсәр синдә нинди хис-тойгылар, уй-фикерләр уятты? Дәреснең иң җитди өлешендә укучылар, укыганнарына нигезләнеп, нәтиҗә ясыйлар. Бу этап бик әһәмиятле. Безгә укучыларга милләтнең алдынгы шәхесләрен шул рәвешле юкка чыгару сәясәтен үткәрелгәнен күрсәтергә кирәк. Хәзер үткәндәге тарихыбыз сабакларын бәяләргә кирәк.

IV. Дәреснең рефлекция өлешендә укучылар әсәргә анализ ясау юлын эзлекле сөйләп, гомуми нәтиҗәгә киләләр.

IV. Өй эшенә эссе язарга бирелә: «Сталин репрессияләре фаҗигасе».

## Барысы чагыла җырымда

Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Муртазина Альбина Николай кызы,

аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе Сарман районы

VII сыйныфның татар төркемнәре өчен татар әдәбияты буенча төзелгән программада шагыйрь Гөльшат Зөйнашева иҗатын өйрәнүгә 2 сәгать вакыт бирелә. 1 нче дәрестә шагыйрәнең иҗаты турында белешмә һәм "Туган җирем – Татарстан" шигыре өйрәнелә. Дәреслектә материал аз булу сәбәпле, 2 нче дәрестә Гөлшат Зәйнашеваның җыр өлкәсендәге эшчәнлегенә тукталып китәм һәм дәресемне "Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә иҗат итәлгән җырлар" темасына уткәрәм.

Максат. Укучыларны Г. Зәйнашева иҗаты белән киңрәк таныштыру; Г. Зәйнашева җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

Җһазлау. Г.Зәйнашева иҗатына багышланган презентация, китап күргәзмәсе, җырлары язылган дисклар; дәрестә исемнәре телгә алынган әдәбият- сәнгать әһелләренең портретлары; компьютер, мультимедия.

Кичәнең барышы.

I.Кереш өлеш.

1 нче слайд. Г.Зөйнашева портреты һәм шигыреннән юллар:

Сөйлә, дисәгез, сөйлимен

Үткән гөмерем турында.

Уткән гөмерем бер җыр, бәет –

Барысы чагыла җырымда.

(Әкрен генә М.Имашевның Г. Зәйнашева сүзләренә иҗат иткән "Әллә кемне күңел сагына" җыры яңгырый.)

Укучылар, сезгә Гөлшат Зәйнашева исеме танышмы? Без аның иҗаты белән ничәнче сыйныфта танышкан идек? (Җаваплары тыңлана.)

- Әйе без башлангыч сыйныфларда Гөлшат Зәйнашеваның “Кояш гомере” шигырен һәм шул шигырьгә Фәтхрахман Әхмәдиев көй язган җырны өйрәнгән идек. Соңрак без бу җырны бергәләп башкарырбыз. Шулай итеп, бүген без бик күп лирик җыр иҗат иткән шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны искә алырбыз, аның кабатланмас иҗатына тукталып китәрбез.

II. Төп өлеш.

1 нче укучы (алдан әзерләнгән призентация буенча чыгыш ясый).

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашева – тәөрле әдәби жанрларда иҗат иткән шагыйрә. Әдәбият белгечләре билгеләп киткәнчә, аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре җыр текстларында аеруча нык чагылыш таба.

Шагыйрәнең халык җыры традицияләре калыбында язылган һәм нигездә мәхәббәт, туган җир, туган табигать яшьлеккә бәйле темаларны гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, идея-хис бөтенлеге, ачык аңлаешлы чагыштыру бизәкләре һәм музыкаль аһәңе белән аерылып тора. Шуңа күрә Гөлшат Зәйнашеваның шигъри иҗаты музыка әһелләренең игътибарын һәрвакыт үзенә җәлеп итте. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзләгән шигыренә көй язылган. Аларның шактые, халык арасында киң танылып, үзешчән һәм профессиональ җырчыларның озак еллар буе даими башкара торган репертуарына әйләнде.

2 нче слайд: танылган җырлар исемлеге:

“Туган җирем – Татарстан”( А. Ключарев көе)

“Китмә сандугач”( Р. Яхин көе)

“Менергә иде Урал тауларына”(М.Мозафаров көе)

“Үз илемдә”(С.Садыйкова көе)

“Зәңгәр төймә”(халык көе)

“Күл буена килсәң иде”(З. Гыйбадулин көе)

“Кичегеп килгән мәхәббәт”(Б. Гайсин көе)

“Кояш гомере” (Ф. Әхмәдиев көе)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина көе)

“Туган авылым урамы” (Г. Сәйфуллин көе)

2 нче укучы. Шагыйрәнең шушы һәм тагын бик күп җырлары татар җыр сәнгатенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итә. Гөлшат Зәйнашева иң популяр җырлары тупланган “Илле җыр” исемле китабы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Укытучы. Әлеге югары премиягә лаек булган әдәбият, сәнгәть әһелләреннән тагын кемнәрне беләсез? (Укучылар җавап бирә.)

3 нче укучы. Гөлшат Зәйнашева иҗатына Татарстанның халык язучы Гариф Ахунов менә нинди бәя бирә (3 нче слайд) “Гөлшат Зәйнашева, нигездә, җыр иҗат итүче автор буларак танылды һәм шул жанрда язучылар берлегенә кабул ителде. Аның халык үз җыры итеп кабул иткән “Менергә иде Урал тауларына”, “Китмә, сандугач” кебек рухи бай, романтик җыр текстлары дистәләп. Сүзләренә тәңгәл килә торган киң колачлы музыка

белән кушылу сәбәпле, халыкның һәм заманның таләбен канәгатьләндереп , бу җырлар зур дөньяга чыгып киттеләр"

(Язмада "Китмә, сандугач" җырыннан өзек яңгырый)

Укытучы. Әйдәгез, укучылар, хәзер "Чыгам Идел буйларына" дигән җырны тыңлап китик әле. (Җыр аудиоязмада яңгырый.)

- Укучылар, ничек уйлыйсыз: лирик герой нинди хисләр кичерә?

- Лирик герой сагыну хисе кичерә. Гайшыйк кешенең сөйгәнен өзелеп көтүе, аның табигатькә мөрәҗәгате тасвирлана. Бу җырга күренекле язучыбыз Шәйхи Маннур менә нинди бәя бирә (4 нче слайд): "Чыгам Идел буйларына" җыры матур язылган, монда йөрәк җылысы да, яшь кешенең үз сөйләгәнен сагынып көтүе дә, гашыйк кешенең табигәтькә мөрәҗәгәть итүе дә – һәммәсе дә бар. Моны чын шигырь итеп тә укып була...

Җыр да, шигырь шикелле үк, әнә шундый эчке мәгънәләргә бай булырга тиеш".

Укытучы. Укучылар, Гөлшат Зәйнашева нindirәк темаларны яктырткан соң? Мин сезгә өй эше итеп шагыйрәнең шигарьләрне анализлап, тематикасын билгеләргә кушкан идем. Әйдәгез, төркемнәргә буленик. 1 нче төркем туган якка багышланган шигырьләрен анализлар, 2 нче төркем мәхәббәт темасын яктыртыр, 3 нче төркем авторның төрле күренекле шәхесләргә багышланган җырларына тукталыр. Хәзер сезне 1 нче төркемгә бирәбез, рәхим итегез.

(Х сыйныф укучысы И. Мәҗитовның Г. Зәйнашева сүзләренә язган "Кыйтырмын" җырын башкара.)

Әңгәмә:

- Укучылар, автор нинди хисләр кичерә?

- Туган авылыннан аерылып киткән лирик герой сагышлана, юксына.

- Моны автор нинди чагыштырулар белән бирә?

- Үзен тау башында ялгыз калган тургай белән чагыштыра, "Чит җирләрдә озак йөри алмам, кайтырмын мин туган ягыма", - ди лирик герой.

- Укучылар, туган як ни өчен газиз, кадерле соң ул?

- Туган якта – эти-эниең, туганнарың. Туган ягыңда син үзеңне чын хуҗа итеп тоясың. Аның хәттә һавасы да дәва бирә.

- Авторның туган якка багышланган тагын нинди җырларын беләсез?

(Укучылар авторның туган якка багышлап язылган җырларын санап үтәләр.)

5 нче слайд:

"Яшел үзәнлек" (А.Хөсәенев көе)

"Хәерле юл" (Ш. Капкаев көе)

"Шундый безнең туган як" (А.Фәйзрахманов көе)

Укытучы. Димәк Гөлшат Зәйнашева үзенең иҗатында туган як темасына зур урын биргән.

6 нче слайд:

Ничек үтәр иде гомер

Булмаса шул мәхәббәт?

Кешене кеше итүче

Мәхәббәткә мең рәхмәт! (Г. Зөйнашева)

Аңлавыбызча, мәхәббәт темасына күчәбез. 2 нче төркем мәхәббәт темасын яктырткан җырларын әзерләргә тиеш иде. Сүз сезгә.

( 2 нче төркем Г. Зәйнашева мәхәббәт темасына язылган җырларыннан попурри төзеп килгән. Язмада һәр җырның берәр куплеты яңгырый. Укучылар җырның исемен әйтергә һәм әсәрнең төп идеясен ачарга тиешләр.)

“Син кемнең сандугачы” (А.Шакиров көе)

“Мәхәббәтең алда эле” (Р.Валиев көе)

“Син икәнсең” (Г. Сәйфуллин көе)

“Өй артында гөлбакча” (Р.Курамшин көе)

“Мин бит кара карлыгач” (Ш. Тимербулатов көе)

“Аерылмагыз” (Ч. Зиннәтуллина көе)

- Укучылар җыеп әйткәндә, автор мәхәббәт тойгысын ничек бәяли?

- Мәхәббәт, тигезлек, сөю – кешене бәхетле итүче төшенчәләр. Гашыйк булган һәм ярата, яратыла алган кеше генә чын мәгънәсендә бәхетле була ала, ди ул.

- Әйе, укучылар, чыннан да, Гөлшат Зәйнашева үзенең җырлары белән җаннарны иркәли, күңелләргә дәрт бирә. Аның иҗатын Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми дә югары бәяли. 7 нче слайд: “Гөлшат Зәйнашева җырларының сихри бер үзенчәлеге, күңелне яулый торган көче бар. Аларга гомумкешелек тойгылары салынган. Сәнгәтьнең бөтен көче дә шунда түгелме соң?”

(Сүз 3 нче төркемгә бирелә. Укучылар Г. Зәйнашеваның төрле күренекле шәхесләргә багышлап язган җырларын туплап килергә тиеш иде.)

Укучы. Гөлшат Зәйнашеваның төрле күренекле шәхесләргә багышлап язган җырлары бик күп. Без аларның берничәсен тыңлап китәрбез.

(Дискта Х. Тимергалиева башкаруында авторның мохсус аңа атап язган “Ак болан” җыры яңгырый.)

- Укучылар, автор ни әйтергә тели?

- Автор хәтта горур лирик геройның да мәххәббәт алдында көчсез икәнен күрсәтә.

- Ә хәзер Хәйдәр Бигичевка багышланган “Хәйдәр җыры”н танылган җырчыбызның үз башкаруында тыңлап китик

(Дискта Х. Бигичев башкаруында “Хәйдәр җыры” яңгырый.)

- Гөлшат Зәйнашева Хәйдәр Бигичев иҗатына соклануын шундый матур итеп сүрәтләгән. Хәйдәр Бигичевның йөрәгеннән ургылып чыккан моңы авторны әсир иткән.

Менә, укучылар, без сезнең белән сөекле шагыйрәбез, популяр җырлар авторы Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына кыскача күзәтү ясадык. Чыннан да, Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты сокланырлык. Ул татар халкына нинди зур, үлемсез мирас калдырып китте.

Шулай да безгә аның сүзләренә язылган бер җыр, балачагыбыздан аеруча якын, кадерле, иң яраткан җырларыбызның берсе булып, күңелебездә саклана. Ул нинди җыр? (“Кояш гомере” яки “Җырлыйм әнием турында”)

Ни өчен бу җырны күпләр яратып кабул итте һәм яратып җырлый, дип уйлыйсыз? (Ул безнең өчен иң кадерле булган кеше – энилəргә багышланган.)

Әйдәгез, җырны бергәләп башкарыйк. (Күмәк җыр башкарала.)

Кичәбезне язучы Роза Хафизованың сүзләре белән йомгаклыйбыз. 8 нче слайд: “Гөлшат Зәйнашева популяр җырлары белән үзенә һәйкәл куйды”.

(Язмада әкрен генә Мәсгут Имашевның Гөлшат Зәйнашева сүзләренә иҗат иткән “Әллә кемне күңел сагына” җырының соңгы куплеты яңгырый.)

## Гөлшат Зәйнәшева әсәрләре аша балаларда табигатькә мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Бәдертдинова Илсөяр Изаил кызы

Фазуллина Гөлнар Изаил кызы,

Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат: Балаларны туган якның табигатен күрә белергә өйрәтү: киң таралган экологик проблемаларның кайберләре белән таныштыру: табигатькә, барлык тереклек ияләренә хөрмәт, мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: дәреслек, табигать турында стендлар, рәсемнәр, фотолар, магнитофон, кассета язмасында Гөлшат Зәйнәшова шигырьләре,”Прогулки по лесу” җәнлекләр тавышы, дару үләннәре, гөмбә рәсемнәре:төсле кәгазь, кайчы, клей, өй макеты: тест” Безнең урманда”.

Дәрес төре: катнаш (уку+ әйләнә - тирә+ хезмәт)

Дәрес барышы.

I. Оештыру моменты.

II. Музейга сәяхәт.” Туган як табигате”.

Табигать нәрсәләрдә чагыла?( рәсемнәрдә, картиналарда)

Карагыз әле, безнең туган ягыбызның табигате нинди матур икән бит!(Картиналар, рәсем- фотолар карау)

III. Дәрескә кайту.

Табигать турында сөйләшүне дәвам итәбез. Магнитофон язмасыннан «Табигать тиңсез хәзинә» шигырен тыңлау:
Табигать ул – тиңсез хәзинә,
Шаулы урман, челтер чишмә дә.
Яшел болын да ул, зәңгәр күк тә,
Сакла аны, аңа син тимә!
Табигать ул – тиңсез хәзинә,
Авылның ул хәтфә урамы.
Йомшак җилнең биттән иркәләве,
Алтын көзнең яфрак бураны.
Очкан күбәләк тә, сайрар кош та,
Кырмыска ул, шөпшә, ярканат.
Агач утырт, гөлләр үстер,
Табигатьне, дустым, син сакла!

Укучылар, без бүген сезнең белән табигать һәм аны саклау турында, үзебезнең туган як урманнары турында сөйләшербез.

1. Урман этажлары. (Тактага этажлап агачлар, куаклар, җәнлекләр, үләннәрябыштырыла) Болар яруслар дип атала (Укытучы сөйләме).

Без сезнең белән урманга экскурсиягә барган идек, (Карточка күрсәтелә). Шунда без сезнең белән урманның төзелешен караган идек инде (Укучылар фикере тыңланыла).

Диалог “Урманга бару”. (Сәхнәләштерү).

(“Прогулка по лесу” кассетасы куела).

1 нче төркемгә – дару үләннәре җыю. (Укучылар дару үләннәре турында сөйлиләр. Алар үлән җыйганда төлке чыгып аларга дөрес җыю һәм киптерү ысулларын аңлата, киңәшләр бирә.)

Төлке: Балалар, урманда нәрсәләр эшләргә ярамый?

1 нче укучы:

- чүп калдырырга

- агачларны сындырырга

-кошлар оясын туздырырга

- җиләк-гөмбәләрне таптарга

-белмәгән гөмбәләрне җыярга

-кечкенә җәнлекләрне куркытырга, кырмыска ояларын туздырырга

-ут, учак яндырырга.

Әйе, укучылар, ут белән уйнарга ярамый. Безгә 295ух акта урманчы абыйларыбыз да кисәтте.

5. Урман хайваннары. (Магнитофон язмасында җәнлек тавышлары).

Бөтен урман – агачларның очыннан алып җиргә-хайваннар белән тулган. Үз тирәбездәге, үзебезнең урмандагы хайваннар турында әйтик әле. (Укучылар фикере тыңланыла. Алар сөйләгәндә укытучы тактага урман җәнлекләрен беркетә)

6. Урманда ял итәбез.

Бергәләшеп җыйналып
Без барабыз урманга
Хәерле юл теләп безгә
Күктә кояш елмая.
Канатларын җилпи-җилпи
Күбәләкләр очалар.
Ал, кызыл, сары,зәңгәр,
Нинди матурлар алар!
Яшел урман аланында
Без чәчәкләр җыябыз.
Ап-ак ромашкалар өзеп,
Такыялар үрәбез.
Ак каеннар төпләреннән
Без гөмбәләр эзләдек.
Агач башында уйнаган
Тиеннәрне күзләдек.
Матур чәчәкләр кочып,
Гөмбәле кәрзин тотып
Без кайтабыз урманнан
Бераз гына арылган.

7. Урманда гөмбәләр татшалыгы.

(«Гөмбә җыю» сәхнәләштерелә. Алар янына аю чыгып укучыларга киңәшләр бирә).

Укучылар, урманчы абыегыз «Безнең урманда» дигән тест җибәргән. Сезнең туган ягыбыз урманнарын беләсезме яки юкмы икәнлеген беләсе килә. (Тест эшләү һәм тикшерү).

8. «Әче тәмләткечләр белән рагу» пешерү.

Укучылар, без тәмле әйберләрне бик яратабыз. Бигрәк тә әниләр пешереп бирсә. Ә бүген без сезнең белән үзебез пешереп карыйк әле. (Таблицалар белән эш). Молодцы, ничек тиз җөмләләр төзедек һәм тәмле рагу пешердек.

Укучылар, тәмле итеп ашадык, ә хәзер Гөлшат Зәйнашеваның “Гөлләр иле” җырын җырлыйбыз.

Ул – йөзләгән җырлары белән халык арасында киң популярлык казанган шагыйрә. Туган җиргә мәхәббәт, Ватанга бирелгәнлек, халкыбыз язмышы турында кайгырту, намуслы хезмәткә өндәү, кешелек дөньясы кабул иткән югары әхлакка чакыру – аның җырларының төп сыйфатлары булып тора, шуңа күрә кайларга гына барсак та, аның җырларын тыңларга, башкарырга яратабыз.

7.Дәресне йомгаклау.

Укучылар, дәресне Туган илебезне, табигатебезне саклагыз! Табигать язмышы безнең язмыш! - дигән сүзләр белән тәмамлыйбыз.

Туган ил! Туган җир! Туган авыл! Туган туфрак! Кеше өчен иң газиз, иң кадерле, иң кыйммәтле, иң мәгънәле сүзләр! Алар һәркемнең йөрәгендә яши. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезе урнашкан туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас матурлыгы, хәзинәсе бар: сокланып туймаслык тугайлары, челтерәп аккан йөгерек чишмә буйлары, соры камышлар белән капланган түгәрәк сазлыклары, балыклы күлләре, куе әрәмәләр белән уратып алган елга үзәннәре, сары гәрәбә бодай үсеп утырган иген кырлары, җырчы кошлар сайрап торган яшел урманнары, сый-нигъмәтләр белән туендыручы кара туфрагы, күкрәгеңне тутырып сулар һавасы, аллы-гөлле чәчәкле болыннары. Кая гына барсаң да, туган якның гүзәллеген, газизлеген бернәрсә дә алыштыра алмый. Туган авылыңның һәр сукмагы, һәр агачы, һәр үләне, аның барча кешеләре күңелгә ифрат та якын. Тәпиләп киткән, беренче тапкыр әттә-әннә дип әйтергә өйрәнгән вакыттан ук күңел түренә туган телебез аша кереп урнашкан ул кадерле төшенчәләр.

Табигать – тиңсез хәзинә. Ә Кеше – табигатьнең бер өлеше. Кеше һәм табигать – бербөтен. Кеше һәм табигать – ул тормыш, ул яшәеш

## Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты

(педагогик проект)

Халитова Наилә Әмирҗан кызы, Горшенина Марина Александр кызы,

Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 3 нче "Алёнушка" балалар бакчасы,

Сарман муниципаль районы

### Кереш

Татарстан Республикасының һәр кечкенә почмагының үз үзенчәлекләре бар, үз якташлары, алар белән горурланалар. Алар турындагы истәлекне без киләчәк буыннар өчен саклап кала алабыз һәм сакларга тиеш. Безнең Сарман районында да бик күп танылган

кешеләр бар. Аларның берсе – танылган татар шагыйрәсе, Г.Тукай премиясе лауреаты – Гөлшат Хисамовна Зәйнашева.

Гөлшат Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Сарман районы Иске Теләнче авылында туа. Г. Х. Зәйнашеваның әдәби әсәрләре беренче тапкыр XX гасырның 50 нче еллар ахырында дөнья күрде. Аның шигырьләре, җырлары, эстрада өчен әсәрләре һәм беренче пьесалары еш кына татар периодик матбугатында басылып чыга. Шигырьләренең үзенчәлеге шунда: алар мәхәббәт, кече Ватанына тугрылык хисләре белән сугарылган.

Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләрен 4 циклга бүлеп була: балалар һәм табигать, саннарны өйрәнү, Салават күпере төсләре белән танышу, шулай ук Яңа ел җырлары. Барлык текстлар да ачык һәм балаларга аңлаешлы, әдәби телнең җанлы образы, баланың эчке дөньясын аңлау белән җәлеп итә. Аның шигырьләре аша балалар ихтирам, өлкәннәргә хөрмәт, игелек һәм ярдәмчел булырга өйрәнә. Балаларда хезмәт сөючәнлек, намуслылык, кыюлык, тыйнаклык, җаваплылык кебек кыйммәтле сыйфатлар формалаштыруга ярдәм итә, мәктәпкә һәм белемгә кызыксыну уята.

Безнең проектның нигезендә танып-белү һәм иҗади эшчәнлек ята. Безнең тәрбияләнүчеләребезнең Бөек язычуларны белүләрен телибез.

Проектның максаты: шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның тормыш һәм иҗатын өйрәнү, балаларда якташ шагыйрәнең иҗат мирасына кызыксыну уяту.

Проектның бурычлары:

1. Тәрбияләнүчеләрнең күзаллауларын киңәйтү, Кече Ватан тарихы, аның күренекле кешеләре турында белемнәрне тулыландыру.

2. Балалар сөйләмен үстерү, сүзлек запасын баету; ирекле фикер йөртергә, фантазияләргә өйрәтү.

3. Шәхеснең әхлакый сыйфатлары: туган як тарихына һәм кешеләргә карата хөрмәт, якташларың өчен горурлык хисе тәрбияләү.

4. Проектны тормышка ашыру процессында ата-аналар белән хезмәттәшлекне оештыру.

Проектта катнашучылар: мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, балаларны татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары.

Балаларның яше: 6-7 яшь.

Мәгариф өлкәләрен интеграцияләү: "Танып-белү үсеше», "Сөйләм үсеше», «Социаль-коммуникатив үсеш», «Сәнгать-эстетик үсеш», «Физик үсеш»

Проектның вакыты: кыска вакытлы (3 атна).

Проектның төре: танып-белү һәм иҗади.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Проект эшчәнлеген оештыру һәм планлаштыру 3 юнәлеш буенча алып барыла:

- балалар белән эшләү;
- тәрбиячеләр белән эшләү;
- ата-аналар белән эшләү.

Проектның этаплары:
1 этап әзерлек:
- теманы сайлау, максатлар һәм бурычлар кую; әдәбият эзләү;

- танып-белү һәм методик әдәбиятны өйрәнү;
- музыкаль әсәрләр сайлау;
- интернет-ресурслар мәгълүматы куллану;
- күрсәтмә материал әзерләү.

Төп этап:

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә фән-үсеш тирәлеген камилләштерү (китап почмаклары, мәгълүмати стендлар);
- шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу буенча балалар белән белем бирү эшчәнлеге үткәрү;
-әңгәмә;
- музыкаль әсәрләрне тыңлау;
- якташыбызның әсәрләрен уку;
-балалар поселок китапханәсенең уку залында булу;
- рәсемнәр һәм иллюстрацияләр карау;
- дидактик уеннар;
- ата-аналар белән эшләү.

3 нче йомгаклау этабы:

-балалар бакчасы хезмәткәрләре өчен тәҗрибә тәкъдим итү;
- проект эшчәнлеген рәсмиләштерү;
- нәтиҗәләр ясау.

**Проект эшчәнлеге планы**

| **Катнашулар** | **Эш формасы** | **Вакыты** |
|---|---|---|
| Балалар белән эш | 1. Балалар белән шагыйрә- Гөлшат Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты белән таныштыру, әңгәмә.<br>2. Кичке укулар: "Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләре буенча сәяхәт».<br>3. Балалар белән бистәбебезнең китапханәсендә уку залында булу.<br>4. Китап күргәзмәсе «Зәйнашева – балаларга».<br>5. Г. Зәйнашева әсәрләре буенча китаплар, иллюстрацияләр карау<br>6. Г. Зәйнашева шигырьләренә музыкаль әсәрләр тыңлау.<br>7. Г. Зәйнашева шигырьләре буенча сәнгать иҗаты (әвәләү, кисеп ябыштыру, рәсем ясау)<br>8. “Бер атнада ничә көн”, “Шырпы уенчык түгел” шигырьләрен сәхнәләштерү. | Гыйнвар |
| Тәрбиячеләр белән эш | 1. Проектның максатлары һәм бурычлары турында фикер алышу; проектны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча кызыксыну формалаштыру.<br>2. Балаларны язучының иҗатына, туган як иҗатына җәлеп итү буенча методик материаллар, рекомендацияләр эшләү һәм туплау.<br>3. Тәрбиячеләр өчен консульция: "Балаларны якташларыбызның тормышы һәм иҗаты белән ничек таныштырырга". | Гыйнвар |
| Ата-аналар белән эш | 1. Ата-аналар арасында китап уку буенча анкета тутыру.<br>2. Күчмә папка: "Укырга киңәш итәбез". | Гыйнвар |

Нәтиҗә

Әлеге проект нигезендә нәтиҗәләр ясарга мөмкин: без куйган максатыбызга ирештек, без балаларның күзаллауларын киңәйттек, якташыбызның иҗаты белән таныштык, кече Ватаныбызны күбрәк яратырга һәм кадерен белә башладык.

Алга таба эш перспективалары:

1. Кече Ватаныбыз шагыйрьләренең иҗади мирасын өйрәнүне дәвам итәргә.

**Кушымта**

Балаларның иҗади эшләре

“Кыш килде” шигыренә рәсем




«Бияләй түгел, перчаткы» шигыренә рәсем



“Песня Снегурочки” шигыренә эшчәнлек



“Помидор” шигыренә эшчәнлек



"Безнең песи" шигыренә рәсем



"Шырпы уенчык түгел" шигыренә рәсем



**Күңелле шигырьләр иртәсе**

(6 -7 яшьлек балалар өчен сценарий)

Дәүләтҗанова Регина Дамир кызы,

Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге

6 нчы "Теремкәй" балалар бакчасы, Сарман муниципаль районы

Максат: Балаларны Гөлшат Зәйнашева шигырьләре белән таныштыру. Якташ шагыйрә иҗатына кызыксынучанлык тәрбияләү. Гөлшат Зәйнашева иҗатына ихтирам, кызыксыну уяту.

Җиһазлау: Гөлшат Зәйнашева китапларыннан күргәзмә, шигырьләре буенча ясалган рәсемнәр, җыр язмалары, презентация.

Залда өйнең эчке бизәлеше. Балалар урындыкларга кереп утыралар.

Тәрбияче: Кадерле дусларыбыз. Без сезнең белән «Күңелле шигырьләр» иртәсенә җыелдык.

“Туган ягым — гөлләр иле” җыры яңгырый.

Тәрбияче: Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Без бүген шушы шигырь юллары авторы, шагыйрә Гөлшат Зәйнашева Хисам кызына багышланган «Күңелле шигырьләр иртәсе» исемле күңел ачу кичәсенә җыелдык.

(Салмак көй астында залга әби килеп керә. Кулында кызыл төенчек).

Әби: Улым, алтыным, әйдә тизрәк җыен, абыеңнарга коймаклар илтеп кайтыйк.

Малай Нияз: И әбекәй, әбекәем. Безгә бит кунаклар килде, без бәйрәм ясарга булдык.

Әби: И-и-и. Күрмичә дә торам икән. Исәнмесез, балакайларым.

Балакайлар: Исәнме, әбекәй.

Малай Нияз: Әбием, әйдә син дә безнең белән бәйрәм ит.

Әби: Рәхмәт, балам. Мин алайса йон эрли торырмын, сезне тыңлап утырырмын.

(Әби йон эрләргә утыра).

Азалия: «Бөрлегән» (Гөлшат Зәйнашева)

Артур: «Кыш килде (Гөлшат Зәйнашева)

Тәрбияче: Балалар, сезгә саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен Гөлшат Зәйнашева саннар турында шигырьләр язган. Әйдәгез әле балалар шигырне сөйләп күрсәтик.

Әминә:
Саннар саный башласак,
Иң беренче — бер саны.
Мактап әйткән кебек, без
«Беренче» дибез аны...
Бер саны ул бер генә,
Әни дә бит бер генә,
«Әнием — бергенәм» дип
Кадерлибез гел генә.
Дамир :
Табигатьтә бөтен нәрсә
Ике төрле килгән безгә.

Бер чорлары кара булса,
Икенчеләре ап-ак төстә.
Регина:
Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле өчпочмакларны
Әни йөри пешереп.
Айдар:
Түп-түгәрәк җир шары,
Аның да бар дүрт ягы.
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы.
Эльза:
Әнкәй пешерә ял көнне безгә
Бишбармак бишебезгә:
Әткәй, әнкәй, абыйга,
Сеңелем белән миңа.

Тәрбияче: Булдырдыгыз балалар. Әйдәгез әле хәзер, Гөлшат Зәйнашеваның бик матур җырын җырлап күрсәтик.

Балалар түгәрәккә басып, хәрәкәтләр ясый- ясый “Бөрлегәнем” җырын башкаралар.

Тәрбияче: Булдырдыгыз, балалар. Әйдәгез, бер уйнап алыйк: «Чума үрдәк, чума каз».

Тәрбияче: Ә хәзер Гөлшат Зәйнашева язган төсләр турында шигырьләрне сөйлибез.
Самира:
Җырлый-җырлый җиләк җыям,
Кызыл каен җиләген.
Кып-кызыл җиләкләр белән
Тула инде чиләгем!..
Энже:
Алтын төсле матур яфрак,
Җәйдән көзгә бүләктер,
Көзләр мул уңышлы булсын
Дигән изге теләктер.
Һәр агач моңаеп кына
Кызгылт-сары яфрак коя.
Бала чага, шатланышып,
Кызгылт-сары яфрак җыя!
Айдар:
Сары чәчәктән чәчәккә
Оча сары күбәләк.
Сары күбәләк шатлана,
Сары күбәләк шатлана,
Чәчәк белән бергәләп.
Шамил:
Язлар җитте, бар табигать:
«Без яшәрәбез,» - диде.
Урман, болыннар, тугайлар
Яшел киемен киде.
Ильяс:
Күк йөзе күксел томан,
Күксел болытлар сыман.

Күксел диңгезләр дәшә,
Еракта уйный рәшә.
Сәлим:
Зәңгәр елга өсләреннән
Агыла зәңгәр болыт.
Әллә шуңа бөтен нәрсә
Күренә зәңгәр булып.
Алина:
Шәмәхә төс – матур төс ул,
Шәмәхә төс яратам.
Урманга барсам шәмәхә
Чәчәкләр җыеп кайтам,
Чәчәкләр җыеп кайтам.
Әби: Булдырасыз, балалар.
Мин бер табышмак әйтәм,
Әткәм-әнкәмнән калган.
Әгәр җавабын тапсагыз,
Уеннар итәр дәвам.
«Кечкенә генә бер әби
Йөгерә-йөгерә йон җыяр».
Балалар: Орчык!

Әби: Бик дөрес. Һәрбер эшнең җае бар, ботканың да мае бар, диләр. Әйдәгез түгәрәк ясап утырыгыз. Бу орчыкның ике ягы бар: бер яктан – җеп эрләү, икенче яктан – күңел ачу.

Орчык башы кемгә карап туктаса, шул кеше берәр һөнәр күрсәтә. Әйләндерәм орчыкны. ( Орчык кемдә туктый, шул балага җәза бирелә).

Булдырдыгыз, балалар.
( Балалар шагыйрьнең "Тиктормас", "Конфет" шигырьләрен сөйлиләр).
(Бүлмәгә елап Белмәмеш керә).

Белмәмеш: Мин бернәрсә дә өйрәнә алмыйм, булдыра алмыйм, мәктәпкә бармыйм.

Тәрбияче: Борчылма, Белмәмеш, без сиңа булышырбыз, безнең янда кал, балалар белән уйнарсың, өйрәнерсең, шигырьләрен тыңларсың.

( Балалар шагыйрьнең "Әбиемне яратам", "Сагыз" шигырьләрен сөйлиләр)

Белмәмеш: Искә төште, искә төште.
Мин бит бер уен беләм.
Уеннар бит, балалар,
Витамин кебек алар.
Күңелләрне үстерче,
Йөрәкләргә көч бирүче.
Әйдәгез «Зәңгәр чәчәк» уенын уйнап алыйк.

Тәрбияче: Белмәмеш, Гөлшат Зәйнашеваның күңел серләре сыйган шигырьләрен безнең тәрбиячеләр дә үз итteләр.

Регина Дамировна: «Ак күгәрчен» шигыреннән өзек.

Дания Фатиховна: «Китмә, сандугач»

«Куш кулым» уены.

Тәрбияче: Ә хәзер безнең балалар, Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган *“Кояш гомере”* җыры башкаралар.

Тәрбияче: Булдырдыгыз. Белмәмеш, сиңа бездә ошадымы? Безнең балалар нинди матур шигырьләр сөйләделәр, уеннар уйнадылар.

Белмәмеш: Рәхмәт, балалар, сез бик акыллы, булган икәнсез.Тырышкан табар – ташка кадак кагар. Сез миңа бик булыштыгыз. Хәзер инде мәктәпкә ашыгыйм. Сау булыгыз.

Әби: Ә мин сезне, балакайларым, тәмле коймаклар белән сыйлыйм. Акыллы, тәртипле, тәмле телле булып үсегез, әти-әниегезгә игелекле балалар булыгыз.

Балалар: Рәхмәт, әбекәй, авырма, сызланма.

Күңел ачу кичәсе Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган җырны тыңлау белән тәмамлана.

**PIRLS халыкара тикшеренү критерийларын кулланып**

**« Уку сыйфатын тикшерү һәм текстны аңлау»**

7-8 нче сыйныф укучылары на тикшерү эше

Осипова Людмила Иван кызы,

2 нче урта гомуми белем мәктәбе, Лениногорск муниципаль районы

PIRLS уку һәм грамоталылык төшенчәләрен берләштерә, укырга сәләтле дигәнне аңлата. Бу төшенчә үз эченә нәрсә укыганны аңлауны һәм шуны шәхси һәм иҗтимагый максатларны тормышка ашыру өчен корал буларак файдалануны күздә тота. PIRLS тесты түбәндәгеләрне үлчәүгә һәм бәяләргә юнәлтелгән:

-грамоталылыкны үстерү һәм уку күнекмәләрен булдыру;

-мәгълүмат алу һәм аны куллана белү.

Әлеге максатлар - укуның ике төп максаты булып санала.

PIRLS буенча бәяләнә торган дүрт төрдәге күнекмәләр.

Әдәби һәм мәгълүмати (фәнни-популяр) текстларны укырга өйрәнгәндә китап укучылар осталыгының(умения) дүрт төркеме бәяләнә:

-ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны табу;

-нәтиҗәләрне формалаштыру;

-интерпретация һәм гомумиләштерү;

-текст эчтәлеген, тел үзенчәлекләрен һәм структурасын анализлау.

Эшнең максаты:

1.7-8 нче сыйныф укучыларында әдәби текстның эчтәлеген аңлап, уку күнекмәләрен билгеләү.

2. Эш эчтәлеге программа таләпләренә: төп белем бирү мәктәбенең 7-8 нче сыйныф укучыларының белемнәренә, осталыкларына һәм күнекмәләренә туры килә. Аңлап укуларын тикшерү дәрәҗәсе үз эченә түбәндәгеләрне параметрларны күзаллый:

1. Фактагы мәгълүматны, ягъни ачык рәвештә бирелгән мәгълүматны алу дәрәҗәсен тикшерү. Укучының текстта сүзнең нәрсә турында баруын аңлауы ачыклана. 2. Тексттагы ачыктан-ачык булмаган мәгълүматны аңлау дәрәҗәсен тикшерү, ачык һәм яшерен мәгълүмат нигезендә нәтиҗәләр ясый белүне тикшерү. Баланың текстта әйтелгәнне аңлый белүе тикшерелә 3. Тел чараларын, текст элементларын анализлауның уңышлылык

дәрәҗәсен тикшерү. Баланың текстта күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләр, күп мәгънәле сүзләр, образлы гыйбарәләр, фразеологик әйләнешләрне аңлау, текстның мәгънәле өлешләренең эзлеклелеген, жанр үзенчәлекләрен аңлавы тикшерелә. 4. Концептуаль мәгълүматны алу дәрәҗәсен тикшерү, тексттан алынган мәгълүматны интерпретлау һәм гомумиләштерү.Текстның гомуми мәгънәсен аңлый белү, текстның төп фикерен аңлый белү тикшерелә.

Эшнең структурасы.

1. Сыйныфның һәр укучысына эчтән мөстәкыйль рәвештә уку өчен текст. 2. Бу текстка егерме бер бирем. Әдәби текст тәкъдим ителә. Текстка караган барлык биремнәрне, аларның билгеләнешенә карап, дүрт төркемгә бүләргә мөмкин:

1 нче төркем биремнәр укылган текст эчтәлеген гомуми аңлауларын тикшерүгә, ачык рәвештә бирелгән мәгълүматны таба белүгә юнәлдерелгән.

2 нче төркем биремнәр тексттан ачык булмаган рәвештә бирелгән мәгълүматны алу, текст укылганнан соң катлаулы булмаган нәтиҗәләр формалаштыра белүне тикшерүгә юнәлдерелгән.

3 нче төркем биремнәр текстта кулланылган тел чараларын аңлауны тикшерү, текстның мәгънәле өлешләренең эзлеклелеген, жанр үзенчәлекләрен аңлауны тикшерү өчен юнәлдерелгән. 4 нче төркем биремнәр текстның гомуми мәгънәсен аңлый белүне тикшерү, автор фикерен билгеләү, санап үтелгән кайбер тәкъдимнәрдән текстның төп фикерен җиткерүче тәкъдимне сайлап алуны күздә тота.

Алда әйтелгән төркемнәр нигезендә биремнәрне бүлү:

| Биремнәрнең төркеме | Биремнәрнең № | Биремнәрнең гомуми саны |
|---|---|---|
| 1нче төркем биремнәр | 2,4,6,7,8,10, 13 | 7 |
| 2нче төркем биремнәр | 1, 3,5 ,11,12,16 | 6 |
| 3нче төркем биремнәр | 18,19,20 | 3 |
| 4нче төркем биремнәр | 9,14,15,17,21 | 5 |

Тикшерү эшендә өч катлаулылыктагы: база дәрәҗәсе, катлаулы, югары дәрәҗәдәге биремнәр бүлеп бирелгән.

| Катлаулылык дәрәҗәсе | Биремнәрнең № | Биремнәрнең гомуми саны |
|---|---|---|
| база дәрәҗәсе | 2,4, 6,7,8,10,11,13,16,21 | 10 |
| катлаулы | 1, 3,5,9, 12,14, 15,20 | 8 |
| катлаулы (югары) | 17, 18, 19 | 3 |

Тикшерү эшендә түбәндәге төрдәге биремнәр кулланыла: дүрт тәкъдим ителгән җаваптан дөрес җавап сайлап алу биремнәре (21 дән 15 - е); җөмләләр нумерациясе буенча бирем. Укучылар, план пунктларының дөрес эзлеклелеген билгеләп, саннарны 1дән 5кә кадәр җиткерергә тиеш; кыскача һәм тулы җаваплы биремнәр. (21 дән 5 - е)

Эшне башкару вакыты.

Эшне башкаруга бер дәрес бирелә. (40 минут). Укучылар текст язылган бит һәм махсус бланклар алалар, аларда текстка биремнәр язылган. Укучылар әлеге бланкларда эшлиләр, дөрес җаваплы хәрефне түгәрәккә алалар яки тамгалыйлар (+).

5. Биремнәр һәм эшләрне бәяләү. Тикшерү эше балларда бәяләнә.

| № | Биремнең № | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | 1 | Дөрес җавап өчен –2 балл<br>Өлешчә дөрес җавап -1 балл |
| 2 | 2 | Дөрес җавап өчен –1 балл |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | 3 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 4 | 4 | Дөрес җавап өчен –2 балл<br>Өлешчә дөрес җавап -1 балл. |
| 5 | 5 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 6 | 6 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 7 | 7 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 8 | 8 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 9 | 9 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 10 | 10 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 11 | 11 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 12 | 12 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 13 | 13 | Дөрес җавап өчен –2 балл<br>Өлешчә дөрес җавап -1 балл |
| 14 | 14 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 15 | 15 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 16 | 16 | Дөрес җавап өчен –2 балл<br>Өлешчә дөрес җавап -1 балл |
| 17 | 17 | Һәр дөрес пункт өчен–1 балл<br>План тәртибе тулысы белән дөрес–5 балл |
| 18 | 18 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 19 | 19 | Дөрес җавап өчен –2 балл<br>Өлешчә дөрес җавап -1 балл |
| 20 | 20 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| 21 | 21 | Дөрес җавап өчен –1 балл |
| | | Максималь балл–30 |

Тикшерү эшләрен башкару сыйфатына гомуми бәя:

| **10 баллдан әз** | **11 дән 20 баллга кадәр** | **21дән до 30 баллга кадәр** |
|---|---|---|
| түбән дәрәҗә | уртача | югары дәрәҗә |

| **27 һәм аннан да күбрәк балл** | **21 дән 26 баллга хәтле** | **11 дән 20 баллга хәтле** | **10 баллдан да әзрәк** |
|---|---|---|---|
| билге «5» | билге «4» | билге «3» | билге «2» |

Текстка карата биремнәр

1.Тын елга буенда оя ясаучы кошлар ни өчен икенче урыннарга очып киттеләр? Исбатла.______________________________________________________________________

_

2.Вакыйгалар кайсы авыл булган урында бара?

А) Асылъяр

Б) Акъяр

В) Ак Кыя

Г)Аккүл

3. Ерак көньяклардан тагын кайсы кошлар очып килде?

1)аккошлар

2)тургайлар

3)сыерчыклар

4)торналар

4. Сулыкның ярларын кайчаннан башлап күзәтеп тордылар? Дөрес җавапларны күрсәт.

1) гөрләвекләр агып туктаганнан соң

2) яз башыннан

3) җәй башлану белән

4) гөрләвекләр ага башлаганчы
5. “Даими рәвештә алып барылды” дигәнне ничек аңлыйсың?
1) бертуктаусыз
2) вакыт-вакыт
3) ай саен
4) көн аралаш
6.Кошлар кайлардан очып кайталар?
1) төньяклардан
2) ерак көньяклардан
3) чит илләрдән
4) төрле җирләрдән
7. Тиешле урыннарны ничек тәртипкә китерделәр?
1) ком салып
2) балчык салып
3) таш салып
4) бетон салып
8. Акъяр тирәсендәге барлык йорт һәм каралты-куралар кая күчерелде?
1) яңа җиргә
2) чирәм җирләргә
3) шәһәр тирәсенә
4) урман янына
9. “Үзәк лабораториядә” дигәнне ничек аңлыйсың?
1) авылдагы лабораториядә
2) төп лабораториядә
3) шәһәрдәге лабораториядә
4) ерак лабораториядә
10. Үзәк лабораториядә нәрсә сынадылар?
1) су тизлеген
2) су агымын
3) су басымын
4) су күләмен
11. Кар сулары кайда тотылып калачак?
1) сусаклагычта
2) елгада
3) күлдә
4) чокырда
12. Елгаларда боз кузгалгач, беренче көннәрдә Тын елга нинди хәләттә иде?
1) элекке рәвешен шунда ук үзгәртте
2) тизлеген үзгәртте
3) ташып акты
4) элекке рәвешен үзгәртмәде
13. Гаять зур күл каян хасил булды? Дөрес җавапларны билгелә.
1) Кар сулары сусаклагычта тотылып калды.
2) Быел кар күп булды.
3) Резервуарлар шартлады.
4) Тотылган кар сулары күл хасил итте.
14. “Гаять зур” нәрсә дигәнне аңлата?
1) гаҗәп
2) уртача зурлыкта
3) бик зур
4) зурга охшаган
15.Күл нинди тизлек белән хасил булды?

1) уртача тизлек
2) шактый тиз
3) әкияттәге тизлек
4) бер көн эчендә

16. Акъяр кешеләре ни өчен моңсуландылар? Дөрес җавапларны күрсәт.
1) Яшәгән урыннарын су басты.
2) Урманнарны, болыннарны сагындылар.
3) Гомер сөргән урыннары су астында калды.
4) Шәһәргә күченеп китү ошамады.

17. План пунктларын дөрес тәртиптә урнаштыр.
1. Акъяр кешеләре моңсуланды.
2. Ташу сулары көтелгән куркыныч тудырмады.
3. Тын елга буе үзгәрде.
4. Тын елга урынында күл хасил булды.
5. Акъяр авылының урыны гына калды.

18. Кайсы җөмлә текстка исем була алыр иде?
1) Тиешле урыннарны кыш буе тәртипкә китерделәр.
2) Тын елга элекке рәвешен үзгәртмәде.
3) Тын елга буенда зур үзгәрешләр башланды.
4) Бозлар сусаклагычның югары башында утырып калдылар.

19. Текст нәрсә турында? Дөрес җавапларны күрсәт.
1) Туган якка яз килү турында.
2) Җирләрне яңарту, зур төзелешләр, үзгәрешләр турында.
3) Тын елгада боз китү күренеше турында.
4) Яңа авыллар төзеп, яңа җирләрдә тормыш башлау турында.

20. Бу әсәрне нинди җыентыкка керетер идең?
1) Әкиятләр
2) Мәсәлләр
3) Хикәяләр
4) Шигырьләр

21. Әсәрдәге “Ниндидер кодрәт белән” дигәнне ничек аңлыйсыз? Дөрес җавапларны күрсәтегез.
1)ниндидер зур көч белән
2)ниндидер кешеләр хезмәте белән
3)ниндидер ысуллар белән
4)зур көч куеп барлыкка килгән

Текст

## Тын елга буенда

Кызлар кебек көлеп яз килде... Элек-электән Тын елга буендагы карт усакларга, өянкеләргә оя ясый торган кара каргалар агачлары киселгән урыннарда очышып йөрделәр. Таныш агачларны күрмәгәч, ниндидер ямансу тавышлар белән кычкыра-кычкыра, икенче урыннарга очып киттеләр. Алардан соң килгән башка кошлар да кайчандыр бала чыгарган урыннарын таба алмадылар.

...Акъяр һәм тагы шул тирәдәге берничә авылның урыны гына калган, барлык йорт һәм каралты-куралар яңа җиргә күчерелгән иде инде. Сыерчыклар да, ерак көньяклардан безнең бу тарафларга килгәч, үз ояларын карап, нигезләре генә күңелсез утырып калган өйләр тирәсендә очышып йөрделәр.

Әле гөрләвекләр ага башлаганчы ук, булачак сулыкның ярларын, Никитин приказы буенча, гел карап, гел күзәтеп тордылар. Тиешле урыннарны кыш буе тәртипкә китерделәр, тирән җирләргә бетон салдылар. Яр буе корылмаларына тәүлек буе дежурлар куелды. Үзәк

лабораториядә су басымын сынау кебек эшләр дә даими рәвештә алып барылды. Кешеләр быелгы кар суларының сусаклагычта тотылып калачагын көздән ук беләләр иде. Әле елгаларда боз кузгалгач та, беренче көннәрдә Тын елга элекке рәвешен үзгәртмәде. Ләкин инде берничә көннән соң хәл бөтенләй үзгәрде. Ул гына түгел, гүяки әкияттәге тизлек белән гаять зур күл хасил булды. Яр буйларында кичен-иртәсен кешеләр кайнашты. «Ниндидер кодрәт белән» әле яңа гына пәйда булган «диңгез»не карарга хәтта тирә-як авыллардан да килә башладылар. Элекке Акъяр кешеләре кайчандыр үзләре гомер сөргән урыннарның су астында калуларын күргәч, бераз моңсуланып та алдылар. Ләкин аларга моңаеп йөрергә вакыт юк: яңа авылда, яңа күчкән җирләрендә бик хәтәр яңарту, төзү эшләре бара иде.

Баштарак байтакларны, йөзләгән километр ераклыктан ташу сулары агып килеп, сусаклагычта коточкыч боз таулары тыгылыр, хәтта буага да куркыныч тудырыр дигән уй борчыган иде. Әмма ул хәл булмады. Бозлар сусаклагычның югары башында утырып калдылар. Анда бер-берсеннән өзек-өзек аерылып торган зәңгәр-ак төстәге «таулар», карап туймаслык бер матурлык биреп, тирә-якны сихри төсләргә керттеләр. Ләкин алар кечерәйгәннән-кечерәя барды.

Сөббух Рафиковтан

**Гөлшат Зәйнашева иҗаты**

«Туган җирем – Татарстан» шигыре.

Гарипова Рүзилә Салихҗан кызы,

Ризаэддин Фәхреддин исемендәге 1нче гимназия, Әлмәт шәһәре

Дәреснең максаты:

1. Өйрәтү максаты: Гөлшат Зәйнашева “Туган җирем– Татарстан” шигырен анализлау; монологик, диалогик сөйләм телен үстерү.

2. Белем үстерү максаты: укучыларны үз фикерләрен дөрес, эзлекле әйтә белергә өйрәтү; әсәрдән иң мөһим фикерне аерып чыгару күнекмәләрен үстерү;

3.Тәрбияви: туган илгә карата укучыларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

Эш формалары: фронталь, индивидуаль, парларда, төркемнәрдә эш.

Планланлаштырылган нәтиҗәләр:

Предмет- Гөлшат Зәйнашева “Туган җирем– Татарстан” шигырен өйрәтү, сөйләм телен үстерү.

Метапредмет- җаваплылык хисләре, туган илне ярату, хөрмәт итә белү теләге тәрбияләү.

Регулятив: үз-үзеңнең, бер-береңнең эшләрен тикшерә, бәяли; биремнәрне максатка яраклы итеп үти белү.

Коммуникатив: парлап эшләгәндә, иптәшең белән килешә, бер-береңнең фикерен тыңлый, нәтиҗә чыгара, аңлатып бирә белү;

Танып белү: үз фикереңне дәлилли белү; әсәрне анализлаганда, белем һәм күнекмәләрне файдалана белү.

Шәхси: туган илгә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен үстерү.

Материал- дәреслек 2 нче кисәк, 30-34 нче битләр, эш дәфтәрләрендә 38-39 нчы битләр.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның портреты, презентация.

Дәрес барышы:

I. Актуальләштерү.

Укытучының сәламләү сүзе:

-Хәерле көн, укучылар! Хәлләрегез ничек? Кәефләрегез тагын да яхшы булсын өчен бер-берегезгә карап елмаегыз әле. Бүгенге дәресебез дә кызыклы булыр. Сез үзегезгә файдалы мәгълүматлар алырсыз. Бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз.

Ә хәзер өй эшен тикшереп китик әле. Сезгә өй эше итеп, әле генә без тыңлап киткән җырның авторы - шагыйрә Г.Зәйнашева турында мәгълүматлар тупларга, үзегезгә ошаган шигырьләрне ятлап килергә кушылган иде. 1-2 укучы Г.Зәйнашеваның биографиясе белән таныштырып китә.

1нче укучы җавабы: Г.Зәйнашева 1928 нче елның 13 нче гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туган.Әтиләрен кулак дип авылдан сөрәләр.2 яшьлек Гөлшатны әтисенең апасы үзенә ала. Аның балачагы Минзәлә районының Югары Тегермән авылында уза. Ләкин апасының ире бу баланы яратмый, аны хәтта кайчакларда кыйный да.

Гөлшатларның өйләре клуб янында урнашкан була.Минзәләдән артистлар килгәч, аларга фатирга керәләр.4-5 яшьлек кызны артистлар үзләре белән концерт карарга ала торган булалар.Спектакь караганнан соң артистлар аны урындыкка бастырып шигырь сөйләтәләр.Өйдә ялгыз калса, ул артист булып уйнарга ярата.

Гөлшат кечкенәдән үк тырыш кыз була.Мәктәптә бик әйбәт укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

2 нче укучы җавабы: Мәктәпне тәмамлаганнан соң башта педагогия училищесын тәмамлый, аннары 1945-1949 нчы елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Бер үк вакытта театр училещысына йөреп, дәресләр ала. Әмма аңа я институтны, я театр училещысын сайларга кушалар. Ул институтны сайлый, ләкин концерт бригадалары белән бергә авылларга чыгып йөри, концертлар алып бара. Институтны тәмамлагач, Г. Зәйнашева Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 50 нче елларда беренче шигырьләре,җырлары матбугат битләрендә күренә башлый. 1958 нче елда "Тыңларсыңмы җырларымны" исеме белән беренче китабы басылып чыга.

Укытучы сүзе: Педагогия институтында укый башлагач та, җиңел булмый аңа. Иң башта фронтта бер кешең дә юк дип, тулай торактан урын бирмиләр. Гөлшат бер-берсенә терәп куелган урындыклар өстендә йоклап йөри,бер елдан соң гына урын бирәләр аңа. Бик яхшы укыганы , җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен аңа Дәүләт стипендиясе бирелә.

Тагын шуны өстәп әйтәсем килә: Г.Зәйнашева моңлы, матур тавышка ия була. Һәркем белә: җырчы тавышына ия булган кеше бәхетле, чөнки ул йөрәк түрендә сакланган серләрне беркемнән яшермичә җыры аша әйтеп бирә.

II. Яңа тема өстендә эш.

Дәресебезне "Туган җирем – Татарстан" җыры тыңлап дәвам итик әле. Җырны игътибар белән тыңлагыз, соңыннан сезнен белән сөйләшеп алырбыз.

1.Бу җыр нәрсә турында?

2.Нәрсә соң ул Туган җир?

3. Сез туган җиребезне яратасызмы соң?

Укытучы сүзе: Әйе, укучылар без барыбыз да туган җиребезне яратабыз. Ә шагыйрә Гөлшат апагыз бу турыда ничек әйткән соң? Моны белү өчен безгә тагын бер тапкыр текстны укып чыгарга кирәк булачак.

4.Сезгә бигрәк тә кайсы юллар ошады? (укучыларның фикерләре тыңланыла).

5. Төркемнәрдә эш.

1 нче төркем.

Туган җир нинди? Шул турыда языгыз.

2 нче төркем.

Туган җирегезнең истәлекле урыннарын атагыз.

3 нче төркем.

Бирелгән сүзләрдән мәкаль төзегез.

Кадерен, туган, белерсең, йөрсәң, читтә, илнең.

Җавапларны тыңлап, бәяләү.

6. Г.Зәйнашева шигырьләре белән танышуны дәвам итү.

Укучылар, без Г.Зәйнашева иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез. Ә хәзер шигырьләр тыңлап китик әле.

1. "Шаулый урман "шигыре тыңланыла.

Укучылар, шигырьне игътибар белән тыңлагыз, шагыйрә нәрсә әйтергә тели, нинди проблема күтәрә? (Табигатьне саклау проблемасын күтәрә)

7. Укытучы сүзе: Без сезнең белән шагыйрә Г.Зәйнашеваның шигырьләренә күз салдык, аның сүзләренә язылган җырны тыңладык. Ә шигырьләргә музыканы кем яза соң? (Композиторлар). Әйтегез әле сез нинди композиторларны беләсез? (Укучыларның җаваплары тыңланыла)

-Гөлшат Зәйнашева сүзләренә җырлар язган композиторларыбыз бик күп. Минем бу урында Г.Зәйнашеваның композитор С.Садыйкова белән дуслыгы турында әйтеп үтәсем килә. Алар иҗатташ дуслар гына түгел, җан дуслар булалар. Сара апа каты авырып киткәч, аның янында Гөлшат булды. Соңыннан С.Садыйкова вафат булгач, ул кадерле дусты, иҗатташының якты образын мәңгеләштереп китап язды. Бу китап-авторның проза өлкәсендә дә уңыш белән эшли алу мөмкинлеген сөйли. (Г.Зәйнашеваның "Сара Садыйкова" китабы күрсәтелә).

8. "Гөлләр иле" исемле шигырьләр җыентыгыннан табышмаклар тәкъдим итәргә була.

9. Нәтиҗә ясау.

Укучылар, бу дәрестә без шагыйрә Г.Зәйнашева иҗатына кыскача күзәтү ясадык. Билгеле, бер дәрестә без аның иҗатын – ул язган шигырьләрне, җырларны һ.башкаларны карап бетерә алмыйбыз.

Г.Зәйнашева – әдәбиятның төрле жанрларына караган китап авторы. Аның драма әсәрләре "Гайфи бабай, өйлән давай" комедиясе К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында сәхнәсеннән төшмичә уйналып килә. Аның балалар өчен, зурлар өчен язган шигырьләре бик күп. Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән шагыйрә. Бер генә концерт та Г.Зәйнашева җырларыннан башка узмый. Шунысы билгеле: һәрбер язылган шигырь җыр булып китә алмый, һәм шулай ук һәрбер шагыйрь дә җыр текстлары яза алмый. Ә Г.Зәйнашеваның һәр шигыре диярлек көйгә салынган. Җыр барлыкка китерү өчен аерым талант кирәк һәм шагыйрә шул талантка ия була. Тактага язылган юлларга игътибар итик әле.

Әйе, укучылар, чыннан да, шагыйрә Г.Зәйнашева бәхетен туган ягында, туган җирендә тапты. Аның җырлары һәркөн радиодан, телевизордан, республикабызда гына түгел татарлар яши торган төбәкләрдә яңгырый. Аның җырлары-мәңгелек, үлемсез. Халык яшәгәндә аның җырлары да яшәячәк. Мин ышанып калам: киләчәктә сез дә талантлы шагыйрә Г.Зәйнашева иҗаты белән кызыксынырсыз дип.

III. Йомгаклау. Дәрестә актив катнашкан укучыларга билгеләр куела.

Өй эше: Үзегезгә ошаган берәр шигырьне ятлап килергә.

## Сандугач образы

(Г.Зәйнәшеваның «Китмә, сандугач» шигыре буенча Осталык дәресе)

Зәйнуллина Эльвира Тимерҗан кызы,

10 нчы күппрофилле лицей, Алабуга шәһәре

Максат: 1) Шигырьнең эстетик матурлыгын дөрес тоярга, сүз сәнгатенең тәэсир көчен аңларга өйрәтү; лирик герой хисенең сәбәбен, дәрәҗәсен аңлауларына ирешү;

2) укучыны образлар дөньясына алып керү һәм сәнгатьнең төрле төрләрендә образ тудыру үзенчәлеген тоярга ярдәм итү; образлы фикерләргә өйрәтү һәм иҗатка омтылыш булдыру;

3) матурлыкны тоярга һәм үз матурлыгыңны тудырырга теләк формалаштырырга тырышу; укучыда үз-үзенә ышаныч хисенең үсүенә этәргеч бирү.

1 слайд. (Матур табигать, чишмәле болын күренешләре, кошлар сайравы) Уңай психологик халәт тудыру

2 слайд. Мин сезгә Г.Зәйнәшеваның “Китмә, сандугач” шигыренә нигезләнеп,

“ Сандугач образы” дигән мастер-класс тәкъдим итәм.

Кереш сүз. “Матурлык дөньяны коткарыр” – дигән И.Ганди. Сәнгать ул – матурлык дөньясы. Укучыны әйләндереп алган дөнья никадәр төрле һәм бай булса, шәхеснең күңел дөньясы да шулкадәр бай һәм матур була.

3 слайд (проблема кую). Бүгенге иң зур проблемаларның берсе – яшь буынга хисслелек, кичерешләр тирәнлеге җитмәү, каты күңеллелек, үзен әйләндереп алган дөньяга карата битарафлык чагылышы, әдәбият укытучысы һәм гади кеше буларак, мине борчый һәм бу проблеманы чишүдә үз ысулларымны эзләүгә этәрә.

4 слайд (әдәбият һәм сәнгать бөтенлеге). Сәнгатьнең һәр төре дөньяны үзенчә сурәтли. Рәсем сәнгате дөньяның төсләр балкышын бирә алса, музыка исә кешенең

хисләрен чагылдыра. Ә әдәбият исә сүз ярдәмендә образны вакыйгалар эченә алып керә, аны җанландыра, тәэсир көчен тагын да арттыра. Сәнгатьнең башка төрләренә мөрәҗәгать итү укучыны гадәти дәрес кысасыннан чыгара, үзенең матурлыгы белән сокландыра, гаҗәпләндерә.

5 слайд (технологияләр). Шуңа күрә әдәбият дәресләрендә мин сәнгатьнең төрле якларына игътибар итәргә, аларның бөтенлегенә ирешергә һәм шулар аша укучы күңеленә үтеп керергә, аны уятырга, матурлык дулкынына көйләргә тырышам. Укучыга үзе тапкан, үзе ачкан матурлык әһәмиятле. Максатка ирешү өчен, дәресләрдә эшчәнлекле укыту, уен технологияләренә нигезләнәм. Проблемалы укыту шулай ук бүгенге көн таләбе. Иң мөһиме, укучыда эмоциональлек арта, хисләре уяна, иҗади фикерләве үсә.

Әлеге мастер-класста мин әдәби образны өйрәнү, аны сәнгатьнең төрле төрләре яссылыгында ачу проблемасына тукталам һәм укучының үзенә образ тудыру ысулларын аңлатырга омтылам.

6 слайд (сандугач рәсеме). Татар әдәбиятында сандугач образы бик еш кулланыла. Бүген без шушы образ турында сөйләшербез.

Имитацион уен.

- Әйтегез әле, дусларым, сезнең сандугачны күргәнегез бармы? Аларның барысы да бертөрле сайрыймы? Сандугач җырлый, дип әйтәләр, ул, чыннан да, җырлыймы? Аларның үзенә хас холкы, характеры буламы? (Фикерләр тыңлана).

- Әйе, сандугачны кешеләр моңлы, тылсымлы сайравы өчен ярата. Үзене моңы белән ул язучы-шагыйрьләрне, композиторларны, рәссамнарны иҗатка илһамландыра, шуңа күрә аның турында җырлар да, шигырьләр дәкүп.

- Сандугач һәм былбыл бер үк кош исемнәреме? Ни өчен бер үк кошны ике исем белән атыйлар? (укучыларның җаваплары тыңлана)

- Әйе, сандугачны халык яратып былбыл дип атый.

Релаксация. –Әйдәгез, сандугач тавышын тыңлап, борчу-мәшәкатьләребезне онытып, илһамланып алыйк әле. Бүген сез нинди игелекле гамәл кылдыгыз яки әле ниндидер яхшылык эшли алыр идегез?(сандугач сайравы тыңлана).

- Күңелебезгә матурлык, яктылык тулдымы? Шушы дулкында бер хисләнеп алыйк әле. Сандугач турыда нинди җырлар беләсез?

(җырның беренче ике юлы тыңлана, дәвам итәргә тәкъдим ителә)

(“Сандугачлар ияләшкән су эчәргә миләштән...”, “Сары сандугач баласын кулларымда сайратам...”, “Ай былбылым, ай былбылым, Агыйделнең камышы...”, “Талларга качты сандугач, мин аны эзлиммени...”(“Сандугач керде күңелгә”, “Сайра, сайра, сандугачым, зифа талларга кунып...”, “Сандугач булыйм димә, карлыгач булыйм димә...”, ...һ.б.)

- Ә хәзер төркемнәрдә эшләп алыйк . Сандугач образы халык авыз иҗатында ни дәрәҗәдә чагылыш таба икән? “Таралган” мәкальләрне җыегыз” уены. (укучыларга сандугач турындагы мәкальләрдән сүзләр һәм сүзтезмәләр бирелә, шулардан мәкаль җыю уены үткәрелә).

(Очканда карлыгач, җырлаганда сандугач узар. Козгынга да үз баласы былбыл булып күренер. Сандугач сайрый дип карга да кычкырган. Бака кычкыра башлагач, сандугач телдән калыр. Былбылны алтын читлеккә япсаң да, үз тал-тирәген сагынып сайрар. Өй артында куагың булса, сандугач кунагың булыр.)

- Бик яхшы. Инде мәкальләребезне укып та күрсәтик (һәр төркемнән бер кеше укый). Әйе, сандугач турында мәкаль-әйтемнәр дә, җырлар да күп.

- (Сандугач) Ә хәзер мин үз яныма Алиянең чыгуын сорыйм. (Таныштыру).

- Дусларым, минем Алиябезне сандугач дип атыйсым килә. Сыйныфыбызның нәни сандугачы ул! (сандугач рәсеме һәм кеше) Килешәсезме? Дәлилләгез. (Без болай дип күчерелмә мәгънәдә әйтәбез. Чөнки ул бик матур җырлый. Үзенең татарча матур җырлары белән күпләрнең күңелен күтәрә, аны тыңлыйсы да тыңлыйсы килә ...)

- Димәк, сандугач белән кемне чагыштыра алабыз? (матур җырлаучыны).

- Әйе, болай фикер йөрткәндә, без табигатьтәге сандугач турында гына түгел, аның белән чагыштырыла ала торган образ турында сөйлибез.

7 слайд (теоретик материал). Ә нәрсә ул образ? Шигырь юллары белән әйтсәк:

Образ ул – гомумиләштерү,

Образ ул – табигатьнең үзен кешеләштерү;

Образ ул – алыштыру, тулыландыру,

Тормышны, йөрәкләр аша уздырып, яңадан тудыру

- Мин хәзер сезгә Г.Зәйнәшеваның “Китмә, сандугач” шигырен тәкъдим итәм. Сез текстны укыйсыз һәм шул ук вакытта Ришат Төхфәтуллин башкаруында әлеге җырны тыңлыйбыз да, кушылып җырлыйбыз да. Бу җырга көйне танылган композиторыбыз, Татарстан гимнының авторы Рөстәм Яхин язган.

8 слайд.
Китмә, сандугач
Сандугач, сандугач.
Китмә, китмә, сандугач!
Канатларын талдырып,
Туган җирне калдырып
Бездә туып үстең син.
Чык суларын эчтең син.
Сандугач, сандугач!..
Син китәсен, мин калам,
Дусларыма җырлар өчен
Җырыңны отып алам
Сандугач, сандугач.
Китмә, китмә, сандугач!..
Курыкма син кышлардан.
Кал син башка кошлардан.
Саклармын салкын җилдән.
Китмә син туган илдән.
Сандугач, сандугач!..
Син китәсең, мин калам
Дусларыма җырлар өчен
Җырыңны отып алам!

- Җыр ошадымы? Әйе, күңелне нәфислек, чисталык, бераз гына моңсулык белән тутыра торган җыр бу!

- Анализ ясап алабыз. Сез инде беләсез, лирик шигырьнең нигезендә хис ята. Әсәрдә нинди хис өстенлек итә? (соклану, ярату, мәрхәмәтлелек). Бу хиснең сәбәбе нәрсә? (сандугач, аның көз көне китәргә мәҗбүр булуы). Лирик герой аны ни дәрәҗәдә ярата? (ул аны салкын җилләрдән сакларга да әзер) . Ни өчен сандугачны җибәрергә теләми? (сандугачның туган җире кала, туган җир кошларга да газиз). Ни өчен “Син китәсең, мин калам” ди? (Кеше өчен кошлар җыры бик мөһим). Лирик геройның юанычы бармы? (Әйе,

ул аның җырын үзендә саклап кала, аны дусларына җырлап, сандугач әйләнеп кайтканчы, матурлыкны ул үзе тудырачак). Шигырьне укыгач, күңелдә нинди хисләр уяна? (игелеклелек, кайгыртучанлык).

- Ә хәзер рәсемнәргә карыйбыз. (төркемнәргә төрлечә сурәтләнгән сандугач рәсемнәре бирелә (ана сандугач ояда, атасы янында сайрый; матур болында сандугач сайрый һ.б., сораулар язылган биремнәр өләшенә). Рәсемдәге сандугач турында сөйләгез. Аларда сандугачның нинди сыйфатлары ачыла? Образлы итеп әйтеп биреп карыйк әле (башта сыйфатын билгелибез, бу сыйфатны ни белән булса да чагыштырабыз, сандугачны җанландырабыз, сөйләштерәбез...). Бу төркем фикерен кем яклый? (Төркемнән бер кеше чыгыш ясый).

- Ял минуты. (9 слайд) (Сандугач тавышы). Үзегезне матур чишмә янында итеп хис итегез. Өздереп сандугач сайрый. Нинди хисләр кичерәсез? Хисләрегезне матур сүзләр белән сөйләп бирегез.(Һәр төркемнән бер кеше фикер әйтә)

- Без иҗади фикер йөртергә өйрәнәбез. Ә хәзер үзебез иҗат итеп карыйбыз. Синквейн язабыз. Кайсы төркем иҗадирак булыр?

(10 слайд. Кагыйдәсе:

1 юл – 1 сүз, шигырьнең исеме, гадәттә, исем белән белдерелә

2 юл – 2 сүз, теманы ачу өчен сыйфатлар яки сыйфат фигыльләр белән бирелә (теркәгеч, бәйлекләр булырга мөмкин);

3 юл – 3 сүз (фигыльләр) теманың эше, хәрәкәте;

4 юл – 4 сүз. Җөмлә. Монда авторның темага мөнәсәбәте ачыла;

5 юл – 1 сүз – ассоциация. Синоним, теманың асылын ача, исем яки исемләшкән сүз төркеме белән бирелә)

11 слайд. Ә минем вариантым мондый:

Сандугач.

Нәфис, моңлы.

Сокландыра, хисләндерә, яшәртә.

Кешеләргә яшәү көче бирә.

Былбыл.

Рефлексия. Иҗатка килү өчен нинди этаплар үттек?

12 слайд. - Эзләнү- тикшерү, анализ, күзәтү, иҗади фикер йөртү, иҗат итү.

- Без нишләдек?

- Башта сандугач образының халык авыз иҗатының нинди төрләрендә, ничек бирелүен тикшердек, аннары шигырьгә анализ ясап, сандугач образының бирелүе турында фикерләштек, рәсем сәнгатендә ничек тасвирлануын күзәттек, фикерләребезне әдәби тел белән матур итеп әйтергә тырыштык, ахырда үзебез шигырь яздык)

- Дәрестән нинди фикер белән китәсез?

- Һәр кешенең күңелендә ачылмаган шагыйрь утыра. Табигать матурлыгын күрә белгән,аны сакларга, якларга омтылган кеше – матур кеше! Андый кешеләр күп булса, тормыш матур булачак!

**Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган**

«Күңелле шигырьләр» иртәсе

(Зурлар төркеме)

Иксанова Рәмзия Мөдәрис кызы,

катнаш төрдәге Җәлил 5 нче "Әкият" балалар бакчасы, Сарман муниципаль районы

Максат:

1. Балаларны Г.Зәйнашеваның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Балалар шагыйрәсе иҗатына карата ихтирам итү хисен тәрбияләү.

2. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү.

3. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Татарча матур һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү.

Җиһазлау: Гөлшат Зәйнашева портреты һәм китаплары күргәзмәсе, шагыйрә иҗатына багышланган стенд, балалар рәсемнәре, бүләккә китап, интерактив җайланмалар, магнитофон.

Эшчәнлек барышы

*Бүлмә бәйрәмчә бизәлгән. Музыка уйный, балалар бүлмәгә керәләр.*

Алып баручы: Хәерле көннәр, кадерле дусларыбыз! Без сезнең белән “Күңелле шигырьләр” иртәсенә җыелдык. Без бүген үзебезнең як шагыйрәсе Гөлшат Зәйнашеваның матур-матур шигырьләрен сөйләрбез, кызыклы уеннар уйнарбыз.

- Балалар, әйтегез әле, ә сез шигырьләр тыңларга, сөйләргә яратасызмы соң? *(Әйе)* Хәзер мин сезгә бер табышмак әйтәм. Ә сез аның җавабын табыгыз. Әгәр дә табышмакның җавабын дөрес әйтсәгез, минем серле сандыгымнан ул әйбер чыгачак.

Юк аягы, теле юк,

Сөйләмәгән сүзе юк.

Телгә аннан оста юк,

Аннан якын дус та юк. (*Китап*)

- Дөрес, балалар карагыз әле, безнең серле сандыгыбыздан китап килеп чыкты. Бу китапта нәрсәләр турында язылганын белү өчен, әйдәгез аны ачып карыйбыз.

- Балалар, бу кем? (*Гөлшат Зәйнашева*) Г. Зәйнашева безгә бик зур байлык – шигырьләр, җырларга сүзләр язып калдырган.

*Г.Зәйнашеваның “Тибрәнә җыр күңелдә” дигән җыры куела.*

Алып баручы: Балалар, ә сезнең арада тапкырлар бармы? Сез табышмаклар яратасызмы? Ә хәзер табышмаклар чишәргә вакыт җитте. Табышмаклар төсләр турында. Һәр балада бер төс бар, әгәр дә җабын дөрес әйтсәгез, ул төс турында бала Гөлшат Зәйнашева язган шигырьне сөйләячәк. Беренче төс турында табышмакны тыңлыйбыз.

Алып баручы:

Күрә аласыз мине

Алмада һәм чәчәктә,

Карлыганда, җиләктә,

Помидорда бигрәк тә. (*Кызыл*)
Бала: Җырлый-җырлый җиләк җыям,
Кызыл каен җиләген.
Кып-кызыл җиләкләр белән
Тула инде чиләгем!..
Алып баручы: Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле өчпочмакларны
Әни йөри пешереп.
Бала: Түп-түгәрәк җир шары,
Аның да бар дүрт ягы.
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы. (*Кызгылт-сары*)
Алып баручы:
Мин иң матур төс,
Иң якты төс,
Кояшта күреп була,
Лимон белән банан да
Минем төсне ярата. (*Сары)*
Бала: Сары чәчәктән чәчәккә
Оча сары күбәләк.
Сары күбәләк шатлана,
Сары күбәләк шатлана,
Чәчәк белән бергәләп.
Алып баручы:
Мин урман төсе, яфраклар төсе
Җирдә үсүче хәтфә чирәм төсе. (*яшел*)
Бала: Язлар җитте, бар табигать:
«Без яшәрәбез,» - диде.
Урман, болыннар, тугайлар
Яшел киемен киде.
Алып баручы:
Кайгырмагыз, дусларым,
Мине күргәч болытта,
Минем төсемне хәтта
Әйберләр дә ярата. (*Зәңгәр*)
Бала: Зәңгәр елга өсләреннән
Агыла зәңгәр болыт.
Әллә шуңа бөтен нәрсә
Күренә зәңгәр булып.
Алып баручы:
Исемем минем кызык,
Шуңа күрә дә балалар,
Бик тиз алалар отып.
Тәмле җимешләремне,
Торалар бик озак көтеп. (*Шәмәхә*)
Бала: Шәмәхә төс – матур төс ул,
Шәмәхә төс яратам.
Урманга барсам шәмәхә
Чәчәкләр җыеп кайтам,
Чәчәкләр җыеп кайтам.

Алып баручы: Булдырдыгыз! Барлык төсләрне дә таптыгыз. Балалар, әйтегез әле без бу төсләрне барысын бергә кайда күрә алабыз? (Салават күперендә)

Алып баручы: Балалар, һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Әйтәләр бит, “Калган эшкә кар ява”, – дип. Кечкенәдән өйрәнергә кирәк һәр эшкә, аннан соң булырга мөмкин. Ә безнең балалар һәр эшне вакытында башкара.

Ә хәзер, балалар башкаруында “Татар халык биюен” карап китик.

Алып баручы: Ә менә хәзер, безгә уйнасак та була. ә безнең яраткан “Ачык авыз” уенын уйныйбыз.

Уен “Ачык авыз”

(Балалар аллы-артлы парлашып түгәрәк ясап басалар. Бер кеше парсыз кала. Ул уртада басып тора. Бию көе уйный. Шул вакытта эчке якта торган укучылар түгәрәк ясап җитәкләшәләр һәм бию көенә әйләнәләр. Шулай бераз әйләнгәннән соң, көй кинәт кенә туктала һәм эчке яктагылар тышкы якта басып калган кешеләр белән парланалар. Бер кеше тагын парсыз кала. Шул кешегә җәза бирелә)

Алып баручы: Сез “Әкият” балалар бакчасында. Алда әйтеп киткәнчә бүген бездә Шигырь бәйрәме. Менә балалар да яраткан шагыйрәбезнең бик күп шигырьләрен өйрәнделәр. Менә сез дә безнең белән бергә аларны тыңлап китегез. Балаларга саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен Гөлшат Зәйнашева саннар турында шигырьләр язган.

Бала: Саннар саный башласак,
Иң беренче – бер саны.
Мактап әйткән кебек, без
«Беренче» дибез аны...
Бер саны ул бер генә,
Әни дә бит бер генә,
«Әнием – бергенәм» дип
Кадерлибез гел генә.
Бала: Табигатьтә бөтен нәрсә
Ике төрле килгән безгә.
Бер чорлары кара булса,
Икенчеләре ап-ак төстә.
Бала: Өч санын күрим дисәң,
Кара кухняга кереп.
Тәмле өчпочмакларны
Әни йөри пешереп.
Бала: Түп-түгәрәк җир шары,
Аның да бар дүрт ягы.
Көнчыгышы, көньягы,
Көнбатышы, төньягы.

Алып баручы: Безнең балаларыбыз бик уңган булып чыктылар. Гөлшат Зәйнашеваның шигырьләрен күп беләләр икән. Гөлшат Зәйнашева уңган, тырыш балаларны кем дип атаган? (бөрлегән)

Бала: Бөрлегәнем, җиләгем, дип
Иркәли мине әни.
Мин бит әле бик кечкенә,
Мин бит әле бик нәни.
Зур түгел шул, бик кечкенә
Бөрлегән мин, бөрлегән.

Бөрлегән генә булсам да,
Һәр эшкә дә өлгерәм.

Алып баручы: Әйдәгез әле, балалар, Гөлшат Зәйнашеваның табигать дуслары, әбиләр турындагы бик матур шигырен тыңлап китик әле.

Бала: Әнкәй пешерә ял көнне безгә
Бишбармак бишебезгә:
Әткәй, әнкәй, абыйга,
Сеңелем белән миңа.

Бала: Без – табигать баласы,
Без табигать дуслары.
Безне сәламләп сайрый
Туган якның кошлары.

Бала: Мин үзем шәһәрдә яшим,
Авылга кайтам җәен.
Чөнки ул авылда яши
Яраткан әбекәем.
Мин үскәч, әбием белән
Авылда торачакмын.
Әбием картаеп киткәч,
Ярәмче булачакмын.
Әбиемне яратам, яратам,
Әбием янына кайтам!..

Алып баручы. Әни – һәр кеше тормышында иң кадерлеседер, әлбәттә. Гөлшат Зәйнашева иҗатында әниләр бик зур урын алып тора. Безнең һәрберебезне дә кечкенә чакта әниләребез бишек җырлары җырлап йоклаткандыр. Ә хәзер сезнең игътибарга Гөлшат Зәйнашева сүзенә язылган “Кояш гомере” җыры тәкъдим итәбез.

*“Кояш гомере” җыры башкарыла*

Алып баручы: Шуның белән бәйрәмебез тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Бу бәйрәмне Гөлнур Айзатуллованың шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә.

Мин бәхетле, әгәр балаларым,

Сөйләсәләр ана телендә.

Кайгыларын, шатлыкларын бергә,

Бүлешсәләр татар телендә.

Сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр.

**Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе**

(Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен Гөлшат Зөйнашева

иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе)

Талибуллина Гөлнара Рәис кызы,

Җәлил бистәсенең 3 нче санлы "Аленушка" балалар бакчасы,

Сарман муниципаль районы

Максат:

1. Г. Зөйнашеваның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге белән таныштыруны дәвам итү.

2. Балаларның бәйләнешле,сәнгатьле сөйләм телен, хәтер сәләтен үстерү; тапкырлык, зирәклек күнекмәләрен тикшерү. Татарча матур һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәтү.

3. Г. Зөйнашеваның әсәрләре аша балаларда туган җиргә мәхәббәт, аның белән горурлану хисе; дуслык, татулык сыйфатлары тәрбияләү.

4. Шагыйрәнең иҗатына кызыксыну, ихтирам уяту.

Җиһазлау: проектор, магнитофон, Г.Зәйнашева портреты һәм китаплары күргәзмәсе, балалар рәсемнәре, бүләккә китаплар.

Барышы:

Музыка залы бәйрәмчә бизәлә. Өстәлдә чәчәкләр. Г. Зөйнашеваның портреты стенага язып эленә. Китапларыннан күргәзмә оештырыла. Бер якта шагыйрәнең әсәрләре буенча балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе. Проекторда – презентация “Г. Зәйнашева иҗаты”

Алып баручы: Хөерле көн, кадерле балалар һәм хөрмәтле кунаклар! Балалар, сез шигырьләр яратасызмы?

Балалар: Әйе, яратабыз.

Алып баручы: Ә шигырьләр язучы кеше кем дип атала?

Балалар: Шигырьләрне шагыйрь яза.

Алып баручы: Сез нинди татар шагыйрьләрен беләсез?

Балалар: Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Дамир Гарифуллин, Роберт Миннуллин, Клара Булатова һ.б.

Алып баручы: Бүген безнең бәйрәмебез тагын бер татар халкының яраткан шагыйрәсее, безнең якташыбыз Гөлшат апа Зәйнашевага багышланган.

Экранда – слайдлар: болыннар, урманнар, Татарстан Республикасы табигате,

шигырьне тәрбияче укый. “Гөлләр иле” Г.Зәйнәшева шигыре.

Алып баручы: Туган як турында бу матур юлларны язучы – безнең якташыбыз, татар халкыбызның моңлы җырчысы Гөлшат Зәйнашева.

Шагыйрәнең тормыш юлына күз салыйк. Сарман районында Иске Теләнче авылында 1928 нче елның 13 нче гыйнварында дөньяга килгән. Әмма бала чагын Минзәлә якларында Югары Тәкермән авылында үткәргән.

Ятимлек сәбәп моңа – моңлы ятимлек. Моңнар әнә каян килә ул Гөлшатка. Минзәләдә ул педагогия училищесын тәмамлый, Казанда педагогия институтында белем ала. Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында эшли.

Бик яшьли китаплар укырга ярату, мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтылу, үзешчән сәнгать һәвәскәре авыл сәхнәләрендә, бераз соңрак институт кичәләрендә катнашу да аның әдәбиятка, сәнгатькә якынаюына сәбәпче булгандыр.

Казанда Гөлшат шагыйрьләр, музыкантлар, җырчылар, композиторлар белән якыннан таныша, аралаша. Композитор Алесандр Ключарев белән булган иҗади дуслыгы аңа канатлар куя. һәм ул «Туган җирем – Татарстан» җыры белән бәйгедә җиңеп чыга. Бу җырның музыкасы дәртле, халык күңелендә туган җиренә булган изге тойгыларны әйтеп бирерлек моңлы.

Җыр башкарыла «Туган җирем – Татарстан»

(Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе)

Алып баручы: Кечкенә Гөлшатның әтисен сөргәнлеккә җибәргәннәр, һәм 5 бала белән калган әнисе Әнвәр апа ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы - Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Матур табигатьле бу авыл, балачак хатирәсе булып, Гөлшат Зәйнашева күңелендә гомерлек эз калдыра.

Нинди авыл ул, дисәгез,

Моңлы авыл Тәкермән.

Китсәң, сагынып кайтасың,

Мәңге чыкмый хәтердән.

Шагыйрәнең бала чагы, инде белгәнебезчә, Тәкермән авылында үтә. Бу бик матур авыл, аны Гөлшат апа һәрвакыт сагынып сөйли. Ул авылда да матур урынныр, чишмәләр, су буйлары булган. Безнең кызлар хәзер су буеннан көянтә – чиләкләре белән су алып кайтырлар.

Бию “Су буенда”

Алып баручы: Шушы авылдагы өйләре клуб янәшәсендә була кечкенә Гөлшатларның. Минзәләдән артистлар килсә, аларга фатир төшерәләр. Кичләрен артист Сабир Өметбаев аны күтәреп клубка алып керә. Спектакль тәмамланганнан соң, артистлар аны, урындыкка бастырып, шигырь сөйләтәләр. Өйдә ялгыз калса, кечкенә кыз Гөлшат артист булып уйнарга ярата. Мич аралыгына корылган чаршау артыннан чыгып, яшелле-күкле тавыш белән: "Кәнсиртебезне башлыйбыз! Җырлый Гөлшат Зәйнашева", - дип белдерү ясый.

Кечкенәдән шигырләр яраткан Гөлшат Зәйнашева балалар өчен шигырьләр яза. Әйдәгез, берничәсен тыңлап үтик.

“Бер атнада ничә көн?”, “Кыш килде” шигырьләре укыла.

Алып баручы: Г. Зәйнәшева әле бик бәхетле әни дә, кызы Асиянның балалары - Дамир белән Камилгә әле ул дәү әни дә була. Алар аны, яратып, "Гөләни" дип йөртәләр. Г.Зәйнашеваның “Әбиемне яратам" дип аталган китабы бар, һәм ул, билгеле, аның оныкларына багышланган. Ул китаптан да шигырьләр тыңлап үтик. (“Чәчтем шалкан” шигыре).

Алып баручы: Безнең бакчада татар халкының яраткан бәйрәмнәребезнең берсе – Сабантуй бәйрәме ел саен уздырыла һәм ел саен без аны матур, күңелле җыр белән башлыйбыз – “Күңелле Сабантуй”. Беләсезме, дусларым, аның авторы – Гөлшат апа Зәйнашева. Бергәләп яраткан җырыбызны башкарыйк әле (“Күңелле Сабантуй” җыры)

Алып баручы: Гөлшат апа Зөйнашева туган ягыбызны, татар халык мәдәниятен бик яраткан һәм хөрмәт иткән. Ягез әле, уйнып алыйк. Мин әйткән мәльләрне дәвам итегез әле!

Сүзле уен “Мәкальне дәвам ит”

Әткәй шикәр-әнкәй бар.

Ипидән зур нәрсә юк.

Сәламәтлек-зур байлык.

Кем эшләми, шул ашамый.

Иң татлы тел-туган тел, әнкәм сөйләп торган тел.

Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.

Китап-белем чишмәсе.

Дустың булмаса-эзлә, тапсаң-югалтма.

Көз көне бала кебек-бер көлә дә бер елый.

Туган ил була бер генә, туган илнең кадерен бел генә.

Алып баручы: Булдырдыгыз, дусларым! Афәрин!

Гөлшат апа әнисеннән, әбисеннән башка үссә дә аларны сагынган һәм яраткан. Аның әби турында җырын балалар башкаруында тыңлап үтегез.

"Әбиемне яратам" җыры (*Асия Зәйнашева музыкасы)*

Алып баручы: Менә ничек матур, ягымлы итеп эндәшә бу шигырьдәге әни үзенең баласына. Балалар, ә сезгә әниләрегез нинди матур исемнәр белән эндәшәләр?

Балалар: Кояшым, кызкаем, улкаем, җимешем, күз нурым, алтыным, куяным, һ.б.

Алып баручы: Бигерәк матур итеп эндәшәләр икән!

Балаларга саннарны өйрәнү җиңел булсын өчен Гөлшат Зәйнашева саннар турында шигырьләр язган. Әйдәгез, балалар, шигырьне сөйләп күрсәтегез әле.

Алып баручы: Гөлшат Зәйнашева әсәрләре, җырлары белән сез, балалар, киләчәктә мәктәптә танышуны дәвам итәрсез. Ә бүген без шуны әйтә алабыз – шундый шагыйрәнең безнең райондашыбыз, якташыбыз булуы белән без һичшиксез горурланабыз! Бәйрәмебез тәмам, сау булыгыз!

## ... Мин тормышка гашыйк ...

(Тапкырлар һәм зирәкләр бәйгесе )

Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы, Баһавиева Лилия Данис кызы

Яңа Савин районының 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре

Кичәнең максатлары:

Дидактик максат: Укучыларның танылган балалар шагыйрәсе Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты буенча алган белемнәрен тикшерү, ныгыту һәм яңа мәгълүматлар белән баету;

Үстерешле максат: Укучыларның сорауларга тулы, дөрес җавап бирүләрен һәм уйлау, логик һәм иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эшләү;

Тәрбияви максат: Укучыларда Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксынуга, аның әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләүгә җирлек әзерләү.

МАТЕРИАЛ: Презентация.

Кичә барышы

Сәхнә бәйрәмчә бизәлгән. Г.Зәйнәшева турында төрле плакатлар эленгән, “Кояш гомере” җыры яңгырый.

1- 2 слайд Ребуслар чишү

3 слайд <u>Г.Зәйнәшеваның портреты</u>

Сәхнәгә бер кечкенә кыз йөгереп чыга.

Кыз: Сөйләр сүзләрем шундый күп минем,

Күңелем тулы җыр һәм моң кебек.

Ләкин сүземнең иң кирәклесен

Никтер әйтәлмыйм кебек.

Кыз янына малай чыга.

Малай: Син кем? Монда нишләп йөрисең?

Кыз: Мин Алия.

Малай: Син монда нишләп йөрисең?

Кыз: Мин Гөлшат апаның бик матур шигырен тапкан идем, шуны башкаларга да сөйләргә булдым.

Малай: Гөлшат апа Зәйнәшева кем соң ул?

Кыз: Ничек инде син шуны да белмисең!

Малай: Мин аны каян белим инде.

Кыз: Ярар алайса, Гөлшат апаның иҗатына багышланган интелектуаль уен булачак, шунда барыгыз да рәхим итегез!

*Алып баручылар чыга.*

1 нче алып баручы: 4 слайд

Кайда барма чын дусларны табам,

Дуслар белән озын юл кыска,

Әллә җирдә дуслар күп булганга,

Мин тормышка гашыйк, тормышка (Г.Зәйнәшева)

2 нче алып баручы: Хәерле көн, балалар! Без бүген сезнең белән Гөлшат Зәйнәшеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган кичәгә җыйналдык. Быел бөек шагыйрәбезнең тууына 95 ел булды. 5 слайд

1 нче алып баручы: Марс Гаитов Гөлшат апаны “Тормышта халык белән бергә атлаучы, аны борчыган проблемаларны һәм куандырган шатлыкларны уртаклашып яшәүче, бик сизгер, зыялы кеше,” - дип атады.

2 нче алып баручы: Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева – күренекле татар шагыйрәсе, драматург, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе (1991), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1969 елдан). Татарстан АССР атказанган сәнгать эшлеклесе (1988).

Гөлшат Зәйнәшева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстан АССРның Чаллы кантоны (*1930 елдан Сарман районы, 1937 елдан Ворошилов районы, хәзерге Тукай районы*) Иске Теләнче исемле авылда урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. 1930 елда, авыл халкын күмәк хуҗалыкларга берләштерү чорында, гаиләләрне «кулак» тамгасы белән читкә сөргәндә, эти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыгарга җөрьәт итмичә, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче этисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә калдыралар. Балачагы шул авылда уза. Югары Тәкермәндә башлангыч, Хуҗаматтә җидееллык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогика укуханәсен тәмамлагач, 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

1 нче алып баручы:Беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырь, җыр, эстрада әсәрләре,үзешчән драма түгәрәкләре өчен язган бер пәрдәле пьесалары – вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» кебек күмәк

җыентыкларда басылып чыккан. Зур күләмле «Рамай» пьесасы халык театрлары сәхнәсендә уңыш казана. 1958 елда лирик шигырьләре тупланган «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1958-2005 елларда авторның төрле жанрда язылган ике дистәдән артык китабы басылып чыккан.

Г. Зәйнашева җыр өлкәсендә актив иҗат иткән. Халык җырлары традицияләрендә язылган, мәхәббәт, туган җир, табигать, яшьлек темаларына багышланган лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ритмик төзеклеге, матур чагыштыруларга бай булуы белән аерылып тора. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан йөзгә якын шигыренә көй язылган. «Туган җирем – Татарстан» (Александр Ключарев), «Китмә, сандугач» (Рөстәм Яхин), «Менәргә иде Урал тауларына» (Мансур Мозаффаров), «Үз илемдә» (Сара Садыйкова), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (Зиннур Гыйбадуллин), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Бәхти Гайсин), «Кояш гомере» (Фәтхерахман Әхмәдиев), «Аерылмагыз» (Ч. Зиннәтуллина), «Туган авылым урамы» (Ганс Сәйфуллин) һ. б. җырлары үзешчән һәм һөнәри җырчыларның озак еллар башкара торган репертуарына кергән.

2 нче алып баручы: Драматургия өлкәсендә дә актив иҗат итә. «Бәхет кошым», «Кем гүзәл ?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак» һ. б. драма-комедияләре Минзәлә һ. б. татар театрлары сәхнәсендә уйнала. «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Җаным җәл түгел сиңа» комедияләре Тинчурин театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

Нәниләргә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына атап язылган шигырьләре һәм җырлары «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) китапларында тупланып бирелгән.

1950-1960 елларда тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Сәнгать кешеләренә (Зифа Басыйрова, Әлфия Галимова, Әлфия Авзалова, Рокыя Ибраһимова, Фатыйма Ильская, Хәдичә Әхтәмова, Флера Сөләйманова һ. б.) сәхнә эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр, Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова тормышы һәм иҗаты турында китаплар яза.

1 А.б. Бүген безнең ике команда катнаша:
“Зирәкләр” командасы һәм
“Тапкырлар” командасы.
Кайсы күбрәк белә диеп,
Тапкырларга сынау булыр.
Зирәклекне күрсәтергә,
Тырышырга кирәк булыр.

*Сәламләү*

“Тапкырлар” командасы:
“Зирәкләргә” дусларча кайнар сәлам!
Телик бер-беребезгә без,
Сәламәтлек һәм уңыш!
Кайсыбыз җиңеп чыкса да,
Бетмәсен безнең дуслык.
Хөрмәтле жюрибез!
Телибез сезнең бүген
Безне тигез күрүне,
Тырышканны белүне.

Безнең девиз:
Тапкыр җиңәр, оттырмас,
Сезгә куып тоттырмас!

“Зирәкләр” командасы

“Тапкырларга” ялкынлы кайнар сәлам!
Дөньяда янып яшәгез,
Көч сынашыйк без бүген.
Үскәч тә искә алыйк бу
Бүгенге ярыш көнен.
Бәхетле булсын һәммәгез,
Жюрига да шул теләк.
Очколарны кызганмагыз.
Санагыз безгә теләп.
Безнең девиз:
Зирәк һәр җирдә кирәк,
Тик чын зирәк бик сирәк.
1 А.б. 6 слайд

Бәйгебезне өй эшен тикшерүдән башлап җибәрик әле. Ул "Мин сиңа, син миңа"дип атала. Һәр команда өйләрендә "Безнең Гөлшат апабыз" дигән темага сочинение язып килергә тиеш иде. Бер команда икенче командага үз сочинениесен укый. Аннан соң шул командага текст эчтәлегенә караган 3 сорау бирәләр. Дөрес җавап өчен баллар куела.

2 А.б. 7 слайд

Ярышны башлыйбыз, дуслар.Икенче бәйге “Һәр сүзнең үз урыны” дип атала. Мин сезгә Г.Зәйнәшеваның бер шигыреннән дүрт юллыгын бирәм, тик ул юллардагы сүзләр буталышып беткәннәр. Шуларны үз урынына куеп укырга кирәк. Сезгә бер минут вакыт бирелә. Вакыт чыкты. (Командалар үз вариантларын укыйлар)

Туган, гөлләр, ягым, иле,
иле, сөмбелләр, Гөлләр.
кунып, сайрап кына, Гөлгә
иле, былбыллар, Үскән.

2 А.б. 8 слайд

(Туган ягым – гөлләр иле,

Гөлләр, сөмбелләр иле.

Гөлгә кунып сайрап кына

Үскән былбыллар иле...)

Командалар эшләгәндә, бер укучы Г.Зәйнәшеваның "Мин тормышка гашыйк" шигырен сөйли.

Командаларның җаваплары тыңлана. Жюри әгъзалары нәтиҗә чыгара. 9 – 21 слайд

1 А.б. Өченче бәйгебезне башлап җибәрәбез. Ул “Җиде кат уйла, бер кат әйт” дип атала. Сез чиратлап Г.Зәйнәшева белән бәйле сорауларга җаваплар бирәчәкбез. Балларны үзегез сайлыйсыз. Әгәр бер команда бирелгән сорауга җавап бирә алмаса, сорау икенче команда бирелә.

1б. Г.Зәйнәшева кем ул? (шагыйрә, драматург)

2б. Г.Зәйнәшева кайчан туган? ( 1928 елның 13 гыйнварында)

3б. Г.Зәйнәшева кайда туган? (Татарстан Республикасының хәзерге Тукай районы Иске Теләнче авылында)

4б. Әтисенең исеме ничек? (Хисам)

5б. Г.Зәйнәшева кайларда укый? (Югары Тәкермәндә башлангыч, Хуҗамәттә җидееллык мәктәптә, Минзәлә педагогика укуханәсендә, Казан дәүләт педагогия институтында укый)

6б. Г.Зәйнәшева ничәнче елда Казан дәүләт педагогия институтында укый? (1945 – )

7б. Г.Зәйнәшевага ничәнче елда Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде? (1991 елда)

8б. Г.Зәйнәшева нинди өлкәдә бик актив иҗат итә? (җыр, драматургия өлкәсендә)

9б. Драматургия өлкәсендә нинди әсәрләр иҗат итә? («Бәхет кошым», «Кем гүзәл ?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сукмак», «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Җаным җәл түгел сиңа»)

10б. Г.Зәйнәшева ничәнче елда вафат була? ( 2005 елның 1 апрелендә)

11б.

Идел ярларына нурлар сибеп

Матур булып ата бездә таң.

Таң шикелле якты туган илем,

Бәхет биргән җирем - ..... .

- Г.Зәйнәшеваның бу шигырендә күп нокталар урынында нинди сүз төшеп калган? (Татарстан)

22 слайд Г.Зәйнәшева портреты

2 А.б. 23 – 24 слайд

Дүртенче бәйгебезгә дә килеп җиттек. Ул “Г.Зәйнәшеваның әсәрләрен тап” дип атала. Шушы шакмаклар эчендәге хәрефләрдән Ш.Галиев әсәрләренең исемнәрен табасыз. Һәр әсәргә бер балл бирелә. Башладык.

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Р** | **Г** | **Г** | **Т** | **Д** | **У** | **С** | **Т** |
| **А** | **И** | **А** | **Ә** | **Б** | **Н** | **А** | **Ы** |
| **М** | **Т** | **Р** | **К** | **У** | **А** | **Е** | **М** |
| **А** | **А** | **М** | **Е** | **Р** | **Р** | **Р** | **А** |
| **Й** | **Р** | **У** | **Р** | **А** | **А** | **Ы** | **В** |
| **Б** | **А** | **Н** | **М** | **З** | **Л** | **Л** | **З** |
| **А** | **Ы** | **Ч** | **Ә** | **Н** | **А** | **М** | **Ы** |
| **У** | **Л** | **Ы** | **Н** | **А** | **Р** | **А** | **Г** |

1 А.б. 25 – 26 слайд

Әйдәгез, хәзер командаларның капитаннарын да сынап карыйк әле. Капитаннар, сезгә сүзләр бирелә, шул сүзләрдән җөмләләр җыярга һәм андагы Г.Зәйнәшеваның кайсы әсәренә туры килгәнен әйтергә тиеш. Кем тизрәк җыеп бетерә һәм әсәрнең исемен дөрес әйтә, шул җиңүче.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Борынгы | картаймыйсың | кодрәтләрдән | чибәр | Казан | аласың? | яшәрәсең, |
| нинди | әллә | кызларың | дәрт | яшәртә? | булсаң да | яңарасың... |

(Борынгы булсаң да картаймыйсың,

Нинди кодрәтләрдән дәрт аласың?

Әллә чибәр кызларың яшәртә? –

Яшәрәсең, Казан, яңарасың... – *"Яшәрәсең, Казан, яңарасың" шигыреннән.*)

2 А.б. 27 слайд

"Рәссамнар" дип аталган бишенче бәйгебезне башлыйбыз. Командаларга Г.Зәйнәшеваның ике әсәре бирелә. Алар шул әсәр буенча рәсем ясыйсыз. Икенче команда аның кайсы әсәрдән икәнен белергә тиеш. Белсәгез, бер балл бирелә.

Рәссамнар эш белән шөгыльләнгән вакытта, әйдәгез, җанатарлар, сезгә дә бер бирем бирәбез. Г.Зәйнәшеваның әсәрләреннән алынган шигырь юлларындагы төшеп калган сүзләрне табыгыз. 28 – 29 слайд

1 нче команда җанатарларына:
Күпме җырлар ... халкым бүген,
... җирем, синең турында.
... бәхетле сине сөюемне
Әйтә ... шушы җырымда.
*(Күпме җырлар җырлый халкым бүген,*
*Туган җирем, синең турында.*
*Мин бәхетле сине сөюемне*
*Әйтә алсам шушы җырымда... ).*
2 нче команда җанатарларына:
Чишмәләрнең ... отар идем
Җыр ... идем һәр коштан,
Әллә кошлар ... сайраганга,
Мин тормышка гашыйк, ... .
*(Чишмәләрнең җырын отар идем*
*Җыр өйрәнер идем һәр коштан,*
*Әллә кошлар матур сайраганга,*
*Мин тормышка гашыйк, тормышка...)* .

2 А.б. 30 – 37 слайд

Бәйгебезнең соңгы битенә дә килеп җиттек. Бәйгебез "Кем яхшырак сөйли?" дип атала. Сезгә бер шигырдән өзек бирелә. Шул өзекне укый барасыз, аннан яттан сөйләп бирергә кирәк булачак.

Туган ягым – гөлләр иле,

Гөлләр, сөмбелләр иле.

Гөлгә кунып сайрап кына

Үскән былбыллар иле...

1 А.б. Жюри әгъзаларына сүз бирелә (нәтиҗәләр ясала).

2 А.б. Кичәбезне “Туган авылым урамы” җыры белән тәмамлыйбыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт! Киләсе очрашуларга кадәр!

Саубулыгыз!

**Кушымта**

| **Бәйгенең исеме** | **Максималь балл** | **“Зирәкләр” командасы** | **“Тапкырлар” командасы** |
|---|---|---|---|
| **“Мин сиңа, син миңа”** | **10** *(7 балл – сочинениегә, 3 балл – сорауларга дөрес җавап биргәндә)* | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **“Һәр сүзнең үз урыны”** | **5**<br>*(һәр сүз дөрес урнаштырылса – 5 балл)* | | |
| **“Интерактив уен”** | **11**<br>*(сорауга дөрес җавап бирелсә – 1 балл)* | | |
| **“Г.Зәйнәшева әсәрләрен тап”** | **8**<br>*(бер әсәргә –1 балл)* | | |
| **“Капитаннар ярышы”** | **5**<br>*(җиңүчегә –5 балл)* | | |
| **“Рәссамнар”** | **7**<br>*(матур ясалган рәсемгә – 5 балл, әсәр исеме дөрес әйтелсә – 2 балл)* | | |
| **Җанатарлар бәйгесе** | **4**<br>*(һәр дөрес әйтелгән сүзгә – 1 балл)* | | |
| **“Кем яхшырак сөйли?”** | **5**<br>*(шигырьне яттан дөрес сөйләгән командага – 5 балл)* | | |
| **Барысы** | **55 балл** | | |

**Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган интеллектуаль уен**

(өлкән сыйныфлар өчен)

Шагалиева Гөлназ Нәҗип кызы,

Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

Максат:

Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлын, иҗатын искә төшерү, ныгыту; логик фикер йөртү сәләтен үстерү, җырлары аша укучыларда татар җырына, моңына соклану хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты буенча ясалган презентация, компьютер, мультимедиа проекторы, штрих-кодлар, телефоннар, китап күргәзмәсе.

Уенның барышы:

- Хәерле көн, кадерле балалар. Бездә бүген зур бәйрәм. Көчледән көчле кем көчле булуын сынау, ярышу бәйгесе.

Тормыш һич тукталып тормый. Үсә, үзгәрә, бик күп яңалыклар алып килә. Телевизор экраннарында яңадан яңа тапшырулар барлыкка килә. Әлбәттә, без дә тукталып тормыйбыз. Телевизор экраннарында бара торган төрле уеннарны карыйбыз. Менә бүген без бер интеллектуаль уен уйнарбыз.

Сөйлә, дисәгез, сөйлимен

Үткән гомерем турында.


Үткән гомерем бер җыр, бәет –

Барысы чагыла жырымда.

- Бу юлларны кем язды икән? Әлеге сорауга җавап бирү өчен, телефоннарны алып, штрих-кодны укырга һәм биремне башкарырга кирәк. Пазлны җыйсагыз бүгенге чараның темасын белерсез. Кем беренче?

- Сезнең алдыгызда кем портреты чыкты? *(Гөлшат Зәйнашева)*

- Гөлшат Зәйнашева – күренекле татар шагыйрәсе, драматург. Беренче иҗат тәҗрибәләре — шигырь, җыр, эстрада әсәрләре, пьесалары — вакытлы матбугатта, «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» күмәк җыентыкларда басылып чыга. Бүгенге уенда Гөлшат апаның тормыш юлын, иҗатын искә төшереп, җырларын тыңлап, җырлап, ял итеп, ярышып алырбыз. (Уенны командаларда да, берничә укучы белән дә уздырырга мөмкин.) Уенның кагыйдәсе белән танышыйк.




Санлы шакмакны сайлагыз һәм шуңа басыгыз
Сорауны укыгыз.
Уйлау өчен 5 секунд вакыт бирелә.
Вакыт беткәч,телдән җавап бирегез.
Һәр дөрес җавапка 10 балл бирелә.
Дөрес җавапны белү өчен, экранга басыгыз.
«Уенны дәвам итегез» төймәсенә басып уенны дәвам итегез.

- Катнашучылар әзерме? Уенны башлыйбыз.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Гөлшат Зәйнашева туган ел? (1928)

2. Бу җырның исемен әйтегез.

Көн саен берәр кыз белән
Таныша кайберәүләр.
Мәхәббәт эшендә шулай
Ярыша кайберәүләр. (Әй егетләр, егетләр!..)

3. «Алтын куллы, киң күңелле, җор телле, шаян тапкыр бабай инде үз өендә үзе артыкка әйләнә. Кызы аңа “бай кәләш” – фатирлы әби эзли.» Бу өзек нинди әсәрдән? («Гайфи бабай, өйлән давай!»)

4.  Җырчының исем фамилиясен әйтегез.

(Салават Фәтхетдинов)

5. Бу җырның исемен әйтегез?

Туган җирем, үскән җирем —

Гади генә бер авыл.

Гади булса да, яз җиткәч,

Гөл бакчасы була ул. (Туган авылым урамы)

6.  Бу җырчының исем фамилиясен әйтегез. (Әлфия Авзалова)

7. “Аерылмагыз” җырын җырлагыз. (https://www.youtube.com/watch?v=A1M6Q0QuZAk&t=36s караоке)

8.  Бу кем? (Зөһрә Шәрифуллина)

9. Шагыйрә туган авылны әйтегез. (Иске Теләнче)

10. Гөлшат Зәйнашева Казанда укыган институт ничек атала? (Казан дәүләт педагогия институты)

11. 1 Бу шигырь юлларының исемен әйтергә кирәк.

Котлап сине туган көнеңдә

Алтын кояш сибә нурларын.

Кояш балкыган язгы иртәдәй,

Якты булсын, якты булсын

Тормыш юлларың. (Туган көн вальсы)

12. Кызганыч! Баллар саны 10га кими. Уен икенче командага күчә.

13. Гөлшат апа Минзәләнең Югары Тәкермән авылында яшиме? (әйе)

14. Бәхет елмайды! Өстәмә 10 балл! Уенны икенче команда дәвам итә.

15. Бәхетле очрак! Өстәмә 10 бал! Уен күчә.

16. Г.Зәйнашева хезмәт юлын кайсы эшчәнлектән башлый? (Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире)

17. Җидееллык мәктәпне кайда тәмамлый? (Хуҗамәт авылында)

18. Бу юллар кайсы шигырьдән?

Сөйгән ярың кем, дисәгез,

Гади генә бер кеше.

Гармун уйнау, баян уйнау —

Аның бар белгән эше. (Син — гармунчы, мин — җырчы)

19.  Бу җырчы да Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган җырларны башкара. Кем ул? (Фирдүс Тямаев)

20. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә Мәсгут Имашев көй язган “Кукмара” җырын җырлагыз. (https://www.youtube.com/watch?v=keJYriA-NqI караоке)

21. Кайда педагогия училище тәмамлый? (Минзәләдә)

22. 1958 нче елда чыккан беренче китабы ничек атала? (Тыңларсыңмы җырларымны?)

23. «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем нинди хезмәтләре өчен бирелә? (Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен)

24. Бу шигырь юлларының исемен әйтегез әле.

— Әйдәгез дусларым, җырлыйк бергә,

Иң матур җырларны сайлап кына.

Иң матур җырларны сайлап кына,

Яшик бу дөньяда сайрап кына.. (Әйдәгез, дусларым, җырлыйк бергә)

25. «Илле җыр» китабы өчен нәрсә белән бүләкләнә? (Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе)

26. Гөлшат апа Зәйнашева сүзләренә язылган тагын бер җырны җырларга тәкъдим итәм. Ул җыр “Кердем карурманнарга”. Сез әзерме? (https://www.youtube.com/watch?v=oSo-gPP0wco караоке)

27. Гөлшат Зәйнашева шигырьләр генә язып калмаган, ул сәхнә әсәрләре дә иҗат иткән. Сәхнәдә уйнау өчен язылган әсәр жанры ничек атала? (Драма)

28. Көлкеле әсәрнең бер төре. (Сатира)

29. Гөлшат апа Зәйнашева ничәнче елда вафат була? (1 апрель 2005 ел)

30. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме кайчан бирелә? (1988 елда)

31. «Рамай», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрләренең кайсы Г.Зәйнашеваныкы түгел? («Әлдермештән Әлмәндәр»)

32.  Бу легендар җырчыны таныгыз. (Илһам Шакиров)

33. Их! Гомуми баллдан 5не алабыз! Уен алдагы командага күчә.

34.  Бу бөек шәхес кем? (Хәмдүнә Тимергалиева)

35. Әлеге шигырь юлларының исемен әйтегез.

Эштә үткәндер көнегез,

Ямьле булсын кичегез.

Ай сокланып йөрсен күктә,

Күңелле ял итегез. (Күңелле ял итегез)

Уенга йомгак ясала. Җинүчеләр бүләкләнә.

- Без сезнең белән сөекле шагыйрәбез, популяр җырлар авторы Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына кыскача күзәтү ясадык. Чыннан да, Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты сокланырлык. Ул татар халкына нинди зур, үлемсез мирас калдырып китте. Кичәбез ахырына якынлашты. Саубулыгыз.

**Гөлшат Зәйнашева «Йокла, куяным!»**

(Функциональ грамоталылык, уку грамоталылыгы)

Хабибуллина Гөлнара Флорис кызы

Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе филиалы –

“Юлтимер төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат.1.Г.Зәйнашеваның “Йокла, куяным” шигыре белән, татар халык авыз иҗатының бер жанры булган – җырлар һәм бишек җырлары жанры белән танышу.

2.Тема буенча белгәннәрне гомумиләштерү, ныгыту, системалаштыру. Укучыларда уку грамоталылыгын һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү, иҗади эш алымнары белән танышу.

3.Г.Зәйнашеваның иҗатына кызыксыну уяту. Җырлырны һәм бишек җырларын укыганда, тыңлаганда укучыларның акылын, хисләрен үстерү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

- шәхес буларак УУЭ: татар халык авыз иҗатының бер жанры -бишек җырлары белән таныштыру, үзара дуслык, өлкәннәргә хөрмәт хисләре тәрбияләү,
- коммуникатив УУЭ: информация табу, иптәшләре белән бергә эшли белү, тикшерү, үз фикерен тулы әйтә белү
- регулятив (көйләгеч) УУЭ: әлегәчә белгән һәм белмәгән күнекмәләрне үзара бәйли белү, конфликтны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү
- танып-белү УУЭ: сорауларга тулы җавап бирә белү, предметара бәйләнешләрне кулланып, кирәкле информация туплау, язучы тормыш юлы турында белемнәрен арттыру, шәхси батырлык үрнәген аңлауга ирешү, эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль таба белү.

Җиһазлау: Г.Зәйнашеваның портреты, китаплар күргәзмәсе, презентация, аудиоязма “Йокла, куяным!”.

Эшчәнлек барышы.

Оештыру.

-Хәерле көн, укучылар. Чираттагы дәрестән тыш эшчәнлекне башлыйбыз. Мин сезгә бүгенге шөгыльдә тел ачкычы, аң-зиһен, акыллы, матур җаваплар бирүегезне, яхшы кәеф телим.

Белемнәрне актуальләштерү:

-Татар халык авыз иҗаты әсәрләренең нинди төрләре сезгә таныш?

(Мәкаль, әкият, табышмак, халык җырлары.)

-Халык җырлары турында сез нәрсә әйтә аласыз? (балар фикере тыңланыла).

-Халык җырлары – ул безенң бабаларыбыз тарафыннан калдырылган мирас. Ул халкыбызның күңелен сурәтли. Халык элек-электән сөенеч булса да, күңеленә авыр булса да җырлаган. Ул үзенең бар моңын шушы җырларда күрсәткән.





- Сез бу рәсемнәрдә нинди татар халык авыз иҗатын күрәсез? (бишек җыры).

- Бишек җырларын кайчан җырлыйлар? (баланы йоклатканда).

- Ә бишек җырларын кем җырлый? (әниләр, әбиләр, бала караучылар).

- Җырны ничек җырлыйлар? (салмак итеп, моңлы итеп).

- Татар язучыларыннан кемнәр бишек җырларын язган? (Габдулла Тукай, Муса Җәлил).

- Балалар, бишек җырлары да бик борынгыдан килгән татар халык авыз иҗаты. Бишек җырын җырлаганда ана үзенең баласына булган мәхәббәтен күрсәткән.

Яңа материалны өйрәнү.

- Балалар, безнең үзебезнең якташ шагыйрәбез Гөлшат апа Зәйнашева иҗаты белән танышырбыз.

Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Гөлшат апаның бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә. 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия

институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып, аны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлап чыккач, Г.Зәйнашева хезмәт юлын башлый.

Г.Зәйнашева – популяр җырлар авторы. Аның лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре дә нәкъ менә шул жанрда ныграк ачыла. Моның сәбәбе – моңлы ятимлек, яшьтән үк татар әдәбиятын ярату, мәктәптә укыганда ук җыр язарга омтылу. Аның җыр булып киткән шигырьләре күп: “Туган җирем – Татарстан”, “Үз илемдә”, “Җырлыйм әнием турында” һәм башкалар. Гөлшат апа бик матур бишек җыры да иҗат иткән.

Бирелгән рәсемне карыйк әле. Сез бу рәсем буенча ниләр әйтә аласыз? Текст төзеп карыйк әле. (Балаларның фикерләре тыңланыла).



Физминутка.
Куян килгән урманнан,
Ерак диеп тормаган.
Уйный балалар белән,
Колакларын селкетә,
Сикергәләп тә китә,
Сикерәләр балалар,
Аннары кул чабалар.
Дәрес темасын өйрәнүне дәвам итү.

Ә хәзер мин сезгә Гөлшат апа Зәйнашеваның “Йокла, куяным!” дип исемләнгән шигырен укырга тәкъдим итәм. (Укучыларга аудиоязмада җырны тыңлату. Аннан соң балалар чылбыр рәвешендә укыйлар).

Иң яраткан уенчыгым,
Ап-ак йомшак куяным.
Көне буе уйнасам да,
Бер дә синнән туймадым.
Ай калыкты, төн җитте,
Йоклыйк инде, куяным.
Үз яныма сиңа да
Урын җәеп куямын.
Уенчыкларым күп минем,
Төлкем дә бар, аю да.
Аю баласы тәгәрәп
Йоклый кояш баюга.
Ай калыкты, төн җитте,
Йоклыйк инде, куяным.
Үз яныма сиңа да
Урын җәеп куямын.
Аю, төлке, бүре, керпе, —
Барчасы йоклап киткән.
Бишек җыры җырлый, әнә,

Йолдызлар зәңгәр күктән.
Ай калыкты, төн җитте,
Йоклыйк инде, куяным.
Үз яныма сиңа да
Урын җәеп куямын.
- Шагыйрәнең шигыре сез төзегән текст белән туры килдеме?
- Нинди туры килгән җирләре очрады? Кайсы җирләре икенче төрле иде?
- Баланың нинди уенчыклары бар?
- Иң яратканы нинди уенчык?
- Ул нинди төстә?
- Кояш баюга кайсы уенчыгы тәгәрәп йоклый?
- Куянга нәрсәләр бишек җырын җырлый?
- Бала ничек итеп җырлый?
- Куян нигә озак йоклый алмый икән?
Өйрәнгән материалны ныгыту.

Ә сезнең нинди яраткан уенчыгыгыз бар? Үзегезнең яраткан уенчыгыгызны сез йокларга яткызасызмы? Аңа бишек җырын ничек итеп җырлар идегез? (балаларга җырлатып карау).

Йомгаклау.

- Җыр – кешенең балачагыннан алып соңгы гомеренә кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ул нечкә күңелле, мәрхәмәтле була. Ә нечкә күңелле, матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул кешеләрне ярата, чит җирләрдә яшәгәндә дә туган ягын сагынып яши, йомшак бәгырьле, кешеләргә ярдәмчел, мәрхәмәтле була. Ә бишек җырлары – дөньядагы иң татлы, иң ләззәтле җырлар ул. Чөнки без бишектә ятканда ук ул җырларны ишетеп, күңелебезгә сеңдереп үсәбез. Әнкәбезнең ягымлы тавышы белән халкыбызның милли моңнары безнең күңелләребезне эретә. Бишек җырлары һәркемгә кадерле, чөнки алар балачакны хәтерләтә.

- Шушының белән шөгылебезне тәмамлыйбыз. Барыгызга да катнашуыгыз өчен зур рәхмәт.

## Гөлшат Зәйнәшеваның тормышы һәм иҗаты

Шәйдуллина Айгөл,
Алабуга шәһәренең 1 гимназия укытучысы, Алабуга районы

Максат: Бер-берсен тыңларга өйрәтү, китапханәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искәртү, Гөлшат Зәйнәшева иҗатына кызыксыну уяту.

Җиһазлау: дәреслек, таратма материаллар, презентация

I.Оештыру өлеше. Мотивлаштыру.

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек?

Укучылар. Безнен кәеф яхшы!

Укытучы. Укучылар, мин сезнең өчен бик шат! Дәресебез кызыклы, нәтиҗәле булыр дигән теләктә калам.

II.Актуальләштерү.

Бүген без сезнең белән бик күп белемнәр тупланган “Тылсымлы китапханә” гә юл тотырбыз. Тик аның менә ишекләре бикле. Алга таба үтү өчен, безгә ачкычларны йозакка

туры китерергә кирәк. Укучылар, безгә “Буталган иҗекләр” уены тәкъдим ителә. Әлеге китапханәдә танышачак бүгенге язучыбызның исемен белү өчен, сезгә хәрефләрне дөрес тәртиптә урнаштырып, язучының исемен ачыкларга кирәк.

Укучылар, нинди сүз төзедегез? (Гөлшат Зәйнәшева)

Белемнәр туплар өчен, юлыбыз ачылды. Ә безне яңа белемнәр алырга өндәп, китапханәче каршы ала.

III. Төп өлеш.

Инде бергәләп китапханә түренә узыйк. Безне монда китапханәдә үз үзеңне тоту кагыйдәләре каршы ала.

1.Сез китапханәгә керү белән, исәнләшегез

2. Китапханәчене тыңлагыз, аны борчымагыз.

3. Китапларны ертмагыз, аларны саклагыз.

4.Сезгә бирелгән китапны вакытында тапшырыгыз.

Китапханәче (видеоязма). Исәнмесез, китап сөючеләр. Без сезне бүген якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнәшеваның тормышы һәм иҗаты белән танышырга чакырабыз.

Язучыбыз Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның хәзерге Тукай районы Иске Теләнче авылында дөньяга килә. Ул үзенең балачагы турында “бала чакта бәхетем бишегеннән егылып төшкәнмен” дип әйтә торган була. 1930 елда, колхозлашу елларында, Г.Зәйнашеваның әтисе Хисам абыйны, кулак исеме тагып, Архангельск өлкәсендәге Соловки лагерына сөрәләр. Берсеннән-берсе кечкенә биш бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган Әнвәр апа ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы – Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Матур табигатьле бу авыл, балачак хатирәсе булып, Гөлшат Зәйнашева күңелендә гомерлек эз калдыра.Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган. «Илле җыр» исемле китабына җыр сүзләре тупланган.

Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аны, шаяртып, “татарның җыр сандыгы” дип тә атыйлар. Туган җиренең бөтен табигатен, гүзәллеген, үз җаны аша үткәреп, халкына бүләк иткән шагыйрә ул.

2 нче китапханәче: Сезгә Г. Зәйнашеваның түбәндәге китапларын тәкъдим итәм. (Китап күргәзмәсе белән таныштыра). Нәниләргә һәм кече яшьтәге балаларга атап язган шигырьләре һәм җырлары шагыйрәнең «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) исемле китапларында урын алган. «Илле җыр» исемле китабына җыр сүзләре тупланган.

Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат иткән язучы. Аны, шаяртып, “татарның җыр сандыгы” дип тә атыйлар. Туган җиренең бөтен табигатен, гүзәллеген, үз җаны аша үткәреп, халкына бүләк иткән шагыйрә ул. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрәнең йөзгә якын шигыренә көй язылган, алар халык арасында киң таралган: (экраннан укып танышалар):

«Туган жирем – Татарстан» (А.Ключарев музыкасы), «Китмә, сандугач» (Р.Яхин музыкасы), «Менәргә иде Урал тауларына» (М.Мозаффаров музыкасы), «Үз илемдә» (С.Садыйкова музыкасы), «Зәңгәр төймә» (халык көе), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин музыкасы), «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Б.Гайсин музыкасы), «Кояш

гомере» (Ф.Әхмәдиев музыкасы), «Аерылмагыз» (Ч.Зиннәтуллина музыкасы), «Туган авылым урамы» (Г.Сәйфуллин музыкасы)

Укытучы: Китапханәчеләргә сорауларыгыз бармы?

IV.Белемнәрне кабатлау.

- 1928 елның 13 гыйнварында Тукай районы Иске Teләнче авылында туа
- 1930 елдан Минзәлә районына Югары Тәкермән авылында яши, укый, Хуҗамәт авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый
- 1941-1945 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый
- 1945-1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый
- Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире
- Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир
- Радиокомитетта музыкаль тапшырулар мөхәррире
- Г.Тукай исемендәге клуб директоры
- Беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре һәм бер пәрдәле пьесалары «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада», «Клуб сәхнәсе» җыентыкларында басыла
- «Рамай» исемле беренче зур күләмле пьесасы бик күп халык театрлары сәхнәләрендә куела
- 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исеме белән беренче шигырьләр китабы дөнья күрә
- «Илле җыр» исемле китабы өчен 1991 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе тапшырыла
- Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә
- 2005 елның 1 апрелендә Казанда вафат була
- СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Укытучы: Хәзер хәтерегезне тестлар ярдәмендә тишереп карагыз:

1. Г.Зәйнашеваның туган авылы:

1) Тукай районы Иске Теләнче авылы

2) Минзәлә районының Югары Тәкермән авылы

3) Минзәлә шәһәре.

2. Г.Зәйнашева кайсы уку йортында укымаган?

1) Минзәлә шәһәре гимназиясендә

2) Минзәлә педагогия училищесында

3) Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә.

3. Г.Зәйнашева хезмәт юлын кайсы эшчәнлектән башлый?

1) Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире булып

2) Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры

3) профессионал язучы.

4. «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем нинди хезмәтләре өчен бирелә?

1) татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен

2) сәхнә әсәрләре өчен

3) тәрҗемә эше өчен.

5. Авторы Г.Зәйнашеваныкы булмаган сәхнә әсәрләрен билгеләргә:

1) «Рамай»

2) «Язмышлар һәм ялгышлар»

3) «Әлдермештән Әлмәндәр».

6. Г.Зәйнашеваның кайсы сәхнә әсәре Минзәлә театры тарафыннан куелмаган?

1) «Рамай»

2) «Язмышлар һәм ялгышлар»

3) «Гайфи бабай, өйлән давай».

7. «Илле җыр» исемле китабы өчен Г.Зәйнашева нинди бүләккә лаек була?

1) Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә

2) СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы

3) Рәшит Гәрәй бүләге.

Тикшерү.Үзбәя.

V. Ял вакыты.

Укучылар, әйдәгез әлеге китапханәдә ял бүлмәсе дә бар,әйдәгез әле бергәләп кереп ял итеп чыгыйк.

Бәяләү.

VI. Рефлексия. “Төсле тасмалар” алымы. Укучылар,әйдәгез инде хәзер үзебезгә дәрес барышында ничек эшләвебезгә карап,билгеләр куйык.

Кызыл тасмалар - нинди сүз төркеме белән таныштык? Зәңгәр тасмалар - дәрестә нинди яңа белемнәр алдык? Сары тасмалар - миңа дәрестә нәрсә кызыклы булды? Яшел тасмалар- дәреснең кайсы өлеше сездә авырлык тудырды? Дигән сорауларга җавап бирик әле.

Гомуми белемнәрне бәяләү.

Өй эше. Көндәлекләрегезнең соңгы битендә сезгә һәрвакыттагыча 3 дәрәҗәдә өй эше тәкъдим итәм.

1. Г.Зәйнашева шигырьләренә карата ирекле рәсем ясарга.

2. Г.Зәйнашева иҗаты буенча инша язарга.

3. Көлкеле шигырьләр иҗат итәргә.

Укучылар, без сезнең белән бүген китапханәдә кунакта булдык, Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатын өйрәндек. Инде дәресебез тәмам,чыгарга мөмкин.

**Гөлшат Зәйнашева «Кем булырга?» шигыре**

Измайлова Гөлназ Фарис кызы,

Киров районы 182 нче политехник лицей, Казан шәһәре

Максат: 1. Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, «Кем булырга?» шигырен өйрәнү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү;

2. Һөнәр сайларга әзерләү;

3. Тормышта үз урыныңны, үз һөнәреңне, аңа ирешү юлларын табарга өйрәтү.

Бурыч: Гөлшат Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында балаларның белемнәрен уен формасында гомумиләштерү һәм системалаштыру. Команда белән эшләгәндә хезмәттәшлек күнекмәләрен камилләштерү. Актив фикерләү эше белән бәйле репродуктив эшчәнлек үсешенә ярдәм итү: аргументлау, анализлау, классификацияләү, гомумиләштерү сәләте. Китапка кызыксыну уяту. Китапларга сакчыл караш тәрбияләү.

Дәрес тибы: яңа белемнәрне үзләштерү

Ресурслар: проектор, экран, Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?” шигыре, Г.Зәйнашеваның тормышы һәм иҗаты турында презентация, видеоролик.

| **Вакыт** | **Дәрес этабы** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** |
|---|---|---|---|
| 1 мин | I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру | Дәресне оештыру<br>Исәнләшү. Кәефләрне белешү. Психологик уңай халәт булдыру.<br>Күтәренке кәеф белән<br>Дәресебезне башлыйбыз!<br>Укучылар! Бер-берегезгә карагыз әле, матур итеп елмаегыз, хәерле көн теләгез. | Тыңлау |
| 2 мин<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>10 мин | 2.Актуальләштерү.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>3.Уку мәсьәләсен кую. | Бүген без эшне төркемнәрдә оештырабыз. Төркемдә эшләү кагыйдәләрен искә тошерик әле.<br>- Барлык биремнәрне бергә киңәшләшеп эшлисез;<br>- Үзегезнең командирны сайлагыз.<br><br>(Слайд һөнәр рәсемнәре)<br><br>Рәсемнәргә карагыз, әле, сез кемнәрне күрәсез? *(укытучы, чәчтараш, төзүче, тегүче, табиб,, сатучы, пешекче, очучы)*<br>Бер сүз белән аларны ничек берләштерергә була? (*Болар –һөнәрләр)*<br>Нәрсә соң ул һөнәр? (Слайд)<br>Халыкта мондый мәкаль бар: Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс. *Һөнәр – ул нәрсә дә булса җитештерү, ясау өчен осталык.*<br><br>Һөнәрләр безнең бик күп. Илебездә 40 меңләп һөнәр барлыгы билгеле. Бу санны сез әле күз алдына да кирә алмыйсыз<br>1.Хәзер тактага карагыз. «Кем булырга?» ролик карау. (Слайд ролик карау)<br><br>- Укучылар сез үскәч, кем булырга телисез? Сезнең уйланганыгыз бармы?<br>- Роликта нәрсә турында сүз бара? *Һөнәр сайлау турында.*<br>- Дөрес. Әйдәгез уйлап карыйк әле, язучылар, шагыйрьләр һөнәрләр турында әсәрләр язалармы? *Язалар.* | Тыңлау<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Сорауларга җавап бирәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - Бүген без танышачак шагыйрә дә һөнәр сайлау турында язган. Тактага карагыз, бу кем портреты?<br>( Слайд Гөлшат Зәйнашева портреты)<br>- Бүген без сезнең белән гаҗәеп кеше, талантлы язучы турында сөйләшербез. Аның китапларын балалар бик яратып укыйлар.<br>- Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашева 100ләгән шигырьләр авторы. Ләкин ул бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә.<br>- Ә бүген без Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?” шигыре аркылы төрле һөнәрләр белән танышырбыз. | |
| 8 мин<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>3 мин | II.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү. | - Әйдәгез, хәзер укучылар шагыйрәнең кыскача тормыш юлы белән танышыгыз. Сезнең алдыгызда шагыйрәнең тормыш юлы турында текст. Әйдәгез укып чыгыгыз һәм сорауларга җавап бирегез. (Слайд)<br>- Шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Тукай (элекке Сарман) районы Иске Теләнче авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Авыл халкың күмәк хуҗалыкларга көчләп берләштерү чорында, 1930 елда, гаиләләрне кулак сыйфатында авылдан сөргәндә, әти-әниләре, ике яшьлек Гөлшатны өлкәнрәк башка балалары белән берлектә ерак юлга алып чыгарга куркып, аны күршедәге Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында яшәүче, әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясенә биреп калдыралар. Гөлшатның бала чагы шул авылда уза, шунда ул башлангыч мәктәпне, күрше Хуҗамәт авылына йөреп җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары укуын Минзәлә педагогия училищесында дәвам иттерә.<br>- Гөлшат Зәйнашева кайларда эшләгән соң? (Слайд)<br>- Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, аннары унбер елга якын (1952-1963) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1964-1965 елларда ул янәдән радиокомитетта - музыкаль тапшырулар мөхәррире хезмәтендә. 1965-1966 елларда Г.Зәйнашева Татарстан язучыларының Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге клуб директоры, ә 1973 елдан алып 1983 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлеге инспекторы вазифаларын башкара. Шуннан соң ул профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.<br>(Слайд)<br>- Шагыйрә кайчан һәм кайда туа?<br>- Ул кайларда укый?<br>- Ул кайда эшли?<br>- Рәхмәт укучылар, булдырдыгыз.<br>- Ә хәзер, төркемнәрдә эшлибез. Өстәлдә хәрефләр бар, ә сез шул хәрефтән башланган һөнәр исемен әйтегез:<br>1 төркем<br>- А – артист, агроном, архитектор, адвокат<br>- Б – бригадир, баянчы, бетонщик<br>- В – врач<br>- Г – геолог, галим<br>2 төркем<br>- Д – доктор,дережёр<br>- Т – тегүче, теш табибе,төзүче, тракторчы<br>- У – укытучы, умартачы, урманчы<br>- С – сатучы, сварщик, слесарь, сыер савучы | Сорауларга җавап бирәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 мин<br><br>6 мин<br><br>3 мин | | - Ә хәзер Г.Зәйнашеваның «Кем булырга?» шигыре белән танышыйк.<br><br>- Укучылар шигырьнең исемен укыгыз әле. Шигырь нәрсә турында булыр икән? *Кеше узенә һөнәр эзли, кем булырга дип уйлый.*<br>1) Шигырьне укытучы укый.<br>2) Укучылар үзләре эчтән укый.<br>3) Шигырьне кычкырып, ярым тавыш белән укыйлар.<br><br>- Укучылар сезгә шигырь ошадымы?<br>- Нәрсәсе белән ошады?<br>- Малайга киңәшне кемнәр бирә?<br>- Малайга нинди киңәшләр бирәләр?<br>- Яхшы, булдырдыгыз. Әөдәгез хзер төркемнәрдә эшләп алырбыз 1нче төркем беренче сигез юлда нинди һөнәрләр ишеттегез? һөнәр исемнәрен языгыз (*баянчы, артист, шофер).*<br>2 нче торкем шигырьнең калган өлешендә ишеткән һөнәр исемнәрен языгыз. *(Табиб , сатучы)*<br><br>- Үрнәк буенча парлап сөйләшү. ( 15 слайд)<br>- Син кем булырга телисең?<br>- Мин ...... булырга телим.<br>- Ни өчен?<br>- Миңа бу һөнәр бик ошый. | |
| 2 мин | III. Рефлексив бәяләү. | 1. Рефлексив кабатлау.<br>-Без бүген дәрестә нәрсәләргә ирештек? (Слайд)<br>Слайдка карагыз әле, тәкъдим ителгән шаблоннарны кулланып, җавап бирегез.<br>Шаблоннар:<br>- Бүген мин дәрестә......белдем.<br>- Бүген мин дәрестә ...... аңладым.<br>- Минем өчен бүген дәрестә җинел булды, чөнки...<br>- Миңа дәрестә авыр булды, чөнки.....<br>-Укучылар бүгенге дәрестә актив булдыгыз, барыгызга да бик зур рәхмәт. | |
| 1 мин | IV Өй эше | - Сезгә өй эшенә ике вариант бирелә, кайсын эшләргә үзегез сайлап алырсыз.<br>а) шигырьне сәнгатьле итеп укырга;<br>б) шигырьне ятларга. | |

**Г.Зәйнашева «Бер атнада җиде көн»**

(уку дәресе)

Исламова Халидә Абдулла кызы, Галләмова Ләйсән Илдус кызы,

Яңа Савин районының 23 нче лицее, Казан шәһәре

| | |
|---|---|
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы:** үз вакытыңны дөрес һәм файдалы итеп оештыра белү<br>**Метапредмет:**<br>*Танып-белү УУГ:* тыңлап аңлау, аңлап уку, нәтиҗә чыгара һәм гомумиләштерүләр ясый белү<br><br>*Коммуникатив УУГ:* сорауларга җавап бирә алу, төгәл һәм дөрес итеп фикерләрне җиткерә белү<br><br>*Регулятив УУГ:* уку мәсьәләсен куя белү, эшне планлаштыру, үзбәя<br><br>**Предмет буенча:**“ Бер атнада җиде көн” шигыренең эчтәлеген белү, шагыйрә турында кыскача мәгълүматлы булу. |
| **Дәреснең тибы** | Яңа теманы өйрәнү дәресе |
| **Төп төшенчәләр** | Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе |
| **Предметара бәй-ш** | Уку дәресе |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемдә, парларда |
| **Чыганаклар** | 1.“Күңелле татар теле”: рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе 4 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус балалары өчен), Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013 |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **Оештыру Мотивлаштыру (1-2 мин)** | -Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн.<br>Хәлләрегез ничек?<br>Сыйныфта кем дежур?<br>Бүген кем юк?Әйдәгез, дәресне башлап җибәрик!<br>-Дәрескә барыгыз да әзерме? | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр, сорауларга җавап бирәләр, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар)<br>*-Исәнмесез, укытучы апа. Хәерле көн. Бүген дәрестә барысы да бар* | Шәхескә кагылышлы: татар телен өйрәнүгә ихтирамлы карашта булу.<br>Танып-белү: тыңлап аңлау, нәтиҗә чыгара алу<br>Коммуникатив: укытучы һәм сыйныфташларың белән теләктәшлек булдыру.<br>Регулятив: эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **Белемнәрне актуальләштерү** | Өй эшен тикшерү, сорауларга җавап алу: хәзер нинди ел фасылы?Кыштан соң (яздан соң...) нинди ел фасылы?Димәк, ничә ел фасылы бар?Һәр ел фасылы ничэ ай була? Хәзер кышның ничэнче ае? Бүген атнаның нинди көне?Кич нинди көн иде? Ә иртәгә? | Ел фасылларын күрсәткән презентациягә карап сорауларга җавап бирәләр. | Шәхескә кагылышлы: фикерләү сәләтен үстерү.<br>Танып-белү: сорауларга аңлап, дөрес җавап белү.<br>Коммуникатив: күмәк эшли белү.<br>Регулятив: җаваплпрны дөресли белү. |
| **Уку мәсьәләсен кую** | Уку мәсьәләсен билгеләтү.<br>Һәр сабакта 7 яфрак җөмләсен тәрҗемә итү. Димәк, без дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез?Атна көннәре турында шигырь дә укырбыз. | Слайдта табышмак: 1 агач, 12 ботак, һәр ботакта 4 сабак, һәр сабакта 7 яфрак. Табышмакның җавабын эзләп табалар. | Регулятив: фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, планлаштыру.<br>Танып-белү: танып-белү мәсьәләсен аңлау, кирәкле информацияне таба белү. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү** | 1. Шигырь өстендә эш;<br>а) шигырьне аудиоязмада тыңлау;<br>ә) шигырьне эчтән уку;<br>б) фонетик күнегү: төрле, яттан, онытма, мәңге, көннәре;<br>в) сүзлек эше (төрле, җидесен, яттан, мәңге, онытма, димәк, калган) ;<br>г) шул сүзләр кергән җөмләләрне, сүзтезмәләрне табып тәрҗемә итү.<br>д) шигырьне тагын бер кат (кычкырып) уку;<br>г) сорауларга җавап бирү:<br>2. Сорауларга җавап бирү:<br>а) шигырьдә ничә строфа (юл)?<br>ә) шигырьне кем язган?<br><br>б) бу шагыйрә сезгә танышмы? Аның турында кайда белергә була? | Укытучы күрсәтмәләре белән эшлиләр<br><br>Слайдта бирелгән сүзләрне тәрҗемә итеп укыйлар<br><br>Сорауларга җавап бирәләр<br><br>Шигырьнең авторы турында мәгълүматлар алалар.<br>Слайдта: Г.Зәйнашеваның портреты, аның | Шәхескә кагылышлы: үз вакытыңны дөрес һәм файдалы итеп оештыра белү.<br>Танып-белү: шигырьне тыңлап аңлау, уку, шигырьдән кирәкле информацияне эзләп табу,тема буенча лексик берәмлекләрне белү.<br>Коммуникатив: сорауларга җавап бирү, фикерләрне дөрес һәм төгәл итеп җиткерү.<br>Регулятив: эш тәртибен аңлап, мөстәкыйль эшли белү.<br>Предмет буенча: Г. Зәйнашева турында мәгълүматлы булу, “Бер атнада җиде көн” шигыренең эчтәлегенә төшенү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | в) атнаның кайсы көннәре ял көннәре? Автор аларны атнаның нәрсәләре дип әйтә?Җавап ничәнче юлда? Ни өчен шулай ди?<br>г) калганнары нинди көннәр? Автор аларны атнаның нәрсәләре дип әйтә? Җавап ничәнче строфада , ничәнче юлда? Ни өчен шулай әйтә?<br>д) шагыйрә сезгә нинди киңәш бирә? Җавап ничәнче строфада, ничәнче юлда?<br>е) Атна көннәрен белү ни өчен кирәк?<br>3. Шигырьне сәнгатьле итеп (строфалап уку) | балалар өчен чыккан китаплары.<br>Сорауларга җавап бирәләр.<br><br>Сорауларга җавап ны шигырьдән табып укыйлар. | Танып-белү: укылган тексттан кирәкле информацияне табып әйтә белү, аңлап укый белү.<br>Коммуникатив: үз фикереңне тәгъбир итә белү.<br>Регулятив: үзеңә максат куя һәм бурычларны билгели белү. |
| **Ял минуты** | Матур сүзләр уйладык<br>Ял итәргә туктадык.<br>Җилкәләрне турайттык,<br>Тирән итеп суладык,<br>Башны як-якка бордык,<br>Чүгәләдек һәм тордык,<br>Бер урында йөгердек,<br>Аннары соң сикердек.<br>Сузылдык –киерелдек.<br>Югарыга үрелдек.<br>Соңыннан тынычланып<br>Дәресне дәвам итик. | | Шәхескә кагылышлы: коллективта үзеңне контрольдә тоту. |
| **Яңа теманы ныгыту***(Яңа белемнәрне беренчел ныгыту)* | 1.Атна көннәрен тәртип буенча әйтү.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>2.Дәфтәрләрдә эшләү. Бирелгән хәрефләрдн атнадагы көн исемнәрен төзеп, тәртип буенча язу.<br><br>3 7 саны турында мәгълүмат бирү:<br>-Ни өчен атнада 7 көн? 6 яки 8 түгел?<br>-җиде саны белән аталган әйберләр әйберләр бармы? Сез беләсезме? | 1. Укучылар атна көннәре язылган карточкалары белән тәртип буенча тезелеп басалар һәм әйтәләр. (Дүшәмбе атнаның беренче көне...)<br>2..Слайдта:<br>Ә-и-с-ш-м-б,<br>Г-о-җ-м-а,<br>Б-м-и-ш-ә,<br>Ш-м-ә-ү-б-е-д,<br>Ч-ш-е-м-ә-ә-р-б,<br>М-б-е-п-ә-н-ш-е-ә-ж.<br>Я, ш, б, е, м, к, ә- онытма мәңге!<br><br><br><br>- Слайдта :<br>- Салават күперенең 7 төсе;<br>- әкияттә 7 кәҗә бәтие; | Шәхескә кагылышлы:фәнне яхшы өйрәнү теләге тудыру.<br>Танып-белү: белемнәрне тәртипкә салу, аңлап, сөйләмә һәм язма формада күрсәтү, мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр чыгара белү.<br>Коммуникатив: үз фикернеңне ачык һәм төгәл итеп җиткерә һәм дәлилли белү.<br>Регулятив: ихтыяр көче, активлык кебек сәләтләрне үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -Әле 7 саны кергән мәкальләр дә бар.<br><br>7.-дөньяда иң буталчык сан (запутанное число) 7-нәрсәнеңдер гадәти булмаганын яки гадәтән тыш икәнен күрсәткәндә кулланыла торган сан.<br><br>4.Атна көннәренең тәртибен белү, кирәклеген аңлау өчен сораулар бирү.<br>-Атнаның икенче көне чәршәмбеме? Чәршәмбе көнне ничә дәрес була?<br>-Ә җомга көнне ничә дәрес? Җомга атнаның ничәнче көне?<br>Бүген рус теле дәресе буламы? Ә бүген нинди көн? Рус теле дәресе тагын нинди көннәрдә була?<br>-Атна көн тәртибен белү кирәкме?<br><br>5.Ситуатив күнегүләр тәкъдим итү<br>- спроси у друга сколько уроков будет во вторник?<br>- будет ли урок чтения в четверг?<br>-какие уроки будут в субботу?<br>- воскресенье что ты делаешь? Как помогаешь своим родителям?<br>- сколько уроков будет в понедельник? | - Музыкада 7 нота;<br>- Дөньяда 7 могҗиза.<br>Мәкальләр<br>-7 кат үлчә. 1 кат кис;<br>- Дустыңнан аерылган 7 ел елар. Иленнән аерылган гомер буе елар.<br>- 7 йортның телен бел. 7 төрле белем бел.<br><br>Укучылар тулы итеп җавап бирәләр.<br><br>Укучылар җөмләләрне тәрҗемә итеп, сораулар бирәләр, сыйныфташлары җавап бирә.<br><br>Слайдта:<br>Атна көннәре:<br>Дүшәмбе-хоккей; | Шәхескә кагылышлы: иптәшләрең белән яхшы мөнәсәбәттә булырга тырышу.<br>Танып-белү: нәтиҗәләр ясый, төп фикерне билгели белү.<br>Регулятив: җавапларны дөресли һәм бәяли белү.<br>Коммуникатив: тыңлый һәм сорауларга җавап белү.<br><br>Шәхескә кагылышлы: Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү.<br>Танып-белү: кирәкле информацияне җиткерә белү.<br>Коммуникатив: парларда эшли белү.<br>Регулятив: уку эшчәнлеген контрольгә ала белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6. Таблица өстендә эшләү.<br>-Син атна дәвамында нинди түгәрәкләргә барасың?<br>-Сез спорт түгәрәкләренә йөрисез. Димәк, спортны яратасыз. Спорт белән шөгыльләнгән балалар сәламәт һәм матур була. | Сишәмбе-туризм;<br>Чәршәмбе-бассейн;<br>Пәнҗешәмбе-Футбол;<br>Җомга-каратэ;<br>Шимбә-көрәш;<br>Якшәмбе-<br>Укучылар җөмләләр төзеп әйтәләр (Мин дүшәмбе көнне хоккейга барам) | Шәхескә кагылышлы: әңгәмәдәшнең фикерен тыңлый белү.<br>Танып-белү: җавапны сөйләмә формада аңлап оештыра белү.<br>Регулятив: үрнәк буенча эш итә белү.<br>Коммуникатив: үз фикереңне туры һәм төгәл итеп әйтә белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Өйгә эш бирү** | Өй эше биремен аңлату:<br>а) шигырьне сәнгатьле укырга;<br>ә) атна көннәре исемнәре белән сорау җөмләләр төзергә;<br>б) календарь белән эшләргә: бәйрәмнәр кайсы көннәрдә була? ( мәсәлән: 8 март чәршәмбедә була) | Өй эше биременең аңлашылып бетмәгән өлешен ачыклыйлар. | Танып-белү: биремне аңлау.<br>Регулятив: эшчәнлекне оештыра белү, планлаштыру, дифференциацияләнгән биремне аңлау. |
| **Рефлексия** | Дәрескә нәтиҗә ясау:<br>-без бүген нәрсәләр турында сөйләштек? Аларның тәртибен белү кирәкме? Ни өчен?<br>-Дәрестә нинди яңалыклар белдегез?<br>-Тагын нәрсәләр эшләдек?<br>Шигырьнең исеме , авторы исегездә калдымы?<br>2. Укучыларның белемнәрен бәяләү. | Укучылар әңгәмәдә катнашалар . Үзләренең сыйныфташларының җавапларын бәялиләр. | Шәхескә кагылышлы: үз вакытыңны дөрес һәм файдалы итеп оештыра белү.<br>Коммуникатив: диалогта катнашу, фикерләрне дәлилле итеп җиткерү.<br>Регулятив: үз эшчәнлеген бәяли белү, үзбәя. |

**Эчтәлек**

**Тыңларсыңмы җырларымны**

(Г.Зәйнәшеваның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби – музыкаль кичә)

Шәфигуллина Лилия Әгъзәм кызы, Арча 7 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Арча муниципаль районы ....................................................................................3

**Җырга багышланган гомер**

(Чара эшкәртмәсе)

Габдрахманова Гөлназ Расит кызы, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ....................................................................................5

**Туган ягым – гөлләр иле**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗатына багышланган әдәби музыкаль кичә)

Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы, Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы, Адлер Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........................8

**What do you know about Gulshat Zainasheva?- Гөлшат Зәйнәшева иҗаты турында niләр беләсез?**

(Уен-викторина 9–10-х класслар өчен татар әдәбияты һәм инглиз теле дәресе эшкәртмәсе (катнаш дәрес))

Габдрахманова Алина Марсель кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы, Сарман муниципаль районы Фахразиева Наилә Рәис кызы, Чуар-Абдул урта мәктәбе укытучысы, Азнакай муниципаль районы ....................................................................................11

**Гөлшат Зәйнәшева шигырьләренең тематикасы**

Семенова Гөлназ Дон кызы, Җәлил бистәсенең 3 нче санлы «Алёнушка» балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы ....................................................................................17

**Йөрткән сезне язмышлар...**

(Дәрестән тыш чара эшкәртмәсе)

Нуртдинова Раушания Равил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Кәлимуллина Әлфия Нәҗиб кызы, китапханәче, Адлер Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ....................................................................................19

**Гөлшат Зәйнашева эзләре буенча сәяхәт**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган дәрестән тыш чараның план- конспекты)

Сәйфуллина Гөлназ Фирдәвес кызы, Түбән Табын мәктәп-интернатының югары категорияле укытучы-дефектологы, Мөслим районы ....................................................................................26

**Җырларым бар, моңнарым бар йөрәк түремдә...**

(Дәрес-концерт)

Гильфанова Гөлия Рәис кызы, Адлер Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ....................................................................................31

**Сталин культы корбаннары. Сөббух Рәфыйков.**

(Телдән журнал)

Гыйбадуллина Гөлия Марсил кызы, Курса Почмак урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Арча районы ....................................................................................33

**Сыйфат сүз төркемен гомумиләштереп кабатлау. Моңлы халыкның талантлы баласы.**

(6нчы сыйныфның татар төркемендә татар теленнән дәрес конспекты.)

Шайхулова Гөлназ Фаяз кызы, Яңа Кәшер санатор интернат-мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Әлмәт районы.......................................................................................34
**Җырлы-моңлы иҗат иясе – Гөлшат Зәйнәшева**
(Г.Зәйнәшева иҗатын йомгаклау)
Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы, Югары Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Түбән Кама муниципаль районы .......................................40
**Гөлшат Зәйнәшева җырларына нигезләнеп төзелгән Әниләр көненә багышланган кичә**
Гәрәева Миләүшә Равил кызы, Җәлил бистәсенең 3 нче санлы «Алёнушка» балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе, Сарман районы..............................................................................46
**Мин тормышка гашыйк**
(Гөлшат Зәйнәшева тууына 95 ел тулуга багышланган тәрбия сәгате)
Адлер Эльвира Демьяновна, Заһитова Ләйлә Азгаровна, Мәлбагыш урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары, Азнакай районы..................................................51
**Танылган шәхес -Сөббух Рәфыйков**
(яңа белемнәрне ачу дәресе)
Шәфигуллина Гөлгенә Рифкать кызы, Шәүкәт Галиев исемендәге Бакырчы төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Апас муниципаль районы ......................................................................53
**Кулда каләм, телдә фикер...**
(Шагыйрә Гөлшат Зәйнәшевага багышланган әдәби-музыкаль кичә)
Ганиева Алсу Сахиул кызы, Менделеевск шәһәренең Советлар Союзы Герое М. С. Фомин исемендәге 1нче урта мәктәбе, Менделеевск районы ....................................................................61
**Тыңлыйсызмы, мин сөйлимен...**
(Гөлшат Зәйнашева иҗатында халык авыз җәүһәрләре чагылышы. Рус мәктәбенең татар төркеме укучылары өчен дәрестән тыш эшчәнлеккә авторлык программасы)
Салихова Гөлнара Атлас кызы, Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернаты, Әлмәт районы Халык зур, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.Г.Тукай ................................................65
**Шигърият дөньясына сәяхәт**
(Гөлшат Зәйнәшеваның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)
Галиәкбәрова Илмира Мөзәккир кызы, 2 нче санлы "Лилия" балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы ..............................................................................................................................69
**Туган җирем – изге җир**
(Гөлшат Зәйнәшеваның туган көненә багышланган шигырь бәйрәме) Гаскәрова Ләйсән Минифәвис кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы, Сарман районы ...................75
**Гөлшат Зәйнашеваның “Бер атнада ничә көн ?” шигырен уку**
(Мәктәпкә әзерлек төркемендә ана теленнән белем бирү эшчәнлеге)
Афзалова Алия Мөнәвир кызы, Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 1 нче “Каенкай” балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы ..........................................................................77
**Гөлшат Зәйнашеваның иҗат кичәсе**
(Иҗади кичә)
Хакимова Гөлүсә Габдулла кызы, Җәлил бистәсенең 3нче санлы «Аленушка» балалар бакчасының тәрбиячесе, Сарман районы ..............................................................................79
**Сөббух Һади улы Рәфыйковның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган КВН кичәсе**
Гарифуллина Әлфинур Флер кызы, Харисова Илсөяр Мөҗәһит кызы, Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы.................................................81

**Гөлшат Зәйнашева “Кем булырга?”**

( 6 сыйныфның рус төркемендә туган (татар) әдәбияттан дәрес эшкәртмәсе)

Лифантьева Лилия Гарифулла кызы, М.С. Устинова исемендәге гимназия укытучысы, Казан шәһәре ........................................................................................................................83

**Якташыбыз С.Рәфыйков – «Тамчы» газетасы битләрендә**

(Pablischer программасында юбиляр язучыга багышланган газета саны эшләү буенча түгәрәк яки дәрестән тыш эшчәнлек дәресе)

Шәйдуллина Ландыш Камил кызы, Шәйдуллина Чулпан Камил кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы................................................90

**Кояш гомере телим**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗатына багышланган кичә)

Тәҗмиева Рушания Миннахмәт кызы, Бөреле гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы,

Биектау районы ........................................................................................................................92

**Тарихның “кара таплары”...**

(С. Рәфыйков истәлегенә багышланган ачык чарага сценарий)

Шайхулова Айгөл Илдар кызы, Яңа Кәшер урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, Әлмәт районы ..........................................................................................................94

**Шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага 95 яшь**

Хасанова Миләүшә Мисалих кызы, Иске Ибрай урта мәктәбе укытучысы, Аксубай районы

**Кояш гомере**

(Мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркеме балалары белән Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган күңел ачу кичәсе)

Латыпова Дания Фатых кызы, Тимербаева Зөлфия Зөлфәт кызы, Җәлил бистәсенең 6 нчы санлы “Теремкәй” балалар бакчасы тәрбиячеләре, Сарман районы..........................................101

**Балачак җырчысы – Гөлшат Зәйнашева**

(Гөлшат Зәйнашева иҗаты буенча квест-кичә)

Сафина Резеда Рашат кызы, Күәм урта гомуми белем мәктәбе башлангыч сыйныфлар укытучысы, Әтнә районы........................................................................................................104

**Гөлшат Зәйнашеваның әдәби кунак бүлмәсендә очрашу**

(Сыйныф сәгате конспекты)

Галиәхмәтова Гөлнара Илшат кызы, Бариева-Саетгараева Гүзәл Фирдәвес кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы ..................................................................110

**Гаилә иминлеге кем кулында?**

(Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында якташыбыз Гөлшат Зәйнәшева иҗатына нигезләнеп төзелгән ата-аналар белән түгәрәк өстәл эшкәртмәсе)

Харисова Илзирә Алмас кызы, Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы,Сарман районы ....................................112

**Г.Зәйнашева – күренекле шагыйрә**

(Шагыйрәнең иҗатына һәм тормыш юлына багышланган әдәби- музыкаль кичә конспекты)

Якупова Гүзәлия Фаиз кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы,

Сарман районы .........................................................................................................................115

**Тыңларсыңмы җырларымны?!**

(Тәрбиячеләр арасында Гөлшат Зәйнәшева тормышы һәм иҗатына багышланган КВН)

Хәлиуллина Рүзилә Рубирт кызы,Җәлил бистәсенең 6 нчы санлы “Теремкәй” балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе,Сарман районы ..........117

**Гөлшат Зәйнашева «Кем булырга?»**

(дәреснең технологик картасы)

Чернова Ирина Григорий кызы, Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Зәй районы..........120

**Сарман ягы-талантларга бай як**

(Сыйныф сәгате)

Гыймадеева Римма Зөфәр кызы, Гыйлфанова Ильмира Альберт кызы, Сарман гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучылары, Сарман районы..........124

**Туган ягыбызның моңлы шагыйрәсе**

(шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы, Җиһангиров Айдар Фаиз улы, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы ..........130

**Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты**

(5 нче сыйныфта үткәрелгән сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)

Загидуллина Рүзилә Фирдәвес кызы, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы ..........133

**Сөббух Рәфыйков иҗатына багышланган конференция**

(Сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)

Нуртдинова Гөлнар Сәлихҗан кызы, Салихова Айгөл Роберт кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы ..........135

**Голшат Зэйнашева – татарнын жыр сандыгы**

Гыймранова Эльвина Фәнис кызы,
6 нчы санлы балалар бакчасы тәрбиячесе, Әлмәт районы..........137

**Күңелләрдә яши моңнары**

(Гөлшат Зәйнәшева иҗаты багышланган әдәби кичә)

Галләмова Гөлназ Мөбәрәк кызы, Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Актаныш районы..........138

**И гүзәл туган ягым...**

(Гөлшат Зәйнашева иҗатына күзәтү. 3 нче сыйныфта туган тел дәресе план-конспекты)

Абдуллина Кадрия Галимҗан кызы, Күтәмәле төп гомуми белем бирү мәктәбе башлангыч сыйныфлар укытучысы, Сарман районы ..........142

**Балачакның матур китабы.**

( Китапнамә ясау. Гөлшат Зәйнашева. “Асия”)

Әминова Рима Сөнгатулла кызы, Рәхимова Ризәлә Камил кызы, Р.И.Зарипов исемендәге Байлангар урта мәктәбе башлангыч сыйныф укытучылары, Кукмара районы ..........148

**Г.Зәйнашева иҗатына багышланган әдәби кичә**

(ачык дәрес сценариясе)

Галиәхмәтова Гөлнара Илшат кызы, Бариева-Саетгараева Гүзәл Фирдәвес кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы ..........153

**Гөлшат Зәйнәшеваның 95 яшьлек юбилей кичәсе**

Каримова Регина Нәфис кызы, 2 нче санлы Түбән Мактама мәктәбе укытучысы, Әлмәт районы ....156

**Иң элек син Кеше бул, балам!**

(Гөлшат Зәйнашеваның “Кем булырга?”шигыре буенча 6 нчы сыйныфта үткәрелгән дәрес планы)

Йосыпова Руфина Рим кызы, 2 нче санлы Урыссу гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Ютазы районы ....159

**Г.Зәйнашева “Тукран белән сөйләшү”**

(интеллектуль карта төзү. 2 нче сыйныф укучылары өчен әдәби уку дәресе)

Мияссарова Ләйлә Кәбир кызы, Шангараева Нәзифә Наил кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе башлангыч сыйныф укытучылары, Сарман районы ....163

**Безнең уен**

(Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган интеллектуаль уен)

Хәйруллина Гөлнар Илдар кызы, Балтач урта гомуми белем мәктәбе укытучысы, Балтач районы ....167

**Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган**
әдәби кичә

Шакирҗанова Гүзәлия Зиннур кызы, Галимова Роза Зәкәрия кызы, Мөхәммәдиева Дамира.Заһит кызы,Кече Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Югазы районы ....170

**Туган ягым – гөлләр, сөмбелләр иле**

(Дәрестән тыш эшчәнлек, сыйныф сәгате, түгәрәктә куллану өчен методик эшкәртмә)

Ризатдинова Эльвира Хәниф кызы, «Адымнар – Әлмәт» полилингваль гимназиянең башлангыч сыйныфлар укытучысы, Әлмәт районы ....172

**Тел өйрәнгәндә Гөлшат Зәйнашева иҗаты һәм фигыль турында төшенчә бирү**
(4 нче сыйныфның татар төркемендә туган (татар) тел дәресе)

Шакирова Эльмира Финус кызы, Җәлил гимназиясе укытучысы, Сарман районы ....174

**Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә иҗат ителгән җырлар тарихы**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган әдәби кичәнең план-конспекты)

Ганиуллина Римма Ясир кызы, Сарман гимназиясе педагог-китапханәчесе, Хаҗиева Равия Рафаиль кызы, Сарман гимназиясе башлангыч сыйныфлар укытучысы ....179

**Туган ягым – гөлләр иле**

(9-11 нче сыйныф укучылары өчен Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына багышланган әдәби – музыкаль кичә)

Шәймарданова Лилия Нур кызы, Соловьева Фәнүзә Фәнис кызы, Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы ....184

**Көн исемнәре**

(Зурлар төркеме балалары белән үткәрелгән шөгыль конспекты)

Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы, Җәлил бистәсенең 5нче номерлы” Әкият” балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы ....190

**Талант иясе Гөлшат Зәйнашева**

( Шагыйрәнең туган көнен билгеләп үтү кичәсе)

Шәймарданова Ландыш Атлас кызы, Түбән Мактама 1 нче мәктәбе укытучысы, Әлмәт районы ....192

**Беренче яз – колхоз оешунын беренче язы**

(Сөббух Рәфыйковның “Беренче яз” әсәре буенча 10 нчы сыйныф татар төркемендәге сыйныфтан тыш әдәби уку дәресе)

Галиева Ләйсән Әнвәр кызы, Зиннәтуллина Алина Илдар кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........194

**Адашкан йолдыз**

(Адлер Тимергалин иҗаты буенча)

Сәлимгараева Әлфия Мидхәт кызы, Халикова Лиза Әхәт кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары, Сарман районы ..........196

**Гөлшат Зәйнашева**

(«Кем булырга?» шигыре, «What do you want to be? The world of professions» темасы буенча 6 сыйныф, рус төркеме өчен татар әдәбияты һәм инглиз теле дәресе эшкәртмәсе (катнаш дәрес))

Закирова Әлфия Ринат кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы,Сарман районы, Аскарова Люция Фирдинат кызы, Күлле гомуми урта белем бирү мәктәбе укытучысы, Биектау районы ..........197

**Тамчы – шоу бәйгесе**

(3-4нче сыйныф укучылары өчен класстан тыш чара)

Фәрхетдинова Т.Ф., Хамидуллина А.Х. икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........201

**Югары сыйныфларда функциональ грамоталылыкны тикшерү өчен эшләнгән биремле текстлар**

Шакирова Эльмира Шәрифулла кызы, Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........206

**Тибрәнә җыр күңелдә...**

(Рус мәктәбендә укучы башлангыч сыйныф укучылары белән үткәрү өчен әдәби-музыкаль тәнәфес)

Шәйхелисламова Л.Ф., Бариева Ф.Ф., икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучылары, Сарман районы ..........211

**Гөлшат Зәйнәшева – яралы язмышлы шагыйрә**

(эшлекле уен)

Хәсәншина Фирая Зәкәрия кызы Гомуми үстерү төрендәге"Лилия" №2 балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы ..........214

**Шат күңелле, кояшлы шагыйрә**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның тууына 95 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Сәгъдиева Эльмира Кашаф кызы, Хәкимҗанова Гөлнара Фәрид кызы Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбе, Биектау районы..........218

**Барлык һөнәрләр дә яхшы, барлык һөнәрләрләр кирәк**

Сиразетдинова Гөлшат Рәис кызы Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 6 нчы санлы "Теремкәй" балалар бакчасы, Сарман районы ..........221

**Туган җирнең сайрар былбылы**

(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗаты буенча класстан тыш чара эшкәртмәсе)

Баязитова Гөлфинә Фәһим кызы, Казан шәһәре 117нче гомуми урта белем бирү мәктәбе ..........224

**Гөлшат Зәйнәшева тормышына - иҗатына багышланган башваткыч уены**

Мәхмүтова Резедә Рафаэль кызы, Вахитов районының 14 нче номерлы рус-татар мәктәбе

Казан шәһәре ....................................................................................................................228
**Г. Зәйнәшева иҗаты белән таныштыру**
(3 нче сыйныфта әдәби уку дәресе)
Кашапова Гөлназ Марс кызы, Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ....................................................................................................235
**Гөлшат Зәйнашева. Гөлләр иле**
(Китапханә дәресе)
Ситдыйкова Эльвера Дамир кызы, Мөслим лицее Мөслим районы ...........................................238
**Кем булырга?**
(Г.Зәйнәшева)
Баһавиева Лилия Данис кызы, Вәлиева Зөлфия Фәргат кызы, Яңа Савин районының 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре..........................................................................241
**Гөлшат Зәйнәшева-халыкчан шагыйрә**
(класс сәгате эшкәртмәсе)
Корбыева Гөлчәчәк Фаил кызы, Шәйдуллина Гөлназ Ришат кызы Ләшәү-
Тамак төп гомумбелем бирү мәктәбе Сарман районы ..................................................................248
**Гөлшат Зәйнашева – якты йолдыз**
(шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган дәрестән тыш чара план-конспекты)
Абдуллина Эльмира Валера кызы, Носы төп гомуми белем мәктәбе, Арча районы ................250
**Барысы да чагыла җырымда**
(Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган әдәби кичә)
Даутова Роза Могайяр кызы,Кәүҗияк төп гомуми белем бирү мәктәбенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Сарман районы ..................................................................253
**Иң элек син Кеше бул, балам!**
Гөлшат Зәйнашева иҗаты.“Кем булырга?” шигыре.
Хәмидуллина Алсу Тәкъсин кызы, Урыссу бистәсенең 3 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе, Ютазы районы ........................................................................................................256
**Гөлшат Зәйнашеваның «Кем булырга»? шигыре**
(Дәреснең технологик картасы)
Хәсәнова Гадения Газизҗан кызы, Кече Лызи урта гомуми белем бирү мәктәбе, Балтач муниципаль районы ........................................................................................................261
**Иң элек син Кеше бул, балам!**
(Дәреснең технологик картасы)
Романова Галина Николай кызы, 6 нчы гомуми урта мәктәп, Зәй шәһәре ..................................265
**Мин тормышка гашыйк**
(Гөлшат Зәйнашева тормышы һәм иҗатына багышланган әдәби квест)
Хәсәнова Э.Г., Гыйләҗева Ф.Х., икенче санлы Лениногорск урта гомуми белем бирү мәктәбе ........................................................................................................................................267
**Motherland is… (Родина – это…) из произведений Г. Зайнашевой.**
(технологическая карта урока)
Вәлиәхмәтова Заря Азат кызы, 16 нчы санлы Әлмәт урта гомуми белем бирү мәктәбе
Нуретдинова Айгөл Гамирҗан кызы,икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..............................................................................................................................272

**Мин тормышка гашыйк...**

(Якташ язучыбыз Гөлшат Зәйнашеваның 95 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Мөхәммәтдинова Эльмира Феликс кызы, Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе филиалы

Каташ-Каран төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы ........................................................277

**Иң гүзәл биеклек**

(Күренекле шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашеваның тууына 95 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Магданурова Гөлназ Файз кызы, Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Актаныш районы.........................................................................................................................281

**Бер күрешү – бер гомер**

(Аулак өй кичәсе - бөек шагыйрә Гөлшат Зәйнәшеваның тууына 95 ел тулуга багышлана)

Хәбибулхакова Иркә Мөхәмәтнаил кызы, Петровка завод урта гомуми белем бирү мәктәбе

Сарман муниципаль районы ...........................................................................................285

**Әдәбият дәресләрендә – тарихи чынбарлык**

Г.Г.Хәлиуллина, Илексаз төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы,Сарман районы ...........287

**Барысы чагыла җырымда**

Әсәдуллина Әлфия Мансур кызы, Муртазина Альбина Николай кызы, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе Сарман районы ............290

**Гөлшат Зәйнәшева әсәрләре аша балаларда табигатькә мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү**

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Бәдертдинова Илсөяр Изаил кызы Фазуллина Гөлнар Изаил кызы,

Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы ..........................................294

**Гөлшат Зәйнашеваның иҗаты**

(педагогик проект)

Халитова Наилә Әмирҗан кызы, Горшенина Марина Александр кызы, Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 3 нче "Алёнушка" балалар бакчасы, Сарман муниципаль районы ......296

**Күңелле шигырьләр иртәсе**

(6 -7 яшьлек балалар өчен сценарий)

Дәүләтҗанова Регина Дамир кызы, Җәлил бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 6 нчы "Теремкәй" балалар бакчасы, Сарман муниципаль районы ........................................................301

**PIRLS халыкара тикшеренү критерийларын кулланып « Уку сыйфатын тикшерү һәм текстны аңлау»**

7-8 нче сыйныф укучылары на тикшерү эше

Осипова Людмила Иван кызы, 2 нче урта гомуми белем мәктәбе, Лениногорск муниципаль районы..........................................................................................................................304

**Гөлшат Зәйнашева иҗаты**

«Туган җирем – Татарстан» шигыре.

Гарипова Рүзилә Салихҗан кызы, Ризаэддин Фәхреддин исемендәге 1нче гимназия, Әлмәт шәһәре ..........................................................................................................................309

**Сандугач образы**

(Г.Зәйнәшеваның «Китмә, сандугач» шигыре буенча Осталык дәресе)

Зәйнуллина Эльвира Тимерҗан кызы, 10 нчы күппрофилле лицей, Алабуга шәһәре................312

**Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган**

«Күңелле шигырьләр» иртәсе *(Зурлар төркеме)*
Иксанова Рәмзия Мөдәрис кызы, катнаш төрдәге Җәлил 5 нче "Әкият" балалар бакчасы, Сарман муниципаль районы ........................................................................................................316
**Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе**
(Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе)
Талибуллина Гөлнара Рәис кызы, Җәлил бистәсенең 3 нче санлы "Аленушка" балалар бакчасы,
Сарман муниципаль районы ........................................................................................................319
**... Мин тормышка гашыйк ...**
(Тапкырлар һәм зирәкләр бәйгесе )
Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы, Баһавиева Лилия Данис кызы Яңа Савин районының 43 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Казан шәһәре ..............................................................322
**Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган интеллектуаль уен**
(өлкән сыйныфлар өчен)
Шагалиева Гөлназ Нәҗип кызы, Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Азнакай районы..............................................................................................................................328
**Гөлшат Зәйнашева «Йокла, куяным!»**
(Функциональ грамоталылык, уку грамоталылыгы)
Хабибуллина Гөлнара Флорис кызы Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе филиалы – ..........................................................................................................................................332
“Юлтимер төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы.....................................................332
**Гөлшат Зәйнәшеваның тормышы һәм иҗаты**
Шәйдуллина Айгөл, Алабуга шәһәренең 1 гимназия укытучысы, Алабуга районы...................335
**Гөлшат Зәйнашева «Кем булырга?» шигыре**
Измайлова Гөлназ Фарис кызы, Киров районы 182 нче политехник лицей, Казан шәһәре.......339
**Г.Зәйнашева «Бер атнада җиде көн»**
(уку дәресе)
Исламова Халидә Абдулла кызы, Галләмова Ләйсән Илдус кызы, Яңа Савин районының 23 нче лицее, Казан шәһәре....................................................................................................................342

ӘДӘБИ
ТУГАН ЯК